# АМИРХАН ЕНИКИ

## СОЧИНЕНИЯ
в пяти томах

## 3

*Повести*

Казань
Татарское книжное издательство
2002

# ӘМИРХАН ЕНИКИ

ӘСӘРЛӘР
биш томда

3

*Повестьлар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2002

ББК 84(2Рос=Тат)-44
Е 56

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Т.А.Миңнуллин, Н.С.Фәттах, М.Х.Вәлиев, Н.Т.Ильясова*

**Еники Әмирхан**

Е 56 Әсәрләр, 5 томда. 3 том. Повестьлар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. — 400 бит.

ISBN 5-298-01065-2 ©Татарстан китап нәшрияты, 2002



# ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

*Баязит Бикбайга*

# I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк. Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә аннары иелеп алып чиләгенә сала. Тагын як-ягына каранып эзләп китә. Тагын кизәкне, чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала... Шулай да бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң ул! Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәрне» җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт. Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната, ә үз җае белән әкрен генә кайнап пешкән аш бик тәмле була ул. Әйтерсең чирәм исе керә ашка.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә, яки тиктомалга яндыра да башлый. Үзенчә, мәтрүшкәсенниен эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый. Менә бүген дә, кояш шактый ык кыздыруга карамас-

тан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора; аркасы буйлап әледән-әле салкын кымырҗу йөгереп уза, шул ук вакытта күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк»,— ди ул үз-үзенә иренеп кенә һәм, чиләге кизәк белән тулмаса да, авылга таба борыла.

Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән? Хәер, тәгаен ничә яшьтә булуын ул үзе дә белми. Былтыр гына аның җитмештән узган Миңлегәрәй исемле улы үлеп киткән иде. Хәзер бабай Миңлегәрәйнең зур улы Миңлегалидә тора. Миңлегалинең дә өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызлары бар. Миңлебай карт менә шуларның балаларын, ягъни үз токымының дүртенче буынын күрде. Дүртенче буын әкәмәт икән ул, бер дә бабай дигәнчә түгел. Ул хәтта аларның исемнәрен дә отып ала алмый. Вилне Вилдан дип, Эмманы Әсмабикә дип тик йөртә шунда...

Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде; алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр, ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде.

Ләкин былтырмы икән, өченче ел микән, кемнәрнеңдер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа шулай да исе китте. Кара син аны. Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу, ичмасам, бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан атып йөриләр, имеш. Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә

ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза. Аның хәзер бер генә эше бар — ул ялан таптарга ярата. Һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул, озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм күзе караган якка таба китеп бара. Берәр түбә җиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр. Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр барысы да күмелеп калды шунда...

Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: «Саумы, Миңлебай бабай?» — дип дәшсә, «Ару әле» яки «Шөкер!» дип кенә узып китә. Ни уйлап, нәрсә карап йөри торгандыр карт — белүче юк.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап, аңа:

— Нихәл, арумы, Миңлебай агай? — диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

— Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! — диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле, һәм Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр.

— Каян кайтып киләсең болай? — диде карт.

— Менә кизәк җыярга чыккан идем.

— Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

— Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора,— диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

— Авырма инде, син — ялгыз кортка, карар кешең юк.

— Алладан вакыт җитмәгән булса, үтәр әле.

— Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек,— диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек апак кылдай сакалын селкетеп.— Ярый, кортка, юлыңда бул! — Һәм карт, озын аякларын сыга биреп, китеп тә барды. Ул карчыклар белән күп сөйләшеп торырга яратмый иде.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә ипләп кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә берике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Нигәдер күңеле бүген сызык йөгерткән буш умачны корот катып кына ашарга теләп тора иде. Ләкин карчык сизә, пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана, гәүдәсе менә гел ятарга гына сорап тора... Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрне алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишегалдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

— Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

— Ә, ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят! — диде уңган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты. Аның бик җылынасы килә иде. Ятып күзләрен йомуга, ул, салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте, кымырҗып, акрын гына калтырана башлады. Күпмедер вакыттан соң бераз гына җылынган кебек булды, ләкин тәмам эреп, изрәп китә алмыйча, ярым уяу, ярым йокылы хәлдә һаман бөрешеп кенә ята бирде. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме, дип сорады. Әби: «Локма да кабасым килми, кайнар чәй генә эчәр идем»,—диде. Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде. Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте, Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйтте, тирләп бер йокласам, иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты. Га-

рифә барысын да эшләргә булды, тыныч кына ятарга кушты һәм карчыкның өстен әйбәтләп ябып чыгып китте.

Ләкин карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып үткәзеп җибәрерлек түгел иде. Ниндидер җитди чиргә охшый. Карчык үзе алай дип уйларга тырышмаса да, әллә Ходайдан вакыт җитүе шушы микән дип, шомланып та куйгалый иде.

Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар, Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларына, кызларына хәбәр итикме, болай яту ярамас бит дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята —йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр — шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Шулай көйләнде инде карчыкның тормышы: асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм

ел буе диярлек тик шуңа әзерләнә. Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, коротын да шулар өчен киптереп куя. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта, үзе дә бер бәйрәм итеп кала, бичара. Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар. Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсының эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары балаларыбыз авыл җирендә авырыпнитеп китә күрмәсен дип куркалар да булса кирәк, кыскасы, бер атна торгач та, карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, юатыр өчен кулына мул гына акча тоттырып, вәгъдәләр биргән булып, китеп тә баралар. Шулай итеп, ел буе көтеп алган санаулы көннәр төш кебек кенә үтә дә китә. Аннары тагын шул кыска гына тансык төшнең яңадан иңүен көткәндәй, озын йокыга охшашлы ялгыз гына яшәү башлана.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча торды. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач... Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр. Акъәби үзе кыз чагында башкорттан яки татардан доктор барлыгын ишеткәне дә юк иде. Әле дә хәтерли, элек авылда берәрсенең теше сызласа, моннан унсигез чакрымдагы чуваш авылына, тәмәке алып кайтыр өчен, ат мендереп кеше чаптыра торганнар иде. Булган заманнар. Юк, аның балаларына килде инде бәхет, килде, әйтәсе дә түгел!

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә, тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да,

аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек. Уйлары да, күңелләре дә бүтәндә булса кирәк... Менә зур улы Суфиян. Күпме ил гиздe, нинди зур дәрәҗәгә ирeштe, олайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп җитте, инде хәзер беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар — аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, нindидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. (Суфиян сугышка чаклы ук әле, Саратовта хезмәт иткән чагында, марҗа кызына өйләнгән иде, һәм Акъәбинең ул чакта моңа күңеле бик тә сыкранган иде.) Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора. Полковникның кереп туган авылын күрергә һәм әнисен куандырырга вакыты да, җае да табылмый. Ничек моңа күңел сыкранмасын ди.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читән аша гына карап кала иде. Егет беркөн эчендә Юлкотлының бөтен тирә-ягын йөреп чыкты; машинасына ыбыр-чыбыр балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды, аннары колхоз келәтендә аунап яткан ике потлы гер ташын табып кайтты да иртә-кич гел шуны күтәреп-чөеп уйный башлады.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде — кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр — һәм Акъәбинең моңа бик эче поша иде. Оныгының күңелен табар өчен, ул әледән-әле аңа башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни аңламыйча, «бабушкасына» бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

— А, да-да, точно! — дип, баш кагып куя иде.

Әби белән онык арасында бер кызык хәл дә булып алды. Шулай иртәнге чәй янында оныгын сары майда гына йөзгән әче коймак белән сыйлаган чакта Акъәби «безнең башкорт халкы...» дип нидер сөйли башлаган

иде, Геннадий, шуны үзенчә аңлап булса кирәк, көтмәгәндә генә баш бармагы белән күкрәгенә төртеп:

— Я — башкирин, бабушка, башкирин! — диде һәм, җитмәсә әле «борчылма!» дигәндәй, әбисенә күз дә кысып куйды.

Акъәби уйчан гына аңа карап торды, үзалдына гына күрсенгәндәй итте, аннары моңсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисең, бу җирән чәчле егеттә аның каны, башкорт каны ага иде шул!

Менә шулай Акъәби ялгыз башы шушы көнгә кадәр улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, алар турында үзенең күңелле һәм күңелсез уйларын эченнән генә уйлап, исән-имин генә яшәп килде. Җәйгә чыгу белән, һәрвакыт өметләре уяна торган иде, бәйрәм көннәрен көткәндәй рухланып, шуңа бер дә иренмичә әзерләнә башлый иде. Әмма быел, Ходайдан вакыт җиткәнме, җәйгә аяк басу белән, үзен начар сизә башлады һәм бирешмәскә тырышып йөрде-йөрде дә ахыр чиктә менә урынга ук ятарга мәҗбүр булды.

Башта торып китәрмен дигән өмет белән ятты, күршеләренең калага улларына хәбәр итик дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле аның отыры начарлана барды. Биш-алты көн эчендә ул күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, ашаудан калды. Күршеләре, карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда Юлкотлыдагы колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар.

Колхоз идарәсе моннан алты чакрымдагы Сыртлан авылында иде, шунлыктан Сәетгали кечкенә Юлкотлыда бердәнбер хуҗа һәм баш кеше. Һәр көнне иртән иртүк ул, мотоциклының сиртмәле биленә атланып, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә Сыртланга китеп бара, ә кич белән тагын шулай җен кебек машинасында тумырылып кайтып җитә иде. Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, Сыртланга узышлый, үзенең мотоциклында пырылдап, Акъәбинең капкасы төбенә килеп туктады. Акъәби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм ни өчен икән бу дип борчылып уйлап куйды. Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадир белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинжәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.

— Саумы, Акъәби? — диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.— Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

— Авырыйм шул, Сәетгале,— диде карчык, гаепле кеше сыман итеп.

— Куй, юкны сөйләмә, гомердә авырмаганны... Синең кебек корткага килешәмени ул!

Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды, карчык юрганын үзенә таба җыя төште.

— Килешми дә бит, нишлисең, Ходайдан вакыт җиткәч...

— Җиткән ди сиңа... Болай гына, салкын-фәлән генәдер әле... Кай җирең авырта соң?

— Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр...— диде Акъәби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.

Сәетгали карчыкның суырылган, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды.

— Йә, нишлибез, Акъәби, доктор чакыртыйкмы?

— Кирәкмәс, Сәетгале улым, иншалла, болай да үтәр әле...

— Үтә күрсен! — диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап. Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора.— Әллә, мин әйтәм,— диде бригадир сак кына,— калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса, Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

— Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,— диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.

— Анысын куй,— диде Сәетгали, урыныннан торып, бер әсәйләре өчен вакыт табарлар әле. Ярый, идарәгә баргач, мин Гыйльман агай белән сөйләшермен. Берәр чарасын күрербез. Ә син, әбекәем, тыныч кына ят. Терел.

— Иншалла!.. Рәхмәт керүеңә, Сәетгале улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар. Аннары мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде, һәм озак та үтми, аның тавышы ераклашып, ниһаять, бөтенләйгә тынды.

Ә берничә көннән соң Сыртлан ягыннан Юлкотлыга таба тузан уйнатып килгән өр-яңа яшел «Волга» машинасы күренде. Һәм, озак та үтми, киң урамның күк үләнендә ярылып яткан кара эз калдырып, Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Алар урам тәрәзәләре ябык караңгырак өйгә килеп

кергәч һәм кызының: «Әсәем!» — дип дәшүен ишеткәч, йокылы-уяулы хәлдә яткан Акъәби сискәнеп күзләрен ачты, бер мәлгә өнемме, төшемме бу дигәндәй аптырап, каушап калды, аннары куанычыннан онытылып китеп, капыл гына урыныннан тормакчы булды.

— Кызым, Гөлбикә! — диде ул, өзелеп.

Кызы, шунда ук килеп, аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар тотынышып икесе дә елап җибәрделәр. Мәһабәт кияве дә, килеп, карчыкның кипкән ябык кулын зур, таза кулларына алды, иелә төшеп, күтәренке тавыш белән: «Нихәл, әби җаным, авырып киттеңмени? Ничево, ничево, берни дә булмас!» — диде һәм, пальто чабуын кайтарып, аз гына читкәрәк, сәке кырыена утырды. Кызы да чажлап торган плащы белән әнисенең аяк очына чүкте. Алар икесе бертавыштан карчыкка кузгалмаска куштылар. Ләкин карчыкка кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде, әмма тик, нишләсен, ятарга чарасыз мәҗбүр иде. Шулай да ул түшәк өстенә торып утырды һәм Гарифәгә урам тәрәзәсен чыгып ачарга, тизрәк самовар куярга кушты.

Тәрәзә капкачы ачылгач, өй эче яктырып китте. Акъәби шәһәрчә бик пөхтә киенгән кадерле кызы белән кадерле киявенең чиста, шома йөзләрен күрде. Күрде дә үз хәленнән тагын бер уңайсызланып, елыйсы килеп, авыр сулап куйды. Үз нәүбәтләрендә алар да бик ябыккан, тәмам кечерәеп калган әниләренең зәгъфрандай саргайган, сулган йөзен күрделәр. Күрделәр дә, сүзләрен оныткандай, бер мәлгә тынып калдылар һәм яшерен генә карашып алдылар. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Хәер, колхоздан калага шалтыраткач та, алар карчыкның чынлап авырып китүен белеп, башта ук тәгаен бер ният белән юлга чыкканнар иде. Хәзер исә ике төрле сүз булырга мөмкин дә түгел. Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча, карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.

— Әсәем,— диде кызы, әнисенә үрелеп.— Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

— Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык тиз генә җавап кайтара алмады, аның кинәт күңеле тулды, шул ук вакытта нигәдер бик борчылып та куйды.

— Рәхмәт инде, балалар! — диде ул, бераздан әкрен генә.— Юкка мәшәкатьләнгәнсез, үз өемдә дә терелер идем әле, Ходай насыйп итсә.

— Юк, әсәем, сине хәзер монда калдырып китеп булмый,— диде кызы, кабаланып.— Алып китәбез. Яхшылап дәваларга кирәк сине...

— Өй ялгыз кала бит.

— Калсын, берни дә булмас, күршеләрең карый торырлар.

Карчык бүтән бер сүз дә әйтмәде, авыр сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкә-фәлән эчкәләп кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, Ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына — карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Ләкин ничек итеп менә хәзер ул алырга дип килгән кызы белән киявенең ихтыярына каршы тора алсын? Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар, шуның өчен килгәннәр бит. Юк, авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Чәй урынын карчык янына, сәке өстенә әзерләделәр. Карчык, яткан җиреннән генә, Гарифәгә кушып, үзенең сыйларын — баздан сөтен, маен, чоланнан кәрәзле балын, каклаган казылыгын табынга китертте. Ярлырак та бит, нишлисең, таза чагы булса, үзе тиз генә берәр кайнар аш та өлгертер иде, ә болай кешегә кушып кына буламыни ул. Аннары кызы белән кияве дә: «Борчылма, әсәй, бик әйбәт, бик җиткән»,— дип кенә торалар. Ашыгалар, күрәсең. Алып китәргә дип килгәч, алар үзләре дә бу юлы күчтәнәчләр төяп кайтмаганнар иде. Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфет китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды. Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.

Табын әйләнәсенә утырыштылар. Гарифә чәй ясый башлады. Карчыкка берьюлы рәхәт тә, күңелле дә булып китте. Менә Ходаның рәхмәте, көтмәгәндә генә ул иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле. Аның

өчен елына бер генә килә торган бәхет бит бу, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен. Шуңадыр, ахры, бу минутта аңа никадәр генә рәхәт булмасын, нечкәргән күңеле нидер сизенгәндәй ирексездән ямансулап та, шомланып та куйгалый иде. Хәерлегә була күрсен инде...

Чәй янында сүз дә гел китү белән бәйләнгән эшләр турында барды. Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде шикелле, шуңа күрә күбрәк кызы бу турыда кайгыртып утырды. Аның соравы буенча карчыкның кәҗәсе белән тавыкларын Гарифә карап торырга булды. Келәтнең үз йозагы бар икән, өйне бикләргә дә бер иске богау йозагы бар икән әле, Гарифәгә шуның белән өйне бикләп, ачкычын үзендә сакларга куштылар. Боларны тыңлап утырганда, карчыкның рухы акрынлап һаман сүнә барды. Ахырда түзмәде, өзелергә торган тавыш белән еламсырап әйтте:

— Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен дип уйлаган идеммени мин...

— Әсәем, бу ниткән сүз? — диде кызы, гаҗәпләнгән булып.— Бөтенләйгә ташлап китмисең бит, менә тиздән терелеп, үзең дә кайтып җитәрсең.

Карчык: «Юат инде, кызым, юат!» — дигәндәй, үзалдына моңсу-зәгыйфь кенә көлемсерәп куйды, әмма кайтарып бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Чәйдән соң юлга да әзерләнә башладылар. Кияү кеше ашыга иде, аңа ниндидер бер кичке җыелышка кайтып җитәргә кирәк икән. Ул машинасы янына чыгып китте. Тузан кунган яшел «Волга»ны бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп җиткән. Зурраклары машинаның бөтен ялт иткән нәрсәләрен тотып-сыйпап, әйләнеп йөриләр, тик түбәсенә генә менеп китмиләр. Зур, таза абзый чыккач, алар башта куркып читкә сибелделәр, ләкин тиз үк яңадан машина тирәсенә җыела башладылар. Аларның тынгысыз елтыр күзләре бу шәп агайга, машинасында бер йөртеп килмәсме дигән яшерен өмет белән, гел чекерәеп карап кына торалар. Хәтта бер кап-кара башлы малай әрсезләнеп һәм юмаланып сорап та куйды:

— Агай, ә, агаем, безне анавы очтан гына бер йөртеп килсәң ине!

Мәһабәт агай башын кагып, телен шартлаткан булды:

— Юк шул, малайлар, булмый хәзергә, ашыгабыз. Менә Акъәбиегезне китерә килгәч, мин сезне рәхәтләнеп бер йөртеп кайтарырмын, ярыймы!

Малайлар, Акъәби дигәнне ишеткәч, шунда ук тындылар, артык бәйләнеп тормадылар. Кайчагында алар мәсьәләнең җитдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар каладан кайткан кадерле кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен шулай әдәп саклап, көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Йөзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул — кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тә тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар. Алар артыннан бер хатын зур мендәр күтәреп чыкты.

Кияү машина ишеген ачты. Карчыкны иплəп кенә утырттылар, мендәрен, таяныр өчен, янтыгына салдылар. Кызы янәшәсенә кереп утырды. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде.

— Акъәби җаным, хуш, сау бул инде!

— Акъәби, бәгырем, терелеп кайта күр!

— Хуш, безне онытма, без көтәбез сине! — диделәр аңа.

Ә таякка таянган бер кортка:

— Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен! — диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Гөлбикә иренә тизрәк кузгалырга кушты. Машина алдында торучыларга кыска гына бер гудок бирде дә шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби кинәт урыныннан кузгалып.

— Һай, кәфенлегемне онытканмын лабаса! — диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтелмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм чыраен сытып:

— Куйсана, әсәй! — диде, үпкә катыш рәнҗү белән.— Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

Яшел машина йомшак кына тирбәлеп һәм тузан уйнатып, Юлкотлыдан зур калага таба чыгып китте. Кечкенә өйнең капкасы төбендә җыелышып калган хатын-кызлар бөтерелеп тузан сузылган юл буена, машина күздән югалганчы, тик кенә карап тордылар.

## II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тонык кына ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята. Урыны йомшак, астында чип-чиста ак җәймә, өстендә сатин юрган — ипле, рәхәт аның арыкҗиңел гәүдәсенә... Рәхмәт инде киявенә дә, кызына да — аны менә шулай кадерләп, аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Дөрес, аларны бер дә тыгызлыйсы килмәгән иде килүен, ләкин кияве белән кызы бу хакта авыз да ачтырмадылар. Хәтта элек бу бүлмәдә торган асрау кызларын да кухняга чыгардылар. Тик бераздан гына сизде карчык: монда авыру кешенең яткан җире генә түгел, ашаган-эчкән савыт-сабасы да аерым булырга тиеш икән.

Гомумән, карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп җиттеләр. Чүкечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы хром итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тартынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде.

Әнисе карчык янына күрешә килгәч тә, ул карлыкканрак тавышы белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

— Һай, әсәй, әсәй, әсәем! — диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып.— Ни булды сиңа, авырып киттеңмени, ике күзем?.. Ну, ничево, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип...

— Нәрсә соң ул... пәникә дигәнең, улым?
— Улмы, ул ни... курку, әсәем!
— Мин бер дә курыкмыйм, улым,— диде карчык, тыныч кына.— Тәкъдирдән узмыш юк, барысы да Алла кулында.
— Һи, әйттең тагын! Барысы да безнең кулда! — диде полковник, һаман шаулап.— Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..
— Рәхмәт, улым, рәхмәт!
Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште. Караватъ кырыена урындык алып утырды да, авыруның хәленә керергә теләгәндәй, аңа чын кызгану белән карап тора башлады. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк — карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде. Шулай да Мария Васильевна ире аркылы булса да берничә сорау бирде.
— Әсәй, киленең менә синнән, кай җирең авырта, дип сорый.
Карчык уйчан-моңсу гына әүвәл улына, аннары килененә карады.
— Тыным кысыла,— диде ул, күкрәген күрсәтеп.— Хәлем бер дә юк.
— Күптәнме?
— Тыным бетүен кыштан ук сизә башладым. Ә хәлсезләнүем күптән түгел.
Суфиян карчыкның сүзләрен русчага әйләндергәч, Мария Васильевна иреннәрен мәгънәле генә кысып, башын селкеп торды. Аннары ашыкмыйча гына нидер әйтте.
— Әсәй, киленең әйтә,— диде Суфиян,— опасный берни дә булмас, бронхлары ниткәндер, борчылмасын, ди.
Карчык дәшмәде, тик күзләре белән генә рәхмәтен белдереп, килененә бер тутырып карап алды.
Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Геннадий инде Юлкотлыга барып, әбисендә кунак булып кайткан егет, шуңа күрә ул карчык белән бик үз булып: «Ха, бабушка!» — дип шатланып күреште һәм, урындык алып, караваты янына утырды. Акъәби сөенеп-яктырып, башкортча: «Улым, килдеңмени, рәхмәт төшкерем!» — диде, ә егет аның ни әйткәнен аңлагандай, елмаеп башын какты. Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап

ярата иде — барыбер аның токымы ич, аның каны!.. Нишлисең, якын шул, бик якын!.. Тик егет үзе «бабушкасының» йөрәгендә аңа карата нинди тирән һәм газаплы мәхәббәт ятканын сизәме икән?.. Юк, сизәргә тиеш, әнә килгән бит әле ул, әнә елмаеп әбисенә нидер әйтә дә бит әле... Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

Егет әдәп кушкан кадәр утырганнан соң кузгала башлады, торып, әбисенең кипкән ябык кулын сыйпады һәм: «Пока, бабуся!» — дип баш какты да чыгып китте. Карчык аңардан бик шат, риза булып калды.

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы — Татьяна, Светлана, Рита — белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр. Кызлары да суеп каплагандай әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр... Тик Боря (Борис) гына атасына охшаган, атасы кебек зур башлы, зур битле, арыш чумарыдай кап-кара бер малай иде. Бусын инде бер дә икеләнмичә Суфиян малае Шәяхметов дип йөртергә була.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, дорогая бабушка!» — дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен караватянындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җиңле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән.

Ә Акъәби, үз нәүбәтендә, бу җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя — нидер әйтергә тели, ахрысы... Менә ул күзләрен Боряга төби, әкрен генә кулы белән ымлап, аны якынрак килергә чакыра. Боря курыккандай башын сөзеп, каш астыннан гына карап, кузгалмыйча тора, тик апалары «иди, иди» дип аркасыннан этәргәч кенә, әбисенә якынлаша. Карчык, бердән яктырып, малайның аркасыннан сөеп: «Бәбкәчем,— ди,— зур егет бул, Алла тәүфыйк бирсен үзеңә!» — ди... Малай берни аңламыйча, кызарып, әбисе яныннан тизрәк китә, ә кызлар, нидер әйтеп, шаулап көлешәләр... Карчык исә һич үпкәсез, әмма боексагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул,

үзенеке!.. Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор Акъәби белән бик ачык сөйләште, күп сорашты, аннары күкрәген алдан да, аркасыннан да әйбәтләп тыңлады, тик ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз дә әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп китерде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән... Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты, вакыт-вакыт иреннәрен кысып, авыруга озак кына уйланып карап та торды, аннары яңадан сорашты, яңадан тыңлап карады. Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» — диде. Шуннан соң барысы да залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Акъәби, күңеленә ни генә килсә дә, сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча, тыныч кына ята бирде. Ләкин докторларны озаткannan соң янына кергән кызының бик җитдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды. Дөрес, кызы аңа берни әйтмәде, әмма бу киеренке хәрәкәтсез чырай, бу юри аңа карамаска тырышкан борчулы күзләр хәлнең ничек икәнлеген һәртөрле сүздән дә ачыграк әйтеп торалар иде кебек... Ә хәлләр чынлап та бик шомлы-куркыныч иде: докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торудан мәгънә юк, иң яхшысы — үзенә әйтмичә юатып, тыныч кына яткыру да авыру газабын төрле дарулар белән җиңеләйтергә тырышу — бары менә шуны гына эшләргә мөмкин. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора иде. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Докторлар килеп киткәннән соң, карчыкка игътибар һәм тәрбия тагын да көчәя төште. Кызы белән кияве генә түгел, улы белән килене дә башта әсәйләренә бик йомшак булдылар, гел кайгыртып кына тордылар. Кирәк даруларын да табып китерделәр, күңеле теләгән ризык-

ны да алдыннан өзмәделәр. Гүя алар көннәре санаулыга калган әсәебез алдында соңгы бурычыбызны үтик дип тырышалар иде. Һәм шушы хәл үзе генә дә инде карчыкка күп нәрсә турында сөйли иде кебек... Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя, һәм чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, иң элек бер Алласына сыенып, тыныч кына ята бирә иде.

Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар. Бу шактый читен мәсьәлә иде. Карчыкның кече малае кайтып-китеп йөрмәслек бер җирдә эшләгәнгә күрә, аны, гомумән, чакырып маташудан мәгънә юк иде. Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында балалар врачы булып эшли, җәй көне эше аеруча тыгыз була, шуңа күрә аны да вакытлы-вакытсыз борчырга ярамый иде. Кыскасы, карчыкның хәле бер көерәк торган чакта чакыру белән ашыкмаска булдылар.

...Көннәр үтә, гүя алар зур каланың түбәндәге шаушуы кебек тонык кына гүләп, читләтеп үтә. Колакка сеңгән бу шау-шуның башы-ахыры булмаган кебек, үтеп торган көннәрнең дә исәбе һәм билгесе юк. Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эри-сыза...

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылар өчен бу бик читен хәл: алар үз-үзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, җан җылысымы, борчылып торумы, кимеде кебек. Һәрхәлдә, кайгырту-карау гадәткә кергән мәҗбүри бер мәшәкать төсен алды шикелле. Аннары кызы да, кияве дә бик эшле кешеләр, һәр көнне үзләренең хезмәтләренә йөриләр, шулай булгач, аларның авыру әсәйләренә бөтен игътибарларын биреп бетерә алмаулары бик табигый иде.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать, тик ул көне буе ялгыз ятудан бик туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә.

Кеше тансык, кеше кирәк аңа. Бигрәк тә кызының ике баласын — алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Аларны балалар бакчасына йөртәләр — иртән илтеп куялар, кичкә табан алып кайталар. Алар кайткач, зур квартир тулып, җанланып киткәндәй була. Бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, такы-токы нидер сөйләнәләр, һәм Акъәби ишектән күзен алмыйча аларны көтеп ята. Равиле — малай кеше — әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә, тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга, ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» — дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «Әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.

Кызы Гөлбикә, вакыты тыгыз булса да, кергәләп: «Әсәй, хәлең ничек, берәр нәрсә кирәкмиме?» — дип сорап чыга. Карчык, күңеле булып:

— Рәхмәт, кызым! Кунакларыңны кара, кунакларыңны! — ди аңа.

Ә залда мәҗлес матур гына дәвам итә. Сөйләшеп-көлешеп арыгач, берәрсе пианинода уйный башлый, аңа кушылып, кемдер җырлап та җибәрә. Ә кайчагында исә кунакларның тавышы бөтенләй тына, аның урынына ят бер хатын-кызның ашыгыбрак сөйләгән ясалмарак тавышы ишетелә. Бу инде телевизор дигән нәрсә булырга тиеш. Карчыкның аны әле күргәне юк, ләкин шундый әкәмәт бер әйбер барлыгын, өйдәгеләрнең аны бик көтеп, бик яратып карауларын ул инде белә. Вакыт-вакыт шул «тилевәзир» дигән нәрсәдән бик моңлы курай тавышы да, бик борынгы башкорт җыры да яңгырый... Шул чакта карчык ишекләрне ачарга куша һәм җанына тансык бу җырмоңны тәмам эреп, хыялларга китеп тыңлый. Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.

Әмма кайвакытта бу «тилевәзир» бик әкәмәт нәрсәләр дә күрсәтеп куя, ахрысы. Шундый әкәмәтләрнең берсен

өйдәгеләр «футбол» дип атыйлар. Нәрсәдер инде ул футбул дигәннәре, Хода белсен!.. Ләкин шуны күрсәтә башласалар, хуҗалар да, килгән кунаклар да ашау-эчүләрен дә, дөньяларын да оныталар. Бервакытны шул хәерсез футбул аркасында Акъәби бичара чак җаныннан аерылмады. Тик кенә уйланып ятканда, залдагы бер ханым кинәт:

— Керде! — дип чинап җибәрде.

— Гол! — дип үкереп салды җитмәсә тагын бер ир кеше.

— Әстәгъфирулла, тфү, тфү! — диде карчык, тәмам агарынып.

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә, авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек — утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу — тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!» — дип ике куллап күрешә, аннары урындык алып, карават кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның эчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъәби, Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә.— Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем Акбикә,— ди карчык, бу көтелмәгән сораугa бераз пошынып.— Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

— Димәк, син гомереӊ буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! — дип әйтәсе килеп тора.

— Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкотлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы»* дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

— Ә, шулаймыни? — ди шагыйрь, кызыксынып, һәм карчыктан иплəп кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына. Акъәби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар белән тыңлап утыра... Карчык сөйләп беткәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

— Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди җыр, сулар үргә акса да ди, усал әйтә! Берсе дә — узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

— Килешмичә нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса, сагыныр идем,— ди карчык, уйланып кына.— Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

---

* Кышлау дип борын күчмә башкортларның җәйләүдән соң кыш уздырыр өчен тукталган җирләренә әйткәннәр.— *Ә.Е.*

— Борчылма, улым,— ди карчык, сабыр гына.— Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, Алла бирсә!

— Гаҗәп сүз әйттең, әсәй бәгырем, гаҗәп сүз!..— Һәм шагыйрь, кинәт кенә тураеп, бер аягы белән идәнгә акрын гына суга-суга җырлап җибәрә:

Аппак микән, йомшак микән йәнкәемнең куллары,
Салават күпере кү-ү-үк суга барган юллары.

Онытып кара син бу җырны, онытып кара, мөмкинме соң!..

Шагыйрь тавышы өзелгәндәй шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә. Тик бераздан тынычлангач кына, гафу үтенгәндәй әйтеп куя:

— Син мине тилегә санама инде, яме!.. Нишлим, мин шагыйрь кеше, халык җырын, бөек Тукай әйтмешли, рәсүлнең тырнагыдай йөрәгемдә саклап йөртәм.

— Ә мин Тукайны беләм,— ди карчык, һич көтмәгәндә.

— Китче! — ди шагыйрь, шаккатып.— Кайдан беләсең син аны?

— Суфияннар мәктәптә укыган чакларында: «И туган тел, и матур тел»,— дип бер җыр ятлап йөриләр иде, шуннан хәтеремә кереп калган.

— Суфиян агай «Туган тел»не җырлап йөрдеме?.. Кызы-ык! — Һәм шагыйрь, бөгелә төшеп, тавышсыз гына көләргә тотына: — Их, генерал, генерал!..

Ләкин Акъәбинең җитдиләнеп китүен күргәч, ул көлүеннән шунда ук туктый, иелеп чәчләрен сыпыра, аннары баладай юаш кына әйтә:

— Син мине кичер инде, әсәй, синнән бернәрсәмне дә яшерә алмыйм шул...

— Бик яхшы, улым,— ди карчык, тыныч кына.— Күңелең кешеләргә көзгедәй һәрвакыт ап-ачык булсын!

— Рәхмәт, әсәй, рәхмәт!.. Җиңел, рәхәт миңа синең янда... Тик күп лыгырдап ялыктырам бугай үзеңне... Ярый, кузгалыйм, булмаса, син дә ял ит инде, ял ит, безгә карама, без — әрсез кунаклар!..— Һәм шагыйрь, торып, карчыкның юрган өстендә яткан сап-сары кулын йомшак кына сыйпый да исерә төшкән кешедәй аз гына чайкала биреп чыгып китә.

«Сәер кеше! — дип уйлана карчык аның артыннан,— ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, чын ихластан кызганып кала торган иде.

...Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Бик ябыкты ул, тамагына бернәрсә капмас булды, шуның өстенә тавышы да бетә башлады. Яңадан врачлар килде, карадылар, юаткан булдылар, тагын ниндидер яңа дарулар язып калдырдылар. Хәер, карчык өчен боларның берсе дә кирәкми иде инде. Ул барысын да белеп ята. Шулай ук аның хәлен уллары-кызлары да бик яхшы белеп торалар... һәм эчләреннән генә куркып, шомланып үлемне көтәләр. Карчык хәзер моны үзе дә сизә, карчыкның сизгәнен алар да беләләр.

Ләкин шуңа карамастан һаман: «Әсәй, борчылма, үтәр, терелерсең!» — дип аны да, үзләрен дә алдарга тырышалар.

Карчык соңгы көннәрдә бик уйлана башлады. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Уйлар күп, уйлар төрле-төрле, өзлексез килә торалар, китә торалар... Башта ул чынлап та Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе — яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, маллары — бер генә минутка да исеннән чыкмый... Бөтенесе — өе, алачыгы, киләте, кәҗәсе, тавык-чебешләре — күз алдында тора, бөтенесен ап-ачык ишетә, күрә... Менә кәҗәсе көтүдән кайткач, ишек төбенә килеп, Акъәбине дәшкәндәй, тавышын калтыратып кычкыра торгандыр. Җавап булмагач, тык-тык басып, өйалдына ук керә башлыйдыр... Тавыклары да тибенеп йөргән җирләреннән туктап: «Нигә әле безнең әбиебез күренми?» — дигәндәй, башларын кырын салып, җелт-җелт карана торганнардыр. Казлары да, күл буеннан кайткач, ишегалдында озак кына каңгылдаша торганнардыр да, чыгучы, дәшүче булмагач, боек кына чирәмгә чүгәләшеп, башларын сыртларына салып, йокыга талалардыр... Әйе, алар барысы да әбинең юклыгына гаҗәпләнә торганнардыр, күңелсезләнеп, боегып, моңаеп йөри торганнардыр... Шуларны уйлагач, Акъәбигә гаять авыр булып китә, алар да, үзе дә аңа бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан кайнар яшьләре мөлдерәп агып төшә... Юк, күрмәс инде ул аларны — туып-үскән Юлкотлысын да, гомер иткән өен дә, күршеләрен дә, терлекләрен дә — берсен дә яңадан күрә алмас инде!

Шушы котылгысыз аерылышуны сизеп торганга күрә дә булса кирәк, карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар — җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул курыкмый, ул тыныч көтә бу серле, рәхимсез сәгатьне, тик бер Ходаеннан җан бирү газабын җиңеләйтүне генә со-

рый... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде... китәргә дә була.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: «Инде, мулла-мәзин чакырып, тәхлил әйттерү кебек зур мәшәкатьле эшне сорамыйм да, анысын эшләмәсәләр дә ярый. Әмма ләкин гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде. Аннары, берәр карттан гына булса да, баш очымда Коръән укытсыннар иде...» Авылында булса, аны шулай күмәрләр дә иде, аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп тоткан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул... Ничек кенә булмасын, улы-кызы аның бу үтенечен тыңларга тиешләр. Үзләре ышанмасалар да, кирәксез нәрсә дип тапсалар да, ул кушканча эшләргә тиешләр — бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

Һәм кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

— Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар,— диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән.— Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Менә исемдә чакта әйтеп каласым килә...— Аңа сөйләве авыр иде, әледән-әле тыны кысыла, авызы белән көчкә генә өзеп-өзеп сулышын ала.—Ух, ух, Тәңрем, җиңеллек бир... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне берүк...

Гөлбикә, кызганудан йөзен чытып, шунда ук аның сүзен бүлде:

— Әсәй, әсәем, нигә ул хакта сөйлисең әле... Куй, кирәкми, борчылма, уйлама ул турыда...

— Һай, кызым, ничек уйламыйсың ди, килә бит ул әҗәл, килә, күрмисеңмени?.. Ух, уф... Соңгы сүземне әйтеп калыйм...

— Әсәем, бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә,— диде кызы, кат-кат башын селкеп.— Хәлең юк, тавышың беткән, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

Карчык бераз күзен йомып торды, аннары ничектер хәл кергәндәй тыныч кына әйтте:

— Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул... Сез, яшьләр, шәригать йолаларын белмисез, үзем әйтеп калдырмасам, кем мине мөселманча җирләр?.. Яшнеккә салырсыз да илтеп куярсыз...

Кызы урыныннан ук торды — ул, гадәтенчә, каядыр ашыга иде.

— Юк хәсрәт төшкән башыңа, әсәй!.. Ярар, бу хакта сүзне бетерик... Врачлар киңәшен тыңларга кирәк. Хәзер менә шушы даруыңны эч, бераздан Фатыйма кайнар чәй кертер... Онытма, ямьсез уйларга бирелеп яту синең өчен бик зарарлы ул... Ярый, хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде, тик «бар!» дигәндәй башын гына каккандай итте. Һәм бик озак күзләрен йомып, берни уйламагандай, тын гына ятты. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгыртып ятамыни ул — дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары аның бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Авыр аңа, ямансу аңа, ничектер кинәт бик ятим, бик ялгыз калгандай хис итә ул үзен... Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми. Җәнлек үзенең ярасын ялап төзәткәндәй, ул да җәрәхәтле йөрәген сабыр акылы белән тизрәк тынычландырырга, юатырга ашыга: ярамый болай, язык булыр, ди, балаларымны бәхилләп, ризалыкларын алып китәргә тиешмен, ди. Шәт, алар да мине аңларлар, сүземне тыңларлар, кадерләп озатырлар... Әйе, аның өмете зур һәм әйтер сүзе дә күп әле, күп...

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар — шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзар-курасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр — колхозга бирәләрме, сатып акчасын бүлешәләрме — алар эше.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде. Улының хатыны булгач, ул аңа да якын бит, бәлки, Мария килен дә каенанамның төсе дип бөятне үзендә саклар иде.

Билгеле, кызы — кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр, ул кадәресен генә Акъәби аңлый инде. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка, яшәп килде. Ул менә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Нишлисең, тәкъдирдән узып булмый шул, узып булмый!.. Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Ходаем, туган илкәйгә юл, онытылырга тиешмени соң ата-бабадан килгән андагы тормыш, андагы кешеләр? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил — туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә:

— Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез икегез дә укыган, белемле, дәрәҗәле, зур кешеләр булдыгыз. Икегезнең дә түгәрәк кенә тормышыгыз бар, бер-бер артлы балаларыгыз үсеп килә, үзегез дә инде олыгаеп барасыз. Хак Тәгалә барыгызга да тигез гомер биреп, шул балаларыгызның игелеген күрергә насыйп итсен! Амин!..

Ләкин сезнең дә сабый чакларыгыз бар иде. Сез «Аслы күл» әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы «Аслы күл» Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендырыр өчен атагыз мәрхүм сезне, арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә «Аслы күл»нең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган, нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» әкиятен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар төбеннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын, кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең «Аслы күл» яклары! Һи, ниләр генә сөйләп булмас иде безнең башкорт илләре, башкорт җирләре турында!..

...Мин бераз читкәрәк киттем шикелле, балалар! Әйтәсе килгәнем бүтән иде... Зиһенемне азрак җыйыйм әле... Әйе, менә шул... Сез Юлкотлыда тудыгыз, аның киң урамында чабышып йөрдегез, чирәмендә ятып аунадыгыз... Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз... Бүтәннәрдән бер аермагыз да юк иде, бүтәннәр шикелле үк сез дә ситсы күлмәк, бөрмәле ыштан киеп, ялантәпи йөрүче кап-кара балалар идегез, үскәч кенә менә кем булып киттегез!

...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез. Шунда тел ачкычы таптыгыз, шунда күңел күзегез ачылды... Икешәр-өчәр көн рәттән котырган кышкы бураннарда үзем сезне җитәкләп мәктәпкә илтә торган идем... Атагыз Әлшәй базарыннан, куенына кыстырып, сезгә китаплар, дәфтәрләр алып кайта торган иде... Бик ипле, бик бала җанлы кеше иде ул, мәрхүм!..

Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны да бетергәч, калага китәбез дидегез,— каршы тормадык. Гәрчә сезне бер-бер артлы яныбыздан җибәреп тору авыр булса да, уку — изге эш, без күрмәгәнне балаларыбыз күрсеннәр, безгә насыйп булмаган аларга насыйп булсын дип, хәлебез җиткәнчә һәркайсыгызның өс-башын юнәтеп, акчасын да аннан-моннан табып, сезне ерак юлга озаттык. Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем ашарга утырган саен кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә иде...

Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез, Юлкотлыны сагына идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз? Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз?.. Ике сүзнең берендә «туган ил» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыругтан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә әле исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк сез алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббердән кача, тәкәбберге бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган кечкенә зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк... Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак, кабер җир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең җаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?.. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени? Килә, бик килә, тик күңел саранлыгыннан котылырга кирәк, тик кемгә бурычлы булуыгызны онытмаска кирәк!.. Имештер, яшь чагында көтү көткән, соңыннан бик баеп киткән Өфенең бик зур бер куписы үзенең шул кайчандыр киеп йөргән иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә генә элеп тоткан, ди. Күрәсез, ул да, бахыр, намаз укыган саен шуларга карап, элек кем булуын онытмаска тырышкан. Менә сезгә гыйбрәт!

Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүген-

ге югарылыкка күтәрде — сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Бу аның өчен бик тә кирәк иде, әйтмичә китәсе килми иде, хәтта үлгәннән соң да әйтә алмыйча калган васыяте өчен каберендә борчылып ятар кебек иде. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һәй, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле»,— диделәр. «Сиңа күп сөйләргә ярамый, врачлар кушмый»,— дип гел тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәге шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

— Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

— Китәсең... Кая китәсең? — ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Әй берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

— Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга,— ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

— Юк, китмисең, китмисең!..— ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби үксеп җибәрмәс өчен иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча ята. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә, тагын әйтеп куя:

— Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

— Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

— Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

— Ә нәрсә ул чулпы? Нигә син аны алып килмәдең?

— Онытканмын.

Бала, ышаныргамы, юкмы дигәндәй, әбисенә карап тора-тора да, нидер сизенгәндәй, башын селкеп куя.

— Син алдыйсың,— ди ул, сузып кына.— Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби йөзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый,

ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки, соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, энисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чулпы җибәрми?» — дип сорап йөдәтер. Һәм карчык сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә бернинди шик-шомлану калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

— Юри генә әйттем, бәбкәчем, юри генә! Сине калдырып китәмме соң?.. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң Акъәби гомумән васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт тыелып торды. Әллә ничек шунда һичнәрсәгә исе китмәстәй, һичнәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде. Һәм бары шуны гына ул үз янына ашыгып кына кереп чыккан улы Суфиянга ишетелер-ишетелмәс тавышы белән тагын бер тапкыр әйтеп карады:

— Улым, үтенәм сездән, мине, зинһар, үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде.

Улы Суфиян уйлап та тормыйча:

— Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны! — диде гаҗәеп бер җиңеллек белән: — Менә әйтте диярсең, мөфти хәзрәтнең үзен чакыртам яныңа... Только син, әсәем, үләргә ашыкма әле, яме! Торыйк әле, торыйк, Алласына, мулласына үч итеп дигәндәй...

— Көфер сүз сөйләмә, улым! — диде карчык, сабыр, җитди генә.

Ләкин Суфиян авыру кешегә бердәнбер кирәк нәрсә, ул да булса (үз сүзе белән әйтсәк), бодрость дип белә иде. Шуңа күрә ул һәр сүзне уенга бора, үзенчә шаяртмакчы-көлдермәкче була. Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып та китә иде. Ә карчык, бичара, ни уйларга да белмичә, аның артыннан башын гына чайкап кала. Чынлап әйттеме ул, юри генә әйттеме, нигә утырып, әйбәт кенә сөйләшмәде соң, кая ашыга, кая чаба ул? Гаҗәп бу шәһәр халкының гадәте — барысы да каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар!..

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды. Бала шикелле тәмам кечерәеп калды, күзләрен дә инде йөртә алмый башлады.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр — торса, тагын бер атна-

ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тутырды. Димәк, әсәй карчык китә!.. Һәм бик ачык, котылгысыз булып алларына килеп баскан бу гаять авыр, хәсрәтле үлем аларны тәмам аптырауга төшерде. Хикмәт шунда, үлем дигән нәрсә аларның өенә беренче мәртәбә керә әле, моңарчы аларның мондый фаҗигале хәлне күргәннәре дә, кичергәннәре дә юк иде әле... Борчылмыйча, уйланмыйча һич мөмкин түгел. Иң элек карчыкның үлеме балаларга бик авыр тәэсир итәчәк, куркытачак бу нәрсә аларны... Аннары мәетне юу бар, җыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич тә белмиләр. Кемнән эшләтергә, ничек эшләтергә боларны? Түбәндәге дворник хатыны Сәрбиҗамал апага әйтсәң, ул бик теләп боларның барысын да оештырыр иде... Юарга, кәфенләргә карчыкларын да табар иде, бәлки мулласын да чакырып китерер иде. Ләкин болар барысы да гаять мәшәкатьле эш бит, әллә ничек күңелсез эш. Кияве, бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый. Мөселманча булсын дип әллә нинди карчыкларны, муллаларны үзенең квартирасына бер дә китерәсе килми аның.... Килешми аның хәлендәге кешегә бу нәрсәләрнең берсе дә. Ничектер бүтән юл, бүтән чара табарга кирәк бу положениедән чыгар өчен...

Кияве белән кызы арасында шушы хакта берничә көн буена сүз барды. Гаять четерекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин шулай да ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр. Хәер, асылда аларның фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә, бик авыр, бик күңелсез булачак.

Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк,— диде.— Больницада әле аңа яхшырак та булыр, урын-җире чиста, врач көн дә карап тора, сестралар һәрвакыт янында, үзебез дә чиратлашып янына баргалап торырбыз... Нишлисең инде, үләргә булгач, кайда да барыбер... Аның каравы, балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп, тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар... Аннары больницада мәетләрне әйбәтләп юындырып, киендереп озатучы махсус кешеләр дә бар. Ә без үзебез монда нишли алабыз?.. Юк, иң яхшысы — больницага салу инде...»

Гөлбикә бу эшнең күңелгә авыр, оят, килешмәгән ягын белсә дә, уйлый-тора ахырда риза булды. Шулай сөйләшеп килешкәннән соң, алар үзләренең бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште.

— Што сез,— диде кычкырып,— кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз! Оятын ничек күтәрерсез, хурлыгын кая куярсыз?.. Юк, юк, мин моңа асла риза түгел!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

— Каенагай, оят мәсьәләсендә синең безгә бер сүз әйтергә дә хакың юк. Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык, терелмәсме дип бөтен чараларны күрдек... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер, дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзеңә аласың... Сиңа да ана бит ул!.. Әмма мин әсәйнең үлгән чагын балаларга күрсәтеп, аларның йөрәкләрен җәрәхәтләргә теләмим.— Һәм шунда ук, каенагай тагын дулап китмәсен дип булса кирәк, иплəп, йомшартып кына әйтте: — Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез. Авыруны больницага салуның һичбер гаебе юк. Беркем бер сүз әйтмәячәк. Инде анда үлеп китә икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп, бөтен шартын җиткереп, соңгы юлына озатырбыз. Ә өйдән мәет озату бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул, син безнең хәлебезне аңларга тиешсең, Суфиян!

Бу сүзләрдән соң Суфиян шактый аптырауга төшеп, үзенә терәк эзләгәндәй, алмашлап бер сеңелесенә, бер хатынына карады. Ире артына посыбрак, бөрешеп кенә утырган сеңелесе гүя бөтен кыяфәте белән: «Миңа карама, мин арыдым, мин берни дә эшли алмыйм»,— дип әйтеп тора иде. Ә юан ак беләкләрен зур күкрәкләре өстенә кушырып салган хатыны, бу мәсьәлә аңа һич кагылмагандай, йомык бер битарафлык саклап утыра иде. Суфиян акрын гына җилкәсен кашырга тотынды.

— Шулай, каенагай! — диде кияве, аның хәлен җиңеләйтергә теләгәндәй.— Борчылырлык урын юк, барысы да бик әйбәт булыр, менә күрерсең!

Һәм Суфиян бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Кияү, билгеле, бу эштән читтә калырга теләде, чөнки ул, нинди генә якын кеше булмасын, карчыкның үз баласы түгел... Шуңа күрә улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй, җаным,— диделәр алар аңа иплəп кенә,— докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син

борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның чын сәбәбен сизгәндерме, юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар, кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым җитте, аңлагыз шуны!» — диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар, киендереп чыгардылар һәм «Волга» машиналарына кырын яткырып, алдан кияве сөйләшеп куйган бер больницага илтеп салдылар.

...Өч тәүлек үтүгә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй тавыш-тынсыз гына киткән дә барган. Әйтерсең үзенең Юлкотлысына...

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Алар килгәндә, Акъәбине үлекләр ята торган цемент идәнле таш бүлмәгә төшереп куйганнар иде инде. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар. Йөзе бер дә бозылмаган иде, киресенчә, ничектер авыр газапларыннан котылып, тынычланып калган кебек иде. Әмма күзләрендә ни торып калгандыр, анысын күрмәделәр — күзләрен кемнеңдер бармагы сак кына йомдырып куйган иде.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек итеп җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җеназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр дә икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар. Бер чиста күлмәген китереп өстенә кидерделәр, башына «мөселманча» итеп ак батист яулык бәйләделәр, шуннан соң гәүдәсен кечкенә кызыл табутка салдылар. Табут әйләнәсенә чәчәкләр тезделәр, күп итеп ислемай сиптеләр, һәм Акъәбиебез хәйран матура-

еп китте. Ул бичара, хәтта көлемсерәп яткандай күренә башлады.

Зиратка табутны машинага куеп илттеләр. Озата баручылар күп түгел иде; иң якыннары да аларның кайбер дус-ишләре һәм шулар арасында әлеге кечкенә буйлы шагыйрь дә бар иде. Ләкин ул бүген дә кызмача иде шикелле.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, килене Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Кияве, иреннәрен кысып, читкәрәк китте. Ә улы Суфиян, әсәен озату шәрәфенә, бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник, кабер кырыенда таш сындай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

...Күмеп бетергәч тә, борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь, ак балчык өеме янына басып, мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

— Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек,— диде ул, ашыкмыйча, салмак кына.— Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?.. Күрә белдекме без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян кычкырып аның сүзен бүлде:

— Син ни сөйлисең, ә?! Ташла, кирәкми...

— Безобразие бу! — диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Бу күңелсез тамаша аркасында озата килүчеләр яңа гына кабергә куелган Акъәбине ничектер онытып җибәрделәр. Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, аңа әһәмият бирмәскә, сүзне уенга борырга тырыштылар. Һәм үзара сөйләшә-шаулаша кабер яныннан тарала да башладылар. Иң ахырдан кузгалган

Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда, кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше-тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук карчыкның колхоз машинасына салып җибәргән иске яшел сандыгы да килеп төшә. Күрәсең, яхшы күңелле Гарифә үзенчә бер изгелек эшләргә теләгәндер инде, ләкин монда ул сандыкны берәү дә әле көтми иде. Яңа гына кичергән кайгы-мәшәкать аркасында, гомумән, Юлкотлыда калган өй-нигез турында да, башкасы турында да уйлашырга өлгермәгәннәр иде. Инде менә әсәйләренең үзе белән бергә картайган, буявы да уңып беткән иске сандыгы: «Мин сезнеке, мине нишләтәсез?» — дигәндәй, Гөлбикә квартирына килде дә керде. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте, бер мәлгә аптырап-каушап калгандай булды. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты. Шул ук көнне кичкә таба агасы белән җиңгәсе Мария Васильевна, зур уллары Геннадийны да ияртеп, аларга килеп тә җиттеләр.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, тик ак материяне сак кына бер читкә алып куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәңкәле кара җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле кара кәзәкие белән камчат бүреге дә килеп чыкты — карчык шушы көнгә

кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!.. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.

Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.

— Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бит бу! — дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

— Да-а, менә бу, ичмасам, реликвия! — диде кияве дә, сокланып.— Тик кем саклар аны?

— Ә аның хуҗасы бар,— диде Суфиян, катгый рәвештә, һәм улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте: — Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу!..

Һәм Геннадий Шәяхметов баш кагып, елмаеп кына өч җәпле камчыны кулына алды.

...Инде калган әйберләрне нишләтү, ничек бүлешү мәсьәләсе кузгалды. Белгәнебезчә, әсәйләренең бу хактагы теләген алар тыңламыйча калдылар. Шулай да һәркайсы үзенә ошаган нәрсәне алырга хаклы иде. Ләкин бу тәңкәле җилән, хәтфә камзул, бөят, кашмау, чәчкаплар белән алар нишләрләр икән?.. Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач, череп-тузып кына бетәрләр... Шул чакта кияүләренең башына бик шәп бер идея килде. Ул болай диде:

— Менә нәрсә, Гөлбикә, каенагай! Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит!.. Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә, киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр. Чын, уйлагыз әле!

Бу фикергә шунда ук Мария Васильевна да кушылды:

— Бик дөрес әйтәсез, Сәхип Карамович, безгә нигә алар, артистлар кисеннәр.

Ләкин Суфиянга да, Гөлбикәгә дә мондый тәкъдим белән тиз генә килешүе авыррак иде. Ничектер күңелләре тартып бетерми иде. Әллә ничек менә әсәйләреннән яхшы түгел кебек — алар өчен саклаган, аларга дип калдырып киткән бит әле ул... Инде тот та бөтенесен кочагы белән театрга илтеп ташла! Килешерме, оят булмасмы?

Шул ук вакытта кияүләренең сүзендә дә дөреслек бар: бүлешеп алсалар, әрәм-шәрәм булып кына бетәчәк, ниш-

лисең, тәңкәле җиләннәр, укалы камзуллар заманы үтте шул инде!.. Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен киемсалымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә... Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә. Ыштан балагын эчкә тыгып кигән ак оекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән, әйтерсең Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

— Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми — ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган, ахрысы, бу картка»,— дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

— Алдама,— ди ул, таягының башын селкеп.— Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөзьяшәр Миңлебай карт!

*1965*

# ВӨЖДАН

Бәкер дус, ялгышмасам, менә утыз биш ел инде безнең очрашканыбыз юк. Уйласаң, шактый гаҗәп бит бу!.. Син Казанда, мин Ташкентта — бу ике араны халык гел йөреп тора, аннары йөрү дә хәзер бик ансатлашты — самолетка утырсаң, дүрт-биш сәгатьтән, әйтик, Казанда буласың. Ә шулай да без күрешә алмыйбыз. Ни өчен, сәбәп нәрсәдә? Күрәсең, кеше бары үзе теләгәнчә генә йөри алмый. Йә сылтавы табылмый, йә җае чыкмый, йә вакыты булмый. Мин үзем, мәсәлән, Себердән алып Кавказга чаклы күп кенә шәһәрләрдә булдым, ә менә Ташкенттан кул сузымында гына торган күрше Фрунзеда була алганым юк. Барып күрәсем бик килүгә дә карамастан...

Казан исә минем өчен башка исәптәге шәһәр, кайта алмавымның сәбәбе дә башкада. Казанда мин укыдым, эшләдем, иртә яшьлегемне шунда үткәрдем, хәтта беренче мәхәббәтемне дә шунда кичердем. Туып-үскән җирем дә Казаннан ерак түгел... Кыскасы, минем үз шәһәрем ул, туган-туфрагым кебек үк якын, кадерле ул миңа... Әмма, шулай булуына карамастан, минем юлым Казанга күптән өзелде. Сугышка чаклы бөтенләй кайтасым да килмәде, ә сугыштан соң бер генә тапкыр кайткан идем, анда да дүрт-биш көннән артык тора алмадым (отпускамның ахыры иде). Ләкин син, Казанга минем ниндидер үпкәм бар икән дип уйлый күрмә. Казан үзе, әйткәнемчә, миңа якын, кадерле, сагынам да, онытмыйм да мин аны... Ә ташлап китүемнең, аннары кайтмыйча йөрүемнең сәбәбе башкада.

Менә шул сәбәпне мин сиңа сөйләргә җыенам, Бәкер дус!.. Үзең беләсең, безнең арада кайчандыр кыска вакытлы, әмма шактый якын, керсез дуслык булып алды. Сиңа ничектер, ләкин миңа калса, яшь чактагы дуслыктан да ныграк, сафрак дуслык юк шикелле... Олая башлагач туган дуслыклар нигәдер ул хәтле бик тирәнәеп, ныгып китә алмый. Күрәсең, яшь чакта без ихласрак, эчкерсезрәк, саф күңеллерәк була торганбыздыр. Шуңа күрә безнең дуслыгыбыз да һәртөрле исәп-хисаплардан өстен торгандыр инде.

Ләкин озак еллар күрешмәгәч, мондый дуслык та әкренләп суына, сүнә бара, әмма бөтенләй үк онытылмый, ничектер үзеңнең ерак яшьлегең төсле һаман күңелдә саклана. Без дә, Бәкер, синең белән бик ераклаштык, ике төрле кешегә әйләндек, уртак нәрсәләребез дә калмады диярлек. Ә шулай да менә хәзер мин сиңа үземнең, русча әйтсәк, исповедымны (бу сүзнең татарчасы юк шикелле) язарга керешәм. Чөнки мин яшьлегемә кайтам, ә яшьлегемдә иң якын дусларымның берсе булып син торасың. Ерак булсаң да, үзгә булсаң да, сиңа сөйләү минем өчен җиңелрәк.

Аннары соңгы вакытларда безнең хат язышa башлавыбыз да минем телемне чиште. Ул хатлардан син инде минем кайда, кем булып эшләвемне беләсең. Шулай ук минем өйләнмичә ялгызак кеше булып калуым да сиңа билгеле. Бу соңгы хәл синдә зур кызыксыну уятты булса кирәк, менә икенче тапкыр инде миннән: «Хәбиб, ничек ул алай килеп чыкты, нишләп өйләнмичә калдың, сәбәп нәрсәдә?» дип сорап язасың... Әйе, бик четерекле сорау, үтә шәхси, нечкә, авыр мәсьәлә бу минем өчен... Моның сәбәбен мин бервакытта да, беркемгә дә сөйләмәдем. Теләгем дә булмады, кирәк дип тә тапмадым. Дөресен генә әйткәндә, баштарак сиңа да язасым килмәгән иде. Ләкин син, Бәкер, үзеңнең хатларың белән ничектер минем еллар күмеп киткән, иске дәфтәр шикелле каядыр онытылып яткан хатирәләремне кузгаттың. Һәм менә котылгысыз рәвештә шуларны, ниһаять, сиңа сөйлисем килү теләге туды... Бел, бары сиңа гына...

Әлбәттә, мин бөтен үткән гомеремне сөйләргә җыенмыйм — бу хәзергә мөмкин эш түгел. Мин бары башымнан кичкән бер вакыйганы гына сөйләп чыкмакчы булам. Ләкин бу вакыйга үзе дә сиңа минем ни өчен Казаннан китүемне, озак еллар кайтмыйча йөрүемне, шулай ук ни өчен өйләнмичә калуымны да аңлатып бирер дип ышанам... Ә хәзер вакыйганың үзенә дә күчәргә була.

## I

Утызынчы елның җәй башында мин, ниһаять, рабфакны бетереп чыктым. Яхшы укыдым, яхшы тәмамладым... Билгеле, мин шат идем. Шактый биек тауга менеп җиткәндәй ничектер җиңеләеп бер сулыш алдым, әмма шул ук вакытта миңа бераз ямансу да иде. Дүрт ел гомер үтте дә китте. Дүрт ел буена ияләшкән, күнегеп беткән нәрсәләрдән — рабфак бинасыннан, класс-аудиторияләрдән, тулай торактан, шул торак белән рабфак арасын бергә таптаган иптәшләрдән аерылыр көн дә ки-

леп җитте. Аерылышыр вакыт җиткәч, кешегә вак кына, юк кына әйберләр дә бик якын булып тоела башлый икән. Ничектер аларны тиз генә онытып булмас кебек... Мәсәлән, шул ук торакны (элеккеге «Франция» номерларын), аның иләмсез биек түшәмле, ун-унике кеше сыярлык зур бүлмәсен, бүлмә уртасында кара белән буялып, пычак белән тамгаланган озын, шәрә өстәлен, бакыр чәйнеген, калай кружкаларын, ниһаять, тар, шыгырдавык тимер караватын... Бигрәк тә шушы капчык матраслы, соры одеаллы, уртасы батып төшкән алама карават бер дә онытылмас кебек иде... Чынлап та ул замандагы, әллә лазаретлардан, әллә казармалардан җыеп китерелгән төрле иштәге, әмма барысы да иске студент караваты берәр музейда сакланмыймы икән — рәхәтләнеп үзенә тагын бер карар идем. Күпме хыяллар, күпме татлы уйлар, сагыш-уфтанулар, матур һәм ямьсез төшләр күреп уздырмадык без шул туйдырып бетергән, үзе шыгырдык, үзе чыдам караватыбыз кочагында!..

Әйе, боларның барысы да искә төшереп сөйләргә генә калды. Син беләсең инде, рабфак — укуның ярты юлы гына, аны бетергәч тә ВУЗга китәргә кирәк. Теләсәң кайсына — рабфак бетерүчеләр өчен бөтен җирдә ишекләр ачык. Ләкин мин, уйлап тордым да, бу мөмкинлектән файдалануны бер елга кичектерергә булдым. Ник дисәң, дүрт ел буена баш күтәрмичә уку шактый ялыктырды, аннары иң начары — матди яктан бик бетеренгән идем. Стипендия такы-токы ашаудан артмады, беркайдан бернинди ярдәм юк, очы-кырые күренмәгән өзлексез кытлык. Бигрәк тә кием-салым бик хөртиләнде: аякта ямаулы ботинкалар белән ертык галош, өстә иләнә-иләнә аркау җепләре чыга башлаган пинжәк-чалбар, ә кышкы пальто инде ул, бичара, студентның үзе кебек чыдам — икенче шәхесеңә әйләнеп дигәндәй өстендә йөри дә йөри. Алыштырып-яңартып җибәрергә һич рәт юк. Син дә хәтерлисеңдер әле: мин җәйге каникул вакытларында авылга әнине күрер өчен бер-ике атнага гына кайтып килә идем дә, аннары көзгә чаклы диярлек пристаньда яки станциядә йөк бушатып, өс-башлык акча эшләргә тырыша идем. Тик рәхәтләнеп эшләргә эше генә гел булып тормый иде. Кыскасы, чынлабрак акча табасы, ВУЗга кергәнче ничек тә бер бөтенәеп, яңарып аласы килде. Болар өстенә тагын шундый уй да бар иде: гел уку да уку, ә тормышны юньләп күргән юк, ул әнә ашыга-ашыга ничектер читләтеп үтеп бара. Бер елны югалтканнан ни булыр?.. Ичмасам, чын хезмәт дигән нәрсәне татып, үзем теләгәнчә бер торып та алырмын. Бәлки, бу миңа

киләчәк профессияне сайлау мәсьәләсендә дә ярдәм итеп куяр... Әнә шулай уйлап, мин, әйткәнемчә, ВУЗга китүне бер елга кичектереп торырга һәм эшкә керергә булдым.

## II

Ул елларда безнең Казанда мех эшкәртү производствосы бик кызу гына үсә башлаган иде. Кыска гына арада Яңа бистәдә мех фабрикасы ачылды. Гел татарлар гына тыгызланып утырган бистәдә чын фабрикалар ачылу — бу, һичшиксез, зур вакыйга иде. Бистә тормышына, политэкономия теле белән әйтсәк, яңа производство мөнәсәбәтләре керде. Анда яшәгән җыен кустарь, ломовой, вак сәүдәгәр халкын шул фабрикалар үз эчләренә тарта башладылар... «Кайда эшлисең?» дип сорагач: «Меховойда!» дип кенә җибәрүчеләрне еш очратырга була иде... Газеталар да меховойлар турында мактап һәм мактанып язарга тотындылар... Индустриализация башланган вакытлар иде бит.

Менә шуның тәэсиренә бирелеп булса кирәк, мин дә Яңа бистәгә таба юнәлдем. Яңа җир, яңа эш, мин әйтәм, хезмәт юлымны шуннан башласам, начар булмас иде, дим. Ләкин мехның нәрсә икәнен әзрәк кенә белсәм дә (әти мәрхүмнең читенә кама тоткан бәрән туны бар иде), аның ничек эшләнүе турында һичбер хәбәрем юк иде. Яки болай дип кенә белә идем: матур мамык тиреле җәнлек урманда чабып йөри, аны атып яки капкынга эләктереп алалар да, шуннан соң тиресен сыдырып, иләп-йомшартып якага куялар... Менә шул. Ә фабрика чаклы фабрикада аны нишләтәләр, бу кадәресен күз алдыма да китерә алмый идем.

Ул вакытта инде фабрикалар белән идарә итәр өчен «Мехкомбинат» дигән нәрсә дә оештырылган иде — мин менә шунда барып кердем. Август башларында булды бу — аңарчы авылга, әни янына кайтып килгән идем... Мехкомбинатта мине яхшы каршы алдылар. Сораштылар, документларымны карадылар, ләкин яңа гына рабфак бетергән, моңарчы әле бер җирдә дә эшләмәгән «яшел» егет булуымны белгәч, бераз уйга калдылар. Кая, нинди эшкә алырга?.. Белеме бар, әмма бернинди тәҗрибәсе юк кешегә лаек эш табу, күрәсең, җиңел түгелдер... Мин үзем исә теләсә нинди эшкә керергә, хәтта өйрәнчек булып эшли башларга да риза идем. Шулай да бераз уйлашканнан соң миңа әйттеләр: сезне фабриканың берәр цехына кара эшче яки өйрәнчек итеп алудан мәгънә юк, чөнки рабфак бетергән кешене кара эшче итеп алу просто килешми, ярамый, ә өйрәнчекнең хезмәт

хакы бик кечкенә. Шуңа күрә без сезне, әгәр дә риза булсагыз, мехбазага җибәрәбез, анда укыганрак егетләр кирәк, эше дә чистарак, диделәр.

Ә нәрсә ул мехбаза һәм кем булып мин анда эшләргә тиешмен?.. Мехбаза ул бөтен фабрикаларның эшләп чыгарган әзер продукцияләре керә торган җир икән. Анда әзер мехларны сортларга аералар, кләймә сугалар, сорты-сорты белән бәйләп, ящикларга салып, алдан килгән наряд буенча төрле шәһәрләргә озаталар. Мехларны дөрес итеп сортларга аеру шактый нечкә, җаваплы эш икән. Чөнки аларның күбесе экспортка китә, имеш. Бу эштә зур квалификацияле белгечләр эшли икән.

Мин менә шул мехбазаның каракүлләр цехына өйрәнчек булып барырга тиешмен. Андагы өйрәнчекләрнең хезмәт хакы да, фабрика өйрәнчекләренә караганда, шактый өстен икән. Шул ук вакытта мине цех начальнигының ярдәмчесе итеп тә билгеләделәр — әлбәттә, аерым хезмәт хакы белән. (Өйрәнчекне бер үк вакытта начальник ярдәмчесе итеп кую хәзер бик сәер тоелыр, ләкин ул заманда һәм яңа оешкан производствода андый хәлләр була иде, моның үз логикасы, үз политикасы бар иде.)

Озын сүзнең кыскасы, әнә шулай эшкә урнашып, мехчы булып киттем мин... Мехчы абзагызның матди ягы да бер ай эчендә диярлек шәбәйде: кырык сум да алтмыш сум — барлыгы йөз сум, ә ул заманда бу шактый зур акча иде. Сентябрь башында ук инде мин хәзерге Куйбышев урамындагы бер марҗадан кечкенә бүлмә табып, рабфак торагыннан шунда күчтем. Бүлмә ишегалды түрендәге бер генә катлы таш йортта иде, тыныч, аулак, урам шау-шуы бөтенләй ишетелми диярлек. Караваты, өстәле, урындыгы, хәтта трюмо көзгесе дә бар — прәме җәннәт! Минем бит әле үз гомеремдә беренче тапкыр аерым бүлмәдә торуым — рәхәт нәрсә икән ул. Дөрес, башта минем белән шул ук мехбазадан Вафа исемле егет тә торды. Ләкин озак түгел — бер ай, ай ярымнан үзенә бүлмә табып, чыгып китте.

Толчоктан мин бер тотылган будильник сатып алдым. (Каплап куйсаң гына йөри торган иде.) Һәр кичне үзен сәгать алтыга борып куям, һәр иртән шуның калтырана-калтырана чәрелдәвенә уянып китәм. «Җитәр, көчек!» дип тиз генә сикереп торам, әйбәтләп салкын су белән юынам, аннары кухняда гына Серафима түтәйнең берәр стакан куе чәен эчәм дә, салкынча тын иртәдә гаҗәеп бер тән һәм җан җиңеллеге тоеп, батыр басып, эшкә юнәләм. Һәрхәлдә, бүгенге язмышымнан мин бик канәгать!..

## III

Мехбаза Бауман урамындагы элекке ломбард йортына урнашкан иде. Бу — шәһәрдәге иң зур, иң биек йортларның берсе. Анда кайчандыр ломбард булуын без инде белмибез — бөлгенлеккә төшкән чакта артык киемеңне илтеп салып, бурычка акча алып тору күптән бетерелде, ләкин йортның һәр катындагы ялан кадәр заллары үзләре үк аларның кеше малын, кеше күз яшен җыяр өчен махсус ясалган булуын әйтеп торалар иде. Менә шул йортка хәзер һәркөнне Казан мех фабрикаларыннан эшләнеп чыккан «йомшак алтын» йөге-йөге белән килеп керә һәм, безнең куллардан үтеп, чит илләргә, төрле шәһәрләргә китә тора.

Мехбаза, әйткәнемчә, күптән түгел оештырылган үзенә бер мөстәкыйль хуҗалык иде. Аның үз җитәкчесе (управляющие), үз конторасы, үз штаты, үзенең партия һәм профсоюз оешмалары бар. Банк белән дә турыдан-туры үзе эш итә. Кешеләрне эшкә алу яки эштән чыгару да аның үз кулында — мехкомбинат бу очракта тәкъдим итүче, җибәрүче генә... Тагын шуны да әйтергә кирәк, мехбаза фабрикаларның әзер продукцияләрен алып торучы гына түгел, аларны чимал белән тәэмин итеп торучы да иде... Моны снабсбыт диләрме?.. Кыскасы, биреп эшләтүче һәм эшләткәнен сатып ятучы бик бай бер фирма сыман оешма иде ул. Ике йөз иллеләп кеше эшли иде үзендә...

Мехбаза яңа оешкан бер хуҗалык булгач, аның бөтен коллективы да, билгеле, яңа иде, ягъни бер вакыттарак җыеп алган кешеләрдән тора иде. Боларның бер өлеше мехкомбинаттан килгән, сайлап куелган яки билгеләнгән җитәкче кадрлар, икенче зур өлеше төрле җирләрдән чакырылган квалификацияле белгечләр һәм шуларга өйрәнчек итеп алынган яшь егетләр, яшь кызлар... Белгечләр дигәнебез мехны танучылар, мехны сортларга аеручылар, аларга бәя куючылар... Мехбазаның тоткасы алар. Нинди мех кайсы сортка керә, кайсысын экспортка җибәрергә ярый — бары тик алар хәл итә... Тагын иң кызыгы шунда, бу белгечләрнең күпчелеге, бигрәк тә бөтен каракүлчеләр Мәскәү, Ленинград тирәсеннән табып, чакыртып китерелгән мишәрләр иде... Маматов, Байтирәков, Ишмаметов, Ширинский кебек ничектер ихтыярсыздан хөрмәт уята торган фамилияләр... Болар, һичшиксез, зур осталар, кайчандыр Мәскәү фабрикантларында (мәсәлән, Ирзиннарда) һәм Ленинград аукционында эшләгәннәр, ә кайберләре элегрәк үзләре дә мех белән сәүдә иткәннәр. Хәтта аларның берсен, Ишмаметовны, Бохара әмиренең

каракүлләрен чит ил купецларына сатып торучы булган дип тә сөйлиләр иде. Болар инде, иптәшкәй, каракүл нәкышләрен нәфис гарәп язуын укыгандай укый-таный беләләр. Шуңа күрә дә мехбаза аларның күбесен, һәркайсы белән аерым договор төзеп, зур хезмәт хакы бәрабәренә чакырып китергән иде.

Шунысы гаҗәп, Казан үзе борын-борыннан тире-яры, мех эшләре белән танылган шәһәр булса да, җирле татарлардан чын мехчылар юк дәрәҗәсендә аз иде. Чимал складында сарык тиреләрен сортлаучы ике татарны исәпләмәгәндә, әзер мехта эшләүче бер генә белгеч тә юк иде. Бигрәк тә каракүл танучылар. Ни өчен бу болай, булып та таралып, югалып беткәннәрме — әйтүе дә читен. Кыскасы, ул чакта чын мехчылар — мишәрләр, бу эш тулысынча алар кулында иде*.

Инде менә без, моңарчы мәче тиресе белән куян тиресен дә аера белмәгән яшь егетләр, яшь кызлар, шул мишәр дәдәйләрдән мех сортлауның нечкә серен өйрәнергә һәм тора-бара аларны акрынлап алыштырырга тиеш идек.

## IV

Ләкин мин бит әле өйрәнчек кенә түгел, цех начальнигының (ул вакыттагыча әйтсәк, мөдиренең) ярдәмчесе, әлеге шул белгечләргә беркадәр баш кеше дә... Баштарак мондый хәл миңа шактый сәер, читен, уңайсыз да булып тоелган иде. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән цех ишегеннән беренче мәртәбә атлап кер, берни белмә, үзең нибары өйрәнчек кенә бул, ә шулай да ниндидер начальник кисәге булып йөр!.. Әллә ничек бер уен төсле бу... Ләкин озак та үтмичә, мин үз хәлемнең алай ук искитмәле түгел икәнлеген күрдем: минем вазифам бик гади һәм бик кечкенә иде.

Иң элек цех начальнигының үзе турында берничә сүз. Бу кырык-кырык бишләр тирәсендәге Васильев дигән бер кеше иде. Тутырып әйткәндә, Василий Иванович Васильев. Үзе бик ябык, күкрәге тар, калак сөякләре беленеп тора, ә куллары озын, авыр. Аз сүзле, сүлпән хәрәкәтле, елмаюны белми яки бик сирәк кенә, ничектер көчәнеп кенә елмая, ә эчкә баткан күзләре җирән куе кашлары астыннан зәгыйфь бизгәк уты белән янып, шул ук вакытта уйчан-хәлсез карыйлар... Беренче күргәч

---

* Сүз биредә мехны эшкәртүчеләр турында түгел, ә әзер мехны танучылар, сортлаучылар турында бара. Югыйсә мехны эшкәрткән фабрикаларда татарлардан зур гына белгечләр бар иде.— *Ә.Е.*

тә мин бу караңгы чырайлы сөмсер кеше белән эшләве бик авыр булыр дип борчылган идем. Характеры начарга охшый, эшемнән бер дә канәгать булмас, гел гаебемне табып, тиргәп кенә торыр дип курыккан идем. Ләкин бик тиз мин бу борчылу-куркуның нигезсез икәнен аңлап алдым. Тышкы кыяфәте белән әнә шулай шомландырса да, Василий Иванович асылда шактый йомшак, ипле бер эчкерсез кеше булып чыкты. Ул, бичара, бик авыру икән (чахотка кимерә үзен), һәм аның сөмсерлеге дә, сүлпәнлеге дә, күзләрендәге бизгәк уты да әнә шуңардан килә икән.

Кыска гына арада мин аның хакында мехбазага элегрәк кергән кешеләрдән дә, шулай ук Василий Ивановичның үзеннән дә күп кенә нәрсә ишетеп белдем. Ул бик түбәннән чыккан, укуны юньләп күрмәгән, әмма тормышның авыр, каты мәктәбен үткән. Дүрт ел буена Герман сугышының пычрак һәм салкын окопларында аунаган, шуның бөтен фаҗигасен, газабын кичергән. 1917 елда ук большевиклар партиясенә кергән, аннары гражданнар сугышын башыннан ахырынача узган... Ләкин хикмәт анда гына түгел. Мине барысыннан да элек җәлеп иткәне шул булды — Василий Иванович боларның берсе белән дә һич мактана белми иде. Иң гади, иң тыйнак кеше булып йөри бирә, әмма эчке иманы нык, таза булырга тиеш... Шулай сизә идем мин аны.

...Аның мехбазага килеп эләгүе дә ул вакыт өчен шактый кызыклы. Әйтүенә караганда, Василий Иванович кайчандыр яшүсмер чагында тире иләүчедә өйрәнчек малай булып эшләгән икән. Һәм менә шушы «һөнәре»н белгәч, аны тотканнар да мехбазага цех начальнигы итеп җибәргәннәр.

— Нишлисең, башыңа төшкәч, башмакчы буласың,— ди ул үзе, ялкау гына елмаеп.

Хәер, мәсьәлә бик ачык: тире иләүчедә өйрәнчек малай булып эшләве түгел, ә ышанычлы коммунист булуы аны бирегә китергән. Яңа производство, иске белгечләр — монда инде, һичшиксез, коммунист күзе, коммунист кулы кирәк булган.

Ләкин Василий Иванович, авыру сәбәпле, үзенә бик ныгытып ярдәмче сорый башлый. Татар булсын ди (чөнки безнең цехта күпчелек татарлар), укыганрак, аңлырак кеше табарга куша. Шулай итеп мине, моңарчы мех дигән нәрсәне иснәп тә карамаган яшь егетне, бу гаять тыйнак, ипле-сабыр агайга ярдәмче итеп куялар.

Мех эшен әкренләп өйрәнер, анысы качмас, ә хәзер җитәкчелекне ныгытырга кирәк дип уйлаганнардыр инде. Чынлап та, мактанып әйтүем булмасын, Васильев өчен

мин бик кулай ярдәмче булып чыктым. Иң элек аның бер дә яратмаган язу эшләре — төрле рапортлары, докладнойлары, нарядлары — барысы да миңа күчте. Шулай итеп мин аңа бик әйбәт писарь булдым. Аннары фабрикадан кайткан мехларны вакытында цехка китерү, сортланып эшләре беткәнне тизрәк цехтан озату да минем өскә төшә башлады. Гомумән, һәртөрле йөгерү-чабу белән бәйләнгән эшләргә Васильев агай гел мине җигә торган булды. Шуның өстенә тагын тәнәфес вакытларында беседалар үткәрү, газеталар уку кебек агарту эшләрен дә ул тизрәк миңа йөкләде. Мин, билгеле, боларның барысын да рәхәтләнеп үтим, чөнки мин яшь, мин яңа кеше, аннары Васильев агай да начальникларча боерык биреп түгел, ә арган, йончыган кеше сыман үз итеп кенә «Давай, брат, син генә эшлә инде» дип куша торган иде.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, аның үзен көн дә диярлек һәртөрле утырышларга — йә управляющийга, йә бюрога, йә фабкомга чакырып кына торалар. Кайчагында көннең яртысын ул шуларда утырып уздыра. Ул югында инде мин цехта баш кеше булып калам, бөтен эшкә һәм бөтен кешегә күз-колак булып торам... Менә минем ярдәмчелек вазифам асылда шулардан гыйбарәт иде. Күргәнеңчә, әллә ни катлаулы, кыен эш түгел, һәм мин аларның барысына да бик тиз өйрәнеп, күнегеп киттем.

## V

Начальник ярдәмчесе булгач, мин тиз арада мехбазаның югары җитәкчеләрен дә күреп, белеп өлгердем. Цехтан үткәндә алар туктап сорашып китәләр, йә булмаса чакырып алып, берәр боерык бирәләр, кайчак исә управляющий кабинетына утырышка-фәләнгә дә чакыралар. Әйтергә кирәк, аның кабинетына кереп, утырып чыгу бу минем өчен үзенә күрә бер дәрәҗә иде. Калын, гөмбәз аяклы, яшел постаулы зур өстәл торган биек, якты кабинеттан мин ничектер үсеп киткәндәй булып, хәтта бераз горурлана да төшеп чыга идем.

Кабинетның хуҗасы, ягъни мехбаза управляющие, Решевский дигән кеше иде. Юлий Давидович Решевский. Башта мин аны поляк түгелме икән дип уйлаган идем, ләкин поляк булып чыкмады ул... Хәер, хикмәт анда түгел. Нинди генә милләттән булмасын, әмма ул үзенә бер гаҗәеп оригиналь кеше иде. Аны Казан мехбазасына управляющий итеп Мәскәү җибәргән. Бирегә килгәнче ул «Главпушнина»да зур урын биләгән һәм чит илләргә дә чыгып йөргән диләр... Һәм моңа бер дә икел-

әнмичә ышанырга була: бөтен кыяфәте, килеш-килбәте, өсте-башы аның чит илләр белән эш итүче югары белгечләр арасында кайнаган, шуларның купшылыгын һәм бәйсезлеген отып алган, коеп куйган интеллигент бер кеше булуын әйтеп тора иде... Кечкенә җыйнак гәүдәле, нәфис ак чырайлы, салкын соры күзле, бармаклары да кызларныкыдай нечкә-озын, җитмәсә, шул бармакларның берсендә калын алтын балдак та елтырап тора. Ә бит ул заманда алтын балдак кияр өчен чыннан да бик бәйсез кеше булырга кирәк иде... Кием-салымын инде әйткән дә юк: безнең Казан кышына үч иткәндәй ул бик затлы тегелгән кыска драп пальтодан, калын кепкадан, сары штиблетлардан, тик муенына эре шакмаклы мамык шарф кына урап йөри торган иде.

Мин аңа бик кызыксынып, хәтта беркадәр сокланып та карый идем. Мех эшендә аны зур белгеч диләр, чит ил фирмалары белән эш итүче оста коммерсант диләр. Ә бит ул шактый яшь әле, утыз бишләр тирәсендә генә булыр. Кай арада үскән, кай арада бу дәрәҗәгә ирешкән диген! Күрәсең, бик башлы, сәләтле кеше... Аннары Мәскәүдә аның зур элемтәсе, зур таянычы да булырга тиеш. Һәм моны барысы да беләләр дә иде шикелле... (Җәяләр эчендә генә тагын шуны да әйтим: ул Шетинкин гостиницасында ике бүлмәле номер алып, шунда ялгызы гына тора иде. Семьясы Мәскәүдә — бер айны үзе кайтса, икенче айда хатыны килеп, торып китә икән. Күргән кешеләр аның хатынын да гаҗәп сылу, матур һәм искиткеч шәп киенгән бер асыл сөяк дама дип сөйлиләр.)

Решевскийның иң беренче кайгысы — мехларны мөмкин кадәр күбрәк экспортка чыгару иде. Еш кына бу безгә: «Онытмагыз, илгә валюта кирәк, барысыннан элек валюта өчен эшләргә тиешсез!» дип әйтә торган иде. Аның бу хакта үзенә чакырып сөйләшкән, киңәшкән кешеләре дә күбрәк әлеге белгеч мишәрләр була торган иде. Шуларга таяна, шулардан таләп итә... Мехбазаның башка төр эшчеләре белән аның алыш-биреше аз иде. Инде коллектив тормышына килгәндә, ул бу турыда кайгыртуны тулысынча партия, профсоюз җитәкчеләренә тапшырган иде.

Һәм бу урында мехбазаның тагын бер җитәкче кешесе — партоешма секретаре (бер үк вакытта кадрлар бүлегенең мөдире) турында да әйтеп китәргә тиешмен. Бу — Перов Федор Николаевич — урта яшьләрдәге кеше. Йөзе чиста-матур, ләкин чәчләренә чал керә башлаган инде, күз төпләре дә йончыган кешенекедәй шешенке, ә күзләре менә бик тере, ничектер өстән генә капшап узгандай җитез карыйлар. Гомумән аның кыяфәте гел шулай ике

төрлерәк тәэсир калдыра торган иде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр, белмим, тик күрә башлагач, мин бер нәрсәгә игътибар иттем: ул һәрвакытта Решевский янында була — нәкъ менә командир янындагы комиссар сыман. Управляющий кабинетында үткәрелгән утырышларның берсеннән дә калмый, сүзгә аз катнаша, күбрәк тыңлап кына утыра. Аның каравы, гомуми җыелышларда ул күп сөйли һәм, әйтергә кирәк, бик кайнар сөйли... Һәр көнне газеталарда язылып барган политик мәсьәләләр белән аның яхшы таныш булуы күренеп тора, һәм шуны ул тыңлаучыларга бик оста җиткерә дә белә.

Цехка кергәндә дә ул култык астына бер кочак газета кыстырып йөри, шулардан берәрсен цех начальнигына яки аның ярдәмчесенә тәнәфес вакытында кычкырып укыр өчен биреп калдыра. Мине дә ул бу эшкә бик тиз җикте. Беренче танышкач та:

— Менә бик яхшы, безгә сезнең кебек грамотный егетләр кирәк тә,— диде үзенең әз генә нечкәрәк тавышы белән.— Монда халык яңа, бик чуар, пропаганда эше беренче чиратта торырга тиеш. Ә Василий Иванович үзе — авыру кеше, аннары грамотасы да чамалырак, так что бу эш сезнең өстә, кем, иптәш Юлдашевмы әле?..

— Әйе, Юлдашев.

— Менә шулай, иптәш Юлдашев... Ә нәрсә укырга кирәклеген мин үзем сезгә күрсәтеп бирермен.

Һәм шулай итә дә торган иде. Мин дә аның күрсәтеп биргәннәрен цехта укып чыгарга тырыша идем (болар күбрәк бишьеллыкны үтәүгә, колхоз төзүгә, корткычларны, сыйнфый дошманнарны фаш итүгә багышланган материаллар була торган иде), шуның өстенә, әгәр вакыт җитсә, чит ил материалларын да укымыйча калдырмыйм, чөнки бу тема тыңлаучыларны һәрвакытта кызыксындыра торган иде.

Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен тиз генә белү бик читен. Минем үземә парторг Перов гомумән ошый иде, ләкин менә безнең Василий Иванович аны ни өчендер бик үк өнәп бетерми... Бер-ике мәртәбә мин аңардан: «Ялтырарга ярата бу кеше!» дигән сүзне дә ишеткәләдем. Башта моңа гаҗәпләндем, аннары аңлаган кебек тә булдым: Василий агай үзе аз сүзле, тыйнак кеше булгач, тегенең кешеләрдән читтәрәк һәм өстәрәк торып, күп сөйләргә яратуын ошатмый иде, күрәсең.

Кыскасы, безнең мехбазаның ике җитәкчесе — управляющие белән парторгы — әнә шундый, берсе үз-үзенә бик нык ышанган, бик тәкәллефле, горур, икенчесе — шактый шома телле, тынгысыз, өлгер кешеләр иде.

## VI

Смена башланып, цехтагы эшләр бетә төшкәч, мин үзем дә өйрәнчеккә әйләнеп, каракүл сортлау өчен киң, озын өстәл янына баса идем. Минем өйрәтүчем Әмин әкә Маматов. Нишләптер, мин аңа «әкә» дип дәшәргә өйрәнеп киттем. Ул үзбәк түгел, үзбәккә охшаган җире дә юк, чыкылдап торган мишәр. Ләкин мин беләм, ишеткәнем дә бар, үзбәкләр үзеннән олы кешегә, аеруча хөрмәт йөзеннән, «әкә», «әкә җан» дип дәшәләр. Менә мин дә, шул гадәт буенча, үземнең остама «абзый» диясе урында «әкә» дип дәшә башладым. Бу ничектер бик табигый килеп чыкты, хәтта миңа ияреп бүтәннәр дә аңа шулай дип дәшә торган булып киттеләр. Ул үзе дә моны бик тыныч, бик табигый кабул итте.

Әмин әкә бик таза гәүдәле, кызыл чырайлы, аю сыман алпан-тилпән атлап, ашыкмыйча гына йөри торган бер кеше иде. Ләкин гаҗәп шат күңелле, уен-көлке ярата торган кеше, кызыл чыраеннан бервакытта да елмаю төшми, һәм юк кына кызыктан да балаларча рәхәтләнеп, корсагын селкетә-селкетә көлеп җибәрә иде. Аннары җыр дигәндә үлә дә китә торган иде: ул үзе бер көй, бер авыз җыр белми, әмма инде кеше җырлаганны эреп, чөчеп дигәндәй көне буе тыңларга да әзер. Күршесендә өйрәнчек булып эшләүче Бибинур исемле кызны да ул һаман: «Канатым, яле бер сәк кенә, ваты минем өчен генә «Алиябану»ны күләп ал!» дип кыстап кына тора. Кыскасы, беренче караштa Әмин әкәне чынлап кайгыра да, борчыла да, хәтта кәефсезләнә дә белмәгән гаҗәеп ваемсыз, пошымсыз бер кеше диярсең!.. Һәм шушы кеше, әйткәнемчә, безнең мехбазаның иң зур белгече иде. Баш белгеч. Мәсәлән, үзе кебек оста белгечләр тарафыннан экспортка әзерләнгән каракүлләрне ул управляющий белән «Главпушнина» вәкиле алдында яңадан бер карап уздыра, һәм аның кулыннан узган мехларның берсе дә инде кире әйләнеп кайтмый иде.

Аның янында эшли башлагач, мин башта бик аптырый идем: өстәлдә өелеп яткан каракүлләр минем өчен барысы да бертөсле, ничек итеп аларны бер-берсеннән аерырга — һич акылым җитми иде. Ә ул шул каракүлләрне, бизәкләренә карап, уналты, унсигез төрлегә аерып сала да һәркайсының ишен табып, өсти генә бара. Бик нечкә эш бу... Каракүлдәге бизәк шәкелләрен, бердән, аера, икенчедән, ишен таба белү өчен, ничек дим, рәссам күзе кирәк. Әмин әкәдә нәкъ менә шундый күзләр булган иде, күрәсең!..

Мишәр абзыйларның бүтәннәрен баштарак мин аерып бетә алмыйча йөдәдем. Аларның кайсысы Ариф абзый

да кайсысы Алим абзый — аптырабрак калгалый идем... Ничектер яшьләре белән дә, буй-сыннары, хәтта характерлары белән дә алар барысы да бертөслерәк иде. Барысы да диярлек кырык-кырык бишләр тирәсендә, эре-тазалар, басынкы-салмаклар... Биредә шуны да әйтеп китәргә кирәк, минем элегрәк мишәргә карашым ни сәбәптәндер бик үк шәптән түгел иде. Ләкин, бергә эшли башлагач, бу карашның никадәр хата булуын бик тиз аңладым. Яман белән яхшы һәр милләттә, һәр кабиләдә була ул, бер яклы гына хөкем итү һич тә ярамый икән... Минем янымдагы мишәрләр исә барысы да диярлек бик әйбәт кешеләр иде. Ничектер менә бөтенесенә дә бер үк дәрәҗәдә хас булган тыйнаклык һәм әдәплелек бар иде аларда. Үзләренең шул каты телләре белән йомшак кына сөйләшәләр, берәүгә дә тупас кагылмыйлар, бервакытта да кычкырышмыйлар, киресенчә, бер-берсенә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торалар. Гомумән бик бердәм халык. Ихтимал, бу кадәресе аларның гел читтә, читләр арасында эшләп йөрергә мәҗбүр булуларыннан килә торгандыр инде.

Мишәрләр гадәттә бик әче, бик әшәке итеп сүгенергә яраталар дип ишеткәнем бар иде, ләкин минем бу дәдәйләремдә андый нәрсәнең әзе дә юк иде. Тик кәефләре бик кырылган чакта гына «явыл», «сатана», «брамат» дип кенә җибәргәлиләр иде. Олы кешеләр, алама сүзгә өйрәнмәгәннәр.

Эшкә килгәндә алар бик дисциплиналы халык, бик гаделләр, бик күндәмнәр, сменага һәрвакыт яшьләрдән алда киләләр һәм, звонок булганын да көтмичә, аерылып торган китапларына тотынган шикелле, тизрәк каракүлләренә ябышалар иде. Эшләрен бик яраталар һәм безне дә чын ихластан өйрәтергә тырышалар иде.

...Мишәрләрдән бер коммунист та бар иде. Вафа Янбулатов. Утны-суны кичкән, бик үткен, бик башлы егет... Алдарак күргәнсеңдер, ул минем бүлмәдә бер ай ярым чамасы торып та киткән иде. Ләкин Вафа үзенең үткәне белән дә һәм хәзерге вакыттагы эше белән дә бездәге мишәрләрдән шактый аерылып тора иде. Ул барысыннан да яшь, Кызыл Армиядә хезмәт иткән, Урта Азиядә басмачыларга каршы сугышып йөргән һәм шунда партиягә дә кергән булса кирәк. Аннары бездәге мишәрләрнең күпчелеге әзер мехта (мехбазаның үзендә) эшләсәләр, Вафа Пләтәндәге чи тиреләр складының мөдире булып эшли иде. Шуңа күрә аңа үз токымнары белән артык аралашып йөрергә туры да килми иде...

Мишәрләр турында тагын нәрсә әйтәсем калды?.. Алар ике-өчесе бергә, Суконныйдагы берәр апаның бүлмәсенә

кереп, шунда үзләре чиратлашып пешергән уртак казаннан ашап, эшкә йөрүдән башканы белмичә, тыйнак кына торып яталар. (Җәяләр эчендә генә әйтим, алар мишәрчә итне бик мул салып, ашны бик тәмле пешерә торганнар иде...) Барысының да диярлек семьялары Рәзән-Касыйм тирәсендәге авылларда — болар исә алган хезмәт хакларының күп өлешен шул семьяларына җибәреп торалар. Элек-электән үк шулай килгән инде: үзләре каядыр читтә, еракта эшләп яки алыш-биреш итеп йөргәннәр, ә хатыннары, бала-чагалары белән, болардан килгән акчага үз авылларында тук, тыныч кына яши биргәннәр. Йорт-җирләре, сизүемчә, таза-бай булырга тиеш.

Ләкин соңгы бер ел эчендә авылда зур вакыйгалар башланып китте: анда колхозлашу бара, җирләрне, малларны кушалар, кулакларны бетерәләр, көрәш гаять кискенләшкән, төрле шомлы хәбәрләр йөри. Бу хәбәрләр безнең мишәр абзыйларны да куркуга салган иде. Үзләре производствода эшләүче булсалар да, алар, табигый, авылдагы семьялары, йорт-җирләре өчен борчылалар, уйланалар, эчләреннән генә кайгыралар иде. Күрәсең, авылда купкан өермә кайберләренең семьяларына да кагыла башлагандыр — күбесе мехбазада эшләүләре турында белешмә алып, үзләренең авыл советларына җибәрделәр. Ләкин борчылуларын тыштан сиздермиләр, күп сөйләнмиләр, хәтта авыл хәлләре турында бик төпченеп сорашудан да тыелалар.

Бездә эштән соң еш кына төрле җыелышлар була торган иде. Мишәрләргә бер әйтү җитә, барысы да түбәндәге зур контора бүлмәсенә бөтенесеннән алда диярлек төшеп, озын эскәмияләргә күгәрченнәр шикелле тезелешеп утыралар. Тыгызлыктан тирләп-пешеп бетсәләр дә, кузгалмыйлар, чыгып йөрмиләр, кыскасы, өйләренә ут капса да җыелыш ташлап китү юк. Ә җыелыш озакка сузыла, ялкынлы сүзләр күп була — сүзләр дә күбрәк зур мәсьәләләр, ягъни чорыбызның бөеклеге, илдә бөтен фронт буйлап капитализм калдыкларына һөҗүм башлануы, сыйнфый көрәшнең кискенләшүе, һәр җирдә уяу булырга кирәклеге турында бара. Һәм моны башлыча ни өчендер әлеге шул иске белгечләргә — сакаллы мишәрләргә карап сөйлиләр иде кебек... Белмим, бу сүзләр мишәр абзыйларда ниләр уяткандыр — әйтүе читен, чөнки алар бервакытта да сорау-фәлән бирмиләр, чыгып сөйләмиләр, бары тик бик игътибар белән тыңлап кына утыра торганнар иде.

Әйе, мишәрләргә ышанып бетмиләр иде. Һәм алар үзләре дә моны сизәләр иде шикелле. Шуңадыр инде бик тыйнак булырга, гадел эшләргә, сак сөйләшергә тырышалар иде. Ләкин бу гына җитми иде, ахрысы. Эч-

ләрендә ни, заманга ничек карыйлар, хәзерге үзгәрешләрне кабул итәләрме, юкмы — менә нәрсә шикләндерә, менә нәрсәне беләселәре килә. Кайберәүләр фикеренчә, алар —иске белгечләр, капиталга хезмәт иткәннәр, хосусый милекчелек белән агуланганнар, бай яшәгәннәр, кыскасы, безнең заманга күпмедер дәрәҗәдә үги кешеләр. Бәс, шулай булгач, аларга карата һәрвакытта уяу булырга кирәк.

Билгеле, мин дә уяулык кирәктер шул дип уйлый идем, ләкин яхшымы, начармы бер гадәтем бар — кешегә һич сәбәпсездән ышанмыйча шикләнеп карый алмыйм, яратмыйм алай карауны. Кеше яхшы эшли, гадел эшли, бернинди кыек эше сизелми, берәүгә дә зарары тими, ә син тот та аның турында бу алама кеше булырга тиеш дип, аңардан шикләнеп, аны сагалап йөр, имеш. Юк, әллә ничек менә табигатем кабул итә алмый моны...

Уяулык күрсәтү җәһәтеннән бездә бик тырышып йөрүче Басыйр Рәҗәпов дигән бер шадра егет бар иде. Бездән бер катка түбән, пушнина цехында эшли... Моңарчы мин белгән шадралар барысы да ничектер бик сөйкемле, тыйнак була торганнар иде, ә бу, ничек кенә дип әйтергә, әллә нинди усал, зәһәр шадра иде. Үзе бик астыртын, һавалы, шуның белән бергә шактый әрсез дә. Җитмәсә, өйрәнчек кенә булуына карамастан, ни сәбәптәндер, билгеле бер хөрлек белән дә файдалана, ягъни эш вакытында цехлар буйлап йөрергә ярата иде. Сынаганың бардыр инде, шадра кешеләр гадәттә бик төз-ыспай гәүдәле булалар. Бу да нәкъ шундый — нечкә гәүдәсен бик төз, ә башын ата каз шикелле текә тотып, еш кына безнең цехтан узгалый торган иде. Башта мишәрләр янына тукталып, аларның эшләрен карап тора, аны-моны сораштыра, аннары мине бер читкә әкрен генә дәшеп ала.

— Йә, эшләр ничек? — ди бу, серле генә итеп.

— Эшләр яхшы бара,— мин әйтәм.

— Яхшы микән соң?

— Ник яхшы булмасын. Мехларны, күпме керсә дә, сортлап кына торабыз, цехта озак яткырмыйбыз, вообщем, абзыйлар шәп эшлиләр.

— Эшләмичә хәлләре юк,— ди Басыйр, авыз кырые белән генә елмаеп.

— Ә алардан тагын ни кирәк? — дим мин, аучым килә башлап.— Җырлап-биеп тә торсыннармы әллә?

Басыйр, кылыйрак күзләрен кыса төшеп, миңа бераз карап тора да әйтә:

— Алар өчен синең үзеңә биергә туры килмәсен, парин!

Мин дә аңар батырып карыйм:

— Сүзеңне ачык әйт, нәрсә болгатып маташасың.

Басыйр нишләптер кинәт кенә йомшарып китә.

— Йә, йә, мин уйнап кына... Син бит монда начальник кеше, үзебезнең кеше, вәт мин сиңа дусларча әйтәм: син ул мишәрләргә бик ышанып бетмә, күзеңне ачыбрак кара, беләсең хәзерге вакытны.

— Минем аларга ышанмаска хакым юк.

— Белмисең әле син бер нәрсә дә, белмисең,— ди бу сузып кына.

— Барысын да яхшы беләм, ләкин син, Рәҗәпов, кычытмаган җирне кашып йөрисең, менә шул.

— Шулаймы?! Ярый, без моны син әйткәнчә теркәп куйыйк. Соңыннан кемнеке кычыта башлар, күрербез.

Минем аңа отыры саруым кайный, кырт кисеп кенә үзенә: «Бар, кит моннан...»,— дип әйтәсем килә, ләкин ул, шуны үзе үк сизгәндәй, китәргә ашыга һәм, ике арадагы күперне сакларга теләгәндәй, иптәшләрчә генә әйтеп китә:

— Вабщем, бүдәнә сугыштырмыйк әле без, парин, син миңа, мин сиңа кирәк булырбыз. Ә пока!

Баштарак аның миңа шулай каты гына бәрелүе берничә тапкыр кабатланды. Ләкин минем бер дә курыкмыйча нык торуымны күргәч, егет шактый йомшарды. Хәтта дуслык та күрсәтә башлады. Яхшатланып, үз итеп, минем бүлмәгә дә килеп йөрде. Ашап-эчеп утырган чаклар да булды. Билгеле, мин дә аңа кырын тормадым. Бергә эшләгән иптәш үзе теләп якыная икән, нигә аңардан качарга яки нигә аны тибәргә?.. Яшьлек, үзең беләсең, читләшүдән бигрәк якынаерга, дуслашырга ярата. Аннары аның белән бергә утыру да күңелле булып кала торган иде. Ул чыкылдап торган Казан егете, сүзгә дә бик җор, Акком астының* жаргон-әйтемнәрен сибә генә. Һәм яңгыравык тавыш белән матур гына җырлый да. Шушы яклары өчен булса кирәк, мин аңа шактый ияләшеп тә киткән идем. Әмма шулай да чын ихлас дуслык безнең арада урнаша алмады. Нигәдер минә күңел дигәнең ышанып бетми иде бу кешегә һәм тикмәгә генә булмаган икән ул.

## VII

Югарыда әйткәнемчә, безнең цехта әлеге каракүлче мишәрләрдән башка, шуларга өйрәнчек итеп куелган күп кенә яшьләр эшли иде. Ә аларның яртысы диярлек кызлар иде. Менә шул кызларның берсе белән... Хәер, бу

---

* Казанның татарлар гына торган бер урамы. Сазлык урында. Хәзер урам үзе дә, сазлык та бетерелде.— *Ә.Е.*

хакта сүз башлаганчы, мин үз хәлем турында әйтеп бетерим әле.

Цехтагы яшьләр арасында мин яшькә дә олырак, укубелем ягыннан да өстенрәк идем. Шуның белән бергә, цех начальнигының ярдәмчесе дә. Ә бу нәрсә инде мине башкалардан аерыбрак куя, миңа инде начальник итебрәк карыйлар. Минем кечкенә генә булса да властем бар, бүтәннәргә куша, боера алам, зур гына хөрлек белән дә файдаланам — йөрим, карыйм, тикшерәм. Кешеләр миңа йомышлары, зарлары, үтенечләре белән киләләр... Цех начальнигына әйтәсе сүзләрен дә күбрәк минем аша җиткерәләр, чөнки Васильев агайның миңа ышанганын күреп торалар.

Карт белгечләр белән дә, яшьләр белән дә минем арам гомумән яхшы иде. Яшьләр өчен мин — үз тиңнәре кебек үк дияргә була, ә мишәрләр миңа «үзебезнең татар малае» дип карыйлар иде. Әлбәттә, мин моның белән барысына да бертигез ошый идем, барысы да миннән бик канәгать иде дип әйтергә җыенмыйм. Бервакытта да алай булмый ул. Эчләреннән көнләшүчеләр дә, яратып бетермәүчеләр дә булгандыр, һичшиксез, булгандыр... Моңа бер дә искитәргә ярамый — коллективта бит кырык төрле кеше. Мин үзем дә һәркемгә бер үк дәрәҗәдә ошарга, ярарга тырышмый идем — тырышсаң да ничектер булдырып булмый аны... Тик шуны гына әйтәсем килә: цехта эшләгәндә миңа берәү белән дә дошманлашырга, ачыктан-ачык бәрелешергә туры килмәде.

Инде хәзер яңадан теге кызларга кайтыйк. Әйе, безнең цехта кызлар күп иде. Һәм озак та үтми, шул кызлар арасыннан берсенең миңа шактый игътибар итүен сизә башладым. Минем буем-сыныммы, укыган егет булуыммы, әллә начальник кеше булым йөрүемме кызның күңелен җәлеп иттеме икән, белмим, әмма ул миңа очраганда күзләрен тутырып, озаграк итеп карый иде, янына килеп сөйләшкәндә дә күзләремә туры карарга тырышып, сөйкемле елмаеп һәм бик теләп сөйләшә торган иде. Хәтта яныннан китеп баргач та, мин аның артымнан карап калуын сизә идем. Бу бит башка берәүгә дә түгел, ә миңа гына! Мин моны тоймыйча, моңардан беркадәр исереп китмичә кала алмый идем, һәм, билгеле, минем дә аңа игътибарым көннән-көн әкренләп көчәя бара иде. Ул кыз Ариф абзый Байтирәковта өйрәнчек булып эшли. Исеме аның Хафаза иде.

Моңарчы кызлар белән танышып, яратышып йөрүдә минем тәҗрибәм бик аз иде әле. Укыганда, үзең беләсең, кыен эш ул. Дөрес, әле берәү, әле икенче белән дигәндәй, мавыгып киткән вакытларым булгалады. Озата барулар да,

капка төбендә суыктан таптанып торулар да, көчләп кочарга, үбәргә азапланулар да булмады түгел, булды. Ләкин эш тиз сүтелә торган иде. Әлеге шул студент хәерчелеге —өсбаш хөрти, кесәдә акча юк, акча булмагач, кызыңны теләгән җиргә илтеп тә, күпме-азмы сыйлап та булмый, шуннан тотасың да кулыңны селтисең! Боерган булса, укып бетергәч, боларның барысының үчен алырмын әле дип үз-үзеңне юаткан буласың. Шулай ул ярлы студент хәле —мәхәббәтен дә, бәхетен дә кичектереп торырга мәҗбүр.

Әмма хәзер минем хәл башка инде. Акча бар, аерым бүлмәм дә бар, һәм, иң мөһиме, еллар буенча буылып, тынгылык бирмичә килгән мәхәббәткә көчле сусау да бар. Кемнедер ярата башларга вакыт иде, кирәк иде. Ләкин... ләкин шулай да мин бу Хафаза туташка егылып китүдән баштарак тыелып маташкан булдым. Ул өйрәнчек кенә, ә мин, ни әйтсәң дә, начальниграк кеше, үзеңә күпмедер буйсынган кыз белән роман башлау килешмәс, ярамас дигән уй мине тотыбрак торды. Андый нәрсәне бик тиз сизеп алалар, сүз китәчәк, берәр күңелсез эш килеп чыгуы да мөмкин. Аннары тагын кызның миңа тутырып караулары, елмаеп сөйләшүләре минем башымны әйләндерсә дә, мин аңа карата үземнең чын хисләремне ачык кына белми идем әле. Нәрсә бу, кыз үзе миңа йөзен борганга күрә генә туган хисләнүме, әллә чын ячын яратуның туа башлавымы?

## VIII

Кызны сиңа ничек сурәтләп күрсәтергә?.. Дөресен генә әйткәндә, аның ул хәтле һуштан егарлык матурлыгы да юк кебек иде. Буйга кечкенә, аяклары да бик үк турыыспай түгел, йөргәндә аз гына чайкалыбрак йөри, кыскасы, буе-сыны белән ике бистә арасында үскән кызларга бик охшаган иде. Ә син беләсең инде, Казанның бу начар, сасы һавалы җирендә үскән кызлар арасыннан чын сылулар сирәк очрый... Әмма мине сихерләгән гүзәллеге аның йөзендә, йөзеннән дә бигрәк күзләрендә иде.

...Ничек итеп язсам да, сурәтләп бирә алмам кебек... Болай: йөзе аның түгәрәк, бит урталары аз гына чокыраеп тора, елмайганда энҗедәй вак кына тигез тешләре ачыла һәм бит чокырлары тирәнәеп китә; маңгае чистаак, ә кашлары нечкә, кара; борыны кыска, җәенкерәк, ә иреннәре яңа гына ачылган иртәнге чәчәктәй кечкенә, йомшак, тәмле-сусыл кебек... Һәм, ниһаять, күзләре... озынчарак зур күзләре — ничек кенә дип әйтим — антрацит күмердәй чем-кара иде. Ләкин хикмәт анда гына да түгел. Хафазаның ул күзләре һәрвакыт диярлек юка

гына дым пәрдәсе белән өртелгән була иде, һәм бу дым пәрдәсе аларны, бер карасаң, ерак-томанлы итеп күрсәтә, ә икенче карасаң, ничектер юып алгандай, ачыкландырып-яктыртып җибәрә иде. Әйе, хикмәтле күзләр!

Һәм менә шул кечкенә буйлы, йомры гына кызый үзенең Ходай биргән сихри күзләре белән цехтагы барлык кызлар арасында диярлек иң чибәрләрдән санала иде. Бигрәк тә безнең мишәр абзыйлар аңа мөкиббән китеп гашыйк булганнар иде. Сөеп карыйлар, сөеп кенә дәшәләр, ике сүзнең берендә: «Хафаза, якты күзем!», «Хафаза, ак канатым!»— дип кенә торалар. Билгеле, алар бервакытта да әдәп киртәсеннән чыкмыйлар, андый-мондый нәрсә сиздермиләр, бары гаҗәеп бер гөлгә карагандай, аңа соклануларын яшерә алмыйлар. Әйтергә кирәк, Хафаза да үз бәясен яхшы белә иде. Шаркылдап көлми, чытлыкланмый, сырпаланмый, тик кызларга кирәк кадәр генә үзен азрак һавалы, азрак кына иркә-назлы итеп тота... Шуңадыр инде мишәрләр Хафазаны акыллы кызга саныйлар иде.

...Баштарак мин, әйткәнемчә, сагаеп һәм саклыныбрак маташтым. Ләкин сизәм, керә... керә кызый әкренләп йөрәккә... Берни эшләр хәл юк, һәркөнне сигез сәгать без бер цехта, һәркөнне мин аның яшерен генә дәшеп караган дымлы-якты күзләрен очратам, һәркөнне энҗедәй тешләрен күрсәтеп, елмаеп кына әйткән сүзләрен ишетәм. Мин аның кечкенә буен, кыска аякларын күрми башлыйм, ә йөзе-күзе, сөйкемле елмаюы бөтен бер кыяфәтенә әверелеп, минем хыялымнан чыкмый башлый. Мин инде аны көтеп алам, цехка килеп кергәнен күрмәсәм дә сизәм һәм ялгышмыйм. Әгәр дә авырып-нитеп эшкә килми калса, мин аны бик юксынам, борчылам, тынычлыгымны югалтам. Алай гына да түгел, мин Хафазаның үзенең дә шундыйрак хәл кичерүен — мине күрергә теләвен, мине эзләвен, мин булсам — аңа да яхшы, булмасам — аңа да күңелсез булуын тоеп торам. Шулай итеп безнең йөрәкләр арасында ниндидер бер бик нечкә, әмма бик нык җеп сузылды. Без инде әкренләп бер-беребезнең серен укый алган кешеләргә әйләндек... Бу хәл вакыт-вакыт мине һаман әле борчып куйгалый иде, әмма моңа, бу хәлгә каршы тору мөмкин түгел иде инде.

Менә шулай, дус кеше!.. Килде мәхәббәт, миңа да килде. Ни әйтим? Бәлки, өстәп тагын шуны әйтәсе калгандыр: мәхәббәтнең килүе төрлечә булырга мөмкин — беренче караштан, әкренләп йөри торгач, ләкин дә аның тагын бер этәргече бар икән, бу — кеше сүзе, кеше димләве... Ышанасыңмы шуңа? Әлбәттә, кеше димләве белән генә чын мәхәббәт бервакытта да туа алмый, әмма шулай да йөрәккә

төшкән чаткыны көйрәтеп, көчәйтеп җибәрергә кеше сүзе җитә кала. Әлеге мишәр абзыйлар, нидер сизенеп булса кирәк, Хафазаны миңа үтереп мактый башладылар: мировой кыз — акыллы, әдәпле, инсафлы, сөйкемле, чибәр, матур, роза, ласточка, шикәр-бал — тагын әллә ниләр. Кыскасы, бер сандык хәзинә! Мин ни... кызарам, җилкәне кашыган булам, ә үзем «әйе» дим инде, телдән әйтмәсәм дә күңелемнән генә «әйе» дип кенә торам. Хафаза бит ул!.. Һәрбер тиле гашыйк төсле, мин дә Хафазаны бары яхшы итеп кенә, пакь итеп кенә, гүзәл итеп кенә күрәм. Җитмәсә әле, кешеләр дә аны нәнә шундый итеп күрәләр икән. Йә, иңгә кунган асыл кош түгелмени ул!..

Алга йөгеребрәк булса да тагын шуны әйтим: Хафаза белән без күз карашып, сынашып йөрүдән узгач, инде артык яшеренмичә шактый якынаеп йөри башлагач, шул ук мишәр абзыйлар моны бик тиз күреп алдылар һәм кызны миңа чынлап торып димләргә дә тотындылар. Бу җәһәттән бигрәк тә Әмин әкә мине яман кысрыклый башлады. Бер генә түгел, әллә ничә тапкыр бу миннән тота да сорый:

— Син, кәбәм, өйләнмәгән егетме?

— Үләнмәгән егет,— мин әйтәм.

— Соң, шулай булгач, ник авызыңны ачып йөрисең?

— Аңламыйм, Әмин әкә!

— Аңламыйсың?.. Мин сиңа, Хафазаны ычкындырма, дип атәм. Үлән шуңа, үлән!

— Ә ник мин аңа үләнергә тиеш әле? — дигән булам инде мин.

— Их, брамат,— ди Әмин әкә, ботын чабып.— Шундый кызга да үләнмәгәч, сине кем дип кенә әйтергә? Үзе красавица, үзе умница, андыйны вет син, парин, көндез чыра яндырып та таба алмыйсың. Үлән, ычкындырма, акылың булса!

— Үлән дә үлән! Әйтерсең эш миннән генә тора... Хафаза үзе ни уйлыйдыр бит әле.

— Ә син анысы өчен хафаланма. Үзебез аның белән сүләшербез. Күр дә тор, ике куллап риза булыр... Без вәт сизәбез.

— Белмим шул,— дим мин, бу юлы җилкәне чынлабрак кашып.

— Беләсе юк, рисковать кирәк. Туеңны да үзебез күтәрешербез. Мин инде монда үзебезнең братлар белән сүләшкәләдем...

— Рәхмәт, Әмин әкә, рәхмәт!..

Хәер, чын күңелдән рәхмәт әйтсәм дә, мин мондый сөйләшүләрне баштарак уенга гына алган идем. Ләкин күрәм, мишәрләрем минем белән уйнап кына сөйләшмиләр.

Хәтта бервакыт Әмин әкә миңа мондыйрак нәрсә дә әйтеп ташлады: әгәр синдә Хафазага өйләнү теләге булмаса, кызның башын юкка әйләндереп йөрмә, үзебез бүтән яхшы кеше табабыз — әнә Арифның Касыймда җиткән улы бар, чакырып китерәбез дә шуңа сватать итәбез, янәсе.

Бу инде ультиматумга охшый иде. Гаҗәп, безне болар көчләп диярлек өйләндерергә тырышалар. Ни өчен?.. Чынлап та ни өчен?.. Озак та үтми моның сере ачылды: алар фикеренчә, әгәр мин өйләнмәсәм, Хафаза кебек шундый әйбәт кызның әллә нинди юньсез кешегә эләгеп куюы бар —менә нәрсә аларны бик борчый икән! Кызык... Яхшы ат белән яхшы кызны яман кулга җибәрмәү — бу татарның борыннан килгән гадәте булса кирәк.

Ә мин уйланам, көн-төн борчылып һәм сөенеп уйланам: шулай ук Хафаза минем өчен генә яратылган кыз микәнни, шулай ук язмыш безне мәхәббәт җепләре белән гомерлеккә бәйләп куяр микәнни?!

## IX

Әйе, Хафаза белән безнең дуслык көннән-көн көчәя, тирәнәя бара. Мин үзем кызлар белән йөреп шомарган егет түгел, ләкин аның кирәклеге дә сизелми, ничектер үзеннән-үзе бик табигый рәвештә без бер-беребезгә һаман ияләшә, якыная барабыз... Көн дә мин цехка иртәрәк киләм һәм тегесен-монысын эшләп йөргән арада да ишектән күземне алмыйча аны көтәм. Ул, гадәттә, башына эре кара чәчәкле кызыл яулык бәйләп, кулына бик кечкенә чемодан тотып эшкә килә иде. Күз кырыем белән генә күреп калсам да, мин аны шул яулыгыннан танып алам һәм аз гына тыелып торганнан соң янына барып, кечкенә йомшак кулын кысам: «Нихәл, кадерлем, килдеңме?» — дим әкрен генә... Аның дымсу күзләре шунда ук яктырып китә, бит алмалары да алсуланып китә, ә үзе сөенеченнән бары тик башын гына кагып куя. Аннары, якын тирәдәге кешеләрдән уңайсызлангандай: «Кара, минем каракүлләрем күп калмаган икән,— дигән була.— Син, Хәбиб, миңа тизрәк яңаларын китерерсең, яме!..» Ә бераздан смена башлана... Мин аңардан өч өстәл аша гына эшлим, ләкин аның ягына еш карый алмыйм — каракүл игътибарны үзенә бик нык бәйли, әмма барыбер уем аңарда, аны тоеп эшлим... Нәкъ шушындый ук хәлне ул да кичерәдер кебек, күзләре каракүл бизәкләрендә булса да, күңеле гел миндәдер кебек — мин моны да сизеп торам шикелле... Һәр сәгать саен биш минутлык тәнәфес булып ала. Егетләр, кайбер мишәр абзыйлар ишек төбендәге махсус урынга

тәмәке тартырга китәләр, ә кызлар аякларын ял иттерер өчен өстәлләренә менеп утыралар. Мин ул вакытта тәмәке тартмый идем әле, шуңа күрә, әгәр Хафаза ялгыз гына калса, тизрәк аның янына барам, әгәр кызлар җыелып өлгерсә, шул тирәдәрәк утырган Әмин әкә яки Ариф абзый янына барып, сөйләшеп торган булам. Һаман бер нәрсә инде — ничек тә Хафазага якынрак буласым, аны күреп һәм аңа күренеп торасым килә.

Ләкин болай яшеренеп, тыелып маташуның хәзер мәгънәсе юк иде, әллә ничек уңайсыз да иде — барыбер күрәләр, беләләр. Без инде, смена беткәч, еш кына бергә кайтабыз, җыелышлар вакытында да гел генә бер тирәдәрәк утырырга тырышабыз... Аннары безнең һич ничек тә яшерергә мөмкин булмаган үзара мөнәсәбәтебез, күз карашларыбыз, сөйләшүләребез барысын да әйтеп, кычкырып тормыймыни?! Юк, яшерену мөмкин түгел иде инде, һәм без, ниһаять, берәүдән дә качмый-яшеренми башладык.

Безнең мехбазадагы яшьләрнең күпчелеге татар кызлары, татар егетләре иде. Күбесе Казанның үзеннән... Алар арасында Хафазаны электән үк белүчеләр бар икән. Шуларның берсе — әлеге Басыйр булып чыкты. Ул еш кына Хафаза янына бара, бик үз кешедәй аның белән көлеп, сөйләшеп тора. Баштарак бу хәл минем эчемне пошыра иде. Көнләшү дип әйтмәс идем мин моны, чөнки хатынлы Басыйрның Хафазаны үзенә карата алуына күңелем һич ышанмый, ләкин шулай да аның кыз тирәсендә артык сырпалануы миңа ничектер шикле күренә иде. Кыскасы, яратмый идем мин ул кешенең Хафаза тирәсендә чебен шикелле әйләнүен... Ахырда моның сәбәбен белер өчен туп-туры Хафазаның үзеннән сорарга булдым.

— Әйт әле, Хафаза,— дидем,— нишләп бу Басыйр бик еш синең яныңа килеп йөри? Берәр серегез бармы?

Соравым дорфарак килеп чыкты, күрәсең, Хафаза гаҗәпләнгәндәй миңа бер карап куйды.

— Нигә алай дисең, Хәбиб? — диде ул, сузып кына.

— Просто беләсем килгән өчен генә,— дидем мин, уңайсызланыбрак.

— Без бит бер мәктәптә укыдык. Аннары кайчандыр бер үк урамда торган да идек. Күптәнге таныш, бары шул гына...

— Алай икән, мин моны белмәгән идем... Нәрсә, бер үк класста укыдыгызмы?

— Нишләп инде бер класста булсын, ул бит миннән күп олы... Мин беренче класска килгәндә, Басыйр әллә өченчедә, әллә дүртенчедә укый иде шунда. Бөтен шәрикләре арасында иң зур малай иде. Мин аны куып та җитә яздым — дүртенчегә күчкәндә, ул һаман бишенчедә утыра

иде. Ләкин шуннан ары укымады, китте... Ул бүрек тегүче малае. Бер урамда торган чакта мин аның да бүрекләр күтәреп, базарга киткәнен күреп кала идем. Аннары без Акком астыннан Болак буена күчтек...

— Шуннан соң очрашмадыгызмы?

— Юк, очраштык... Бик кызык булды ул. Өч елмы, артыгракмы вакыт узгач, безнең мәктәпкә өр-яңа юнгшторм кигән бер бик төз буйлы егет килде. Бу кем дип карасак, аптырап киттек: безнең Басыйр!.. Чәчләрен уртадан ерып, ике якка тарап җибәргән, биленә таянып кына сөйләшә — шадрасы булмаса, Басыйр дип тә белмәссең!.. Мин хәзер комсомолда эшлим, менә сезгә җыелыш үткәрергә килдем әле, ди бу... Кызык... Бөтен кызлар, малайлар аны тыңлар өчен бер зур класска дөбердәшеп тулдык... Шәп сөйләгән иде шул чакта Басыйр. Ул бит начар укыса да сүзгә, бик оста малай иде. Комсомолның агымдагы бурычларын ярып кына салды безгә... Менә бит кеше ничек үзгәрә!..

Әйе, бу минем өчен дә кызык кына иде. Басыйрның кем икәнен, нинди юллар узганын тагын да ачыграк белә төштем. Хәер, аның начар укып та шәп сөйләүче булуына артык исем китмәде. Төрле кешедә төрле сәләт. Фәнгә теше үтмәгән, җитди, тирән белемне сеңдерә алмаган, ләкин кеше сүзен, китап сүзен өстән генә эләктереп ала белгән шома телле егетләрне минем күргәнем бар иде инде. Андыйлар гадәттә көндәлек политика белән бик мавыгып китәләр һәм җәмәгать эшендә яки комсомол эшендә кайчак бер ялтырап та алалар. Әмма аларның ялтырап узулары, минемчә, озакка бармый, чатыр-чотыр ут-төтен чәчрәткән фейерверк шикелле бик тиз сүнәләр.

Ләкин бу очракта мине бер нәрсә шактый гаҗәпләндерде: комсомолда эшләгән, хәтта мәктәпләргә барып, җыелышлар үткәреп йөргән егет ни өчен, ничек итеп хәзер безнең мехбазага гади өйрәнчек булып килеп эләгә?.. Сәбәбе нәрсәдә?.. Моны минем беләсем килде, һәм туры гына шуны Хафазадан сорадым.

— Нигә,— диде Хафаза, бик гади генә итеп.— Кеше гел бер урында гына эшләми бит инде.

— Анысы шулай, ләкин кеше үз теләге белән зур эштән кечкенә эшкә күчәме соң?.. Әллә комсомол аны безгә җибәргәнме?

— Мин ул кадәресен белмим. Юктыр, чөнки аның комсомол эшеннән китүенә шактый булды инде.

— Ә ни өчен китте соң ул? — дип сорадым мин.

Хафаза җавап бирергә аз гына икеләнеп торды — гүя аңа бу турыда сүз алып баруы кыен иде. Әмма, мин сорагач, әйтмичә мөмкин түгел... Тотлыга биреп:

— Ни... Басыйр, дөресен генә әйткәндә, үзе китмәде, аны... чыгардылар,— диде ул, ниһаять.

— Ни өчен?

— Синең бик беләсең киләмени? — диде Хафаза, нигәдер борчылып.

Бу хәл миңа бик сәер тоелды. Хафазаның миннән яшерерлек нәрсәсе булырга мөмкин?! Аптырадым, ни әйтергә дә белмәдем, ахырда коры гына: «Ихтыярың»,— дип куйдым. Шушы сүз аңа җитә калды булса кирәк, ашыгып, хәтта ялваргандай:

— Син ачулана күрмә, бәгърем! — диде ул.— Басыйр бу хакта сиңа әйтмәскә кушкан иде, ләкин мин әйтәм, әйтәм... тик ике арада гына калсын, яме!

— Аңламыйм мин сине, Хафаза! — дидем мин, отыры гаҗәпләнеп.— Ни өчен мондый кисәтү?.. Әгәр сиңа кеше серен ачу кыен икән, зинһар, әйтмә! Моның өчен мин сиңа ачуланмаячакмын. Тик... миңа ышанмавың гына...

— Юк, ышанам, әйтәм! — диде ул, тизрәк минем сүземне бүлеп.— И җаным, сер диярлеге дә юк аның, күпләр беләләр дә инде аны... Тик син яңа кеше, шуның өчен генә Басыйрның белгертәсе килмәгәндер. Бик ямьсез нәрсә бит... Эш болай: Басыйр авылдан килгән яшь кенә бер кызны үзенә ала. Өч ай да тормыйча бичараны куып җибәрә — янәсе, кызның атасымы, агасымы шунда... раскулачивать ителгән, имеш... Шуннан соң озак та үтми, тагын бер чибәр генә шәһәр кызына өйләнә... Күпмедер торгач, бусын да аерып җибәрмәкче була, ләкин бусы инде теге авыл кызы кебек җебегән булып чыкмый... Бара да әйтә. Шуннан тикшерү башлана. Комсомолда эшләгән кеше өчен бик начар, оят эш ич бу, көн дә хатын алыштыру... Дөрес, моның өчен Басыйрны комсомолдан ук чыгармыйлар чыгаруын, ләкин райкомнан куалар... Менә аның бөтен тарихы шул.

— Алай икән,— дидем мин, уйга калып, һәм янымда гаепле кеше сыман ничектер уңайсызланыбрак басып торган Хафазага беравык сүзсез генә карап тордым. Уйларым яктыдан түгел иде. Әнә нинди козгын әйләнә икән минем кечкенә Хафазам өстендә! Әмма ул үзе шуны сизәме?.. Куркамы ул шул козгыннан? Һәм гомумән шушы хәлдән соң Басыйр белән аның арасында нинди генә мөнәсәбәт булырга мөмкин?

— Әйт әле, сөеклем, Басыйрның ул эшләренә син үзең ничек карыйсың? — дип сорадым мин, ниһаять.

Хафаза чын ихластан үпкәләгән тавыш белән:

— Сорыйсың тагын! — диде.— Билгеле, бик начар карыйм. Япь-яшь кенә кызны алдау — бик зур кабахәтлек ич!

«Ә сине дә алдамасмы соң?» дип әйтәсем килде минем, ләкин тыелып калдым. Аның урынына:

— Син үзең Басыйрдан курыкмыйсыңмы? — дип сорадым.

Хафаза, балаларча беркатлылык белән күзләрен зур ачып, сузып кына:

— Менә әкәмәт, нишләп мин аңардан куркыйм,— диде.— Нишләтә ала ул мине?.. Син дә инде...

— Юк, шулай да?

— Нәрсә шулай да?

— Гел синең тирәңдә әйләнә бит әле ул.

Хафаза кычкырып көлеп җибәрде:

— Тиле, тиле!.. Әллә көнләшәсең дәме?.. Куй, кеше көлдермә, җаным!.. Бел, өч тиенгә дә кирәкми ул миңа, өч тиенгә дә!.. Электән таныш булгач, килеп йөри инде шунда, кешене куып җибәреп булмый бит.

Мин дәшмәдем, мин бары аның күзләренә — әлеге шул сабый баланыкыдай зур, дымсу, саф күзләренә генә төбәлеп карадым: бу күзләрдә ялган булмаска тиеш иде, әйе, булмаска тиеш!.. Һәм Хафаза да минем бу минутта ниләр кичергәнемне сизде булса кирәк:

— Борчылма юкка! — диде, кулыма әкрен генә орынып.— Сине борчырлык бернәрсә дә юк, бәгърем, ышан!.. Басыйрны мин, бәлки, яныма якын да китермәс идем, тик ул да бит сине мактый.

— Мактый? — дип ычкындырдым мин, үзем дә сизмәстән.

Хафаза миңа тагын да якыная төшеп, бәхетле көлемсерәгән йөзен күтәреп, аз гына шукланып әйтте:

— Ышанмыйсың?! Билләһи менә мактый шул, әйбәт егет, укыган егет, ди, аның белән дус булырга ярый, ди... Әллә ышанмыйсың?

Юк, нигә ышанмаска. Басыйр белән без бер-беребезне иснәп танып алырга өлгердек инде. Соңгы вакытта, әйткәнемчә, ул үзе үк миңа елыша башлады. Әзрәк мактаса да, гаҗәп түгел... Тик нинди максат белән мактый икән ул? Менә хикмәт нәрсәдә. Бу минем өчен шактый серле табышмак. Ишеттегез инде, Басыйр бер күтәрелеп түбән тәгәрәгән һәм бик ямьсез рәвештә тәгәрәгән кеше булып чыкты. Бу нәрсә аның хәзерге гамәлен бераз аңлата да кебек: шөһрәтнең, карьераның тәмен бер татыган кеше «тәгәрәп төшүе» белән, әлбәттә, килешмәячәк. Димәк, ул яңа җирдә яңадан күтәрелергә тырышачак — теләсә ничек, теләсә нинди юллар белән... Әмма ләкин аның бу максаты өчен без нигә кирәк, нәрсә көтә, нәрсә өмет итә ул бездән?.. Һич аңлый алмыйм... Тик сизәм, мактавы

да аның тикмәгә түгел, юк, түгел. Әмма, ни кызганыч, шул чакта мин нидер сизенсәм дә, ул кешенең кара эчен күрә белмәдем, Бәкер дус!

## X

Хәер, бер Басыйрдан нигә ул хәтле шикләнеп-шүрләп торырга?.. Хафаза әйтмешли, кем ул, нишли ала ул безгә? (Шулай тынычландырдым мин үземне.) Безнең тирәдә яшьләр күп, иптәшләр күп, барысы белән дә арабыз яхшы... Яратышып йөрүебезгә дә ничектер җылы теләктәшлек белән карыйлар төсле... Һәрхәлдә, берәүнең дә көнләшүен, яман күзен сизмибез — чын яратуны кеше аңлый, хөрмәт итә белсә кирәк.

Безнең үзебезнең дә иптәшләр арасыннан чыкканыбыз юк, гел бергә... бергә эшлибез, бергә күңел дә ачабыз. Төрле кампанияләр үтеп тора, җыелышлар бик еш булып тора — берсен дә калдырмыйбыз. Ул елларда илдә барган зур вакыйгаларны без күңелебезгә бик якын ала идек, шулар белән рухлана идек, шуларга сөенә идек. Бигрәк тә төрле җирдә башланган зур-зур төзелешләр безне куандыра, безне хәйран калдыра иде. Әлбәттә, бу әле тормышта барысы да ал да гөл, безне борчыган мәсьәләләр, аңлавы читен хәлләр юк иде дигән сүз түгел. Һәр замандагы шикелле, ул чакта да бар иде алар, хәтта артыгы белән, ләкин без ул авыр мәсьәләләрдән, ул аңлавы читен хәлләрдән котылыр өчен «вакытлы гына бу, тиздән барысы да әйбәт булачак» дип ансат кына үзебезне юата торган идек.

Аннары без яшь идек бит әле, бик яшь идек, шайтан алгыры! Ә яшьлекнең хыял күге, үзең беләсең, һәрвакытта аяз була, яшьлек, өзлексез искән җил төсле, кара болытларга баш өстенә җыелырга ирек бирми — гел куалап кына тора. Безнең мәхәббәткә сусаган чагыбыз, безгә уен-көлке кирәк, шау-шу кирәк, дәрткә дәрман кирәк... Безнең арада матур гына җырлаучылар, биючеләр, оста гына гармунда уйнаучылар, мандолина чиртүчеләр дә бар иде. Һәм озак та үтми, без бер драмтүгәрәк сыман нәрсә дә оештырып җибәрдек. Һәр эшнең үз остасы табыла дигәндәй, бу эшкә дә дәртләнеп тотынучы үзенең һәвәскәре табылды. Ул — мехбазаның конторасында ниндидер бер бик кечкенә эштә утыручы Мостафа исемле егет иде. Үткән-сүткәндә мин аның гел энә-җеп тотып, кәгазьләр тегеп утырганын күреп уза идем. Аннары ул көн дә цехларга менеп, газеталар таратып төшә иде. Басыйрның әйтүенә караганда, ул бик зур бер мәшһүр Ка-

зан баеның малае, имеш, ләкин әтисен ташлап чыккан да ярлы гына кешенең кызына өйләнеп, хәзер шулар семьясында яши, имеш. Моңа бер дә икеләнмичә ышанырга була, чөнки аның кыяфәте үк шуны раслап тора: нечкә озын буйлы, ап-ак чырайлы, аксыл чәчле, төскә чибәр, шуның өстенә кызлардай тыйнак, оялчан гына егет иде ул. Гүя аңа кемнәрдер дөньяда яшәргә рөхсәт иткәннәр дә, бу шуңа гаять сөенеп, рөхсәт итүчеләрнең ачуын китермим, югыйсә яшәүдән тагы мәхрүм итеп куярлар дигән төсле мыштым гына, куркып кына йөри иде кебек... Һәм шушы егет театрдан шактый хәбәрдар, үзе дә чибәр генә уйный белүче булып чыкты. (Кайчандыр аларның өйләренә зур артистлар җыела торган булган, ул шуларны күреп үскән икән.) Сәхнәдә Мостафа үзен, киресенчә, хөр, иркен, кыю тота иде, чөнки бу чын тормыш түгел, бары тик уен гына... Без аны түгәрәкнең режиссеры итеп куйдык. Мин дә, билгеле, читтә торып калмадым. Цех начальнигының ярдәмчесе булгангадыр инде, мине сайлап тормыйча гына бу түгәрәкнең җитәкчесе итеп таный башладылар. Репетиция көннәрен билгелим, халыкны җыярга кушам, аннары Мостафа белән икәү генә рольләр бүләбез — шуның белән минем эш тә бетә. Калганы инде Мостафа өстендә. Хәер, минем өстә тагын суфлерлык кала, мин бик әйбәт суфлер, әмма үзем, әллә килештермәгәнгә, әллә кулымнан килмәгәнгә күрә, бервакытта да роль алмый идем. Хафаза да, билгеле, шунда, ул уенга катнаша, һәм аңа еш кына рольнең әйбәтен бирәләр. Ни өчен икәнен әйтеп тормасам да аңлашыладыр...

Менә шулай башланып китте безнең эш... Башта көчне сынар өчен бер-ике пәрдәлек кенә әйберләр куйгаладык. Ярыйсы гына чыкты кебек, халык та, гомумән, канәгать булып калды, ә мишәрләрне инде әйткән дә юк — ни генә һәм ничек кенә уйнасаң да, алар бик кәефләнеп карыйлар... Аннары бер ныгып алгач, без «Галиябану»га тотынырга булдык. Моның да сәбәбе аңлашылса кирәк. Беренчедән, «Галиябану» — бик танылган әсәр, халык аны яратып карый, икенчедән, һәрбер драмтүгәрәк «Галиябану»-ны уйнап, тамашачы алдында үзенчә имтихан тота, шуны ерып чыга алса, ул инде тагы да зуррак әйберләрдән курыкмый башлый, өченчедән, «Галиябану» — уйнар өчен бик күңелле, бик мавыктыргыч нәрсә. Кыскасы, бөтен клублар, бөтен түгәрәкләр уйнап күрсәткән әйберне нигә безгә дә куеп карамаска дидек без... Һәм, азаплана торгач, куйдык та. Әйтергә кирәк, бик кызыклы, бик әкәмәт килеп чыкты безнең «Галиябану»ыбыз!.. Әлбәттә, зур газаплар белән ирештек без бу «уңыш»ка. Иң элек, һәрбер

түгәрәктәге шикелле үк, бездә дә һәртөрле ризасызлыклар, үпкә-рәнҗүләр рольләрне бүлүдән башланып китте. Төп героиня Галиябану роленә ике кызыбыз бар иде: Хафаза һәм әлеге Бибинур. Хафаза Галиябану булырга җан атып тора, ләкин Бибинур буе-сыны, матуррак җырлавы белән Галиябануга күбрәк килә төшә. Мостафа белән без шактый кыен хәлдә калдык. Икебез дә Галиябануны Бибинур уйнарга тиешлеген белеп торабыз, ләкин шуны туры гына әйтергә Мостафа, бичара, миннән курка, ә мин Хафазадан шүрлим. Аның теләгенә каршы килеп, үпкәләтәсем килми иде. (Шунда белдем, һәвәскәрләр һәм гомумән артистлар арасында роль өчен талаш бишектән үк башлана, ахрысы.) Инде бу мәсьәләне тиз генә чишә алмагач, без Хәлил роленә күчтек. Хәлилгә исә безнең яраклы кешебез юк иде. Кемнән уйнатырга? Мостафа үзе буе-сыны белән бик туры килә, һәм әйбәт уйнаячак та ул, әмма җыр юк, җырдан бөтенләй мәхрүм... Нишләргә инде дип аптырап торган чакта, кемдер Миңнулла исемле егетне безнең исебезгә төшерде. Миңнулла бар бит, коеп куйган Хәлил, менәтерә! —диде. Чынлап та, безнең түгәрәк тирәсендә йөргән, ләкин моңарчы бер спектакльгә дә катнашмаган андый егет барын белә идек. Дәшеп алдык үзен. Җырлатып карадык. Көчле, матур тавыш — шәп җырлый, каһәрең!.. Менә дигән Хәлил, артыгын эзлисе дә юк. Ну... кыяфәт суя!.. Тәбәнәк, юантык, аяклар да кылтый-былтый, бите дә шанхайчарак. Ничек ярата алыр икән Галиябану мондый Хәлилне — ай-һай?! Ләкин Миңнуллага конкурент юк, үзе дә: «Һи, уйныйм мин аны!» дип кенә тора. (Хәлилне кем генә уйнамас!) Җилкәләрне кашыдык та егеткә рольне бирергә булдык. Грим, кием, биек үкчәле итекләр егетне тартып-сузып Хәлил ясамасмы, дидек.

Сөйгән егет Миңнулла буласын белгәч, Хафаза да бик тиз сүрелде. Мин дә аның колагына әкрен генә: «Көнләшәм, иркәм, мин сине Миңнулладан»,— дигәч, ул бөтенләй Галиябану роленнән баш тартты. Ә Бибинур —күндәм кыз, берсүзсез риза булды һәм, әйтергә кирәк, Миңнулланы бөтен йөрәге белән яратырга тырышып, бик матур җырлап, елатырлык итеп уйнап та чыкты.

Исмәгыйльне Мостафа уйнады. Дөрес, башта ул, күңеле нидер сизенгәндәй, бу рольгә бик каршы торды, ләкин без инде аны көчли-көчли дигәндәй ризалаттык. Безнеңчә, ул үзе дә бай малае, аңа бай малае булып кыланасы юк, чыгасы да уйныйсы гына... Һәм без, билгеле, ялгышмадык: сәхнәдә тере Исмәгыйль үзе иде! Буй-сын шәп, кием шәп, ә уен? Судагы балыкмыни — йөзә генә егетең!.. Әмма моның нәтиҗәсе нәрсә булып чыкты диегез?.. Су буе күре-

нешендә Мостафа-Исмәгыйль белән Миңнулла-Хәлил беренче тапкыр очрашкач, тамашачы аптырый да кала. Торабара бу аптырау чын-чынлап гаҗәпләнүгә әйләнә: күпләр, бигрәк тә хатын-кызлар, ачыктан-ачык: «Чистый юләр икән бу Галиябану, шундый сөлек кебек егетне яратмыйча, бер бүкәнгә гашыйк булган, тиле!»— дия башлыйлар... Бичара Миңнулланың бик киерелеп матур итеп җырлавы да тамашачыны үз ягына аудара алмый (хикмәт җырлый белүдәмени), хәтта бай малаеның аны атып үтерүе дә гомуми тәэсирне үзгәртми диярлек.

Шулай итеп, спектакль, Исмәгыйль файдасына бетте. Минемчә, бер генә театр, бер генә түгәрәк тә мәшһүр «Галиябану»ны болай уйнап күрсәтмәгәндер әле... Әлбәттә, бу мактану түгел, киресенчә, без барыбыз да шактый хафага төштек, бигрәк тә Мостафа үзе ниндидер ярамаган эш эшләгән кешедәй бик борчылып йөрде. Мин аның хәлен аңлый идем: үзе бай малае булгач, Исмәгыйльне нинди шәп уйнады дип әйтүләреннән курка иде ул, мескен! Асылда исә монда беркемнең дә гаебе юк. Исмәгыйль табылды, ә Хәлил — юк, бары шул гына. Хәер, алай дисәң, Миңнуллабыз Хәлилне уйнавыннан башын чөеп, бик һаваланып йөрде. Драмтүгәрәкләрдә шулайрак инде ул — уйнау важно, ә ничек итеп уйнау түгел... Озын сүзнең кыскасы, «Галиябану»ны куеп, без, кемдер әйтмешли, бик әйбәт кенә фәс кидек. Аның каравы, шактый тәҗрибә туплап калдык, хәзер инде тагы да зуррагына тотынырга була.

Ярый, бу хакта күбрәк сөйләп ташладым, ахрысы. Сине, билгеле, Хафаза туташ белән минем ара кызыксындыра, шуның ни белән беткәнен тизрәк беләсең килә торгандыр. Ышан, минем үземнең дә шуңа тизрәк барып җитәсем килә, әмма капкадан кермичә өйгә узып булмый дигәндәй, монда да азрак кереш ясамыйча һич тә мөмкин түгел.

## XI

Яратышып йөрүнең һәр көне безне отыры ныграк бәйли-якынайта бара. Без хәзер гел бергә — эштә дә, урамда да, өйдә дә... Яшеренеп торулар бетте. Күпләр инде безнең исемнәрне «Хәбиб — Хафаза»— дип бергә кушып кына йөртәләр. Мишәр абзыйлар туй көтәләр. Әледәнәле миңа күз кысып: «Тизме инде, кайчанрак?» дип сорап кына торалар. Кайчак, нидер сизенгәндәй: «Син, брат, бик сузма, кызуында сук!»— дип тә куялар. Без үзебез дә, гәрчә өйләнешү турында өзеп сөйләшмәсәк тә, шуның буласына ышанып йөри башладык.

Хафаза көн дә диярлек минем бүлмәгә килмичә калмый. Чакырганда яки ияртеп кайтканда гына түгел, әтеләсә кайчан гап-гади генә килә дә керә. Минем, Бәкер дус, синең алда суфиланып (дөресрәге, ханжаланып) торасым килми... Егерме ике яшьлек егетнең хәлен беләсең, ул сөйгән яры янында чи агач булып кала алмый, ул аны сөяргә, назларга тиеш. Мәхәббәт үзе шуны сорый, кыз үзе шуны көтә, ниһаять, егетлек абруе шуны таләп итә. Без барыбыз да табигать балалары, тик «кеше» дигән зур һәм җаваплы исемебез бар... Һәм бер дә рияланмыйча гади генә итеп әйткәндә, мин дә, дөньядагы барлык гашыйклар төсле үк, сөйгән ярымны коча да, иркәли дә, үбә дә торган идем. Шунсыз инде чын ярату гүя булырга мөмкин дә түгел. Хафаза өчен дә бу шулай — аңа да яратуны гел тоеп һәм яратуын гел сиздереп торырга кирәк... Без бик якынайдык, бер-беребезгә тәмам ияләштек... Мәхәббәтнең бу гаять нечкә, яшерен ноктасына җиткәч, кеше табигате кайчак һәм көтелмәгән яктан ачылып куя.

Ничек кенә итеп әйтергә сиңа, минем Хафазам иркәләр-сөяр өчен шактый... йомшак кыз булып чыкты. Песи кебек дисәм, кимсетү булыр, һәрхәлдә, син аңлыйсыңдыр инде... Миңа гына ул шулаймы, чын, тирән ЯРАТУданмы бу?.. Вакыт-вакыт ямьсез шик күңелне тырнап куйгалый иде.

Шулай да аның миңа сыенып назланган чагында үзеннән бер сорадым:

— Хафаза, әйт әле, миңа кадәр синең берәр яраткан кешең булдымы?

— Булды,— диде ул, һич икеләнмичә.

— Кемне?

— Башта Рәүф исемле бер класста укыган малайны.

— Башта!.. Ә соңыннан?

— Соңыннан Гали исемле егетне... Җизнинең энесен...

— Хуш, тагын кемне?

— Бүтән юк.

...Тиледән сорама, үзе әйтер... Кәефем азрак кырылса да, ни гаҗәп, аңа ачуым килмәде. Һаман әле тыныч кына сорашкан булдым:

— Йә, шуннан, синең ул ике егеткә гашыйк булуың ни белән бетте?

— Берни белән дә бетмәде.

— Ничек ул алай?..

— Менә шулай... Алар бит бернәрсә дә белмәделәр. Үзеннән-үзе үтте дә китте.

Валлаһи, аның бу кадәр ваемсыз, хәйләсез сөйләвенә аптырап, мин ни дияргә дә белмәдем. Шактый дәшә ал-

мый торгач, ул үзе башын минем күкрәгемә терәп, пышылдап кына сорады:

— Син ачуланмыйсыңмы?

— Юк,— дидем мин, аз гына көттереп.— Хәер... Синең гашыйкларың арасында өченче кеше булу минем өчен бик үк күңелледән түгел.

— Ни сөйлисең?! — диде Хафаза, курыккандай.— Син беренче, син минем беренче мәхәббәтем, мин хәзер генә яратуның нәрсә икәнен белдем.

— Ә тегеләр?

— Әйттем ич, үтте дә китте, дип... Бер җүләрләнү генә иде ул.

— Алдамыйсыңмы?

— Ышанмасаң, менә йөрәгемне ачып кара. Анда син генә, Хәбиб, син генә!..

Һәм аның өзелеп әйткән бөтен сүзе, йөрәген ачарга теләгәндәй киерелеп миңа сыенуы бернинди шиккә урын калдырмый иде кебек... Әмма шулай да нинди йөрәк, нинди җан соң бу кечкенә, иркә, йомшак кызда?.. Үзе кушканча, аның йөрәген ачып карап булмый лабаса!

— Ә син, дустым, миңа ышанасыңмы? — дидем мин, ниһаять.

Ул дымлы күзләрен тутырып, сәерсенеп миңа карады:

— Аңламыйм... Нигә алай дип сорыйсың?

— Минем әйтәсем килә: әгәр мин сине алдасам, ташласам...

— Юк, юк,— диде ул, ишетәсе дә килмәгәндәй кабаланып,— син мине алдамыйсың, син мине рәнҗетмисең... Мин сиңа ышанам, бәгырем, ышанам!

Менә хикмәт нәрсәдә икән!.. Ул миңа ышана, тәмам буйсынган хәлдә, актык чиккә җитеп ышана... Әйе, ул, минем Хафазам, бик нечкә күңелле, бик тиз хискә бирелүчән, сагаюны белми, әмма ләкин бу аның йомшаклыгымы соң?.. Кайбер җан иясе дә үзен шулайрак тота түгелме?.. Әйтик, яшь колын кешене үзенә якын җибәрә, муеныннан, сыртыннан сөйдерә һәм, билгеле инде, кеше миңа кинәт искәртмәстән китереп сугар дип һич тә көтми ул... Минем Хафазам да әнә шундыйрак — ул да алдауны, явызлыкны көтми, аның булуына ышана алмый иде.

Сүз дә юк, Хафазаның миңа сабыйларча ышануы минем өчен бик кадерле иде. Учтагы кошчык шикелле сакларга кирәк иде аны... Безнең кавышыр көннәребез алда әле, ә хәзергә... менә шулай саф килеш, пакь килеш яратышырга — моның үз ләззәте, үз матурлыгы да гаҗәп бит!.. Ул сиңа буйсына, ә син аны саклыйсың — бу чын мәхәббәт өчен зур горурлык түгелмени, Бәкер дус?!

Билгеле инде, мин үзем дә Хафазага ышандым, беткәнче җаным-тәнем белән ышандым, алай гына да түгел, бөтен уй-фикерләремне бары аңа гына сөйлисем килеп тору минем күңел ихтыяҗына, ниндидер бер заруриятка әйләнде. Хафаза минем мәхәббәтем, мин аның каршында көн кебек яп-якты булырга тиешмен дип уйлый идем... Шуңа күрә күңелемә ни генә килмәсен, шунда ук мин аны Хафазама җиткерә торган идем. Барысын — зурысын да, вөк-төяген дә... Хәзер инде авыздан ниләр чыкканын хәтерләп бетерү мөмкин дә түгел, ләкин шулай да сүзнең күбрәк мәхәббәт тирәсендә әйләнүен яхшы хәтерлим. Үземнең яратуым хакында, бәлки, күп тә әйтмәгәнмендер («яратам»ны еш кабатларга яратмый идем), ә менә мәхәббәт турында гомумән акыл сату күп булгандыр — бу бит гашыйкларның бер бәласе... Аннары мин аңа еш кына шигырь укый торган идем — Гомәр Хәйямнан алып үзебезнең Такташка хәтле... Син беләсең инде, поэзия ул минем «чирем» иде.

Рабфакта укыган чакта ук соңгы тиеннәргә булса да зур шагыйрьләрнең шигырь китапларын алгалый идем; аннан минем бер калын дәфтәрем бар иде — менә шуңа күңелгә ошаган шигъри парчаларны, акылияләренең үткен, тапкыр сүзләрен, шулай ук үземнең кайбер күзәтүләремне язып бара торган идем. (Җәяләр эчендә генә әйтеп китим, Хафаза миңа килгән саен бу дәфтәрне бик кызыксынып актарып утырырга ярата иде...) Кыскасы, мин сөйгән ярым белән урамда йөргәндә дә, хәтта аны кочагыма алып сөйгәндә дә, настроениегә карап дигәндәй, шигъри юлларның төрлесеннән әз-әзләп кенә аның нәни колакларына әйткәли тора идем. Хафазаның шуңа бик кәефе килә иде, гүя тәмле шәрабтан авыз иткәндәй, әзрәк исереп киткән төсле дә була иде... «Яхшы!» дип куя иде ул еш кына, башын чайкап...

Әнә шулай шигырь белән, ихлас сөйләшү һәм гөнаһсыз үбешүләр белән күңелле-матур гына, рәхәт-тату гына бара иде безнең бу дуслык-мәхәббәтебез... Һәм менә көннәрдән бер көнне кинәт барысы... җимерелде, бетте, юкка чыкты. Әйтерсең минем аяк астымда җир упты — мин каядыр түбәнгә мәтәлеп төшеп тә киттем... Син инде шаккатып калгансыңдыр, колакларыңа ышанмыйча: «Бу ни хәл, ни булды?» — дип куркынып, тизрәк сорыйсың киләдер... Аз гына сабыр ит, Бәкер дус! Синең кебек исләре китеп аптыраучылар аз булмады, хәтта менә мин үзем дә күпме еллардан соң һаман да әле ни булганын ачык кына төшенеп бетә алганым юк... Дөрес, теге чакта кайберәүләр миңа әйттеләр, син Хафазага артык ышан-

гансың, менә шунда синең хатаң, диделәр. Ләкин мин бу фикерне кире кактым, катгый рәвештә! Яраткан кешеңә ышанмыйча мөмкин түгел, абсурд бу!.. Әгәр без яратуны ышанудан аерсак, дөньяда мәхәббәт дигән нәрсә бетәр, юкка чыгар иде... Юк, мин ышануыма үкенмим, Бәкер дус, һич тә үкенмим. Әмма ышануны кем ничек аңлый — бу инде бөтенләй икенче мәсьәлә.

Сүз дә менә хәзер нәкъ шул турыда барачак. Тик моңарчы сөйләгәннәрдән шуны исеңдә тот: мин Хафаза белән утызынчы елның җәй ахырында танышып йөри башладым; көзге, кышкы айларда инде безнең дуслык бик тирәнгә керде, өйләнешү теләге дә туды, гәрчә бу хакта өзеп кенә сөйләшмәсәк тә, эшнең шуңа таба баруын икебез дә бик яхшы белеп тора идек. Ләкин утыз беренче елның февраль башларында миңа кинәт кенә авылга кайтып китәргә туры килде. Әни карчык каты авырып киткән икән, өйдән чакырып язган хат килеп төште, һәм мин үз исәбемә бер атналык отпуска алдым да тиз генә Япанчыга китеп бардым.

## XII

Япанчы минем туган авылым — шунда тудым, шунда үстем. Туган авыл! Мактарга кирәктер инде аны, ләкин нәрсә дип мактыйм?.. Зур да түгел, кечкенә дә түгел, ике мәчетле гадәти генә татар авылы. Җире-суы да тирәяк авылларныкыннан бер нәрсәсе белән аерылмый. Үрләр, үзәнлекләр җәелгән шәрә кырлар, чокыр-чакырлар, вак куаклыклар, үз урманы юк. Казна урманы авылдан биш чакрымда — без, малайлар, җыйнаулашып шул урманга җәен какы, балтырган, җиләк җыярга, көзен чикләвеккә, баланга йөри идек. Авылның кечкенә инеше бар, түбән очтарак юкә бәйләмнәре, арба көпчәкләре, кисмәкләр батырырлык сай гына буасы да бар — без шуның пычрак суында, борын төбенә кара мыеклар чыкканчы, шапыр-шопыр коена торган идек. Хәзер болар барысы да калын кар астында инде.

Картайды җиһан!
Гөлләр дә бетте.
Кичмәктә заман —
Кышлар да җитте.
Иелде ботаклар,
Карлар асылды;
Таулар, болаклар —
Бар да басылды...

Әйе, әнә шулай балалык хатирәләре дә акрынлап ел-

лар астында күмелеп кала баралар. Туган авылым белән мине бәйләгән җепләр соңгы елларда бик нечкәрде. Сирәк кенә кайткалый торган кунак кына хәзер мин монда... Хуҗалык бетте диярлек, чөнки хуҗа кеше юк, абый Ташкентта утырып калды, апайлар кияүгә чыгып киттеләр, мин дә укырга китеп бардым, шулай итеп, таралышып беттек. Кайчандыр түгәрәк, таза гына тормышның болай бетүгә йөз тотуы әткәй үлгәннән соң башланды. Унсигезенче елны бөтен илгә таралган рәхимсез тиф алып китте аны... Шул чагында әнкәй дә авырды, апайлар да авырды (тик мин генә нишләптер авырмадым), барысы да әкренләп аякка бастылар, ә менә иллегә дә җитмәгән тап-таза ир күтәрә алмады — сынды да куйды. Миңа ун яшь иде, «ятим» дигән сүз иң кызганыч сүз булып тоела иде — инде менә мин дә ятим калдым. Боегып, мескенләнеп йөрдем, кызгану көттем, ләкин кызганып, баштан сыйпап узучы булмады шикелле, чөнки вакыты ул түгел иде, бик буталчык, киеренке вакыт иде — кеше кайгысы киштәдә!.. Без үзебез дә югалту хәсрәтен тиз оныттык...

Әткәй үлмәс борын әле абыйны да Кызыл Армия сафларына алганнар иде. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә безнең йорт ике кулсыз торды да калды. Моның нәтиҗәсен ничек кенә аңлатырга?.. Ике тәртә берьюлы сынгандай, безнең тормыш арбасы бик тиз түбәнгә таба тәгәри дә башлады. Башта әкрен-әкрен, аннары отыры кызурак... Кучәрдән тәгәрмәчләр берәм-берәм ычкынган шикелле, атайдан калган күпме-азмы мал-мөлкәт тә һаман югала-бетә барды... Бер ел эчендә ике аттан бер алашага, ике сыердан бер сыерга калдык, сөрү, чәчүнең чиреген дә эшли алмадык, азык кытлыгы, курмы кытлыгы чынлап торып өебезгә керде... Ул арада егерме беренче елның ачлыгы да килеп җитте. Һай, ул ачлык!.. Тәмам бетереп, очлап куя язды ул безне... Кыш кергәнче үк әле ак келәтне дә сатып ашадык, җирән алашаны да ашадык, тимерле тарантас та тамакка кереп китте, инде яшькелт-кара алабутадан башка ашар нәрсә дә калмады. Әни шешенде, апа шешенде, минем яңакларга тырпаеп соры төкләр чыкты; ахрысы, берәм-берәм сәкегә сузылып үләргә генә калды дигәндә, ярый әле, абый Ташкенттан кайтып, безне ачлык тырнагыннан йолып алды. Бай яктан шактый акча белән кайткан иде ул, бәясе-ние белән хисаплашып тормыйча, чувашлардан бер еллык печкән үгез дә алып суйды, күрше базардан бер-ике капчык алабута оны белән ярты капчык арыш оны, тагын күпмедер тары да алып кайтып бирде. Шул рәвешчә атна-ун көн эчендә әниләргә кыш чыгарлык азык җыеп калдырды да, мине үзе белән ияртеп, яңадан Ташкентка китеп тә барды.

Бик озак бардык без ул Ташкентка — җүләр әйтмешли, әллә ике атна, әллә өч атна. «Икмәкле шәһәр»нең юлы ай-һай озын, ай-һай авыр икән лә. Самара станциясеннән ычкына алмыйча ничә көн җәфаландык. Галәмәт зур, биек вокзал эче ачлыктан качып баручы, бетләп беткән сәләмә агайлар, хатын-кызлар, бала-чагалар белән шыгрым тулы. Аяк басар урын да юк. Шунда мин беренче тапкыр кешенең җан биргәнен күрдем. Абыйның чемоданы өстендә бөрешеп кенә утырып тора идем, миннән нибары ике-өч адымда гына таш идәндә чалкан сузылып яткан бер урыс карты, биек түшәмгә каерылып карагандай, әллә ничек тагы да сузыла төшеп, сакаллы ияген кинәт-кинәт кенә бер какты, ике какты да тынып та калды. Шунда ук күзләре аларып, артка таба киткәндәй булды... Нишли икән бу дип, аптырап, куркынып тора идем, ул да булмый, янында утырган марҗасы: «Үлде!» — дип чырылдап та җибәрде... Ләкин аның бу ачы тавышы, коега төшкән таш кисәгедәй, гөж-ж итеп улап торган вокзал эчендә юньләп ишетелмичә дә калды. Борылып караучы да булмады. Мәхшәр! Җылаш-талаш, акыру-бакыру, бәрелү-сугылу — кая монда кеше үлде дип аяк астына карап тору?! Тик минем генә миемдә уелып калды урыс агайның соңгы тапкыр ияк кагуы... Озак газаплады ул мине...

Әмма Ташкент үзе безне чалт аяз көнге, җылы кояшы белән каршылады. Кыш бит, ә нинди җылыкай! Икмәге авызыма эләккәнче шушы сары майдай җылысы минем ачтан кибеп күшеккән тәнемне рәхәтләндереп, эретеп җибәрде. Гүя кояш эчемә үк кереп оялады, атна буенча мин шуны гына тоеп, шуңа гына сөенеп йөрдем.

Аннары бераздан абый мине приютка, Рәсәйдән килгән ач балалар йортына урнаштырды... Монда алабутаны түгел, арыш ипиен дә белмиләр, ашаганыбыз — ап-ак калач та дөге боткасы. Өрек, йөзем, шыпталы. Өстә ак бүздән күлмәк-ыштан, башта — дупы (үзбәк түбәтәе)... Торган җиребез тәбәнәк дувал белән әйләндереп алган зур җимеш бакчасы — чылтырап арыклар ага, түгәрәк һәүзләр елтырап ята... Бөтенләй икенче дөнья!.. Бер кызык искә төште әле: кайчандыр Бохара әмиренә: «Галиҗәнап, фәлән илдә халык ачлыктан кырыла»,— дип әйткәч, әмир бик гаҗәпләнеп: «Нигә соң ул халык пылау ашамый икән?» — дип сораган, имеш. Белмим, аның үз халкы пылау гына ашап тордымы икән?.. Һәрхәлдә, әмирне куганнар. Менә мин дә хәзер шуның гөл багында яшим төсле... Кемгә рәхмәт әйтергә — абыйгамы, үзбәк халкынамы, Совет властенамы?.. Әмма аңлый төшкәч, мин бу рәхмәтнең иң олысын әүвәл

үзебезнең властька, Совет властена, аннары киң күңелле үзбәк халкына йөрәгемдә саклап йөрттем... Хәер, бер мин генәме соң бу рәхмәтне йөрәгендә саклап йөртүчеләр?!

Мин инде приютта торганда күргән һәртөрле авырлыкларны, ямьсез якларны искә төшереп, сөйләп тормыйм. Җылы якта да бит гел аяз, кояшлы көннәр генә булып тормый — сөякләргә үтәрлек салкын томанлы, җепшек көннәр дә булгалый. Шуның төсле, кырык ата баласы җыелган җирдә дә төрле хәлләр — талаш-ызгышлар да, сызланып рәнҗүләр дә, хаксызга түгелгән күз яшьләре дә — һәммәсе дә булып торды. Ләкин адәм баласы гадәттә начарын онытырга, яхшысын гына хәтерендә сакларга ярата... Иң мөһиме шул — безне сакларга, укытырга, кеше итәргә тырыштылар.

Ике ел чамасы вакыт үткәч, буй җиткән үсмерләрне, приюттан чыгарып, төрле җиргә эшкә яки уку йортларына урнаштыра башладылар. Шул чакта мин илгә кайтып китәргә булдым. Абый да каршы килмәде — ул үзе дә әле өйләнмәгән, күбрәк командировкаларга йөрүче ялгызак бер кеше иде. (Соңыннан минем абый, ниндидер ике еллык курслар бетереп, юрист булып китте.) Кыскасы, Ташкент бик әйбәт, пылау да бик тәмле, әмма авылны, өйне, әнине шулкадәр сагындым, күземә берни күренми башлады.

Өс-башны яхшы гына бөтенәйтеп, шактый гына тансык күчтәнәчләр төяп, җәй башында кайтып төштем мин үзебезнең Япанчыга... Авыл, авыл... нинди тын һәм нинди буш!.. Әллә ничек сәер генә. Искерә дә төшкән, чүгә дә төшкән, боега да төшкән кебек... Ишек-тәрәзәләре кагылган өйләр яки бөтенләй бушап калган ихаталар да очрый — ачлык елның галәмәтедер инде бу... Ә шулай да никадәр таныш, никадәр якын ул миңа!.. Ник бер генә капкасы, бер генә агачы, бер генә сукмагы онытылсын!

Бу ике елда мин буйга бик үсеп киткәнмен, ахрысы —әнкәй дә кечерәйгән, апай да кечерәйгән, хәтта өйалды ишегеннән дә бөкрәебрәк керергә туры килә. Ә авылдашлар танымыйлар да: «Бәй, синмени бу, Хәбиб? Прәме егет булгансың, малай!» — диләр. Егет инде, егет, тик тавыш кына ныгып җиткәне юк әле, еш кына сынып киткәли, бигрәк тә көлгәндә «күкле-зәңгәрле» тавышлар чыгып куйгалый.

Минем кайтуыма өйдәгеләр бик сөенделәр... Сөенмичә, «йорт башы» кайтты бит... Ул җәйне миңа, хуҗа булып, җиң сызганып бик нык эшләргә туры килде. Агай-эне ярдәме белән азрак бодаен да, тарысын да чәчтек, печәнне дә чабып җыйдык, тиресен дә суктык. Ара-тирә кешеләргә дә эшләштергәләдем. Җәйнең үткәне сизелми

дә калды. Менә явымлы көз, аннары салкын кыш та килеп җитте. Шул чакта мин бер нәрсәне бик ачык аңладым: күңел минем авылдан аерылган икән инде... Авылда каласы килми, хәтта калу куркыта мине... Хыялымда бер генә уй, бер генә теләк: укырга кирәк, укырга, укырга!.. Авыл тормышы, крестьян эше минем өчен түгел, минем юлым башка булырга тиеш. Заман үзе укырга өндәп, укырга чакырып тора. Ә минем сәләтем бар, мин моны беләм инде... Озын сүзнең кыскасы, әнә шулай урыныннан купкан, һич тынычлана алмаган күңел белән тагын бер җәйне эшләп үткәрдем дә, әнкәй бичараны бик кыенлык белән күндереп, бөрмәле капчыкны яңадан иңемә астым. Юлым Казанга, үзебезнең башкалага иде... Калган ягын син беләсең инде.

Туган авылга кайткан саен үткәннәр ни өчендер гел генә искә төшә. Гүя иске сукмаклардан тагын бер үтәргә туры килә. Менә бу кайтуымда да барысын искә төшереп, уйламаган җирдән сиңа да сөйләп чыктым, Бәкер дус!

## XIII

Кайтсам, авыл, арба басып киткән кырмыска түмгәгедәй, мыжгып тора. Бу ни хәл?.. Әле утызынчы елның башында ук безнең авылны тоташ колхозлаштырып куйганнар иде. Шул чакта халык бер кузгалып, чайкалып, дулкынланып алган иде инде. Сөреләсе кешеләр сөрелеп, колхоз, ниһаять, оешып беткәч, беренче өермә-давыл үтеп киткән шикелле булган иде, ләкин бөтенләй ук басылып бетмәгән икән әле. Эш нәрсәдә?.. Моның серен миңа кайтып төшкән көнне үк белергә туры килде. Башта, теләпме, теләмичәме, колхозга кереп тулган агайлар Сталин хатыннан соң кире агылып чыга башлаганнар. Тоташ колхоз яртыга, чиреккә калган. Бу хәл оештырып йөрүчеләрне нык кына борчуга салган булса кирәк, алар ашыгыч чаралар күрергә тотынганнар. Иң элек колхоздан башлап чыккан яки чыгарга өндәгән күпмедер кешене авылдан сөргәннәр. Аннары күп кенә агайларның кергән чакта биргән атын, эш коралын, орлыгын кире чыкканда үзләренә кайтарып бирми башлаганнар (баштарак биргән булганнар)... Шуның өстенә, билгеле, һәркайсын көн дә идарәгә чакырып аңлаталар, үгетлиләр, куркытып та карыйлар — кыскасы, үз файдасын белмәгән үҗәт мужикны ничек тә хак юлга кертергә тырышалар. Ә мужик ни өчендер аңларга теләми, ни өчендер һаман дүрт аягын терәп, карышып маташа... Менә шундый талаш-тартыш вакытына туры килдем мин. Әйтергә кирәк, бу тартыш агай белән идарә арасында гына түгел, һәр өй эчендә

диярлек бара икән — хуҗа үзе икеләнебрәк булса да колхозга борыла башласа, хатыны дулап каршы тора, яки малае керик дисә, атасы тешен кысып, йодрыгын күрсәтә.

Минем үземә бу колхозлашу хәрәкәте, билгеле, турыдан-туры кагылмый иде. Мин — шәһәр кешесе. Атайдан калган өйне исәпләмәгәндә, авылда минем атым да юк, туным да юк. Шулай ук әнкәй карчык та, бездән килгән ярдәм белән, ялгыз башы гына яшәүче — колхозга кирәк кеше түгел. Моңарчы әле аңа «кер» дип әйтүче дә булмаган.

Кыскасы, менә шундый хәл. Минем, билгеле, Япанчыдагы хәлләргә тыгылырга вакытым да, теләгем дә юк иде. Ләкин икенче көнне үк күрше-тирәдәге агайлар, туган-тумачалар миңа килә дә башладылар. Янәсе, шәһәрдән кайткан егет, үзебезнең егет, укыган егет, берәр файдалы сүз ишетеп булмасмы?.. Киләләр, ачык йөз белән: «Һи, Хәбиб туган, исән-сау гына кайттыңмы?»— дип ике куллап күрешәләр, аннары ниндидер бер мескен кыяфәт белән ишек төбенә, мич буена чүгәлиләр. Ләкин зарларын әйтергә ашыкмыйлар, башта анысын-монысын, Казан хәлләрен сораштырган булалар. Һәркайсы диярлек: «Мәскәүдән ни ишетелде, Мәскәү ни яза?»— дип сорап куя. Мин инде Казан турында, Мәскәү турында белгәннәремне бер дә иренмичә сөйлим, әлбәттә, мактап, зурлап сөйлим. Шуннан соң берәрсе авыр гына сулап: «Каланың эше рәхәт!» — дип куя. Бусы инде миннән: «Нигә, авылда начармыни?»— дип әйттерер өчен... Һәм, сизә торып, шундыйрак сорауны бирәм дә:

— Нигә, авылда да бит хәзер зур үзгәрешләр бара, начармыни ул?

— Кем белсен аны! — ди әлеге хәйләкәр, уйлап тормыйча гына.

— Баруын бара да бит, Хәбиб туган, ләкин хәерлегәме соң ул? — ди икенчесе, уйланыбрак.

Минем ачыграк әйтәсем килә:

— Әгәр сүз колхозлашу турында бара икән, ул, һичшиксез, хәерлегә булачак.

Агайлар озак кына дәшми торалар. Болай алдан ук өзеп әйтүне яратмыйлар, ахрысы... Кайсы бүреген салып, башын кашый, кайсы тун кесәсеннән ашыкмыйча гына тәмәке янчыгын чыгара. Ләкин мин тәмәке тарттырмыйм (түрдә, чаршау эчендә әнкәй авырып ята). Хәер, алар үзләре дә моны беләләр — тәмәкеләрен төрәләр дә учларына гына йомып утыралар. Түземе беткәне генә өйалдына чыгып, бер-ике суырып керә.

Тагын миңа сүзне башларга туры килә:

— Сез бит инде колхозга кергәнсез, шулай булгач, нигә болай уфтанасыз?

— Кергән идек тә, чыктык,— ди арадан берсе, кинәт кыюланып.

— Керү ирекле дип әйтәләр бит,— ди икенчесе, гүя аны йомшартып.

Бу сүзләре мине шактый аптырашта калдыра.

— Кызык икән! — дим мин, ни әйтергә белмичә.

— Бик тә инде! — диде шунда өченчесе, ачулы киная белән.— Үкереп елыйсы гына, парин!

— Хәтта!.. Юк, сез ачык кына әйтегез әле, эш нидә соң?

Агайлар бер-берсенә карашалар. Кем, ниһаять, аңлатып бирә мәсьәләне?.. Гадәттә, элек мондый чакта арадан берәр олырак, тәҗрибәлерәк кеше барысы өчен әйтеп бирә торган иде. Бу очракта исә берсе дә, әллә саклык йөзеннән, әллә авызы пешкәнгә күрә, андый вазифаны һич өстенә алырга теләми. Әйтсә, бары үз уен, үзенә кагылган кадәресен генә әйтә. Мәсәлән, безнең күрше Гандәлиф абзый:

— Мин колхозга каршы түгел,— ди, алдына карап кына,— мужет, ул бик файдалы нәрсәдер. Тик мин белмим бит әле аны, колхозны әйтәм, сыналмаган эш... Менә кергәннәр эшләп күрсәтсеннәр, карыйк, әгәр дә мәгәр, әйткәнегезчә, файдалы нәрсә булып чыкса, керермен, ник кермәскә?! Мин мондагы кеше, качып китәргә җыенмыйм, Алла сакласын!

— Мөселманнар да Мөхәммәт пигамбәргә барысы берьюлы иярмәгәннәр,— ди, аңа өстәп, безгә туганрак тиешле Хисам абзый. Ул шулай китапчарак сөйли торган кеше инде.

Ә менә Күпер төбе Бәдри абзыйны башка бер нәрсә борчый икән. Бу инде кайнар, әтәчрәк кеше.

— Менә кара,— ди ул кинәт минем борын төбендә кәкре, керле бармакларын тырпайтып.— Тигезме?.. Юк, тигезме?.. Шул шул, менәтерә, аппагым!.. Ә кешеләрне тигезләмәкче булалар. Тигезләрсең син аларны! Әйтик, менә мин үзем эшләргә кирәк булса, эшлим инде, җенен чыгарам, эшең генә чыдасын... Ә әнә теге, кем, кылый Зариф, Сәхәпләр күршесе, ул бит, парин, аркылы ятканны буйга алып сала торган кеше түгел, иелеп чабатасын бәйләргә дә иренә, астына күн теккән оектан йөри... Йә, шундый кеше белән мин бер колхоз булдым ди. Мин баш күтәрми эшләрмен, ә ул минем аркада бет симертеп ятсынмы?.. Булмый бит ул алай, туган, булмый!

— Шулай шул,— диештеләр абзыйлар салмак кына.

— Туктагыз әле,— мин әйтәм.— Колхозда бит эшенә карап бирә торганнардыр, эшләсәң тия, эшләмәсәң — юк.

— Анысы шулаен шулай да, әмма Зариф кебекләр дә эшләгән булып, селкенеп йөриләр, андыйларга да язарлар, ә бәрәкәте ни?..

— Аннары,— дип ялгап китә Гандәлиф абзый,— мәсьәләнең бу ягы да бар. Кергәндә, әйтик, берәү ике аты белән, берәү бер аты белән, ә берәү кысыр кәҗәсен җитәкләп керә. Бу да бит тигезлек түгел. Мал газиз, берәүгә дә буш килмәгән.

Озын сүзнең кыскасы, Бәкер дус, агайларның мондый зарлары, шикләре күп булды, әгәр барысын да язып китсәм, бик күңелсезгә әйләнер иде. Үзең күрәсең, монда колхоз дигән яңа, сыналмаган нәрсәдән курку да бар, ата-бабадан килгән, күнегеп беткән тормыштан аерыласы килмәү дә бар, «үземнеке» дип чат ябышып яткан мал-мөлкәтен кызгану да бар — җыеп кына әйткәндә, авыл кешесенең чуар, каршылыклы характерына нәрсә хас булса, шулар барысы да бар... Ни әйтергә, ни диеп җавап бирергә тиеш идем мин аларга?.. Колхозны әле мин үзем дә якыннан күреп белмим, ә болай акылым белән генә аның нәрсә икәнен күз алдыма китерәм. Шуңа күрә бөтен әйткәнем: «Абзыйлар, юкка борчылмагыз, төрле шикләрегезне ташлагыз, колхоз ул сезнең өчен, сезнең файдага, шуңа бик нык ышаныгыз!» — бары шул гына иде. Ләкин, билгеле инде, моныңише гомуми сүзләр аларның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга — чөнки минем кебек сакалсыз димләүчеләрдән алар аны бик күп ишеткәннәр. (Арадан берсе: «Колхозны башлап йөрүчеләр дә бит җыен яшь-җилкенчәк, нәрсә белә алар?» — дип әйтеп тә куйган иде.) Чөнки һәркайсының үз уе, үз исәбе бар, шуңа җавап көтә ул... Кызык бер момент: мин сөйләп беткәч, Гандәлиф абзый бүрегенең эченә карап, сакланып кына әйтә:

— Һәркемнең җилкәсендә үз башы бар, нәрсә аңа файдалы, нәрсә зарарлы, үзе хәл итәр, тик менә...— Ләкин әйтеп бетерми.

— Тик... нәрсә соң, Гандәлиф абзый?

Гандәлиф абзый, авыр сүзен ничек чыгарырга белмәгәндәй, иреннәрен сәер генә кыймылдаткалап тора:

— Тик... көчләмәсеннәр иде, туган! — ди ул, ниһаять.

— Көчләү?.. Нинди көчләү?

— Һи... һи-һи,— дип көлештеләр агайлар.— Син юләр сатма инде, Хәбиб туган, бала түгелсең ләбаса!

— Юк, мин чынлап сорыйм,— дим, нигәдер уңайсызлана төшеп. Шунда ук берсе тун кесәсеннән әллә ничәгә бөкләп тыккан иске газета тартып чыгара.

— Менә моны укыгансыздыр инде... Сталин хатын? —

ди ул, тузып, тетелеп бетә язган газетаны сак кына ача башлап.

— Укыдым, билгеле.

— Соң, шулай булгач?! Монда бит крәстиянне колхозга көчләп кертергә ярамый дип акка кара белән язылган... Көчләү булмаса, язар идемени?

— Ә сез хатның исеменә игътибар итегез: «Уңышлардан баш әйләнү» диелгән бит. Ягъни бөтен җирдә дә крестьяннар колхозга үзләре теләп, оешкан рәвештә керделәр, тик кайбер урыннарда гына тизрәк колхозлаштырып бетерү өчен көчләү юлына аяк басулар булды дип яза ич иптәш Сталин...

— Бездә дә ул шулайрак булды...

— Ничек булды?

— Башта өеребез белән кердек... Берәүләр теләп, берәүләр ияреп, берәүләр куркып дигәндәй... Аннары... менә кире чыктык.

— Ни өчен?

— Иптәш Сталин хаты күзебезне ачты. Теләмәсәң, кермәскә дә була икән.

— Димәк, сез колхозга бер дә керергә теләмисез инде?

Агайлар дәшмиләр. Аларның йөзләре ничектер шунда ук йомыла, иреннәре кысыла, күзләре каядыр читкә төбәлә — яратмыйлар алар бу сорауны, яратмыйлар!.. Тик болай дәшми тору уңайсыз була башлагач кына Бәдри, теш арасыннан чыгаргандай, мыгырданып әйтеп куя:

— Хикмәт анда түгел!

— Нәрсәдә соң?

Һәм ул кинәт кенә кычкырып сала:

— Көчләү булмасын!.. Әйе, менә шул, көчләү булмасын!

Аңа тизрәк ярдәмгә килгән кебек, башкалар да берьюлы шаулап үзләренекен әйтергә ашыгалар:

— Закон бозмасыннар!

— Без, мужет, иртәгә үк барып керербез, түлке үз аягыбыз белән. Ирекле дек ирекле!..

— Соң! Кәҗәне генә мөгезеннән сөйриләр.

Агайларның бу сүзләрен ишеткәч, кылт итеп исемә төште: Горький үзенең бер әсәрендә бер герой авызыннан мондый сүзләрне әйттерә: «Я не позволю тащить меня на веревке даже и в рай...» Күрдегезме, кеше нинди ул?!

Ләкин миңа агайларны ничек тә тынычландырырга кирәк иде:

— Туктагыз әле,— дим,— башта кергәнсез, аннары үз иркегез белән чыккансыз, бу көчләү буламыни?

Агайлар тагы да яманрак шаулап, ачулы-зәһәр итеп көләргә тотыналар:

— Их-хи-хи! Тә-тә-тә! Ну, Хәбиб! Сөннәткә утыртылмаган баламыни!.. Белмисез икән, туганкай, безнең мондагы хәлләрне, гүпчем дә белмисез икән... Әһ, егетләр!

Менә шуннан соң алар минем аптыраган башыма безнең Япанчыда булган көчләү-кысуларның төрле мисалларын яудыра башлыйлар: кемнеңдер чыккан чакта атын бирмәгәннәр, ат урынына җигәргә ярамаган тай биргәннәр; кемнеңдер, ниндидер сылтау белән, сыерын тартып алганнар, бик күбесенә орлыкларын һаман да бирмичә йөртәләр икән; барысына диярлек әллә нинди адәм күтәрә алмаслык заданиеләр салып бетергәннәр. Ә җиргә килгәндә, берсен дә яңадан элекке үз басуларына чыгармаганнар, төрле ташландык түбә җирләрдән кисеп биргәннәр... Жалу белән йөрергә ярамый, йөрсәң — артыңнан: «Бу кеше колхозга каршы коткы тарата» дип язалар да бирәләр — шуның белән эшең бетте, кодагый! Әнә Түбән оч Шәрифулланы авылдан ук сөргәннәр. Ни өчен диген! Янәсе, өй борынча кереп, әйдәгез, уптым чыгабыз дип котыртып йөргән, имеш. Үзе дә юләр инде. Башы нужадан, аягы чабатан чыкмаган бер йолкыш югыйсә, ә теле аркасында подкулачник булып китте дә барды.

Белмим, бу зарларның күпмесе ни дәрәҗәдә дөрестер. (Авыл кешесе гомумән үзен кызгандырырга бик ярата.) Ләкин, ничек кенә булмасын, алар юкны сөйләп утырмыйлар, алар башларына төшкән, үзәкләренә үткән нәрсәләрне — һичшиксез, күпмедер дәрәҗәдә булган нәрсәләрне —ачынып-әрнеп сөйлиләр. Моңа ышанмыйча мөмкин түгел, һәм, билгеле инде, минем бу көчләүләргә, бу хаксыз рәнҗетүләргә ачуым килә. Бигрәк тә үзебезнең халыкны, үзебезнең чын крестьянны көчләү-кысу белән килешү һич мөмкин түгел, бу бик хәтәр-куркыныч нәрсә!.. Мин моны беләм, хаклы булуымны беләм, әмма менә хәзерге очракта мин нәрсә эшләргә тиеш, нәрсә эшли алам — монысына һич акылым җитми... Каядыр, кемгәдер барып, турыдан-туры гына Япанчыда агайларны көчлиләр, кыерсыталар дип әйтеп булмый — моны фактлар белән исбат итәргә кирәк, ә фактларны башта әйбәтләп тикшерергә, белергә кирәк булачак. Моның өчен кайда вакыты, кайда шарты?.. Шуның белән бергә мин бер хакыйкатьне бик яхшы белеп торам: колхоз яшәргә, колхоз ныгырга тиеш, һичбер нинди киртәләргә, һичбер нинди корбаннарга карамастан!.. Бу эшкә хәзер бөтен партия һәм совет органнары, милиция, суд, комсомол — барысы да җигелгән, барысы да, таугa авыр йөк тартып мендергәндәй, колхозны тарталар. Мондый гаять киеренке буталчык бер вакытта гаделлек эз-

лим дип ак-караны аермыйча, белер-белмәс барып тыгылу — каш ясыйм дип күз чыгару гына булыр иде.

Хәер, агайлар үзләре дә миннән ходатай булып йөрүемне сорамадылар. Минем авыру әнкәй янына кыска гына вакытка кайткан кеше булуымны алар күреп торалар. Бөтен сөйләгәннәре эчләрен бушатыр өчен дә берәр акыллы киңәш ишетер өчен генә булды, ахрысы. Шулай да мин аларга бик ныгытып, сезне колхозга көчләп кертү булмаска тиеш, партия алай кушмый, партия аңлату, үгетләү юлы белән генә крестьянны колхозга тартырга куша, әле Ленин да урта хәлле крестьяннарны җәберләү-көчләүдән бик сак булырга кушып калдырган, дидем; әгәр инде шуңа да карамастан сезне монда төрлечә кысалар икән, хаксызга кыерсыталар икән, сезнең бу турыда районга, Казанга, хәтта Мәскәүгә чаклы да язарга хакыгыз бар — куркып тормагыз, дидем. Шуның белән бергә мин, билгеле, кабатлап алар өчен колхозга керүдән башка чара юклыгын, иртәме-соңмы барыбер шуңа ышанырга туры киләчәген дә әйттем. Абзыйлар яңадан бәхәскә кереп тормадылар, йомылып сүзсез генә тыңладылар да авыр гына кузгалып, болай хәтер өчен генә: «Рәхмәт, туган!» — дип чыгып киттеләр.

Әлбәттә, мин аларны нәрсәгә дә булса ышандырдым, үзгәрттем дип һич уйлый алмыйм, чөнки, Тукай әйткәнчә, шигырь (бу очракта — сүз) башка да дөньяны әйләндергән чыгыр башка!.. Һәркайсы үзенең нindидер ихтыяҗы, нindидер зары белән килгән булса, шуларны үзе белән, бүреге эчендә, кире алып та китте... Шуңадыр инде минем күңелдә авыр бер төер утырып калды һәм бу төер миңа тынычлык бирми башлады.

Мин колхоз председателе Хәйрүш абзый белән сөйләшеп карарга булдым — барыбер аның янына кереп, күрешеп чыкмыйча ярамас. Алдан шуны әйтим: минем әнкәй салкын тидерүдән үпкәсе шешеп авырган булган. Ул чакта бу күпләрне теге дөньяга алып китә торган хәтәр авыру иде. Ләкин, бәхеттән, мин кайтканда әнкәйнең кризисы узган, эш әкрен генә юнәюгә таба борылган иде. Әмма шулай да мин, берничә көн бер яры да чыкмыйча, гел аның янында булырга тырыштым. Аны өзлегеп-нитеп китүдән сакларга кирәк иде. Бер җирдән дә салкын-мазар үтәрлек булмасын дип, урынын да түр сәкенең тәрәзәдән ераграк почмагына күчердек, чаршау да кордык, әйләнәсенә өстәп ястык-мендәрләр дә салдык. Ярый әле, күрше авылдан кече апай да кайткан иде, ул авыруның төрле ихтыяҗларын үтәсә, мин аның аяк очыннан китмичә, әледән-әле пульсын капшап, кул сырты белән температурасын чамалап,

бигрәк тә гел кибеп барган иреннәренә шикәрле җылы чәй эчереп тордым. Ул елларда хәзерге антибиотикларның берсе дә юк — кеше авыруны күбрәк үзе генә җиңә ала иде. Чыдам, сабыр, арык кына гәүдәле әнкәйнең моңа көче җитте — берничә көннән күзләре ачылды, сөйләшә башлады, әз-мәз генә тамагына каба башлады. Без дә апай белән бер иркен суладык — иншалла, куркыныч үтте шикелле... Ул арада минем китәр көнем дә килеп җитте.

Иртәгә китәм дигән көнне мин колхоз идарәсенә барырга чыктым. Авылны кар баскан, койма-читәннәрнең өстеннән үк калын көрт, тик капка аллары гына кереп-чыгып йөрерлек итеп көрәлгән, сукмаклар беткән — урам уртасындагы чана юлыннан гына барып була. Көн кояшлы, карга баткан авыл өсте гаҗәеп киң, иркен, якты, юл буйлап күксел табан эзе тонык кына елтырый, кыек читләрендә беренче тамчылардан сузылган бармак буйлык кына «сөңгеләр» җемелди, кайбер морҗалардан төтен тузгый, ишегалларында кояшка чыккан арык сыерлар күзләрен йомып, ялкау гына күшәп торалар, бер абзар түбәсеннән икенче абзар түбәсенә чыпчыклар фырлап очалар... Әле бу капкадан, әле теге капкадан чыгып киткән яки кайтып кергән берәр кара бишмәтле апай яки сары тунлы агай күренеп кала, ләкин каршыма туры гына берәү дә очрамый... Менә шушы карга күмелеп, әкрен генә кымшанып, сулап яткан тын, якты авыл өстенә карап, булачак очрашу турында уйланып барам.

...Хәйрүш абзый. Безнең Япанчыда колхоз оештыруны башлап йөрүчеләрнең иң беренчесе һәм колхозның беренче председателе — ничек каршы алыр икән ул мине? Ул да мине, мин дә аны беләм. Шахтер, коммунист кеше. Аның атасы Челән Хөснулла авылның бер ярлысы иде. Җиргә артык ябышып ятмыйча, күбрәк Идел буена китеп, крүшник булып йөрде. Аты булмады, йорт-җирен рәтләп карамады, ләкин акча төшереп кайткан чакларында синкедән генә пешергән ак күмәч ашады. Ни өчендер минем әткәй мәрхүмне ярата иде, кайтты исә, муллага бармыйча, әсмүхә чәен, бер кадак шикәрен күтәреп, безгә килә иде.

Хәйрүш абзый да әтисе эзеннән китте. Егет дип әйтерлек яшькә җиткәч тә, шахталарга китеп йөри башлады. Әле дә күз алдымда аның шахтадан кайткач, ялт иткән кара итек, кара чалбар, сары сатин күлмәк киеп, билен өч каптырмалы киң березент каеш белән буып, урам уртасыннан бик фырт кына үтеп китүләре. Корыч чыбыктай нык сеңерле, какча, җыйнак кына егет иде, усалкыю да булган дип әйтәләр. Чынлап та бер кайтуында

ул Югары оч Шәмсетдин картның Рәхимә исемле кече кызын качырып кына үзе белән алып та киткән иде.

Егерме бишенче-егерме алтынчы елларда Хәйрүш абзый әтисенең иске куышы урынына менә дигән алты почмаклы, такта түбәле йорт салдырып керде. Авылда бер йорт! Моңа исләре китүчеләр дә күп булды. Хәер, ул елларда шахтага йөрүчеләр акчаны бик мул төшерәләр икән дип сөйлиләр иде. Бигрәк тә өйләнәсе егетләр, берике кыш барып, эшләп кайтсалар, йә ат алалар, йә бура торгызалар иде. Шуның өстенә әле үзләре белән сандык-сандык чүпрәк-чапрак та төяп кайталар. Минем әнкәйнең дә сукранып миңа: «Шул хәерче Казанга киттең дә баттың, әнә шахтага йөрүчеләр, ичмасам, баеп кайталар»,— дип әйткән чаклары булгалады...

Шулай да Хәйрүш абзый Япанчы җиренә тиз генә тамыр җибәрә алмады — яңа зур өенә хатыны белән балаларын кертеп утыртты да үзе һаман шахтага йөреп торды. Яландай буш ихата эчендә шул ялгыз өеннән һәм читән абзарыннан башка аның каралты-курасы да, аты-туны да булмады. Тик авылда зур үзгәрешләр башланыр алдыннан гына ул шахтадан бөтенләйгә кайтып, җиң сызганып дигәндәй, колхоз оештыру эшенә тотынды. Ихтимал, авылның бердәнбер коммунисты булганга күрә аңа бу авыр, зур хәрәкәтне башлап җибәрергә кушканнардыр да.

Мин колхоз идарәсенә — авылдан сөрелгән кибетче Сәгъдиләр өенең урам башына барып кердем. Моннан бер ел элек кенә хуҗаларыннан бушаган бу таза, нарат өйгә казенный төс кермәгән дә кебек әле, ничектер гаилә тормышының исе, җылысы сизелә кебек — шул ук гади аш өстәле, шул ук пыяла шкаф, кара кәнәфи, шомарып беткән урындыклар, хәтта ишек төбендәге ләгән, чиләкләр дә хуҗалардан калган килеш тора шикелле... Тик өйнең бер почмагын җиңел кулдан ак такта белән бүлеп куйганнар. Председатель бүлмәсе икән ул — мин туры гына шунда уздым. Хәйрүш абзый кызыл чүпрәк япкан кечкенә өстәл артында утыра иде. Башта ул мине танымады, аннары танып алгач, урыныннан авыр гына торып, миңа кулын бирде, утырырга кушты.

Мин беренче тапкыр күргәндәй аңа карап торам — үзгәргән, бик үзгәргән Хәйрүш абзый. Элек тә карасу йөзе хәзер көйгән касмак төсле кара-сары булып киткән, күзләренә дә сары йөгергән, кайчандыр бик купшы йөрткән күперенке мыегы да нечкәреп, авызының ике ягыннан сәлперәеп төшкән. Күз төпләре шешенке, каш арасында тирән сызык. Зур, сөякчел куллары ничектер, иясенең ихтыярыннан тыш дигәндәй, өстәлдә хәрәкәтсез

ята. Күренә, абзый арган, йончыган, таушалган. Миңа килгән агайлар аның хакында сүз әйтүдән тыелсалар да, мин ишеткән идем инде: Хәйрүш бик усалланган, имеш, бер дә рәхим-шәфкать дигән нәрсәне белми, тоткан җиреннән шартлатып сындыра, имеш. Менә үзен күргәч, шуңа ничектер ышанасы килеп китте.

Шулай да сүз агай-энечә тату гына башланды.

— Кайттыңмы? — диде ул миңа.

— Әйе, кайттым... Менә әнкәй карчык авырып киткән...

— Ишеткән идем... Озаккамы?

— Юк, тиздән китәм.

— Әнкәңнең хәле ничек соң?

— Рәхмәт, әкренләп терелә инде.

— Ярый алайса,— диде Хәйрүш абзый, аннары йокымсыраган сыман алдына карап, тынып торды. Инде мин сүзне ничек дәвам иттерәсе икән дип уйлана башладым, ләкин шул арада ул үзе яңадан телгә килде:

— Калада нишлисең, укыйсыңмы?

— Юк, хәзергә эшлим әле. Рабфактан соң бер генә ел булса да эшләп алырга булдым. Бераз материаль якны рәтлисе килде.

— Кайда эшлисең?

— Меховойда, дөресрәге — мехбазада.

— Нәстә эшлисең анда?

— Мехлар сортлыйбыз.

Хәйрүш абзыйның мыек астында «Тапкансың эш!» дигән төслерәк бер елмаю чагылып киткәндәй булды, ләкин ул бары:

— Ярый, бу да ярый,— дип кенә куйды.

Мин үзебезнең производствоны мактарга ашыктым.

— Ишеткәнсездер инде, Казанда мехлар эшләп чыгару бик нык үсеп бара бит. Яңа фабрикалар салына... Эшләгән мехларның күбесе заграницага китә, без менә шуларны...

Ләкин Хәйрүш абзый, тыңлыйсы килмичә, минем сүзне бүлде:

— Син, парин, кайткансың икән инде, рабочий класс исеменнән безнең колхозчыларга берәр докладмы-ниме шунда сөйләп китәр идең. Менә бу бер дильни эш булыр иде.

Билгеле, аның болай дорфа гына сүзне бүлүе минем кәефемне дә кырды һәм шактый гына аптырашта да калдырды.

— Нәрсә турында? — дидем мин, аңлап бетермичә.

— Мало што нәрсә турында. Пример, каланың авылга ярдәме турында яки международный палажения... Крестьянның хәзер күпне беләсе килә.

Әлбәттә, Хәйрүш абзый белән сак сөйләшергә кирәк иде.

— Иртәгә китәм шул,— дидем мин, әз генә үкенгәндәй.— Алдан хәбәрләшеп тә булмады. Аннары...

— Аннары... нәрсә?

— Япанчыдагы хәлләр белән дә танышлыгым аз. Сездән кайбер нәрсәләрне сорашып беләсе дә килгән иде, Хәйрүш абзый...

— Пример, нәрсәне?

— Ну, мәсәлән, авылның күпме хуҗалыгы колхозда инде хәзер?

— Җитмеш проценты, ә язга йөз проценты белән колхозда булачак, вәт шул.

— Алай, яхшы икән,— дидем мин һәм маңгаемны сыпырган булып, аз гына уйланып калдым: җитмеш процент булуы, әлбәттә, яхшы, ләкин Хәйрүш абзыйның язга йөз процент булачак дип кистереп әйтүе миңа шактый сәер тоелды. Минем шунда ук аңа иң төп һәм иң четерекле соравымны бирәсем килде, әмма, сизеп торам, ул аны яратмаячак. Шулай да, үземчә йомшартырга тырышып, ярым сорау рәвешендә генә әйтеп куйдым: «Билгеле, агайлар барысы да үзләре теләп керә торганнардыр инде?..»

Хәйрүш абзый кызара төшкән күзләрен шунда ук миңа төбәде:

— Нигә алай дип әйтәсең? Без берәүне дә арканлап сөйрәмибез.

Юк, сөйләшү бу тонда киткәч, миңа да артык сагайган булып, сүзне икеле-микеле алып барырга ярамый иде. Әйткәч-әйткәч, ачык һәм туры әйтергә кирәк — шунсыз булмый. Әлбәттә, кызмыйча гына.

— Сүз арканлап сөйрәү турында бармый, Хәйрүш абзый, ә колхозга ирекле рәвештә керү принцибын бозмау турында бара... Иптәш Сталин хатында нәкъ шул хакта әйтелә бит. Ләкин, кызганычка каршы, ирекле керү принцибын бозулар һаман да бар икән әле.

— Кайда?

— Менә үзебезнең шушы Япанчыда ук.

— Кемнәр әйтә?

— Кемнәр әйтә дип, сүз иясе белән йөрми инде.

— Юк, бу бик важны,— диде Хәйрүш абзый, кашларын усал җыерып.— Давай, ачык әйтеп сүлә!

— Мин ачык сөйләшәм, Хәйрүш абзый... Менә агайларның әйтүенә караганда...

— Кайсы агайларның?

— Ну, шушы авыл агайларының.

— Аларның төрлесе бар, кайсын тыңлыйсың бит.

Күреп торам, председатель миннән ничек тә аерым кешеләрнең исемнәрен әйттерергә тырыша, ләкин минем һич тә әйтәсем килми иде.

— Мин дә шушы Япанчы егете, Хәйрүш абзый (Хәйрүш абзыйны еш кабатлыйм шикелле), кемнең кем булуын азрак беләм... Ләкин хикмәт анда түгел. Минем сездән әнә шул бозулар дөресме дип сорыйсым килә.

— Пример, нинди бозулар?

— Иптәш Сталин хатын укыганнан соң колхоздан кире чыккан кешеләрне төрлечә кысасыз икән... Нигә бу, чыкмасыннар, яңадан керсеннәр дипме?

— Тукта, ничек итеп кысабыз? Давай, примерын китер.

— Примерлары күп аның, нигә миннән сорарга.

— Юк, шулай да.

— Ну, әйтик, колхоздан чыккан чакта агайларның кайсына атын, кайсына орлыгын бирмисез икән.

— Кемгә, пример?

— Соң бит инде аларны үзегез дә беләсез.

— Хәлүшләрне әйтәсеңме?

— Кайсы Хәлүш?

— Теге Бoҗыр Хәлүш... Хәлиулла... Да, без аңа атын бирмәдек, ат урынына ике яшьлек тай бирдек. Ник дисәң, атын суеп сатачак та яңадан колхозга буш кул белән керәчәк. Беләбез без ул агайларны!.. Орлык белән дә эш шулайрак. Язга чаклы бирми торабыз, ату ашап бетерәчәкләр. Алар бит бергм-берәм колхозга барыбер кире кайтачак...

— Ә кайтмаса, кайтырга теләмәсә?

— Кайтмаса — күз күрер. Ә пока ярамый, орлык бик кадерле нәрсә, һәр бөртеге исәптә.

Хәйрүш абзыйның ачыктан-ачык әйткән бөтен сүзе һәм үзен шулкадәр бәйсез, хуҗа итеп тотуы мине бик гаҗәпләндерә иде. Ул бит һич акланмый, акланырга уйламый да, гүя бөтен хакыйкать аның ягында!

— Ләкин бу законсызлык була түгелме соң? — дидем мин, аңа каршы торасым килеп.

— Закон! — диде Хәйрүш абзый, мыскыллы елмаеп.— Ә колхозны таратып бетерсәк, ул законлы булачакмы?.. Син, брат, абзаң кебек адвокат булып кайткансың икән. Түлкем кемне, нәрсәне яклыйсың?!

Аның бу сүзләре, ниһаять, минем бәгыремә килеп кадалгандай булды. Ачуым килеп китте, нигә әле мин бу кешедән куркып торам дигән уй белән, кыза төшеп, туптуры үзенә әйттем:

— Мин партия боерыгын яклыйм, беләсегез килсә.

Партия крестьянны, сездәге шикелле, төрле юллар белән кысып, көчләп колхозга кертергә кушмый, кушмый гына түгел, катгый рәвештә тыя.

Хәйрүш абзый кинәт кара янып китте, күзләрендә әллә нинди чәнечкеле утлар кабынды.

— Һа! — дип куйды ул, тәмам ярсып.— Син әле, малокосос, безне өйрәтергә кайттыңмыни? Алайса, белеп тор: партия кушкан иң зур эшне эшлибез, без колхоз төзибез, безгә колхоз кирәк! Япанчыда колхоз булырга тиеш!.. Башка юл юк!.. Инде кайбер тискәре беткәннәр, кулак коткысына ияреп, или анда сознаниеләре җитмәгәннән, киреләнеп маташалар икән, без үзебез белербез аларга карата нинди политика үткәрергә!.. Указ кирәкми. Монда дураклар утырмыйлар... Белеп торабыз кемнәр сиңа барып сайраганын... Лучше син, егет, тыгылып йөрмә, кайткансың икән, кунак бул да әнә юлыңны кара!.. Ату...— Ул хәтәр тынып, сүзен бүлде.

Әйе, бу инде үтереп хурлау гына түгел, ачыктан-ачык куркыту да иде. Минем бөтен эчемне диярлек ут алды, бер тезем үзеннән-үзе сикерергә тотынды, бугазымны ике яктан нәрсәдер буа башлагандай булды. Ләкин мин курку дигән нәрсәне һич тә тоймадым, киресенчә, аның үзе кебек үк, минем дә үчләнеп-ярсып җавап кайтарасым килде, тик менә әллә ничек бер мәлгә сөйләшү куәтемне югалтып җибәрдем... Ә Хәйрүш абзый шул арада тиз генә алдында яткан кәгазьләрне актаргалап, шуннан бер дәфтәр битен миңа таба этәрде.

— Менә сиңа барып җылаганнарның берсе, Күпер төбе Бәдри, кичә гариза калдырып китте. Яңадан колхозга алуны сорый...

Мин аптырадым да калдым, күзләремә ышанмыйча торам... Бу бит чынлап та әлеге шул миңа килеп: «Көчләү булмасын!»— дип иң нык шаулаган Бәдри абзый лабаса! Ни әйтергә, ничек аңларга бу халыкны?!

— Да, кызык бу...— дидем мин, ирексездән, инде шактый сүрелеп.— Ләкин нидән күрәсез сез аның яңадан колхозга кайтуын?

— Кая барсын ул йолкыш,— диде Хәйрүш абзый, ваемсыз гына,— колхозга кайтмыйча...

— Ә сез миңа килгән ул кешеләрне әллә нинди дошманнар итеп күрсәтмәкче буласыз.

— Үзләренә дошманнар.

— Соң ул чагында яхшылап аңлатырга, төшендерергә кирәк иде аларга...

— Их, энем, энем! — диде Хәйрүш абзый, ачынып-сабырсызланып.— Белмисең әле син мужикны, белмисең!..

Коры сүз белән генә аны бер нәрсәгә дә күндереп булмый, көлә генә ул синнән, көлә генә! Менә син бер генә атна минем урында утырып кара, валлаһи дип әйтәм, ыштаныңны муеныңа урап, авылдан качачаксың! Кул кирәк монда, брат, кул! — Һәм аның өстәлдә яткан зур, сөякчел кулы гүя үзлегеннән таштай йодрыкка әйләнде, аннары акрын гына кире ачылды... Хәйрүш абзый йөзен читкә борып, басынкы гына өстәде:

— Ярый, җитәр, яхшы чакта аерылышыйк, туган!

Мин урынымнан тордым. Күңелдә әйтәсе күп сүзләр бар кебек, ләкин, юк, чыкмый инде, бетте, дөрестән дә, яхшы чакта китү хәерлерәк.

Без кул бирешеп аерылыштык.

Юл буенча үземне тиргәп кайттым... Ни пычагыма кирәк булгандыр миңа тыгылып йөрергә!.. Үз мәнфәгатьләрен аңламаган, үз мәнфәгатьләренә каршы торган агайлар, шуларны хак юлга мунчаклап сөйри-сөйри кырысланып, усалланып беткән Хәйрүш абзый — йә, кем хаклы да кем хаксыз монда — аерып, хөкем итеп кара!.. Әнә төерле белен генә килеп чыкты бу сөйләшүдән... Күңелдә авыр юшкын гына утырып калды, хәерсез!.. Ә шулай да мин әйткән сүзләрем өчен үкенмим, мин беләм — алар дөрес сүзләр, хак сүзләр, ләкин шул ук вакытта Хәйрүш абзыйның да бөтен кырыс кыяфәтендә, кискен-усал сүзләрендә ниндидер бер рәхимсез дөреслек бар иде — мин моны да сизмичә калмадым... Әйе, каршылыклы заман, катлаулы кешеләр!..

...Икенче көнне мин авылдан китеп тә бардым.

## XIV

Мин Казанны, эшемне, иптәшләремне сагынып кайттым. Бигрәк тә Хафазам — кара күзкәемне сагындым. Безнең бит әле беренче тапкыр аерылып торуыбыз, ә аерылып тору мәхәббәтне иң нык сыный торган нәрсә инде ул...

...Тормыш кайда да киеренке, әмма шулай да безнең шәһәр җирендә сулыш алуы җиңелрәк икән. Аннары хезмәт үзе бик шифалы нәрсә — кайткач, шуңа тагын бер тапкыр инандым. Һәркөнне иртән иртүк сине әлеге каплап куйган иске будильник чәрелдәп йокыңнан уята. Өстеңнән авыр йөкне селтәп ыргыткандай сикереп торасың, тизрәк салкын су белән бит-күзеңне юасың, шунда ук примуска киң төпле чәйнекне куясың — аның шаулый башлавы бүлмәгә ничектер җан кертеп җибәрә. Куе, кайнар чәйне шикәрләп, ипиләп эчкәннән соң, әйбәт кенә киенеп, әле яктырып та җитмәгән, тапталмаган, пычранмаган кышкы буш, тын урам-

га чыгасың. Тымызык, таза, салкын һава, дворниклар кыштыр-кыштыр урам көриләр, шәһәр өстендә йөзләрчә төтен баганалары әкрен генә һавага сузыла, тәрәзәләре туңган якты трамвайлар шалтырап уза... Бу вакытта эшкә баруы бик рәхәт. Йокы күптән качкан, тән җиңеләеп киткән, аяклар үзләреннән-үзләре ашыгып, рәхәтләнеп атлыйлар... Яшь, таза ат кебек сизәсең үзеңне. Юк, алай гына да түгел. Ходай бирмеш һәр иртәне менә шулай җиңел атлап эшкә бару кешене ничектер яңарта — яшәве, уйлавы, хис итүе өр-яңадан башлана кебек... Һәм бу яңаруны син һәр эш иртәсендә татымыйча калмыйсың.

Әнә шулай башланып китте минем аз гына өзелеп торган хезмәт көнем. Цехта да иптәшләр мине бик ачык каршыладылар. Аларның күбесе өчен минем китеп торуым сизелми дә калган шикелле:

— Һи-и, Хәбиб малай, кайттың дамыни әле син?! — дип гаҗәпләнделәр.

Беренче көнне үк яныма, ап-ак тешле чалышрак авызы белән елмаеп, Басыйр да килеп җитте.

— Нихәл, саумы, Хәбиб дус! — диде ул миңа, кул биреп.— Кайттың?

— Кайттым,— мин әйтәм.

— Йә, ниләр җимереп кайттың? Авыл чибәрләренең баш-күзләрен әйләндереп бетермәдеңме?

— Вакыт булмады, малай, авыру әнкәй яныннан бер дә чыгып йөри алмадым.

— Шулаймыни, кызганыч!.. Ну, авыл ничек соң?

— Авыл ничева,— мин әйтәм.

— Гөрлиме?

— Гөрли.

— Ярый,— ди ул гамьсез генә, аннары аз гына тукталып, сорап куйды: — Бүген эштән соң кая барасың?

— Нигә?

— Берәр җиргә кереп, сөйләшеп утырыр идек, күптән авыз чылаткан юк.

— Бүген булмый, Басыйр,— дидем мин.— Башка вакытта.

— Ә-ә, аңлашыла! — диде ул ияк кагып.— Хафаза гөлкәй белән кавышасың бармы?

Мин дәшмәдем, ә ул миңа дусларча күз кыскандай итте дә китеп барды... Дөрес әйтә, шадра пәри, минем бүгенге кичем бары Хафаза өчен генә, мин Хафазаны үземә алып кайтачакмын. Без әле бүген иртән генә күрештек, кул һәм күзләр белән генә, әмма шунда ук никадәр сагынышуыбызны, тизрәк бергә буласы килүебезне аңлап-тоеп өлгердек. Смена гына бетсен!..

Бу урында шуны әйтеп китәсе килә, Басыйр үзенең «берәр җиргә кереп утырыйк» дигән чакыруын ни өчендер яңадан кабатламады. Онытты мы, әллә кирәк тапмадымы, безгә икәүдән-икәү генә «авыз чылатып» утырырга туры килмәде. Дөрес, берме-икеме тапкыр, эштән чыккач, егетләр белән юл өстендәге сыраханәгә кереп сыра эчкәләдек, ләкин анда да сүз юк-бар уен-көлкедән узмады. Аннары минем кичләрем дә буш түгел иде, кичләрем гел Хафаза белән тулы иде.

Бер уңайдан тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк: минем йөреп кайтуым ни сәбәптер мишәр абзыйларда шактый зур кызыксыну уятты. Хәер, мин аларны аңлыйм, күбесенең бит семьялары авылда, авыл хәлләре аларның уйларын һәрвакыт биләп-борчып тора. Шулай да алар бик сак кына сорашалар. Әле берсе, әле икенчесе яныма килеп, башта: «Нихәл, брат, аман гына йөреп кайттыңмы? Анай ничек, саумы? Ярый, ярый, Алла мәдәт бирсен!» дип сүз башлый, бары шуннан соң гына: «Йә, салада хәлләр ничек соң, брат, колхоз нишли, агайларны абижать итмиләрме?» — дип сораштырырга тотына. Күреп торам, миннән аларның бик турысын гына ишетәселәре килә. Ләкин шулай да мин аларга капчыкны төбеннән үк тотып селекмәдем: ышанмаудан яки куркудан да түгел, ә бөтен ишеткән-күргәнне сөйләп, аларны артык тәшвишкә төшерәсем килмәде. Тәшвишләнер өчен сәбәп аларга болай да җитәрлек иде. Аяк астыннан чыккан бәла дигәндәй, мин югында безнең мехбазада шактый күңелсез бер вакыйга булып алган: көннәрнең берендә ГПУ работниклары килеп, базаның подвалында упаковщик булып эшләүче Гыйльметдин исемле бер татар агаен алып киткәннәр. Баксаң, ул ниндидер җинаять эшләп, авылдан качкан зур гына бер кулак, имеш. Чын исем-фамилиясе дә аның бүтәнчәрәк булган, диләр. Эшкә дә ул ялган документ белән кергән. Кыскасы, тапкан дошман кереп посар урын!

Сортланган каракүлләрне подвалга төшергәндә мин бу кешене күргәли идем. Базык кына, таза гына, карап торырга гади бер авыл кешесе. Күп сөйләшми, күп аралашмый, тыныч кына үз эшен эшли бирә, хәтта әбәт вакытында подвалдан чыгып та йөрми, күбрәк шунда түкләр өстенә утырып кына, алып килгән бер шешә сөтен зур түтәрәм кара ипи белән ашый торган иде. Хәтерем ялгышмаса, безнең управляющий аны яхшы эшләгәне өчен бер бүләкләгән дә иде шикелле... Маңгаена язылмагач, аның кем икәнен каян беләсең?!

Һәм менә шушы «яхшы» упаковщикның көтмәгәндә, туп-туры эшләгән җиреннән кулга алынуы безнең мех-

база өчен шактый ямьсез бер ЧП — гадәттән тыш вакыйга була. Берәүләрне ул борчуга сала, икенчеләрне куркуга төшерә, ә кайберәүләрнең шик-шөбһәләрен көчәйтеп җибәрә. Мәсәлән, шул ук Басыйр бу вакыйганы миңа сөйләгәннән соң, бик мәгънәле генә итеп: «Бар әле аның койрыклары бездә, бар!» — дип әйтеп куйган иде... Тагын шул, бу ЧП өчен безнең Перовка да әзрәк эләккән шикелле, чөнки Гыйльметдин кулак аның кулы аша узган, ә күрсәткән документының ялган булуын бала да танырлык, имеш.

Менә шул. Мин югында булган бер эш булгач, аңа әллә ни зур игътибар да бирмәдем. Безнең көннәрдә аның ише хәлләрнең булгалый торуы бер дә гаҗәп түгел иде. Аннары минем уйларым бөтенләй башкада бит әле...

...Алдан вәгъдәләшкәнчә, мин шул ук көнне Хафазаны үземә алып кайттым. Сменадан соң Хафаза түбәндә эшләремне бетереп, цехтан чыгуымны көтеп торды. Кайтышлый магазинга кереп бер шешә портвейн да алып чыктым — беренче кичебезне авылдан кайткан күчтәнәчләр белән бәйрәмчәрәк итеп үткәрәсем килде.

Бүлмәгә кайтып кергәч, мин аның пальтосын салдырып, кулыннан гына тотып, өстәл янына китереп утырттым, үзем дә урындык алып, каршысына утырдым... Өстендә кызыл сатин кофта, кара юбка, аякларында кечкенә кара киез итекләр — бик гади, хәтта ярлы дияр идем, әмма үзенә бик килешә, ничектер җыйнак итеп күрсәтә үзен... Менә ул утырган җиреннән генә киерелеп, ике кулы белән тузгый төшкән чәчләрен рәтләргә тотынды... Мин, һич орынмыйча, аңа — аның алсуланып янган йөзенә, энҗедәй ике генә төртке җемелдәгән зур кара күзләренә, кечкенә тулы иреннәренә, уртасы чокырлы йомшак иягенә, йомшак, шома муенына карап утырдым... Болар барысы да миңа бик таныш, бик якын, әмма ләкин минем нидер күрәсем килә: шул ук Хафазамы, берәр үзгәреш юкмы үзендә? Ни әйтсәң дә бер атна аерылышып тордык ич! Ә яраткан кызыңа бер көннән соң да әзрәк сынап карыйсың инде — аның сиңа ничегрәк каравын белер өчен генә булса да... Ләкин юк, берни дә юк шикелле, шул ук Хафаза, шул ук, хәер... бүген ул ни өчендер әз генә боек, әз генә уйчан кебек... Нидән икән бу?.. Әллә миңа гына шулай күренәме?.. Аннары сүз башларга да ничектер кыймыйчарак утыра кебек... Бик кыска гына вакыт аерылышып тору да яшь кызны шулай әзрәк кенә тарсынырга, әзрәк кенә каушарга да мәҗбүр итә микәнни?.. Әллә миңа карата, авылдан бу берәр кыз белән шаярып кайтмадымы, дигән шиге-мазары бармы икән?.. Мәхәббәт ансыз була аламы

соң?! Хәер, булмаска тиеш, без андый вак шик-шөбһәләрдән күптән уздык бугай, мин үзем, мәсәлән, аңардан бөртек тә шикләнмим. Аннары мин, әгәр берәр гаебем булса, аңа болай эчкерсез сагынып, сынап карый алыр идеммени?.. Ахырда менә ул үзе дә түзмәде:

— Карама ул хәтле, оялтасың! — диде дә, йөзен яшерергә теләгәндәй, миңа таба иелә төште.

Бусы инде нәкъ элеккечә килеп чыкты. Еш кына ул шулай «Оялтасың!» дип миңа сыена торган иде. Билгеле, минем һәртөрле юрап маташуларым таралды да китте. Иелгән йөзен ияге нннән күтәреп, үзен кочагыма тартып алдым:

— Кара чәчәгем син!..

— Нигә... кара? — дип кенә өлгерде аның иреннәре.

Ә бераздан мин аңа төшендердем: роза чәчәгенең карасы да була, искиткеч нәфис, матур, затлы чәчәк ул!.. Тик бик чәнечкеле, дип көлдем ахырдан... Хафаза бер сүз дәшмәде, яңадан чак сизелерлек борчылу йөзенә чыккандай булды.

Аннары мин, торып, өстәл әзерли башладым. Әнкәйнең хәзинәсеннән кече апа биреп җибәргән бер йомарлам акмайны, калай савыт белән балны, пешкән ярты казны, карарак бодай оныннан пешерелгән тәмле кабартмаларны алып кердем. Хафаза да кунак кына булып утырмады — шуларның барысын да матурлап өстәлгә тезеп куйды... Эмаль чәйнек белән чәй дә кайнатып керттем, портвейнны да, азаплана торгач, пәке белән ачып, өстәл уртасына куйдым. Табыныбыз шактый мул, ямьле булып китте. Шуңа сөенеп, Хафазамны кыстап-кыстап, сыйларга тотындым. Безнең әле болай икәүдән-икәү кенә «байларча» сыйланып утырганыбыз юк иде. Мин әз-мәз эчкәләгән кеше булсам да, Хафазаның әйтүенә караганда, вино дигән нәрсәне моңарчы авызына да алганы булмаган икән әле. Шулай да, кыстый торгач, ул да бер ярты стакан чамасы портвейнны бүлгәләп кенә эчеп куйды... Эчми эчкәнгәндер инде, аның йөзе шундук алсуланып китте, күзләре дә дымланыбрак елтырый башлады, ә бераздан теле дә чишелде. Баштагы теге сәер тартыну, кыенсыну дигән нәрсәнең дә әсәре калмады. Ботактагы кошчык шикелле, үзеннән-үзе җанланып һәм юктан да көлә-көлә, миңа бер атна эчендә мехбазада булган вөк-төяк хәлләрне сөйләп чыкты. Мин аны бер дә бүлдермичә, ләкин күбрәк сөйләвенә сокланып тыңлап утырдым. Шул чакта, ни сәбәптәндер, күңелгә һаман бер уй килә торды: соң мин бу кызны, мине яратам дигән, миңа инде тәмам ияләшкән, алай гына да түгел, өйләнәм дисәм,

миңа чыгарга да әзер торган сөйкемле-чибәр кызны чын-чынлап беләмме?.. Бөтен эче-тышы белән дигәндәй һәр яктан да белеп бетердемме әле мин аны?.. Моңарчы, әлбәттә, беләм, бик яхшы беләм дип ышанып йөрдем, хәзер дә шуңа ышанам, әмма белүнең чиге бармы? Никадәр генә белсәң дә кешенең ниндидер күрүе дә, сизүе дә мөмкин булмаган яклары калмыймы? Кеше бит әле кайчакта үзен-үзе дә белеп бетерми. Әйтик, ул үзен куркак түгел дип йөри, ә хәтәр бер хәлгә эләккән чакта тота да куркаклык күрсәтә. Яки ул бервакытта да үзен батырга санап йөрми, әмма кайбер очракта, үзе дә уйламастан, батырлык эшләп ташлый. Дөрес, безнең әле андый сынауларны үткәнебез юк, без әле куркаклык та, батырлык та күрсәткәнебез юк (бүген мин моны Хафаза өчен дә ышанып әйтәсем килә), бары тик икебез дә бер җирдә эшлибез һәм бер-беребезне яратабыз. Ләкин бит ярату да батырлык, зур батырлык, минемчә... Аны ничектер аклый да, саклый да белергә кирәк. Мәхәббәт тә бит кайчакта авыр сынаулар аша үтәргә мәҗбүр була.

Нәкъ менә шушы урында әлеге Басыйр, кылт итеп минем исемә төште. Башта әйткәнемчә, мин бу кешегә һич тә ышана алмыйм. Эчке бер сизенү ничектер миңа бу кешедән сак булырга куша. Ә менә Хафаза аңа ышана шикелле... Һәрхәлдә, иске таныш, бергә укыган иптәш дип һаман аны үз тирәсендә йөртә. Бүген иртәнчәк тә Басыйр, минем белән күрешеп киткәч, Хафаза янына барып, бик үз кешедәй аңа иелә биреп, тик ни өчендер кылый күзләрен тирә-якка йөрткәләп, озак кына сөйләнеп торды. Бетмәгән ни сүзе бардыр инде... Әллә һаман мине мактаган буламы?.. Мин, билгеле, алар янына барып тормадым һәм соңыннан да Хафазадан нәрсә сөйләштегез дип сорарга телем бармады — просто ваксынасым килмәде... Хафаза болай да минем Басыйрга ничегрәк каравымны белә, сүз дә булганы бар, ләкин үзенең ваемсызлыгы аркасындамы, йә булмаса мине көнләшә дип белепме, еш кына ул миңа балаларча беркатлылык белән: «Куй, җаным, юкка борчылма, Басыйр бервакытта да безнең арага керә алачак түгел... Шул кылыйга мин карыйммы соң, Аллам сакласын!» — дип әйтә торган иде.

Һәм мин дә валерианка капкандай аның бу сүзләреннән тынычланып кала идем. Чынлап та Басыйр шикелле ике хатын аерган кеше ничек итеп безнең арага керә алсын ди? Аннары без гөнаһсыз кешеләр ич, Хафазага минем җәберем тигәне юк, аның да хәзергә кадәр мине борчырлык бер нәрсә дә эшләгәне юк — Басыйргамы соң бездән берәр төрле кер табарга?! Тик, кызганыч-

ка каршы, мин ул чакта казакъның бер бик шәп мәкален белмәгәнмен: яманның сигез аягы була, берсе тимәсә, берсе тия, ди казакъ.

Ләкин, ничек кенә булмасын, бүген әле Хафаза минем өчен иң якын, иң ышанычлы кешем. Мин инде аны сагынмыйча, аны күрмичә, аңа күңелемдә булганнарны ачмыйча, бушатмыйча тора да алмыйм. Бу үзенә күрә бер гадәткә, җан таләбенә әйләнде дисәм дә хата булмас... Билгеле, мин аңа шушы беренче кичтә үк авылдан ишетеп-күреп кайтканнарымны түкми-чәчми сөйләп бирдем. (Авыл төяп җибәргәннәрнең барысыннан да тизрәк бушанырга кирәк иде.) Дөрес, мөмкин кадәр гадирәк итеп, җиңеләйтеп, көлдереп тә, ләкин вакыйганың җитдилеген дә яшермичә сөйләргә тырыштым. Шул ук вакытта бу вакыйгага үземнең бәяне бирергә ашыкмадым, чөнки Хафазаның ничегрәк аңлавы, нәрсә дип әйтүе минем өчен кызыклы иде. Кыскасы, Хафазага сөйләп, аның аша үземдәге кайбер уй-шикләрне дә ничектер сынап беләсем килде... Һәм, билгеле инде, безнең сөйләшүне һичкем ишетмәде, белмәде — барысы да ике арада гына калырга тиеш иде.

Хуш, ә минем чибәрем мине ничегрәк тыңлады соң? Беренче генә сөйләвем түгел, һәм, әйтергә кирәк, тыңлый белә иде ул, минем Хафазам!.. Зур күзләрен балалар шикелле миңа хәрәкәтсез төбәп, тулы иреннәрен ача төшеп, үзенчә бик игътибар белән тыңлап утыра торган иде. Ярата иде, ахрысы, мин сөйләгәнне, еш кына үзе үк: «Хәбиб, сөйләле берәр нәрсә?» — дип әйтә торган иде. Аннары ни генә сөйләмим, ул һәрвакытта шуның белән бик җиңел генә килешә дә иде. Бәлки, бу нәрсә азрак сәер дә тоелыр, ләкин мин аңа гаҗәпләнми идем. Чөнки Хафаза, кабатлап әйтәм, бик яшь иде әле, белеме дә чамалы гына, үзенчә уйларга, үзенчә аңларга өйрәнеп тә җитмәгән, кыскасы, үзеннән олырак һәм өстенрәк кешеләр авызыннан ни чыкса, аның шуңа ышанып, шуның белән килешеп яши торган чагы иде.

Бу юлы да ул әнә шулай күзләрен тутырып миңа караган килеш, иреннәрен ача төшеп, сабыйларча бирелеп дигәндәй мине тыңлап утырды. Баштарак аңа кызык та тоелды, ахрысы, Япанчы агайларының ничек итеп зарлануларын сөйләгәндә еш кына көлгәләп тә алды. Ләкин соңга табарак ничектер җитдиләнә төште, йөзенә борчылу да чыккандай булды, ә Хәйрүш абзый белән минем бәрелешне ишеткәч, чын-чыннан куркынып: «Әй, җаным, нигә андый кеше белән сүз көрәштерәсең?» — дип тә куйды.

Бу минем өчен шактый кызыклы иде. Димәк, мәсьәләнең җитдилеген минем Хафазам да аңлый! Вакыйга-

ның уен гына булмавын дөрес чамалый!.. Ул гына да түгел, минем өчен чын ихластан курка да, борчыла да икән!.. Билгеле инде, мин моңа эчемнән сөенмичә кала алмадым, ләкин шул ук вакытта аның мәсьәләне никадәр дөрес аңлавын да ныграк беләсем килде.

— Тик син әйт әле, бәгърем, кайсыбыз хаклы бу бәхәстә, минме, әллә Хәйрүш абзыймы? — дип сорадым.

Ул ике дә уйламыйча:

— Син инде, җаным, син! — диде.

— Ни өчен мин?

— Син бит, җаным, үзеңне якламагансың, кешеләрне яклагансың... Нигә, яклау гаепмени?

Бу үзенә күрә резонно иде. Ләкин шулай да минем аңардан иң кирәген, иң мөһимен ишетәсем килә.

— Сүз бит, бәгърем, кемнәрнедер яклау турында гына бармый,— дидем, ничек тә гади генә аңлатырга тырышып,— мәсьәләнең, ничек дим, принципиаль ягы да бар. Менә мин колхозга көчләп кертергә ярамый, дим, бу эштә көчләү булмаска тиеш, дим. Менә син шуңа ничек карыйсың, дустым?

— Ничек карыйм? — диде Хафаза, шома маңгаен җыергандай итеп.— Син үзең яхшырак беләсең инде, җаным, ә мин нәрсә әйтим?

— Шулай да минем белән килешәсеңме син, мине хаклы дип табасыңмы?..

Хафаза аптыраган шикеллерәк дәшмичә торды да аннары ничектер кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Килешәм...

— Ни өчен?

— Ни өчен... ни өчен? Син булган өчен...

— Ә бүтән кеше шулай дип әйтсә?

— Йөдәтмә мине,— диде Хафаза, ялварып.— Сиңа ышанам, тагын ни кирәк?

Әйе, тагын ни кирәк? Ышанам ди ич, син хаклы, җаным, ди ич!.. Аркасыннан сөеп рәхмәт кенә әйтәсе... Әмма шунысы гаҗәп: минем бу сораудан соң Хафазам ни өчендер тагын уйчанланыбрак калды һәм йөзенә дә аның әлеге күңелсезләнүме, борчылумы — ничек дип әйтергә дә белмим — чыккандай булды. Нидән, ни өчен?

— Бәгърем, нигә әле син болай күңелсезләнеп киттең? — дип сорадым мин, ниһаять, аңардан.

— Юк,— диде ул, нигәдер ашыга төшеп, аннары күтәрелеп миңа елмайды.— Киресенчә, мин шат.

— Шулаймы?

— Чын, без бит тагын бергә...

— Әйе, әйе, без тагын бергә, кадерлем! — дидем мин,

аны үземә тартып. Хафаза, күзләрен йомып, сүзсез генә миңа сыенды.

Әнә шулай бетте безнең бу сөйләшү... Гадәттәгечә иркәләнү, сөю белән. Минем җаным тыныч иде. Япанчыдан алып кайткан күңелсез вакыйганы Хафазама сөйләгәч, миңа әле җиңел, рәхәт тә булып калды. Бердәнбер сердәшчем бит ул минем!.. Тыңлап кына утырса да, мин бик канәгать идем. Әнә шулай юандым мин. Шуннан башкасын уйлый да, күрә дә белмәдем.

Мин авылдан кайтып, бер-ике атна үткәч, Хафаза үзен тагы да сәеррәк тота башлады, ничектер йомыла, сагая төшкән кебек булды, ваемсыз, сәбәпсез көлүләр кимеде, кочагыма алып сөйгәндә дә элекке кебек эреп бармый, әллә ничек менә эчке бер тыелу сиздерә... Аннары, иң гаҗәбе, үзенең һәрвакыт миңа тутырып карый торган хәйләсез саф күзләрен миннән яшерә башлады. Мин күрмәгәндә генә карый, ә күзгә-күз очрашудан кача. Әйтерсең минем нидер сизенүемнән курка. Баштарак мин бу сәер үзгәрешләргә ни өчендер (бәлки, аның хәтерен саклаптыр) игътибар итмәскә тырыштым. Ләкин эчем поша, игътибар итмичә мөмкин түгел, Хафазада нидер бар, нидер аны кимерә, юкка гына булмаска тиеш аның болай үзгәрүе...

Ахырда мин аңардан сорадым:

— Ни булды сиңа, бәгърем, әллә авырыйсыңмы?

Ул иңбашын җыерып кына:

— Юк, берни дә юк,— дигән булды.

Ләкин күреп торам: әйтеп бетерми кызым. Тагын җаен туры китереп иплән кенә сорыйм:

— Шулай да, кадерлем, соңгы вакытта син шактый үзгәреп киттең, нидер бар синдә, мин күрәм ич!.. Әйт, яшермә!

Ә Хафаза сабырсызланып, һаман үзенекен кабатлый:

— Юк инде, юк, сиңа гына шулай күренә торгандыр, җаным! — Һәм, борчылма, дигән төсле миңа елыша.

Мин ни әйтергә дә белмичә югалып калам. Бәлки, чынлап та мин ялгыша торганмындыр. Дөресен генә әйткәндә бит, Хафазада нинди дер җитди үзгәреш китереп чыгарырлык бер генә сәбәпне дә мин белмим, уйлап та таба алмыйм. Бигрәк тә минем тарафтан берәр төрле сәбәпнең булуына һич тә акылым җитми. Аллага шөкер, миндә бер үзгәреш тә юк, барысы да искечә — яратуым да, кадерләвем дә, ышануым да... Хәтта көчәя баруын гына тоям... Шулай булгач, борчылыр өчен нинди генә нигез бар?

Аннары без көне буе эштә, ә эштә чакта һәрнәрсә үзенең гадәти агымы белән бара, төрле шикләр, уйланулар да онытылып тора. Мөнәсәбәтләр дә шул ук: Хафаза

миңа якын, мин Хафазага якын, моны һәркем белә, һәм берәү дә безнең арага ниндидер күләгә төшүен сизми дә, күрми дә... Шуның өстенә болар барысы да бик яңа бит әле, сынарга, белергә вакыт та тигәне юк.

Ә тагын бер атнадан Хафаза кисәк кенә миңа килеп йөрүдән туктады. Мин аңардан: «Бәгърем, сиңа ни булды?» — дип сорадым. Ул түбән карап, боек кына: «Авырыйм»,— диде. Мин борчыла калдым, чыннан да аның йөзе суырылган, агарган кебек күренде. Ләкин ул эшкә йөрүдән туктамады. Мин аңа бюллетень алырга куштым. Ул теләр-теләмәс кенә: «Үтәр әле»,— диде. Тәнәфес вакытларында, миннән яшеренгәндәй, гел кызлар арасына кереп, кысылып утырды, ә эш беткәч, мине көтмичә, ашыга-ашыга китеп бара торган булды.

Бу инде Хафазаның миннән китүе иде. Димәк, миңа билгесез, ниндидер бер явыз көч безнең дуслыкны җимерә, безне бер-беребездән аера!.. Әмма моңа юл куярга ярыймы соң?! Һичшиксез, миңа хәзер Хафаза белән ачыктан-ачык, туп-туры сөйләшергә кирәк. Вакыт җитте, ләкин, ни хәлләр генә итәсең, вакыт үтеп тә киткән икән. Мин соңга калдым, Бәкер дус!

## XV

Бишенче апрельдә, дүшәмбе көн, безнең мехбазада ачык партия җыелышы булды. Мин авылдан март башларында кайткан идем, димәк, бу җыелышка хәтле нәкъ бер ай вакыт үтеп киткән икән...

Бездә моңарчы да төрле җыелышлар еш кына булып тора иде. Без моңа гадәтләнгән идек инде, халык бездә дисциплиналы, җыелышлардан качу юк, чакырган җиргә сәгатендә дәррәү кереп утыра торганнар иде.

Ләкин, шуңа да карамастан, мине бер нәрсә шактый гаҗәпләндерде. Элек, мәсәлән, цехка белдерү элсәләр яки эш бетәр алдыннан цех начальнигы кешеләргә: «Җыелышка керегез!»— дип кычкырып бер әйтсә, шул җитә торган иде. Бу юлы исә, көн ахырына табарак, контораан яшь бер кыз цехка менеп, кулындагы исемлек буенча һәркемнән кул куйдырып, чакырып йөрде. Кешеләр: «Ни өчен болай итәсез?» — дип сорасалар да, кыз: «Белмим, миңа шулай куштылар»,— диюдән башканы әйтә алмады. Бу нәрсә булачак җыелышны ничектер серлерәк итеп җибәрде, кызыксынуны көчәйтте, төрлечә уйлау-юрауларга сәбәп булды.

Әйткәнемчә, мине дә бу хәл бик гаҗәпләндерде. Чыннан да, ни өчен болай куллар куйдырып чакыралар? Берәр

гадәттән тыш мәсьәлә каралмакчымы, әллә бик мөһим берәр хәбәр бармы? Тагын шунысы: бу җыелыш хакында белдерү эленмәгән иде һәм аның көн тәртибе дә билгесез иде. Кызык, нәрсә булмакчы соң?

Эш бетәр алдыннан гына мин цехтан узып барган Басыйрны күрдем.

— Карале, Басыйр,— дип, туктаттым мин аны.— Бүген нинди җыелыш бездә?

— Нигә, әйтмәделәрмени? — диде ул миңа борылмыйча гына.— Ачык партия җыелышы.

— Анысын беләм. Ә нәрсә каралмакчы, нигә кешеләрне атап чакыралар?

— Белмим, парин, белмим,— диде Басыйр һәм, каядыр ашыккандай, тизрәк китеп тә барды.

Басыйр белән безнең бу араларда юньләп очрашкан да, сөйләшеп йөргән-утырган да юк. Бик эшле кешедәй ул соңгы көннәрдә ничектер артык җитдиләнеп, эреләнеп китте әле. Еш кына менә шулай, кешеләргә карамыйча, үрә каткан килеш туп-туры гына үтә дә китә. Мин кайткан чакларда көн дә диярлек Хафаза янына килмичә калмый иде, хәзер аны да нишләптер «күрми» башлады. Бу кешегә бервакытта да ышанып бетмәсәм дә, аның болай «үзгәрүенә» мин әллә ни игътибар итмәдем. Карьера ярагучы кешеләр гадәттә шулай йә бик ялагайланып, йә артык эреләнеп китүчән булалар. Һәм менә бүген дә аның, миннән качкандай, юньләп сөйләшмичә тизрәк китеп баруы әзрәк ачуымны китерсә дә, күңелемдә бернинди шик яки борчылу тудырмады.

Гөнаһ шомлыгына каршы, бүген цех начальнигы Васильев та авырып эшкә чыкмаган иде. Шуңа күрә сменадан соң миңа, цехтагы вак-төяк эшләрне бетереп, җыелышка соңгарак калып керергә туры килде.

Җыелышлар бездә икенче каттагы зур контора бүлмәсендә үткәрелә. Өстәлләрне бер почмакка күчереп куялар да, эскәмия-урындыклар тезеп, халыкны шунда утырталар. Кысан җир, ләкин хәзергә башка урын юк.

Мин килгәндә җыелыш башланмаган иде әле. Халык бүген аеруча күп (кул куйдыргач, берәү дә китмәгән), бер-берсенә ябышып дигәндәй, озын эскәмияләргә тезелгәннәр. Элегрәк вакытларда Хафаза минем өчен үзе янында урын алып кала торган иде, бу юлы инде мин, билгеле, аңардан моны көтмәдем дә. Бүген ул үзе дә алгы эскәмияләрнең берсенә, кызлар арасына кереп, кемнәндер поскан шикелле, кысылып кына утырган иде. Шулай итеп, без бу җыелышта беренче тапкыр диярлек берберебездән, ят кешеләрдәй, аерылган идек... Кая уты-

рыйм икән дип каранып торган чагымда, ниһаять, Әмин әкә мине үз янына дәшеп алды.

Каршыда, управляющий кабинетына керә торган ишек төбендә генә, кызыл япкан кечерәк өстәл. Өстәл артында ике кеше — партоешма секретаре Перов белән мехбаза управляющие Решевский утыралар. Өстәлнең уң як башына, тезләре өстенә иске кара портфелен куеп, олы гына яшьтәге бер кеше урнашкан. Безгә таныш түгел. Ләкин җыелыш башлангач та белдек: ул райкомнан доклад сөйләр өчен килгән кеше булып чыкты. Фамилиясе әллә Беляев, әллә Белов иде — хәзер ачык кына хәтерли алмыйм инде.

Тагын бер нәрсә минем игътибарымны җәлеп итте. Өстәлдән аз гына читтәрәк, ялгыз урындыкта, аягын аяк өстенә салып һәм залга карап, Басыйр утыра. Ул шундый итеп утырган — аны президиумда дип тә уйларга була (чөнки йөзе белән безгә караган), шул ук вакытта өстәлдән бераз читтәрәк тә — теләсәң ничек аңла!.. Аның болай утыруы миңа шактый сәер тоелды.

Минем кереп утырганны гына көткән шикелле, партоешма секретаре Перов шунда ук, торып, җыелышны ачык дип тә белдерде. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — колхозларның бүгенге хәле турында доклад, диде һәм шул докладны сөйләр өчен райкомнан килгән әлеге кешегә сүз бирде. Докладчы урыныннан торды, портфеленнән бергә теркәгән кәгазьләр чыгарды һәм, шуларга караштырып, ашыкмый гына сөйләргә тотынды. Хәзер дә онытасым юк — аның докладны «Колхозларда икенче большевистик яз» дип аталган иде... Хәер, хикмәт исемдә түгел, мәсьәләнең үзендә. Ә мәсьәлә бик кызыклы, бөтен кешене диярлек кызыксындыра, мине исә аеруча... Дөрес, биредә, ни өчен әле шәһәрләрдәге бер кечкенә производство коллективына килеп, колхозлар турында сөйләргә кирәк булды? — дигән сорау туарга мөмкин. Ләкин бу да бик аңлашыла: ул елларда авылдагы хәлләр белән шәһәр дә бик нык кызыксына торган иде. Шәһәр җирендә авылдан чыккан кешеләр бик күбәйде, аларның күбесе үзенең авылы белән өзелеп тә бетмәгән (безнең шушы мехбазада да андыйлар шактый), шулай булгач, партия оешмаларының шәһәр кешеләренә авыл хәлләре турында сөйләүләре бик табигый иде.

Мин докладчыны бик игътибар белән тыңларга җыендым... Ниндидер бер киеренкелек тууын сиздем үземдә. Нәрсә ишетермен? — дигән көтү иде шикелле бу.

Докладчы башта бөтен ил күләмендә барган каты сыйнфый көрәштән соң колхоз төзелешенең тәмам җиңүе, крестьяннарның иң зур күпчелеге үз язмышларын инде

ныклап колхоз белән бәйләүләре турында сөйләде. Авылда социализмның нигезе салынды, диде ул. Шуннан соң колхозларның бүгенге хәленә күчте. Колхозлар икенче большевистик язны каршылыйлар, диде, һәм бу язның алар өчен гаять әһәмиятле булуын сөйләп китте. Менә шунда инде докладчының сүзе, ничек дим, җылы яздан салкын көзгә авыша башлады. Шактый җәелеп, ул авылларда кискен сыйнфый көрәшнең һаман да әле дәвам итүе, төрле ярыкларга кереп поскан кулак калдыкларының һәм кулак иярченнәренең колхозларга каршы тыпырчынып, көрәшеп маташулары, халык арасында һәртөрле коткы таратулары, кайбер җирләрдә хәтта колхоз активларына кул күтәрүләре, кыскасы, сыйнфый дошманның барлык чаралар белән колхозларны ничек тә какшатырга, язгы чәчүне өзәргә, илне икмәксез калдырырга тырышулары турында сөйләде. Бу шомлы, куркыныч хәлләрнең мисалларын да китерде: фәлән районда кулак калдыклары колхоз амбарларын яндырганнар, фәлән авылда колхоз атларын агулап үтергәннәр, фәлән колхоз председателенең тәрәзәсенә төнлә белән таш тондырганнар... Болардан нәтиҗә: сыйнфый уяулыкны һәр җирдә көчәйтергә, кулак агентларын посып яткан җирләреннән казып чыгарырга һәм пролетариат хөкеменә тартырга, һәртөрле дошман коткысын таратучыларны, колхоз төзелешенә яла ягучыларны, гомумән партиянең бөек эшенә шикләнеп караучы елакларны рәхимсез фаш итәргә һәм большевистик тәнкыйть белән беткәнче көйдерергә кирәк. Тагын бер нәтиҗә: мондый бәндәләрнең, авылларда гына түгел, шәһәрдә дә, кайбер коллективлар эчендә дә булуларын истән чыгармаска.

...Җыелыш тып-тып. Кешеләр селкенергә дә курыккандай гаять киеренке бер хәлдә утыралар. Бер-берсенә карамыйлар, дәшмиләр, гипнозга эләккәндәй, бары докладчының авызына карап катканнар. Ирексездән минем дә йөрәгемә салкын йөгерде. Әйтерсең шушы минутта котырып чабып килгән машина сине таптап-изеп китәчәк!.. Моның өчен үзеңне гаепле дип белү дә кирәкми. Гомумән менә шулай рәхимсез көрәшкә өндәп, янап, куркытып сөйләгәнне ишеткәндә кеше дигәнең, минемчә, ничектер бер мәлгә ихтыярсыздан каушап, югалып кала, ниндидер билгесез шомлану аның бөтен җанын өшетеп җибәрә. Миндә дә шундыйрак рефлекс булды.

Докладчы сөйләп бетергәч, председатель өнсез тынып калган җыелышка карап: «Йә, иптәшләр, кем сөйләргә тели?» — дип сорады. Әлбәттә, залда утыручылардан берәү дә әле сөйләрлек хәлдә түгел иде. Ләкин председа-

тельнең әйтүе булды — шунда ук Басыйр торып та басты. Шик юк, бу аның алдан ук сөйләргә әзерләнеп куйган булуын күрсәтә иде. (Бик хәтәр нәрсә әйтергә җыенган кешенекедәй, йөзе дә агарган, кашлары да тартылган, ә сул кулы әзрәк калтырый да кебек...) Гадәттәгедән дә үрә катыбрак сөйли башлады ул, һәм, әйтергә кирәк, сөйли белә иде, шактый матур көр тавышы тыңлаучыны ихтыярсыздан үзенә тарта иде.

Ул колхозларның хәле, нәрсәгә мохтаҗ булулары, аларга нинди ярдәм итү кирәклеге турында бер сүз дә әйтеп тормады. Туп-туры сыйнфый көрәштән башлады. Уяу булырга чакырды. Докладчы иптәш бик дөрес әйтте, кулак үзе яки аның агентлары безнең арада да бар әле алар, диде. Шуның мисалы итеп, күптән түгел менә мехбазада Гыйльметдин исемле кулакның табылуын һәм кулга алынуын искә төшерде. Ләкин Гыйльметдин белән генә эш бетте дип тынычлану дөрес булмас, аның койрыклары бездә тагын булырга тиеш әле, диде. Шуларның берсе, диде, һәм, эффект өченме, әллә бер генә секундка кыюлыгы бетепме, аз гына тукталып калды, аннары кычкыра биреп, минем исем-фамилияне әйтеп салды. Мин бер генә мизгелгә сискәнеп киттем, ләкин шунда ук бөтен дөньямны онытып, беркемне, бернәрсәне күрмәс булып, бары Басыйрның авызына карадым да калдым. Ә чалышрак авыз бер ачыла, бер ябыла, ашыга-ашыга минем өчен искиткеч ят, сәер һәм куркыныч сүзләрне чәчә дә чәчә: имеш, мин колхозга каршы, имеш, мин кулаклар җырын җырлыйм, имеш, мин партиянең авылда үткәргән политикасы белән риза түгелмен! Кыскасы, мин сарык тиресе ябынган бүре икәнмен ләбаса! Менә аның дәлилләре дә: «Ул,— диде әлеге минем күз алдымда өзлексез ачыла да ябыла торган чалыш авыз,—күптән түгел туган авылына кайтып килде. Ул анда крестьяннарны колхоздан чыгарга котырткан (?!). Ул колхоз председателенә барып, нигә сез агайларны колхозга көчләп кертәсез, дип тавыш чыгарган (?!). Ә монда кайткач, крестьяннар колхозга үзләре теләп кермиләр, барысы да колхоздан качарга гына торалар дип сөйләп йөргән (?!). (Шушы урында минем «Ялган!» дип бик каты кычкырасым килде, ләкин — ни гаҗәп! — кычкыру түгел, селкенә дә алмадым.) Менә кем булып чыкты ул, рабочий битлеге кигән Юлдашев иптәш!.. Йә, без андый контр сүзләр таратучы кулак агентын үзебезнең арада тота алабызмы?! Юк, иптәшләр, андый кешегә безнең арада урын булмаска тиеш!»

Иң элек бик табигый рәвештә минем күңелгә шун-

дый уй килде: «Хәйрүш абзый язып җибәргән!.. Әйе, әйе, бу бары тик аның эше!» Ләкин шуның артыннан ук икенче уй да килде: «Ә ул, Хәйрүш, минем монда кайткач ниләр сөйләп йөрүемне кайдан белә?.. Бусы тагын кемнеке? Басыйрның үз уйдырмасы гынамы?» Һәм менә шул чакта минем башыма әйтерсең яшен китереп сукты: «Хафаза!.. Хафаза!.. Йа Ходаа!» Мин берьюлы коелып төштем, ничектер бөрешеп, кечерәеп калдым, хәтта эчемнән генә — янымда утыручылар ишеткәннәрдерме, юктырмы —ыңгырашып та куйдым... Бу, бу... әллә нәрсә бу, сүз юк, сүз таба алмыйм, акылга сыймый, ышанасым килми, дөрес булса да һич кенә бер ышанасы килми... Коточкыч!!

Ләкин хәзер ук, шушы минутта ук нидер эшләргә кирәк иде. Мин берни уйлап тормыйча ашыгып кулымны күтәрдем. Перов күреп алды да:

— Сезгә нәрсә? — диде.

Мин тордым. Минем уйлап куйган сүзем юк иде, минем бары бу коточкыч ялганны туктатасым килә иде. Җыелышка мөрәҗәгать итмичә, туп-туры Перовның үзенә әйтергә ашыктым:

— Монда ниндидер бик зур ялгышлык бар, болай ярамый, мин әйтергә тиешмен...

Ләкин Перов миңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде, салкын-коры гына:

— Сез үз сүзегезне соңыннан әйтерсез,— диде.

— Ни өчен соңыннан?.. Мин хәзер әйтергә телим...

— Сез инде, пожалуйста, тәртип бозмагыз... Вакыты җиткәч, без үзебез сезгә сүз бирербез.

— Ләкин бит...

— Бернинди «ләкиннәр» юк,— диде Перов, сабырсызланып.— Тыныч кына утырыгыз!

Җыелыштан «сөйләсен!» дип бер генә тавыш бирүче дә булмады. Җыелыш өнсез иде... Мин утырдым. Дөресрәге, мине баштан ук гаепләнүче сыйфатында утыртып куйдылар. Кагыйдәсе шундый — мин түзә алган кадәр тыңлап кына утырырга тиешмен.

Басыйрдан соң сөйләүчеләр күп булмады — әллә өчәү, әллә дүртәү иде шунда. Араларында мине юньләп белмәгән, минем белән аралашмаган кешеләр дә бар иде. Мәсәлән, Шәрипов дигән берәү чыгып, бик тотлыгып, әйтерсең оятыннан, бик кызарып сөйләде. Ә бит бу чи тиреләр складында эшләүче, озын кара керфекле матур егетнең минем белән, исәнләшеп узудан башка, туктап ике авыз сүз дә сөйләшкәне юк!..

Алардан соң безнең управляющий Решевский урыныннан торды. Аның сөйләргә җыенуы залда берьюлы зур

кызыксыну уятты булса кирәк, кешеләр ничектер аеруча тынып калдылар. Мин инде бөтен барлыгым белән аңа төбәлдем. Шунда ук күңелдә җылы өмет тугандай булды: ул бит минем иң югары начальнигым, ул мине белә, эшемне дә белә, ә үзе акыллы, төпле, җаваплы кеше — әлбәттә, ул мине болай ансат кына, сәбәпсез-нисез хур итеп ташларга юл куймас, куярга тиеш түгел!.. Һәм менә ул, постау кепкасын кулына тотып, мамык шарфын ике иңеннән генә салындырып, өстәл янына туры гына басты да, залга зур салкын күзләре белән беравык тыныч кына карап торганнан соң, ашыкмыйча, тигез тавыш белән сөйләп китте... Ләкин ни ишеттем мин, ни ишеттем?! Уйлап кына карагыз: мәсьәләнең үтә җитдилеге, кеше язмышы хәл ителүе турында бер сүз әйтмәстән, ул... минем надан, рухи җитлекмәгән, бик кечкенә бер кеше булуымны исбат итәргә тотынды. Моның өчен нәрсәне файдаланды диегез? Иблис тә уйлап таба алмас — минем көндәлек дәфтәр тотуымны! Димәк, Хафаза шуны да җиткергән булып чыкты!.. Их, егетләр! Һәм менә гомеремдә күрмәгән шул дәфтәр белән Решевский мине тетеп кенә тетә... Янәсе, көндәлек дәфтәр тотар өчен бик зур кеше, бик зур акыл иясе булырга кирәк. Мәсәлән, Лев Толстой кебек. Әнә ул гомере буена көндәлек язып барган, чөнки ул бөек художник, бөек философ — аның язар сүзе, язар фикерләре булган. Ә бу кем? Кичәге рабфак студенты, күкәйдән яңа гына чыккан бер чебеш! Нәрсә генә яза ала ул? Күп булса, үзенең буталчык, пешмәгән, хата уйларын, өч тиен дә тормас вак зарларын, яшь кызларны гына алдарлык (ай-һайһай!) сай, түбән хисләрен язып маташкан. Янәсе, күрегез, мин нинди кеше! Менә шул дәфтәр инде безгә аның черек җанын ачып та бирә. Эшчеләр казанында кайнап ныгыйсы, пролетариат тәрбиясе аласы урында бу егет, элекке елак гимназистлар шикелле, үзенең караңгы эчендә казынучы, үзен әллә кемгә санаучы, асылда исә бернигә яраксыз, берни күрми-аңламый торган сукыр эгоист булып кала биргән... Һәм шуның нәтиҗәсендә әнә нинди политический хата юлга да кереп баткан ул!

Решевскийның бу чыгышы мине шаккатырды дисәм генә аз булыр. Ул мине өнсез итте, һични аңлый алмаслык бер хәлгә китерде. Гүя сүз минем хакта да бармый!.. Чынлап та әллә икенче бер кеше белән бутыймы ул мине?.. Әле кайчан гына, мин авылдан кайткач кына бит, Решевский үзе, үз авызы белән миңа: «Васильев авыру кеше, цехны алып бара алмас, ахрысы, аның урынына, иптәш Юлдашев, сезне калдырырга туры килер, сез сәләтле егет, эшне тиз белеп алдыгыз, сезгә ышанып була»,— дип әйткән

иде. Ә хәзер кем булып чыктым инде мин? Бернигә яраксыз, булдыксыз, ышанычсыз, череп таралган сукыр эгоист! Гаҗәп! Гаҗәп!.. Кичә генә яхшы идем әле мин, бүген исә әнә нинди әшәке кешегә әйләнгәнмен! Ә дәлиле, ә нигезе кайда?.. Ул бит минем шул дәфтәрне төшендә дә күргәне юк. Берәүнең әләгенә таянып кына кешегә шундый коточкыч гаеп тагу —бу бит әллә нәрсә, бу бит абсурд!.. Юк, сыймый болар берсе дә минем акылга, сыймый, егетләр, теләсәгез нишләтегез!!

Дәфтәр турында да сүз чыккач, Хафазаның миңа кылган хыянәте аеруча әшәке-җирәнгеч булып тоелды. Дөрес, мин әле бу хыянәтне аңлый да алмыйм, ул хакта уйлый да алмыйм, тик бер нәрсәне бөтен җаным белән тоям: шушы минуттан ул кызый минем өчен үлде, бетте, юкка чыкты... Һәм, тиле кешедәй, бер нәрсәгә сөенәм: ярый әле бүген безнең урыннарыбыз бергә туры килмәде — нишләр идем мин югыйсә?!

Шулай ук мин тирә-юнемдәге кешеләрне дә күрми дә, сизми дә идем. Алар миңа карыйлармы, карасалар — ничегрәк итеп, белмим, аңарда кайгым юк. Күзләрем минем каршыдагы өстәлдә генә, шул өстәл янына чыгып басучыларның авызларында гына... Вакыт-вакыт мин башымны түбән иеп тә тыңлыйм, ләкин кемнән дә булса оялудан түгел, ә гел бер хәлдә утырып арудан гына... Соңыннан миңа: «Син тыныч идең, тик, кәгазьдәй, бик агарындың»,— дип әйтүчеләр дә булды. Белмим тагы, тик бер генә нәрсәне беләм — миңа энә белән чәнечсәләр дә берни тоймас идем шикелле... Нервлар әйтерсең тимерчыбыкка әйләнделәр.

Решевскийның шаккатыргыч чыгышы минем мәсьәләгә соңгы ноктаны куярга тиеш иде, ахрысы. Чөнки ул сөйләп бетергәч, председательлек итүче Перов, гүя шуны аңлатырга теләгәндәй, бары: «Бүтән сөйләүчеләр юктыр инде»,— дип кенә әйтте дә миңа күтәрелеп карады. Хәер, кыстаса да сөйләргә теләүче табылмас иде. Кайдан табылсын андый кеше?.. Кешеләр минем үзем шикелле үк тәмам аптырап, югалып, ничектер төсләре качып, шомланып калганнар иде.

Ләкин шулай да берәү урыннан күтәрелде. Бу — Вафа Янбулатов иде. Ул сүз сорады һәм өстәл янына чыгып тормыйча, баскан җиреннән ашыкмыйча, тыныч кына сөйли башлады. Минем эчкә аз гына җылы кергәндәй булды. Нидер әйтер, читләтеп кенә булса да, минем файдага нидер әйтергә тиеш дип көттем мин. Ә ул, мондагы сүзләрне бөтенләй ишетмәгән бер кешедәй, тотты да безнең коллективның язгы чәчү өстендә колхозларга нинди ярдәм күрсәтә алуы турында сөйләп китте. Һәм бик эшлекле итеп, конкрет тәкъдимнәр

кертеп сөйләде... Аның бу чыгышы миңа гына түгел, күпләргә шактый сәер булып тоелгандыр дип уйлыйм, чөнки ул кешеләрнең игътибарын мине талкудан әзрәк башка якка борып җибәргәндәй итте. (Асылда бу докладның төп темасына кагылган бердәнбер чыгыш иде.) Җыелышның һавасы да ничектер җиңеләя төшкән кебек булды.

Менә Вафа сөйләп бетте шикелле — артына борылып, урындыгына карап алды... Шулай ук бер нәрсә дә әйтмәс микәнни?.. Юк, нидер әйтергә җыена шикелле... Аз гына тынып торды да башын күтәреп, тыныч кына:

— Да, тагын шуны әйтмәкче идем,— диде.— Биредә иптәш Юлдашев хакында күп сүз булды. Ләкин мине шактый гаҗәпләндерде бу сүзләр... Мин дә бит Юлдашевны беләм, без кайчандыр бер бүлмәдә дә торган идек. Тик әйтергә тиешмен, Юлдашевның андый начар якларын мин беркайчан да сизмәдем, шулай ук аңардан нинди дә булса ялгыш, зарарлы фикерләр дә ишетмәдем.

— Димәк, сездә уяулык җитмәгән,— дип кыстырды шул чакта Басыйр, әче генә көлемсерәп.

Вафаның моңа да бик исе китмәде, һаман шул тынычлыгын саклап:

— Уяулык, әлбәттә, кирәк нәрсә ул,— диде,— ләкин кешене болай гаепләр өчен дә бит бик җитди фактлар кирәк, менә мин шуларны күрмим.

Шулай диде дә ул ашыкмыйча гына урынына утырды. Җыелыш гаҗәеп тын иде. Тагын кем нәрсә әйтер дип, бик җигелеп көтеп тору сизелә иде. Әмма ләкин кузгалучы, авызын ачучы булмады.

Ахрысы, минем үземә чират җиткәндер — Перов бая ук инде миңа карап куйган иде. Нәрсә дип әйтергә, ничек итеп? Күңелдән мең төрле уй, мең төрле сүз өермәсе бөтерелеп узды, ә шулардан сайлап алган бер нәрсәм дә юк диярлек. Тик акылым миңа әйтә: «Тыныч бул, тыныч бул!» — ди. Әйе, һичшиксез, тыныч булырга, каушамаска кирәк. Җылак-җебегәнне бер вакытта да аямыйлар. Мин бит биредә өелгән гаепләрнең берсе белән дә килешмәскә тиеш — барысын да катгый рәвештә кире кагарга, себереп түгәргә!! Бу минем иң көчле теләгем, йөземне аклый алырлык бердәнбер теләгем!.. Тик нервлар гына бирешмәсен иде...

Ниһаять, председатель:

— Инде иптәш Юлдашевның үзен тыңлап карыйк,— диде. Бу миңа ошамады, алдан ук миңа ышанмау белдергән шикеллерәк булып тоелды.

Мин тордым, өстәл янына узмыйча, бары эскәмиядән чак кына читкәрәк чыгып бастым. Башымны иеп, аз гына тынып тордым. Бөтен кешенең күзе миндә генә, бөтен кеше

гаять киеренке бер игътибар белән миннән сүз чыкканын көтә... Бу хәл мине тагы да богаулый төште, ләкин каушатмады, кешеләрнең миңа ят-дошман итеп карамауларын ничектер йөрәгем белән сизәм кебек. Башымны күтәреп карагач, бик табигый рәвештә, иң башлап шуны әйттем: «Монда ишеткәннәрем минем өчен шулкадәр көтелмәгән бер нәрсә булды ки, менә хәзер генә мин ни дип әйтергә дә белмим, иптәшләр!..» Аннары өстәл янында утыручыларга карап: «Мин бик гаҗәпләнәм,— дидем,— сезнең минем белән алдан сөйләшмичә, сорашмыйча, миңа шундый зур гаеп тагып җыелыш алдында чыгуыгызга... Мин моны просто аңламыйм!..»

Болай диюем председательгә бер дә ошамады булса кирәк, ул шунда ук миңа каршы төште:

— Сез, Юлдашев, бүтәннәрне гаепләргә ашыкмагыз... Иң элек үз гаебегез турында әйтегез.

— Нинди гаеп?

— Ник, ишетмәдегезмени?

— Ишеттем,— дидем мин һәм кинәт туган бер катгыйлык белән, хәтта кыза да төшеп туп-туры әйттем: — Минем бернинди дә гаебем юк, монда сөйләгәннәрнең барысы да чеп-чи ялган, берсе белән дә мин килешмим!..

Моның тәэсире булды, ахрысы, кешеләр ничектер кузгалышып куйдылар, ләкин Перов тизрәк шуны сүндерергә теләгәндәй:

— Сез әле авылга да кайтып килмәдем диярсез тагын?! — диде ясалма гаҗәпсенү белән.

— Юк, алай дияргә җыенмыйм,— дидем мин.— Ләкин авылга кайткач, минем ни эшләвемне, кемнәр белән нәрсә сөйләшүемне сез белмисез бит?!

— Ә бәлки, беләбездер,— дип куйды Басыйр, каядыр читкә карап кына.

Мин аның йөзенә нәфрәт белән кадалдым:

— Беләсез? Ләкин кайдан, кемнән ишетеп?.. Минем үземнән сезнең бер авыз сүз дә ишеткәнегез юк.

Перов, чыраен сытып, алга табарак иелде.

— Сез нәрсә,— диде ул, әкрен-усал итеп,— монда обструкция ясамакчы буласызмы? Барып чыкмас бит ул!.. Мондый юл белән акланырга тырышу берни дә бирмәс сезгә, Юлдашев! Үз гаебегезне честный рәвештә өстегезгә алсагыз яхшырак булмасмы?

Әйе, мин үземнең хәтәр юлга кереп баруымны, ниһаять, сизеп алдым. Бу рәвешчә үчләнеп каршы тору, әлбәттә, берни дә бирмәячәк. Әмма нинди дөрес юл бар?.. Алар миннән: «Мин гаепле, кичерегез!»— дигән сүзне көтәләр, көтмичә хәлләре юк, чөнки миңа гаепне тагып өлгерделәр

инде. Ә мин моны әйтә алмыйм, әйтмәячәкмен!.. Инде бөтенесен — авылга кайтуымны, анда ниләр күрүемне, ә монда кайткач, кемгә нәрсә сөйләвемне сөйли башласам, бердән, бик озынга китәчәк, икенчедән, һичшиксез Хафазаны телгә алырга туры киләчәк. Ләкин менә хәзер, шушы җыелыш алдында мин моны булдыра аламмы соң?! Хафаза миңа артык якын кеше, барысы да диярлек моны бик яхшы беләләр, әгәр шуннан мин аның бу эштәге әшәке ролен ачсам, халык гаҗәп-хәйран калачак. Хәтта ышанмаулары да мөмкин. Яраткан кешеңә яла ягу, яраткан кешеңне батыру — бу бит тиз генә акылга сыя торган нәрсә түгел... Аннары Хафаза үзе генә гаеплеме соң бу эштә? Мине батырыр өчен «кирәк» булган сүзләрне аңардан ничек алганнар?.. Мин бит әле бернәрсә дә белмим, белмим... Бәлки, аның сүзләрен монда бөтенләй үзгәртеп сөйли торганнардыр?.. Ни өчен Хафаза үзе торып бер сүз дә әйтмәде — миңа ташланган гаепләрне ник расламады яки кире какмады?.. Ничек кенә аңларга соң боларның барысын да?.. Искиткеч авыр хәл!

Һәм шушы гаять киеренке минутта минем башыма кинәт кенә бер фикер килде: барысыннан элек безгә Хафаза белән очрашып сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Мин моны шул ук Перов, шул ук Решевскийлар алдында эшләргә дә әзер — әйдә, алар да чын хакыйкатьне ачуда катнашсыннар... Бу фикерне мин үземчә бик хаклы дип таптым. Һәм шуны тизрәк әйтергә дә ашыктым:

— Сүз биредә минем язмышым турында бара, иптәшләр! Мәсьәлә бик җитди, үтә җитди... Әгәр минем берәр гаебем булса, мин аны яшереп тормас идем. Ләкин юк ул, юк... Һәм мин үземнең гаепсез булуымны сезгә исбат итәрмен, тик сездән бүген үк ашыгыч нәтиҗә ясамавыгызны, минем мәсьәләне яңадан партоешмада каравыгызны һәм шунда мине яхшылап тыңлавыгызны сорыйм. Тик миңа вакыт кына бирегез, мин барысын да сезгә ачыктан-ачык сөйләрмен. Шулай ук минем, авылдан кайткач, нәрсә сөйләвемне ишеткән кешене дә чакырырсыз. Сез... аны беләсез... Кыскасы, миңа вакыт һәм мөмкинлек бирегез, мин сездән шуны үтенәм.

Шулай дидем дә урыныма утырдым. Минем соңгы сүз Перовны һәм, бигрәк тә, Басыйрны бер мәлгә аптырауга төшерде шикелле, алар иреннәрен кысып, аз гына вакыт тып-тын булып калдылар. Басыйр, хәтта куркынгандай кылый күзләрен елтыратып, Перовка җәһәт кенә карап та алды. Ләкин Перов бик тиз исенә килде, тынычлыгын югалтмыйча, өстәлгә таянып кына урыныннан торды һәм көлемсерәп кенә:

— Мин сезнең үтенечне аңлап җиткермим, иптәш Юлдашев,— диде.— Ни өчен без бирегә җыелдык, сөйләшер өчен түгелмени? Безнең бит коллективтан яшерен эшебез юк... Менә иптәшләр җыелыш алдында үз сүзләрен әйттеләр, ә ник сез әйтергә теләмисез?

— Бүген мин әзер түгел, кичерегез! — дидем мин, башка сүз таба алмыйча.

— Аңлашыла! — дип куйды Перов, бик мәгънәле итеп кенә.

Җыелыш әүвәлгечә тып-тын утыра. Кемнәр ни уйлый торгандыр — мин аны белә алмыйм, әмма әйткән сүзләремнән канәгать булмауларын ничектер сизәм шикелле... Чыгышым минем, әлбәттә, «уңышсыз» булды. Һәм председательлек итүче Перов үзенең йомгаклау сүзендә моны бик «оста» күрсәтеп тә бирде:

— Без хәзер генә иптәш Юлдашевның сүзен тыңладык,— диде ул, гадәтенчә ашыкмыйча гына башлап, әмма отыры кыза барып.— Үзен аклап, нәрсә әйтә алды ул, нинди дәлилләр китерде?.. Юк, кызганычка каршы, юк бит, бөтен әйтергә тырышканы: аңа тимәгез, ул гаепсез, аны менә монда — коллектив алдында түгел, ә бүтән бер җирдә, кешеләрдән яшеренеп кенә тыңлап карагыз!.. Нәрсә бу, ә? Мин сездән сорыйм... Җаваплылыктан качарга, эз яздырырга азаплану гына түгелме соң бу?..

— Юк, түгел! — дидем мин, шактый кычкырып.

— Ә сез, Юлдашев, тыныч кына утырыгыз, без сезне тыңладык инде. Ләкин белегез, сез ташлаган кармакка без барыбер капмабыз!.. Менә шулай. (Аннары җыелышка карап) Йә, ничек бәяләргә тиеш без, иптәшләр, Юлдашевның мондагы чыгышын һәм кыланышын?.. Дөресен генә әйткәндә, без аңардан иң кирәген ишеттек шикелле: ул барыбызны да чеп-чи ялган сөйләүдә гаепләде... Уйлап кына карагыз, иптәшләр, монда утыручылар, шул исәптән хәтта безнең управляющий Решевский да, ялган сөйләүчеләр, тик аныкы гына дөрес, ул гына хаклы... Бу бит демагогия, иптәшләр, кычкырып торган демагогия! Шулай гына бәяләргә мөмкин аның бу чыгышын... (Ә сезнең монда бөтен сөйләгәннәрегез демагогия түгелмени? — дип янә кычкырасым килде, ләкин тыелдым, тыелырга тиеш идем.) Димәк, иптәш Юлдашев биредә аңа карата әйтелгән ачык, таза тәнкыйтьне кабул итми, үзенең бер генә, кабатлап әйтәм, бер генә хатасын да танырга теләми. Димәк, ул әле һаман да үзенең нинди ялгыш юлга кереп киткәнен, нинди оппортунизм сазлыгына кереп батканын аңламый. Яки аңларга теләми... Менә шундый гына нәтиҗә ясарга туры килә, иптәшләр!

Мин шаккатып тыңлыйм. Ихтыярсыздан, чынлап та шулай микәнни, дип хәйран калып уйлыйм. Ничек итеп үз хәлеңне дөрес аңларга соң?.. Алар әйткән сазлыкка мин кайчан, ничек кереп батканмын?.. Гаҗәп бит бу!.. Син үзең шуны белмә, бүтәннәр белсен, имеш! Җитмәсә әле, син үк акланырга да тиешсең! Ай-яй, кая таба китте эшләр!..

Ә председатель шул арада сүзен болай дип дәвам иттерде:

— Монда чыгып сөйләүчеләр дөрес әйттеләр: кулак идеологиясен таратучыны без үз арабызда калдыра алмыйбыз, иптәшләр! Бигрәк тә үз хатасын танырга теләмәгән кешегә карата без либераллык күрсәтергә тиеш түгелбез... Рәхимсез сыйнфый көрәш бездән шуны таләп итә. (Бу урында ул Гыйльметдин кулак вакыйгасын да телгә алды, Вафаның фактлар юк дигән сүзен дә оста гына кире какты. Аныңча, уяулык дигән нәрсә коры фактлар җыюда гына түгел, ә шуның иң кечкенәсеннән дә политик нәтиҗә ясый белүдә күренергә тиеш.) — Шуңа күрә мин үзем,— дип сүзен бетерде ул,— иптәш Юлдашевны эшеннән азат итәргә кирәк дигән тәкъдим белән тулысынча килешәм. Администрация дә җыелышның бу теләген кабул итәр дип ышанам. Башка тәкъдимнәр юкмы, иптәшләр? Алайса, иптәш Юлдашевның эшеннән азат ителүен администрациядән сорарга дигән тәкъдимне тавышка куям... Кем дә кем...

Һәм ул иң элек үзе башлап кулын күтәрде. Аңа ияреп, өстәл тирәсендә утыручылар, залдагы кешеләргә бик төбәлеп, сынап караган килеш кулларын күтәрделәр. Мин залга, хәтта күршемдә утыручыларга да карый алмадым. Ләкин нәкъ шул чакта, кисәк кенә җил исеп киткәндәй, кешеләрнең ничектер хәрәкәткә килеп, үзара пышылдашып алуларын сизеп калдым. Ни булды дип күтәрелеп карасам, ишектән ашыгып, бәрелә-сугыла Хафаза чыгып бара!.. «Түзмәде, мескенкәй!» — диде артымда утырган кемдер берәү... Мин, әйтерсең, таш сынга әверелдем — шулкадәр хәйран итте бу хәл мине!.. Бары тик Перовның: «Каршылар юк!» — дигән сүзен ишеткәч кенә айнып киттем.

...Җыелыш бетте, кешеләр авыр гына урыннарыннан кузгалдылар. Кысылып, бер-берсенә ышкылып, ашыкмыйча гына ишеккә таба агыла башладылар... Шул чакта кемдер, Әмин әкә булса кирәк, сак кына минем терсәктән кыскандай итте. Ләкин бу минутта миңа беркемнең дә кызгану ишарәсе кирәкми иде. Мин халык арасыннан тизрәк ычкынып, урамга чыгу, күздән югалуны гына тели идем. Ахрысы, якын иптәшләр үзләре дә моны сизгәннәрдер — миңа иярүче, озата баручы булмады.

## XVI

Шулай итеп, Бәкер дус, мин — бүген генә әле берни сизмичә цехта рәхәтләнеп эшләп йөргән, барлык иптәшләр өчен дип әйтерлек үз, якын булган кеше — шушы язгы җылымса-җепшек бер кичтә эштән, эштән генә түгел, тормыштан сөрелдем. Сөйгән кызыма, якын дусларыма, бөтен коллективка (ә бәлки, бөтен җәмгыятькә) чит-ят кеше булып — очраганда хәтта кул бирергә дә ярамый торган хәтәр бер кешегә әверелеп калдым. Махау (проказа) авыруы йоктырган кеше мин хәзер! Хет үкереп ела, хет тилереп көл!

Ул кичтәге хәлемне мин ничек дип аңлатырга да белмим. Авырмы миңа?.. Белмим. Җиңел түгеллеген беләм, әмма авыр икәнлеген ничектер тоймыйм, тоя алмыйм. Уйлыйммы мин? Белмим. Миемнең бер генә күзәнәге дә эшләмичә тормаганын беләм, әмма конкрет нәрсә уйлавымны аңламыйм, аңлый алмыйм.

Тик бер нәрсәне беләм икән (аны да яткач кына сиздем): башым үземнеке түгел кебек, ул кабак хәтле булып зурайган, эче буш һәм берөзлексез әкрен генә шаулап тора... Тагын шул, йоклаганда да мин җыелышта ишеткән-күргәннәрдән котыла алмадым — әлеге Басыйр, Решевский, Перовларның чырайлары күз алдымда гел селкенеп, тавышлары колагымнан китмичә азаплады.

Икенче көнне йокыдан торгач, әйбәтләп боздай салкын су белән юынгач һәм берни ашамыйча диярлек кайнар куе чәй эчкәч, мин иске хәлемә кайткандай булдым. Һәрхәлдә, миңа күпмедер дәрәҗәдә сәламәт зиһенем кайтты. Билгеле, мин эшкә барып тормадым (куылган җиргә ни өчен барыйм?), кирәк булсам, үзләре чакырып алырлар дидем... Васильев та чыкмаган булса, цехның бөтенләй күз-колаксыз калуы мөмкин, хәер, анысы хәзер минем эш түгел инде... Шуңа күрә тар бүлмәмнән беркая чыкмыйча иркенләп, үземчә тыныч кына уйларга тотындым. Вакыт — чиксез, беркемнең — адәм заты гына түгел, бер этнең дә киләсе юк, гарык булганчы уйла да уйла!.. Һәм мин утырып та, ятып та, ишекле-түрле йөреп тә «рәхәтләнеп» уйладым.

Билгеле инде, иң элек табигый рәвештә минем уйларым, экранга төшкән нур көлтәседәй, Хафазага төбәлде. Кечерәк буен да, тулы-тыгыз гәүдәсен дә, кара җимештәй зур күзләрен дә күрәм мин, ләкин боларның берсе дә хәзер минем сыңар төгемне дә кыймылдатмый, ичмасам! Агачка караган шикелле карыйм мин аңа һәм, бөтен акылымны җигеп, тик бер нәрсәне аңларга тырышам: кем

булып чыкты ул? Ничек итеп аңларга аның бу эшен?.. Әлбәттә, миңа Хафаза турында тыныч кына уйлау җиңел түгел, бер дә җиңел түгел... Ихтыярсыздан бөтен эчемне тирән ачу-нәфрәт ялкындай каплап ала башлый. Әмма ләкин, вакыт-вакыт әнә шулай ярсып китүемә карамастан, мин аны ничек тә дөрес, гадел аңларга тырышам. Бигрәк тә кичә аның җыелыштан кинәт кубып, бәреләсугыла чыгып китүе мине бик нык уйга калдырды. Ничек аңларга аның бу эшен?.. Ни кылганын аңлап алдымы, намусына көч килдеме, әллә минем өчен куркып киттеме? (Ихтимал, ул болай ук булыр дип һич тә уйламагандыр.) Ләкин ничек кенә юрама, аның бу чыгып качуы ниндидер бик тирән җан газабыннан туган булырга тиеш иде. Шулай сизәм мин моны һәм шуңадыр инде, бәгырем бик катса да, ничектер менә рәхимсез хөкем итә алмыйм үзен... Җәлләү дә түгел бу, гафу итү дә түгел, тик ничек кенә әйтергә?.. Үзе дә бәхетсезлеккә төшкән кешене беркадәр аяу гына.

Баштан ук бер нәрсә миңа ачык иде: бу эштә Хафаза үзе генә гаепле түгел, әлбәттә. Кемнәрдер аны бу хаинлык юлына этәргәннәр, көчләгәннәр, мәҗбүр иткәннәр — һичшиксез, ул шулай! Сез беләсез инде Басыйр дигән бәндәнең соңгы вакытларда миңа тыштан дус булган булып, күбрәк Хафазага елыша баруын. Моның өчен сылтавы да бар иде — янәсе, алар кайчандыр бер мәктәптә укыганнар. Әлбәттә, Хафазага елышуның төбендә бер генә максат — минем хакта аңардан ничек тә күбрәк сүз алу булган дип уйларга кирәк. Хәзер инде эшнең ничегрәк булганын күз алдына китерүе дә читен түгел: авылдан кайткач, минем беренче көнне үк сөйләгән сүзләремне Хафаза, ачыгавыз, аны-моны уйламыйча Басыйрга әйткәләгән булырга тиеш. Ә теге җәсүскә шул гына кирәк тә инде: җепнең очын бер эләктереп алгач, ул, ычкындырмыйча, һаман әкрен генә тартып чыгара барган. Шулай итеп, «дус» кыздан шактый суыргач, Басыйр бөтен ишеткәннәрен Перовка җиткергән булырга тиеш.

Ә шуннан соң?.. Шуннан соң Хафазаны Перов бүлмәсенә чакырып алганнар да минем хакта бөтен белгәнен сөйләргә кушканнардыр. Анда Перов белән Басыйрдан башка, ихтимал, управляющий Решевский да булгандыр. Мондый «авторитетлар» алдында Хафаза ничек итеп сөйләмәсен ди?.. Билгеле, кызыйдан бар белгәнен сөйләтер өчен аны үгетләү дә, төрлечә юмалау да, ә бәлки, оста гына өркетү дә булгандыр. Яшь, тәҗрибәсез, куркак бер кызны сөйләтер өчен күпме кирәк соң? Менә шулай күз алдыма китерәм мин бу эшне... Менә шуңа

күрә дә аның сөйләвенә минем ул хәтле исем дә китми һәм әллә ни ачуым да килми — хәтта гафу да итә алыр идем мин аны. Әмма инде аның шушы эшен миңа белдермәве, миннән яшерүе мине соң дәрәҗәдә гаҗәпләндерә. Дөрес, тегеләр аны: «Белдермә!» — дип бик нык кисәтеп куйганнардыр, ләкин ул барыбер... барыбер миңа белдермичә түзмәскә, белдермичә калмаска тиеш иде!.. Бала түгел бит инде, яраткан кешесенә нинди зарар, нинди бәхетсезлек китерүен әзрәк чамаларга тиеш иде ләбаса! Белмим, белмим. Куркак булырга мөмкин, бөтенләй җебегән, ихтыярсыз бер кеше булырга мөмкин, әмма бу кадәр түбән төшәргә, бу кадәр намусыңны буарга мөмкинме соң?! Мәхәббәт хакына кешеләрниләр генә эшләмәгәннәр, нинди генә корбаннарга бармаганнар! Ә ул нишләде? Кылган әшәкелеген эченә яшереп, соңгы көннәргә кадәр диярлек минем яныма килеп йөрде, минем тезләремдә утырды һәм читләтеп кенә булса да бер сүз әйтмәде! Син хәтерлисеңдер, мин бит аның шул вакытларда нәрсәдәндер һаман күңелсезләнә, йомыла баруын күреп, шуңа борчылып, үзеннән: «Ни булды сиңа, бәгърем? Әйт, яшермә!» — дип сорадым лабаса, сорадым. Ә ул, куян шикелле, шул чакта да: «Юк, берни дә юк», — дип мине алдады. Туры сорауга җавап кына бирергә дә йөрәге җитмәде. Кичерергә мөмкинме соң моны? Юк, бервакытта да! Ирексездән кылган хыянәте өчен генә дип әйтмим, ә кешенең ышануын җимергән өчен, иң кабахәт рәвештә алдаганы өчен, ниһаять, мәхәббәт дигән иң изге, якты, кадерле бер хисне таптап, пычратып ташлаганы өчен кичерү мөмкин түгел!

Белмим, мин, бәлки, аңа карата артык рәхимсезлек күрсәтә торганмындыр! Бәлки, болай ук каты булырга ярамыйдыр? Төп гаеп тегеләрдә бит. Әйе, аларның гаебе коточкыч! Алар безнең яратышып йөрүебезне беләләр иде бит. Шул ук Басыйр безне өйләнешергә димләп йөрүчеләрнең берсе түгелме?! Ә нишләделәр алар? Бер яшь, куркак кызны яраткан егете өстеннән әләкләргә, яраткан егетенә яла ягарга мәҗбүр иттеләр. Барлык заманнарда, барлык халыкларда мәхәббәт белән тугрылык аерылгысыз булган. Тугрылыктан башка мәхәббәт була алмаган. Ә монда нәрсә? Мәхәббәт һәм донос!.. Йа Хода! Моны бит Басыйр шикелле бөҗәк аңламаса да, теге Лев Толстой дип төкереген чәчкән «интеллигент» Решевский аңларга тиеш иде. Катгый рәвештә: «Ярамый бу, берниндидә моральгә сыймый бу!» — дип әйтергә тиеш иде... Мин дә көрәшне әзрәк аңлый торган кеше, көрәшнең бик рәхимсез нәрсә икәнен яхшы беләм. Әмма ләкин һәрнәрсәнең

чиге булырга тиеш: мәхәббәт һәм донос, ата хакы һәм донос — бу әхлак һәм кешелек кагыйдәсеннән тыш нәрсә!.. Моны кабул итү мөмкин түгел!

Син, Бәкер дус, болар барысы да әле юрау гына, тәгаен ничек булганын ачык кына белмисең бит әле син, дип әйтерсең, бәлки?.. Ник тизрәк Хафазаны күрергә ашыкмыйсың, ник аңардан барысын да сорашмыйсың, дип әйтәсең киләдер?.. Әйе, дөрес әйтәсең, дөрес!.. Бүген күземне ачып җибәргәч тә миндә туган беренче теләк, беренче омтылыш ничек тә аны эзләп табу, аны күрү булды. Хафазаны күрмичә торып, мин бит тәгаен бер нәрсәне белә дә һәм берни эшли дә алмыйм. Ул үзе минем белән очрашырга теләрме — белмим, әмма миңа ул кирәк, стенага терәп булса да мин аңардан барысын да сөйләтергә тиешмен... Ләкин бүген ул эштә, хәзер генә аның янына бару да, сөйләшү дә һич мөмкин түгел. Көтүдән башка чара юк. Шуңа күрә дә мин бүгенге көнемне, ялгыз тоткын шикелле, менә шулай уйланып та юрап уздырырга мәҗбүрмен...

Аннары, дөресен генә әйткәндә, мин, уйлана торгач, әзрәк сүрелә дә төштем. Асылда бит, Бәкер дус, спектакль уйналды инде — шаккатыргыч, ялган, бозык спектакль (кичер, башкача мин аны атый алмыйм) — кем оештырган, ничек әзерләнгән ул — хәзер моның ни әһәмияте бар?! Уйнаучыларын да күрдек, кемнең нинди роль башкаруын да белдек дияргә ярый. Басыйр турында әйтеп тә тормыйм, аның роле миңа хәзер көн кебек ачык: шымчы-хаин, үзенең карьерасы өчен туган атасын да сатып җибәрер!..

Перовны да аңлап була. Гыйльметдин кулак вакыйгасыннан соң аның бер «кылыч ялтыратып» аласы килгәндер. (Бу вакыйганың җиле аңа да бераз кагылганын мин әйткән идем инде...) Моның өчен шарты да туры килә, сылтавы да табыла: менә берәү (ягъни, мин) авылына барып кайткан: кайткач, колхоз турында ярамаган сүзләр сөйләгән. (Ә сүзне төрлечә бозып, күпертеп була. Әйтик, мин агайлар зарлана дип әйткәнмен икән, аны минем дә үз зарыма әйләндереп җибәрү ни тора?) Җитмәсә, болар барысы да Хафаза кебек миңа иң якын кешедән, Басыйр кебек минем «дустымнан» алынган сүзләр... Йә, монысын игътибарсыз калдырырга ярыймы соң?.. Перов үзе үк бит еш кына: «Положение обязывает»,— дип әйтергә ярата торган иде... Һәм менә бу юлы инде ул, ниһаять, «положение кушканча» эшләп тә куя. Әлбәттә, ул моны минем гаепле, ә үзенең хаклы булуына ышанып эшләгәндер... Хәер, бу кадәресе аның өчен әллә ни әһәмиятле дә булмаска тиеш. Монда төп максат әһәмиятлерәк. Ә төп максат шул: хәзерге кие-

ренке шартларда уяулык күрсәтү сылтавы белән мине «фаш иткән» булып, үзенең дәрәҗәсен күтәрү, урынын ныгыту — бары шулай гына аңлыйм мин аның гамәлен... Чөнки әгәр ул намусы кушканча һәм чын коммунистларча эшләргә теләсә, иң элек чын хакыйкатьне белергә тырышыр иде. Менә болай гына, миннән сорашмыйча-нитмичә, артымнан башыма казык белән китереп ормас иде.

Йә, әйт, Бәкер, минем бу юрауларым нигезсезме, минем хәлдә калган кешенең башкача уйлавы мөмкинме? Миңа бик авыр... Бәлки, рәнҗүдән, ялгызлыктан, артык ярсудан мин нәрсәнедер аңлап җиткермимдер, ниндидер детальләрне белеп бетермимдер, әмма мин үземнең гаепсез икәнлегемне беләм, мин гаепсез, һәм моңа ышанган кеше минем хәзерге хәлемне дә аңлар, шәт!

...Көн бик әкрен уза. Эш юк, хәрәкәт юк — нишләргә? Мин моңарчы гомеремнең бер генә көнен дә менә болай эшсез тик ятып үткәргәнем юк иде әле... Үземне белә башлаганнан бирле йә эш, йә уку! Каникул вакытларында да ял итим дип тик ятмадым: авылга кайтсам, икенче көнне үк җиң сызганып әнкәйнең хуҗалык эшләренә тотындым, шәһәрдә калсам, Усиягә төшеп, баржалардан йөк бушатып йөрдем. Инде андый эш таба алмасам, университет китапханәсенә барып, шунда сәгатьләр буенча утыра идем. Гомумән эшсез-хәрәкәтсез тору бу, Тукайга ияреп, «әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору»!.. Ләкин күпме генә болай торырга мөмкин?

Ә тышта яз, абзыкаем, яз! «Назланып, сазлар чиртеп, уйный-җырлый яз килә» — ә мин шуны күрми торам... Әнә безнең көрт баскан ишегалдыннан ак ерганаклар сикерә-сикерә уйнаклап урамга чабалар. Ике малай актыгы такта кисәгенә чыра кадаган «көймәләрен» абынасөртенә агызып маташалар. Күрше йортның кояшка караган баскычына зур бер ала песи кырын сузылып яткан — җылыкай рәхәттән тәмам мәлҗерәгән, юньсез, шул тирәдә чыр-чу килгән чыпчыкларда да гаме юк. Ачык капкадан урамда үтеп-сүтеп йөргән кешеләр күренә. Ирләр, хатыннар, егетләр, кызлар — гүя тормыш үзе язгы ташкындай агып тора минем янымнан...

Юк, болай ярамый. Болай яту — сазга бату! Көзге болытлардай басып, каплап алган бу авыр, караңгы уйлардан ничек тә чыгарга, котылырга кирәк. Аларның очыкырые булмас. Бүгенге көнем ялгыз чүмәләдәй утырып янды инде, әмма әүвәл-ахрысы шул булсын. Җитте. Тизрәк яңа көн тусын... Тегеләр үз эшләрен эшләделәр, миңа да хәрәкәт итә башларга кирәк. Әйе, кирәк, ләкин ничек итеп? Бу сорау, тимер ыргактай, алдымда селке-

неп тора. Башка бөтен уйлардан, нигә, ни өчен дигән газаплы сораулардан котылып булса да, бу — кала, моңардан котылу юк: әйе, ничек, нәрсәдән башлап хәрәкәт итәргә? Моның өчен бит кайдадыр, кемнәрдер алдында Хафаза белән очрашырга туры киләчәк... Кичәге ике гашыйк —бүген ике дошман — менә кайда ул фаҗига!

Әйләнәм дә өстәлдәге иске будильникны килеп карыйм. Миңа тавыш биреп торучы бердәнбер «җан иясе», гаҗәеп бер ваемсызлык белән, ашыкмыйча гына минутларны, сәгатьләрне саный тора. Инде бишенче ярты да булган икән. Бездә эш беткән вакыт. Кешеләр өйләренә тарала-лар бугай... Ә мин борчылам, көтүдән аерылган тай кебек борчылам. Әледән-әле тәрәзәгә килеп карыйм. Кемне көтәм мин? Хафазанымы? Ул бит көн дә, эштән кайтып ашагач-эчкәч, кичкырын ашыгып миңа килә торган иде. Шушы бүлмәгә, минем яныма, кулга ияләшеп беткән күгәрчендәй, килеп керә иде. Бәхетле идем мин шул минутларда, тавышын гына ишетсәм дә, җиңел, куанычлы бер рәхәт татый идем. Бәлки, шуны оныта алмыймдыр, шуны гына көтә торганмындыр?! Авыр, бик авыр барысын да тиз генә йолкып ташлавы!..

Тәрәзәгә бер килеп каравымда мин ишегалдында басып торган ике кызны күрдем. Кемнәр болар? Кемгә килгәннәр? Ләкин минем тәрәзәгә карап торалар бит болар, минем тәрәзәгә! Ничектер тик кенә, кыюсыз гына карап торалар — һичшиксез, миңа килгән кызлар! Тизрәк ашыгып тышкы ишеккә чыктым. Карасам — Бибинур белән Сара! Бер мәлгә аптырап киттем, аннары кычкырып дәштем үзләренә.

— Кызлар!

Ишеттеләр дә йөгереп килделәр. Кызарышканнар, каушаулары йөзләренә чыккан, сүзләрен әйтә алмыйча аптырап миңа карап торалар. Ахырда үзем:

— Нинди җилләр ташлады сезне? — дип сорадым.

Кызлар, инде нишлибез, нәрсә әйтәбез дигән төсле, бер-беренә карашып алдылар. Азрак ык-мык итеп торганнан соң, ниһаять, Бибинур ашыгып, бер тыннан әйтеп куйды:

— Сезне күрергә килдек...

Мин нигәдер чәчемне артка сыпырырга тотындым.

— Без бик борчылдык, Хәбиб абый,— дип өстәде Сара, әкрен генә.

— Шулаймыни? — дидем мин хәзер генә исемә килгәндәй.— Әйдәгез, алайса керик.

Кызлар тагын карашып алдылар. Сарасы хәтта башын да селеккәндәй итте. Куркалар, ахрысы, куркалар, бичаралар!

— Без сезне тәрәзәдән генә күреп китәргә уйлаган идек,— диде Бибинур, гаепле генә елмаеп.

— Юк,— дидем мин катгый рәвештә,— керегез! Килгәч инде керәсез, кызлар! Әйдәгез!

Кызлар кыюсыз гына бүлмәгә уздылар. Икесенә дә урындык биреп, утырырга куштым — пальто төймәләрен дә ычкындырмыйча, аякларын кушырып кына болар утырдылар. Үзем тынычланыр өчен ишекле-түрле йөреп алдым, аннары каршыларына басып:

— Борчылмагыз, кызлар! — дидем.— Берни дә булмас, булырга тиеш түгел.

Кызлар дәшмәделәр. Алар әле берни сөйләрлек хәлдә түгелләр иде, тик балаларча күзләрен тутырып, бик сәерсенеп миңа карыйлар,— әйтерсең мин теге дөньядан әйләнеп кайткан кеше! Әллә ничек аяныч та, әзрәк көлке дә булып китте аларның бу чырайлары...

— Йә, сөйләгез инде,— мин әйтәм,— ничек болай кинәт кенә... Үзегез уйладыгызмы, әллә берәрсе куштымы?

— Юк, үзебез,— диде Бибинур, ашыгып.— Бары үзебез, берәү дә белмәде дә.

— Рәхмәт, кызлар, рәхмәт!

— Без бик курыктык,— диде Сара, нигәдер кызарып.

— Кемнән, нәрсәдән?

— Сезнең өчен курыктык. Берәр хәл булмады микән, йә авырып китмәдегезме икән дип курыктык. Кичә сезгә бик начар булды бит. Ничек түзәр Хәбиб абый, дибез, ничек түзәр? Үзенә берәр нәрсә эшләп куймасын тагы, дибез. Шуннан Бибинур әйтә, әйдә, ди, эштән чыккач барып карыйк, ди. Куй, мин әйтәм, Хәбиб абый күрсә, куып кына җибәрер... Аннары кешеләрдән дә яхшы түгел, белсәләр, әллә ни уйларлар, дим.

Бибинур аның сүзен әләктереп алды:

— Сара шундый инде: үзе миннән дә күбрәк кайгыра, ә үзенең коты чыга.

— Чыкмыйча... ни бит, кичә нәрсә эшләттеләр бит, бөтенләй, әйтергә куркыныч, контр ясап куйдылар.

— Ә сез шуңа ышандыгызмы?

— Ышансак, килеп тә йөрмәс идек,— диде Бибинур, кыюланып.

— Юк, мин ул турыда уйламадым да,— диде Сара.— Тик бик капыл булды бит, шулай ярыймы, бөтен кешене аптыратып.

— Ләкин, кызлар,— дидем мин,— монда ул хәтле аптырарлык эш юк. Тыныч булыгыз, мин алар әйткән кеше түгел. Тиздән моңа бүтәннәр дә ышанырлар. Дөрес, миңа авыр булды, яшермим. Ләкин шулай да башны ташка

бәрергә җыенмыйм әле... Килүегез өчен сезгә тагын бер тапкыр бик зур рәхмәт! Батыр кызлар икәнсез. Менә миңа да ничектер берьюлы җиңел булып китте. Инде сөйләгез, цехта ниләр бар, кемнәр ни сөйли?

— Цехта барысы да искечә, Хәбиб абый,— диде Бибинур.— Килдек, урыннарыбызга бастык, эшли башладык. Тик сез генә юк. Моны барыбыз да сизеп торабыз, ләкин беркем берни сөйләми, башын игән, эшләвен генә белә.

— Бөтенесендә караңгы чырай,— дип өстәп куйды Сара.

— Арттырасың, Сара! — дидем мин.

— Билләһи менә, һич арттырмыйм,— диде Сара, тагын кинәт кенә кызарып.

— Дөрес, Хәбиб абый,— диде Бибинур, иптәшен яклап.— Бигрәк тә приказны укыгач, әллә ничек бик күңелсез, авыр булып китте.

— Нинди приказны?

— Шул инде, сезне эштән чыгару турындагы приказ... Цехка кертеп элделәр.

— Шулаймыни? — дидем мин, ни әйтергә белмичә, мыгырданып кына.

Бу хәбәр йөрәкне ничектер әрнетеп, телеп узды. Каядыр күңел төбендә, бәлки эштән үк чыгармаслар әле, дигән кечкенә бер өмет чаткысы яши иде — менә шул кинәт кенә сүнде дә куйды. Бер мәлгә зиһенем чуалып, ничектер югалып та калдым... Ләкин бу хәлне кызларга сиздермәскә кирәк иде. Көчләнебрәк, ясалмарак бер тавыш белән:

— Шулай да, кызлар, мине эштән чыгаруның ул кадәр ни әһәмияте бар искитәрлек? — дигән булдым.

— Ник булмасын,— диде Бибинур, чын ихластан гаҗәпләнеп.— Кичә генә безнең арада эшләп йөргән кешене бүген цехка кертмәсеннәр әле. Сез карак түгел ләбаса!

— Юк, син дөрес әйтмисең, Бибинур! — диде акыллы Сара.— Каракка, бәлки, тимәсләр дә иде. Әнә, кем, Фәрдәнә дигән кыз ике каракүл тиресе белән тотылган иде дә бит, чыгармадылар ич... Ә монда эш бөтенләй башка. Кичә ишеттең бит, Хәбиб абыйга нинди зур гаеп тактылар, моның өчен, беләсеңме, эштән генә дә чыгарып калмыйлар. Тик кешеләр шуңа ышанып бетмиләр, дөресме соң бу? — дип аптырыйлар. Менә эш нәрсәдә.

— Кызык әле бу,— дидем мин, маңгайны кат-кат ышкып.— Кешеләрнең нәрсә уйлаганын кайдан беләсез, үзегез беркем, берни сөйләми дисез?

— Әйе шул, аптыраганга күрә сөйләмиләр. Сезне гаепләп, дөрес эшләделәр дип әйтерләр иде — чынын гына

белмиләр, ышанмыйлар. Дөрес түгел бу дип әйтергә дә аптырыйлар, ә бәлки, курка да торганнардыр. Аны сизеп була бит инде.

— Беләсезме, Хәбиб абый,— диде Бибинур, тавышын әкренәйтә төшеп,— безнең цехка берничә мәртәбә Басыйр Рәҗәпов кереп чыкты. Әле берәүләр янына барып туктала, әле икенчеләр янына. Безнең янга да килде. Нихәл, кызлар, дигән була, кәефләр ничек, эшләр барамы, имеш. Ярый хәзергә, бара, дигән булдык. Бүтән бер сүз дә әйтмәдек. Ә ул һаман таптана, һаман нидер көтә, ә без аңа күтәрелеп карыйсыбыз да килми. Сизәбез инде, сер алырга йөри. Башкалар янына барса да шулай, дәшмиләр-сөйләшмиләр, эшләүләрен генә беләләр. Дөрес бит, Сара?

— Дөрес, Бибинур!

Кызларның бу сөйләгәннәре минем өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле иде. Миңа әйтерсең шифалы су эчерделәр —берьюлы терелеп киткәндәй булдым. Эчемә җылы йөгерде, күңелемдә өмет уяна башлады. Тик әле боларның барысына да ышаныргамы, юкмы дип куркыбрак торам. Әмма ләкин кызлар дөрес сөйли торганнардыр бит, шайтан алгыры?! Аларның кача-поса килүләре үзе үк дөрес сөйләүләрен, чын ихластан сөйләүләрен күрсәтмимени соң?! Бәлки, азрак арттырып җибәрә торганнардыр, әмма барыбер дөресен белеп була бит! Ә дөресе, чын дөресе шул: кешеләр минем «контр булуыма» ышанмаганнар, кешеләр мине ансат кына эштән куып чыгару белән килешмәгәннәр!.. Димәк, мин беткән кеше түгел, мин яшәргә хаклы! Аннары кешеләрнең үзләренчә, үз намуслары кушканча уйлый белүләре дә гаять мөһим, куанычлы бер хәл бит әле... Димәк, дөньяга ышаныч бар, дөнья вакыт-вакыт караңгыланып китсә дә, үзенең туры, якты юлын югалтмаячак!

Шулай уйладым мин бу минутта, шулай кабынып рухландым. Кинәт аяк астымда тигез каты җир тойгандай булдым. Димәк, аякларны нык терәп басып торырга була икән әле! Ахрысы шуңадыр, кызлардан артык төпченеп сорашасым да килмәде — ишеткән кадәресе дә миңа бик җиткән иде. Хәер, кызлар, мин сорашмасам да, бөтен алып килгәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирделәр. Әмин әкәнең болар тирәсендә нидер әйтергә җыенып, ләкин әйтә алмыйча ах-вах килеп йөрүен дә (гомумән исә мишәр абзыйлар бик шым булып калганнар икән), цех начальнигы авыру Иван Васильевичның бүген зур шарфка уранып кына эшкә килүен, ләкин озак тора алмыйча кайтып китүен дә, шуннан соң цехта баш булыбрак Ариф абзыйның калуын да ашык-пошык кына сөйләп уздылар. Миңа бигрәк тә Васильев турында әйткәннәре бик

хикмәтле булып тоелды. Иван Васильевич Ариф абзыйга әйткән, имеш (Сара — аның өйрәнчеге, үзе ишетеп торган): «Мин управляющий Решевскийда да, Перов янында да булдым. Нишләдегез сез? — дип сорадым.— Юлдашев — минем ярдәмчем, мин беләм аның кем икәнен, миннән сорашмыйча аны эшеннән куарга сезнең ни хакыгыз бар? — дидем. Юк. Әллә нәрсә бу! Башбаштаклык!.. Терелеп кенә чыгыйм, бу эшнең төбенә төшәм әле мин»,— дигән... Әйтер, Васильевка ышанам мин, намуслы кеше. Ул инде, һичшиксез, гаделлек ягында булачак. Менә кем белән сөйләшеп карыйсы иде, тик, кызганычка каршы, бик авыру шул, әнә килгәч тә кире кайтып китәргә мәҗбүр булган. Шулай да аның әйткәннәре минем өчен бик әһәмиятле иде.

Кызлар миңа тагын бер көтелмәгән хәбәр әйттеләр: Хафаза бүген эшкә чыкмаган, имеш! Сәбәбен белмиләр. Хәтта миннән: «Ни булды икән аңа, сезнең янга килмәдеме?» — дип тә сорадылар. Бу хәбәр мине ирексездән борчып дулкынландырып куйды, ләкин, күрәм, кызлар безнең арада ни булганын белмиләр, ахрысы. Ничек тә сиздермәскә кирәк иде (андый начар эшне белми торулары яхшырак), шуңа күрә мин аларга, Хафаза, мөгаен, авыргандыр, сез инде аның хәлен белешә күрегез, дип кенә әйттем.

Соңыннан алар миңа шактый читен сорау бирделәр: инде нишләргә уйлыйсыз, Хәбиб абый?

Мин күпме генә уйласам да, әйткәнемчә, нишләргә, кайсы очтан башларга кирәклеген белми идем әле. Дөресрәге, ни генә эшләргә җыенсам да, бу эшнең Хафаза белән бәйләнгән булуы мине бик борчый, аптырата иде. Шуңа күрә кызларга да, менә уйлыйм әле, дип әйтү белән генә чикләндем. Кызлар исә үз нәүбәтләрендә бик кайнарланып, бик ихластан миңа: «Хәбиб абый, болай калдырмагыз, зинһар, райкомга барыгыз, кирәксә, аннан да югарырак җиргә барыгыз, тик үзегезне ничек тә аклагыз!» — дип киңәш бирергә тотындылар. «Рәхмәт, кызлар, рәхмәт, киңәшләрегез өчен!» — дидем мин аларга, ирексездән күңелемнән нечкәреп. Шуннан соң алар, килгәндәге шикелле, сак кына чыгып та киттеләр.

Мин тагын буш бүлмәдә берүзем торып калдым. Ләкин юк, мин хәзер алай ук ялгыз түгел идем инде, минем яныма кешеләр керде, бу караңгы баздан чыгарга алар миңа гүя кулларын суздылар. «Әйе,— дидем мин, ишекле-түрле кызу атлап,— кызлар хаклы, иртәгәдән үк хәрәкәт итә башларга кирәк! Барырга, йөрергә, беркемнән, бернәрсәдән куркып тормаска! Тик бу озын төн тизрәк үтсен дә яңа көн генә тусын!»

## XVII

Һәм ул көн туды. Ләкин нинди көн булып чыкты соң ул?

Алтыдан торып эшкә чабасы булмагач, мин будильникны кичтән борып, йөзтүбән каплап куймаган идем. Ләкин будильник ут капкандай калтыранып чырылдамаса да, мин өйрәнелгән гадәт буенча нәкъ сәгать алтыда күземне ачып җибәрдем. Әмма сикереп торырга ашыкмадым. Халык белән бер вакытта барып, цех ишеге төбендә кешеләрдән аерылып калу минем өчен бик авыр булачак иде, шуңа күрә тар тимер караватымда түшәмгә карап, ялкау гына уйланып ята бирдем.

Шуны әйтергә онытканмын: кичә минем хозяйка Серафима түтәй дә көн буе өйдә булмады,— каядыр Әмәт тавында торучы сеңлесенә киткән иде. Аннан ул бик соң гына кайтты. Һәм бер яктан бу яхшы да булды әле — ичмасам, минем көнозын бүлмәдән чыкмыйча ни хәлдә ятуымны күрмичә калды. Ләкин бүген инде аның бик гаҗәпләнүе мөмкин: «Хәбиб, сезгә ни булды, нигә эшкә бармыйсыз?» — дип, һичшиксез, сораша башлаячак. Ә минем аңа берни дә сиздерәсем килми, аңа гына түгел, үз анама да мин ни булганын хәзер генә әйтә алмас идем... Димәк, болай бүрәнә шикелле сузылып ятарга ярамый, Серафима түтәй торып йөри башлаганчы тиз генә чыгып сызарга кирәк. Аннары кылт итеп исемә Хафаза төште — бүген инде ул эшенә бара торгандыр, юл өстендә булса да аны очратып, күреп калырга кирәк. Һәм, шулай уйлап, кинәт кенә тордым да, ашык-пошык киенеп, битемне дә юып тормыйча, мыштым гына чыгып та киттем.

Мехбазага барырга иртәрәк иде әле. Мин кызу-кызу гына Кольцога төшеп, шуннан Болак буена таба атладым. Болак буендагы өч катлы озын таш йортның ике генә бүлмәле кечерәк бер квартирасында Хафазалар торалар. Ләкин миңа ул квартира эчендә бер генә тапкыр да булырга туры килмәде. Хикмәт шунда, Хафаза абыйсы белән җиңгәсендә тора (моңарчы бу хакта әйтергә ничектер һаман җай чыкмады), ахрысы, шуңадыр, ул мине бервакытта да үзләренә «әйдә, керик» дип чакырмады. Озата килгән саен капка төпләреннән генә аерылып китәргә туры килә иде. Хафаза үзе дә өенә чакыра алмавына уңайсызлана иде шикелле, ләкин мин инде моңа игътибар итмәскә тырыша идем. (Чөнки җитеп килгән кыз өчен абый белән җиңги кулында яшәүнең нәрсә икәнен әзрәк чамалый идем.) Аннары безгә алар өенә кереп утыруның хаҗәте дә юк иде. Бөтен очрашу-сөй-

ләшүләр барысы да минем аулак, тыныч бүлмәмдә бик рәхәт кенә үтә торган иде.

Инде менә бүген мин шушы озын кызыл йорт каршында, Хафазаның чыкканын көтеп, арлы-бирле йөрергә мәҗбүрмен. Мехбазага моннан бик якын, Хафаза әле китеп өлгермәгән булырга тиеш. Хәзер җиде туларга егерме минут — эшенә барып җитәргә аңа биш-алты минут та җитә. Әлбәттә, бу кыска гына вакыт эчендә әллә ни сөйләшеп булмаячак, ләкин аңа бер карау, аның белән очрашырга сүз куешып калу да минем өчен бик мөһим, бик кирәк. Ә вакыт үтә, мин һаман йөренәм, күземне кызыл йортның җимерек капкасыннан бер дә алмыйм диярлек, ләкин ул юк, күренми... Сәгатемә карасам, җиде тулып ун минут киткән — мехбазада эш башланды. Димәк, көтеп йөрүдән мәгънә калмады, йә китеп өлгергән ул, йә бүген дә эшкә бармаска булган. Шулай ук авырый микәнни? Ничек итеп моны белергә?.. Моңарчы алар өендә булмавыма ихтыярсыздан үкенеп тә куйдым. Әгәр абыйсына яки җиңгәсенә бер генә тапкыр күренгән булсам да, менә хәзер мин аларга туп-туры барып керә алыр идем. Хәер, кереп нәрсә эшләргә генә мөмкин? Хафаза аерым бүлмәдә тормый, ә абыйсы яки җиңгәсе алдында сөйләшеп тә, аңлашып та, хәтта очрашырга сүз куешып та булмаячак. Нишләргә соң?.. Ахрысы, Бибинур яки Сара аша записка җибәрергә туры килер. Ләкин алары да эштә бит әле, хәерсез...

...Шактый аптырауга төшеп, тагын бер биш минут чамасы арлы-бирле йөрендем дә кире Кольцога таба киттем. Иң элек каядыр кереп, әзрәк ашап чыгарга кирәк — бер тәүлек бит инде юньләп авызга капкан да юк. Ә анда, Островский урамының башында, бик иртә ачыла торган бер ашханә бар. Эчендә гел пар йөзгән, стеналары һәрвакыт юешләнеп торган бу ашханәгә гадәттә ломовойлар, «барабыз»чылар, толчокчылар, һәртөрле «баш төзәтүчеләр» керәләр, чөнки анда кайчан гына керсәң дә, аракы белән кайнар шулпа була. Менә мин дә шунда кереп, үпкә-бавыр, тозлы кыяр турап пешергән бер ташаяк кайнар «рассольникны» аракысыз гына әйбәтләп ашап чыктым. Кәеф бердән яхшырып киткәндәй булды. Кем әйтмешли, ашау бөек нәрсә ул — бигрәк тә бер тәүлек «уразадан» соң... Шул үпкә-бавыр җылысы белән мин җиңел генә мехбазага таба атладым.

Хуш, ә нәрсә өчен барам соң әле мин анда? Приказ чыккан, цехка кертмиләр, сөйләшеп аңлашыр кеше дә юк. Ләкин бармыйча да булмый, барырга кирәк. Мехбазадан кендек бөтенләй өзелеп бетмәгән ич әле. Эшләгән

көннәр өчен акча аласым бар, аннары килеп, әлеге шул әшәке приказның күчермәсен дә алырга кирәктер инде —үз хакымны яулап кая гына барсам да, аны миннән сораячаклар бит. Кыскасы, ул миңа хәрәкәт итә башлар өчен кирәк булачак. Янә килеп, теге кызларның берәрсен цехтан ничек тә чакыртып чыгарасы иде. Үзем, билгеле, цехка керә алмам, ләкин конторада утырган Мостафа дустан сорасам, ул йә Сараны, йә Бибинурны чакырып төшәр дип ышанам. Курыкмаса, аңа моны эшләү берни түгел.

Менә шундый исәпләр корып, мин мехбаза конторасына барып кердем. Керүемә — кем белән диегез! — партоешма секретаре Перовның үзе белән күзгә-күз очраштым. Һич көтелмәгәндә килеп чыкты бу, һәм мин бер мәлгә каушабрак та калдым: исәнләшергәме-юкмы? Ләкин шул арада Перов үзе минем белән исәнләште:

— Саумысыз, Юлдашев?

— Саумысыз! — дидем мин дә.

Ул җәһәт кенә миңа сынаулы караш ташлап алды:

— Килдегез?

— Килдем,— дидем мин.

Шуннан соң ул, аз гына дәшми торып, ни өчендер тирә-ягына каранып алды да тавышын әкренәйтә төшеп:

— Минем янга керегез әле,— диде һәм, минем җавапны да көтмичә, кызу гына алдан китеп тә барды.

Болар барысы да бик тиз булды, барысы да бик сәер тоелды, ләкин шулай да аңардан азрак кала биреп (нигәдер шулай кирәктер кебек иде), артыннан иярдем.

Аның кечкенә бүлмәсе коридор очында ук иде. Барышлый, буеннан-буена киң генә барьер сузылган зур бухгалтерия бүлмәсен узарга туры килде. Барьер эчендә кара күзлекле баш бухгалтер Глеб Ефимович, аның ике ярдәмчесе, тагын күп кенә хисапчы кызлар утыралар. Шулар арасында дус егет Мостафа да утыра. Минем узганны күбесе шәйләми дә калдылар, ләкин Мостафа күреп алды булса кирәк. Ул кинәт кенә башын күтәрде, болай да зур күзләре тагын да ныграк ачыла төште, һәм йөзенә гаҗәпләнү катыш куркумы, кызганумы чыккан төсле булды. Мин, туктalып тормыйча, аңа баш кына кагып уздым.

Перов кечкенә бүлмәсендә мине көтеп утыра иде инде. Миңа да якынрак килеп утырырга кушты. Менә без икәүдән-икәү генә, ләкин сүзне ул да, мин дә башлап китә алмыйча торабыз. Мин, әлбәттә, аңардан көтәм — ул чакырды, ул башларга тиеш. Һәм нәрсә әйтмәкче була ул миңа хәзер?..

Аның йөзендә мин усал кырыслык яки мине ачыктан-

ачык өнәмәү кебек нәрсәне күрмим күрүен, ләкин ул нигәдер тынычсызлана, миңа туры карамаска тырыша, алдында яткан кәгазьләрне дә анда-монда этәргәли. Шактый сәер иде бу. Ахырда сүз башлар өчен генә булса кирәк:

— Йә, ничек соң? — дип, кисәк кенә сорап куйды.

Мин бу билгесез сорауга каршы бары иңбашымны гына җыергандай иттем. Хәер, ул минем җавапны көтеп тә тормады, үзенең шул тынычсызлануын әйтергә ашыккандай, тагын:

— Да, шактый ямьсез эш килеп чыкты,— дип куйды.— Үзең гаепле, егет!

— Нәрсәдә соң минем гаебем? — дидем мин.

— Аны нигә миннән сорыйсың?.. Синең гаеп, син белергә дә тиешсең.

— Юк, белмим шул,— дидем мин, башымны селкеп.— Менә ике тәүлек инде бертуктаусыз уйлыйм, иптәш Перов, ләкин һич кенә дә белә алмыйм.

— Кызганыч!

— Миңа «кулак агенты» дигән гаеп... тактылар. Әмма ләкин бу гаепне мин ассагыз-киссәгез дә өстемә ала алмыйм, иптәш Перов! Моңа бит берәү дә ышанмый иде.

— Анысына мин дә ышанмыйм,— диде Перов, кулын селтәп.— Чепуха бу!

Мин авызымны ачкан килеш каттым да калдым. Нәрсә ишетәм мин?.. «Ышанмыйм» диде! Минем «кулак агенты» булуыма ул, Перов, ышанмыйм, диде. Чынмы бу?.. Дөрес, ул моны уйлап тормыйча, кызулык белән әйтеп ташлады, әмма чынын әйтте, һичшиксез, чынын әйтте! Хәтта «чепуха бу» дип тә ычкындырды. Димәк, мин аның карашында бүген дә, кичә дә, җыелыш вакытында да андый әшәке кеше булып саналмаганмын икән ләбаса! Бу минем өчен гаҗәеп бер ачыш, әмма бөтенләй үк көтелмәгән ачыш түгел... Әлбәттә, ул минем «кулак агенты» булуыма ышанмаска тиеш, бернинди нигезе юк аның ышанырга! Ләкин ул чагында ни өчен соң...

Перов минем умарта күчедәй кинәт котырып киткән уйларымны тизрәк бүлде. Ул саксызрак әйтеп ташлаган сүзләренең миндә ниләр кузгатканын сизенде булса кирәк, куе кашларын җыерып:

— Ләкин сезнең гаебегез бар, Хәбиб иптәш,— диде,— зур гаебегез бар. Моны инкарь итеп маташу сезгә бары зарар гына итәчәк.

— Нидән гыйбарәт соң минем гаебем, Федор Николаевич? Әйтегез, зинһар, әгәр дөрес икән, мин һич инкарь итеп тормаячакмын.

— Сез бит надан кеше түгел, рабфак бетергән егет, хәзерге

ситуацияне үзегез дә аңларга тиешсез. Авылда кискен сыйнфый көрәш бара, кулак калдыклары, кулак иярченнәре бөтен көчләре белән колхоз эшенә аяк чалырга, халыкны колхоздан биздерергә, куркытырга тырышалар... Ә сез шундый чакта авылыгыздан кайткансыз да монда «крестьяннарны колхозга көчләп кертәләр» дип сөйләгәнсез! Йә, бу дошман тегерменәнә су кою түгелме? Мондый сүзләр өчен хәзер баштан сыйпамыйлар, иптәш Юлдашев!

Миңа ничек тә тыныч булырга кирәк иде, ничек тә чын дөресен генә аңлата белергә кирәк иде — беләм, бу сөйләшү гаять мөһим минем өчен, яңадан кабатланмас та ул.

— Федор Николаевич,— дидем мин, сабыр гына,— сез мине яхшылап тыңлагыз әле... Иң әлек шуны әйтәсем килә: мин авылдан кайткач, беркемгә дә «крестьяннарны колхозга көчләп кертәләр» дип сөйләп йөрмәдем. Бу дөрес түгел. Мин авылда күргән, ишеткәннәремне бары берәү, иң якын кешемә генә сөйләдем. Сез аны беләсез.

— Берәүгә әйтү дә җитә, шуннан тарала ул.

— Ләкин бит минем аңа ниләр сөйләгәнемне сез тәгаен генә белмисез. Сүзне бит аны төрлечә бозып, төрлечә җиткереп була. Шундый зур мәсьәлә кузгалгач, сез башта минем үземне чакырып сорашырга тиеш идегез.

Бу соңгы сүзләрем Перовка бер дә ошамады булса кирәк, аның йөзе кинәт караңгыланып китте.

— Сезнең мәсьәлә инде каралган, беткән, давай без аңа яңадан кайтып тормыйк,— диде ул, кырыс кына.— Сез приказны укыдыгызмы?

— Юк әле, ләкин ишеттем.

— Приказ сезне эштән азат итү турында.

— Беләм.

— Шулай булгач, бәхәсләшеп торырга соң инде. Сезгә үз хәлегез турында уйларга кирәк.

Перовның сүзне болай кинәт кенә икенчегә борып, очлап куюы мине бик нык аптыраште калдырды. Мин әле әйтергә теләгәнемнең чиреген дә әйтә алмадым. Приказ чыккан, эш беткән булса да, минем бу юлы олы яшьтәге абзыйга, коллективның рәсми кешесенә, үземнең гаепсез булуымны бик тә аңлатасым килгән иде. Ә аның бу хакта тыңлыйсы да килми... Алайса, ни өчен ул мине чакырып кертте, борчылып сүз башлады? Максаты нәрсәдә? Менә шундый аптырауга төшеп, мин күпмедер вакыт сүзсез калып утырдым. Перов та, нидер көткән кебек, үзенекен әйтергә ашыкмый иде.

Ахырда мин, уйлап түгел, ә гаҗизлектән генә сорап куйдым:

— Нишлим соң мин? Нәрсә эшләргә кушасыз?

— Менә күптән сүзне шуңардан башларга кирәк иде,—диде Перов, җиңелчә бер сулагандай итеп.— Мин бит сезнең хәлегезне аңлыйм. Сез яшь кеше, сезнең киләчәк көнегез бар, бу хакта уйламыйча булмый... Кыскасы, минем сезгә кешеләрчә ярдәм итәсем килгән иде, әгәр кадерен белсәгез... Тик бу ике арада гына калырга тиеш. Инде ничек итеп сезнең положениене төзәтергә мөмкин? Моның өчен бер генә юл бар: сез партоешма исеменә гариза язарга тиешсез.

— Нинди гариза?

— Әйтеп беткәнне көтегез... Сез үзегезнең гаризагызда яшьлегем һәм политик сизгерлегем җитмәү аркасында зур ялгышлык эшләдем, гаебемне өстемә алам, киләчәктә төзәлергә һәм эшем белән моны исбат итәргә сүз бирәм, тик мине коллективтан аермагыз, өйрәнчек итеп булса да, калдырырга, дип язысыз... Ә мин управляющий белән сөйләшермен, бәлки, приказны үзгәртеп тә булыр. Аңладыгызмы?

Шунда ук күңелгә шик килде: аның бу тәкъдиме дә алдан ук уйланмаган микән? Һәм мин ирексездән сорамыйча булдыра алмадым:

— Димәк, сез миңа гариза язып, тәүбә итәргә кушасыз инде?

— Тәүбәме бу, үтенечме — анысын теләсәгез ничек дип атагыз. Ләкин сезнең бүтән чарагыз юк. Иелгән башны кылыч кисми, шуны белегез!

— Федор Николаевич,— дидем мин, ничек тә сак булырга тырышып,— ә шулай да нинди гаепне мин өстемә алырга тиешмен? Җыелышта миңа «кулак агенты», «кулак коткысын таратучы» дигән гаеп тактылар, ләкин бу гаепкә сез үзегез дә ышанмыйсыз ич!..

— Һай, Аллам! — диде Перов, бик ачынып.— Мәсьәлә андамыни? Сезне эштән куалар, аңлыйсызмы? Ә мин сезгә шуңардан котылуның бердәнбер юлын өйрәтеп утырам. Кулак агенты булсагыз, мин моны эшләр идеммени?!

— Анысы өчен рәхмәт сезгә, Федор Николаевич,— дидем мин, аска карап кына.— Тик... тик нинди генә гаепне өстемә алыйм икән соң?

— Аптырыйм, укыган кеше ләбаса сез! Неужели, гариза да яза белмисез? «Мин кулак агенты идем» дип язу һич тә шарт түгел бит. Аңламыйча, белмичә сөйләгәнмен дип язсагыз да җитә бит.

— Ләкин... сөйләгәнем дә юк ич!

— Минем сүзем бетте,— диде Перов, шактый кискендорфа итеп, һәм алдында яткан кәгазьләрен ачу белән тагын күчергәли башлады.

Әлбәттә, минем соңгы сүзем артык иде, эшне генә боза торган сүз иде. Ычкынды, хәерсез! Тезләремә таянып азрак уйланып утырдым, аннары, таш астыннан чыккандай, акрын гына кузгалдым.

— Рәхмәт, мин уйлармын,— дидем, берсүзсез чыгып китүне килештермичә.

Ләкин Перов дәшмәде.

## XVIII

Мин Перов бүлмәсеннән генә түгел, мехбазадан ук чыгып киттем. Хәзергә эш калмады монда... Каядыр читкәрәк китәргә кирәк. Берәр аулак урынга барып, бу ишеткәннәрне ничектер сеңдерергә кирәктер инде. Ләкин, кая барасымны ачык кына белмичә, башта мин Бауман буйлап киттем, аннан ни өчендер Болакка таба борылдым, аны да узып, Печән базарына барып чыктым. Базар, әлбәттә, мин эзләгән урын түгел, аның таш кибетләре, тыз-быз чапкан кешеләре арасыннан тизрәк үтеп, Кабан күленә таба киттем. Күл буенда хөрти генә бер бакча кисәге бар, шуңа җитеп, чокыр-чакырлы юлыннан эчкәрәк уздым да арты каерылган бер эскәмиягә, ниһаять, килеп утырдым. Көн гаҗәеп җылы, кояшлы — язны камчылап ашыктыра торган көннәрнең берсе. Ярдан котырып шарлавыклар ага, күлнең читләренә тоташ су җәелгән, тик ярдан ярга сузылган чана юлы гына сары сыртын кабартып, ярылып ята... Каршы яктагы икешәр катлы иске агач йортларның тәрәзәләре әйтерсең утта яна... Шулардан уңдарак, нурлы аяз күккә сузылган кара бармактай, «Спартак» фабрикасының нечкә тимер трубасы күренеп тора.

Ләкин бу күренешләр ничектер күңелгә кермичә, күзләремнән генә чагылып узды — уйларым минем бөтенләй башкача иде. Бер дә көтелмәгән ситуация туды бит әле. Миңа ансат кына эшне җайларга була икән ләбаса! Кайларгадыр, кемнәргәдер барып йөрүнең кирәге дә юк, имеш. Шул ук мехбазага гариза гына язып илтәсе — һәм эш җайланачак. Әмма бу хәл мине ни өчендер бер дә куандырмый. Киресенчә, ул мине борчый, бик нык борчый. Иң элек Перовның миңа «изгелек» күрсәтергә теләвенең сәбәпләрен һич аңлый алмыйм. Башта батыра, аннары тартып чыгармакчы була — ни өчен? Изгелекме бу, әллә берәр төрле мәкерлекме? Ягъни миннән «гаеплемен» дигән сүзне әйттереп, мине чын-чынлап гаепле итеп калдыруымы, яки инде хәлемә кергән булып, мине тәмам үз кулына алырга тырышуымы? Болар бит икесе дә, яше-

рен тозак шикелле, минем өчен гаять куркыныч! Эләгә калсаң, ничек итеп ычкынырга да белмәссең!.. Әмма шул ук вакытта ул бит әле минем гаепле булуыма ышанмыйм да диде. Алайса ни өчен бу мәче белән тычкан уены? Максаты нәрсәдә?.. Ничек кенә аңларга соң хөрмәтле секретарьның мондый икейөзле гамәлен?! Белмим, белмим, ни дип әйтергә дә белмим, егетләр?

Ярый, бик тирәнгә кермик әле, калдырып торыйк, болай да башка төшкән йөк бик авыр. Менә минем алга бик конкрет мәсьәлә куелды, шул хакта тыныч, сабыр гына уйларга кирәк... Хуш, мин нишләргә тиешмен? Хөрмәтле Перов иптәш миңа ярдәм кулын сузмакчы, тик бер генә шарты бар: мин тәүбә итәргә тиешмен. Нәрсәдән? Миңа тагылган ялган гаептән: булмаганны булды дип, мин чынлап та ялгышканмын дип, инде, зинһар, кичерә күрегез дип, баш иеп кичерү сорарга тиешмен. Әгәр шулай итсәм, ягъни үземне гаепсез санаган хәлдә, өстемә нindидер гаеп алсам, алар мине кичерәчәкләр. Бүре билеты тоттырып эштән чыгарып җибәрмәячәкләр. Ләкин юк гаепне өскә алып тәүбә итү — бу да икейөзлелек күрсәтү була түгелме соң? Бу да алдашу юлына басу, тиреңне саклау өчен намусыңны көчләү — йә, шуннан соң мин кем булып калам? Типкән итекне ялаучы вак җан — шулай түгелме?! Әмма типкән итекне эт тә яламый лабаса!

Хәер, нигә мин бу кадәр әшәке итеп уйлыйм әле? Әгәр юк гаепне өстемә алып, тәүбә итсәм, кешеләр моңа ышаначаклар бит. Минем икейөзлеләнеп, бары тиремне саклау өчен генә үз-үземә яла ягуымны белмәячәкләр. Хәтта мактап: «Кара, ялгышуын әйтеп бирүдән курыкмады, молодец, честный егет икән»,— диячәкләр... Ә инде үз вөҗданыма килгәндә, аны да тынычландырып, юатып булачак: мәҗбүр иттеләр, дисең, минем урында һәркем шулай эшләр иде, дисең, дөньяда торырга кирәк ләбаса, дисең. Хәйләсез — дөнья файдасыз, диләр ич «акыллы» кешеләр. Аның каравы, син акылга утыртылган тәти егет булып каласың, түбәнлек, икейөзлелек, ялагайлык бер дә начар нәрсә түгел икән дип, мыштым гына яши бирәсең!

Ходаем, ниләр уйлыйм мин? Гүя ургылып аккан елга уртасыннан чыгар өчен, әле бер ярга, әле икенче ярга ташланам. Болай булмый бит, болай ярамый, ике ярның берсенә чыгарга кирәк. Яки — яки!.. Гамлет шикелле озак баш ватарга минем вакытым да, мөмкинлегем дә юк. Датский принц түгел мин — эшсез бер генә көн дә яши алмыйм. Димәк, яки расчет алырга да, бүре билетын тотып, каядыр чыгып олагырга! Яки инде, Перов киңәшен тыңлап, баш иеп карарга, шулай итеп кара

мөһердән котылырга — чәнчелеп китсен! Күңел каралса да, исемем «чиста» калыр... Сайларга, сайларга... әмма ләкин кайсын сайларга? Әйтегез инде, әйтегез, туганнар! Мине белүчеләр, мине аңлаучылар, миңа ышанучылар!..

Әйе, мин кемнеңдер акыллы, дөрес сүзенә мохтаҗмын, бик мохтаҗмын. Ни әйтсә дә әйтсен, тик айнык сүзен әйтсен! Кем белә, бәлки, мин аңардан иң кирәкле киңәшне ишетермен. Ләкин кемгә, кем алдына бу газаплы аптыравымны күтәреп барырга?.. Иң яхшысы — Вафага, Вафа дуска! Вафа — коммунист. Ул минем белән дусларча ачык сөйләшүдән курыкмаячак. Куркырга тиеш түгел.

Урынымнан тордым — торгач кына аякларымның юеш карда нык кына өшегәнен сиздем. Аксабрак булса да, ашыга-ашыга бакчадан чыгып киттем. Хәер, ашыгудан бер мәгънә дә юк иде. Вафа эштә, ә эш бетәргә вакыт бик күп әле. Көнне ничектер үткәрергә кирәк. Кая барырга, нишләргә?.. Татарстан чатында тукталып, үткән-сүткәннәргә, пычрак карны чәчрәтеп чапкан машиналарга, атларга карап тора башладым. Барысы да уза минем яннан, барысының да ниндидер эше, мәшәкате, теләге-максаты бар... Бер генә минут та тик тору мөмкин түгел — ташка әйләнерсең!.. Кузгалырга кирәк. Иң элек җылы бер урынга кереп утырасым килде. Мәскәү урамына узып, «Сарай» номерлары астындагы ашханәгә барып кердем. Халык күп иде, шулай да түрдәрәк бер буш өстәл табып, шуңа барып утырдым. Половойлар, өстәлләр арасыннан юргалап, кара поднос белән чуар чәйнекләрдә чәй ташыйлар. Мин дә шуларның берсеннән ике шешә сыра китерттем. Монда торганы авыл агайлары диярлек, чөнки күршедә генә алар төшә торган крестьян йорты. Туннарын салмыйча, бары бүрекләрен генә салып һәм тирләгән муеннарын сузып, тәлинкәдән шөбер-шөбер чәй эчәләр... Минем ашыгыр җирем юк, сыраны әз-мәз генә йотымлап, шуларга карап утырам. Кемнәр алар — колхозчылармы, единоличниклармы — белмим, ләкин эчемнән генә үзләренә әйтәсем килә: «Менә, эт талаган нәрсәләр, сезнең аркада без фәкыйрегезне утлы табага бастырдылар бит әле... Сез шуны күрмисез дә, сизмисез дә, бары мышнап чәй чүмерүегезне генә беләсез. Хәер, белсәгез дә яклап бер сүз дә әйтмәс идегез, берни төшенмәгән аңгыралар булып кыланыр идегез. Хәйләкәр төлкеләр сез!..» Әйе, мужик — бик катлаулы, бик четерекле җан иясе. Кем әйтмешли, сукранмыйча җәннәткә дә кермәс ул.

Сыра эчкәч, ашыйсы да килеп китте. Токмач белән кәтлит заказать иттем. Чын булса, нервлары кузгалган кеше-

нең аппетиты бик яман ачылып китә, имеш. Акча барында бу әллә ни куркыныч түгел түгелен. Ярый, токмач белән макаронлы кәтлитне дә ялт иттереп куйдык. Инде моннан кузгалырга да вакыттыр — әдәп дигән нәрсә бар.

Урамга чыккач, тагын шул ук мәсьәлә: кая барырга? Вафаның эше дүрттә бетә, ә хәзер вакыт икенче ярты гына әле. Ләкин кая таба булса да атларга кирәк. Киттем. Атлый торгач, «Чаткы» киносына барып чыктым. Гарри Пил катнашы белән ниндидер Америка картинасы бара икән, сеанс та башланырга гына тора — мин тоттым да, билет алып, шуңа кереп утырдым. Ике сәгать вакытны үткәрергә ярап куйды бу... Аннары торганы атышлар, куышлар, биек-биек йортларның берсеннән икенчесенә сикерүләр белән тулы картинаны карап утыру җанга әзрәк ял да биргән кебек булды.

Кинодан чыккач та, мин туры Вафага киттем. Ул шушы Тукай урамында — моннан ерак түгел бер ялгыз карчыкта тора. Әле кайтып җитмәгән булырга тиеш. Мин өенә кермичә, урамда әрле-бирле йөренеп, көтәргә булдым.

Тукай урамында татар кызлары күп очрый, ара-тирә бик чибәрләре дә килеп чыккалый... Нишлисең, яшьлек бит, баш түбәсеннән хәсрәт сөреме бөркелеп торса да, мин шул чибәрләргә кызыксынып карамыйча булдыра алмыйм. Күңелгә сәер уй килә: кешегә, бәлки, нәкъ менә бик авыр хәсрәтле чагында хатын-кыз иркәләве аеруча кирәктер дә. Бәлки, җан сөйгәненең шифалы кочагында ул барысын да онытa, тынычлана алыр иде. Һай, тиле күңел!.. Нәкъ менә шундый кочакта аны җылан чакканын да онытырга әзер...

Әнә Пеләтән ягыннан эре-эре атлап, кулларын селкә-селкә кайтып килгән Вафа да күренде: мин, йөрүдән туктап, аны көтеп алдым. Килеп җиткәч, Вафа минем белән кул биреп күреште. Бернинди гаҗәпләнү-сәерсенү сиздермәде, гүя бу очрашуны ул алдан ук белеп кайткан. (Мондый чакта дус кешенең әз генә читенсенүе дә минем өчен, билгеле, авыр булыр иде.)

— Күптәнме? — диде Вафа, борчылгандай.

— Юк, күптән түгел,— дидем мин.

— Әйдә керик алайса! — диде ул, гади генә.

Без кечкенә кухняны узып, зал сыман иркен генә бер бүлмәгә кердек. Урамга караган ике тәрәзә, тәрәзә төпләрендә гөлләр, стенада ике рәсем: берсе — Ай-Суфия мәчетенең күренеше (карчыкныкы булырга тиеш), икенчесе Ленин портреты (монысын, билгеле, Вафа элгәндер); уң кулда карсак кына шкаф, уртада чуклы эскәтер япкан түгәрәк өстәл, ә тәрәзәләргә каршы стена буенда ак шарлы киң генә карават; бер сүз белән әйткәндә, Иске бистәнең

урта кул татар бүлмәсе. Әйткәнемчә, Вафа ялгыз карчыкта тора, карчык үзе кухня белән янәшә караңгы бүлмәдә ята икән, ә монда Вафа үзе генә хуҗа. Аннары Казан карчыкларының бер шәп гадәтләре бар — алар өй саклап утырырга яратмыйлар. Ходай бирмеш көн алар, ниндидер үзләре генә белгән сылтау табып, кемгә дә булса бармыйча, кемнең дә булса чәен эчеп кайтмыйча калмыйлар. Вафаның да карчыгы нәкъ шулай икән — биләмгә чыкмыйча бер генә көнне дә уздырмый, имеш. Икесенә ике ачкыч эшләтеп алганнар, һәркайсы үзе теләгән вакытта кайтып-китеп йөри... Вафадан минем: «Карчыкның сине болай ташлап йөрүе уңайсыз түгелме соң?» дип сораганым да бар. «Һи, буйдак егет өчен, киресенчә, бик уңай инде ул!» дип көлә генә Вафа... Кыскасы, карчыктан да, торган җиреннән дә бик канәгать булса кирәк.

Бүлмәгә кергәч тә, Вафа миңа:

— Син утырып тор, менә газеталар караштыр, ә мин өстемне генә алыштырып алыйм,— диде һәм чөйдән чиста күлмәген, чалбарын, караватастыннан йомшак чүәкләрен алып, кухняга чыгып китте. Мин беләм, Вафа — тәртип, пөхтәлек ярата торган егет. Эштән кайткач та, һичнигә карамыйча, иң элек юынып, өстен алыштыру — бу аның көндәлек кагыйдәсе. Кем генә килсә дә, ул аны бозачак түгел. Сабыр гына көтәргә кирәк.

Бүгенге «Красная Татария» газетасын хәвефләнебрәк кулыма алдым. Газета битләрендә хәзер һәртөрле «фаш итүләргә» күп урын бирелә. Әгәр шуннан минем хакта да берәр фельетон-мазар язылган булса, нишләрсең?! Баш очыңа казык сугып кую белән бер булыр иде бу, әкәмәт! Ярый, шөкер, андый-мондый хәтәр нәрсә юк икән әле. Газета игътибарын җәлеп итәрлек дәрәҗәгә үсмәгәнбез әле без — моның өчен аңа үпкәләп булмый, билгеле.

Вафа юеш чәчен артка тарый-тарый килеп керде. Озынча зур бите алсуланып киткән, өстендә ап-ак күлмәк белән шәп үтүкләнгән кара чалбар, билен тар каеш белән кысып буган — егеткә карап торуы күңелле!

Кергәч тә ул, миңа кәефләнеп:

— Ә хәзер без, дус кеше, синең белән аристократларча гына каһвә эчеп җибәрик,— диде.— Дәрт кереп китсен!

Аның болай минем хәлемне белмәгәндәй, шаяруга бирелеп, ваемсыз, җиңел генә сөйләнүе, бер яктан, әйбәт тә кебек — ничектер мине дә тынычланырга, онытылырга мәҗбүр итә. Әмма, икенче яктан, минем өчен бик үк уңай да түгел шикелле, чөнки алда гаять җитди сөйләшү тора. Фикерне таратмыйча, йомшартмыйча гына дигәндәй, аны ничектер башларга кирәк.

Ә Вафа үз эшендә. Менә ул пыяла шкафтан ике стакан, шикәр савытын, кофе тартмасын алып өстәлгә куйды. Аннары кухняга чыгып, бераздан чәйнек белән яңа гына кайнаган су һәм саплы кастрюль белән кайнар сөт алып керде. Шуннан миңа да, үзенә дә сөтне, шикәрне мул салып, нык кына болгатып, хуш исле кофе ясап куйды. Шуны әйтергә кирәк, чын кофе ул — хәзер бер җирдә дә табылмый торган нәрсә. Ә менә Вафада бар. Күрәсең, Ленинградтагы туганнары аңа җибәрә торганнардыр.

Кайнар кофены без әз-әзләп кенә эчәбез. Чынлап та, бик тәмле нәрсә. Арпа кофесын күп эчкәнем бар, ләкин моны, каяндыр эссе иллә рдән килгәнен, хәтерләмим дә.

Мин Вафадан сүз көтәм. Ни булса да сорарга тиеш бит ул. Сорамаса, әллә ничек бик сәер булыр иде. Мин дә сүзне ничек итеп башларга белмәс идем...

Юк, сорады. Гади генә итеп:

— Бүген эшкә чыкмадыңмы? — диде.

— Юк,— дидем мин.— Приказ бар бит.

— Күрдем. Безгә дә килгән иде.

— Ә минем күргәнем юк әле. Ишеттем генә. Ничегрәк язганнар?

— Ничегрәкме? — диде Вафа, кофесын ашыкмыйча гына болгатып.— Шактый хәйләкәр: «Ачык партия җыелышының соравын искә алып, фәлановны эшеннән азат итәргә»,— диелгән.

— Начармы бу?

— Ничек, дим. Беренче карашка начар да түгел кебек. Һәрхәлдә, приказның үзендә сиңа конкрет гаеп такмаганнар. Ләкин ул приказны кая гына илтеп күрсәтсәң дә, безнең мехбазадан синең хакта кем ул, ни өчен чыгарылды дип сораячаклар. Конверт эчендә җавап барачак. Ә аның эчендә нәрсә язылганын син үзең дә белергә тиешсең.

— Кулак агенты, колхозга каршы коткы таратучы — шулаймы?

Вафа уңайсызланыбрак елмайды.

— Җыелышта сөйләүчеләрнең әйтүенә караганда, шулайрак килеп чыга.

— Ә син шуңа ышанасыңмы? — дидем мин, туп-туры аның күзләренә карап.

— Нигә алай дип сорыйсың? — диде Вафа, кинәт җитдиләнеп.— Мин бит җыелышта үз сүземне әйттем инде... Без хәзер сиңа бүтәннәр таккан һәм җыелыш карарына кергән гаепләү турында сөйләшеп утырабыз.

— Кичерә күр, Вафа, мин кызулык белән генә... Ләкин ул «бүтәннәр» минем андый начар кеше булуымны кайдан беләләр?

— Юк, син, дус кеше, аны миннән сорама инде. Мин кайдан белим? Миңа синең бер сүз дә әйткәнең юк бит. Бәлки, башка берәр кешегә нинди дә булса ярамаганрак сүз әйткәнсеңдер! Яшермә!

— Вафа, синнән яшерер бер нәрсәм дә юк минем,— дидем мин, бөтен ихласым белән.— Ышан, дус!

— Ышанам!

— Син беләсең, минем бердәнбер яраткан, ышанган кешем ул — Хафаза иде. Менә Япанчыдан кайткач, мин аңа авылдан күргән-ишеткәннәремне сөйләдем.— Бары шул гына... Бүтән бер кешегә берни әйткәнем булмады.

— Син инде, Хәбиб дус, миңа да, Хафаза туташка сөйләгәнчә, тулырак итеп сөйләле! Нәрсә ул «күргән-ишеткәннәрең?» — диде Вафа, елмая биреп.

— Пажалыста! — дидем мин һәм Япанчы агайларының миңа килеп зарлануларын, шул хакта колхоз председателе Хәйрүш абзый белән шактый кискен сөйләшергә туры килүен, соңыннан шуның өчен борчылуымны аңа нәкъ булганча, ләкин озынга да сузмыйча, сөйләп чыктым. Тик ахырдан өстәдем: — Менә, ышансаң, нәкъ Хафаза туташка сөйләгәнчә!

— Аңлашыла! Хуш, ә ул нәрсә диде инде?

— Хафазамы? Нәрсә әйтсен. Гадәтенчә, минем һәр сүзем белән килешеп барды. Авыл хәлләрен белми дә ул, аннары үзенчә фикер йөртерлек чамасы да юк аның. Ә менә җиткерә белгән.

— Ул дисеңме?

— Бары ул гына. Дөрес, үзе башлап барып сөйләмәгәндер, монысына ышанмыйм. Сүзне аңардан әкренләп алганнар, һәм кем алганын да беләм, ләкин барыбер мин Хафазаның бу эшен каберемдә дә онытачак түгелмен! Бигрәк тә шуны миңа әйтмәвен кичерә алмыйм.

— Син кызма,— диде Вафа, тыныч кына.— Сиңа кызарга ярамый. Кая, тагын берне ясыйм.— Ул стаканга яңадан кофе ясый башлады.— Хафазаны син алай бик каһәрләп ташлама, интрига корбаны ул, әллә аның үзенә җиңелдер дип беләсеңме? Ничек кенә булмасын, ул сине ярата йөргән кыз бит.

— Менә шуңа күрә дә гафу итеп булмый аны.

— Ашыгыбрак сөйлисең әле, дус кеше, ашыгыбрак! Ярый, Хафаза мәсьәләсен калдырып торыйк. Инде үзең нәрсә эшләргә уйлыйсың?

— Менә шул хакта киңәшергә дип сиңа килдем дә, Вафа! Бүген мин Перов белән сөйләштем. Дөресрәге, ул мине бүлмәсенә чакырып сүз башлады.

— Йә, шуннан?

— Иң элек мин аңардан шуны ишеттем: ул минем кулакларны яклаучы, колхозга каршы коткы таратучы кеше булуыма үзе дә ышанмый икән... Аңлыйсыңмы, Вафа, үзе дә ышанмый!

Әмма, ни гаҗәп, Вафаның моңа һич тә исе китмәде. Бары «аңлыйм» дип кенә куйды.

— Юк, син, Вафа, чынлабрак уйла әле, нәрсә килеп чыга соң? — дидем мин, яңадан кайнарлана башлап.—Димәк, ул миңа үзе дә ышанмаган гаепне таккан, мине нахакка политик җинаятьче ясап, эштән кудырган — шулай түгелме?! Син менә шуны миңа аңлатып бир!

— Кеше өчен җавап бирүне бер дә яратмыйм, Хәбиб! — диде Вафа.— Ләкин Перов сүзләрен җиңел аңлап була, минемчә... Просто сиңа ул кадәр зур политик гаеп тагар өчен аның дәлилләре җитәрлек түгел, нигезе юк, ничек ышансын?

— Алай булгач...

— ...Нигә эштән кудылар дисең инде? Моның да сәбәбе ачык: «фаш итү» шаукымына бирелеп, алар таякны катырак бөгеп ташладылар. Бары шул гына.

— Бары шул гына!.. Әйтерсең сүз тәкә башы турында бара!

— Юк, сүз тәкә башы турында бармый,— диде Вафа, җитди генә.— Югыйсә Перов синең кулыңа шундый козырь тоттырыр иде микән?! Монда ниндидер сер бар. Давай, син дәвамын сөйлә, аның әйткәннәре кереш кенә булгандыр — шулайрак сизәм.

— Дөрес сизәсең... Ул миңа «изгелек» эшләмәкче була.

— Ничек итеп?

Әгәр мин гаебемне өстемә алып, кичерү сорап, партоешма исеменә гариза язсам, ул мине эштә калдырырга вәгъдә итә.

— Так, так! Нинди гаепне өстеңә алырга куша инде ул?

— Ну, янәсе, мин политик сизгерлегем җитмәү аркасында нәрсәнедер аңлап бетермәгәнмен, ниндидер хата фикерләр әйткәнмен — менә шулайрак. Кыскасы, ул минем үземә белеп язарга куша.

— Менә хәзер мәсьәлә ачыкланды инде, Хәбиб дус! — диде Вафа, урыныннан торып.— Перов сиңа килешер өчен кулын суза, аңлыйсыңмы? Әгәр ул синең чынлап та кулак иярчене, колхозга каршы кеше булуыңа ышанса яки шуны исбат итәрлек дәлилләре кулында булса, ул моны эшләмәс иде, әлбәттә. Хафаза сүзләре генә җитми моның өчен, син аларны һәрвакытта кире кага аласың. Ләкин хикмәт анда гына түгел. Алар ботканы пешерделәр пешерүен, әмма ашаучы юк, ягъни коллективны синең шундый начар кеше

булуыңа ышандыра алмадылар. Ә бу партоешма секретаре өчен мактаулы эш түгел. Менә хикмәт нәрсәдә. Хәзер ул үзенең позициясен ничектер ныгытырга тиеш — менә ни өчен аңа синең гаризаң кирәк. Аңлыйсыңмы?

— Ләкин бит мин аның кулына андый гариза язып бирмәячәкмен.

— Тукта, ашыкма. Бусы икенче мәсьәлә.

— Ничек икенче мәсьәлә? — дидем мин, бик гаҗәпләнеп.— Перовның гамәлен аклар өчен мин үз-үземә яла ягыймммы?! Бу бит акылга сыя торган эш түгел.

— Сабыр, сабыр!..

— Җитмәсә әле, кулыңнан алдап гаризаңны алырлар да барыбер эштән дә куарлар. Ышан син аларга!..

— Юк, кумаслар. Перов сүзендә торыр. Торырга тиеш. Аның өчен сине чыгарып җибәрмәү файдалырак — инцидент шуның белән бетәчәк. Беләсең килсә, синең хәлне төзәтү өчен бу иң ансат юл.

— Гариза язумы?

— Әйе. Гариза язу.

— Неужели син миңа шуны эшләргә кушасың?

— Мин кушмыйм. Язасыңмы, язмыйсыңмы — анысы синең эш. Тик минем сиңа бер нәрсәне төшендерәсем килә. Бел, сине ачык партия җыелышының соравы буенча эшеңнән азат иттеләр — приказда шулай диелгән. Димәк, аны беркем дә үзгәртә алмый.

— Туктале, Вафа, ни сөйлисең? Хәзер генә үзең коллектив минем гаепле булуыма ышанмый, дидең...

— Әйе, дидем. Ләкин җыелышның карары бар.

— Көчләп тагылган карар бит ул. Барысы да алдан хәзерләнгән ләбаса!

— Җыелышларны һәрвакытта алдан хәзерлиләр! —диде Вафа.— Син моны белергә тиеш идең инде...

— Юк, юк, Вафа дус! — дидем мин, башымны кат-кат чайкап.— Дөнья әле бер мехбаза белән генә бетми, мин әле райкомга, обкомга, кирәксә, Мәскәүгә чаклы барып җитә алам. Бер гөнаһсыз кеше булуымны мин әле исбат итә алачакмын!

— Белмим шул,— диде Вафа, сүлпән генә.

— Нигә? Бөтен җирдә дә Басыйр да Перов ишеләр утырмыйлардыр бит?

Вафа чыраен сытып куйды, күрәсең, ошамады аңа бу сүзләр. Бераз дәшми торды.

— Син, Хәбиб, бер нәрсәне аңларга теләмисең,— диде ул, ниһаять.— Сыйнфый көрәш гаять кискенләшкән хәзерге шартларда политик гаепне өстеңнән төшерү бик авыр эш ул. Моңа алиби юк... Әгәр синең Хафазага әйткән бер

генә кыек сүзең расланса да, ниндидер гаепләүгә урын кала. Ярый, син кардан ак, сөттән пакь булуыңны исбат итә алдың ди. Моның өчен бит башта Хафазаның чеп-чи ялганчы, яла ягучы икәнен күрсәтергә кирәк. Онытма, ул хәзер ялгыз түгел, аның әнә Перов, Решевский кебек таза терәкләре бар. Билгеле, алар барысы да бер сүздә булачак... Тагын шуны да исеңдә тот, алар гаепләүче, син акланучы, ә аклануы һәрвакытта авыррак...

— Димәк, синеңчә, аклану инде мөмкин түгел?

— Юк, мин алай дип әйтмәс идем. Гаделлек, ахыр чиктә, җиңеп чыгарга тиеш. Ләкин ничек булачак ул?.. Син, бик тырыша торгач, Хафазаның бөтен җиткергән сүзләрен юкка чыгардың,— ди, син гаепсез, син яла корбаны... Ниһаять, сине акладылар, ләкин сине аклау — Хафазаны батыру дигән сүз, чөнки ул яла ягучы гына түгел, партоешманы да алдаучы булып калачак.

— Ләкин бит аны ул эшкә мәҗбүр иткәннәр! — дидем мин, ярсып.

— Җүләр сатма, зинһар! — диде Вафа, ачуланып.— Кайда синең дәлилең?

— Ул үзе әйтер, әйтергә тиеш.

— Тиеш! Тиле син... Мәҗбүр иттеләр дигән нәрсә недоказуемый абсурд ул, беләсең килсә! Авызыннан чыккан сүзгә бары Хафаза үзе генә җаваплы... Бала түгел бит ул... Озын сүзнең кыскасы шул, син күпмедер дәрәҗәдә акланырсың, Басыйр белән Перовка чүп тә булмас, ә менә Хафаза туташ бу быкырдыкның бердәнбер корбаны булып калыр... Син шуңа ризамы?..

Вафаның бу сүзләреннән мин әллә ничек бөгелеп төшкәндәй булдым. Әйтерсең иң авырткан сөялемә китереп басты ул! Ыңгырашырга җитеп, мин:

— Вафа, ник алай дип әйтәсең? — дидем.— Мин бит Хафазадан үч алырга җыенмыйм. Ачуым никадәр генә көчле булмасын, күпме генә рәнҗемим мин аңа, әмма кичә генә әле миңа шундый якын, кадерле булган бер кеше белән бүген ерткычлардай дошманлашу, шул зәгыйфь, куркак җан белән күзгә-күз очрашу, аңа нәфрәт белән карау, аның йөзенә гаеп ыргыту, ниһаять, аны хур итеп, пычратып ташлау — бу минем теләгем түгел, Вафа, аңла син! Бик түбән, чирканыч эш бу минем өчен... Минем бөтен ачу-нәфрәтем тегеләрдә, безне аерган, безнең мәхәббәтебезне җимергән әнә шул шымчы Басыйр белән Perовларда. Менә кемнәрнең явызлыкларын фаш итәргә, менә кемнәрдән үч алырга тиеш идем мин... Ә син Хафаза, дисең!..

— Их, Хәбиб! — диде Вафа, ачынып.— Мин әйтәммени аны, логика әйтә, хәзерге вакытның логикасы, аңлый-

сыңмы?.. Ә бу эштә логика шуннан гыйбарәт: син «тегеләргә» пычак та эшли алмаячаксың, ә Хафазаны, үзең әйткәнчә, хур итеп ташларга мәҗбүр булачаксың. Һичбер нинди благородный теләкләреңә карамастан! Менә шулай!

Вафаның логикасы рәхимсез иде. Мине тәмам гаҗизлеккә төшерде ул. Бәхәсләшер урын да калмады кебек. Шулай да бу каһәр суккан хәлдән ничектер чыгарга кирәк ләбаса!.. Соңгы өмет белән тагын Вафага карыйм:

— Нишлим соң, Вафа, нинди киңәш бирәсең, әйт, зинһар! Шул кара мөһер белән калыйммыни инде мин?..

— Читен мәсьәлә! — диде Вафа, авыр сулап.— Нинди генә киңәш бирә алыйм мин сиңа, Хәбиб? Әгәр Хафазаны бутыйсың килмәсә, монда ике генә юл кала: йә расчет аласың да чыгып китәсең, йә Перов тәкъдимен кабул итәсең.

— Мин моны беләм.

— Белсәң, сайла инде.

Мин бик нык уйга калдым. Сайларга, сайларга... Икесенең берсен — бүтән чара юк, күрәсең. Шуларның кайсын куша минем акылым һәм вөҗданым?.. Хафазаны аяп түбәнлеккә баруымы, әллә аны корбан итеп булса да, аклануымы?.. Әгәр минем өчен дөреслек, гаделлек, ниһаять, йөз аклыгы кадерлерәк булса, соңгысын сайларга тиеш түгелме мин?.. Чынлап та, үзе явызлык эшләгән кешене ни өчен аяп торырга?.. Бу нинди филантроплык?! Кем моны эшләр иде?.. «Явызлыкка каршылык күрсәтмәү!» — юк, бу кагыйдә белән яшәү мөмкин түгел, Хафаза да, ниһаять, моны белергә тиеш.

Инде безнең арадагы мәхәббәт әнә шулай адәм хуры булып, дошманлыкка әйләнеп бетә икән, моның өчен кешеләр мине гаепләмәсләр. Сәбәпчесе билгеле.

Кыскасы, менә шулай... Һич икеләнмичә, миңа үземне аклау өчен хәрәкәт итә башларга кирәк... Иң дөресе шул.

— Вафа дус,— дидем мин, яңадан телгә килеп.— Мин сайладым.

— Хуш, нәрсәне?

— Мин Перов тәкъдимен кире кагам... Иртәдән үк үземне аклау чарасына керешәм. Ни булса, шул!

— Ярый, хәерле сәгатьтә! — диде Вафа, ничектер битараф кына.— Әлбәттә, син бу эшнең бөтен ягын да уйлагансыңдыр инде?

— Уйладым... Миңа гаделлек кирәк, мин акланырга тиешмен... Инде Хафазага авырлык килә икән, үзенә үпкәләр, минем башка чарам юк.

— Син хаклы,— дип куйды Вафа.

— Тик син миңа тагын бер киңәш бирсәң иде,— дидем мин, аз гына дәшми торып.

— Нинди киңәш?

— Кая барыйм, кем исеменә языйм икән?..

— Син хәзергә берни дә язмый тор,— диде Вафа.— Башта сөйләшергә кирәк. Мин сиңа райкомга барып, анда Мангушев дигән бер иптәш белән сөйләшергә кушар идем. Уйлап эшли торган төпле егет... Барысын да ачык-тан-ачык сөйләрсең... Шуннан ул үзе сиңа кемгә, ничек итеп язарга кирәклеген әйтеп бирер. Аңладыңмы?

— Әйе, аңладым... Ләкин ул миңа ышаныр микән соң?

— Ник ышанмасын — ышаныр... Син бит хәзергә мәсьәләнең яңадан каралуын сорыйсың — шулай түгелме? Бу бик хаклы таләп.

— Әйе, хаклы таләп,— дидем мин, уйланып.— Тик ул ялгыз минем таләп кенә булып калмаса иде.

— Син анысы өчен борчылма! — диде Вафа, мине юатырга ашыккандай.— Мәсьәлә бер кузгалгач, куәтләүчеләр дә табылыр. Менә мин үзем дә Мангушевка әйтермен әле... Аннары синең Васильев белән араң ничек?

— Моңарчы яхшы иде... Ул теге җыелышта булмады бит. Соңыннан белгәч, карт бик борчылган дип әйттеләр. Хәтта, мин бу эшне болай гына калдырмыйм, диеп тә әйткән, имеш.

— Әнә күрдеңме,— диде Вафа, җанланып.— Бу бик важно. Васильевны райкомда яхшы беләләр, хөрмәт тә итәләр, аның сүзенә һичшиксез, колак салачаклар. Беләсеңме, Перов үзе дә аңардан әзрәк шүрли,— карт кыек эшне бер дә яратмый бит... Аннары тагын сер итеп кенә әйтим: синең урынга Басыйр Рәҗәповны куярга чамалап торалар...

— Шулаймыни? — дидем мин, бер дә гаҗәпләнмичә.—Басыйр үзенекен алыр, юкка гына тырышмагандыр...—Аннары әллә ничек уйламастан гына сорап куйдым: — Ә Хафазаны нишләтерләр икән, мин аклана калсам, аны эшеннән чыгармаслармы?

— Борчылма, чыгармаслар,— диде Вафа, тыныч кына.

— Ләкин син аңа начар булачак дидең бит?

— Мораль яктан — әйе... Ышанычын югалтыр, кешеләр күзеннән төшәр, ихтимал, шелтә бирелер... Ә эшеннән чыгармаслар — кечкенә кеше бит әле ул, бары өйрәнчек кенә... Сез әле, егетем, яңадан бергә эшләрсез, бәлки, яңадан дуслашып та китәрсез.

Мин аңа, нәрсә бу — үртәп әйтәме, әллә чынлапмы дип, бик гаҗәпләнеп карадым. Ләкин Вафа, бик гади бер нәрсә әйткәндәй, һич исе китмичә көлемсерәп кенә тора!

— Ничек син моны әйтә аласың, Вафа? — дидем мин, тәмам аптырап.

— Нигә? — диде Вафа, ваемсыз гына.— Мәхәббәт бит ул, әгәр чын икән, тиз генә үтеп китә торган нәрсә түгел. Бигрәк тә яраткан кешең гел янында булып торган чакта. Барысы онытылыр, ә мәхәббәт әкренләп терелер...

— Чынлап әйтәсеңме син моны?

— Бик чынлап.

— Һәм син минем Хафазаны кичерә алуыма да ышанасыңмы?

— Ничек кенә әле! — диде Вафа, бу юлы рәхәтләнеп көлә-көлә.— Тиле, мәхәббәт нәрсәне генә кичерми ул!..

Һәм кинәт минем күз алдыма Вафа әйткәннәр чын булып килде дә басты. Ирексездән хәтта тетрәнеп киттем. Булуы бик мөмкин бит моның, бик мөмкин! Нишләп соң әле бу нәрсә бер генә тапкыр да минем уема килмәде?! Килмәде, әмма күңелем нидер сизенә иде түгелме?.. Бу куркыныч бар икән ләбаса, бар икән, тамыры бөтенләй үк корымаган икән!.. Ләкин мондый тирән ярадан соң минем мәхәббәтем терелергә тиешме, кирәкме, ярыймы ул?.. Терелә калса, мин үземне гомерлек газапка, бәхетсезлеккә дучар итмәммме?.. Мәхәббәт ышанудан башка була алмый бит, ә мин ул ышанычны яңадан ничек кайтарыйм соң?!

— Юк, бу булачак түгел,— дидем мин, тешләремне кысып,— булачак түгел!

— Ә син алдан кычкырырга ашыкма, дус кеше! — диде Вафа, сабыр гына.— Тормыш бу, кешене кырыкка бөгә...

— Әйтмә, әйтмә, Вафа, минем бөгеләсем килми! — дидем мин, башымны кат-кат чайкап.

Вафа сынагандай беравык миңа җитди генә карап торды, аннары йомшак кына әйтте:

— Менә нәрсә, Хәбиб, син аргансың, нервларың да кузгалган, сиңа хәзер ял кирәк. Бүгенгә җитәр. Сөйләшәсен сөйләштек, хәзергә шуның белән бетерик.

Әйе, Вафа дөрес әйтә. Мин хәзер үземне кыйнап ташлаган эт шикелле тоям. Зиһенем дә әллә ничек чуала башлаган кебек... Җитте, ахрысы, бик җитте... Кайтырга кирәк. Авыр гына сулап мин урынымнан тордым.— Ярый, Вафа,— дидем, аңа кулымны сузып,— бөтен әйткән сүзләрең, биргән киңәшләрең өчен рәхмәт! Бел, синнән башка минем килеп төртелер кешем дә юк иде.

Ул «аңлыйм» дигәндәй, башын гына какты һәм мине ишеккә чаклы озата чыкты. Аерылышкан чакта гына шулай да әйтеп куйды:

— Хәбиб, син давай бу хәлне артык зур трагедиягә әйләндермә, ашыгыч нәтиҗәләр ясама, үзеңне тыныч тот!

— Рәхмәт, Вафа!

Мин тагын бер мәртәбә аның кулын кыстым.

## XIX

...Урамда күз бәйләнерлек караңгы иде инде. Кич ничектер тымызык-моңсу, томанлы, фонарьлар да кабынмаган — аяк астын шәйләп булырлык та түгел. Мин, чокыр-чакырлы иске тротуар буйлап, тәрәзәләрдән төшкән яктыда бик тонык кына чагылган суларга басмаска тырышып, шулай да әледән-әле суның нәкъ күзенә баскалап, китеп бардым. Трамвайга утырасым килмәде. Каюм Насыйри урамына борылдым, аннан Татарстанга килеп чыктым. Монда яктырак иде, һәм кызулап туры гына үзем торган Куйбышев урамына таба атладым.

Мин кайтып кергәндә, Серафима түтәй кухняда үзенең зур таш чәшкәсеннән чәй эчеп утыра иде. Мине күрүгә:

— Хәбиб, син бүген эшкә бармадыңмыни? — дип сорады.

— Нигә? — дидем мин, аптырабрак.

— Фая килгән иде, сезне бик озак көтеп утырды.

Мин, бусагага ябышкандай, катып калдым.

— Хафаза?!

— Әйе инде...

— Күптәнме?

Серафима түтәй миңа бик сәерсенеп карады, гүя ул минем тавышымны танымый иде.

— Әле бик күптән түгел,— диде ул, күзләрен миннән алмыйча,— китүенә бер ун минут булыр.

Мин шул секундта ук кире борылып чыгып та киттем. Ак-караны күрмичә, ашыга-ашыга Хафазалар торган якка — Болак буена таба атладым. Кичке томан эчендә селкенгән шәүләләрне, аңа охшаса-охшамаса да, куып җитәм дә узып китәм, куып җитәм дә узып китәм... Хәер, мин әле ни өчен болай йөгерә-атлый баруымны да аңлап җиткермим... Аны куып җитәр өченме, күрер өченме?.. Ләкин хәзер бу мөмкин түгел бит инде — ун минут эчендә ул өенә кайтып җиткән булырга тиеш.

Шулай бара-бара мин адымнарымны әкренәйтә башладым. Болак чатына җиткәч, ниһаять, туктадым. Хафазаны куып җитү яки артыннан өенә барып керү ни белән бетәчәк?! Юк, зиһенем әле сау чакта, үзем-үзем хуҗа чакта, миңа туктарга кирәк, туктарга!.. Шәүлә куып барудан мәгънә юк, мәгънә калмады... Мин кире борылдым. Абына-сөртенә кире киттем... Шушы минутта мин үксеп җибәрсәм, моңа берәү дә гаҗәпләнмәс иде... Ул, Хафаза бәгырькәем, миңа килгән, көткән, озак көткән!.. Ә мин аның ялганын фаш итмәкче булам, кемнәрдер алдына барып, үземне акламакчы, аны гаепле итеп кал-

дырмакчы булам. Мин тап-таза ир башым белән шул кеч-кенә зәгыйфь җанга каршы көрәшмәкче булам... Ниндидер бер ярсу-тәвәккәллек йөрәгемне ялкындай каплап алды, шушы җепшек, томанлы төнгә кычкырып әйтәсем килде: «Юк, булмас бу, булмас, кичәге мәхәббәтемне мин бүген аяк астына салып таптамаячакмын!.. Тәүбә дә юк, аклану да юк!.. Бер селтәнүдә барысын өзәргә, бетерергә, ташлап китәргә — бары шул гына!»

...Икенче көнне мин үземдә ниндидер бер җиңеллек хис итеп уяндым. Тиз генә торып, юынып, чиста күлмәк, яңа костюмымны, шулар өстеннән зәңгәр плащымны киеп, мехбазага киттем. Көн бик җылы-йомшак, бик якты иде. Фәрештә канатыдай... Шуның шифасыдырмы, минем дә җаным гаҗәп тыныч иде, кичәге газаплардан берни дә калмаган, гүя барысы да үз урынына кайткан, утырган... Хәтта киләчәгем дә бүгенге көн шикелле яп-якты сыман...

Билгеле, мехбазага барышлый да ачык акыл һәм тыныч җан белән тагын үз хәлем турында уйландым. Хафазаны аяп, аклануда баш тарту, барысын да ташлап китү дөрес булачакмы? Мондый карарга килүем кичәге тирән, газаплы кичерешләр нәтиҗәсе генә түгелме?.. Юк шикелле, алай гына түгел шикелле... Хафазаны аяу өстенә тагын бик җитди бер сәбәп барлыгын бүген менә аеруча нык сизәм кебек... Аклану мөмкин булачакмы — менә хикмәт нәрсәдә. Кайда гарантия?.. Йөреп-йөреп тә барып чыкмаса, нишләрсең?.. Вафа кичә әйтте бит, вакыты хәзер шундый, бер генә хата сүзең расланса да, акланып булмаячак, диде. Әйе, хәвефле вакыт!.. Гүя кемдер тарафыннан юри өреп дөрләтелгән «көрәш уты» берәүне дә аяп тормый. Ә мин ялгыз башым Перов, Решевский кебек шул утның кисәү агачларына каршы торырга тиешмен. Мәгънәсезлек түгелме соң бу?! Берсе — партоешма секретаре, икенчесе —управляющий, кайда, кем генә алар хаксыз, мин хаклы дип әйтә алыр икән? Алар да бит «вакыт кушканны» эшләүчеләр. Нигә, шулай түгелмени?.. Җыелышта мин купшы интеллигент Решевскийның чыгышына хәйран калган идем. Ә хәзер — юк, хәзер гаҗәпләнмим инде. Интеллигент та бит ике башлы түгел, ә бер башны ничек тә сакларга кирәк. Мин дә газиз башымны сакларга тиеш түгелмени? Ничек итеп?.. Тәүбә итүдән баш тарттым, акланып маташудан исә мәгънә чыкмаячак. Көч, коточкыч көч алар ягында. Ачуларын китерсәң, маңгаеңа тагы да карарак мөһер чәпәрләр — бары шул булыр!

Димәк, кичә уйлаганча, тотарга да чыгып китәргә! Һичнигә карамастан! Башка юлым юк минем...

Мехбазада эшем тиз бетте. Бухгалтерия миңа расчет-

ны әзерләп үк куйган икән. Үткән айның ике атнасы, бу айның биш көне өчен хезмәт хакын, шуның өстенә сигез ай эшләгән өчен тиешле отпуска акчасын бирделәр. Кулыма йөз егерме сум тиде. Зур акча иде бу... Торып була икән әле, дидем мин, хуҗаларча салкын исәп белән. Аена ун тәңкәгә дә торып өйрәнгән кеше без.

Кулыма приказ күчермәсен дә бирделәр. Акчаларны бик эчкәре куйдым, ә бу күчермәне бөгәрләп тышкы кесәгә генә тыккан булдым. Ул миңа кирәкми иде.

Мостафаны тагын күрә алмадым — мехкомбинатка киткән, диделәр. Шулай итеп, берәү белән дә күрешмичә диярлек, мехбазадан мин чыгып киттем. Минем өчен күңелле җир, яхшы җир иде бу мехбаза... Шушында сигез ай эшләп, мишәр абзыйлардан каракүл бизәкләрен «укырга» өйрәндем, шушында Басыйр кебек чүпләрдән башка, әйбәт иптәшләр таптым, шушында, ниһаять, беренче яратуның үкенечле ләззәтен татып карадым, инде менә...

Ярый, сынмыйк, сыкранмыйк!.. Илдә чыпчык үлми, дигәннәр безнең агайлар.

## XX

Бәкер дус, минем хикәям шушының белән бетте, инде нокта куйсам да ярый торгандыр. Ләкин синдә: шуннан соң ни булды? — дигән сорау туарга мөмкин. Бик кыска белешмә рәвешендә генә әйтеп китим, булмаса.

Башта язганымча, максатым бер ел эшләп, кая да булса укырга китү иде. Хәзер инде бу минем өчен бердәнбер теләк һәм чара булып калды. Ләкин кая китәргә? Баштарак мин Казан университетына керү турында уйлана идем. Эшләр болай булып киткәч, минем Казанда һич каласым килми башлады. Саф һавага сусагандай, күңел өзелеп яңа җир, яңа кешеләр тели иде. Аннары миндә кинәт кенә энергетика белгечлегенә укыйсы килү теләге туды. Әледән-әле Ленинның электрофикация турында әйткән даһи сүзләре искә төшә дә тора. Минем өчен хәзер, бәлки, нәкъ менә шул баганалы юлга чыгу кирәктер дә. Мәскәүдән кала тагын Иваново шәһәрендә дә энергетика институты бар икән. Тыныч кына, бирелеп кенә укыр өчен шушы кеше таптамаган аулак шәһәрне сайларга булдым. Ләкин көзге имтиханнарга бик ерак иде әле... Аңа чаклы нишләргә, вакытны кайда үткәрергә? Серафима түтәйдә бүлмә биләп, эшсез тик яту мөмкин түгел... Дөрес, миңа хәзер институтка керер өчен нык кына әзерләнергә кирәк, ләкин монда түгел: күп ха-

тирәләр саклаган бу бүлмәдә бер дә каласым килми иде. Серафима түтәй дә тора, тора да: «Фая нигә килми, ни булды?»— дип сорап куя. Юк, моннан китәргә кирәк, китәргә!

Иделнең тулып, җәелеп ташыган чагы. Беренче пароходлар төште. Аларның сузып-сузып кычкырткан тавышлары күңелләрне җилсетеп, әллә кайларга чакырадәшә кебек... Җанны кая куярга белеп булмый... Бер Әстерханга төшеп китәргә дип тәмам җыенып та беткән идем, ләкин тыелып калдым — акча кызганыч, акчаны сакларга кирәк иде. Шуннан соң тоттым да Май бәйрәменең икенче көнендә ат-арбалар төяп йөртә торган иске «Волгарь» паромына утырып, үзебезнең Югары Осланга чыгып киттем. Ул елларда әле Казан халкы шул якка күпләп дачага чыга торган иде. Миңа да бу нәрсә харам булмас дип, шундагы бер түтәйдән арзан гына почмак табып, торып калырга булдым. Кайтып, барлы-юклы әйберләрем һәм китапларым белән күтәренеп тә килдем. Шулай итеп, уйламаган җирдән генә Югары Осланда тора башладым. Ерак түгел генә Печище тегермәне бар, ә минем нык-таза чак, һәм менә ара-тирә шул тегермәнгә барып, баржага он төяшәм. Белешмә-мазар сорамыйлар, акчасын шунда ук түлиләр, иш янына куш дигәндәй, бу миңа ярап куя иде.

Шунда мин июль урталарына чаклы тордым. Аннары атна-ун көнгә Япанчыга кайтып килдем. Ә август башларында инде мин, тәвәккәлләп, Иваново шәһәренә киттем.

Имтиханнарны уңышлы гына биреп, әлеге шул энергетика институтына укырга кердем. Яңадан студент булдым. Еллар авыр иде. «Лаеш шулпасын» шактый эчәргә туры килде. Аннары татарлардан мин берүзем генә идем. Шәһри Казанны, милләттәш туганнарны ирексездән иңрәп сагынган чакларым булгалады. Кайчагында онытылып: «Хәмдиягә сүз әйтмәгез, зиһене таралган чагы...»— дип җырлый башлый идем дә аннары кинәт кенә өзелеп, үз-үземә: «Син, Хәбиб, бозау булма!»— дип, бармак яный идем һәм күзгә килгән яшьләрне селтәп ыргыта идем.

Дүрт елдан соң мин, институтны тәмамлап, инженер булып чыктым. Мине Үзбәкстанга билгеләделәр. Ике дә уйламыйча риза булдым. Кайчандыр миңа кояшын һәм икмәген биргән юмарт илгә үземне бурычлы саный идем. Белемем, дәртем, өметләремне кушучыма салып дигәндәй, киттем мин шул эссе-аяз илгә! Бу — 1936 ел иде. Шул елдан минем озын хезмәт юлым башланды.

Инде менә ике елдан миңа алтмыш яшь тулачак, Бәкер дус! Гомер узды... исте җилләр, күчте комнар... Өметләр-

нең кайсылары үтәлде, кайсылары юк... Ә мин эшләдем дә эшләдем. Айлар артыннан айлар, еллар артыннан еллар үзем суздырган электр чыбыгы буйлап китә торды. Тулаем алганда, мин канәгать. Үзбәкстанда хәзер Ильич нуры кермәгән өй калмады... Шулай итеп, үземә тигән эш агачының җимешен әкренләп өзеп бетереп киләм. Дөресен әйтергә кирәк, татлысы да, әчесе дә күп булды. Табигый хәл!.. Тик менә мин үзем генә җимешсез, кысыр агач булып калдым. Син беләсең инде: минем хатыным да, балам да юк. Вакытында өйләнә алмадым. Моның сәбәбен бер Хафазага сылтасам, һич тә дөрес булмас иде. Әйе, Хафаза минем йөрәгемә кадалган шырпы булды, ләкин ул күптән ит белән үрелде, күптән онытылды. Дөрес, баштарак мин хатын-кыздан, ничек дим, гайрәтем чигеп, бизеп йөрдем. Аннары тора-бара бу ятлашу, бу чиркану бетте, басылды. Мин бит тап-таза ир идем, шулай ук аскет та, ханжа да түгел идем һәм, яшермим, хатын-кызсыз да тормадым. Ләкин, ни хикмәттер, шуларның берсенә дә чын, тирән мәхәббәт миндә яңадан уяна алмады. Ә чын мәхәббәттән башка өйләнүне ничектер җаным кабул итмәде... Кыскасы, ычкындырдым мин өйләнү вакытын, ә инде олыгаюга киткәч, әйтик, утыз биштән соң, тәвәккәлләү бик читен икән. Әлбәттә, бу мәсьәлә мине һәрвакытта борчып килде, картлык якынлаша башлагач, аеруча нык уйландырды, әмма, нихәл итәсең, булмый менә, мәҗбүр итә алмыйм үземне, ялгызлыгыма өйрәнеп җиттем, ә ахырын уйламаска тырышам.

Сине, бәлки, Хафаза язмышы кызыксындырадыр. Нәрсә әйтим? Мин үзем дә бик озак вакыт аның турында хәбәрсез яшәдем. Башта Иваново, аннары Ташкент дигәндәй, аралар да бик ерак булды, еллар да күп үтеп китте. Яшермим, баштарак мин аны еш кына исемә төшереп, кайда, нишли икән? — дип уйлана торган идем. Оныттым дисәм дә, Бәкер, ул кызый күңелнең әллә кайсы гына төшендә һаман яшеренеп ята бирде...

Сугыштан соң мин Ташкентта һич көтмәгәндә генә элек мехбазада бергә эшләгән бер кызны очраттым. Билгеле, Хафаза турында сорашмыйча түзә алмадым. Ул кыз (хәер, бу вакытта инде ул ханым иде) миңа шуны сөйләде: Хафаза миннән соң мехбазада бер ел чамасы эшләп йөргән, шул арада пединститутны бетергән бер башкорт егете белән танышкан һәм шул егет аны үзе белән Уфага да алып киткән. Хәзерге вакытта да шунда яшиләр, ди... Хафаза бик әйбәт кенә тора, имеш, өчме-дүртме баласы да булган икән инде, кыскасы... әнә шулай... Бу хәбәрне сөйләгән ханым белән минем яңадан очрашасым килмәде.

Бетте шикелле. Арыдым да бугай. Син инде, Бәкер дус, миннән: «Ни өчен бу нәрсәне яздың?» — дип сорама. Нәтиҗәне үзең ясa. Кешегә бит үзенең гамәле турында хөкем чыгаруы бик читен. Кеше гомер юлын бер генә тапкыр уза — кире кайтып, яңадан башлый алмый ул аны... Әлбәттә, кылган эшләре турында кеше уйланырга мәҗбүр, әмма инде эшләгән кадәресен үзгәртү дә, төзәтү дә мөмкин түгел: дөресме, хатамы — факт булып кала бирә. Минем өчен дә ул шулай... Теге чакта бөтенесенә кул селтәп китүем дөрес булдымы икән, дип, мин дә соңыннан бик күп уйландым. Бигрәк тә Хафазаны күрмичә, аның белән аңлашыйча китүемә бик нык үкенгән чакларым булды. Бер дә генә югалтасым килмәгән икән шул аны!.. Ләкин әнә шулай әрнеп үкенүләргә карамастан, бер рәхимсез хакыйкать минем өчен һаман да бәхәссез булып кала бирде: әгәр теге, Хафаза миңа килгән кичне, без очрашкан булсак, мин, мотлакап, Перов тәкъдимен кабул итәргә мәҗбүр булган булыр идем. Мәхәббәт намустан көчлерәк булып чыгар иде... Һәм вөҗданыма каршы барып булса да, мин, Хафаза хакына, иң үкенечле, соңыннан һич төзәтеп булмас эшне эшләп ташлаган булыр идем. Чөнки Хафазаны саклау, Хафазаны яңадан үземә кайтару өчен минем ул чакта башка чарам да юк иде. Ләкин ахыр чиктә моның нәтиҗәсе нәрсә булып чыгар иде? — бер Ходайның үзенә генә мәгълүм!.. Ялган гаеп өчен тәүбә итеп, котылып калган кешене минем очратканым юк әле. Шуңа күрә әйтәсем килә: Хафаза белән очрашмыйча «качып» китүем, бәлки, хәерлегә булгандыр. Мәхәббәт чәлпәрәмә килсә килде, әмма намусымны көчләргә туры килмәде. Иң авыр вөҗдан газабы, минемчә, кылган гамәлең өчен соңыннан үкенеп яшәү —шулай түгелме, Бәкер дус? Әгәр шулай икән, син минем «качуым» белән килешергә тиешсең... Хәер, мин сиңа үз хөкememне тагарга теләмим. Минем бурыч — башымнан кичкәнне нәкъ булганча язып чыгу иде, ә нәтиҗә ясау —әйткәнемчә, синең эш!

Инде соңгы сүзем: беләсеңме, «мехбаза вакыйгасыннан» соң мин һаман ниндидер үзгәреш көтеп яши башладым. Дөнья гел генә болай тормас, болай бармас дигән әллә өмет, әллә көчле теләк миндә уянды. Килер бер вакыт,— дип уйлый идем еш кына,— кешегә саф үзенчә булу мөмкинлеге туар, вөҗдан һәм акыл үзенең табигый бердәмлегенә кайтыр, икейөзле булу, чын фикерне яшерү, куркып-ялагайланып яшәү бетәр, кеше бары намусы кушканча, бары дөреслек һәм гаделлек хакына яши башлар — әйе, ихлас, әнә шундый уйлар туды миндә, Бәкер дус!

Шундый уйлардан, шундый өметтән башка яшәүнең мәгънәсе дә юктыр шикелле... Ярый, сүз күпкә китте, инде нокта куярга да ярый торгандыр.

Әгәр Ташкентка килергә уйласаң — көз яхшы. Көзен тәмле исләр дә күбрәк була, арыклардан сулар да чистарак ага. Җылы, тымызык, рәхәт вакыт. Мин үзем гомер буе ялгыз яшәгән кеше булгач, аш-суга тәмам өйрәнеп беттем диярлек. Үзбәкчәләп әйткәндә: «Пылауны җөдә һәм саз кыламыз да... Безгә һәм миһман болеп килең ахыр, җүрә-җан, килең!»

Хуш, бигайбә!

*1966—1968*
*Казан*

# БЕЗ ДӘ СОЛДАТЛАР ИДЕК

*(Фронт дәфтәреннән)*

Немецлар чигенә. Безнекеләр алга бара. Июль урталарында Идрица һәм Себеж шәһәрләрен алганнар иде, инде менә Латвия җиренә дә барып керделәр... Һөҗүм итүчеләр артыннан, ниһаять, без дә кузгалдык.

Без дигәнем — кечкенә генә бер взвод. Унбиш кешелек кенә. Безнең эшебез — каравыл хезмәте, без боеприпаслар складын саклыйбыз.

Армиянең һөҗүмгә күчеп, дошманны кыра-кыра алга таба баруы безнең өчен дә көтеп алган иң зур куаныч ул. Без дә бит алга таба барабыз, сугышның ахырына —соңгы җиңүгә таба!.. Үзебезгә калса, без дә һәрбер башланып киткән һөҗүмгә кечкенә генә булса да өлеш кертәбез: дошман өстенә явачак снаряд-бомбаларны көне-төне саклыйбыз, ә бик тыгыз-кызу көннәрдә, посттан кайткач, аларны машиналарга да төяшәбез. Кайчагында әнә шулай ялсыз-йокысыз посттан эшкә, эштән постка йөрү атналап та сузыла, ләкин сыкрану юк, чөнки аңлыйбыз, беләбез һәм, эт булып арысак та, түзәбез.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, без барыбыз да нестроевойлар, ягъни алгы сызыкта сугышырга ярамый торган солдатлар. Безнең арада өч ел фронтта йөреп бер генә тапкыр да мылтык атып карамаган кешеләр бар. Болар «картлар», башта ук нестроевой хезмәткә алынган солдатлар: мәсәлән, казакълардан Өметбаев белән Байәхмәтов, үзбәк Ишмәмәт, яки менә руслардан Шумилов... Ләкин барыбер аларның өстендә дә соры шинель, башларында кызыл йолдызлы бүрек яки пилотка.

Шулай ук безнең арада, алгы сызыкта булып, сугыш эченнән шактый өтелеп чыкканнар да бар. Болар, каты яраланып, госпитальдә ятканнан соң, нестроевой булып, фронтка кире кайткан солдатлар. Шундыйлардан менә Хафиз Акшалов, Дорды Ходайбирдин (икесе дә казакълар), минем якташлардан Төхфәт абзый белән чуаш Емелькин — боларны инде чын солдатлар дияргә була, тик сугышырга гына ярамыйлар... Яудан имгәнеп чыккан ба-

тырлар!.. Шулай да мылтык тотарлык булгач, аларны кайтарып җибәрмиләр, каравыл хезмәтендә булса да тоталар. Илдән күпме генә яңа көчләр килеп тормасын, барыбер җитәсе түгел — сугыш убыр ул!..

Ләкин без барыбыз да, тегендә алда булганнар гына түгел, ә менә монда арттарак торучылар да, сугышның дәһшәтле, рәхимсез ерткыч чыраен, әйтергә кирәк ки, шактый «әйбәт» күреп-танып өлгердек. Бигрәк тә баштагы ике ел дәвамында. Ул чакларда немецларның авиациясе безнең теңкәбезгә бик нык тиде. Кайда гына тукталмыйк, баш очыбызда шулар. Кара тәреле саргылт самолетлар, ала каргалар шикелле, түбәннән генә очып киләләр дә, безне җиргә сеңдереп, дөмбәсләргә тотыналар. Яралanucылар да, үлүчеләр дә була иде. Бомбежкадан һәлак булу бик начар нәрсә ул, чөнки җирдәге солдат, һавадагы дошманына каршы берни дә эшли алмыйча, иң үкенечле рәвештә үлә дә китә.

Мин үзем дә бер-ике тапкыр кыл өстендә генә калдым. Шулай, кырык икенче елның кышында, Баталино дигән станциядә торабыз (ул чагында әле мин ротада писарь булып утыра идем)... Яңа гына килеп төпләнгән чагыбыз. Рота станция поселогына урнашты, мине кечкенә «кәнсәм» белән ни өчендер тимер юл буена караган бер кызыл йортка куйдылар. Ә тимер юлларда туп-туры эшелоннар, җирдә тау-тау бушатылган йөкләр — немец самолетларының килеп «каплавын» көт тә тор. Ләкин ул чакта без әле чынлап куркырга да һәм сакланырга да өйрәнеп җитмәгән идек.

Һәм менә беркөнне миңа, ниндидер кәгазьләргә кул куйдырыр өчен, рота командирын эзләп табарга кирәк булды. Өстәлемне әзрәк җыештырдым да, папкамны култыкка кыстырып, өйдән чыгып киттем. Чыккач, кайдан эзләргә икән дип, аз гына уйланып тордым, шулай да башта командирның торган квартирына барырга булдым. Һәм поселокка таба атладым. Станция белән поселок арасында мәйдан сыман киң генә буш ара — мин менә шул буш араны, һичбер нинди куркыныч якынлашуын сизмичә, тыныч кына үтеп барам. Ләкин өйдән чыгып, йөз-йөз илле адым китәргә өлгермәгәнмендер, күк йөзен тоташ каплап, һаман көчәя барган шомлы бер гүләү тавышын ишетеп алдым. Бу миңа бик таныш гүләү иде. Шунда ук туктап, һавага күтәрелеп карадым, һәм, ни күрим, поселок артындагы урман өстеннән генә безгә таба, өчәр-өчәр тезелешеп, немец самолетлары ашыкмыйча гына киләләр!.. Алар күбәү иде, билгеле бер ара саклап, гүя урман артыннан гына күтәрелгән шикелле, өчәрләп

чыгып кына торалар. Бу бик куркыныч иде, бик дәһшәтле иде, мин ихтыярсыз артыма борылып карадым. Тимер юл буендагы кешеләр дә бу дәһшәтне инде күреп, тызбыз чабарга, төрле якка сибелеп качарга тотынганнар иде. Мин дә коелып төшкән бер хәлдә нишләргә, качаргамы, кая таба качарга дип, тәмам аптырап калдым. Шул арада, шактый соңга калып булса да, ачык платформадагы безнең кечкенә зенит туплары кабаланып, тотлыга-тотлыга ата башладылар. Ул да булмый, алдан килгән өч самолет пикка кереп (түбәнәеп), юллар өстенә авыр бомбаларын бер-бер артлы төшереп тә җибәрделәр. Шул секундта ук мин дә җиргә йөзтүбән капландым. Башта кыеклап очкан бомбаларның чучка шикелле яман чинап төшүләре ишетелде, аннары шуның артыннан ук барлык тавышларны да күмеп, бөтен тирә-якны тетрәтеп, гөрс тә гөрс шартларга тотындылар. Беришеләре еррактарак шартлаган кебек, ә кайберләре, чинаган тавышларына караганда, нәкъ минем өскә төшеп килә шикелле. Астымдагы җир олы бер җанварның сырты сыман калтырана һәм мине күтәреп-күтәреп җибәрә. Тирә-ягыма кар аралаш тузан-туфрак ява, ара-тирә зур гына җир кантарлары да килеп төшә, ә мин, ике куллап башымны учлаган килеш, җиргә тагы да ныграк сеңәргә тырышып, йөзтүбән ятам да ятам. Шушы минутларда ни уйлавымны, нәрсә теләвемне һич белмим, хәтерләмим — акылым тәмам сүнгән иде.

Бу мәхшәр бер ун минутка сузылгандыр. Самолетлар, бер-бер артлы түбән кадалып, бомбаларын ташлап бетергәч тә, станция өстендә авыр үкереп, әйләнә-әйләнә пулеметтан сиптереп йөрделәр. Бары шуннан соң гына киттеләр... Киттеләр, бәдбәхетләр! Дөнья бер мәлгә тып-тын булып калды.

Мин, башымны җирдән сак кына күтәреп, бераз колак салып торганнан соң, ниһаять, әкрен генә торып бастым. Көн бөтенләй караңгыланып киткән, тимер юллар өстендә тузан-төтен асылынып тора, ачык кына бер нәрсә дә күреп булырлык түгел, хәтта зур гына вокзал бинасы да куе тузан эчендә иде. Әйе, шик юк ки, анда һәлакәтказа, кан-үлем күп булырга тиеш иде.

Барысыннан да элек минем үзем торган йортны кире кайтып күрәсем килде. Ни булды икән анда? Минем «хуҗалык» ни хәлдә?.. Ротаның бөтен эшләре, секрет кәгазьләре кечерәк кенә тимер сандыкта — аны мин башым кебек сакларга тиешмен. Ашыга-ашыга киттем. Йортка якынлашу белән үк инде мин кар өстендә аунап яткан берничә мәетне күрдем. (Шуны әйтергә кирәк, бомбеж-

када яраланучылар күп булмый; кеше күбрәк контузия ала яки бөтенләй һәлак була.) Килеп җиткәч, ни күрим, йортның нәкъ мин торган башындагы бер почмагы тәмам актарылган. Дөрес, бомба туп-туры йортка тимәгән, ул берничә метр гына читкәрәк төшеп шартлаган, ләкин шулай да почмакны актарып ташлаган. Эшләр яман икән, дидем мин, һәм ашыгып өйнең эченә уздым. Башлап күргәнем — кухня бусагасында үлеп яткан бер яшь хатын гәүдәсе булды. Ул йөзтүбән ята иде, ләкин иелебрәк карагач, мин аны таныдым: йа Рабби, бу шушы йортта торучы хатын ич! Эчкәре бүлмәләрнең берсендә өч яшьлек кызы белән генә тора иде ул. Коридорга чыккан чакта мин аны гел кызчыгы белән бергә диярлек күргәли идем. Ләкин соңгы ике-өч көн эчендә алар күренмәс булдылар, ахрысы, хатын бу хәтәр җирдән кызын тынычрак урынга алып киткәндер, дип уйладым. (Чөнки безнең хуҗаның да аны, кит, торма монда, тиле, дип куганын ничектер ишетеп калган идем.) Ә хәзер менә шул егерме дүрт-егерме биш яшьлек чибәр генә хатынның җансыз гәүдәсе монда кан эчендә ята. Ничек кенә булды икән соң бу?.. Берәр йомыш белән бүлмәсенә кайткан чагы булды микәнни бичараның?.. Һәм шунда ук тагын бер уй йөрәгемне өшетеп җибәрде: ә кызчыгы кайда соң моның, кызчыгы?.. Бәлки, ул да... Юк, минем моңа ышанасым килмәде. Булмас, булырга тиеш түгел. Әнисе янында юк ич, коридорда да күренми, тавышы да ишетелми. Бәлки, әнисе, кызын калдырып, ялгыз гына кайткандыр — минем шуңа бик нык ышанасым килде. Минем хәтта кемнәндер шулай булуын ялварып сорыйсым килде. Бүгенге кебек фаҗигане бала йөрәге татырга тиешме соң, Ходаем?!

Инде үз бүлмәмә килсәм, аның бикле ишеге каерылып ауган, аскы тупсасына гына эләгеп тора, ә үзе бомба кыйпылчыкларыннан яргаланып, тишкәләнеп беткән. (Бәлки, хатынга да шушы ишекне тишеп узган бомба кыйпылчыгы тигән булгандыр...) Эчкәре кердем һәм мондагы тамашага хәйран калып, күпмедер вакыт баскан җиремнән кузгала алмыйча тордым. Бүлмәнең бөтен эче актарылган иде: түр почмагы шыр ачык, ике зур тәрәзәсе икесе дә рамнары белән үк каерылып очканнар, идән тулы пыяла ватыгы, өстәл-урындыклар чәлпәрәмә килеп, аунап яталар, кыскасы, бер бөтен җиһаз калмаган. Тик идәндәге минем сандык белән тимер караваты кына бөтен кебек... Тагын әнә стена буендагы түгәрәк галанка мичнең калаен бомба кыйпылчыклары тишкәләп бетергән. Ә мин бит шушы мич белән тәрәзә арасында утыра идем. Бары тик

менә хәзер генә минем аңыма коточкыч хакыйкать килеп җитте: әгәр дә мин бу бүлмәдән бер-ике генә минут чыгып китмичә торсам, миннән нәрсә генә калган булыр иде икән?.. Өстәленә иелеп, кыштыр-кыштыр нидер язып утырган күзлекле писарьдан, мин әйтәм?.. Нервлар бик киерелгән иде, хәлсезләнеп караватт читенә утырдым... Уйлыйм: мин бит бернинди хәтәр сизмичә чыгып киттем, әмма нәкъ соңгы чиктә генә кузгалганмын, бер генә минутка соңга калсам да, бүлмә эчендә булмаса, йортның тышында мин үлем тырнагына эләккән булыр идем... Кемнең генә догасы мине бу һәлакәттән йолып калды икән?.. Бәлки, әнкәйнеңдер, бәлки, әнкәй минем колагыма шыпырт кына: «Улым, тор, чык!» — дип әйткәндер... Шулай... Гаҗәп икән бу кеше язмышының серләре — үлем килеп җиткәндә генә берәү чыгып китә, ә берәү әнә... кайтып керә!

Миңа бомбежканың төрлесен — бүгенге кебек бик дәһшәтлесен дә һәм вак-төяген дә (әйтик, бер-ике генә самолетның көтмәгәндә килеп чыгып, хәтәр йөгерен кая эләксә шунда ташлап качканнарын да) шактый күрергә туры килде. Ләкин аларны сөйләп торасым килми, бусы да бик җиткән, тик шулай да бер бомбежка вакытында булган гаҗәеп бер хәлне генә сөйләмичә үтә алмыйм — ничектер аңлавы читен хәлләр булгалап тора иде. Менә бу да шундыйларның берсе.

Пено дигән зур гына авылда торган чакта булды бу... Безнең ротада Федько исемле бер шофер бар иде. Бик күп юл чапкан, утны-суны да күп кичкән, ләкин моңарчы әле бер дә бәла-казага юлыкмаган, үзе ваемсыз, үзе җитез, русчалап та әйтсәк, шустрый гына егет иде ул Федько! Көннәрдән бер көнне рота командиры менә шул Федьконы өч солдат белән бергә станциягә азык алырга җибәрә. Баралар, тиешле урыннан кирәкле азыкны алалар, машинага төйи башлыйлар... Нәкъ шул чакта станция өстенә немец самолетлары килеп чыкмасынмы! Солдатлар төрлесе төрле якка йөгерәләр, ә Федько, машинасына сикереп менә дә, тиз генә газ биреп, чаптырып китеп тә бара.

Бомбежка бетеп, күпме вакыт узды икән? Ун-унбиш минут — шуннан да артык булмас, чөнки мин үзем дә йорт янындагы траншеядан чыгып, яңарак кына канцеляриямә кереп утырган идем. (Шуны әйтергә кирәк, бомбежканың нәрсә икәнен белеп алгач, без хәзер кая гына килеп урнашсак та, иң элек бусагадан атылып чыгуга сикереп төшәр өчен тар-тирән генә траншеялар казып куя торган булдык.) Кыскасы, озак та үтми, минем янга

Федько килеп керде... Керде бу, бер сүз әйтмәстән лып итеп табуреткага утырды, башыннан тапланып беткән бүреген алып, шуның эче белән буй-буй кара тир аккан битен сөртте, аннары бүрекне ни өчендер кулында әйләндерә башлады. Егет шактый сәер күренә иде, күзләре дә әллә ничек аларып киткән төсле... Нидер булган егеткә, шулай да мин аның сүз башлавын көтәм. Ә ул мине бөтенләй күрми дә шикелле, тик шунда бүреге белән мавыгып утыра, гүя бер эше дә, бер йомышы да юк кебек. Ахырда үзем дәштем:

— Кайттыгызмы, Федько?

Ләкин ул җавап бирү түгел, миңа күтәрелеп тә карамады. Бу инде шикле иде. Егетебез тәгаен бомбежкага эләккән булса кирәк. Алай дисәң, бар җире дә бөтен күренә. Әллә бераз чукракланып калганмы? (Бусы инде еш була торган хәл.) Шуннан тагы да кычкырыбрак дәштем үзенә:

— Федько, әйт, ни булды сиңа?

Моңа каршы Федько үзе миннән кинәт кенә:

— Командир кайда? — дип сорады.

— Командирмы?.. Белмим шул, парин!.. Ә нигә кирәк иде ул?

Федько җавап биреп тормады, терсәгенә таянды да башын гына түбән иде. Тәмам аптырадым. Әллә минем белән санлашмый, әллә чынлап та ишетми, әллә инде әзрәк миңгерәүләнеп тә киткән?.. Шул арада безнең командир үзе дә килеп керде. Солдат командир килеп кергән чакта торып басарга тиеш, ләкин Федько урыныннан да кузгалмады. Командир аңа кырыс кына карап алды:

— Федько, ә, Федько!

Федько сискәнеп киткәндәй булды һәм авыр гына урыныннан торды. Командир үзе дә егеткә нидер булганын сизеп алды, ахрысы, шунда ук йомшарып, аңа утырырга кушты. Теге аңламыйчарак торгач, иңбашыннан басып диярлек утыртты һәм үзе дә каршысына утырды.

— Йә, сөйлә, ни булды?

Федько, кызганыч кына елмаеп, аңа беравык карап торды, ләкин авызыннан сүзе чыкмады. Командир аңа иелә биреп кычкырды:

— Ишетмисеңмени?.. Мин синнән ни булды дип сорыйм.

— Әллә ни булганы юк, иптәш командир! — диде Федько, һаман шулай елмаеп кына.

— Һе, булганы юк, имеш! Мин күрмимдер шул. Бомбежкага кай төштә эләктегез?

— Станциядә.

— Китеп өлгермәдегезмени?.. Иптәшләрең кайда? Иптәшләрең кайда, дим?

— Иптәшләр... ни, төрлесе төрле якка чаптылар.

— Ә син?

— Мин машина янында калдым.

— Машинаң кайда соң?

— Машина чокырда.

— Нинди чокырда?.. Нинди чокырда, дим?

— Бомба чокырында... Машинаны барып чыгарырга кирәк, иптәш командир.

— Туктале син, Алла колы! Әйбәт кенә төшендер — ничек итеп ул алай машина бомба чокырына эләкте?

— Белмим,— диде Федько, гаепле бала сыман мөгрәнеп кенә.

— Белмим?! Ничек инде белмисең? Машинаны ташлап китмәдем дисең бит!.. Әллә киткән идеңме?

— Юк, китмәдем. То-есть, мин машинаны алып киттем.

— Шуннан... чокырга барып төштеңме?

— Юк, мин үзем чокырга барып төшмәдем.

Командир ботын чабып, урыныннан сикереп торды:

— Валлаһи, һичнәрсә аңлый алмыйм, хет суегыз! Писарь, син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?

Мин дә, билгеле, бер нәрсә аңлый алмыйча утырам, шуңа күрә иңбашымны гына җыерып куйдым.

— Ну, Федько, Федько! — диде командир, башын чайкап, аннары яңадан шоферның каршысына утырып, ничек тә сабыр булырга тырышып, тагын сораша башлады: — Кара әле, Федько, син башлы егет бит, сөйли дә беләсең, әйбәт кенә аңлат әле, зинһар!.. Ничек булды соң, ничек итеп син машинаң белән бомба чокырына барып төштең: наконец, ничек соң син үзең исән калдың?..

— Менә шуны, иптәш капитан, мин үзем дә белмим шул! — диде Федько, кулларын җәеп.

Командир башын учлады:

— Йа Хода, тагын «белмим»!.. Ә кем белә соң? — диде ул, кинәт кычкырып.— Син бит шунда булгансың, син бит әле исән калгансың; һич югы, баштарак ни булганын беләсеңдер, хәтерлә!

Федько, чыннан да, нидер хәтерләргә тырышкандай, кашларын җыерып уйланып торды, бүреге белән тагын битен сөртеп алды, шуннан соң өзек-төтек сөйләргә кереште:

— Без азыкларны төяп бетергән идек инде, шул чакта фашист козгыннары килеп чыктылар. Бомбежка башланды... Карыйм, берәү дә юк, качканнар... Мин — ма-

шинага... Тиз генә газ бирдем... Куам, куам, ә бомбалар төшәләр. Ну, каядыр артта. Мин инде ычкындым дип уйлаган идем.

Федько сүзеннән туктап, көйгән иреннәрен ялап алды. Ахрысы, җеп очын югалтып җибәрде, озак кына дәшми торды.

— Йә, шуннан? — диде командир, сак кына.

— Шуннанмы? Шуннан, әллә уңда, әллә сулда, әллә артта, ну, якында гына, бик яман бомба шартлады. Кинәт дөнья караңгыланып китте, мин дә бер мәлгә аңымны югалттым. Күпме вакыт узгандыр инде, бер заман күземне ачып җибәрсәм, мин бик әйбәт кенә кабинамда утырам, имеш! Даже мотор да эшли!.. Ну, алдымда юл да юк, өйләр дә юк: вообще, бер нәрсә дә юк, бары тик тау шикелле өелеп яткан кара җир генә... Шуннан, бу ни соң, дип чынлабрак карасам, ул тау түгел икән, ә тирән генә бер чокыр икән. Машина менә шул чокыр төбенә арты белән терәлеп, алгы тәгәрмәчләре белән югары карап тора, имеш!.. Нинди чокыр, кайдан килгән чокыр — һич белмим, аңламыйм, шабаш!.. Ә алда чокыр юк иде — мин моны яхшы беләм. Булса, мин ул чокырга кадалып барып төшкән булыр идем, үзем дә, конечно, исән калмас идем. Ну, күрәсез, минем бөтен җирем дә үз урынында, аяк-куллар да, тик баш кына яман шаулый.

— Һәм колакларың бераз тыгылган, шулаймы?.. Ә машина ничек?

— Машина да бөп-бөтен, тырналган җире дә юк.

— Әллә нәрсә бу, шайтан белсен! — диде командир, тиз генә урыныннан торып.— Барып карамыйча булмый. Әйдә, Федько, киттек!

Федько тагын үзенекен кабатлады:

— Иптәш командир, машинаны чыгарырга кешеләр кирәк, мин шуның өчен генә кайттым.

— Писарь,— диде командир миңа,— давай, ротада калган кешеләрне җый да алып бар. Мондый көнне кеше җиткереп буламы соң, барысы да тимер юл буенда.

— Була, иптәш командир! — дидем мин дә җитез генә. Чокыр төбендә утырган машинаны барып карау минем өчен дә кызык иде, билгеле.

Тиз арада ротадагы итекчене, тегүчене, кладовщикны, поварның берсен, тагын бер-ике очраган кешене җыеп, станциягә таба алып та киттем. Таш юл буйлап ашыгаашыга атлыйбыз. Юл туп-туры, шуңа күрә без ерактан ук алда җыелышып торган кешеләрне күрдек. Килеп җиттек, һәм безнең күз алдыбызда менә нинди күренеш ачылды: нәкъ юл уртасында кечерәк кенә өй кереп уты-

рырлык түп-түгәрәк, тирән бомба чокыры, һәм шул чокырның авыл яклап стенасында, тирес коңгызы шикелле, Федько машинасы ябышып тора. Нәкъ Федько үзе әйткәнчә, койрыгы белән чокыр төбенә терәлгән, ә алгы тәгәрмәчләре белән югарыга караган... Һич шик юк ки, бу хәзер генә булып узган бомбежка эше: юлга зур фугас бомбасы төшеп шартлаган, һәм... машина шуның чокырына төшеп утырган! Әмма ничек итеп ул бу чокырга эләккән — моны һич кенә дә аңлап та, күз алдына китереп тә булмый иде. Чынлап та, әгәр дә мәгәр, әйтик, бомба чабып барган машинаның борын төбенә төшсә, ул чагында машинаңны йөге-ние белән әллә кая ыргытып бәрер иде. Индеерактарак төшеп шартласа, ул чагында Федько машинасын йә туктатып өлгерер иде, яки, өлгерә алмаса, чокырга машинасының борыны белән кадалып барып төшкән булыр иде. Ә бит машина һавага карап утырып тора! Әллә чокырны очып чыга яздымы икән?.. Ләкин моңа да ышануы читен, чөнки ул чагында йөк төягән машина ватылмыйча калмас иде. Ә ул, шайтан алгыры, бөп-бөтен, бер генә дә сынган-ниткән җире юк!.. Безнең командир үзе чокыр комын ишә-ишә төшеп, машинаны кат-кат әйләнеп, астын-өстен дигәндәй, җентекләп карап чыкты, әмма бер бөртек ватылган җирен таба алмады. Федько да шуны ук әйтеп тора: машинага берни дә булмады, чокырдан чыгаргач та үз ходы белән китәчәк, ди. Аннары иң хикмәтлесе шул: Федьконың әйтүенә караганда, бомба чабып барган машина алдында шартламаган, ул моңа чукына-чукына ышандыра, ул әйтә: бомба кайдадыр артта шартлады, ди. Димәк, машина алда торган чокырга түгел, артта калган чокырга барып төшкән була! Әллә нинди пәри табышмагы бу!..

Кыскасы, сүз күп булды, кычкырдылар, бәхәсләштеләр, көлделәр, әмма ләкин бу табышмакның ачкычын табучы булмады. Тик иң ахырдан безнең командир, аптырагач-йөдәгәч, башын кашып, сорау рәвешендә генә әйтеп куйды:

— Ә бәлки, шартлау дулкыны машинаны үзенә тартып алгандыр, ә?.. Федько, син шуны сизмәдеңме?

— Кайдан сизим, иптәш командир? — диде Федько, хәтере калгандай.— Әйттем ич инде, шартлады, мин бер мәлгә аңымны югалттым, күземне ачып җибәрсәм — чокыр төбендә утырам, менә шул.

— Бик ипле төшеп утыргансың,— диде командир, көлемсерәп.— Бомба үзе сине шулай сак кына төшереп утырткан инде, чын-чын!

— Булмас ла, иптәш командир,— диде шунда солдат-

лардан берәү.— Чабып барган машинаны кире артка тартып алыр өчен, ай-һай, нинди көч кирәк!

— Ярты тонналы фугаскада көч җитәрлек, паровозны да аударып ташлый ул... Күргәнегез юкмыни?.. Монда хикмәт, минемчә, кире араның ераклыгында, ягъни бомба шартлаган чакта машина аңардан нинди ераклыкта булган. Әйтик, бик якын шартласа, машинаны чәлпәрәмә китерер иде,ерактарак шартласа, бәлки, аңа берни дә булмас иде, ә менә ул, дуңгыз түшкәсе, шундый бер төгәл ераклыкта шартлаган ки, безнең геройны машинасы-ние белән үзенең чокырына иппләп кенә суырган да алган... Нигә, булмас дисезме?.. Ә башкача моны ничек аңлатырга?.. Физика законнарын кем белә, писарь, син белмисеңме?..

— Белмим шул,— дидем мин, кыенсынып кына.

— Белергә кирәк,— диде командир, өзеп кенә.

Ләкин ничек кенә булмасын, командирның хәзер генә әйткәннәре, чынмы-ялганмы, физика законнарына туры киләме ул, юкмы, әмма Федько юлыккан бу гаять сәер хәлне берникадәр аңлаткан кебек булды. Машинаның йөген бушаттык, аннары бер унбишләп кеше аны чокырдан өстерәп тә чыгардык. Йөкне яңадан төягәч, Федько кабинасына утырып, «үз ходы белән» китеп тә барды.

...Әмма ләкин дөньяның кайчак озак кына тынып торган чаклары да була иде. Атналар буенча күк йөзе буш, кояш та йолдызлар гына, дошманның бер генә самолеты да өстебезгә ажгырып килеп чыкмый, тик бик сирәк кенә, бик биектән немецларның безнекеләр «рама» дип атаган разведка самолеты гына, тилгән шикелле, каранып уза,— безнең зенитчылар күп вакыт аңа ут та ачып тормыйлар... Шушындый ук тынлык һәм тынычлык алгы сызыкта да хөкем сөрә булса кирәк, ул тарафтан да туплар гөрелтесе ишетелми, яралылар агылып кайтмый, тик ул тирәләрдә ишле каргалар көтүе генә әйләнә... Җир өстенә әкренләп талгын-ялкау тынлык җәелә... Кеше һәм табигать икесе бергә вакытлыча гына булса да, хәвеф-хәтәрдән арынып, оеп, рәхәтләнеп дигәндәй, бер ял итеп ала. Солдат үзалдына әкрен генә мөгрәнеп, җырлап йөри башлый, бик дикъкать белән ертык-сүтеген тегәргә тотына, чолгауларын салкын суда юып киптерә, аулак урын табып, ялгызы, ашыкмыйча гына хатлар яза. Билгеле, ул рәхимсез сугышны бер генә минутка да онытып тормый, ләкин сугыш үзе дә бу чакта каядыр чигенеп, посып торган шикелле булып тоела аңа... Ул аның турында уйламаска тырыша, хыялы-күңеле

белән икенче дөньяга — кан да, үлем дә булмаган, печән, иген өлгергән, хатынлы, мунчалы, бала-чагалы ерак дөньяга күчә...

Мин үзем бу килеп-килеп булгалый торган аз гына моңсу, аз гына сызландыручан, әмма бик кадерле, бик тансык тынлыкны каравыл хезмәтенә күчкәч, аеруча нык тойдым. Шуны әйтергә кирәк, елдан артык писарь булып утырып, мин бу эштән бик туйган идем. Бәйдәге эт шикелле, бер урында бөкрәеп утырасың да утырасың, теләгән җиреңә ни чыгып китеп булмый, ни солдатлар белән аралашып булмый, ә солдат бит ул үзе кебек солдат белән ышкылып яшәргә ярата. Аңа әледән-әле кемгәдер эчен бушатырга кирәк. Ә мин күп вакытта ялгыз, рухым, җаным белән дигәндәй, ялгыз... Инде яныма керүчеләр булса, алар дәрәҗәләре белән миннән өстен офицерлар — үзләре башлап сөйләшсәләр генә, минем сөйләшергә хакым бар. Дөрес, алар арасында бик гади, бик әйбәтләре очрый иде. Бер дә үзләрен өстен тотмыйча, тиң күреп сөйләшәләр, тәмәкеләре белән сыйлыйлар, хәтта берәр кайгылары булса, анысы белән дә уртаклашалар иде. Шундыйлардан берсен — азык-төлек складының начальник ярдәмчесе Николай Булгаков дигән өлкән лейтенантны һич тә онытасым юк. Көне-төне аяк өстендә чапкан бу кырыклар тирәсендәге түгәрәк битле, зур моңсу күзле кеше минем янга кереп, тәмәке пыскытып, әзрәк ял итеп утырырга ярата иде. Баштарак безнең арада юньләп сөйләшү дә булмый иде. Ул утыра, мин утырам, ник бер сүз дә әйтми бу дип, эчемнән генә пошынам, ләкин сизәм: телсез утыруы мине санламаганнан булмаска тиеш. Йә бик арыган ул, яки инде берәр төрле зур кайгысы бар. Соңрак, билгеле, аның теле чишелде. Ленинградтан икән ул үзе. Путилов заводыннан. Бабасы да, атасы да шунда эшләгән, үзе дә шуннан армиягә киткән... Ленинград фаҗигасен бик авыр кичерә икән, ләкин ул турыда күп сөйләргә яратмый. Хәер, аның хәлен болай да аңлап була — телдән әйтмәсә дә, сүз бит аның туып үскән бишеге — аңа иң якын, иң кадерле, иң газиз шәһәре турында бара. Ул үзе дә, Ленинград турында мин бер генә минут та уйламыйча тора алмыйм, ди. Шулай булгач, моны сөйләп бетерү мөмкинме соң? Һәм кирәкме ул?

Ә беркөнне Булгаков минем янга килгәч, гадәтенчә, озак кына дәшми утырганнан соң, кесәсеннән өч почмаклы бер хат чыгарды. Ләкин укып тормыйча аңлатып кына бирде. Бу хатны агасының ундүрт яшьлек кызы язган икән. Хаттан күренгәнчә, кызның әтисе дошман шәһәрне тупка тоткан чагында, заводка барышлый һәлак

булган, әнисе ачтан үлгән, әбисе дә шулай ук, ә Юрка, кызның уналты яшьлек абыйсы, тоткан да, мин передовойга барам, дип чыгып киткән, имеш. Исәнме-түгелме, анысын белми икән. Ә япа-ялгыз калган балаларны «эвакопункт»ка җыеп алганнар, тәннәрендә җаны булганнарны әкренләп шәһәрдән озаталар икән. Бу үсмер кыз да шул «эвакопункт»та үз чиратын көтеп ята икән.

— Җитеп торырмы? — диде Булгаков, сәер бер җансыз тавыш белән.

Мин дәшмәдем.

— Ә шулай да,— диде ул бераздан,— мин сезгә хатның бер генә төшен укып күрсәтим әле.

Хат аның кулында әкрен селкенә, әмма тавышын сынып китүдән саклагандай, сүзләрне юри хиссез итеп, өзепөзеп кенә укый: «*Абыем, син мине күргәч,*— дип яза кыз, балаларча беркатлылык белән,— *танымассың да инде. Мин бик үзгәрдем, әбиләр төсле булдым. Тук булу нәрсә ул, оныттым инде... Төшемдә гелән генә тәмле итеп ашаганымны күрәм. Кулыма китап эләксә, аның да ашау турында язган җирләрен генә эзләргә тотынам...*»

— Җитәр булмаса,— диде Булгаков, башын күтәрмичә генә, һәм хатын ашыкмыйча гына кире өч почмак итеп бөкләде.

Без шактый вакыт сүзсез утырдык. Эчемнән генә бик борчылып, бәлки, аны юатырга кирәктер, дип уйлыйм. Ләкин куркам, аның ярсу, газап, хәсрәт тулы бәгыренә кагылудан куркам. Һәм сизенәм: аңа кызгану кирәкми, Гитлер башына нәләт яудыру да кирәкми — чөнки болар сүз, бары сүз генә! Чөнки бит ул үзе дә әнә бер генә сүз дә әйтми, бөтен ачык җирен яшергән керпе шикелле йомылып, тырпаеп тик утыра. Кагылып кара син аңа!..

Тик китәргә дип урыныннан торгач кына ул, сабыртыныч кына әйтте:

— Рапорт бирдем, китәм! — диде.

Мин аның кая, ни өчен китүен шунда ук аңлап алдым һәм бары:

— Җибәрәләрме соң? — дип кенә сорадым.

— Җибәрми карасыннар! — диде ул, әкрен-хәтәр итеп.

Әйе, аны хәзер тотып булмаячак иде. Шуны да әйтергә кирәк, ул элек тә үз эшеннән бер дә канәгать түгел иде. Азык-төлек тирәсендә ямьсез эшләр һәрвакытта күп була. Бигрәк тә көн саен вагонлап килеп торган һәм ачык кырга бушатып өйгән азыкны саклау бик читен эш. Бомбежкадан да харап була ул, шул хәлдән файдаланып урлау, читкә озатулар да булгалап тора, һәм гомумән әрәмшәрәм итүләр, кызганычка каршы, җитәрлек. Ленин-

град фаҗигасен белеп торган Булгаковның моңа, әлбәттә, җаны бик сыкрана иде. Хәтта кайбер зуррак начальникларның ашау-эчү мәсьәләсендә чамасыз кылануларына да аның ачуы килә иде. (Үзе ул солдатлар өчен пешерелгән казаннан гына ашап йөри иде.) Кыскасы, бик гадел, намуслы һәм үтә тыйнак бер кеше иде ул, мәрхүм!

Киткән чакта ул үзенең тәмәке уты төшеп, бер чите янган одеялын миңа: «Мә, сержант, инде син ябынып ят!» — дип биреп киткән иде. Озак та үтми, без аның алгы сызыкта һәлак булуын ишеттек.

Әйе, кешеләр бер-берсеннән бик нык аерыла. Писарь булып утырганда миңа аларның төрлесен күрергә туры килде. Кеше язмышы — кеше кулында. Фронт шартларында солдат өчен бу аеруча шулай. Менә минем монда писарь булып утыруым һич тә үземнән түгел. Кемдер куйган иде, кемдер чыгарып та җибәрергә тиеш.

Безнең ротада ни сәбәптәндер командирлар еш алышынып торды. Шул ел ярым вакыт эчендә миңа бер-берсен алыштырган биш командирга буйсынып эшләргә туры килде. Биш командир — биш характер дигән сүз, һәркайсына җайлашырга, көйләнә белергә кирәк иде. Кайберсе белән ара бик әйбәт булып китә, ул сиңа писарь итеп кенә түгел, кеше итеп тә карый. Менә бу Федько вакыйгасын сөйләгән чактагы командирыбыз, капитан Баранов, әнә шундыйлардан иде. Миннән күп белүне таләп итсә дә, ул бервакытта да мине кимсетмәде, юккабарга кыерсытмады. Киресенчә, миңа үзенең якын бер ярдәмчесе итеп карый иде (һәм дөрес карый иде, чөнки писарь аңа рота хәле турындагы мәгълүматларны көн саен әзерләп кенә тора), сораша-киңәшә иде, хәтта еш кына: «Бел, син писарь гына түгел, ә ротаның штаб начальнигы!» — дип, минем дәрәҗәне күтәреп тә җибәргәли иде. Ахрысы, шуңадыр, ул үзе үк миңа ара-тирә командирлар паегыннан өлеш тә чыгара иде, кием-салымның да яхшырагын бирә иде. Билгеле инде, мондый командирга эшең дә, җаның да жәл түгел.

Ләкин аны да бездән ни өчендер алдылар. (Строевой командир дип хәрәкәттәге дивизиягә күчерделәр булса кирәк.) Инде аның урынына килгән командир бөтенләй икенче кеше булып чыкты. Бу да капитан иде, ләкин интендант хезмәте буенча, ягъни хәрби тәэминат кешесе. Фамилиясе — Сидоров иде. Шушы Сидоров ротага килүе белән үзенең үтә формалист, шунлыктан аеруча дорфа икәнлеген күрсәтеп өлгерде. Икенче көнне үк ул минем башымдагы бүреккә бәйләнә башлады: янәсе, ни өчен әле минем башымда командирлар бүреге?.. Кем бир-

де, кем рөхсәт итте?.. Мин ни әйтергә белмичә аптырый калдым, чөнки моңарчы бер генә командирның да, шулай ук безнең ротага килеп чыккан бер генә зур начальникның да минем бүреккә бәйләнгәне булмады. Әллә юри шаярта инде иптәш капитан дип, мин бары елмаеп кына куйдым. Бу аның ачуын китерде.

— Мин сездән сорыйм,— диде ул, тавышын күтәрә төшеп.— Кем рөхсәт итте сезгә командирлар бүреге киеп йөрергә?

— Элекке командир,— дидем мин, каушамыйча гына.

— Нәрсә ул, армия тәртибен белми идемени?..

— Юк, белә иде, ләкин ул үзе миңа бу бүрекне киярга кушты.

— Димәк, белмәгән. Армиядә сержантка командирлар бүреге не положено. Барыгыз, хәзер үк солдат бүрегенә алыштырыгыз.

Мин бераз дәшми тордым, аннары кинәт туган үҗәтлек белән әкрен генә:

— Әгәр бармасам? — дидем.

Командир, колакларына ышанып бетмәгәндәй, миңа бик сәерсенеп карады. Күрәсең, минем тарафтан мондый тискәрелекне һич тә көтмәгән иде, сержант командирына каршы сүз әйтсен әле!.. Моның өчен бит... Һәм ул, ниһаять, корыч тавыш белән өзеп әйтте:

— Бармасагыз, сезгә биш тәүлек гауптвахта!

Әлбәттә, буйсынырга кирәк иде, хәтта иң мәгънәсез боерыкка да буйсынырга кирәк, чөнки рәхимсез кагыйдәсе шул... Ачуымны һәм гарьлегемне йотып дигәндәй, мин үзебезнең старшинага киттем һәм сары тышлы, йомшак мехлы бик әйбәт бүрегемне катырак та, салкынрак та соры солдат бүрегенә алыштырып кайттым. Шулай да мин аны кырын салыбрак кидем. Әйдә күрсен, солдат бүреген дә йөртә беләбез без!

Билгеле инде, башта ук безнең арадан мондый йолкыш кара мәче узгач, килешеп, тату гына эшләү мөмкин булмаячак иде. Шуңа күрә мин бу писарьлык эшеннән ничек кенә булса да ычкынырга ниятләп куйдым. Дөрес, озак та үтми иптәш командир минем үзенә никадәр кирәкле кеше булуымны белеп алды. Һәм, әйтергә кирәк, миңа карата бераз йомшара да төште. Ләкин барыбер писарьлыктан китү уе миндә кире сүрелмәде инде, чөнки ике арадагы боз калды, боз эреп бетмәде. Моны мин генә түгел, командир үзе дә бик яхшы сизә иде шикелле... Тик миңа авыр, миңа гел йомылып та сагаеп кына торырга туры килә. Ә аңа нәрсә, аның эче пошмый миңа, ул бит үзен һәрвакытта хаклы дип санарга өйрәнгән кеше.

Минем бәхеттән озакламый безнең ротага госпитальдән чыккан бер төркем солдатлар килде. Алар арасында элек укытучы булган Спиридонов фамилияле, миннән олырак бер Пенза кешесе дә бар иде. Командир аны минем янга утыртты. Бәлки ул моны билгеле бер максат белән эшләгәндер, ләкин мин моңа һич тә көенмәдем. Киресенчә, икенче писарьның булуы миңа моннан китү өчен юл гына ачачак иде. Шул Спиридонов белән без икәү бер ай ярым чамасы тату гына эшләгәннән соң, мин, ниһаять, командирга мине каравыл хезмәтенә күчерүен сорап рапорт бирдем.

Командир, рапортка күз йөртеп чыкты да, миңа:

— Нигә китәсең? — дигән булды.

Мин, аягүрә баскан килеш, бөтен шартын җиткереп:

— Иптәш командир,— дидем,— үзегез дә беләсез, безнең ротада штат буенча бер генә писарь булырга тиеш. Димәк, безнең беребез монда артык. Шуңа күрә мин сездән башка эшкә күчерүегезне сорыйм.

— Ә Спиридонов үзе генә эшне алып бара алырмы соң?

— Һичшиксез!.. Иптәш Спиридонов шәп писарь булачак!

Шуннан соң командир, бүтән бер сүз әйтмәстән, минем рапортка: «Боеприпаслар складының каравыл взводына җибәрергә»,— дип виза салды. Әлбәттә, мин аңардан рәхмәт сүзе көтми идем, ләкин шулай да ул миннән күңел өчен генә: «Кая күчәргә телисез?» — дип сорарга тиеш иде кебек. Безнең рота саклый торган төрле складлар күп, әмма шулар арасында иң хәтәре әнә шул боеприпаслар склады иде... Хәер, мин моңа артык борчылмадым, чөнки, беренчедән, минем шикелле солдат кеше, язмыштан узмыш юк, дип, үзен юатырга өйрәнгән (чынлап та кемне кайда нәрсә көткәнен белеп буламыни?), икенчедән, боеприпаслар складында төрле милләт кешеләре күбрәк иде. Командирлары да миңа яхшы таныш кыргыз егете — Нугайбәк Кулибаев дигән лейтенант...

Әнә шулай ансат кына каравыл взводына күчеп, мин постка да йөри башладым. Постта торуның нәрсә икәнен сөйләрмен әле, ләкин хәзер бер уңайдан шуны әйтеп калырга кирәк. Взводта командир ярдәмчесе һәм разводящий булып Акшалов дигән казакъ егете йөри иде. Бу — утны-суны кичкән яшь, тәҗрибәле солдат, каравыл хезмәтен дә яхшы белә, ләкин каты яраланудан соң бер аягы бөтенләй бөгелми диярлек. Бик азапланып кына йөри, ә разводящийның бөтен эше аяк өстендә — чокырлы-чакырлы сукмакларны аңа көндезен генә түгел, төннәрен дә ничәмә тапкыр әйләнергә туры килә. Әлбәттә, Акша-

ловка авыр, бик авыр булгандыр. Менә шунлыктан лейтенант Кулибаев, озак та үтмичә, мине, сержант та диптер инде, үзенә ярдәмче (ягъни помкарнач) һәм разводящий итеп куйды. Ә Акшаловны солдатлар торган землянкага даими кизү (дневальный) итеп билгеләде. Һәрбер казакъ баласы шикелле, ул да бик оста аш пешерүче булып чыкты.

Без җимерелеп беткән бер зур гына шәһәр читендә торабыз. Кышкы айларда бу шәһәр өчен бик каты сугышлар барды. Адәм башкайларын монда күп салдылар — шәһәр әйләнәсендәге ачык кырда безнекеләрнең үлек гәүдәләре сибелеп ята, ә шәһәрнең эче-тышы немец үлекләре белән тулы... Кышын аларны җыеп та бетерә алмадылар, күбесе кар астында калды.

Хәзер менә яз башы. Гаҗәеп якты, җылы-йомшак көннәр. Күк йөзе бер офыктан алып икенче офыкка чаклы чалт аяз — бүрек кадәр генә болыт та юк, ичмасам! Ә дәртләнеп йөзгән яшь кояшка без яшьле күз кырые белән генә карап алабыз: ашыкма, китмә син безнең өстән, диясе килә үзенә... Рәхәт безгә, тән генә түгел, җан эри, җан һәртөрле михнәт-газаплардан арына кебек... Ә соң күптәнме әле без бу аяз күктән курка-шомлана идек, безнең өчен болытлы-караңгы көн яхшырак иде. Аяз көн булдымы — немец самолетларын көт тә тор. Еш кына безнең өстебезгә кояш нурлары белән бергә үлем ява торган иде. Ә хәзер инде алай түгел. Куркудан туйдык, ахрысы, куркасы килми башлады. Аннары немец авиациясе соңгы айларда, кыйналган эт шикелле, койрыгын бөтенләй кысты диярлек. Баштагы кебек азына, котырына алмый инде ул. Бик сирәк кенә килеп чыккалый, анда да күбрәк кире борылып сыза. Сызарга мәҗбүр.

Әйе, адәм баласы сугышның үзен дә, аның дәһшәтләрен дә онытып торырга ярата. Хәтта менә бу җимерелеп, ишелеп беткән шәһәр дә аны ул хәтле шомландырмый һәм борчымый кебек. Чөнки шәһәр өстеннән сугыш өермәсе котырынып узган инде, ул да үзенең коточыргыч хәрабәләре белән язгы кояш нурларында тын гына коена, аның да исән калган почмакларына, ышыкланып торырлык ярыкларына, бүрәнә, кирпеч астындагы подвалларына кешеләр кайтып керергә өлгергән — шунда алар нидер кымшана, кага-суга, чүп-чардан тазарта, яңадан тамырланыр, яшәр өчен тырышып ята.

Бу хәрабәләр әйләнәсендә, бу патрон гильзалары, бомба, снаряд кыйпылчыклары тулып яткан җирдә яңадан терелүнең гаҗәеп билгеләрен күрергә мөмкин. Шуның бер генә мисалы. Лейтенант Кулибаев башта мине тимер

юлдан шактый читтә ялгызы гына торган бер иске сарай янына постка куйган иде. Сарайга немецлардан калган снаряд, миналарны җыеп тутырганнар — мин шуларны сакларга тиешмен. Менә шул постка бара торган юл буенда, дүрт-биш адым гына читтәрәк, кар астыннан чыккан өч немец солдатының үлек гәүдәләре аунап ята. Мин көн дә аларны күреп узам. Беренче күрүемдә, ихтыярсыздан чирканып, бик җирәнгән идем — алар инде бик ямьсез бүртенеп чери-таркала һәм төчкелтем мәет исе тарата башлаганнар иде. Безнең бәгырьләр бик каткан, фашистлар солдатын һич кызгану юк, ләкин шул солдатның үлек гәүдәсен күргәч, ул да бәхетсез бер адәм баласына әйләнеп кала. Чиркана-чиркана булса да, ирексездән үзен кызганып узасың... Ә берничә көннән соң, ни күрим, боларның чатлы-ботлы яткан гәүдәләре тирәсеннән, күм-күк битләренә ышкылып, ямь-яшел үлән баш калкытып чыгып килә!.. Ничектер бик серле дә, бик мәгънәле дә булып тоелды миңа бу, асылда, бик табигый күренеш. Җитмәсә, якты кырлар өстендә сабан тургайлары кояшка каршы талпынып-талпынып өзлексез сайрыйлар!.. Чит-ят җирләргә килеп башларын салган, череп яткан шул бичараларның үзләренә дә узышлый: «Йә, камрадлар, безнең Рәсәйдә яз матурмы?» — дип дәшәсе килеп китә.

Әмма ләкин сугыш искиткеч явыз, мәкерле нәрсә икән. Кайда гына сагаламый ул безне! Менә шундый тургайлар сайрап торган кояшлы көннәрнең берсендә, безнең Ефимов дигән солдатыбыз яшь үлән каплап киткән минага туры килеп, һәлак булды да куйды. Ефимов транспорт взводында ат йөртүче (ездовой) булып эшли иде. Беркөнне командир аны, атын җиктереп, шәһәр читендәге үлекләрне җыярга чыгарып җибәрә. Аның белән тагын ике солдат та була. Алар юлсыз-нисез кыр буйлап йөриләр, берничә үлекне табып, арбаларына да күтәреп салалар. Ефимов, дилбегә тотып, гел арбасы кырыннан бара, ә теге ике солдат бераз арткарак калып, үзара сөйләшә-сөйләшә атлыйлар. Шулай барган чакта, кинәт коточкыч шартлау!.. Тузан-төтен... Арттарак килгән ике солдат, җил очыргандай, тәгәрәшеп китәләр. Ләкин аларга әллә ни зур зыян булмый — җиңелчә контузия генә алалар. Бераздан торып карасалар,— бу ни әкәмәт? — ат тора, ә арба юк! Арба, өстендәге үлекләре белән бергә, ваткаланып очкан... Бер читтәрәк ярты бите, ярты башы актарылган Ефимов җирдә чалкан ята,— хәтта кулыннан дилбегәсен дә ычкындырмаган. Ә ат тора, атка берни дә булмаган. Тагын үзенә күрә бер хикмәт! Ничек кенә булган

соң бу болай?.. Теге ике солдат, ат янына килеп, тикшеребрәк карагач, ниһаять, беләләр: немецның танкка каршы куйган минасы өстеннән ат басмыйча уза, арбаның алгы тәгәрмәче дә аңа ничектер туры килми, ә арткы тәгәрмәчнең берсе (Ефимов атын бераз каера төшкәндерме инде) минага килеп тә менә. Көчле шартлау, һәм кеше бер мизгел эчендә һәлак тә була. Йә, нәрсә әйтәсең? Язмыш... Ләкин теге ике солдат өчен дә язмыштыр инде бу, әмма бәхетле язмыш, чөнки, үзләре дә белмәстән, арткарак калып атламаган булсалар, алар да шунда беткән булырлар иде... Әнә шулай көтмәгәндә сискәндереп, сугыш үзен вакыт-вакыт безнең исебезгә төшереп куя. Әйе, чүпләнмичә калган миналар очрый әле, очрый...

Мәрхүм Ефимовны мин күптән белә идем. Бу ротага без бер вакыттарак килеп эләккән идек. Ул гәүдәгә базык кына, холкы белән дә басынкы-юаш кына бер кеше иде. Очрашканда миңа: «Исәнме, писарь!» — дип дәшмичә калмый иде. Үзе дә шушы якныкы иде. Моннан бер-ике атна чамасы элек кенә аның янына хатыны да бер генә кичкә килеп киткән булган. Ирен әйбәтләп сыйлар өчен хатын букчасына күп кенә күчтәнәч тутырып, хәтта, чүпрәккә урап, агач бөке тыккан ике шешә самогон да китергән икән... Транспортчылар землянкасында унбишләп кеше тора иде. Ләкин солдатлар ул кичне, барысы да дәррәү ятып, яман гырылдап, бик каты йокларга тырышканнар... Шул караңгы землянканың бер почмагында Ефимов хатыны белән тавыш-тынсыз гына утырып, төнне уздырып җибәргән. Авыр туфрагы җиңел булсын, бик тыйнак, кыюсыз кеше иде, мәрхүм!

Җитеп торыр. Солдатның хәтер сандыгында бик күп нәрсә саклана, барысын да сөйләп бетереп булмас, хикәянең башына кучик. Әйе, менә без Латвия җирендә. Машиналарда, йөкләр өстенә утырып, тирә-якны бик ачык күзәтеп килдек, шул сәбәпле латышлар җирен ничектер бик тиз танып алдык. Безнең Рәсәй җирләренә бер дә охшамаган икән. Монда бөтен нәрсә — кырлар, басулар, урманнар — күләме белән шактый кечкенә икән. Шәһәрләре дә кечкенә, җыйнак кына... Бездәге кебек зур-зур авыллар бөтенләй юк, бары бер йортлы, күп булса, ике йортлы утарлар гына. Алар бер-берсеннән чакрым-чакрым ярымда ялгыз гына утыралар. Бер утар — бер хуҗалык булса кирәк. Арада бик тазалары очрый: өе дә таштан, каралты-куралары да таштан, түбәләре калай белән ябылган... Искергән, тузганнары да күренә — болары инде агачтан, түбәләре дә каралып беткән дранча гына. Һәммәсенең күпме-азмы иген басуы, печәнлеге,

бакчасы шул утар тирәсендә — әллә кая китеп йөрисе юк. Барысы да якында, кул астында гына. Терлекләре дә шунда гына йөриләр. Әйтергә кирәк, бу утарлар безгә башта сәер-кызыклы да һәм ничектер күңелле-ямьле дә булып күренде. Аларның хуҗалары үз көйләренә, үз җайлары белән эшләп, дөнья ыгы-зыгысыннан читтә, туктыныч кына яшиләрдер кебек тоелды. Ләкин безнең солдатларның бу утарларга карап телдән әйткәннәре бөтенләй икенче нәрсә турында булды. Чын гаҗәпләнү белән алар:

— Боларны колхозга ничек итеп оештырырлар икән соң? — диештеләр.— Барысын да бер урынга җыярлар микән?

Билгеле, алар фикеренчә, бу җирләргә яңадан совет власте кайткач, колхоз да булачак, булмыйча калуы мөмкин түгел... Аннары тагын бер нәрсә безне гаҗәпләндерде: монда шактый терлек күренә иде. Һәрбер утар тирәсендә сыерлар, башмак таналар, сарыклар йөри. Бигрәк тә сарыкларны күргәч, безнең казакъларның исләре китте:

— Эй-бай, монау латышта куйлар калган гой!

Искитмәслек тә түгел, чөнки немец аяк басып киткән Рәсәй авылларында терлек бөтенләй беткән диярлек иде. Берән-сәрән сыер күренгәли, аз-маз дуңгыз бар, әмма сарык юк, сарыкларны ашап бетергәннәр. Ә монда һәрбер утар тирәсендә унлап, унбишләп сарык күренә. Чынлап та гаҗәп иде бу... Ләкин безнең солдатлар төрлечә юрап карасалар да, бу хәлнең серенә, билгеле, төшенә алмадылар.

Безне кечкенә бер станциядән ике километр чамасы читтәрәк торган урман буена китереп туктаттылар. Хәрби кирәк-яраклар склады шушы урман эчендә булачак икән. Склад кешеләре бирегә килеп урнашканнар иде инде. Без дә тиз генә урнашу хәстәренә керештек. Нарат, каен, усак аралашып үскән бу урман шактый җепшек, сазлыклы икән — торыр өчен шәп урын түгел. Җире калын юрган кебек йомшак, йөргәндә аяклар батып-батып китә. Мүк җиләге күп булырга тиеш монда. Ә менә землянкаларны кайда казырга? Немецлардан калган землянкаларга очрасак, безнең эш бик ансатлаша торган иде. (Немец землянканы гадәттә таза, иркен итеп сала.) Мина-мазар калдырып китмәгәнме дип тикшергәннән соң, шул землянкаларны немецларның төрле чүп-чарыннан тазартып, әзер «өйгә» генә керә торган идек. Чүп-чар дигәннән, ул фрицлардан нәрсәләр генә чәчелеп калмый!.. Төрле-төрле печатьле шешәләр, конфет, шоколад,

сигарет кәгазьләре, ялангач хатыннар төшерелгән журнал битләре, оятсыз фоторәсемнәр, уен карталары, сынган тарак, ватык көзге, яньчелгән фляга — тагын әллә ниләр, санап та бетерерлек түгел. Баштарак безнең солдатлардан кайберәүләр шул чүпләр арасында эзләнергә ярата торганнар иде. Соңыннан без аларны бу эштән бик нык тыйдык. Командир үзе ташландык землянканы тикшереп чыкмыйча, аңа берәүне дә якын җибәрми, ә тикшергәннән соң бөтен чүп-чарын бер төшкә өеп, үз күзе алдында яндырта. Исе дә калмасын, ди.

Хәер, бу урманда безгә андый «трофейга» бай әзер землянка очрамады. Башта казыклардан һәм агач ботакларыннан бер өч куыш ясадык, эчләренә бик әйбәт итеп печән түшәдек. Сиртмәле караватың да кирәкми!.. Соңыннан инде, бераз баш-күз алгач, калкурак урында берсе кечерәк, берсе зуррак ике землянка да казырга тотындык. Бу якларның көн саен диярлек килеп торган яңгырыннан землянкасыз һич тә котылып булмый. Ә безнең солдатлар, әйтергә кирәк, «җир сараен» менә дигән итеп салырга өйрәнделәр. Түбәсе өч кат бүрәнәдән — трактор үтсә дә ишелмәс!

Яңа урынга күчеп урнашкан чакта, эш гадәттә бик күп, бик тыгыз була. Килеп машинадан төшкәч тә, алдан билгеләнгән пост нокталарына беренче часовойларны куябыз. Аннары калганнарыбыз тиз генә үзебезгә торыр җир әмәллибез, склад территориясен әйләндереп, берничә рәт чәнечкеле тимерчыбык сузабыз, территориягә керә торган төп юлга шлагбаум белән кечкенә будка сыман нәрсә ясап куябыз... Ул да булмый, складка вагон-вагон боеприпаслар килә башлый. Шул ук чакта, шул ук боеприпасларны алгы позициягә алып китәр өчен территориягә автобат машиналары килеп тула. Бу эшкә кагыйдә буенча каравыл хезмәтендәге солдатларны алмаска тиешләр. Ләкин сугыш синең кагыйдәләрең белән хисаплашып торамыни ул. Кыска гына бер боерык, һәм без, посттан азат солдатлар, барыбыз да вагон бушатырга яки машина төяргә китәбез. Күбрәк төнлә эшләргә туры килә, чөнки төнлә хәвефсезрәк. Ә боеприпас дигәнең ул әрҗәләргә тутырган конфет түгел, боеприпас ул тимер дә корыч, аларның (мәсәлән, авыр снарядларның) берсе-берсе сиксән кило тарткannары бар, абзыкаем! Менә шуларны инде безнең гарип-гораба солдатларыбыз кара тиргә батып, көчәнә-көчәнә күтәреп төшерә яки мендерә. Кайчагында солдатның басып торырлык хәле дә калмый. Ә бит аңа яңадан постка да барырга кирәк.

Тыныч шартларда, әйтик, берәр хәрби объектны саклаучы яшь солдат постта бары ике генә сәгать тора. Каравыл хезмәтенең уставы буенча да ул шулай гына торырга тиеш. Ә монда безнекеләр тоташтан алтышар сәгать торалар. Чөнки кеше җитешми. Һәр постка бары икешәр генә кеше туры килә. Менә шунлыктан күзгә караңгы төннәрдә дә, кышкы салкын бураннарда да безнең әлеге карт солдатыбыз, мылтыгын бер иңенә асып, бер кулына алып, пост дип әйтелгән берәр агач төбендә алты сәгать буена таптанырга мәҗбүр. Утырып тору аңа рөхсәт ителми, арыса — басып кына торырга ярый. Дөрес, без аларны дүрт сәгатьтән дүрт сәгатькә дә алыштырып карадык. Ләкин солдатлар моңа риза булмадылар: кайтып тамак ялгарга да, йоклап алырга да вакыт җитми кала, алты сәгать торып, алты сәгать ял итү безнең өчен әйбәтрәк, диделәр. Үзләре шулай дигәч, билгеле, яңадан алар теләгәнчә калдырдык.

Алты сәгать постта торуның нәрсә икәнен ничек кенә аңлатырга? Разводящий буларак мин моны яхшы беләм, ләкин шуның өстенә әле минем үземә дә каравыл взводына күчкән көннәрдә алтышар сәгать постта торып карарга туры килде. Күнекмәгән кеше өчен бу искиткеч авыр хезмәт. Япа-ялгыз тик бер урында торгач, шул озын төнгә охшаган вакыт һич кенә дә үтеп бетмәс кебек тоела. Арлы-бирле йөренгән дә буласың, авыз эчеңнән генә берәр көйне дә шыңшырга тотынасың, фикерне читкә җибәрер өчен юк-бар нәрсәләр турында да уйларга тырышасың. Әмма миеңне һаман бер нәрсә — күпме вакыт үтте икән дигән уй кимерә дә тора. Баштагы ике-өч сәгатьне шулай да җиңелрәк үткәрәсең, иллә мәгәр калган яртысын үткәрә алмыйча тәмам интегеп бетәсең. Ахырга таба бөтен җирең — башың, күзең, аякларың — барысы да арый һәм шулкадәр арый ки, күзеңә инде һичбер нәрсә күренми башлый. Смена килер алдыннан, үзең сәгать теленә әйләнеп дигәндәй, калган минутларыңны гына санап торасың.

Минем беренче мәртәбә постта торуларым әнә шулай ифрат азаплы үтте. Ләкин адәм баласы, мәгълүм булганча, барысына да күнегә, һәм мин дә, билгеле, әкренләп күнектем. Тора-бара хәтта бу постта торуның үзенә күрә бер, ничек дим, уңай-рәхәт ягын да тапкандай булдым: хыял диңгезендә йөзәр өчен бик шәп урын икән! Тик вакытны гына уйламаска кирәк. Теләсә нәрсә турында уйлан, хыяллан, әнә сәхрәләр кич, диңгезләр кич, Һиндстанга барып чык, Һималай тауларына менеп төш, берәр һинд кызын урлап Питрәчкә алып кайт, иллә мәгәр ва-

кыт үтәме икән дип, һич кенә дә борчылма!.. Ә вакыт үтә ул, үтә, алты сәгать кенә түгел, алты мең елы да үтеп китә, әйдә, чәнчелсен!.. Ул да булмый, смена килә, син алмашыңны дусларча елмаеп каршы аласың — менә рәхәт ял вакыты сиңа да килеп җитә. Землянкага кайтып, дневальный борчак концентратыннан пешереп торган ашны ашыкмыйча, тәмләп кенә ашыйсың, ашап беткәч, кашыгыңны әйбәтләп ялыйсың, котелогыңны җылы су белән чайкап куясың. Аннары бер утырып, урта бармак юанлыгы итеп төргән махраны тәмен-ләззәтен белеп кенә, очына өргәләп кенә көйрәтәсең. Шуннан соң чолгауларыңны кибәргә куясың да печән түшәлгән сәкегә, шинелең белән баштан ук бөркәнеп, йокларга ятасың. Җылынып, изрәп, төшләр күрә-күрә... Нигә, рәхәт түгелмени?

Хәер, безнең картрак солдатларга каравыл хезмәтенә күнегү болай ук авыр булмагандыр, чөнки, беренчедән, аларның берсе дә минем кебек җылы урыннан бу эшкә күчмәгәннәр, икенчедән, барысы да диярлек күптән инде каравыл взводында хезмәт итәләр. Әлбәттә, алар тизрәк күнеккәннәр дә, тизрәк ияләшкәннәр дә, сыкранмыйча гына постка баралар-кайталар, әмма ләкин аларга да барыбер җиңел түгел. Бигрәк тә авыр йөк бушату эшеннән соң постка баруы һәм алты сәгать аяк өстендә торуы — ай-һай, күпме чыдамлык, күпме көч кирәк моның өчен!.. Миңа аларның берсеннән дә каравыл хезмәтен мактап яки яратып әйткән сүзләрен ишетергә туры килмәде.

Шуны да онытмаска кирәк: постта торучыга каты таләп тә куелган һәм зур хокук та бирелгән. Барысыннан элек ул, билгеле, һәр сәгатьтә, һәр минутта уяу-сизгер булырга тиеш. Караңгы төндә дә, томанлы иртәдә дә, җилле-яңгырлы көндә дә... Һәм һич беркемне янына якын җибәрмәскә тиеш. Әгәр берәр кеше якын килә башласа, һәм: «Тукта, кем килә?» — дигән сүзгә җавап бирмәсә, солдатның аны ату белән куркытырга хакы бар. Хәтта килгән кешене ул таныса да, хәтта килүче үзебезнең берәр зур начальник булса да, аңа: «Тукта, атам!» — дияргә хакы бар. Туктамаса, атачак һәм солдатка берни дә булмаячак.

Ике генә кешене ул үзенә якын җибәрә — каравыл начальнигын һәм разводящийны. Шулардан башка һич беркем, хәтта генерал, хәтта маршал да аңа якын килә алмый. (Яки килсә дә, каравыл начальнигына ияреп килә ала.) Әнә шулай каты куелган ул каравыл эше!

Яңа урында әзрәк баш-күз алдык шикелле. Безнең солдатлар үзләренә бер зур гына землянка да өлгерттеләр. Хәзер командир белән икебезгә аерым, кечкенәсен төзеп яталар. Мин бит разводящий гына түгел, командирның

ярдәмчесе дә, ары-бире киткән чагында аны алыштырам, шуңа күрә ул мине үз янында тота торган булды.

Постларның сменалары да тәртипкә салынды. Казакъларны без бер сменага тупладык. Ни әйтсәң дә, алар, бер-берсенә елышып, бергә сайрашып яшәргә өйрәнгән халык. Сменадан кайткач, бергәләп ашыкмыйча чәй эчә-эчә, озак кына гәпләшеп утыру алар өчен үзе бер хозур, үзе бер ял... Югыйсә ялгыз казакъ бик күңелсезләнә, бик моңая ул. (Бу урында шуны әйтеп үтәсе килә: Казакъстаннан килгән бер дивизиянең калдыклары кырык өченче елның башында безнең ротага да килеп эләккән иде, менә шуннан соң бездә казакълар күбәеп китте.)

Сменаларны тәүлеккә дүрт мәртәбә — иртән алтыда, көндез уникедә, кич алтыда һәм янә төнге уникедә алыштырабыз. Бусы инде минем эш. Сменага бер ярты сәгать калгач, мин солдатларга киенеп, әзерләнеп землянкадан чыгарга кушам. Төрле кеше төрлечә дигәндәй, монда да кайберсе бик тиз җыенып чыга, ә кайберләре (мәсәлән, Байәхмәтов) бик озак кыймылдый. Кабатлап, үтемлерәк сүз кушып, кычкырып та әйтергә туры килә. Ниһаять, кыштырдый торгач, барысы да чыгып бетәләр. Мин аларны сафка тезәм дә өс-башларын, мылтык-коралларын тәртиптәме дип тикшереп чыгам. Мылтыкларына сүз юк, чиста, әйбәт. (Чөнки көн саен диярлек чистартырга мәҗбүр итәбез.) Ә менә өс-башларына килгәндә инде, пөхтәлек — ташка үлчим! Кайсының төймәләре каптырылып бетмәгән, кайсының бил каешы буш — йодрык сыярлык, ә Ишмәмәт әнә пилоткасын башына аркылы кигән. Хәер, аның һәрвакытта шулай: йә аркылы, йә алдын артка кигән була — әйтерсең пилоткасы башында әйләнеп йөри!.. (Гомумән, карт солдат — каткан тал кебек, аңардан чын солдат ясавы бик читен.)

Тиешле төзәтүләрне ясаганнан соң, каравыл хезмәтенең кайбер кагыйдәләрен яңадан исләренә төшергәч, мин аларны сулга таба борам да:

— Киттек, бөркетләр! — дип, үз артымнан җилле генә ияртеп алып китәм.

Беренче пост — шлагбаум янында. Бирегә солдатның төзегрәген, үткенрәген һәм грамоталырагын куябыз, ник дисәң, шушыннан өзлексез машиналар да, кешеләр дә үтеп йөриләр. Аларның пропускларын карап үткәрергә кирәк. Шулай ук бу юлдан үтеп-сүтеп йөрүче төрле начальниклар да бер дә өзелми. Часовой монда штык шикелле торырга тиеш. Шуңа күрә бирегә ни җитте солдатны куеп булмый. Хәер, карт солдатлар үзләре дә начальниклар күзенә алай бик кереп торуны яратмыйлар.

Хәзер анда бер күзе пыяла, әмма буе-сыны бик килбәтле Шумилов дигән солдат тора. Сугышка чаклы ул кайдадыр май заводында бухгалтер булып эшләгән, имеш. Ахрысы, шуңадыр, һәртөрле кагыйдәләрне бик төгәл үтәргә ярата һәм кергән-чыкканнарның язуларын да, ашыкмыйча, бик җентекләп тикшерә.

Менә хәзер мин аңа алмашка Җантимеров дигән солдатны китердем. Бу казакълар арасында иң яше, укыйяза белгәне, сугыштан өтелеп чыккан чын солдат, ышанычлы часовой... Сүз уңаеннан тагын шуны да әйтергә кирәк, Җантимеровның гаҗәеп бер сәләте дә бар: сандугач-былбыл булып искиткеч матур сызгыра ул. Агачлар арасына китеп, шундый чын, шундый өздереп чутылдарга тотына ки, ишеткәч, сандугач икәненә тәмам ышанып, сихерләнеп тыңлыйсың үзен... Ничәмә тапкыр ул безне шулай алдады. Казакълар да үзен бик яраталар.

Без шлагбаум янына килеп җиткәндә, Шумилов боеприпаслар төягән дүрт «Студебеккер» машинасын үткәреп тора иде. Үткәреп бетергәч, мин аңа якынлашып:

— Йә, Шумилов, эшләр ничек, бик арымадыңмы? — дип сорадым.

— Әзрәк булды, иптәш сержант,— диде Шумилов, турая биреп.

— Нәрсә, машиналарны күп үткәрергә туры килдеме?

— Ничек дип әйтергә? Бик күп булмаса да, һаман килеп торалар, китеп торалар, так что шлагбаум киртәсеннән бер адым да читкә китәргә туры килмәде.

Бу складның шунысы яхшы: моннан урлап чыгар нәрсә юк. Йөкләрне тикшереп тору кирәкми дә, барыбер артык ящикны әләктереп чыгарга тырышучы табылмаячак. Ә менә азык склады каравыл өчен бик начар — анда инде машинада нәрсә барын карамыйча чыгару юк. Бигрәк тә аракы төягән булса, шоферның утыргычын да күтәреп карарга туры килә.

Бездә часовойларны алмаштыру бик гади эшләнә. Берсе китә, икенчесе торып кала. Бушаганнарын мин үзем белән ияртеп йөрмим, шунда ук кайтарып җибәрәм. Аз булса да ял итә торыр. Кайберләре, бәйдән ычкынгандай, землянкага таба сыптыра гына.

Шумиловны алыштыргач, мин, калган солдатларны ияртеп, чәнечкеле тимерчыбык буйлап сузылган тар сукмактан икенче постларга китеп бардым. Солдатлар җитмәгәнгә күрә, пост аралары шактый ерак, бик кирәк урыннарда гына тора. Шлагбаумнан соң әле берсенә, әле икенчесенә җитеп, часовойларны алыштыра-алыштыра бара торгач, менә иң соңгысына да Ишмәмәт белән икәү генә

килеп җиттек. Бу постның урыны бик аулак, бик матур җирдә: урман кырые, каршыда адәм аяк басмаган киң генә аланлык, чабылмыйча калган бил тиңентен куе үлән — ул инде шулай утырган килеш саргаеп картайган, хәтта чәчәкләре дә коелмыйча гына кипкәннәр... Монда ялгыз-ялгыз бик мәһабәт имәннәр, каеннар үсеп утыра. Бирегә килгән саен, мин эчемнән генә, тукта, бу урын миңа малай чактан ук таныш түгелме соң дип, бик сәерсенеп уйламыйча калмый идем.

Әнә тимерчыбык буендагы ялгыз имән төбендә чуаш Емелькин басып тора. Мылтыгына беләге белән таянып торышыннан ук күренә, дәдәебез бик арыган булса кирәк.

— Ну, Емелькин,— дим мин аңа, килеп җитү белән,— безне көтә-көтә зарыгып бетмәдеңме?

— Бетмәгән кайда инде ул, парин! — ди Емелькин, урыныннан авыр гына кузгалып.— Алты сәгатенә түздек, алты минутка калгач түзүләре бик читен икән.

— Шулайдыр шул... Синең пост иң ахыргы бит, көтмичә дә хәлең юк. Әллә якынрак постка күчерикме үзеңне?

— Юк, кирәкми. Монда әйбәт.

— Әйбәт дисең... Нәрсәсе белән?

— Монда, парин, уйлавы рәхәтрәк. Мишәйт итүче юк.

— Шулаймыни? Ниләр уйлыйсың соң син?

— Барысын да... Әйтеп бетереп буламыни аны?!

— Түтәйне дә сагына торгансыңдыр инде?

— Аны да сагынам, парин, сагынам.

Емелькин җиңе белән юешләнеп торган күзләрен сөртеп алды. Мин сүзне икенчегә борыр өчен сораган булдым:

— Тынычлыкмы, ул-бу юкмы?

— Нәстә булсын... Бер куян гына сикерә-сикерә узып китте. Атмакчы идем дә, тревога ясармын дип курыктым.

— Нигә атасың аны? — диде Ишмәмәт, ничектер кинәт кырыс кына.

— Бәй, нигә дип, суеп ашарга. Тиресеннән бүрек тегәргә.

— Харам ул!

— Харам? Куянмы? — диде Емелькин, бик гаҗәпләнеп.— Их син, үзбәк, белмисең икән әле куян итенең тәмен, тавык итенә биргесез ул.

— Үтереп ашау харам... Җан иясен үтерергә ярамый, гөнаһ булды кү...

— Һе, таптың сүз! Кеше үтерергә ярый, куян үтерергә ярамый, имеш!

— Кеше — явыз.

— Кем, минме? — Емелькин аның өстенә үк бара башлады.

— Йә, җитәр сезгә! — дидем мин, араларына кереп.— Юк өчен әтәчләнмәгез. Кая, эшегезне бетерегез!

— Ортак Емелькин аңламый шул,— диде Ишмәмәт, тыныч кына.— Мин аның кальбен аяп әйтәм, кальбе ташка әверелмәсен...

— Аңламыйм шул мин сине, Ишмәмәт,— диде Емелькин да, шактый йомшарып.— Кальбе дисең, нәрсәдер инде ул, белмим, иллә мәгәр монда таш булырга кирәк, таш... ярар, кил әйдә, карт имәнгә терәл!

Ишмәмәт Емелькин урынына басты һәм мылтыгын җиргә төшерде. Үзе дә мылтык буйлы бәләкәй-юка гына бер кеше инде ул. Чырае да сабыйныкы, күңеле дә сабыйныкы, чебен үтерергә дә кулыннан килмәс, ә шулай да мылтык тотып постта торырга ярый. Хәер, бу сугышта эшкә ярамаган кеше калмады.

— Йә, Ишмәмәт, әйбәт кенә тор инде,— мин әйтәм,— бик боекма, күбрәк йөргәлә... Мин синең яныңа килеп китәрмен әле.

Ишмәмәт мөлдерәп туларга торган күзләре белән миңа моңсу елмаеп кына карый. Бик тә нечкә, йомшак бәгырьле кеше ул безнең Ишмәмәт. Чак кына җылырак сүз әйтсәң, әнә шулай эри дә китә. Җавап бирергә дә көче җитми. Аны хәтта безнең лейтенант та тирги алмый. Ә тиргәргә кирәк чаклар булгалый, чөнки ул, ничек дим, арада иң пешмәгән, иң тугарылып йөри торган солдатларның берсе. Әмма үзе бик чыдам, бик күндәм, кая гына куйсаң да тора һәм алты сәгать түгел, ун сәгать тә тора ала, тавышын-тынын чыгармый. (Бүтәннәр, мәсәлән, ун гына минут артыграк торсалар да сукрана, сүгенә башлыйлар.) Аның дүрт баласы бар икән инде, ул шуларны бик сагына һәм гомумән илен-өен бик сагына булса кирәк, шулай сизелә. Әмма, әйткәнемчә, эчтән сүзсез генә сагына, бүтәннәр кебек тышка чыгарырга, уфтанырга яратмый. Үзенә күрә сәер, серле генә бер кеше ул... Минем аңардан сораганым да бар:

— Ишмәмәт әкә, әйт әле, син үлемнән куркасыңмы?

— Юк, курыкмыйм,— ди ул, тыныч кына.

— Ник?

— Минем береннән-бере кечек дүрттә балам бар кү! — Һәм ул балаларының җирдән күпмегә биек булуын кулы белән күрсәтеп чыга: — Миңа үләргә ярамый, Ходай мине саклаячак.

Һәм Ишмәмәт моны бик нык ышанып әйтә.

Карт имән янәшәсендә генә чәнечкеле чыбыкның кечкенә чокыр өстеннән узган бер иркен урыны бар — без Емелькин белән шул төштән иелеп эчкәре уздык та тар гына сукмактан взводка кайтып киттек. Емелькин салган сукмак бу, иң туры, иң кыска юл... Минем арттан килә-килә ул миңа зур бер нәрсә итеп сөйли:

— Куянның маңгаена туп-туры карап барсаң, парин, ул кача алмый. Ник дисәң, куян туры каршысына килгән кешене күрми, аның күзләре маңгаеның ике ягына чалыш утыртылган... Чапканда да ул башын бер уңга, бер сулга борып, алдына да, артына да карый-карый чаба. Ышанасыңмы?

Мин нәрсә, дим? Куянның алай чапканын һич тә күргәнем юк, ләкин Емелькинга «юк, ышанмыйм» дип әйтәсем килмәде. Чуаш агай куянны миңа караганда яхшырак белергә тиеш.

Алданрак кайткан солдатлар землянка каршындагы тар өстәлдә дневальный сосып биргән борчак ашын котелокларыннан шөбердәтеп ашап утыралар иде инде. Емелькин да, мылтыгын агачка төрәп, биленнән каешын салып ташлады да кулын юып ашарга утырды. Дневальный китереп биргән котелогына кашыгы белән тыгылгач:

— Рәхмәт төшкере, бүген дә борчак икән,— диде.— Каян алып җиткерәләр бу борчакны, әллә Әмерикәдән килә инде?!

Солдатлар көлешеп алдылар. Арадан берсе:

— Юк, булмас,— диде.— Борчак Американың үзенә дә җитми торгандыр...

— Нишләп?

— Нишләп дип, моңарчы бит алар немецка каршы борчак кына атып яттылар.

Солдатлар тагын көлештеләр. Сүзнең мәгънәсе аларга бик ачык: союзниклар (Америка белән Англия) икеөч ел буена икенче фронтны ачмыйча сузып килделәр. Безнең солдатларның бу хәлгә бик ачулары килә иде, шунлыктан җай чыккан саен Америкасына да, Англиясенә дә тибеп узмыйча калмыйлар иде. Бик әшәке итеп сүккән чаклары да күп булды, ләкин хәзер тынычланабасыла төштеләр инде, чөнки союзниклардан башка да немецны җиңеп чыгуыбызга ышана башладылар.

Ашау-эчү бездә төрле вакытта төрлечәрәк була. Безне үзебезнең рота тәэмин итә. Әгәр ротага якын торсак, азыкның һәртөрлесен вакытында алабыз, әгәр инде хәзерге шикелле ротадан ерак китсәк, үзебез алып килгән корысары (концентрат, консерв, шпик) белән генә туенып то-

рабыз. Тик икмәкне генә без көн саен диярлек шушы склад келәтеннән алып кайтабыз.

Башта әйткәнемчә, бу урынга күчеп килгәч, бер-ике атна чамасы эш бик күп, бик тыгыз булды. Әлеге дә баягы боеприпас дигән бик кадерле нәрсәне төяшергә куалап, безне тәмам алҗытып бетерделәр. Зур һөҗүм вакытында гел шулай була инде ул: склад территориясенә йөзләрчә машина килеп тула, көне-төне анда кешеләр кайнаша, зур гына начальниклар сүгенеп, тиргәп, берөзлексез ашыктырып йөриләр. Ә төяп озатучылар барыбер җитешми. Менә шуннан соң инде посттан бушаган солдатка да чират җитә. Әлбәттә, каравылда торучыларга тияргә ярамый дип әйтүче юк. Ә арыган, өшәнгән солдат постында йокласа, башы белән җавап бирергә тиеш.

Кыскасы, берьюлы ике камытны кияргә туры килде безгә... Бик арыдык, чиләндек, өс-баш та тетелеп бетте, ә соңга таба инде аякларны сөйрәрлек тә хәлебез калмады. Ләкин без бер нәрсәне белеп тора идек: дошман чигенеп, фронт ераклашса, безнең хәлебез дә җиңеләячәк. Бөтен теләгебез шул, бөтен өметебез шуңарда гына... Чөнки ул чагында тылдан килеп торган боеприпасларны монда бушатмыйча, алгарак, фронтка якынрак җиргә куачаклар.

Һәм шулай булып чыкты да ул: башта фронт моннан сигез-ун километрда гына иде, ә бер ун көннән инде автобат кешеләре фронтның утыз-кырык километрга ераклашканын әйттеләр. Хәер, без моны үзебез дә сизеп тордык: сугыш бит ул, көчле күк күкрәве шикелле, акрынлап ераклаша һәм тоныклана бара.

Менә безнең территориядә дә эш әкренләп сүрелә башлады, машиналарның килүе шактый кимеде, аннары зуррак начальниклар да китеп беттеләр. Бу инде яхшы фал иде. (Димәк, эшнең кызуы алга күчте дигән сүз.) Дөрес, машиналар һаман әле килгәләп тора, ләкин безне борчымыйлар иде инде. Шулай итеп, без яңадан үзебезнең төп эшебез — каравыл хезмәтендә генә калдык һәм тынычланып, нормага кереп дигәндәй, солдат кешесенә хас көндәлек ашау кайгысы, йокы кайгысы белән генә яши башладык.

Ашау дигәннән, безнең казакълар теге килгән чакта утарлар тирәсендә күренгән сарыкларны бер дә исләреннән чыгармаганнар икән. Шуны әйтергә кирәк, сухой паекны алар, гомумән, яратмыйлар, ирексездән көчләнеп кенә ашыйлар, ә шпикны инде бөтенләй авызларына да алмыйлар. Үзебезнең Россия җирендә торган чакта, әгәр якын-тирәдә генә авыл булса, аларның кай-

берләре, шул шпикны чүпрәккә төреп, авыл арасына чыгып китә иде дә берәр марҗадан бәрәңгегә яки сөткә алмаштырып кайта иде. Ничә тапкыр лейтенант үзләрен шуның өчен эт итеп тиргәде. Ләкин казакъ гаеплемени, нәфсе аның борын-борыннан ашап өйрәнгәнне сорый, йортына кермәгән чучканы ничек ашасын ул?! Ә монда әнә сөйкемле куйлар утлап йөриләр...

Һәм менә беркөнне землянка алдындагы тар өстәл әйләнәсендә чәй эчеп утырган чакта, Байәхмәтов, шул сөйкемле мәхлукны кинәт кенә исенә төшергәндәй, миңа әйтә куйды:

— Анау латышның берәр куен алып суйганда жаксы булыр иде, ә, җулдаш сержант! Казан асып, казакъча бер мәҗлес кылып утырыр идек, ни дисез шуңа?

— Ни әйтим, Байәхмәт әкә, бик хуп күрәм мин бу эшне,— дидем мин дә, аны-моны уйламыйча гына.

Казакълар бердәм җанланып киттеләр:

— Һа, сержант — үземезнең нугай, казакъның җоласын беләде гой!

Акшалов бөтенләй сикереп үк торды:

— Эш нидә? Тотарга да алырга латышның куен...

— Ничек итеп?

— Сатып, сержант! Сатып...

— Сатыр сиңа! Тот капчыгыңны!

Байәхмәтов тагын ашыкмыйча гына үз сүзен кыстырып куйды:

— Мондагы латыш частный адәм! Частный адәм сата ул, бәһасеннән генә тормаска кирәк.

Мин моңарчы бу сөйләшүне бары уенга гына алып утыра идем. Гадәттәге бер хыяллану дип кенә... Ә хыяллану — куй турында да, кирәксә, кыз турында да — солдатка бик килешә ул! Ләкин Байәхмәтнең соңгы сүзләрен ишеткәч, мин бераз сагая калдым: әллә болар чынлап та латыштан куй алып суймакчылар инде?! Кара син аларны!.. Әмма ләкин мондый эшнең булуына ышануы бик читен бит әле. Кем йөри аның артыннан, кем рөхсәт итә аны безгә?.. Аннары мондагы халыкны да без яхшылап белмибез әле. Дусмы-дошманмы дигәндәй, ниндирәк кешеләр алар?.. Бәлки, ул хутор иясе безгә куен түгел, чебешен дә сатмас. Шуңа күрә мин, бары кул селтәп:

— Булмас, юлдашлар! — дидем.— Юкка нәфсегезне сузмагыз!

— Уй-бай, нигә булмас?! — диештеләр казакълар, бик гаҗәпләнеп.

Ә моңарчы дәшмичә хәйләкәр генә елмаеп утырган Дорды кинәт минем алдыма ук торып басты:

— Булмас дисеңме, сержант?.. Менә сиңа кара сакалым, иртәгә үк мин синең алдыңа куйның башын табакка салып китереп куям! Инанасыңмы?

— Ай-һай, Дорды әкә! — дидем мин, көләргә итеп.— Кем генә бирер икән соң сиңа куй башын?

— Латыш үзе китереп бирер! Инанасыңмы, юкмы? Әйт, инанасыңмы?

Мин, икеләнебрәк:

— Юк, ышанмыйм! — дидем.

— Алайса жирәбә тартабыз! — диде ул, миңа кулын сузып.— Мин оттырсам, сиңа... бер «мәскәүский»! Булдымы?

— Ә мин оттырсам?

— Синнән дә «мәскәүский»!.. Сүз бәйләдекме?

— Хуп мәйле! — дидем мин, аның сузган учына сугып.— Ләкин белеп тор, Дорды әкә, әгәр дә мәгәр латышны рәнҗетсәң яки куен урлап алсаң, башың штрафнойга китәчәк!

— Бу ниткән сүз?! — диде Дорды, кинәт караңгыланып.— Кодай сакласын андый эштән! Әйттем гой латыш куен үзе апкилеп бирер дип.

Һәм ул тынычланыр өчен кесәсеннән кечкенә шешәсен чыгарып, тел астына насваен салды да бер читкәрәк китеп барды.

Әнә шулай бетте бу уйламаганда гына килеп чыккан сүз. Ә безнең бәхәс чын булдымы, әллә юри генәме — мин моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Ярый, көтеп карарбыз... Ләкин шуны әйтергә кирәк, Дорды утны-суны кичкән, бик үткен, бик хәйләкәр казакъ иде. Иң элек ул картада искиткеч оста уйный белә иде. Казакътан картежник! — башта бу минем өчен һич көтелмәгән бер яңалык булды. Әле кемнәр белән уйный диегез?.. Бары капитан, майор, подполковник кебек зур чиннар белән генә, чөнки алар үзләре буш вакыт табып картага утырдылар исә тизрәк Дордыны чакыртып алалар. (Невель янында торган чакта минем үземә аны, лейтенант кушуы буенча, посттан бушатып, начальниклар җыелган землянкага җибәрергә дә туры килгәләде.) Һәм кем белән генә уйнамасын, Дорды ул кешене чишендермичә калмый иде шикелле. Моның сере нәрсәдә? — Хода белсен, ләкин казакъларның шыпырт кына әйтүенә караганда, аның бармаклары картаны «күрә», имеш!.. Һәрхәлдә, бер нәрсә ачык билгеле — Дорды акчалы кеше, аның зур яулыкка урап, гимнастерка астыннан биленә бәйләгән утыз-кырык мең сум акчасы гел янында йөри, диләр.

Шуның өстенә тагын бу Каракалпак казагы (туган иле шунда аның) төскә-биткә дә шактый чибәр кеше иде. Бите аның, бүтәннәрнеке кебек ипи каравае сыман түп-түгәрәк түгел, озынчарак та, җыйнаграк; кечкенә генә кара сакал, куе гына кара мыек, ә иреннәре ак сызыклы — ачык беленеп тора. Буе-сыны да аның ыспай-җыйнак, тыгыз-таза... Ул теләгән чагында тип-тигез тешләрен күрсәтеп, сөйкемле генә елмая белә һәм кысыграк майлы-елтыр күзләре белән эчеңә керердәй итеп карый ала. Шуңадыр, ахры, кешеләр аңа тартылалар, аңа якынрак булырга тырышалар. Начальниклар да бит аны, юньләп русча сөйләшә дә белмәгән гади солдатны, тиң күргәндәй яннарына чакырып алалар. Хәтта очраган хатыннар да аңа, эчләреннән генә нидер уйланып, карамыйча узмыйлар иде.

Кыскасы, Дорды — теләгәнен булдыра ала торган кеше. Ләкин мондагы латышны ул ничек итеп сихерли алыр икән? — монысына минем, дөресен әйтергә кирәк, күзем җитми иде. Ахрысы, аңа сарык башы урынына «мәскәүский»не минем алдыма куярга туры килер. Ә «мәскәүский»не таба инде: станциягә бара да тылдан килгән машинистлардан ярты литрны биш йөз тәңкәгә сатып алып та кайта. Моны берничә тапкыр эшләде инде ул...

...Бер көн узды, ике, өч көн узды, ә дүртенче көнне Дорды мине: «Бире килче, сержант, синең белән гәп бар»,— дип, бер читкә алып китте. Агачлар арасынарак узып, җирдә яткан юан бүрәнә өстенә утырдык. Аягын сузып, чалбар кесәсенә тыгылды бу; әллә «мәскәүский»не чыгара инде, юк, насвай шешәсе икән... Шуңардан уч төбенә бер чеметем насвай кагып төшерде дә, сакаллы ияген күтәреп, тел астына салып та җибәрде. Мәгълүм булганча, армиядә солдатларга насвай бирмиләр, насвайны Дорды үзе ясый. Бөрмәле капчыгында аның каяндыр табып алган бәләкәй генә табасы йөри. Менә шул табасында ул чыршы ылысын һәм үзе генә белгән тагын ниндидер үләннәрне тәмәке белән бергә бутап көйдерә дә, шуннан насвай сыман кара-яшькелт бер нәрсә килеп чыга. Татарча әйтсәк, ит югында үпкә дә ярый!

Дорды, насваен тәмләп суырып, бер төчкергәч, бик гади генә итеп миңа:

— Сержант, без, Аллага тапшырып, латышның бер куен алдык! — диде.

Мин, тиз генә сүз таба алмыйча, беравык аңа сынап карап тордым: шаяртамы бу, әллә чынлап әйтәме? Әмма Дорды эчендәге тантанасын һич тә сиздермичә тыныч кына утыра иде. Ахырда үзем сорарга мәҗбүр булдым:

— Ничек алдыгыз?
— Сатып, сержант, сатып...
— Күпмегә?
— Мин латышка үземнең ике мең тәңкә хәләл акчамны чыгардым да бирдем! — диде бу, байларча гына.
— Хәләл акча!.. Ну, ярый, ә куегыз кайда соң?
— Куй иясендә калды әле.
— Нигә, китереп бирмимени? — дидем мин, аңа төрттеребрәк.
— Китереп тә бирер,— диде Дорды, бер дә исе китмичә генә, аннары миңа елыша төште: — Беләсеңме, сержант, без лейтенантка әйтми торып куйны алып кайтырга курыктык. Лейтенантка әйтү кирәк гой!
— Әйе, аңа әйтмичә ярамый.
Шуннан соң Дорды чибәр йөзенә әлеге сөйкемле елмаюын чыгарып, миңа йомшак кына болай диде:
— Алайса син, чырагым, аңа үзең яхшылап-җайлап кына әйтсәңче.
— Туктале, ни өчен мин?.. Ни өчен син үзең түгел?
— Юк, миннән булмый, миңа ярамый... Син, чырагым, лейтенантка якын торасың, син әйтә беләсең, син грамотный адәм, яхшы атаның баласы...
— Йә, йә, Дорды әкә, салам кыстырмыйча гына... Куйны сез алгансыз — җавабын да сез бирергә тиешсез... Шулай ул!
— Кодавәндә! — диде Дорды, ачынып.— Лейтенант безне тыңламый гой! Анау Шумиловны тыңлый, чуаш Емелькинны да тыңлый, ә безне юк, тыңламый... Казакъны башкалардан аеру, якын итү була дип курка. Үзең дә беләсең гой!
Әйе, бу дөрес, мин моны белә идем. Һәм чынлап та лейтенантның эшне бозып куюы бик мөмкин иде.
Хикмәт монда нәрсәдә?.. Лейтенант Нугайбәк Кулибаев милләте белән кыргыз, шуңа күрә казакълар аңа бөтенләй үз кеше итеп карыйлар. Армия тормышында исә бу бик ярый торган эш түгел, армия ул ата белән баланы да аерып, һәркайсын үз урынына куя. Ә казакълар менә шуны һич тә аңларга теләмиләр, алар өчен Кулибаев гүя бертуган кече энеләре... Баштарак әле аңа туп-туры исеме белән генә дәшә торганнар иде: Нугайбәк тә Нугайбәк, ә кайчагында үзләренчә назлап, Нугайбәк чырагым да дип җибәрәләр. Билгеле инде, лейтенант моны ишеткән чакта бик уңайсызланып кала, хәтта ачуыннан бүртенеп тә китә торган иде. Хәер, соңрак ул аларны бу кадәр «якын» итүләреннән тыйды.
— Җитәр! Моннан кәен «Нугайбәк» дип әйткәнегез-

не ишетәсе булмыйм. Мин сезгә командир, миңа устап кушканча дәшегез! — диде.

Кыскасы, лейтенант Кулибаев белән казакъ солдатлары арасында, ничек дим, милли якынлыктан туган әнә шундый бер каршылык яшәп килә иде. Бу каршылык күп вакытта үзен сиздерми дә кебек, ләкин кайчагында кискен генә бәреп тә чыга иде.

Менә хәзер нәкъ шундый хәлнең булуы бик мөмкин. Казакъларның аңа әйтмичә куй алып йөрүләрен белсә, ул моны, һичшиксез, үзе белән санлашмау дип караячак һәм кызган баштан бер сүз белән тегеләрнең эшен өзәчәк! Яшь командир өчен куйдан да битәр абруй кыйммәтрәк.

Димәк, Дордының ялварып соравына колак салмыйча да булмый. Алларына килергә торган ризыктан аларны мәхрүм итү ярамастыр инде. Нишлисең, минем кебек сержант кешегә кайчак шулай командир белән солдат арасында буфер хезмәтен дә үтәргә туры килә.

— Ярый, Дорды әкә,— дидем мин, ниһаять,— лейтенант белән сөйләшеп карармын.

— Һай, чырагым, рәхмәт сиңа!..

— Тукта, рәхмәтең белән ашыкмый тор әле син... Әйтеп беткәнне көт. Әгәр мин казакълар үзләре өчен куй алалар дип әйтсәм, лейтенант, мөгаен, моңа риза булмас...

— Нигә, ни кылып?.. Безнең хакыбыз юкмыни?.. Без үз акчабызга алабыз гой!

— Хакыгыз бар, мәсьәлә анда түгел... Мәсьәлә менә нәрсәдә: сез, әйтик, биш-алты казакъ, аяк бөкләп, куй ашап утырганда башкалар нишләрләр икән? Иреннәрен ялап торырлармы?

— Уй-бай,— диде Дорды, бик гаҗәпләнеп һәм борчылып.— Син, чырагым, казакъның җоласын белмәйсеңме?.. Казакъ куй суеп, казан асса, берәүне дә өлешсез калдырмый ул... Безгә бер табын корып утыру җитәде гой!

Шулай итеп, казакълар мине бу эшкә күндерделәр. Инде мин үз нәүбәтемдә командирны күндерергә тиешмен. Моны эшләп булыр кебек, чөнки лейтенант Кулибаев белән теләсәм нәрсә турында бер дә курыкмыйча сөйләшергә хакым бар, сөйләшә алам һәм үз сүземне үткәрә алуыма да ышанам. Тик аның характерындагы кайбер четерекле нечкә якларны гына истән чыгармаска кирәк. Һәрхәлдә, башта ук аны өркетмәс өчен әзрәк кенә хәйлә кормыйча да булмас.

Бүген лейтенант склад начальнигы белән каядыр китеп, шактый вакыт югалып торды. Кичке разводтан соң землянкага кайтып керсәм, ул да кайткан, итеген, каешын салып, такта тапчанга чалкан сузылган иде.

— Сәлам, лейтенант! — дидем мин,— күп тәпиләгәнсез, ахрысы?

— Булды бераз.

— Кайларда йөрдегез?

— База начальнигында булдык.

— Йә, ниләр ишеттегез?

— Хәбәрләр күп,— диде лейтенант, миңа таба сул ягына борылып.— Әнә бүгенге сводканы алып кайттым, карагыз. Солдатларга да укырсыз.

— Була ул…

— …Фронт һаман алга тәгәри. Безнең армия дә Литва җиренә кергән икән инде… Шул кызулык белән барсалар, анда Германиянең үз җиренә — Көнчыгыш Пруссиягә дә ерак калмый. Сизәсеңме эшләрне?

— Сизмәгән кайда инде!

— Менә шулай… Чәй эчәсе иде бит, сержант!

— Хәзер булдырырбыз аны, лейтенант! — Мин ишекне ачып кына, Акшаловка чәй китерергә куштым.— Алайса без дә тиздән кузгалабыз?

Лейтенант көттеребрәк җавап бирде:

— Безне тиз генә кузгатмаслар, ахрысы.

— Нишләп?

— Монда, әнә, күрәсең, тау чаклы боеприпас өелеп ята. Аларны хәзер күчереп торырга вакыт та юк, аннары транспорт та җитешми. Барлык автобатларны алга куганнар. Шулай диде подполковник Агеев… Хәзер эшелоннарны да монда бушатмыйча туп-туры передовойга таба куалар. Анда инде яңа кыр складлары оештырылган…

— Ә рота кайда?

— Рота да безне күптән узып киткән.

— Без генә койрыкта торып калганбыз икән, кызганыч!

— Хафа булма, сержант, безгә дә чират җитәр. Әллә сугышны шушында бетерербез дип куркасыңмы?

— Юк, анысы өчен курыкмыйм, лейтенант! Ләкин, үзең беләсең, армия алга ыргылган чакта, аңардан бер дә торып каласы килми бит. Аннары бер урында озак яту да туйдырып бетәде гой, сезнеңчә әйтсәк… Менә бу хәбәрләрне безнең солдатлар ишеткәч, аларның да кәефләре бозылачак, рухлары төшәчәк. Солдатның бит бөтен хыялы алга бару, бары тик алга бару, шулай түгелме?

— Анысы шулай инде,— диде лейтенант, җиңел генә сулап.

Акшалов безгә калай чәйнек белән чәй кертеп куйды.

— Карале, Акшал,— диде лейтенант аңа,— син ужынга бирәр нәрсә таярлыйсыңмы?

— Таярлап ятам. Җолдаш лейтенант!
— Нәрсә инде ул?
— Тары боткасы.
— Алай икән. Маең бармы соң?
— Мае эчендә. Концентраттан гой!

Алар сөйләшкән арада, мин снаряд ящигыннан гына корылган кечкенә өстәлгә эмаль кружкаларны һәм бөрмәле янчык белән шакмак шикәрне куйдым. Шикәр гадәтенчә бик дымлы иде. Лейтенант торып, ялангач аякларын салындырып, тапчан кырыена утырды. Акшалов чыгып киткәч тә мин бернинди кереш сүзсез туп-туры аңа әйттем:

— Беләсеңме, лейтенант, менә бу якын-тирәдәге хуторлардан куй сатып алырга була икән.

— Куй? — диде лейтенант, бал капкандай киң битен бик төче җыерып.— Куй! Булмас ла! Кайдан ишеттең?

— Бүген станциядәге зенитчикларның берсен очраткан идем, шул әйтте. Без бер куй алып суйдык, икенчесен алырга җыенабыз, ди.

— Ышанмыйм, алдаша торгандыр.

— Ә нигә алдашсын ул? Бик гади эш бит бу... Үзегез дә күрәсездер, хуторлар тирәсендә куйлар йөри, хуҗалары сатмыйча аларны нишләтсеннәр?

Лейтенант, ышанырганы-юкмы дигәндәй, дәшмичә, миңа ит баскан кысык күзләре белән бераз карап торды. Әлбәттә, сүзне бик тирәнгә җибәрмәскә һәм бу эшне ничек тә гади генә бер нәрсә итеп күрсәтергә кирәк иде. Иң мөһиме — лейтенантны төрле шикләр кимерә башламасын! Шуңа күрә мин ялгап:

— Аннары без үзебез дә аны белә алабыз бит,— дидем.— Менә мин иртәгә үк якындагы берәр хуторга барып чыгармын, сорашып карармын, әгәр сатулары дөрес икән, берәр куйны җитәкләп алып кайтырга да була.

— Шунда укмы? — диде лейтенант, көләргә итеп.

— Изге эшне китап озакка сузарга кушмаган,— дидем мин дә шаярткан булып.

— Изге эш! Кызык кына сөйлисең әле син, сержант! Ә кем рөхсәт итәр икән безгә андый «изге эшләр» артыннан йөрергә?

— Сезнең рөхсәт җитә, лейтенант! — дидем мин, өзеп. Бу аңа ошарга тиеш иде.

— Ай-һай! — диде ул, шулай да икеләнебрәк.— Миңа бит андый права бирелмәгән.

— Анның каравы сезгә солдатларның тамак ягын кайгырту правасы бирелгән. Күптән инде аларга суйган ит ашатканыбыз юк. Гел сухой паекта утырабыз. Бер куй

алып чалган өчен беркем дә бер сүз әйтмәс, ә солдатлардан сезгә рәхмәт кенә явар!

Лейтенант чәендәге шикәрен пычак очы белән болгаткан булып, бераз дәшми торды. Аннары сорады:

— Ә акчасын кайдан алабыз? Син шуны уйладыңмы?

— Солдатлардан җыябыз.

— Һе,— дип куйды лейтенант,— барысы да уйланган икән... Солдатны үз акчасына ашатабыз алайса! Армиядә мондый эшнең булганы юк иде әле.

— Ник булмасын,— дидем мин тиз генә, чөнки лейтенантның бу кинаясе хәтәр иде.— Солдат бит үз акчасына кирәк нәрсәсен сатып алырга хаклы. Оныттыгызмыни, безнең солдатлар, авылларда торган чакта, үз акчаларына сөтен, бәрәңгесен, тәмәкесен дигәндәй, сатып алалар иде, беркем дә тыймый иде бит... Ә хәзер салышып алалар, бары шул гына.

— Дипломат булып беткәнсең син, нугай! — диде бу миңа, чәнчеп.— Әллә үзләренә әйттең дәме?

— Юк, нишләп әйтим, сезнең белән сөйләшмичә торып,— дидем мин, әз генә үпкәләгән булып.

Лейтенант бераз уйга калды. Һаман икеләнә иде шикелле, шайтан алгыры! Ләкин аңа икеләнергә дә, уйланырга да ирек бирмәскә кирәк иде, шуңа күрә мин сүзне тизрәк очлар өчен бик дусларча, әмма җитди итеп әйттем үзенә:

— Сез, лейтенант, бу эшне миңа ышанып тапшырыгыз. Сүз бирәм, кирәксә менә ант итәм, мин барысын да бик законлы итеп эшләрмен. Хуҗа белән дә бик сак кына сөйләшермен, куйны да үз ирке белән сатса гына алырмын, шулай ук солдатларга да бу турыда артык шауламаска кушармын. Йә, фатихагызны бирегез, лейтенант!

Ул миңа җитди генә бер сынап карап алды.

— Ә соңыннан берәр чатаклык килеп чыкса, җавабын кем бирер?

— Ай Алла, бик кирәксә, җавабын да үзем бирермен. Ләкин эш аңа барып җитмәячәк, лейтенант, ышаныгыз!

— Ну... ярый алайса! — диде ул, ниһаять, һәм кинәт көлеп тә җибәрде.— Куйны,— мин әйтәм,— гаҗәп сагынгансың икән, ә, сержант?

— Кыргыз миңа караганда да ныграк сагынгандыр әле,— дидем мин, елмаеп кына.

Лейтенант дәшмәде, тик сул кул сырты белән авызын гына, гүя ихтыярсыздан, сөртеп куйды.

Икенче көнне иртәнге разводтан соң, без Дорды белән, ашап-эчеп тә тормыйча, Аллага тапшырып дигәндәй, куй

хуҗасына киттек. Шлагбаумны узгач та уңга каерылдык, бераз тар сукмак буйлап бардык, аннары икенче пост турысына җитәрәк, Дорды, сулга борылып, мине буш кырлар аша юлсыз-нисез алда күренгән бер утарга таба алып китте. Урман буйлары чабылмыйча калган куе үлән, ләкин ул саргаеп, кибеп беткән инде, атлаган саен кыштырдап сына, коела һәм аяк астыннан, бүрек бәреп куркыткандай, чикерткәләр сикереп китә. Бераздан урган җир өстенә дә чыктык, йомшак камыл таптап, кызу гына атлыйбыз. Ачык кырга чыккач, әллә ничек сәер булып китте: көз дә килеп җиткән икән ләбаса! Игеннәр урылган, көлтәләр ташылган, кырлар буш, тын ята, бөтен тирә-юньгә сары, моңсу төс кергән... Хәтта үзебезнең урман да моннан ничектер тавыш-өнсез, боек булып күренә икән. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге, диләр. Шул урманда күпме яттык, күпме тапкыр кояш чыкканын каршыладык, күпме кошлар сайравын ишеттек, үләннәрен таптадык, черкиләреннән таландык, ә менә уй-хыяллар каядыр читтә, еракта булгач, җәй узганын сизми дә калганбыз.

Бер утарны читләтеп уздык, икенчесенә якынлашып киләбез. Дорды әйтә, куй хуҗасы шунда, ди. Без коралмазар алмыйча гына чыктык, шулай да мин бик шәп трофей пистолетны шинель кесәсенә тыккан идем — белмәссең дөнья хәлен!

Монда утар аралары бик якын — чакрым-чакрым ярым гына булыр. Менә килеп тә җиттек. Утар дигәнебез типтигез кырда япа-ялгыз утырган бер хуҗалык: озынча итеп салынган, дранча түбәле иске генә өй, өйнең үзенә караганда шактый таза, нык каралты-куралар, әмма берничә капка-койма дигән нәрсә юк. Дүрт ягы да кыр, тик өйнең кояш чыгышына караган башында гына берничә карт өянке үсеп утыра, ә кыйбла ягында рәшәткәләп алган кечерәк кенә бакчасы күренә. Анда бары тик чәчәкләр генә — төрле төстәге безгә билгесез бик эре, бик купшы, ләкин инде көзнең беренче салкын сулышыннан шиңә башлаган чәчәкләр! Безгә бик тансык тыныч тормыш галәмәте! Тагын нәрсә? Ә, әнә өй белән каралтылар арасында зур тәгәрмәч-чыгырлы коесы да бар икән... Бөтен ихатасында йокымсыраган тынлык һәм, ялкау гына тибенеп йөргән тавыкларны исәпләмәгәндә, бернинди җан иясе барлыгы да сизелми.

Ләкин без якынлашуга, каяндыр эт өргән тавыш ишетелде. Мин туктала калдым — этнең тавышы шактый калын иде. Шул арада, кулына сәнәк тотып, абзардан чыккан хуҗа үзе дә күренде. Беравык ул безгә, без аңа карашып тордык. Аннары хуҗа безгә якын килмичә генә:

— Курыкмагыз, эт — биктә,— диде.

Моны ишетүгә Дорды ачык тавыш белән кычкырып дәште:

— Ә, хәзаин, исәнме-саумы!.. Менә без килеп тә җиттек.

— Яхшы! — дип кенә куйды хуҗа.

Без аның янына килдек. Мин дә аңа:

— Исәнмесез, хуҗа! — дидем, кулны сузмыйча гына.

Бу — яңакларын кара-җирән каты төк баскан, иллеләр тирәсендәге таза бер ир иде. Өсте-башы да бик хөрти — сәлперәеп төшкән свитер, ямаулы чалбар, тузып беткән галошлар, башында тишек эшләпә. Ул үзе башлап бер сүз дә әйтми, гел көтеп тора, ә саргылт күзләре куе кашлары астыннан салкын-уяу карыйлар.

Сүзне миңа яңадан, әлбәттә, гади-тыныч кына итеп башларга туры килде:

— Өченче көн безнең ике солдат сездә булганнар икән. Берсе — менә шушы казакъ иптәш, таныйсызмы?

Хуҗа таныйм дип башын гына какты. Русчаны начар белә, ахрысы, дип уйлап алдым мин һәм сорадым:

— Сез латыш буласызмы?

— Юк,— диде ул,— без староверлар булабыз.

— Димәк, рус милләтеннән, үзебезнең Россия кешесе?

— Без Россиядән күптән киткәнбез.

Ләкин шуңардан башка өстәп бер сүз дә әйтмәде. Күрәсең, бу хакта да ул артык җәелергә теләми иде. Үтә саклык, нишләтәсең! Шуңа күрә мин төп мәсьәләгә күчәргә булдым.

— Менә иптәшләр кайтып әйттеләр, сез бер сарыгызны безгә сатмакчы икәнсез, дөресме?

— Әйе, шулай дип сөйләшкән идек.

— Билгеле, үзегез теләп сата торгансыздыр инде?

— Аңламыйм,— диде хуҗа, коры гына.

— Минем әйтәсем килә: үзегез теләп сатсагыз гына без алырга риза.

— Мине берәү дә көчләгәне юк. Аннары без килештек бит инде.

Ярый, бу кырыс хуҗа алдында оста дипломат булып булмады, мать якасына!.. Алыш-бирешне тизрәк өзәргә кирәк.

— Алайса сүз бетте,— дидем мин.— Димәк, сарыкны алып китәргә дә була?

— Пожалысты!.. Җитәкләргә бавыгыз бармы соң? — диде ул, Дордыга карап.

— Бар, бар,— диде Дорды, җитез генә.— Куйларың кайда?

— Куйлар абзарда.

— Түлке, хәзәин, үзем сайлап аламын.

— Белмим, ничек сайларсыз икән, мин тотып бирмәсәм,— диде хуҗа, ниһаять, көлемсерәп.

— Әйдә керик әле абзарыңа!

Өчәүләшеп иркен генә абзар эченә кердек. Сарыклар түр почмакта нидер көткәндәй сагаеп, башларын күтәреп, тик кенә өелешеп торалар иде. Дорды, ишекне ябып, аркасы белән шуңа терәлде дә миңа сарыкларны үзенә таба куарга кушты. Ә хуҗага, сез бер читтә карап кына торыгыз, диде. Мин, түр башка узып, «Һайт!» дип бер кул гына селтәгән идем, сарыклар өерләре белән кубып, тыпырдашып чабып та киттеләр. Башта барысы да өелешеп, аннары бер-бер артлы тезелешеп, абзарны әйләнеп чабарга тотындылар. Шул чакта Дорды үзалдыннан чабып узган сарыкларны берәм-берәм сыртыннан ике куллап эләктереп ала да күтәреп карый, эләктереп ала да күтәреп карый. Шулай бер биш-алты сарыкны күтәреп карап җибәргәннән соң, бу, ниһаять, берсен кулыннан ычкындырмады: «Безгә менә шушы куй ярый»,— диде һәм кесәсеннән элмәкле бау чыгарып, тиз генә сарыкның муенына да кидерде.

Яктыга чыктык. Сарык чыннан да таза һәм яшь тә күренә иде. Дорды, маңгай тирен сөртеп:

— Вәт, хәзәин, безгә насыйбы шушы булыр! — диде.

— Ярый инде,— диде хуҗа,— ә шулай да сайлый беләсең икән!

Дорды, мәгънәле генә итеп, тамак кырып куйды, ә мин аның өчен:

— Белмәскә, куйлар арасында аунап үскән казакъ бит ул! — дидем.

— Күрәм, күрәм! — диде хуҗа, Дордының елтыр-шома битенә җитди генә карап.

Икебез дә аңа хушлашыр өчен кул бирдек, рәхмәтебезне әйттек, тагы да күрешербез әле, дидек. Хуҗа үзе дә бездән канәгать иде шикелле, һәрхәлдә, йомышыгыз төшсә, пожалысты, килегез дип әйтүне кирәк тапты.

Ә хәзер китәргә дә ярый торгандыр.

— Әйдә, җитәклә куеңны,— дидем мин Дордыга.

— Юк, алай бармый ул,— диде Дорды,— без аны менә болай итәбез.— Һәм, чүгәләп, башта сарыкның алгы-арткы аякларыннан тотып алды, аннары башын корсагы астына тыгып, тиз генә җирдән күтәрде. Сарык тыпырчынырга да өлгермәде. Ә Дорды муенына атландырган сарыкны ипли төшәр өчен, бер-ике генә селкенде дә кызу гына китеп тә барды. Мин аның артыннан ияРдем.

Ихата аша узганда безгә коедан зур тәгәрмәчне әйлән-

дерә-әйләндерә су чыгарып торган унҗиде-унсигез яшьлек кенә кыз очрады. Шушы йортның кызыдыр инде ул... Өстенә бер кат ситсы күлмәк кенә кигән бу яланбаш, яланаяклы кыз гәүдәгә искиткеч зифа-сылу иде. Туры-тыгыз аяклары, батыбрак торган нечкә биле, таррак кына тигезтөз аркасы, ике якка аерылыбрак караган груша сыман түшләре шулкадәр төгәл, камил, килешле иде ки, күрү белән мин ничектер югалып калдым. Әйтерсең күз алдымда бер мәлгә ак мәрмәрдән терелеп килгән җанлы сын пәйда булды, әйтерсең колагыма гаҗәеп бер нәфис музыка чагылып узды... «Йа Хода,— дидем мин, тыным кысылып,— чыннан да могҗиза тудыра беләсең икән! Әмма ничек ул сакланып калган бу ялгыз утарда? Немец тырнагына ничек эләкмичә калган ул?..» Аннары әкрен генә Дордыга дәштем:

— Күрдеңме әнә үзен?

Дорды, сарык астыннан башын борып, коега таба карады да тирән генә сулап:

— Их сержант, без әле аны кичә үк күреп шаша яздык! — диде.

— Шулай укмыни?

— Беләсеңме, Акшалов нәрсә диде?

— Йә, нәрсә диде?

— Моның кебек ай-сылу очраган чакта башны учлап, җиргә капланасы килә, диде.

— Гаҗәп, нигә ул алай дип әйтә?

— Тәкате беткәнгә күрә, сержант, сагынуы чиктән ашканга күрә! Төшенәсеңме?

Әйе, бу хәлне аңларга мөмкин иде. Еллар буенча хатын-кыз җылысыннан, хатын-кыз назыннан мәхрүм солдатның мәхәббәтне үлеп сагынуы, мәхәббәткә сусап тилмерүе гаҗәпмени соң?!

Ә Дорды, уңга-сулга карамыйча, бөгелә-сыгыла алдан сыптыра гына. Сыптырмас иде, җилкәсендә теге сарык утыра. Бу инде төшеңдә генә керүе мөмкин булган хуҗа кызы түгел, бу — көтмәгәндә кулга эләккән чын бер ганимәт; аны тизрәк үзебезгә илтеп җиткерергә кирәк.

— Бик авыр түгелме? — дип сорыйм мин, артыннан чак өлгереп.

— Һе, куйның кандай авырлыгы булсын,— ди Дорды, кычкырып.— Менә миңа алаптай бер немец мәлгуньне өч чакрым күтәреп кайтырга туры килде, вәт шул чакта, сержант, күзләремнән хәтта тир бәреп чыкты.

Мин моны аңардан беренче тапкыр ишетә идем.

— Кайчан, нинди немецны?

— Күптән. Передовойда чакта... Бик кадерле немец иде ул, сержант! Без аны оясыннан барып алдык.

— Аңлап җитмим әле мин сине, Дорды!

— Ну, «тел»не беләсең гой!.. Менә без, төнлә барып, бер «тел»не каптырдык... Ычкынып кача башлагач, старшина немецның аягына атты, ну, шуннан кәен, хош ни хош, миңа аны аркама атландырырга туры килде... Астында калып, үләм дип торам!.. Ә бу куйны, чырагымны, без йөгертеп кенә алып кайтабыз!

Солдат хәтерендә ниләр генә сакланмый, дип уйладым мин, һич көтмәгәндә менә шулай килә дә чыга. Ә сөйләнми калганы күпмедер әле аның?!

Дорды исә «йөгертеп кенә» илтә торгач, үзебезнең «лагерьга» китереп тә җиткерде. Шунда ук землянкадан казакълар чыктылар, сарыкны сырып та алдылар. Барысы берьюлы шауларга, сөйләнергә тотындылар: «Сөбеханалла!» — диләр, «Куй яман имәс, ризыкка гына язсын!» — диләр, әле түшеннән, әле янбашыннан тотып-тотып, басып-басып карыйлар. Әйтерсең Алланың күктән иңгән кашка тәкәсе бу — шулкадәр сокланырлар һәм куанырлар икән...

Шул арада безнең янга лейтенант Кулибаев та килеп җитте. Сарыкны күргәч, ул да киң бите белән җәелеп елмайды.

— Кара, алып та кайткансыз икән... Ә мин ышанмыйчарак торган идем.

— Нигә, кулдан ычкынып китәр дип курыккан идегезме әллә? — диде Дорды, көлеп.

— Юк, синең кулдан ычкынмый инде ул, бер әләккәч... Хуҗасы сатмас дип уйлаган идем.

— Сатты, лейтенант, бик куанып сатты! Адәм баласы акчага барысын да — малын да, хәтта кызын да сатады гой, әйтик, безнең казакъта... Казакълар дәррәү генә көлешеп алдылар.

— Күпме түләдегез? — диде лейтенант, миңа карап.

— Акчасын әнә Дорды түләде,— дидем мин, турысын гына әйтергә кыймыйча.

Дорды шунда ук миңа ялгап:

— Сорама да инде, лейтенант, сорама да! — диде хәйләкәр генә.— Кыйбат булмады бу хайван, чучка баласыннан да арзанга килде. Ризыкка яза күрсен!.. Инде син, лейтенант, безгә шуны әйт: кайчанрак моны, Аллага тапшырып, нитәрбез, суярбыз икән?

— Бүгеннән дә калдырмагыз,— диде лейтенант, борчыла башлагандай.— Ят адәмнәр күргәнче, эшен бетерергә кирәк.

— Бик хуп, лейтенант! Без үзебез дә шулай уйлаган идек. Алайса тапшырдык?

— Давай, башлагыз!.. Ә син, сержант, бөтенесенә күз-колак бул! Җавапкәрлек синең өстә.

— Яхшы! — дидем мин, теләр-теләмәс кенә: тагын нинди «җавапкәрлек» кирәктер инде аңа.

Лейтенант китеп барды, ә казакълар дәррәү генә эшкә дә тотындылар. Өметбай пычак кайрарга утырды. Акшалов савыт-сабаларын әзерли башлады, Шанаев белән Җантимеров урман эчендәге коега суга киттеләр. Байәхмәтов, балта алып, таган асар өчен җәпле агачлар кисәргә тотынды. Ә Дорды исә, иң зур эшне үтәгән кеше булarak, бу вак-төяк эшләргә катнашмыйча, бер түмгәк өстенә чүгеп, насваен тел астына салып, шуңардан би хуш булып, дәм алып кына утырды. Мин дә шул арада землянкага кереп, әзрәк тамак ялгап чыгарга булдым.

Ә бераздан Дорды, Өметбай, Шанаев пычак-бауларын алып, сарыкны муеныннан сөйрәп, землянкадан читкәрәк агачлар арасына кереп киттеләр. Мин инде алар артыннан ияргмәдем. Бу казакъларның үз эшләре, миңа анда булуның һич тә кирәге юк иде. Гомумән, бу тирәдән минем нигәдер китеп торасым килде. Күз-колак булуның да һич хаҗәтен күрмим — барысын да үзләре бик әйбәт башкарып чыгарлар әле. Шуңа күрә постларны бер тикшереп, йөреп кайтырга булдым. Тик китәр алдыннан Акшаловка шуны гына әйтеп китәсем килде:

— Хафиз, син дневальный кеше, икенче сменаны да онытма. Аларга дигән өлешне баштан ук алып куй, ярыймы?

— Ярый, ярый, җулдаш сержант, хафа булмагыз, барысын да үзем эшләрмен.

— Ә мин постларны йөреп кайтам әле, лейтенант сораса, әйтерсең.

— Әйтермен... Тик нигә китәсез әле? Менә хәзер таганда чәй кайнатам, учак янында чәй тәмле була, чәй эчеп китәрсез!

— Кайткач, Хафиз! — дидем мин һәм землянканың ишек яңагына элгән автоматымны алдым да үз юлым белән китеп бардым.

Иң элек Шумилов янында тукталырга булдым. Аның посты җанлы урын, хәзер дә әле үтеп-сүтеп йөрүчеләр, килгән-киткән машиналар булгалый, кайчагында берәр якташ та шунда очрап куйгалый. Һәрхәлдә, күп кенә яңа хәбәрләрне без шул шлагбаум яныннан ишетеп кайтабыз.

Очрашу дигәннән, бер кызыклы хәл искә төште әле.

Килгән көннәрдә шушы шлагбаум янында мин бер Җаек татарын очраткан идем. Бу озын гына, арык кына бер агай иде. Сөйләшеп киттек. (Җаек белән Татарстан арасы шактый ерак булса да, без инде барыбер якташлар!) Ул миңа сер итеп кенә шуны әйтте:

— Менә әле, туган, госпитальдән качып, үземнең чәсне эзләп барам. Монда боеприпаслар төяп чыккан машиналарны көтеп торуым әле,— бер шофер үзе янына утыртмакчы булган иде. Азык та юк, тамак та ач — беда, парин!

— Ә нигә качтың соң?

— Түзеп булмады, туган, эч пошуга түзеп булмады!

— Ә тотылсаң?

— Тотылсам ни булыр? Мин бит тылга түгел, передовойга качып барам. Тотсалар да барыбер шунда җибәрерләр — башка юлы юк аның!

— Дөрес чамалыйсың,— мин әйтәм,— соң анда, передовойда, әйбәтрәкмени?

— Ничек дип әйтергә?.. Булмаган кеше өчен — коточкыч, ә булган кеше өчен — ничава, әкренләп ияләшәсең... Мин инде биш тапкыр сугышка кердем, ә соңгысында бер ай буена передовойдан чыкмадым. Әллә нихәтле кеше үлеп бетте, парин, әллә күпме пополнение килде, ә мин, ичмасам, бер генә тапкыр да ранен булмадым. Пулялар ышкылып-ышкылып уздылар, ну, тешләмәделәр ничектер... Алла саклады... Тик минем эчтә язве бар, хәерсез, шул каһәрдән кан килә башлагач, мине көчләп дигәндәй, госпитальгә җибәрделәр. Әмма, туган, мин андагы сасыга, андагы ыңгырашуларга түзә алмадым, тоттым да качтым менә!..

— Ә иленә кайтасың килмиме соң?

— Килмәгәннәр кайда инде ул, туган! — ди агай, өзелеп сулап.— Очып кына кайтыр идем дә бит, булмый шул! Миңа, туган, икесенең берсе: йә илгә, йә передовойга... Ату йөрәкнең януына түзәр хәл юк!

Мин аны землянкага алып кайтып, калган ботка белән сыйладым, кулына да бераз икмәк бирдем. Агай бик канәгать булды. Ә озата чыккач, үзенә: «Бу юлы да пулялар тешләми генә узсыннар инде»,— дидем. «Иншалла!» — диде ул, гади генә итеп. Агай үзенең исән-имин калуына бик ышанып китте бугай.

Моның кебек һич уйламаган-көтмәгән кыска гына очрашып аерылышулар фронт шартларында солдат кешесе өчен бик табигый хәл. Ләкин бик күбесе онытыла икән. Бары аерым кеше үзе (әгәр аның кайсыдыр ягы күңелгә ошап калса) яки ул сөйләгән берәр кызыклы вакыйга гына ничектер әле хәтердә сакланып тора. Әмма күбесе онытылса да, көтелмәгән очрашу һәрвакытта нindидер бер эз калдырып китә. Чөнки һәр солдатның күргән-белгәне үзе бер дөнья, шуның өстенә, әле аның бөтенесенә үз карашы, үз аңлатмасы, үз фәлсәфәсе дә була. Боларны син бер газетадан, бер китаптан да таба алмыйсың.

Бүген дә менә, әлеге куй белән әвәрә килеп йөргәннән соң, нигәдер шундый бер очрашу табасы килеп китте. Яңа кеше күрү, яңа сүз ишетү кайчагында бик кирәк була. Ләкин урман эче буш, сукмакларда һичкем күренми, штабельләр ягыннан бер генә машина тавышы да ишетелми, тик мәһабәт-биек, шәрә наратларның чатыр ябалдашлары гына салмак селкенеп, үзенең ямансу-тонык гүләвен урман өстеннән каядыр еракка ашыкмыйча гына куалый. Ахрысы, кызык бетте безгә монда да...

Мин килгәндә Шумилов, шлагбаум киртәсенә күкрәге белән терәлеп, юл буена тик кенә карап тора иде.

— Нихәл, Шумилов, кемне көтәсең?

— Ә, сержант,— диде ул, әкрен генә урыныннан кузгалып.— Кемне көтим, кем килсен безгә? Аякларга бераз җиңелрәк булсын дип кенә шлагбаумга таянып торуым... Вакыт күпме әле?

— Вакытмы? — Мин сәгатемә карап алдым.— Унынчы ярты.

— Шулай гынамыни!.. Күп торасы бар икән әле...

— Ник,— мин әйтәм,— бу вакытны теләгән чакта тизләтеп яки әкренәйтеп булмый икән, ә?! Вакыт — рәхимсез нәрсә. Аның йөрешен үзгәртерлек кодрәт юк дөньяда. Тик шулай да без аны төрлечә тоябыз: кайчакта үткәнен сизми дә калабыз, ә кайчакта үткәрә алмыйча җаныбыз чыга... Шулай түгелме?

— Анысы шулай инде... Менә машиналар өзлексез килеп торган чакта алты сәгать вакыт ничектер тизрәк үтеп китә торган иде. Ә хәзер юк, барысы да тукталды.

— Бүген килүчеләр бер дә булмадымыни?

— Кайсыдыр станциядән зенитчиклар гына килеп, ике машина төяп киттеләр.

— Аз икән шул. Йә, ни сөйлиләр берәр яңа хәбәр ишетеп калмадыңмы үзләреннән?

— Ә нәрсә ишетәсең алардан? — диде Шумилов, кулын селтәп.— Көне-төне күккә карап яталар шунда... Ә күк йөзе чип-чиста хәзер, немец адашып кына да килеп чыкмый, ичмасам. Койрыгын тәмам кысты, мин әйтәм...

— Вакыттыр инде, җитәрлек котырынды.

— Вакыт, вакыт, бик вакыт! — диде Шумилов, бу сүзгә тагы да зуррак мәгънә салып.— Да, зенитчикларның шоферы шуны сөйләп торды әле: немецлар, имеш, Балтик диңгезенең нindидер бер ярыматавында тупланып, ныгып алганнар, имеш. Шунда хәзер бик каты сугышлар бара, ди, ник дисәң, безнең мондагы тыл өчен бик куркыныч икән алар.

— Нинди ярыматау соң ул, сорамадыңмы?

— Курляндия диде шикелле. Әйе, Курляндия!.. Син, сержант, шуны әйт әле, дөресме икән бу, сводкада берәр сүз бармы ул турыда?

— Белмим, тулы сводканы күптән инде күргән дә, ишеткән дә юк.

— Рота да безне онытты,— диде Шумилов та, күңелсезләнеп.— Нишләп ятабыз соң без монда, кайчан кузгалабыз инде?

— Алдан әйтмиләр бит аны,— дидем мин,— вакыты җиткәч, капыл гына кубып китәрбез әле, гадәттәгечә... Ярый, Шумилов, мин киттем, тыныч кына көт сменаңны!..

— Көтәбез инде, көтәбез! Без көтәргә өйрәнгән,— дип калды Шумилов, арлы-бирле йөренеп.

Шуннан мин өченче постка, Төхфәт абзый янына киттем. Төхфәт абзый миңа якташ дидем шикелле — Баулы тирәсеннән ул. Монда татарлардан без икәү генә, ә шулай да безгә эчләрне бушатканчы иркенләп сөйләшергә бик сирәк туры килә. Төхфәт абзый алты сәгать постта торып кайта да, ашап-эчеп, тизрәк ял итәргә ята. Аннары тагын постка барыр вакыты җитә. Мин дә төрле мәшәкатьтән, арлы-бирле чабудан бушый алмыйм. Шулай итеп, бер тәгәрмәчнең ике теше кебек янәшә әйләнәбез дә әйләнәбез. Әмма шуңа карамастан без барыбер эчкә бер якынлык белән якташ булуыбызны гел генә тоеп яшибез.

Баштарак Төхфәт абзый казакълар белән бер сменада иде. Казакълар аңа атлаган саен «нугай» диләр. Төхфәт абзый әллә белмичә, әллә белмәмешкә салынып:

— Ә кем ул нугай? — дип сорый.

— Кем булсын, син гой! — диләр аңа.

— Юк, мин нугай түгел, мин саф татар,— ди Төхфәт абзый, күкрәк сугып.

Тегеләр көләләр генә:

— Без татарны белмәйбез, без нугайны гына беләмез!

Кайчагында шул юк кына нәрсәдән чак талашып китмиләр иде. Соңыннан бер авыз русча белмәгән Ишмәмәтне казакълар янына күчереп, аның урынына Төхфәт абзыйны куярга туры килде. Хәзер бу сменада рус, чуаш, татар — үзенә күрә кечкенә генә бер интернационал. Төхфәт абзый аеруча чуаш Емелькин белән дуслашып китте — серләре килеште, күрәсең.

Өченче пост бәләкәй генә бер калкулык өстендә тора. Өч ягы урман, каршы якта — ачык кыр. Төхфәт абзый шул калкулык түбәсендә әйләнеп йөри-йөри үзенә түп-түгәрәк бер сукмак салып бетергән. Мин килгәндә дә шунда әкрен генә әйләнеп йөри иде.

— Төхфәт абзый, бу мин әле,— дидем, аңа якынлашып.

— Әйдүк, туган, рәхим ит! — диде ул, өенә чакырган-дай бик ачык кына.
— Кәефләр ничек соң?
— Кәефләр шәп!
— Шулай укмыни?
— Көнен кара син, көнен! Атланмай кебек бит. Җылы, тымызык, пәрәвезләр оча, әбиләр җәе инде бу...
Бүген көн чынлап та гаҗәеп хозур иде. Күктә бер болыт әсәре юк, кояш үзе генә бик иркенләп, җәйгечә юмартланып кыздыра, каяндыр тагын әкрен генә иркә-йомшак җил дә искәләп куя — кыскасы, бу якларда мондый вакытта бик сирәк була торган көннәрнең берсе иде.
— Әле, туган,— диде Төхфәт абзый, нигәдер үзеннән-үзе җанланып,— эзли торгач, мин малай чакта атай мәрхүмнең җырлый торган бер көен тәки таптым бит. Күптән эзли идем инде мин аны... Ни хикмәттер, ул көйне хәзер җырламыйлар да, уйнамыйлар да. Белүче юк, ахрысы... «Агач башы» дип атала. Җырлап күрсәтимме?
Аның бу көтелмәгән сәер куанычына мин бераз гаҗәпләнә калдым. Юри генә:
— Постта җырларга ярыймы соң? — дигән булдым.
— Сез рөхсәт итсәгез, ярый торгандыр.
— Хәйләкәр үзең дә!.. Җырла инде, алайса.
Төхфәт абзыйның тавышы көр, матур гына иде. Ул, мылтыгына таянып, аз гына тынып торганнан соң, бер тамак кырып алды да каядыр югары карап, тавышын тыя төшеп җырлап та җибәрде:

Агач башкайлары тәсбих әйтә
Әкрен искән җил белән.
Сәвешеп-сәвешеп тә кауша алмаган
Бер без генә түгел, ил белән.

Җырның соңгы ике юлын бик хисләнеп, сузып-тибрәтеп бетерде дә аннары бәхетле елмаеп:
— Йә, ничек соң, малыкаем! — диде.
— Әйбәт, бик әйбәт! — дидем мин дә әсәрләнеп.
Юк, чыннан да, бу бер дә ишетелмәгән бик матур көй иде. Үзе бик борынгы да булса кирәк. «Агач башы»... «Агач башкайлары тәсбих әйтә...» Гаҗәп, кешенең күңел хәзинәсеннән ниләр генә табылмый! Җитмәсә, менә монда, туган илдән ерак чит-ят җирләрдә!.. Хәер, язмыш кешене кайларга гына ташламасын, күкрәгендә шул бер үк йөрәкне йөртә инде ул...
Тик Төхфәт абзыйдан бер нәрсәне сорыйсым килде:
— Ник син «сәвешеп... сәвешеп» дип җырлыйсың, мишәр түгел ич син!

— Шулай тәмлерәк чыга ул,— диде Төхфәт абзый.— Атай мәрхүм дә шулайрак җырлый иде. Нигәдер ялгыз чакта үзе өчен генә җырлый иде ул аны: күрәсең, бәгыренә төшкән җыру булгандыр инде... Ә мин бәләкәй ул чакта, бернәрсә аңлый да, уйлый да белмәгәнмен, ә шулай да күңелнең әллә кай җирендә генә сакланып яткан бит әле. Табылды, Ходаның хикмәте!

— Тагын югалта күрмә инде.

— Юк, кайда ул югалту! Мин аны, туган, башлар исән булса, илгә алып кайтам әле, авылыбызга... Мәҗлесләрдә җырлыйм әле мин аны, Алла бирсә, фашисттан тере калган җыр итеп...

— Амин диген!

— Амин алайса, амин!

Бу сөйләшүдән соң мин инде башка нәрсәләр (әйтик, безне туйдырып бетергән каравыл хезмәте) турында сүз кузгатып тормыйча, Төхфәт абзыйны үзенең бәхетле табышы һәм күтәренке кәефе белән генә калдырып китәргә булдым. Тагын бер постка сугылып, тизрәк үзебезнекеләр янына ашыктым — анданиләр бар икән?

Кайтсам — тамаша! Казакъ агайлар, әйтергә кирәк, эшне бик кызу тотканнар. Землянкадан бер читтә зур гына таган ясап, астына ут ягып җибәргәннәр, шул таганга аскан ике чиләктә куй ите богыр-богыр кайнап, инде пешеп тә ята!.. Тагын иң гаҗәбе шул — учактан ерак түгел чиста үлән өстенә плащ-палаткалар җәеп әзерләгән табын әйләнәсендә Өметбаев, Байәхмәтов, Шанаев кебек картрак казакълар аяк бөкләп, ашыкмыйча вәкарь белән генә үзара сөйләшеп утыралар, ә учак тирәсендә —кем диегез? — безнең лейтенант белән Акшалов тирләп-пешеп булашалар. (Лейтенант каешын салып ташлаган, изүен чишкән, җиңнәрен сызганган, күренә — бик дәртләнеп эшкә тотынган.) Монда хәзер чин, дәрәҗә дигән нәрсә беткән. Тегеләре өлкәннәр сыйфатында, кунак шикелле, табынга ит килгәнне көтәләр, ә болары яшь булганга күрә дә алар алдына барысын да пешереп-төшереп китерергә тиешләр. Гаҗәп икән ул традиция дигән нәрсә! Башка чакта безнең лейтенант — үзенең шул кечкенә званиесенә дә зур әһәмият биреп, солдатлардан өстен торырга яраткан кеше — хәзер исә бөтенесен онытып, гади бер кыргыз егетенә әверелеп, шул ук солдатларга чын ихластан бик бирелеп хезмәт күрсәтә. Ә мин, җүләр, аны бүген куй тирәсеннән читтәрәк йөрер, дип уйлаган идем.

Табындагы казакълар мине дә, күрү белән, үз яннарына чакыра башладылар:

— Ә, сержант, кил, утыр безнең янга!

Ләкин мин утырырга ашыкмадым. Бердән, аларга караганда мин дә бит әле шактый яшь кеше — өлкәннәр рәтеннән аяк бөкләп, ит килгәнне көтеп утыру килешмәс, йолага сыеп бетмәс, дип уйладым. Икенчедән, ничектер лейтенанттан да яхшы түгел иде — казакъларның чин, дәрәҗәне онытып торырга хаклары булса да, мин сержант башым белән онытырга тиешме?.. Әмма казакълар чын ихластан кыстыйлар: кил, утыр да утыр! Бүген син табынның хуҗасы! — диләр. Бигрәк тә Дорды, җиргә учы белән суга-суга, үз янына чакыра:

— Килсәңче, кил!.. Бүген синең белән миңа түрдә утыру хәләл гой!.. Законный...

Ахырда лейтенант та әйтеп куйды:

— Утыр, сержант! Казакъның әңгәмәсен тыңла, сиңа бүтән эш юк монда.

Билгеле, мин, артык кыстатмыйча, рәхмәтемне әйтеп кенә Дорды янына урнаштым. Башта аякларны бөкләп утырган булдым, ләкин буыннар күптән катып беткәннәр икән инде, тизрәк кырын утырып, «тәртәләрне» читкә сузып җибәрергә туры килде.

Казакъ агайларның әңгәмәсе бүленеп торган икән, мин утыргач та яңадан шуңа күчтеләр. Сүз ашау мәсьәләсе турында барган, ахрысы.

— Йә, сөйләп бетер, Дорды! — диде Шанаев.— Ризык хакында нидер әйтмәкче идең...

— Ә, ийе,— диде Дорды, селкенгәләп.— Кай төштә бүленеп калдык әле?..

— Госпиталь дип башлаган идең гой!

— Тугры... Менә шул, бу ротага килгәнче мин бераз вакыт үзем яткан полевой госпитальдә эшләп алдым. Зур гына бер урыс авылында торабыз. Көн дә пирдавайдан атларда, машиналарда яралыларны китерәләр, без шуларны нәсилкә белән өйләргә ташыйбыз... Авыр эш димәс идем, әмма җанга бик тия торган эш. Аннан-моннан гына марля ураган, кан саркып торган нинди генә яралыларны күрмисең анда!.. Күбесен алып керү белән өстәлгә салабыз. Духтырлар, кассапчыдай, кулларыннан пычакларын төшермичә, ярып-кисеп кенә торалар... Каннан, үле истән тамакка тәмам ризык үтмәс булды, бушаган арада бары кайнар чәй генә эчәбез... Ләкин беркөнне шулай яралылар килгәч, уң аягы тездән түбәнрәк өзелгән бер солдатны нәсилкәсе белән машинадан төшердек... Һушында бу, ыңгырашмый да, җитмәсә, әкрен генә нидер кимерә. Карасам — сохари! Кемдер моңа сохари тоттырган, бу бичара шуны кан эчендә кимереп җатыр!..

Күреп исләрем китте. Әстәгъфирулла, бу ни тамаша, мин әйтәм!.. Шул чакта адәм баласы өчен тамакның никадәр яман нәрсә булуына тагын бер мәртәбә иман китердем гой!

Казакълар гаҗәпләнеп баш кактылар, аннары Дорды белән килешеп, дөрес шул, тамак яман нәрсә, ач тамак барысын да, хәтта өзелгән аякны да оныттыра, диештеләр.

Гомумән, солдатның моның ише искә төшереп сөйләр әкәмәт нәрсәләре күп була. Ышанырлыгы да, ышанмаслыгы да... Тик шулай да карт солдатлар артык тузга язмаганын тыңларга яратмыйлар, күбрәк гыйбрәтлесен генә тыңлыйлар. Менә Шанаев та башыннан кичкән бер хәлне сөйләгән булды. Имештер, ул, кышкы төндә, кайдадыр бер урман авызында постта торган чакта, әрлебирле йөри торгач, аяклары арып бер бүрәнәгә ял итәргә утырган булган. Яктыра төшкәч, утырган «бүрәнәсенә» караса, ни күрсен, ул туңып каткан немец гәүдәсе, имеш!

— Вай-вай, атаңа нәләт! — ди Шанаев, шул чактагы куркуын, янәсе, исенә төшереп.— Тәннәрем эсселе-суыклы булып, арка буйларым кымырҗып китте гой!

Ләкин аның бу әкиятенә берәүнең дә исе китмәде, көлүче дә булмады,— колак төпләреннән генә уздырдылар. Ышанмаудан түгел, мондый нәрсәнең булуы бик мөмкин, тик мәгънәсе юк, мәгънәсе булмагач, кирәге дә юк. Аннары, дөресен генә әйткәндә, алар Шанаевның еш кына борчак сибәргә яратуын да беләләр иде.

Әмма безнең казакъларның иң яраткан эшләре — күргән төшләрен сөйләү һәм шуны юрау... Әйтерсең һәркайсы төш күрер өчен генә ятып йоклый һәм уянгач та хикмәтле төшен бик тәмләп, бик тәфсилләп иптәшләренә сөйли. Тыңлаган чакта, бу төшме икән, әллә үзе уйлап чыгарган берәр әкиятме дип тә аптырыйсың. Чөнки бик тә инде җөе җөйгә килеп торган гаҗәп төгәл, бөтен бер вакыйга булып чыга. Андый төшне бик рәхәтләнеп тыңлыйлар һәм җыйнаулашып юрыйлар. Билгеле инде, бары тик яхшыга.

Шулай да араларында төшнең төрлесен күреп тә, сөйләп тә иң остарганы — Бәйәхмәтов. Әйткәнемчә, бу гәүдәгә зур-таза, мәһабәт казакъ иде. (Менгәндә атның билен сыгып төшергәндер.) Бөтен җире эре аның — башы, бите, аяклары, куллары... Хәрәкәтләре салмак, тавышы да көркалын... Нигәдер ул миңа токымы белән казакъның борынгы аксөяк түрәләренә яки ыруг башлыкларына барып тоташкан, хәзер инде бик сирәк очрый торган, санаулыга гына калган бер кеше булып тоела иде. Шуңа күрә аны саклыйсы да килә. Бездәге нестроевойларны карап үткәргән бер комиссия вакытында врач та, аңа көлеп:

— Син, агай, бу бүсереңне күз алмасыдай сакла, кайтсаң, шуның аркасында гына иленә исән-сау кайтырсың,— дигән иде.

Әлбәттә, ул казакъның түгәрәк табыннарында күп утырган, легендаларны күп ишеткән, думбыра чиертеп әйткән үләңнәрне күп тыңлаган булырга тиеш. Шуңадыр, ахры, аны бик яратып тыңлыйлар. Ул инде төшендә Сталинны да берничә тапкыр күрде, Рузвельтны да күрде, хәтта Гитлерны күрүдән дә куркып тормады. Ә аларны төштә күрүнең хикмәте бик зур икән: сугышның кайчанрак бетүен яки тагын күпмегә сузылуын аеруча шуларның төшкә ничегрәк керүләренә карап юрыйлар.

Менә хәзер дә ул үткән төнне генә күргән төшен сөйләргә җыенды. Көр генә итеп бер тамак кырып куйды. Башкалар шунда ук тынып калдылар.

— Төшем озын имәс,— диде Байәхмәтов, салмак кына сүзен башлап,— әмма хикмәтле булса кирәк. Шулай, бик күп халык кызыл эшелонга төялеп, үземезнең казакъ даласы буйлап китеп бара җатырмыз икән. Яз башы, дала ямь-яшел, бихисап куйлар, җылкылар утлап йөри икән. Шул гаҗәеп тә хозур, сәйран сахраны тамаша кылып барганда, кинәт вагоннарымыз дөбер-шатыр сикерешергә, уңга-сулга яман чайкалырга тотынды гой! Бу ни булды дип ишектән сузылып карасак, эшелонымыз шпаллар өстеннән генә китеп бара-җатыр икән. Төшенәсезме, рельслар җук, шпаллар гына! Шул шпалларны ватасындыра, мәтәлә-кадала, эшелон алга ыргылды гой! Туктау уенда да җук, җен оргырның! Бөтенебез идәнгә тәгәрәшеп беттек, сикереп төшәр мәҗәл дә җук, менәменә хәзер вагоннар авып, бер-берсе өстенә өелеп, барымыз да һәлак буламыз гой, дип үкереп-бакырып җатамыз. Шуннан кәен күпмедер вакыт узгач, вагоннарымыз, Кодайның кирәмәте, чайкалмый башлады. Сикереп тордык, ишеккә җабырылдык, карыймыз — ярабби, эшелонымыз яңадан рельслы юлга чыккан, шома гына, җилдереп кенә китеп бара-җатыр икән!.. Җа куандык, җа куандык, шатлыгыннан хәтта җылаучылар да булды. Яңадан үземезнең сәйран казакъ даласын, шунда утлап йөргән бихисап малларны тамаша кылып, хәйран булып барамыз икән. Аннан кәен, озакламый эшелонымыз ак таштан салынган бик матур, бик мәһабәт бер станция алдына килеп туктады. Мәйданда ул халык, ул халык! — диңгездәй чайкалып тора. Бәйләм-бәйләм гөлләр тоткан казакъ кызлары, балаларын кулларына күтәргән казакъ әялләре безне каршы алырга килгәннәр икән! Барымыз да вагоннардан шаулашып төшә башладык, шул чакта

мин дә... уянып киттем. Әялемне бик күрәсем килгән иде, яңадан күземне җомып та карадым, ликин, җук шул, күреп булмады... җә, ни диярсез?

Казакълар барысы беравыздан:

— Яхшы төш бу, яхшы төш! — диделәр, куанышып.

Дөрестән дә, Байәхмәтов күргән (әллә уйлап чыгарган) бу төшнең «хикмәте» бик өстә ята иде. Вагоннар аумаган, кешеләр исән калган, һәм эшелон ак таштан салынган станциягә дә барып җиткән. Билгеле инде, моны шунда ук тиздән сугыш бетүгә, барысының да исәнаман илгә кайтуларына юрадылар. Өметбаев белән Шанаев исә, кулларын күтәреп:

— Амин, шулай булсын! — дип, дога да кылдылар.

Байәхмәтовның башка вакытта күргән төшләре катлаулырак та, кызыграк та була торган иде. (Тик аның шуны казакъча гаҗәп бай тел һәм казакъча интонация белән сөйләвен генә биреп бетерүе мөмкин түгел, хәерсез!) Бу юлы аңа төшнең шәбрәген «күрергә» нидер (мәсәлән, учак тирәсеннән килгән искиткеч тансык, тәмле ис) комачаулады булса кирәк.

Ул арада куй да пешеп чыкты шикелле... Акшалов, котелокта җылытылган суны китереп, үзе чамалап кына коя-коя, барыбызның да утырган җирдә генә кулларын юдырып чыкты. Ә лейтенант һәркайсыбызга кул сөртергә иңендәге тастымал очын биреп торды. Бу да казакъның өлкәннәргә хөрмәт йөзеннән эшләнә торган бер әйбәт йоласы икән.

— Дорды әкә, — диде лейтенант, — инде син итне бер күреп баксаңчы! Алсак та буламы?

Дорды торып учак янына барды да чиләктәге итне пычак очы белән чәнчеп-чәнчеп карады.

— Булган гой! — диде ул, ләкин шулай да чиләкне утлы күмер кызуында әзрәк кенә тотарга кушты. Ит тәмам йомшарып, сөягеннән аерылырлык булырга тиеш икән әле.

Инде сүз дә бетте. Көтәбез. Тантана башланганны көткән шикелле сабыр гына көтәбез. Һәркемнең алдында пычагы белән кружкасы. Ләкин берәү дә кашыгын чыгармаган. Шулай ук табында икмәк тә юк. Бусы мине бераз борчый: ашавын, казакълардан күрмәли, кашыксыз да ашап булыр, ә менә икмәксез ничек ашарга? Мин үзем итне түгел, ботканы да икмәксез ашый белмим.

Акшалов бик әйбәтләп юган бер ящик капкачын китереп, Өметбай алдынарак куйды. Итне шуңа бушатырсыз, диде. Бездә, билгеле, зур табаклар да, тәлинкәләр дә юк. Котелок, кашык, кружка — менә безнең бөтен сервизыбыз шул.

Кинәт Дорды Ишмәмәтне исенә төшерде:

— Ишмәмәт кайда, нигә Ишмәмәт җук?

— Йоклап җатыр,— диде Акшалов,— уяттым, хәзер килер.

Акшаловның әйтүе булды — землянкадан шинелен иңбашына салып, Ишмәмәт үзе дә килеп чыкты. Ашыкмыйча гына табын янына килде, казакъларга сәлам бирде һәм минем яныма аякларын бөкләп, бөрешеп кенә утырды.

— Син нәрсә, әкә җан,— диде Дорды аңа,— казакъларны санга сукмыйсыңмы әллә?..

— Нимәгә алай дисең?

— Дәстерханга чыкмыйча йоклап ятасың гой!

— Тугры әйтмисең, Дорды! — диде Ишмәмәт, сабыр гына.— Син, миһербанлы адәм булсаң, иң әүвәл минем хәлемне сорап белең.

— Хуш, ни булды соң сиңа, әкә җан? — диде Дорды, шунда ук юмаланып.

Ишмәмәт бераз дәшми торды. Аннары ничектер сабыйларча гына:

— Өшим,— дип куйды.— Бизгәгем кузгалып тора, җылынмаммы дип яткан идем.

— Алайса без хәзер сине терелтәбез. Аракы эчәсеңме?

— Юк, мин аракы эчмәймән.

— Җәл,— дигән булды Дорды.— Аракыдан да шәп дару җуктыр, әкә җан!

Шунда Байәхмәт сүзгә кушылды:

— Без хәзер аңа кайнар куй шулпасы салып бирербез. Шуны эчкәч тә җылынып китәр.

— Рәхмәт, кардәш!..— диде Ишмәмәт, башын Байәхмәткә таба бөгеп. Яхшы сүз — җан азыгы, бүтән дару миңа кирәк тә имәс!

Ниһаять, ике чиләкне дә таганнан алып, табынга китерделәр. Чиләкләр янына зур кастрюльне дә китереп куйдылар.

Лейтенант, Өметбайга карап:

— Ата, сез хуҗа булыгыз инде,— диде.

— Ни өчен мин? — диде Өметбай, гаҗәпләнгән булып.— Янымызда өлкән адәм Байәхмәт тә бар, аңа тапшырыйк.

Ләкин табындагылар барысы беравыздан:

— Юк, ата, арабызда иң өлкәне син, әйдә башла! — диделәр.

Шуннан соң Өметбай чиләкне үзалдына тартыбрак куйды, җиңнәрен кайтара төште, аннары бик әйбәтләп бисмилласын әйтте дә, пычак белән генә кадап, чиләктән зур-зур ит кисәкләрен чыгара башлады.

Шуны әйтәм әле, бу казакъларда өлкәнгә буйсыну, өлкәнне хөрмәт итү бик тә нык сакланган икән. Менә Өметбаев карап торырга гап-гади бер казакъ, бүтәннәрдән һичбер өстен җире юк шикелле. Дордыдагы чаялык та юк аңарда, Байәхмәтов кебек оста сөйләүче дә түгел, киресенчә, бик аз сүзле, бик басынкы бер кеше. Ләкин аңардан алды табынга утырмыйлар, аңардан узып кашык сузмыйлар, чөнки ул барысыннан да өлкән, ата, аксакал дәрәҗәсендәге кеше — аңа күбрәк шулай «ата», «чал» дип кенә дәшәләр дә. Шуңадыр, ахры, аның әллә нидә бер әйткән сүзе дә хөкем урынына йөри диярлек. Атналар-айлар буена кешеләр бер-берсенә бәрелеп-ышкылып яшәгәч, алар арасында ызгыш-талаш та чыгып киткәли, ләкин шул чакта Өметбайның каты гына бер сүз әйтеп куюы җитә — талашучылар шунда ук шып туктыйлар. Ни баш бирмәс Дорды да аны тыңларга мәҗбүр, безнең лейтенант та аңа бервакытта да каты бәрелми, хәтта руслар да картка хөрмәт йөзеннән: «Умутбай — это наш главный казах!» — дип кенә җибәрәләр.

Ике чиләктән дә такта капкач өстенә бушаткач, ит тау хәтле булды. Кабарып пешкән, тәмле булары чыгып торган бер өем ит!

Акшалов зарлана:

— Менә куйның башын пешерергә савыт булмады, башы калды,— ди.

Казакълар да — гаҗәп — шуңа үртәләләр: «Баш кирәк иде, башны калдырмаска иде»,— диләр.

Өметбай ит өемен уртага этәрә төште:

— Җәгез, кордашлар, җитешегез!

Ләкин берәү дә сузылырга ашыкмый иде. Шуннан Өметбай лейтенантка:

— Җәле, Нугайбәк чырагым, син безнең командирыбыз, сиңа хөрмәт, алың әле башлап!

— Юк, ата,— диде лейтенант, елмаеп кына,— бу табында мин командир имәсмен, мин кече адәм, сез инде арамызда иң өлкән адәм, аксакалыбыз, кичерегез, сездән уза алмыймыз!

— Тугры әйтә лейтенант! — диештеләр бүтәннәр дә.

Шуннан соң Өметбай: «Ярый, җоладан узмак җук»,— диде дә, үрелеп, бик зур кисәкне кулы белән генә алдына алып куйды. Аның артыннан Байәхмәт сузылды, аннары Шанаев белән Дорды, тик шуннан соң гына лейтенант та үрелде. Аның артыннан инде мин дә үрелдем. Ишмәмәткә шунда ук кайнар шулпасын да салып бирделәр.

Менә изге бер эш үтәгәндәй, дөнья сүзләрен онытып, бик ипләп-бирелеп кенә мәрхүм куйны ашау башланды.

Казакъларның һәркайсында үткен пычак яки пәке, шуның белән итне җиңел генә калҗалап кисә дә пычак өстеннән төшермичә кабып та җибәрә. Бер калҗа артыннан икенчесен, өченчесен каба, аннары авызы тулгач, ашыкмыйча, озак кына итеп чәйнәргә тотына. Мин дә, алардан күрмәли, пәкемне чыгарып, кискәләп ашарга тотындым, ләкин беренче калҗадан ук икмәксез күңелгә авыр буласын сиздем. Акшаловтан икмәк сорагач, казакълар бик гаҗәпләнделәр:

— Нимәнәгә нан? Итнең тәмен бетерәсең гой!

— Гадәт,— мин әйтәм,— шулай өйрәнгәнбез инде.

Үзләре инде алар, билгеле, калҗаның иң майлысын да чырай да сытмыйча голт иттереп кенә йотып җибәрәләр. Һәм шул чакта бик хуш булып, Дордыны куйның зурысын, симезен сайлый белгәне өчен, ә Акшаловны тәмам җиренә җиткереп пешереп чыгарганы өчен мактап-мактап куйгалыйлар. Бүтән сүз юк, авыз да буш түгел, игътибар да пычак белән иттә генә. Ит белән эш тәмам булгач, кастрюльдән кружкаларына шулпа салып, шуны ашыкмыйча гына эчәргә тотындылар. Казакъча әйтсәк, бу тозлык та бик тәмле-үткер иде. Аны эчкәч, карынга тулган ит бердән сеңгәндәй булып, күңел нечектер ачылып та китте.

Шулай итеп, сүзе, мәшәкате шактый озынга сузылган бу латыш куен — урыны җәннәттә булсын! — ярты сәгать эчендә очлап та куйдык. Аллаһе әкбәр!

Хәзер инде, бәлки, гадәт буенча, мул иттән соң аксакалларга әзрәк мендәргә таянып тору кирәк булгандыр, ләкин безнең лейтенант иң башлап урыныннан торды да сәгатенә карап:

— Постка барыр вакытыгыз җиткән, давай кузгалыгыз! — диде һәм гимнастерка төймәләрен каптырып, агач ботагына элгән каешын алып биленә буды.

Куй хөрмәтенә кыска гына вакытка килгән иске йола тәртибе бетте, чин, дәрәҗә, дисциплина — барысы да кире үз урынына кайтты, яшь Нугайбәк яңадан командирга, ә өлкән казакълар гади солдатка әйләнделәр дә куйдылар... Мин дә ашыгып урынымнан тордым — чыннан да, смена алыштырырга ярты гына сәгать калган иде. Ләкин казакълар, ялварып диярлек, әз генә чәй эчеп алырга вакыт сорадылар.

— Тиз булсагыз гына! — дип кисәтте командир аларны.

Акшалов ашыгып зур кара чәйнеген китерде, һәркайсының шулпадан бушаган кружкасына чәй ясап чыкты. Казакълар дегеттәй каты чәйне, кабаланып, өрә-өрә эчтеләр.

Ә бер егерме минуттан соң инде мин тирләгән-пешкән, пух итеп торган агайларны сафка тезеп, өс-башларын, мылтыкларын тиз генә күздән кичереп, үз артымнан ияртеп постларга алып та киттем. Акшалов исә сменадан кайтучыларга, алар өлешенә калган итне пешерер өчен, яңадан таган аса калды.

Әбиләр җәе дә үтеп китте, көннәр, ниһаять, бозылды, көзге салкын вак яңгырлар башланды. Монда, бу Латвия җирендә, яңгырлар бер башланса, һич тә туктый белми икән. Көне буе ява, төне буе ява, атналар буенча ява — әйтерсең бөтен дөньясын суга гарык итмәкче була. Һавасында — су тузаны, агач ботакларында су агып йөри, ылыслардан тамчылар терекөмештәй өзлексез тәгәрәшә... Үлән арасыннан ун адым да үтәр хәл юк, шинель чабулары шунда ук юешләнә, ә юлга чыксаң, кара үзле балчык итекне аяктан суыра... Һавада йөзгән бу юешлек безнең өстебезгә сеңеп бетте, землянканың бөтен бүрәнәләренә сарылды, хәтта ашый торган азыкларыбызга үтеп керде.

Иң әшәкесе тагын шул: солдат посттан кайткач, юеш землянкада өс-башын киптерә алмыйча интегеп бетә. Акшалов землянка уртасындагы кечкенә түгәрәк тимер мичне өзлексез ягып торса да, бердән, аның җылысы да аз, икенчедән, аның тирәсенә бары чолгауларны элеп, итекләрне генә тезеп куеп була. Ә плащ-палатка, шинель кебек зур киемнәрне киптерергә, гомумән, бернинди дә мөмкинлек юк. Кайберәүләр шинельләрен мич өстенә салындырып, түшәмгә элеп куйган булалар, ләкин аңардан ни файда — шинельнең чабуыннан тамчы тамып, өстеннән пар гына чыгып тора. (Җитмәсә әле, солдат йоклаганда шул шинелен ябынып та ятарга тиеш.)

Яңадан постка барыр вакыт җиткәч, солдат дигән кеше, тагын дымлы чолгавын урап, җылынып җитмәгән итеген, юеш, авыр шинелен киеп, яңгыр сеңеп беткән плащ-палаткасын бөркәнеп, караңгы, пычрак, салкын төн эченә чыгып китәргә мәҗбүр... Әмма иң гаҗәбе — шушындый хәлдә дә берәүнең дә авырганы юк; ичмасам, томау төшеп төчкергән кеше дә юк. Хәтта безнең Ишмәмәт — көзге чебеш — ул да ник кенә бер зарлансын! Бизгәген дә җиңде шикелле... Ә бит аңа, эссе коры яктан шушы салкын юешлеккә килеп эләккән кешегә, күптән авырып егылу кирәк иде. Юк, егылмый, тора, бите йодрык хәтле генә булып калган, авызы-борыны күгәреп беткән, ә шулай да алты сәгатен «эһ» тә итмичә тора! Бер какланса каклана икән адәм баласы!

Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, солдатларның кәефлә-

ре бик начар. Эчләрендә гел ачу кайный, нервлары бик тартылган, юктан да ызгышып китәргә генә торалар, плащ-палатка бавы чәбәләнсә дә, бик әче итеп сүгенергә тотыналар. Бу җәһәттән казакълар бик зәһәр икән. Бер сүгенә башласалар, Гитлерның җиде бабасына барып җитәләр... Билгеле инде, болар барысы да шушы бер урында һәм билгесез бер хәлдә каңгырап торудан килеп чыга. Әгәр кузгалып китә калсак, солдатларның кәефләре көне-сәгате белән үзгәрәчәк.

Кайчагында лейтенант белән без дә «чәкәләшеп» алабыз. Мин аңа: «Кайчан бу сазлыктан ычкынабыз инде, син, командир кеше, ник шуны белергә тырышмыйсың?» — дип бәйләнә башлыйм. Ә ул, кызып: «Кайдан, кемнән беләсең аны? — ди.— Армиядә бервакытта да бернәрсәне дә алдан әйтеп куймыйлар. Может, иртәгә үк приказ килер. Безнең эш — көтү, сержант, көтәргә кирәк!»

Димәк, көтәргә, көтәргә һәм, чуаш Емелькин әйтмешли, службаны онытмаска!.. Минем эш билгеле инде — развод ясау һәм постларны әледән-әле тикшереп тору. Хәзер төннәр бик озын, постларны берничә тапкыр йөреп чыгарга туры килә. Әйтергә кирәк, безнең солдатларның һәркайсы бу дегеттәй төн эчендә, агач башындагы ябалак шикелле, бик уяу тора, якынлаша башлауга шунда ук: «Тукта, кем килә?» — дип кычкырып тавыш та бирә. Инде мин икәнне белгәч, ничектер куанып та китә. Үз кеше, җанлы сүз — менә хәзер аңа бик тансык бит ул, биш-ун минут кына сөйләшеп тору да аның күңелен күтәреп җибәрә, әзрәк кенә вакыты да кыскара төшкәндәй була.

Ә беркөнне лейтенант, Акшаловны ияртеп, үзебезнең ротаны эзләп китте. Ротаның бездән каядыр алга таба бик ерак киткәнен ишетеп белә идек, ләкин урнашкан җире ачык кына билгеле түгел иде. Елгавадан көнчыгыштарак, диделәр... Йомыш күп җыелды. Бу урынга килеп эләккәннән бирле хатлар алганыбыз юк (чөнки хатлар рота адресына киләләр), шулай ук үзебезнең бик кадерле солдат акчасын да (аена утыз ике сум) менә өч ай инде алганыбыз юк, аннары ротадан безгә азык-төлекнең дә яхшысы тия торган иде. Кыскасы, лейтенант чакыру көтеп ятты, ятты да ахырда тәвәккәлләп китәргә булды.

Аның урынына мин калып тордым. Служба шулай бер көйләнгән көе бара да бара, таң ата да кич була, ләкин без хәзер барыбыз да лейтенантның әйләнеп кайтканын көтеп яшибез. Минем исәбемчә, ул кимендә берәр атна йөрергә тиеш иде. Ротаны табасы бар, бер өч-дүрт көн

торасы бар (кумасалар, нигә ашыгырга?), аласы нәрсәләрне аласы бар — боларның барысы өчен дә бер атна күпмени ул? Ләкин лейтенантыбыз өченче көн дигәндә әйләнеп кайтты да төште. Хәер, нәкъ кайткан чагында гына мин взводта юк идем, территориядә йөри идем. Бер заман землянкалар янына килсәм, солдатларның барысының да кулларында хат! Һәркайсы аулаграк урынга китеп, йә сөялеп, йә чүгәләп дигәндәй, хат укып тора!.. Алай, лейтенант кайтып та җиткән икән. Бик шәп. Хат килгән көн бит ул, җанкисәкләрем, солдат өчен иң шатлыклы көн! Чын бәйрәм! Бигрәк тә айлар буе көткәннән соң...

Иң элек мин Төхфәт абзыйга тап булдым. Бер агач төбендә бу борынын тартып, шыңшып утыра — кулында хаты.

— Әллә җылыйсың инде, якташ? — дим мин моңа, янында тукталып.

— Җылыйм шул,— ди Төхфәт абзый, бер дә тартынып тормыйча.

— Ник, әллә берәр кайгылы хәбәр язганнармы?

— Юк, андый хәбәр юк, Аллага шөкер!

— Соң шулай булгач?

— Мә, үзең укы,— ди бу, миңа хатын сузып.— Башыннан ук укы!

Мин, хатны алып, эчемнән генә укыйм:

*«Сезки сөекле, дөньяда иң якын күргән кадерле абыем, сиңа безки туганың Шәрифәдән күңелемнең иң нечкә җирләреннән парланып чыккан ялкынлы саф сәламемне җибәреп, алма бакчаларында төрле матур гөлләргә кунып, тирән уйларга чумып сайраган сандугач-былбыллар санынча сагынып, саргаеп, абыем, синең нурлы йөзләреңне бер күрергә зар-интизар булып, өзелеп, күптин-күп сәламнәремне, абыем, сиңа бүләк итәм...»*

Һәм тагын әнисеннән, Төхфәт абзыйның хатыныннан, балаларыннан, туган-тумачаларыннан, күрше-күләннән шундый ук бик өзелеп, бик ялкынланып, шуңадыр, ахры, шактый керделе-чыктылы итеп язылган сәламнәр тезелеп киткән...

Шуларны укыгач, мин хатны кире Төхфәт абзыйга суздым:

— Бик матур язылган хат ич бу!

— Менә шул шул! — диде Төхфәт абзый, учы белән күзләрен сөрткәләп.— Кайдан гына сүзләрен табып бетергән, бәгырькәем, күз нурым. Ый-ый!..

— Йә, йә, килешмәгәнне! — дигән булдым мин, китә башлап, ә үземнең бугазга шулай да төер килеп тыгылды, хәерсез!.. Һай, бу сагышлар! Солдатның күз яше күптән

кибеп бетте инде, бер генә газаптан, бер генә бәхетсезлектән дә җылый алмый ул, ә менә сагыну яшьләре калган, сагыну яшьләре бәреп чыга. Гаеп итеп буламыни аны моның өчен?!

Мин, ашыгып, үзебезнең землянкага кердем. Лейтенант инде ялгызы гына җәелеп чәй эчеп утыра иде. Хәрби тәртип буенча мин аңа рапорт бирә башлаган идем дә, ул, шунда ук мине бүлеп:

— Ярый, сержант, беләм, барын да беләм, әйдә, уз, әллә кайда йөрисең! — диде.

Бу инде дусларча үз итеп каршы алу иде. Димәк, лейтенантның кәефе бүген аеруча шәп. Шулай да мин сорадым аңардан:

— Бик тиз әйләндегез, иптәш лейтенант, юлыгыз уңышлы чыктымы соң?

— Әйтмә, юлыбыз җөдә уң булды, сержант!

Шулайга охшый. Аның түп-түгәрәк киң бите чыгып килгән ай шикелле балкый иде. Ә өстәлдә күптән күрмәгән ризыклар: ак май, каклаган колбаса, печенье, хәтта берничә шоколад плиткасы да ята. Шуның өстенә әле лейтенант, кыр сумкасыннан чыгарып, миңа ике пачка сигарет та сузды.

— Мә, бусы сиңа күчтәнәч!

Мин дөя сурәте төшерелгән бик матур пачканы әйләндереп-әйләндереп карадым:

— Немецныкы, ахрысы?

— Трофей бу, сержант. Безнекеләр Риганы алганда немецларның ачык складларын бөтен килеш кулга төшергәннәр. Шуннан чыккан нәрсә бу.

— Чигәргә ярыймы икән соң?

— Ярый, ярый, безнең рота командиры үзе даим шуны чигеп йөри.

Аннары ул миңа өч хат та чыгарып бирде.

— Менә болар өчен сезгә, лейтенант, Алатау чаклы рәхмәт! — дидем мин, хатларга ябышып. Ләкин шунда ук ачып укый башларга яхшысынмадым — мине сыйлыйсы килеп көтеп утырган командир белән ничектер санлашмау булыр иде. Шуңа күрә хатларның сызык астындагы адресларын гына карадым да хәзергә үзләрен чалбар кесәсенә генә салып куйдым. Әйдә, мине җылыта торсыннар!

Лейтенантның бу тансык сыйлардан башка төяп алып кайткан яңа хәбәре дә шактый икән, мин чишенеп утыргач та, ул шуларны сөйләргә тотынды.

...Безнең мондагы фронтларда зур үзгәрешләр булырга тора, диде. Балтик буеның күп өлеше немецлардан азат ителгән, сугыш хәрәкәтләре тиздән Польша җиренә һәм

Көнчыгыш Пруссиягә (димәк, Германиянең үзенә) күчәргә тиеш, шул сәбәпле мондагы совет гаскәрләренең күп өлешен бүтән фронтларга күчерүләре ихтимал, шулай булгач, безне дә монда озак тотмаслар, диде. Мин лейтенанттан, теге немец частьларының кайдадыр бүленеп калуы турында йөргән сүзләр дөресме, дип сорадым. Әйе, дөрес, диде лейтенант, фашист гаскәрләренең шактый зур группасы (утызлап дивизия, имеш) Курляндия ярыматавында бүленеп калган, шунда ныгып безгә бирелергә теләмичә бик каты сугышып ята икән. Әлбәттә, ул группаны бетерү өчен монда безнең берничә армияне калдырырлар, ләкин барыбер күпмедер гаскәрне моннан икенче фронтларга күчерергә тиешләр. Шулай дигән рота командиры, офицерлар арасында шундый сүзләр йөри дигән, әмма кайчан, кайда — бу кадәресе хәрби сер, берәү дә белми икән әле аны.

Сыйлар тәмле, хәбәрләр кызыклы иде, ләкин күрәм, лейтенантка ял кирәк. Озын, авыр юлдан ватылган кеше әнә чәйдән соң изри дә башлады.

— Сез ял итегез, лейтенант! — дидем мин, урынымнан торып.

— Әзрәк кенә кирәк шул,— диде лейтенант, тапчанына күчеп.

Мин шинелемне кидем дә кесәдәге хатларны аулакта тыныч кына укыр өчен землянкадан чыгып киттем.

...Тагын җепшек, шыксыз, соргылт көннәр сузылды. Сугыш бар да кебек, юк та кебек, вакыт уза да кебек, узмый да кебек... Көтүдән дә әшәке нәрсә бармы соң?.. Ләкин, мең шөкер, бу юлы безгә шулай да бик озак түзәргә туры килмәде. Иң элек, көннәрдән бер көнне, безнең склад территориясендә ниндидер яңа кешеләр күренде. (Погоннарына караганда артиллерия офицерлары.) Алар склад начальнигы белән берлектә төрле җиргә өелгән штабельләрне карап йөрделәр, территориягә керү-чыгу юлларын тикшерделәр, аннары сөйләштеләр-ниттеләр дә китеп тә бардылар. Безнең лейтенант та гел аларга ияреп йөрде. Соңыннан мин сорагач, ул, болар унынчы армиядән килгән кешеләр, боеприпасларны моннан чыгару турында сөйләштеләр, дип әйтте. Күңелле хәбәр иде бу... Шуннан соң өч-дүрт көн дә узмагандыр, ниһаять, безнең рота командиры да килеп җитте. Үзе генә түгел, аның белән бергә армия базасыннан майор Исаев һәм безгә таныш булмаган бер капитан да килгән иде.

Армиядә һәрвакытта шулай ул — берәр төрле эш башланса, бик кызу тоталар. Рота командиры өлкән лейтенант Поляков безнең белән күрешеп, әзрәк кенә хәләхвәлне сорашкач та әйтте:

— Ну, егетләр, сезгә монда кызынып ятулар бетте. Иске-москыларыгызны җыя торыгыз, бер-ике көннән бу урманда сукыр тычканнардан башка беркем дә калмаячак!

Кыскасы, аның ярым шаяртып әйткәннәреннән шул мәгълүм булды: мондагы барлык боеприпасларны тиздән вагоннарга төяп, алгы позициядәге икенче бер армиягә алып китәчәкләр. Бу склад исә гомумән бетереләчәк.

Ул шунда ук лейтенант Кулибаевка постларны кыскартырга, бары шлагбаум белән штабельләр янында гына ике пост калдырырга кушты.

— Ә сактан бушаганнарның барысын да — боеприпаслар төяргә! — диде.

Без моңа әйтеп бетергесез шат идек. Ниһаять, китәбез! Каядыр алга таба — Литва, Польша якларына таба китәбез! Ротабызга кайткач, мунча керербез, күлмәк-ыштан алыштырырбыз: бәлки, әле җылы өйләрдә дә йокларбыз. Солдатка тагын ни кирәк?!

Шул ук көнне төштән соң биш «Студебеккер» машинасы (зур, таза машиналар!) килде, һәм боеприпасларны шуларга төяп, ике чакрымдагы тимер юлга ташу да башланды.

Безнекеләр җен урынына эшләделәр. Авыр снарядларны төяү-бушатудан бик җәфаланган чаклар да бар иде, ләкин бу юлы тансык бер эш итеп, ничек тә тизрәк бетерәсе килеп, ару-талуны белмичә эшләдек. Командирларыбыз да көне-төне гел яныбызда булып тордылар. Безнең рота командиры, әйтергә кирәк, кешеләрне эшләтә белә иде. Теле белән дә, кулы белән дә. Гомумән, ул бик опитимист табигатьле, шаулап яшәргә өйрәнгән, тынгы белмәс кешегә охшаган иде. Дөрес, мин аны аз беләм, мин писарьлыктан киткән чакта, хәтерлисездер, рота командиры Сидоров дигән бер караңгы чырайлы интендант кисәге иде. Ләкин ул да ни өчендер озак мантый алмаган, аның урынына менә шушы өлкән лейтенант Поляковны билгеләгәннәр. Барлык командирларга караганда да бу гомерлерәк булып чыкты. Менә елдан артык инде ул безгә командирлык итә. Күрәсең, эшне оста алып бара белә торгандыр... Аннары бу инде сугышасын сугышкан кеше, күкрәгендә ничә тапкыр яралануын күрсәткән тасмалары да бар (шуларның икесе — сары төстә), ә карап торуга болай бөп-бөтен кеше кебек... Җөйләре күлмәк астында булса кирәк.

Бер тәүлек эчендә без, барлык боеприпасларны ташып, сигез пульман вагонына һәм җиде кечкенә вагоннарга төяп тә куйдык. Склад территориясендә ватык әрҗәләрдән башка бернәрсә дә калмады. Соңгы ике по-

стны да бетердек. Вәссәлам!.. Инде кайтып бераз ял итәсе дә, моннан төялеп китәсе генә калды. Әлбәттә, үзебезнең ротага —шулай уйладык без.

Ләкин кайтып ашарга-эчәргә өлгермәдек, безнең землянкага рота командиры үзе килеп керде.

— Давай, лейтенант,— диде ул, гадәтенчә сүзне туптуры башлап,— эшелонны озатырга кешеләр билгелә.

Лейтенант аптырабрак урыныннан торды.

— Ничә кеше?

— Алты солдат, шуларга бер старший... Менә сержантны җибәрербез,— диде рота командиры, миңа ымлап.— Калганнарын үзең сайла!

Әллә ничек көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты бу, ләкин нәрсә әйтә аласың?.. Бернәрсә дә әйтә алмыйсың, абзыкаем!.. Китәргә икән — китәргә, мать якасына!.. Алгы позициягә чаклы — бу әле кызыграк та булыр.

Рота командиры, чыгып китәр алдыннан:

— Әзерләнеп бетәргә ике сәгать вакыт сезгә,— диде.— Өч көнлек азык алыгыз, җылырак киенегез. Менә шул. Ике сәгатьтән үзем килермен!

...Ул чыгып киткәч, без лейтенант белән башларны кашыдык та яңадан өстәл янына утырдык.

— Их, мунча кирәсе килгән иде, тагын булмады, эт җыккыры! — дидем мин, үртәлеп.

— Мунчаның кызуына барасыз гой! — диде лейтенант, кеткелдәп.

— Һе, тычканга үлем, мәчегә көлке!.. Йә, ярар, кемнәрне бирәсең, кемнәрне алыйм?

— Син старший, үзең сайла,— диде лейтенант.

— Хуп мәйле!

Бер кәгазь кисәге алып, мин үзем теләгән солдатларның исемнәрен яза башладым: беренче итеп, билгеле, Дордыны яздым — бу үткен-чая һәм ышанычлы солдат; аның янына үз казакъларыннан Шанаев белән Байәхмәтовны теркәдем; дөрес, Шанаев бәлачелрәк кеше, ләкин Дорды аны тезгенләп тота белә. Аннары Төхфәт абзыйны үземнән калдырасым килмәде. Аның янына чуаш Емелькинны да яздым — ике дусны ничек итеп аерасың?.. Бишәү булды. Алтынчыга кемне язарга?.. Акшаловны дигән идем дә, ләкин лейтенант «аны калдыр» диде. Беләм, ул Акшаловны үзенең ординарецы сыманрак итеп йөртә. Шуннан аз гына уйлап тордым да алтынчыга әлеге бик күндәм, бик чыдам бәләкәй солдат Ишмәмәтне язып куйдым.

Исемлекне лейтенантка күрсәттем. Ул бер күз ташлады да: «Ярый, булган!» — диде.

— Алайса әйтәм үзләренә.

— Бар, әйт!

Мин торып чыктым да солдатлар землянкасына кердем. Авыр эштән соң солдатларның күбесе тир, чолгау исләре белән аралаш дымсу һавалы, караңгы землянкада гыр-гыр йоклап яталар иде. Мин үземә кирәк кешеләрне генә төртеп уята башладым:

— Төхфәт абзый, Дорды әкә, Шанаев, давай торыгыз әле, торыгыз!

— Уй-бай, ни булды, сержант? — дип, күзен ачты Дорды.

— Китәбез, Дорды, моннан китәбез...

— Кайчан?

— Менә хәзер үк.

Шулай дигәч, бер Дорды гына түгел, барысы да тиз генә торып, сәке читенә шуышып килделәр. Тик Шанаев кына гадәтенчә кычкырып сукрана башлады:

— Бу ни эш бу, адәмнәргә дем алырга да ирек бирмәйсез!..

— Шаулама! — дидем мин аңа, каты гына.— Командирның приказы бу. Ике сәгатьтән без, менә мин әйткән кешеләр, тимер юлда булырга тиешбез. Эшелон озата барабыз. Төшендегезме?

— Төшендек, сержант, төшендек! — диде Дорды.— Ә бүтәннәр?

— Бүтәннәр калып тора...

Моны ишеткәч, алар ничектер тагы да җанланыбрак киткәндәй булдылар. Кузгалып китү солдатны һәрвакытта дәртләндерә, ә монда бүтәннәрдән алда, менә хәзер, бүген үк икән! Һәркайсы шунда ук йокысыннан айнып, шытыр-шытыр кашына-кашына, кием-салымына да тотынды.

Командирның әйткәнен искә төшереп, мин аларга җылырак киенергә куштым. Безнең взвод ротадан күбрәк аерылып яшәгәнгә күрә, солдатлардан кайбер җылы киемнәрен (мәсәлән, бүрек белән сырган чалбарны) җыеп та алмый идек. Көннәр суытып җибәргәч тә, солдат аларны капчыгыннан чыгара да кия. Ә хәзер тышта ноябрь башы, һава сөяккә үтәрдәй җепшек-салкын, көн дә диярлек карлы яңгыр явып тора.

Акшаловтан мин үзебезгә дигән өч көнлек азыкны исәпләп алдым. Шул бер үк нәрсәләр инде: шикәр, тәмәке, борчак һәм тары концентраты, шпик урынына әзрәк ак май һәм Америкадан килгән колбаса консервысы... Тик икмәкне генә склад кешеләреннән барып алырга туры килде.

Шушы мәшәкатьләр артыннан йөреп, минем үземә җыенырга вакыт җитәр-җитмәс кенә калды. Тиз генә зем-

лянкага кайтып, иң элек бритва, көзге, сабын кебек вак-төяк әйберләремне кыр сумкасына тутырдым, аннары яңабаштан әйбәтләп киенергә тотындым: искесен салмыйча, шуның өстеннән генә җылы күлмәк-ыштан кидем, аякларга чолгауны яңадан урап, итекләрне иплəп кидем, пилотканы бүрек белән алыштырдым. Бу эшләр беткәч, юл капчыгының бөрмәле авызын ныгытып бәйләдем дә пистолет белән автоматымны, ачып-ябып дигəндәй, тиз-тиз генә күздән кичердем. Пистолетны теләсә кемгә күрсәтергә ярамый, ул миңа тиешле нәрсә түгел, ләкин моның кебек асыл әйбердән, кулга бер эләккәч, аерылып буламыни?! Шуңа күрә мин аны шинель кесәсендә генә йөртәм.

Кыскасы, җыенып өлгердем. Солдатлар да әзерләнеп бетеп, билләрен буып, капчык-коралларын күтәреп, землянка алдына чыкканнар иде инде. Тик Дордының гына эше бетеп җитмәгән икән. Ул агачлар арасына китебрәк, үзе генә белгән ниндидер үләннәр һәм чыршы ылысыннан кечкенә табасында юллык насвай «көйдереп» маташа иде. Безнең лейтенант моны күргәч кинәт кабынып китте:

— Хәзер үк ташла бу эшеңне, югыйсә табаңны тибеп очырам,— диде ул, яман кычкырып. Башка вакытта аның болай каты бәрелгәне юк иде, күрәсең, менә хәзер начальниклар килеп җитәр дип курыккандыр инде.

Дорды, авыз эченнән генә нидер сукранып, кайнар табасын насвае белән бергә махсус тегелгән капчыгына тыкты да башкалар янына килеп басты. Емелькин аңа, дусларча кайгырткан булып:

— Юкка җәфаланасың, товарищ! — диде.— Менә миндә чуаш тәмәкесенең аюны үтерә торганы бар, шуны гына суырырсың!

— Тукта, мин сиңа суыртырмын әле, моннан китик кенә,— диде Дорды, күзләренең агы белән генә карап.

Солдатлар бер кәефләнеп көлешеп алдылар.

Ә бераздан сукмак буйлап безгә таба килгән рота командиры белән әлеге ят капитан да күренделәр. Мин солдатларны тиз генә сафка тездем һәм үзем дә алар белән бергә бастым. Тегеләр килеп җиткәч тә, безнең лейтенант рота командирына, солдатлар юлга чыгарга әзер дип рапорт бирде.

— Яхшы! — диде рота командиры, безгә вольный торырга кушты, аннары лейтенанттан: — Авырулар юкмы, яхшылап ашаттыгызмы, кирәк-яракларның барысын да алдыгызмы? — дип сорашырга тотынды. Лейтенант, ике кулын да бот буена сузган килеш, бик төгәл итеп җавап биреп торды.

Шуннан соң өлкән лейтенант, алгарак чыгып, безгә болай диде:

— Сез, иптәшләр, боеприпаслар төягән эшелонны билгеләнгән җиренә чаклы озата барасыз. Эшелон станциядә, паровоз килгәнне генә көтеп тора. Боеприпасның нәрсә икәнен сезгә әйтеп торасы юк... Менә шул хәтәр йөкне бик уяу саклап, тиешле урынына илтеп җиткерергә кирәк. Онытмагыз, сез үтәсе юллар яңарак кына дошманнан әрчелде, анда посып калган диверсантларның да булуы мөмкин. Димәк, сезгә, иптәшләр, зур җаваплы эш йөкләнә, шуны сез чын солдатларча намус белән үтәргә тиешсез. Аңладыгызмы?

Без дәшмәдек. Ләкин безнең аңа төбәлгән күзләрдән ул һәр әйткән сүзенең безгә бик яхшы килеп җиткәнен болай да күрергә тиеш иде.

— ...Эшелон начальнигы булып менә шушы иптәш, капитан Судаков барачак,— диде командир, сүзен дәвам итеп.— Сез турыдан-туры аңа буйсынасыз. Бөтен кирәкле боерыкларны сезгә ул бирәчәк. Бу, сержант, күбрәк сиңа кагыла, белеп тор!

— Есть! — дидем мин, өзеп кенә.

— Тагын шул. Эшелонны исән-сау илтеп җиткергәннән соң, сез үзебезнең ротага кайтырсыз. Капитан безнең ротаның кайда икәнен белә, ул сезгә маршрутны өйрәтеп җибәрер. Ә хәзер кузгалсагыз да була. Хәерле юл сезгә!

Мин, сафтан чыгып, үземнең алты бөртек солдатыма сулга борылырга команда бирдем. Һәм без, кирәк-яракларыбызны күтәреп, пычрак ера-ера китеп тә бардык. Командирлар безнең арттан иярделәр.

Эшелон станциядән агачлык эченә сузылган тупикта тора иде. Килеп җиткәч, безгә шуның сигезенче вагонына урнашырга куштылар. Бу зур пульман вагоны иде. Авыр ишеген шылдырып ачтык; вагонның ике башына да түшәменә чаклы ящик-ящик снаряд өелгән, тик ишек турысындагы урта бер җире генә буш калдырылган иде. Башта мин, минем арттан Дорды эленеп торган тимергә басып, вагон эченә күтәрелдек. Иптәшләрнең кулларыннан капчыкларын, коралларын алдык, аннары үзләрен дә берәм-берәм өскә тартып мендердек.

Ике яклап өелгән снарядларга карап, Шанаев:

— Уй-бай, әҗәлнең үзе янында барамыз икән гой! — диде.

Ә Дорды, исе китмичә генә:

— Һи, снәрәд дигәнен юаш нәрсә ул, аңа башны куеп йокларга да була,— диде, көлдерергә тырышып.

Ләкин берәү дә көлмәде. Безнекеләр боеприпаслар янында торып күнегеп беткән булсалар да, менә болай

хәтәр йөк белән бер вагонда барганнары юк иде әле. Шуңа күрә әзрәк кенә шомланалар да булса кирәк. Хәер, солдат шомлануын бервакытта да сиздерергә яратмый — дөрескә чыга күрмәсен дип курка ул.

Ярый, анысын куеп торыйк, менә монда вагон идәне шыр ялангач та, пычрак та икән — шунысы начар. Иптәшләр, печәнме, саламмы табарга кирәк, диләр. Озак эзлисе нәрсә түгел, әнә юл буенда гына киртәләр белән батырган бер чүмәлә тора — барып, төбеннән генә йолкып, дүрт-биш кочак печән китердек тә идәнгә җәйдек. Шуннан соң солдатлар, снаряд ящикларына аркаларын терәп, аякларын сузып, печән өстенә ял итәргә утырдылар.

Бераздан безнең вагон янына эшелонны озата баручы әлеге Судаков дигән капитан килде. Мин аның каршысына сикереп төштем.

— Йә, урнаштыгызмы? — дип сорады ул миннән.

— Урнаштык, иптәш капитан! — дидем мин, честь бирмичә генә.

Капитан вагон эченә дә үрелеп карады: солдатлар тора башлаганнар иде, ул кулын селкеп тормаска кушты.

Командир-начальникларның төрлесенә очрап, билгеле бер сизгерлеккә өйрәнгәнгә күрәдер инде, мин бу артиллерист погонлы, сүлпәнрәк хәрәкәтле, озын-чандыр капитанның форма таләпләренә артык игътибар итмәвен, солдатларга карата үзен гади генә тотуын чамалап өлгергән идем. Җиңел-азапсыз булыр кебек аның кул астында баруы... Хәер, алгы сызыктан килгән командирлар күбесенчә шундый булалар да.

Ул минем фамилиямне сорады, мин аңа әйтеп бирдем. Шуннан соң беләгемнән алгандай итеп, вагоннар буйлап атлый-атлый, ашыкмыйча гына миңа үзенең боерыкларын бирә башлады:

— ...Иң элек шул: составның ике очына ике часовой куярсыз. Берсен паровозга якын тамбурга, икенчесен — койрыкка. Туктап торган җирләрдә алар төшеп, ике яктан состав буйлап йөреп торырга тиешләр. Бусы аеруча кирәк... Тик менә часовойларны алыштыру мәсьәләсе... сезнеңчә, күпме вакыттан алыштырырга ярый?

— Ике постка алты солдат, иптәш капитан, дүртәр сәгать торсалар, җитәр! — дидем мин.

— Күп булыр,— диде капитан.— Тамбурда өшеп бетәрләр... Ике сәгать, ну, өч сәгать, шуннан да артык тотарга ярамас. Аларны бит эшелон туктап торган чакта гына алыштырырга туры киләчәк, шуңа күрә төгәл вакыт билгеләве дә читен. Сез үзегез моны чамалап хәл итәргә тиешсез!..

— Яхшы, иптәш капитан!

— Аннары, сержант, вагон эчендә электр фонарьдан башка нәрсә яндыра күрмәгез. Шырпы сызу булмасын. Тәмәке тартуны онытыгыз... Туктап торган арада гына төшеп тартырга рөхсәт итегез. Аңладыгызмы?

— Аңладым, иптәш капитан!

— Хәзергә шул... Мин үзем паровозда булырмын, кирәксәм, шунда килерсез!

— Яхшы, иптәш капитан!.. Ә паровоз тиз килерме икән?

Капитан ике кулын җәйде:

— Көтәбез... Күрше станциядән килергә тиеш.

— Часовойларны хәзер үк куяргамы?

— Тамбурга китәр алдыннан гына куярбыз. Ә хәзер ике патруль билгеләгез, состав буйлап йөри торсыннар.

— Була, иптәш командир!

Ул киткәч тә мин вагонга кире кайтып, Байәхмәт белән Ишмәмәтне беренче патрульләр итеп билгеләдем. Болар арада иң өлкәннәр, төнлә тамбурда баруы алар өчен читенрәк булачак, ә йөреп тору ярый, йөреп торганда кеше өшеми дә... Икесе дә мылтыкларын алып төшәргә әзерләнгән, мин аларның берсенә составның бер ягыннан, икенчесенә икенче ягыннан йөрергә һәм вагоннарга читят кешеләрдән берәүне дә якын җибәрмәскә куштым.

Ярый, бу да булды. Бер яктан җан тыныч әле; менә күпме вакыттан бирле инде дошман авиациясенең тыны да чыкмый. Ә тоташ болытлы көзге һавалар башлангач, гомумән, бу тирәләрдә бер генә разведчик-самолетның да күренгәне юк... Һәр начарның бер яхшы ягы була дигәндәй, көзге яңгырлардан интегеп бетсәк тә, элекке шикелле гел шомланып, һавага колак салып тормыйбыз.

Бераздан солдатлар, чәй эчеп аласы иде бит, сержант, дия башладылар. Кирәктер шул, тик ятып өшеп тә киткәннәрдер, аннары иртәнгә чаклы ашау-эчү белән маташып та булмаячак.

— Әйдәгез, алайса, яктырак чакта эчеп калыйк,— дидем мин үзләренә.— Син, Дорды, давай, кара чиләкне ал да су табып китер, ә без әнә агачлыкта ут яга торырбыз.

Барыбыз да вагоннан төшеп, юл буендагы ватык әрҗәләрне җыештырып, агачлар арасына кердек тә кечкенә бер аланлыкта ут ягып җибәрдек. Дорды табып китергән суны чиләге белән кайнатырга куйдык, үзебез чатыр-чотыр янган учак әйләнәсенә чүгәләшеп, кәкрәйгән кулларны, тез башларын җылыта тордык. Солдатлар миннән һаман бер нәрсәне сорыйлар: кая барабыз, сержант?

— Алга таба,— мин әйтәм.

— Юк, син точкасын әйт! — диләр.

— Точкасын паровоз гына белә, ә паровозның килеп җиткәне юк әле,— дигән булам.

— Яшерәсең, сержант!

Мин юри дәшмим, гүя сер саклыйм, имеш! Аннары бераздан:

— Атагызның башы,— мин әйтәм,— сержант белсә, сез белми калыр идегезмени?!

— Тугры, тугры,— диләр тагын үзләре.

Су кайнап чыккач, шуңа бер уч чәй бутап, аяк өсте генә алюмин кружкалардан пешә-пешә чәй эчтек. Төхфәт абзый, җаена мач китереп дигәндәй, такмаклап та җибәрде:

Чәй эчүнең шарты бар: бавырсак та коймак,
Сары майга маньш-маньш кунак алдына куймак!

— Кара мынау нугайны, бавырсакны беләде икән гой! — диде Шанаев, гаҗәпләнеп.

— Һе, белмәскә,— диде Төхфәт абзый, тел шартлатып.— Без ашарбыз әле шишара, ә син карап торырсың, бичара!

Барыбыз да рәхәтләнеп бер көлештек.

Калган чәйне алып кайтып, Байәхмәт белән Ишмәмәткә дә берәр кружка салып бирдек. Ишмәмәт кружкасын ике учына кысып, Дордыга кат-кат рәхмәт укый — гаҗәп бер тәүфыйк иясе безнең бу Ишмәмәт!

Әмма бу паровозлары озак килмичә тәмам җилеккә үтте. Көтүдән дә әшәке нәрсә юк. Әллә кайчан караңгы төште, төн булды, ә без салкын вагон идәнендә утырабыз да утырабыз... Әледән-әле торып, ишектән башны тыгып карыйм — дегет шикелле кара төн, үлек дөнья, шылт иткән тавыш та юк... Тагын утырам, күкрәктәге фонарь белән вагон эчен бер генә минутка яктыртып алам: солдатлар аркаларын бер-берсенә терәп печән өстендә яталар — йоклыйлармы, әллә болай җылы саклап кына яталармы, Ходай белсен!.. Мин үзем дә аяк чәнчеп утырган килеш, әз генә черем итеп алырга тырышып карыйм, вакыт-вакыт башны төшереп җибәреп, яртылаш кына оныталып киткән кебек тә булам, ләкин шунда ук юк кына бер кыштырдаудан да сискәнеп күзләремне чекерәйтеп ачам... Һәм ни өчендер бүрегемне ике куллап тотып карыйм... Юк инде, юк, булмый, койрыгын да тоттырмый йокы!.. Әмма әйтеп куйган нәзерем бар: исән-сау илгә кайтсам, әнкәйнең түшәк-ястыкларына чумып, бер өч тәүлек тоташтан мәрткә киткәндәй йоклаячакмын, насыйп булса!

Ниһаять, төн урталарында теге мөртәт паровоз килде шикелле — нәрсәнеңдер авыр итеп ухылдавы ишетелде.

Сикереп торып, ишеккә ташландым: килгән икән шул, рәхмәт төшкере, әнә ике күзе ялтырап күренә.

Ә бераздан ул безнең составка әкрен генә килеп тагылды, авыр вагоннарны шома гына кузгатып тупиктан алып чыкты. Тагын күпмедер вакыт безне бер алга, бер артка сөйрәп, юлдан юлга күчереп йөртте, аннары туктап, тынып калды. Шул арада мин Төхфәт абзый белән Емелькинны аякка бастырдым.

— Ягез, агайлар, тиз генә җыеныгыз, постка киттек!

Алар сүзсез генә торып кымшана башладылар. Мин ашыктырам, ә Емелькин сукрана:

— Куалама ул хәтле, сержант, бүрекнең колакларын гына төшереп бәйлик, тамбурда барасы бит!

Ахырда әзерләнеп беттеләр, җиргә төштек. Фонарь белән юлны яктыртып, Төхфәт абзыйны паровозга таба алып киттем, ә Емелькинга вагон янында көтеп торырга куштым. (Аны койрыкка илтәсе.)

Безгә ашыга-ашыга килгән капитан очрады:

— Сержант, сезме бу?

— Әйе, мин, иптәш капитан!

— Часовойны илтәсезме? Ярый. Бер биш минуттан кузгалабыз. Кешеләрегез барысы да яныгыздамы?

— Әйе, иптәш капитан! — дидем мин һәм шунда ук Байәхмәт белән Ишмәмәтне искә төшереп борчылып куйдым: алар кайда соң?.. Тупик буенда торып калмасалар ярар иде.

Ләкин борчылырлык эш булмады. Алар да, Ишәй белән Кушай шикелле, каяндыр юллар буеннан абынасөртенә килеп чыктылар. Мин дә часовойларны илтеп куярга өлгердем... Ә бер-ике минуттан паровоз, кычкыртмыйча гына кузгалып, безне алга, сугыш барган якка таба алып та китте.

...Инде бер җиңел суладык. Кәеф тә әйбәтләнеп, йокы да качты. Җанланып, шаулашып, сөйләшеп тә алдык. Ләкин дөм караңгыда сүз озакка сузылмый — иптәшләр берәм-берәм әкренләп тындылар. Мин дә кырынрак ятып, башны снаряд ящигына терәдем. Вагон бер көйгә салмак кына чайкала, ә колак төбендә генә тәгәрмәчләр өзлексез такылдыйлар... Аннары йокы барысын да йотты.

...Минем кечкенә балам бар икән, ләкин ул тавык күкәе эчендә, имеш. Мин шул күкәйне учымда сак кына тотып йөртәм. Ә бала күкәй эченнән бик ачык-нечкә тавыш белән: «Әти, мине төшереп җибәрмә!» — дип әйтә, имеш... Борчылып, кая гына куеп торыйм икән үзен дип, мин иске, ватык җиһазлар белән тулы бер бүлмә эчендә тыныч, хәвефсез урын эзләп, бәрелә-сугыла йөрим икән...

...Кинәт вагон каты гына тартылып куйды — мин, сискәнеп, күзләремне ачып җибәрдем. Менә сиңа кирәк булса төш! Кайдан гына табыла диген, әкәмәт?! Әмма күкәйне төшереп җибәрмәдем, юк, җибәрмәдем!..

Торып вагон ишеген ачтым. Төн, бетмәстәй төн, әкрен генә сыекланып, офыкларга таба чигенә башлаган, иренеп кенә салкын-соры көн туып килә, ә поезд яңа төзәтелгән юлны үтә шикелле — бик сакланып кына китеп бара. Әйләнә-юньдәге күренештә дә үзгәреш юк диярлек: якында һәм еракта утрауларга охшаган урманнар, урманнар арасында җыйнак кына басулар, басулар янында ялгыз утарлар, ләкин мондагы утарлар төзегрәк тә, баерак та икән!.. Алар әйләнәсендә ниндидер тын бушлык хөкем сөрә кебек — бер дә җан иясе барлыгы сизелми. Бу — Латвия җире...

Безнең поезд, вак-төяк станцияләрдә тукталып тормыйча, шактый кызу барды. Тик юлның яңа төзәтелгән яки төзәтелеп яткан урыннарыннан гына бик әкрен узды. Вакыт-вакыт ачык кыр уртасында туктап та торгалады. Мин инде, капитан кушканча, һәр тукталыштан файдаланып, часовойларны алыштыра килдем.

Тамбурда үтәли туңган бичаралар, посттан бушау белән, нашатырь кыстыргандай, тизрәк вагонга чабалар. Кайтып кергәч, үзләрен шап-шап кыйный-кыйный, идән уртасында озак кына тыпырдашалар. Хәер, вагоны да шул ук тамбур кебек инде, тик монда җил генә өреп-сызгырып тормый.

Шулай бара торгач, без кичкә табан, ниһаять, бер зур гына станциягә килеп җиттек. Монда рәт-рәт сузылган юллар да күп иде, юлларга килеп тыгылган эшелоннар да күп иде, күмер, мазут, төтен исе дә җитәрлек,— ахрысы, бер узловой станция булса кирәк. Мин вагоннан төшеп, капитанны күрер өчен паровозга таба киттем. Биредә күпме торырбыз икән — шуны беләсем килде... Барышлый состав буенда капитан үзе миңа очрады.

— Йә, эшләр ничек, сержант? — дип сорады ул миннән, килеп җитүгә.

— Эшләр ярыйсы хәзергә, иптәш капитан!

— Ярыйсы күренә шул,— диде ул, мине баштанаяк карап.— Өс-башыгыз чиста, артык изелмәгән дә, спальный вагонда килгән шикелле... Инде миңа карагыз!

Чынлап та капитанның кыяфәте шәптән түгел иде: шинеле күмер тузанына буялып беткән, йөзендә дә кара таплар, үзе дә бик йончыганга охшый.

— Әшәке нәрсә икән ул паровоз, моннан соң утырырга язмасын! — диде ул, кулын селтәп.

— Әллә безнең янга күчәсезме, иптәш капитан?

— Юк, булмый, ярамый,— диде ул, сүлпән генә.— Хәзер мин комендатурага барып, шуның берәр почмагында әзрәк йоклап алмакчы булам. Теге җәһәннәм казанында бер бөртек тә күз йомарга туры килмәде...— һәм мин сораганны да көтмичә өстәде: — Без монда шактый торачакбыз әле.

— Шулай да күпме?..

— Тәгаен әйтә алмыйм; һәрхәлдә, төн урталары җитмичә җибәрмәсләр.

— Иптәш капитан, ә сәбәбен белергә ярыймы?

— Сәбәбен... Сәбәбен мин сезгә китәр алдыннан әйтермен. Ә хәзер сез дә бу вакытны файдаланып калырга тырышыгыз. Әйбәт кенә ашап-эчеп алыгыз, чиратлап ял да итегез — бу төнне безнең беребезгә дә күз йомарга туры килмәячәк. Менә шул. Үзегез эшелоннан бик читкә китеп йөрмәгез, солдатларны да таратмагыз... Ә мине, бик кирәксәм, комендатурадан табарсыз!

— Яхшы, иптәш капитан!

— Ну, пока!..

Ул китеп баргач, мин аз гына уйланып тордым: төн уртасына чаклы монда торуның сәбәбе нәрсәдә икән?.. Капитан ни өчендер әйтеп бетермәде, ләкин аның сүзләреннән ниндидер бер куркыныч барлыгы шулай да сизелеп калды. Нәрсә булырга мөмкин? Бәлки, тәгаенләнгән җиргә (алгы позициягә) барып җитәргә күп калмагандыр, һәм безнеке кебек хәтәр йөкне ул җиргә бары төнлә генә илтеп җиткерергә ярый торгандыр? Тагын нәрсә?.. Хәер, юрап маташудан мәгънә юк, вакыты җиткәч белербез.

Вагонга борылып кайткач та, мин солдатларыма:

— Менә нәрсә, егетләр! — дидем.— Без монда шактый торачакбыз икән әле... Әйдәгез, ашап-эчеп алу ягын карыйк. Бу зур станция, бәлки, кайнаган су табарбыз.

Моны ишетүгә, Дорды урыныннан сикереп торды:

— Һе, сержант, кая үзем генә табып килим булмаса!

Ләкин минем аны ялгызын гына җибәрәсем килмәде. (Моның кебек зур җирдә аның үзенә кирәк «суны» да эзләп, мутланып йөрүе бар.) Шуңа күрә мин:

— Әнә Төхфәт абзый белән икәү барырсыз,— дидем.

— Бер бидерә сугамы? — дип гаҗәпләнгән булды Дорды.

— Әйе, ике ягыннан тотып китерерсез, җиңелрәк булыр... Ләкин әллә кайларда йөрмәгез, туры станциянең үзенә барыгыз, тапсагыз, шул тирәдән табарсыз.

Солдатларның кайберләре:

— Җылы аш ашыйсы иде бит, сержант! — диделәр.

— Ашыйсы иде шул,— дидем мин, бик килешеп.—

Ләкин кайда пешерәсең аны? Монда бит төшеп ут ягарлык кыр-мазар юк, үзегез күрәсез!.. Ярый инде, кайнар су тапсак...

— Ә тапмасак?

— Ул чагында паровоздан алырга туры килер...

Солдатлар чырайларын гына сыттылар. Паровоздан алган су чынлап та бик тәмсез ул...

— Берәр хәзәйкәдән булса да кайнатып алам! — диде Дорды, бик кисеп. Мин инде каршы дәшеп тормадым.

Алар Төхфәт абзый белән икесе, чиләкне алып, вагоннан төштеләр дә составлар астыннан иелә-иелә чыгып, станциягә таба китеп бардылар.

Шулай да безнең бәхет бар икән, озак та үтми, болар бер чиләк кайнар су белән кайтып та җиттеләр.

— Кайдан таптыгыз? — мин әйтәм.

— Кипәтүк алачыгыннан,— ди Төхфәт абзый.

Чиләккә тиз генә бер әчмуха чәйне тондырдык та суынмасын өчен өстенә сөлге каплап куйдык. Вагон идәненә плащ-палатка җәеп, түгәрәкләнеп утырдык. Капчыклардан ипине, шикәрне чыгардык, берничә «сыер тушенкасы»н ачып куйдык. Бушатырга тәлинкә-мазар юк, пычак очы белән генә казып, әләктереп ашый башладык. Емелькин шуның өстенә әле чүпрәккә төргән шпигын чыгарып, телем-телем кискәләп, бик тәмләп кенә ашарга тотынды. Казакълар аңардан җирәнәләр:

— Кафер, Ходайдан да курка белми! — диләр.

— Ә минем Ходай башка! — ди Емелькин, шпигын чәйни-чәйни.

— Алла — бер,— дип куя Ишмәмәт, тыныч кына.

— Емелькәнең Алласы, үзе кебек чуаш гой! — ди Шанаев.

— Гуй, гуй! — ди Емелькин, аны үчекләп.— Ә сезнең үз Аллагыз юк, сез Алланы татарлардан алгансыз. Ышанмасагыз, әнә сержанттан сорагыз!.. Сержант, казакъны намаз укырга сез өйрәткәнсез бит?

Мин көлеп җибәрдем — каяндыр, нидер ишеткән бит бу шайтан Емелькә!.. Гомумән, боларның ачусыз гына әрепләшүләре һәрвакытта шулай көлке килеп чыга һәм күп очракта көлешү белән бетеп тә куя.

Нибары белән ашап-эчтек... Эч тулды, күңел хуш булды. Төшеп, җиргә чүгәләп кенә тәмәке дә тарттык. Инде караңгы да төште, тагын озын, бик озын төн башланды. Безнең паровозда һичбер җан әсәре сизелми — күрәсең, торачакбыз әле... Солдатлар менеп печән өстенә ятканнар иде инде. Мин дә арлы-бирле йөрендем, йөрендем дә, менеп, Төхфәт абзыйның аркасына терәлеп кенә ят-

тым. Ахрысы, якташның җылысыннан мин шунда ук йоклап та киткәнмен.

Күпме вакыт үткәндер, белмим, менә бер заман вагонның селкенүен ничектер сизәм шикелле... Ләкин һич уяна алмыйм. Ә акылның нindидер бер ноктасы миңа «уян, уян!» ди... Ахырда күземне ачып җибәрдем. Бу ни хикмәт — китеп барабыз түгелме соң? Тиз генә торып, вагон ишеген ачып карыйм: уй-бай, чынлап та барып ятабыз гой!.. Ә тышта ерып йөри алмаслык куе-кара төн!

Күпмедер баргач, эшелоныбыз туктады. Башны тыгып-карыйм, әмма яланмы-кырмы, берәр станция-мазармы — һич кенә дә белеп булырлык түгел. Шул чакта состав буйлап килгән берәүнең башта аяк тавышы, аннары дәшкән тавышы да ишетелде:

— Сержант!

Бу безнең капитан иде. Мин тиз генә җиргә сикереп төштем.

— Мин монда, иптәш капитан!

Ул килеп, караңгыда бәрелешмәс өченме, мине капшап карагандай итте, аннары әкрен генә:

— Әйдәгез, бераз читкәрәк китик әле,— диде.

Без вагон буйлап читкәрәк киттек.

— Менә нәрсә, сержант,— дип, сүзен башлады капитан, тыныч, әмма киеренке бер тавыш белән,— без хәзер юлның иң куркыныч өлешен үтәчәкбез. Куркыныч шул: без үтәсе бу арага немецлар авыр туплардан атып торалар... Шуңа күрә һәртөрле көтелмәгән хәлгә әзер булып торырга кирәк. Часовойларны да тамбурлардан алырга туры киләчәк. Барыгыз да бер урында булырга тиешсез. Ләкин курку булмасын, паника булмасын, нык тот үзләрен!.. Аеруча кисәтеп әйтәсем килә: бер генә бер тычкан уты да күренмәскә тиеш. Фонарегызны яндырмыйсыз, хәтта бер генә секундка да! Безгә кап-караңгы төн кирәк, аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм, иптәш капитан!

— Юлның бу куркыныч өлеше озын түгел, бер өч километр чамасы гына, ләкин аны бик әкрен үтәргә туры киләчәк. Менә шул әкрен барудан файдаланып, кайберәүләрнең җиргә төшәселәре килер, ләкин сез моны һич тә рөхсәт итмәгез! Бары иң актык чиктә генә, ну, әйтик, составка берәр снаряд тия калса гына, барыгыз да вагонны ташлап, җиргә сикерегез. Шуңа әзер булып торыгыз!

Капитан авыр гына сулап куйды, ә мин тын да алмыйча аны тыңлап тордым. Эшләр әнә ничек икән!.. Нидер сорыйсы килә, ләкин сорар нәрсә юк. Әйтер сүз дә юк. Әллә ни каушамадым да шикелле, ә шулай да менә тел бәйләнде.

— Ярый, сержант,— диде капитан, минем шул хәлне сизгәндәй,— тыныч булыгыз! Бәлки әле, шома гына үтеп тә китәрбез, юл үзебезнеке!.. Ә хәзер часовойларыгызны алыгыз.

Ул китә башлагач кына, мин кинәт исемә төшкәндәй сорадым:

— Ә солдатларга әйтергәме, иптәш капитан?..

— Әйтергә кирәк, әлбәттә,— диде ул.

Аның артыннан ук мин часовойларны барып алып кайттым. Вагонга менгәч, аз гына хәл җыеп тордым. Ничектер ашыкмыйча, тыныч кына әйтергә кирәк иде. Посттан кайтучылар да иптәшләре белән сүз алышудан, кыштырдаудан туктасыннар... Аннары сорадым:

— Барыгыз да уяумы?

— Уяу шикелле,— диде кемдер.

Мин электр фонарен бер генә мизгелгә яндырып, вагон эчен «капшап» карадым.

— Әнә теге кем ул, уятыгыз әле!

Дорды аны төрткәли башлады:

— Әй, Шанай, Шанай дим, торсаңчы!.. Сержантның безгә әйтер сүзе бар икән!

Алар селкенешеп, мышнап тынгач, мин:

— Хәзер генә капитан килеп китте,— дидем,— без алгы позициягә якынлашабыз икән... Дошман ерак түгел... Капитанның боерыгы шул: тугарылып ятмаска, бөтенесенә әзер булып торырга!.. Мылтыкларыгыз яныгызда булсын! Тыныч кына утырыгыз! Мин әйтмичә кузгалу юк, төшендегезме?

— Төшендек, сержант! — диде Байәхмәт, барысы өчен дә.— Әмма кая чаклы барамыз без, алгы позициягә якынлашкач, нигә туктамаймыз?.. Шуны әйтеп бирсәңче безгә, сержант!

— Билгеләнгән урынга тиздән барып җитәргә тиешбез, тик юлның шушы... куркынычрак төшен генә үтәсе бар,— дидем мин, ләкин дошманның туптан ату ихтималын әйтеп тормадым. Әллә ата, әллә юк, дип уйладым. Баштан ук куркытып куясым килмәде.

Солдатлар бүтән бер нәрсә турында да сорамадылар. Әмма бик тын калып утыруларына караганда, нидер сизенәләр иде шикелле.

Поезд бераздан тавыш-тынсыз, шома гына кузгалып китте. Күпмедер вакыт ул кызу гына барды, аннары әкренәя башлады... Әкренәя, әкренәя, һаман әкренәя,— ниһаять, бөтенләй туктаган кебек булды... Мин ишекне баш сыярлык кына ачып, тышка сузылып карадым, ләкин бу дөм караңгыда һичнәрсә күреп тә, белеп тә булырлык түгел

иде... Барабызмы соң, туктап торабызмы?.. Чүгәләп, тәгәрмәчләргә колак салып карыйм: тәгәриләр булса кирәк, рельсның сыгылганы ничектер сизелгән кебек, ләкин һич бернинди ышкылган-ниткән тавыш чыкмый иде. Ахырда төшеп беләсем килде. Җиргә сикердем дә баскан җиремдә туктап калдым: вагон минем яннан үтәме, юкмы?.. Үтә шул, үтә!.. Әмма шулкадәр әкрен үтә ки, хәтта җәяү атлап та бу кадәр әкрен барып булмас иде. Исем китте минем бу хәлгә!.. Состав очына карадым. Паровозны күрү түгел, аз гына шәйләп тә булмый иде. Ул әйтерсең бөтенләй юк!

Яңадан вагонга менеп, ишекне бер генә карыш ачык калдырып, кире шылдырдым. Дорды шунда ук сорап куйды:

— Кайда туктап торамыз, сержант?

— Туктап тормыйбыз — китеп барабыз!

— Барамыз... Поезд шулай барамыни?

— Бара икән шул!..

Мин идәнгә, ишекнең ябылып бетмәгән кырыена урнаштым. Нидер көткәндәй, тын гына утырабыз... Һаман бер уй борчый мине: ни өчен без юлның бу хәтәр өлешен бик кызу гына үтеп китмибез, ни өчен бу хәтле әкрен өстерәләбез?.. Күрәсең, кызу үтәр өчен паровоз топкасына гел күмер ташлап барырга кирәктер, күмер ташлагач, морҗадан төтен белән бергә чаткылар да оча торгандыр... Ә бу инде күзәтеп яткан дошманга үзеңне сиздерү була, күрәсең... Шулай уйларга өлгермәдем, каядыр шактый еракта зур агач чүкеч белән нәрсәгәдер китереп суккан шикеллерәк тавыш ишетелеп калды һәм шуның артыннан ук бер авыр снаряд составтан уңдарак төшеп тә шартлады. Солдатлар сискәнеп киттеләр, ләкин ни булганын шунда ук аңлап җиткермәделәр, ахрысы. Тик Емелькин гына: «Бусы тагын нәрсә?» — дип куйды. Мин җавап бирергә ашыкмадым; мин, тын да алмыйча, ату тагын кабатланырмы-юкмы дип көттем. Бик озак тоелды бу көтү... Ниһаять, менә кинәт җил исеп киткәндәй булды, һәм тагын бер снаряд состав өстеннән очып, юлның икенче ягында ухылдап шартлады. Бу юлы инде берничә солдат беравыздан кычкырып җибәрделәр:

— Бу ни тамаша? Нәрсә бу?..

— Шауламагыз! — дидем мин, тыелып кына.— Ишетмисезмени, немец атып маташа!

— Немец ата?! Ах, бәдбәхет!

— Белеп атамы, белмичәме?

— Белмәсә дә ата инде ул,— дигән булдым мин, аларны әзрәк тынычландыру өчен.— Тик ятудан курка немец!

— Үз башына булсын! — дип куйды Төхфәт абзый.

Шул арада өченче снаряд шактый якында төшеп шартлады. Бу юлы Дорды сикереп торды.

— Сержант, атып җатыр гой! Нишлибез?

— Бер нәрсә дә эшләмибез, тик кенә утырабыз! — дидем мин, һаман тышка колак салып.

— Ничек ул алай?.. Мондый чакта тик кенә утырып буламыни?

— Була, Дорды, була,— дидем мин, ачулана башлап.— Тик шыр җибәрмәскә кирәк!

Солдатлар бер мәлгә тындылар... Хәзер мине (мине генә түгел, барыбызны да, билгеле) бер генә уй биләп алган иде: ни булып бетәр моның ахыры?.. Чынлабрак уйлаганда безнең хәл искиткеч мөшкел иде, без кыл өстендә, без һәлакәтнең кырында гына торабыз...

Дөрес, боеприпаслар тулы составының шартлаганын безнең күргәнебез юк, ләкин моны күз алдына китерүе бер дә читен түгел. Әгәр шуннан бер генә снаряд берәр вагонга тия калса... Әмма коточкыч бу хәлне күз алдына китерүдән курыкмаган акылга каршы кешенең җанын, өметен саклый торган бик могҗизалы күңел дигән нәрсәсе бар әле: шушы иң хәтәр минутта да миһербанлы күңел мине һәм минем иптәшләремне, снаряд безгә тимәс, тисә дә, иң очтагы вагонга гына тияр, ул шартлаганчы, аңа ияреп башкалар шартлый башлаганчы, без сикереп төшеп өлгерербез, без юл буендагы чокырга тәгәрәп өлгерербез, дип юатып кына тора... Бу инде, бәлки, мәгънәсез юанычтыр, әмма кирәк ул, кирәк, кирәк!..

Ә немец ата, төгәл бер интервал аша ата да ата. Без һәр снарядның кайдарак төшеп шартлаганын көтеп, тыныбызны да чыгармыйча тыңлап утырабыз. Дошман сукыр килеш, чамалап кына ата булса кирәк, күп кенә снарядлары, безгә килеп җитмичә, төшеп шартлыйлар. Тик кайберләре генә якын төшкәлиләр. Ләкин берсе дә бит аның безгә бик җиткән!..

Мин, ишек ярыгына бер аягымны терәп утырган килеш, вагон эченә дә колак салгалыйм. Иптәшләр, җаннары учларында булса да, болай тып-тыныч кына утыралар. Тик Байәхмәт кенә авыз эченнән үгез шикелле һаман нидер мөгрәнә — белгән догаларын укып маташа, ахрысы. Кемдер әледән-әле тамак кыргалый, кайсыдыр, Емелькин булса кирәк, снаряд төшеп шартлаган саен: «Ух, гад!» — дип куя. Ә менә Ишмәмәтнең бөтенләй өне-тыны юк, бу галәмәт башланганнан бирле шулай тавышын чыгармый. Ни хәлдә икән ул, бичара?!

...Кинәт — мин сизми дә калдым — бик якында гына авыр снаряд яман гөрселдәп шартлады. Безнең вагон хәтта

чайкалып куйгандай булды. Шул ук мизгелдә Шанаев әче тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Сержант, ач ишекне!

Мин секундның күпмедер бер өлеше дәвамында аптырап калдым, хәтта аягым белән ишекне шылдырып җибәрә яздым, ләкин шул секундта ук сикереп торып, ишеккә аркам белән терәлдем:

— Якын киләсе булма, Шанай!

— Синең безне монда тотарга хакың юк! — диде Шанаев, отыры чәрелдәп.

— Бар, паника куптарсаң, атарга да хакым бар!

Шул арада Дорды, Шанаевның чабуыннан тартып булса кирәк, аны шап иттереп кире идәнгә утыртты:

— Бакырма, ишәк!

Шанай ямьсез итеп шыңшый башлады, ә Байәхмәт гадәтенчә салмак кына:

— Куйсаңчы, Шанай! — диде.— Әҗәлнең кайда икәнен белеп буламыни? Әллә җирдә, әллә монда, Ходайның бер үзенә тапшырыйк!

Ниһаять, барыбыз да әзрәк тынычландык. Шулай да нык икән әле безнең абзыйлар!.. Шанаевка ияру түгел, селкенеп тә карамадылар. Ә бит дөресен генә әйткәндә, вагон эчендә безгә йөз мәртәбә куркынычрак — моны һәркайсыбыз белеп торабыз. Әмма ләкин солдат психологиясенең гаҗәеп бер сере бар — нәкъ менә иң куркыныч, иң киеренке чакта ул иптәшләреннән аерылырга һәм теләсә кая ташланырга яратмый. Ни күрсәк тә бергә! — Һәм шушы нәрсә аларны күп вакытта паникадан коткарып та кала.

Теге котыбызны алган снаряд соңгысы булды, ахрысы, бүтән якын-тирәгә төшкәне ишетелмәде. Ләкин немец һаман ата иде әле. Поезд шулай чак-чак кына шуышып бара. Иң җанга тигәне, иң ачуны китергәне — шушы әкренлек!.. Болай шуышып, кайчан гына без дошман уты астыннан чыгарбыз соң?! Түзәргә инде, ничек кенә булса да түзәргә!..

Һәм менә күпмедер вакыттан соң немец снарядларының каядыр составтан арттарак төшеп шартлаганы сизелә башлады. Мин бөтен игътибарымны җигеп, һәр снарядның каярак төшкәнен чамалап, тыңлап кына торам. Юк, чынлап та, отыры арттарак шартлый бит, отыры арттарак!.. Йа Хода, үтәбез, чыгабыз, котылабыз шикелле! Моны мин генә түгел, солдатлар да бик яхшы сизеп торалар иде. Алар җанлана төштеләр, селкенә, кыймылдый башладылар. Ә Дорды хәтта дәртләнеп:

— Байәхмәт! — диде.— Тагын бер аять әйтсәң, котыламыз гой!.. Давай, туктап торма!

Ә бераздан инде без вагон тәгәрмәчләренең кызурак тәгәри башлавын сиздек. Минем моңа чынлап ышанасым килми. Шауламаска кушып, мин тәгәрмәчләр тавышына бик нык колак салып тордым. Әйе, алар кызурак тәгәриләр, рельс ялгаулары өстеннән ешрак сикереп узалар... Ләкин шулай да бу әле чынлап торып кызулап китүгә охшамый иде. Ә дошман снарядларының якында гына түгел, артта шартлаганы да ишетелми башлады. Туктады, ахрысы, мөртәт! Хәзер инде ишекне ачып, юл буена карарга да ярый торгандыр. Әллә азрак кына сабыр итәргәме?

Кинәт поезд тартылып куйды, вагон буферлары шакылдашып алдылар... һәм менә паровозның авыр сулап алга омтылуы ишетелде. Мин түзмәдем, ишекне бөтен көчемә шылдырып ачып җибәрдем. Тизрәк сузылып паровоз ягына карадым. Паровоз чаткылы төтенен ишеп чыгара-чыгара алга ыргыла иде. Отыры кызурак, кызурак!.. Бу инде котылу иде, котылу!..

Мин, бүрегемне баштан сыдырып алып, вагон эченә кычкырдым:

— Иптәшләр, бетте, котылдык!

Барысы да ишеккә ташландылар — мине чак этәреп төшермәделәр. Сузылып-сузылып бер алга, бер артка карадылар. Кычкырдылар, шауладылар, сүгенделәр:

— У-у фашист, атаңа нәләт!

— Җиде бабаңның гүр тактасын...

— Аллага мең шөкер!

— Шанай, бар сикер, ник сикермисең?

Аннары бер-берсенә шап-шап суктылар, берсен-берсе төртеп-төртеп җибәрделәр, ә Емелькин чуашча такмак әйтә-әйтә идән уртасында тыпырдап биергә үк тотынды... Шулай тилерешеп алдылар безнең карт солдатлар. Тик бу галәмәт эчендә Ишмәмәтнең генә барлыгы сизелми иде. Мин электр фонарен кабызып, вагон эчен яктыртып карадым. Бер почмакта, чәйханә сәкесендәге шикелле, аякларын бөкләп, тын гына һәм тик кенә Ишмәмәт утыра... Утыра, әйтерсең бернәрсәдә гаме дә, эше дә юк! Мин бик гаҗәпләндем.

— Нишләп утырасың, Ишмәмәт әкә?

— Тамаша кылып,— ди бу тыныч кына.

— Нәрсәне тамаша кылып?

— Менә бу адәмнәрнең тилерүен...

— Алар бит шатлыктан тилерәләр... Нигә, син исән калуыңа шатланмыйсыңмыни?

— Ә мин, уртак сержант, исән каласымны алдан ук белеп тордым,— ди ул, бер дә исе китмичә генә.

— Кайдан, ничек итеп?

— Минем береннән-бере кечек дүрттә балам бар кү —

һәм кулын идәннән күтәрә-күтәрә балаларын күрсәтә башлый.

Безнең бу сөйләшүне тыңлап торган солдатлар, моны ишетүгә, бердәм шаулап, Ишмәмәтне тиргәргә тотындылар:

— Эх син, дивана!

— Шашкан адәм!

— Кодайның мәҗнүн колы!

Әмма бу һич ачусыз, бары күңелләре ташудан тыела алмыйча гына тиргәү иде. Билгеле инде, үзенең үлемсезлегенә ышанган безнең Ишмәмәт моның ише тиргәүләргә нindидер бер өстенлек белән сабыр гына елмаеп карый...

Көн яктырып килгәндә инде безнең поезд урман эчендәге нindидер бер тупикка кереп туктаган иде. Вагон ишеген төбенә хәтле шылдырып ачтык; үрелеп-үрелеп алга да, артка да карыйбыз, ләкин башка бүтән юллар да, станция-мазар да юк, күренми. Бердәнбер юлда ялгыз безнең поезд гына тора — күрәсең, урман эченә аерылып керүебезне сизми дә калганбыз. Шушы микәнни инде без туктыйсы соңгы «точка»?.. Хуш, нишләргә соң, җыенып төшәргәме, әллә яңадан часовойларны куяргамы? Ләкин мин шулай аптырап уйларга өлгермәдем, состав буйлап кызу гына атлап килгән эшелон начальнигы үзе дә күренде. Тиз генә җиргә сикереп төштем. Килеп җитәр-җитмәс ул безгә дәртле генә кычкырып дәште:

— Ну, егетләр, хәлләр ничек, барыгыз да тере-исәнме, берегезгә дә чиста күлмәк-ыштан кирәкмиме?

— Юк, кирәкми, иптәш капитан, эш ул хәтлегә барып җитмәде,— дидем мин, аның шат кәефенә яраклашып.

— Ярый, бик шәп! Ә шулай да нык шүрләгәнсездер?

— Булды инде әзрәк...

— Әнә күрәсезме? — диде ул кинәт, безнең вагонның стенасына күрсәтеп.— Кыйпылчык тишекләре!

Мин ул күрсәткән төшкә борылып карадым: чынлап та, вагонның аргы башындарак берничә өр-яңа кыйпылчык эзе күренеп тора иде. Соңга калып дигәндәй, мин ничектер ихтыярсыздан куркынып киттем:

— Ә снарядларга... тигән булса?!

Капитан көлеп җибәрде:

— Снаряд үзе дә корычтан бит ул. Капсюленә тимәсә, аңа чорт та булмый.

Анысы шулай инде, снарядны атар өчен капсюленә бәрергә кирәк. Ә кыйпылчык, юньсез, аның ул нечкә җирен эзләп тормаган инде — мәсьәлә ачык.

— Ну, ярый, егетләр,— диде капитан, җитдиләнеп,— ничек кенә булмасын, безнең бу куркыныч сәфәребез уңыш-

лы төгәлләнде. Сез азат хәзер. Җыенып төшсәгез дә була.

Минем солдатларга шуны ишетү генә кирәк тә иде. Тиз-тиз генә җыенып, мылтык, капчыкларын бер-берсенә биреп, вагоннан сикерешеп тә төштеләр. (Шулай да төшкән берсе әлеге кыйпылчык тишекләренә шомланып карамыйча калмады.)

Капитан тагын безгә:

— Әнә урман кырыена барып, шунда мине көтеп торыгыз,— диде.— Мин хәзер килеп җитәрмен.

Ул яңадан паровозга таба китте, ә без юл буендагы казылманы үтеп, урман кырыена күтәрелдек. Бу куе, калын урман иде. Ләкин тирә-якка карангач та безнең бер нәрсәгә исебез китте: бөтен урман эче туп-тулы гаскәр! Агач төбе саен диярлек төркем-төркем солдат, ә бит читтән караганда, бер җан иясе дә юк кебек иде.

Якын-тирәдәгеләре, безне күреп, яныбызга да килә башладылар. Болар барысы да бик яшьләр иде, егерме бишенче-егерме алтынчы елгылар гына булса кирәк. Яңа набор инде бу... Өс-башлары да өр-яңа — яңа шинель, яңа бүрек, яңа итекләр. Билгеле, җирдә аунарга өлгермәгәннәр әле. Үзләре дә шулай пөхтә, көяз булуларына бик канәгать, шат шикелле, тиздән пычраныбыз, канга буялырбыз дип уйламыйлар да кебек. Шуңадыр, ахры, безнең шактый ук искергән, өстәвенә вагон идәнендә аунап изгәләнгән киемнәребезгә һәм салкыннан, йокысызлыктан өшәнгән, бөрешкән кыяфәтебезгә карагач, алар бик гаҗәпләнгәндәй булдылар.

— Кайдан болар, әллә чолганыштан чыкканнармы? — диде арадан бер «тапкыры», килеп җитүенә. Бүтәннәре тайлар шикелле кешни-кешни көлештеләр.

Без дәшмәдек. Без тыныч кына карап торабыз. Нигә болар бездән көләләр әле дип куыкка керү мәгънәсезлек кенә булыр иде. Әйдә, көлсеннәр, көлеп калыр чаклары. Иртәгә ни буласын уйламыйча, менә шулай ваемсыз көлә белү үзе бер бәхет бит әле. Аннары бик яшьләр бит алар, һәркайсы безнең Байәхмәткә яки менә Төхфәт абзыйга малай булырлык егетләр. Күңелдә аларга ачу түгел, ә ихтыярсыздан соклану... соклану... һәм кинәт — җан әрнеткеч кызгану гына кузгала. Менә бүген, шушы сәгатьтә үк сугыш бетсә соң, ни була?!

Ләкин арадан берсе тагын нидер әйтеп, иптәшләрен көлдергәч, безнең Емелькин кабынды да китте:

— Нигә кешнисез әле сез болай, ә?.. Кем дип беләсез сез безне, ә?..

Егетләр отыры ныграк көләргә тотындылар.

— Кара бу дядьканы! Ну гайрәт икән үзендә!

Ә Емелькинга җитә калды, бөтенләй авызлыгын тешләп алды бу... Ни әйткәнен белми, сибә генә. Сез, ди, без, ди, сез фәлән дә без төгән, ди... Без кырык беренче ел солдатлары, без фашист таныкларын күкрәгебез белән каршы алдык, менә минем өч кабыргам юк, бер үпкәм тишек, ди... Ә сез молокосослар әле, яңа әниләрегезнең итәгеннән шуып төшкәнсез, порохны иснәп тә караганыгыз юк бит әле сезнең, ди.

— Тукта, җитәр, Емелькин! — дим мин аңа.— Туктыйсыңмы, юкмы, эт җыккыры! Ату шушы егетләр алдында «Смирно!» бастырам бит үзеңне!

Бары шулай дигәч кенә бу, ниһаять, тыелды. Башкалар да аңа каты гына әйткәләп алдылар.

— Яратмыйм, Емелькин, мин синең тик торганнан шушылай этәчләнеп китүеңне,— диде якташы Төхфәт абзый да.— Без, имеш, без сугыштык, имеш! Ә болар нәрсә, сабан туена килгәннәр што ли! Ярый ла, син, кабыргаңны сындырып булса да, котылып калгансың, ә боларны иртәгә ни көтә, шуны әзрәк кенә уйлыйсыңмы?

— Уйларга баш кирәк гой! — диде Байәхмәт, үзенең көр тавышы белән салмак кына.

Ләкин Емелькинның һаман әле бирешәсе килми, җиңе белән битен-күзен сөрткәләп тора да бер үк сүзен кабатлый:

— Ник көләләр? Көлмәсеннәр, вәт шул!

— Ә көлсәләр, нимә булады? — диде безнең Ишмәмәт, гадәтенчә тыныч кына.— Алар Берлинга баралар кү, уртак Ямәлкин!

Дорды аны җилкәсеннән тотып дер селкетте:

— Вай-вай, ни чыкмаса мновы җен орган әкә җан авызыннан чыгады гой, рәхмәт төшкере!

Инде без барыбыз да рәхәтләнеп бер көлештек. Ә егетләр, әйтергә кирәк, бу вакытта инде шактый тынып калганнар иде. Алар безнең үз иптәшебезне ни өчен битәрләгәнне ачык сизделәр бугай, ничектер җитдиләнеп, хәтта бераз гына уңайсызланып та киткән кебек булдылар. Инде көлү түгел, артык сүз әйтүдән дә тыелып торалар.

Нәкъ шушы минутта безгә таба ашыгып килгән капитаныбыз күренде. Аңа бер старшина да ияргән иде. Егетләр аларны күрү белән, сылтау чыккандай, шунда ук таралыша да башладылар. Аннары старшиналарның күбесе ни өчендер бик бәйләнчек булалар, шуңа күрә солдатлар гадәттә алар белән еш очрашырга да яратмыйлар.

Бу старшина да яшьләрдән түгел иде, «карт бүре» булса кирәк: бөтен ыспай, көяз кыяфәте шуны күрсәтеп тора: кечерәк бүреген куе чәчләре өстенә кырын салып кигән, ә кара мыегын тәкә мөгезедәй итеп югарыга таба бөтереп куйган.

Килеп җиткәч тә капитан аңа:

— Старшина, менә бу иптәшләрне бик шәп кенә җылытырга кирәк,— диде.— Кайнар аш булсын, берәр чәркә дә салып бир үзләренә.

— Була ул! — диде старшина, безгә сынаулы караш ташлап, аннары көлемсерәп өстәде: — Ну, гвардеецлар, әйдәгез алайса!

Без аның артыннан иярдек. Урман эчендә атлаган саен диярлек төрле дәрәҗәдәге командирлар очрап тора, мин аларга җиренә җиткереп честь биреп үтәргә тырышам, ләкин, күрәм, аларның бездә өч тиенлек тә эшләре юк. Күбесе биргән сәламне алып та тормый — бу җәһәттән хөрлек икән монда.

Кечерәк кенә бер ачыклыкка килеп чыктык. Бер читтәрәк ике поход кухнясы төтен чыгарып тора, алардан уңдарак өч рәт булып сузылган тар озын өстәлләр, ә алар артындагы агачлар ышыгында брезент палатка күренә. Кухнялар янында шинель өстеннән бил тиңке генә киндер алъяпкыч буган ике солдат булаша. Шуларның берсенә старшина кычкырып дәште:

— Егорыч, ашың әзерме?

— Әзер, старшина!

— Алайса башлап сал менә бу... бөркетләргә!

— Котелокларыгыз кайда, китерегез! — диде солдат безгә.

Без билгә таккан котелокларны тиз генә чиштек, итек кунычыннан кашыкларны чыгардык. Алъяпкычлы солдат, табуреткага басып, биек тәгәрмәчләр өстендәге казаннан озын саплы чүмеч белән безнең котелокларга аш соса башлады. Шул арада старшина үзе әлеге палаткадан бер кирпеч икмәк һәм ике «яртыны» күтәреп чыкты. Шешәләрнең берсенә кырлы стакан да кидерелгән иде.

Без озын өстәлнең бер башына тезелешеп утырдык.

Старшина:

— Икмәкне үзегез турарсыз, ә менә моны,— диде, шешәнең төбенә җиңел генә сугып,— кайсыгыздан башлыйбыз?.. Сержант, давай синнән, мә тот!

Ул кырлы стаканга аракыны тутыра язып салды. Мин, стаканны алып, салкын гына аракының исен дә, әчесен дә тоймыйча диярлек, чишмә суын эчкәндәй, бер тыннан аударып та куйдым. Үзебезнең «рус әчесе» безгә бик сирәк эләгә, шуңадыр инде без аны һәрвакытта бик теләп кабул итәбез. Әмма хәзерге кебек аның, хәерсезнең, бу хәтле дә шәп төшкәнен хәтерләмим — май капкан шикелле генә булып калды.

Башкалар да үз өлешләрен сабыр гына көтеп алып, мыекларын сыпыргалап, иплә кенә салып куйдылар. Тик Ишмәмәт кенә стаканын кире этәрде. Старшина гаҗәпләнә калды:

— Нишләп? Әллә әзрәк салдыммы?

— Мин эчмәем,— диде Ишмәмәт, алдына карап кына.

— Кызык! Аракыдан баш тарткан солдатны беренче очратам әле...

— Аның бер усал алласы бар, шуңардан шүрли ул,— диде Емелькин, үзенә өмет иткәндәй, ашыгып.

— Алайса без аны аздырмыйк,— диде старшина һәм Ишмәмәт өлешен кире шешәгә бушата башлады.

Ә котелокларда гаҗәеп тәмле, хуш исле, кашык тыккысыз куе, кайнар борщ! Моның кебек ашны күптән күргән юк иде; билгеле инде, без аны урып кына салдык. Борщ артыннан бик әйбәт карабодай боткасы да булды әле — аны да ашыкмыйча гына ялт иттердек. Инде рәхмәт әйтеп, амин гына тотасы, ә минем казакълар шыпырт кына миңа:

— Сержант, чәй кирәк иде, чәй дә булмасмы икән? — дия башладылар.

Старшина аңлагандай:

— Тагын нәрсә? — диде.

— Чәй сорыйлар, иптәш старшина!.. Безнең бу халык чәйсез тора алмый,— дидем мин, көлгән булып.

— Егорыч! — дип кычкырды старшина алъяпкычлы солдатка,— чәең бармы? Булса, салып бир үзләренә!

— Кунаклар өчен барсы да бар,— диде солдат, безгә күз кысып.— Кая, китерегез кружкаларыгызны!

Капчыктан тиз генә кружкаларны чыгарып, аның янына ашыктык. Ул безгә икенче поход казанының бер янтыгындагы кечкенә җиз кранынннан чәй агыза, ә минем казакълар аны аркасыннан кага-кага мактыйлар: «Земляк хорош, хорош, наш брат, понимаеш гой?!» — диләр.

Инде бу кайнар чәйне дә өрә-өрә эчеп бетерүгә, капитаныбыз тагын безнең янга килеп җитте.

— Йә, ничек, дуслар?! — диде ул, елмаеп кына.

Аның шулай үз итеп дәшүенә сөенеп мин:

— Бик әйбәт, иптәш капитан, бик зур рәхмәт сезгә! — дидем.

— Җылындыгызмы?

— Җылындык, хәтта тирләп чыктык!

— Туйдыгызмы?

— Туймаган кайда, менә болай булды! Бик каты сыйладылар... Иптәш старшинага да, поварга да бездән бик зур рәхмәт инде.

— Яхшы алайса,— диде капитан.— Димәк, кузгалырга да ярый?

— Без әзер, иптәш капитан!

— Ул чагында әйдәгез, мин сезгә юл күрсәтәм.

Без капчыкларны тиз генә төйнәп, күтәренеп аның ар-

тыннан иярдек. Агачлар арасыннан бер ун минут чамасы баргач, зур урманны туп-турыга кисеп узган тар юлга килеп чыктык. Шунда капитан тукталды, ә без, гадәткә буйсынып дигәндәй, аның алдына тезелештек. Ул беравык безгә дәшми генә карап торды, аннары бик гади генә итеп:

— Иң элек мин сезгә командование исеменнән рәхмәт белдерәм! — диде.

Мондый чакта, кагыйдә буларак: «Советлар Союзына хезмәт итәм!» — дип җавап бирү кирәк, бу зарури нәрсә, ләкин нишләптер без беребез дә шуны әйтә алмыйча калдык. Күрәсең, капитанның рәсми төс бирмичә, артык гади итеп әйтүе безне тугарды булса кирәк. Аннары: «Ни өчен икән бу рәхмәт?» — дип тә шикләнә калдык шикелле... Хәер, капитан үзе дә безнең мокытлыкка игътибар итеп тормады.

— Инде, сержант, син тыңла! — диде ул миңа.— Менә шушы юл белән уңга, кояш чыгышына карап барыгыз. Бер дүрт километр киткәч, зур таш юлга барып чыгарсыз. Анда, юл чатында ук, регулировщик тора — аңа менә шушы кәгазьгә язылган пунктны күрсәтерсез. Сезнең ротагыз шул җирдә. Ә регулировщик сезне берәр узгынчы машинага утыртып җибәрер... Аңладыгызмы?

— Аңладым, иптәш капитан! — дидем мин, ул сузган кәгазь кисәген алып.

— Ну, хәерле юл сезгә!.. Командирыгызга миннән сәлам әйтегез!

— Рәхмәт, әйтермен! — дидем мин, аңа честь биреп.

Һәм без киттек. Иң алдан мин, иң артта — Ишмәмәт. Аркаларда бөрмәле капчык, иңдә — мылтык, Төхфәт абзыйның кулында тагын чәй кайната торган кара чиләгебез. Тук казлар шикелле салмак кына селкенеп, бер җайга ашыкмыйча гына барабыз. Урман юлы юеш комлык, атлавы әллә ни авыр түгел. Ике якта да биек, төз наратлар, «гаскәр кеби» шылт та итмичә, горур-тын гына торалар. Ә юл туп-туры, юл озын, күзге томанга кереп югалган, ләкин без алга барган саен, томан да әкренләп чигенә бара. Күп уздык без мондый юлларны, тагын күпме узасы калгандыр?.. Билгесез, хәтәр юлларны!.. Әмма бер юл безнең хыялыбызда көне-төне ялтырап, ярылып ята; бу — җиңү аша туган илләребезгә алып кайта торган соңгы юлыбыз... Без, җиде солдат, менә шул юлдан атлыйбыз!

*1971*

# ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ

Көзге кич. Тышта җил, яңгыр. Нидер кыштырдый, дөберди, ыңгыраша. Вакыт-вакыт бу сәер тавышлар көчәеп тә китә. Мин, куркынып, укый торган китабымнан аерылып, колак салып тора башлыйм. Нәрсә икән бу? Әллә безнең капкага чит кешеләр килде микән? Хәзер бик хәвефле чак бит. Шәһәрдә төрле шомлы хәбәрләр йөри. Талаулар, хәтта үтерүләр дә булып тора, дип сөйлиләр. Аллам сакласын! Бигрәк тә әллә нинди буталчык, куркыныч ел булды бу унсигезенче ел!.. Ләкин менә хәзер шомлануым юкка гына икән: әлеге хәерсез усал җил котырына, имеш, шуңардан тыштагы каен ыңгыраша, шәрә ботаклары өйнең стенасына бәрелә-сугыла тырнаша. Әнә тәрәзәдән төшкән яктыда да кара ботакларның, кемнеңдер чатлы-ботлы куллары шикелле, як-якка селкенгәне күренеп тора.

Тынычланып, яңадан китабыма иеләм. Ә укый торган китабым бик кызыклы булса кирәк — «Дим буенда» дип атала. Бүген генә Кәримәдән алып кайттым. Менә шуны йомшак урын өстендә, аякларымны җыеп, мендәргә таянып, аерыла алмыйча укып утырам. Миңа билгесез ерактагы Дим елгасы. Искиткеч гүзәл, имеш, аның буйлары... Менә шунда Исхак дигән карт мирзаның гаиләсе яшәгән. Аның ике улы, бер кызы булган. Аннары Фәридә исемле бер ятимә кыз да аларда торган икән. Бу кыз рояльдә бик оста уйнаган... Кыскасы, гүзәл табигать, бай тормыш, чибәр кешеләр. Әмма ләкин бу роман да бәхетсез мәхәббәт турында булса кирәк. Укый торгач, менә шул ачыла башлады. Гаҗәп, нинди генә романны укымыйм, гел бәхетсез мәхәббәт турында!.. Нигә ул алай икән?.. Әллә тормышта бәхетле мәхәббәт дигән нәрсә бер дә булмый микән?

Тәмле укуымны бүлеп, асрау кызыбыз Сабира бүлмәмә килеп керде.

— Туташ, сезне әтиегез чакыра!

— Нигә инде?

— Бер егеткә күрсәтергә.

— Куй әле шул мәгънәсез шаяртуларыңны...

— Төшкәч күрерсең! — диде Сабира, ваемсыз гына, һәм шунда ук чыгып та китте.

Мин аның сүзенә ышанмадым, әлбәттә. Егет, имеш! Күрсәтер безнең әти егеткә, көтеп тор! Ә дәшкәч төшәргә кирәк. Иренеп кенә аякларымны салындырдым, йомшак чүәкләремне кидем, көзгегә күз салып, чәчемне рәтләштергән булдым да тар баскычтан түбән төшеп киттем. Өстемдә дә минем гади генә ситсы күлмәк иде... Шушы кыяфәтем белән, аны-моны уйламыйча, залга барып та кердем. Һәм керү белән, күзгә күренмәс диварга килеп бәрелгәндәй, шып туктап та калдым. Шаяртмаган икән ләбаса Сабира! Әтием янында, йомшак креслода яшь кенә бер егет утырып тора! Ни сәбәптер шул мизгелдә үк егетнең миңа төбәлгән зур күзләре һәм нечкә коңгырт кашлары белән мәрмәрдәй ап-ак маңгае минем игътибарымны җәлеп итеп тә өлгерде. Билгеле инде, бу хәтле дә көтелмәгән очрашудан мин бик аптырап-уңайсызланып калдым, бит очларым, кинәт ут капкандай, кызарып яна да башлады.

Әтием хәлемне аңлады шикелле, чак кына көлемсерәп урыныннан торды да, гади генә итеп:

— Кызым, бу Салих әфәнде! — диде.

Егет тә, торып, сүзсез генә миңа башын иде. Мин дә аңа баш идем һәм чәч толымнарымны тиз генә аркама күчердем.

Аннары әтием, егеткә карап:

— Кызыбыз Гөләндәм шушы була инде,— диде.

Егет тагын бер кат җиңелчә генә башын иде. Шуннан соң әтием миңа әйтте:

— Кызым, Салих әфәндене мин сиңа музыкадан дәрес бирер өчен чакырттым. Без инде сөйләштек, килештек — Салих әфәнде түбәнчелек белән риза да булды. Хәзер, кызым, эш синнән тора: иншалла, күңел биреп кенә музыкант әфәндедән барысын да белеп, өйрәнеп калырга тырышырсың дип ышанам.

— Рәхмәт, әти! — дидем мин, тыелып кына.

— Әмма бер шартым бар,— диде ул, яңадан Салих әфәндегә борылып.— Дәрес вакытында миңа да бер читтә генә тыңлап утырырга рөхсәт итәрсез инде... Үлеп яратам үзебезнең мөселман көйләрен, ихлас!..

— Ихтыярыгыз! — диде Салих әфәнде, авыз чите белән чак кына елмаеп. Ул әтиемнең «мөселман көйләрен үлеп яратуына» ышанып бетмәде, ахрысы. Хәлбуки әтием музыканы ярата, һичшиксез ярата, яратмаса, менә мине дә укытып маташмас иде. Әмма бу очракта аның дәрес вакытында «бер читтән генә тыңлап утырырга» теләвен, музыкага мәхәббәттән дә бигрәк, безгә күз-колак булыр өчен дип аңларга бик мөмкин иде. Салих әфәнде, әлеге яшерен мәгънәле генә итеп елмаюына караганда, нәкъ

әнә шулай аңлады да булса кирәк. Билгеле инде, әтием өчен миңа да бик уңайсыз булып китте. Асылда, аның әйткән шартын башкача аңлап та булмый. Шәкерт — җитеп килгән кыз, укытучы — яшь кенә егет, күз-колаксыз ярыймы соң?!

Салих әфәнде әтиемнән минем белән сөйләшергә рөхсәт сорады. Әтием, рәхим итегез, дигәч, ул миңа карап йомшак кына сораша башлады:

— Туташ, сез пианинода уйнарга күптән өйрәндегезме?

Аның миңа төбәлгән күксел-зәңгәр күзләренең карашыннан мин ничектер югалыбрак калдым, ирексездән тагын кызардым һәм каушабрак кына:

— Юк, күптән түгел,— дидем.

— Кемнән өйрәндегез?

— Башта үзем генә.

Пианино өстендә нота дәфтәрләре ята иде, Салих әфәнде, шуларга ымлап:

— Ләкин сез нота белән дә уйныйсыз шикелле,— диде.

— Әйе, уйныйм... әзрәк кенә.

— Нотага кем өйрәтте?

Аның бу соравына әтием җавап бирергә ашыкты:

— Күршебездә генә бер яһүдә ханым торган иде, шул бездә пианино барлыгын белгәч, кергәләп йөри башлады. Музыкага бик хирыс хатын икән, үзе кәефләнеп уйнау өстенә, менә безнең Гөләндәмне дә бик теләп өйрәтергә тотынды... Кызыгызда музыкага сәләт бар, чынлап укытырга кирәк, ди торган иде. Без инде каршы килмәдек, бигрәк тә әнисе... Гөләндәм бу нота дигән язуларга шуңардан өйрәнеп тә калды. Тырышты яһүдә, әйтәсе дә юк!

— Кем ул, фамилиясе ничек? — диде Салих әфәнде, шунда ук кызыксынып.

— Ни атлы иде әле ул, кызым?

— Маргарита Яковлевна Зель... Зельберг.

Салих әфәнде аз гына уйланып торды:

— Зельберг?.. Юк, белмим, кызганычка каршы!

— Ул ханым, герман сугышы башлангач, Петербургтан сөрелгән булса кирәк,— диде әтием.— Һәрхәлдә, безнең шәһәрдә вакытлы гына кеше иде, хөррият чыккач та каядыр китеп барды.

Салих әфәнде, яңадан миңа карап:

— Ноталарыгыз белән танышырга рөхсәт итегез! — диде.

Мин баш кагып кына ризалыгымны белдердем. Ул нота дәфтәрләрен берәм-берәм алып карарга кереште.

— Скрябин... Шопен... Ярый, яхшы бу... Ә бусы кем-

неке? Гурилев!.. Хәзерге вакытта күп уйнала торган композиторларның берсе... Аның шушы нәрсәсен уйнап та күрсәтмәссезме, туташ?

Мин чарасыздан диярлек ул сузган нотаны кулыма алдым. Бу «На заре туманной юности» дигән романс иде. Уйнамаган нәрсәм түгел, тик шулай да Салих әфәндегә баштан ук мондый авыр нәрсәне уйнап күрсәтү мине, билгеле, куркыта иде. Ләкин укытучы буласы кешем сорагач, мин, теләсәм-теләмәсәм дә, пианино каршына утырырга мәҗбүр булдым. Нотаны ачып терәп куйдым да, ничек тә каушамаска тырышып, ашыкмыйча, җайлап кына уйный башладым. Салих әфәнде миннән бер читтәрәк, пианино өстенә таянып, бик игътибар белән тыңлап торды. Моңарчы беркемнең дә әле, бигрәк тә музыкант кешенең, яныма басып, мине махсус тыңлап торганы юк иде. Шуңадыр инде, романсны уйнап чыгу минем өчен сират күперен кичү белән бер булды. Ничегрәк уйнавымны үзем бөтенләй сизмәдем дә диярлек.

Уйнап беткәч, Салих әфәнде бары:

— Яхшы! — дип кенә куйды.

Нәрсә яхшы — уйнавыммы, әллә уйнап бетерүемме — мин моны аңлый алмадым. Шуннан музыкант әфәнде (әтием әйтмешли) миңа үзем яраткан берәр көйне нотасыз гына уйнарга кушты. «Татарчамы?» — дип сорадым мин. Әлбәттә, диде ул... Менә монысы инде, оят булса да әйтергә кирәк, минем өчен шактый ук читен эш иде. Хәзергә кадәр әле мине үзебезнең көйләрне юньләп уйнарга өйрәнеп җитә алганым юк. Дөрес, баштарак кайбер көйләрне ярыйсы гына уйный идем кебек, ә менә Маргарита Яковлевнадан нотага өйрәнә башлагач, алары да онытылды диярлек. Маргарита Яковлевна нотасыз уйнаганны ни өчендер бер дә яратмый иде. Иң элек нотадан өйрәнергә, шуннан соң гына яттан уйнарга кирәк, дип әйтә торган иде. Ә нотага салынган татар көйләрен бездә кайдан гына табасың?!

Көтеп торган Салих әфәндегә мин, ниһаять, бик уңайсызланып кына әйтергә мәҗбүр булдым:

— Гафу итегез, татар көйләрен уйный белмим шул.

— Бер дәме? — диде ул, гаҗәпләнеп.

Мин дәшмәдем, дөресрәге, ни диеп әйтергә дә белмәдем.

— Юк, сез уйный беләсез,— диде ул, мине рухландырырга теләгәндәй.— Ягез әле, ягез!.. Миңа бит бары сезне ишетеп карау гына кирәк.

Әлбәттә, карышып тору килешмәячәк иде. Әмма нәрсәне, ничек кенә итеп соң, Ходаем?.. Шулай да азапланып уйлана торгач, электәнрәк белгән бер көйне исемә төше-

реп, бик әкрен генә, бик сак кына уйный башладым. Бу «Яз да була...» дигән көй иде... Күңелемдә ачык яңгырый ул минем... Ахырда уйнап чыктым.

— Менә булды бит! — дип куйды Салих әфәнде, елмаеп кына.— Шәп уйныйсыз, дип мактый алмыйм, туташ, әмма көйне тоя беләсез. Ә бу — музыкант өчен иң кирәге, иң мөһиме!..

Шушы урында әтием тагын сүзгә кушылды:

— Безнең максат, Салих әфәнде, кызыбызны музыкант ясау түгел. Әгәр дә ки үз көйләребезне чибәр генә уйнарга өйрәнсә, без шуңа да бик канәгать булачакбыз. Сезнең ярдәмегез белән, әлбәттә!

Салих әфәнде башта иелә биреп миңа рәхмәт белдерде, шуннан соң гына әтием янына күчте.

— Әхмәтҗан абзый, Гөләндәм туташ татар көйләрен уйнарга да һичшиксез өйрәнәчәк,— диде ул, ничектер бик ышандырып.— Ә бәлки чын музыкант та булып китәр, бөтен эш аның кабилиятенә һәм сезнең теләккә бәйләнгән.

Әтием, килешеп:

— Хак сүз! — диде.— Әмма анысын инде киләчәк күрсәтер, насыйп булса!

— Әйе, киләчәк күрсәтер! — дип кабатлады Салих әфәнде дә.— Ә дәресне без икенче очрашуда башларбыз... Кайчан килергә рөхсәт итәсез?

— Алдан сөйләшкәнчә, сез атнага ике мәртәбә килергә тиешсез. Бүген сишәмбе көн, тагын кайсы көн сезнең өчен уңайрак?

— Җомгадан башка көннәрнең кайсы да ярый миңа.

— Җомга — изге гыйбадәт көне, шуңа фани дөнья эшләре белән шөгыльләнергә теләмисездер инде, Салих әфәнде, шулаймы?

Әтием моны көлебрәк сорады шикелле, ләкин Салих әфәнде, бер дә аптырамастан, аңа шактый кызык кына итеп җавап бирде.

— Киресенчә, Әхмәтҗан абзый, бу көнне изге эшләрем күп минем. Мәсәлән, көндез «Шәрык» клубында балалар өчен, ә кичен «Сәйяр» оркестрында уйныйсым бар.

— Ә, шулаймыни әле, мин сезнең ул хезмәтегезне онытa да язганмын. Кичерегез!.. Соң, алайса кайсы көн мәгъкуль булыр икән?.. Атнакич дисәм, ике дәрес арасы бик якын була кебек... Бәлки, шимбә көн?

— Мин риза. Тик вакыты кичке сәгать биштән җидегә чаклы булсын иде. Көндезләрен бушый алмыйм.

— Безнең өчен дә бу вакыт уңай булачак,— диде әтием.— Кызым, ишеттеңме, Салих әфәнде дәрес бирергә шимбә көн килә.

— Ишеттем,— дидем мин.

Әтием тагын нидер сөйли башлаган иде, ләкин минем аларга (дөресрәге, Салих әфәндегә) карап торуымны күргәч, сүзен бүлеп, әдәп белән генә:

— Кызым, син бүгенгә азат! — диде.

Мин дә әдәпнең нәрсә икәнен аңлап, кызаруымны яшерер өчен башымны иеп кенә залдан чыгып киттем. Алар әле сөйләшә калдылар.

## I

Үз бүлмәмә кайткач та, мин тиз генә тынычлана алмадым. Хәтта мавыгып укып яткан китабыма да яңадан тотынасым килмәде. Нишләптер бу көтелмәгән очрашу мине бик дулкынландырды әле... Салих... Салих әфәнде!.. Хәер, ни өчен көтелмәгән?.. Музыкадан укытучы чакыру турында безнең гаиләдә күптән сүз бара иде бит инде. Иң элек мин үзем моны бик тели идем, шулай ук әнием дә тели иде, аннары тора-бара әтием дә риза булды. Биредә шуны әйтергә кирәк, әнием минем заманына күрә алдынгы карашлы, мәдәнияткә омтылучы хатын иде. Ул бит Сембердә туып үскән, ә Сембер Казан түгел инде — саф рус шәһәре. Ахун хәзрәт кызы булуына һәм асылда мөселманча тәрбияләнеп үсүенә карамастан, әниемә барыбер рус кызлары белән аралашырга, телләрен, гадәтләрен өйрәнергә, өй-гаилә тормышларын якыннан күрергә туры килгән. Болар барысы да аңа билгеле бер йогынты ясамыйча калмаган, әлбәттә. Мәсәлән, әнием бервакытта да йөзен ирләрдән яшерми, шулай ук абыстайлар шикелле укалы камзул, үкчәсез читекләр дә киеп йөрми. Ул европачарак киенергә ярата һәм күлмәкләрен дә бары рус хатыннарыннан гына тектерә.

Билгеле инде, әнием мине дә үзе теләгәнчәрәк тәрбия итәргә тырышты. Казанның иң яхшы, иң алдынгы мәктәпләреннән саналган Ләбибә ханым мәктәбенә укырга бирде. Бу кызлар мәктәбендә безгә, төрле фәннәр укыту белән бергә, рус телен дә укыттылар, шулай ук һәртөрле кул эшенә дә өйрәттеләр. (Мин инде рөштинең дүртенче сыйныфына күчкән идем, ләкин, кызганычка каршы, быел җәй зур пожар вакытында мәктәбебез янып харап булды.) Аннары миндә җыр-музыкага күпмедер сәләт барлыгын белгәч, әнием әтиемнән, ай-ваена куймыйча, пианино да алдырды. Инде менә хәзер махсус укытучы чакырту да — асылда, әнием эше. Әтием исә минем, дөресен генә әйткәндә, шактый иске караштагы кеше. Бигрәк тә тәрбия мәсьәләсендә. Ни өчендер ул, кызларга күп белү

кирәкми, дигән караштa тора. Имеш, артык күпне белгән кыз бала хөрлеккә өйрәнә, ә хөрлеккә өйрәнгәч, үзенең киләчәктәге вазифасын оныта башлый. Ягъни иренә итагатьле хатын, балаларына яхшы ана була алмый, имеш. (Ни өчен була алмый? — мин моны үзем һич тә аңламыйм.) Ярый әле, әтиемнең бер «йомшак» ягы бар — ул күп кенә очракта әнием белән килешергә мәҗбүр. (Әнием бит чыгышы белән дә, тәрбиясе белән дә аңардан өстен, әтием исә «мужиктан» чыккан, тик үзенең зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында гына зур байларның доверенные булган кеше...) Менә миңа музыкадан укытучы алу мәсьәләсендә дә эш шулайрак булды: әнием, кирәк, диде, әтием... Хәер, бу очракта зур бәхәс тә тумады, чөнки, әйткәнемчә, әтием үзе дә музыканы бик ярата иде.

Әмма аның укытучы итеп Салих әфәнде кебек яшь, чибәр бер егетне чакыруы бик гаҗәп иде. Мин үзем дә моны һич тә көтмәгән идем. Күрәсең, берәр могтәбәр кеше, аны бик мактап, әтиемә тәкъдим иткәндер инде. (Музыкант итеп кенә түгел, әдәпле, инсафлы, ышанычлы егет итеп тә; күрдегез ич, ул минем белән әтиемнән рөхсәт сорап кына сөйләште.) Аннары, Салих әфәнде өебезгә килеп, әтием-әнием алдында мине укытып йөриячәк. Димәк, артык хәвефләнергә урын да булмаячак. Ә миңа килгәндә инде, мин бит әле уналты яшьлек кенә кыз бала, укытучыма шәкерт кенә, минем уемда дәрес алудан башка нәрсә генә булырга мөмкин?! Шулай ич!

Шулаен шулай да, әмма ни өчен соң мин Салих әфәндене күрү белән бу кадәр коелып төштем? Каушау һәм нәрсәгәдер куану шул ук мизгелдә икесе берьюлы диярлек минем җанымны биләп тә алды — нидән бу, нидән?.. Кинәт каршымда бик чибәр егет пәйда булганга күрә генәме?.. Әйе, яшерә алмыйм, залга килеп керүемә аның чибәрлеге минем күземә ташланды: бик чиста ак йөзе, сөйкемле генә чокыраеп торган ияге, җыйнактулы иреннәре, кечерәк, әмма килешле генә борыны, бигрәк тә ак мәрмәрдәй шома маңгае белән як-якка ишелебрәк торган коңгырт чәчләре — болар барысы да сокланып каратырлык иде. Мин инде аның күксел-зәңгәр күзләре турында әйтеп тә тормыйм. Бер генә тапкыр күтәрелеп карадым, шунда да ул күзләр әллә тирәнлеге, әллә уйчанлыгы белән мине әйтерсең йотып алды.

Ләкин менә хәзер, тынычлана төшкәч, бер нәрсә гаҗәпләндерә әле мине: бу хәтле үк дулкынлануыма шул Салих дигән егетнең беренче карау белән күземә ташланган чибәрлеге генә сәбәп булды микәнни?.. Алай дисәң, минем бит инде моңарчы да чибәр егетләрне

күргәләгәнем бар иде, әмма аларның берсе дә мине бер үк вакытта каушап калырга да һәм ниндидер билгесез куаныч кичерергә дә мәҗбүр итмәде ич! Димәк, моның сере чибәрлектә генә түгел. Юк, түгел! Ә нәрсәдә соң?.. Бу хәлнең бөтен яшерен серләрен мин әле белмим, белмим... тик шуны гына беләм: чибәрлектән башка тагын... ничек кенә дип әйтергә? — сүзен таба алмыйм, Ходаем!.. Тукта, таптым шикелле: нәфислек! Әйе, әйе, нәфислек!.. Беләсезме, Салих әфәнденең бөтен кыяфәтеннән, килеш-килбәтеннән, торышыннан, хәтта сөйләшүеннән бик зат кешеләргә генә хас үзенә бер нәфислек сизелеп тора иде. Ул — нәфис кеше!.. Менә нинди кешегә Ходай мине һич көтмәгәндә юлыктырды.

## II

Әйтелгән көнне, билгеләнгән сәгатьтә Салих әфәнде миңа беренче дәресен бирергә килде. Бу урында шуны әйтеп китим әле: ул килер алдыннан мин, үземә калса, мөһим генә бер мәсьәләне чишәргә тырышып баш ваттым: миңа нишләргә — залга төшеп көтеп торыргамы, әллә булмаса, ул килгәч кенә төшәргәме? Шәкерт булгач, мин үз урынымда, ягъни пианино янында көтеп утырырга тиешмендер инде. Ләкин шул ук вакытта мин бит әле туташ кеше, димәк, Салих әфәнде килгәч кенә төшсәм дә гаеп булмас шикелле... Хәтта дөресрәк тә булыр. Һәм мин бу юлы шулай иттем дә — ул килгәч кенә залга төштем.

Без баш иешеп кенә исәнләштек. Әтием анда иде инде, аяк өсте генә сөйләшеп торалар иде. Салих әфәнде, әдәп саклап булса кирәк, минем яныма килергә ашыкмады, тик бераздан гына әтиемнән дәресне башларга рөхсәт сорады. «Рәхим итегез!» — диде әтием һәм үзенең сары бәрхет тышлы йомшак креслосына барып утырды. Дәрес беткәнче ул шунда безне тыңлап утырачак. Кыен хәл!.. Бигрәк тә Салих әфәндедән яхшы түгел — аркаңа кемдер күзләрен текәп утырсын әле!.. Ләкин ул, бу хәлгә бер дә исе китмәгәндәй, тыныч кына минем яныма килде, кулындагы төргәген пианино өстенә куйды һәм миңа утырырга тәкъдим итте. Үзе дә урындык алып, аз гына читкәрәк урнашты.

Мин аның беренче сүзен көтәм — укытучым дәресне нәрсәдән башлар икән?.. Әлбәттә, иң элек музыка турында гомумән нидер сөйләр инде. Ләкин ул сүзен бик гади итеп башлады:

— Туташ,— диде, әдәп белән генә,— сез инде нота та-

ныйсыз, пианинода яхшы гына уйныйсыз. Шуңа күрә мин бүгенге дәресне турыдан-туры үзебезнең халык көйләрен уйнарга өйрәтүдән башламакчы булам. Сез каршы килмисездер бит?

Укытучым миннән әнә шулай дип сорады — бу гаҗәп иде! Һәм мин кыюсыз гына «юк» дидем инде.

— Алайса мин сезгә башта берәр көй уйнап күрсәтим. Рөхсәт итегез!

Мин читкәрәк авыштым, ул күчебрәк утырды. Уйный башлаганчы миңа болай диде:

— Татарда көйләр бик күп. Алар, нигездә, барысы да биш тавышлы ладка корылганнар, әмма мелодияләре белән бер-берсеннән нык аерылалар. Әйтик, «Тәфтиләү» бар, «Алмагачлары» бар, икесе дә пентатоникага нигезләнгән, ә аермалары нинди! Берсендә — тирән моңсагыш, икенчесендә — дәрт, шатлык... Халык күңеле әнә шундый инде ул, туташ,— иң нечкә кичерешләренә дә көен-җырын таба белә!.. Без әле аларның төрлесен өйрәнербез, ә хәзергә уйнар өчен берәр җиңелрәген алыйк. Мәсәлән, «Туган тел»не! Сезгә дә ул таныштыр... Мәрхүм Габдулла абый Тукай сүзләре белән аны хәзер бөтен мәктәпләрдә җырлыйлар.

— Без дә хор белән җырлый идек,— дидем мин, кыюланып.

— Менә бигрәк тә яхшы... Элек бу көйне «Анам кабере янында» дип йөртәләр иде. Тукай сүзләренә җырлана башлагач, ул әйтерсең яңадан туды — авыр хәсрәтле көйдән якты рухлы көйгә әйләнде дә куйды. Исеме дә «Туган тел»!

Чынлап та, шулай икән шул!.. Әмма Салих әфәндедең моны ничектер балаларча сөенеп әйтүе миңа тагы да хикмәтлерәк булып тоелды. Мин ирексездән аңа борылып карадым, ә ул, шуны көткәндәй, күзләрен тутырып миңа карап тора!.. Бер генә секундка икебез дә уңайсызланып калгандай булдык. Аннары ул, тыйнак кына:

— Инде тыңлагыз! — диде, уйнарга җыенып.

Ул, утырган җиреннән турая биреп, башын күтәрә төште, югары карап, аз гына уйланып торды һәм бер иңбашын сәер генә селкетеп куйды да кулларын клавишлар өстенә салды. Мин шунда ук аның кулларына игътибар иттем — ак, нәфис, җыйнак кына куллар! Бармаклары бик озын да түгел, ләкин ыспай-нечкәләр. Менә ул матур бер хәрәкәт белән кулларын әз генә күтәрә төште дә ашыкмыйча йомшак-җиңел генә итеп уйный да башлады. Кулларына бөтенләй карамый да кебек, акчарлак канатыдай, алар клавишларга тиеп-тиеп кенә алалар төсле,

ә шулай да көй кирәк урында көчәеп, кирәк урында гына әкренәеп, өзлексез-тигез генә ага иде.

Менә ул уйнап бетерде, музыка тынды, ә көй — ни гаҗәп! — һаман дәвам итә кебек. Салих әфәнде үзе дә шуңа колак салгандай аз гына тынып торды, аннары кулларын клавишлар өстеннән сак кына алды да, җиңел генә сулап:

— Менә шул! — дип куйды.

Аның уенына бәя бирү минем өчен, билгеле, бик читен, бәлки, хакым да юктыр әле, тик шуны гына әйтәсем килә: Салих әфәнде бик табигый, бик садә, ихтимал шуңадыр, бик үтемле итеп уйнады. Хәтта тын гына утырган әтием дә әйтмичә кала алмады:

— Күркәм, бик күркәм, Салих әфәнде!

Салих әфәнде исә көлемсерәп кенә, гүя җавапсыз калмас өчен генә:

— Рәхмәт! — диде һәм, миңа борыла төшеп, сүзен дәвам иттерде: — Һәр музыкант үзенчәрәк уйный, туташ, чөнки көйне дә ул үзенчәрәк ишетә. Шуңа күрә мин сезгә нәкъ менә минем төсле уйнагыз дип куша алмыйм. Ләкин көйне сез дөрес отып алырга тиешсез. Моның өчен башта нотага карап, нота белән уйнарга кирәк булыр... Менә мин сезгә «Туган тел»нең үзем язган нотасын да китердем.

Ул пианино өстенә куйган төргәген сүтеп, шуннан ноталар чыгарды һәм арадан берсен алып миңа бирде.

— Инде сез уйнап карагыз!

Мин якынрак утырдым да ике битлек кенә нотаны алдыма ачып куйдым.

— Ашыкмагыз, башта яхшылап карагыз,— диде Салих әфәнде.

Мин нота билгеләренә күз йөртеп чыктым — көйне «укып» булырлык иде. Инде уйнарга җыенып, кулымны клавишка салгач кына, Салих әфәнде миңа тагын шуны да әйтте:

— Терсәкләрегезне үзегезгә кысмагыз, иркен генә тотыгыз. Менә шулай. Гомумән, уйнаганда иркен, табигый утырырга кирәк.

Моны миңа Маргарита Яковлевна да гел әйтә торган иде, кулны-бармакларны ничек итеп дөрес тотарга, дөрес йөртергә — барсын да күрсәткән иде. Үзем дә беләм инде югыйсә, ә шулай да терсәкләремне һаман янтыгыма кысам. (Әлеге оялчан кызлар гадәте!) Мин әз генә каушый төштем, башлый алмыйчарак тордым. Салих әфәнде, шуны сизеп, миңа әкрен генә көйләде. «Ля-ля-си-ля-фа-диез...» һәм мин тәвәккәл генә башлап киттем. Көй бик гади дә, көй бик таныш та, шуңа күрә мин аны бозмыйча-нитмичә диярлек уйнап та чыктым шикелле... Ләкин

Салих әфәнде ни өчендер бер сүз дә әйтмәде, тик яңадан игътибар беләнрәк кабатларга кушты. Мин тагын бер кат уйнап чыктым. Шуннан соң гына ул әйтте:

— Болай дөрес кенә уйныйсыз, туташ. Тик көйнең агышына ныграк колак салыгыз. Нәкъ нотада язылганча уйнарга тырышыгыз. Ритмны төгәл саклагыз. Бу сезгә аңлашыламы?

— Аңлашыла,— дидем мин.

— Әлбәттә, күп кабатларга кирәк әле. Киләсе дәрескә хәтле сез инде аны күңелдән уйнарга өйрәнегез. Бу минем сезгә беренче сабагым булсын. Аннары, менә нәрсә әйтәсем килә: уйнау техникасын камилләштерү өчен сез иске күнегүләрне дә онытмаска тиешсез. Теге ханым сездән төрле күнегүләрне күп уйнаткандыр, билгеле. Менә шуларны яңадан кабатларга кирәк. Беләсезме, музыкада осталыкка бары көн-төн өзлексез уйнау аркасында гына ирешеп була. Башкача мөмкин түгел... Ә сездә Черни «Этюдлары» юкмы?

— Юк шул, таба алмадым.

— Алайса мин сезгә аны китерермен. Техниканы баету өчен бик файдалы булачак... Ә хәзер «Туган тел»не тагын бер кат уйнап күрсәтим әле. Әйткәнемчә, миннән күчерү өчен түгел, ә дөрес ишетеп калу өчен... Кай төштә салмак-әкренрәк, кай төштә югарырак-көчлерәк — шуларга игътибар итегез!

...Бөтенләй башка шул!.. Ул уйнаганда көй әйтерсең үзенең иң табигый, иң дөрес яңгырашын таба,— башкача уйнау мөмкин дә түгелдер кебек. Бик ачык, бик төгәл һәм бик җиңел дә шикелле... Һәм аның артыннан ук уйнап карыйсы да килә — бәлки, нәкъ ул уйнаганча чыгарып булыр иде... Хәер, бу үз-үзеңне алдау гына. Чын музыкантны кабатлап буламы соң?! Аның үзеннән остарак кеше дә моны эшли алмас иде. Шулай да мин яңадан игътибар беләнрәк, каушамыйчарак уйнап чыккач, Салих әфәнде үзе дә канәгатьләнеп калгандай булды:

— Менә күрдегезме! — диде ул, минем өчен куангандай.— Дөресрәк тә, төгәлрәк тә уйнадыгыз бу юлы. Димәк, кулың белән уйнаганны күңелең белән ишетергә генә кирәк икән, туташ!

Юатыр өчен генә әйтсә дә, аның бу сүзләре минем рухымны бердән күтәреп җибәрде. Белмим, бүтән эштә ничектер, әмма музыкада аз гына өметләндерү дә гаять әһәмиятле, чөнки музыкага өйрәнүче өчен үз-үзеңә ышану һава шикелле үк кирәк ул.

Әнә шулай узды безнең беренче дәрес. Салих әфәнде, миңа тагын бер мәртәбә «Туган тел»не яхшы гына өйрә-

нергә һәм гомумән күнегүләрне ешрак кабатларга кушып, китәр өчен урыныннан торды.

Әтием дә, урыныннан торып:

— Салих әфәнде, ашыкмагыз әле,— диде.— Хәзер чәй әзерлиләр. Чәй эчеп китәрсез!

— Рәхмәт, Әхмәтҗан абзый! — диде Салих әфәнде, түбәнчелек белән.— Миңа китәргә вакыт.

Әтием яңадан «Юк, чыннан да» дия башлагач, ул кыстамагыз дигән сыман, ике кулын күтәрә төшеп, кабатлап рәхмәтен белдерде дә, миңа борылып башын иде:

— Хушыгыз, туташ! — Һәм җиңел адымнар белән ишеккә таба юнәлде. Әтием аны озата чыкты.

## III

Мин үз бүлмәмә мендем. Кәефем бик әйбәт иде. Бүгенге дәрес, миңа калса, бик уңышлы үтте. Һәрхәлдә, мин канәгать, бик канәгать!..

Салих әфәнденең бөтен әйткәннәрен аңлавы җиңел иде, һәр әйткәне ничектер үзеннән-үзе күңелгә кереп, хәтергә сеңеп бара иде. Миңа мөгамәләсе дә йомшак-игътибарлы иде — бер генә тапкыр да ул борчылуын яки кәефсезләнүен сиздермәде.

Аннары махсус тыңлап утырган әтием дә канәгать калгандыр дип уйлыйм. Салих әфәнде үзен бик әдәпле һәм нәзакәтле тотты ич!.. Әмма юри түгел, ә бик табигый рәвештә — күрәсең, ул үзен шулай тотарга гадәтләнгән инде.

Нәфис кеше!.. Әйе, нәфис, әмма бу нәфислек аның тышкы кыяфәтендә, үз-үзен тотышында гына түгел, эчке дөньясында, табигатендә үк бар булса кирәк — менә шуны сиздем мин бүген... Шул ук вакытта ул үз дәрәҗәсен бик саклый да белә икән. Яшь кенә булса да, әтием белән әнә ничек үзен иркен-тигез тотып, хәтта беркадәр өстенлек тә сиздереп сөйләште.

Минем әнием нәсел тикшерергә бик ярата. Ата-анасы, нәсел-ыруына карап, ул кешеләрне гадәттә «затлыга» һәм «затсызга» бүлеп йөртә. Менә мин дә уйлыйм: бу чибәр егетнең әти-әнисе кемнәр икән, нинди гаиләдә, кем кулында үскән ул?.. Берәр хәзрәтнең мәхдүме, зур байның улы, әллә учитель баласымы? Әмма ләкин байныкы да, хәзрәтнеке дә булмаска тиеш, чөнки әнием моны күптән белеп, миңа ул фәлән купецның яки фәлән хәзрәтнең улы дип әйткән булыр иде. Аннары андый гаиләдән чыккан егетнең гади музыкант булып, театрда эшләп йөрүенә ышануы да читенрәк. Әллә берәр бөлгән морзалар нәсе-

леннән микән?.. Юк, булмас, монысына күңелем бөтенләй ышанмый. Хәер, нигә баш ватарга, ни әһәмияте бар моның?.. Кем баласы гына булмасын, Салих әфәнде дөньяга килгәндә үк чын зат иясе булып туган, минемчә... Кыскасы, мин аңа гаҗәпләнәм, сокланам һәм... сөенәм, ни өчен икәнен үзем дә ачык кына белмәстән сөенәм!..

## IV

Үтә вакыт. Менә өченче... бишенче, алтынчы дәрес тә үтеп китте. Шулай итеп, безнең дәресләребез билгеле бер эзгә төште. Салих әфәнде атнасына ике мәртәбә вакытыннан бер минут та соңга калмыйча килеп җитә, төгәл ике сәгать минем белән шөгыльләнеп утыра һәм, дәрес беткәч, артык бер минут та тормыйча, китеп тә бара. Әтием бер-ике тапкыр аны дәрестән соң чәйгә калырга да кыстап карады, ләкин ул һаман, «вакытым юк, эшем күп» дигән булып, рәхмәтен әйтеп, калудан баш тартты. Әлбәттә, эше күптер инде, чөнки оркестрда уйнау өстенә, артистлар белән бергә төрле җирләргә, бигрәк тә казармаларга барып, шундагы концертларга да катнаша икән, әмма шулай да калмавының чын сәбәбе, минемчә, ул гына булмаска тиеш. Миңа калса, Салих әфәнде үзен килеп-китеп йөрүче бер укытучы итеп кенә санаганга күрә, бездә ашап-эчеп утыруны килештермидер, ә бәлки, теләми дә торгандыр. Чын сәбәбе шул булса кирәк. Хәер, аның урынында булсам, мин дә, бәлки, шулай эшләр идем — кеше үз дәрәҗәсен саклый белергә тиеш ич!

Шулай да без әкренләп бер-беребезгә шактый гына ияләштек дияргә ярый. Дәрес вакытында без үзебезне табигыйрәк һәм гадирәк тота башладык. Мин инде артык каушамыйм, юктан да кызарырга тормыйм, ә ул үзен иркенрәк тә, тәкәллефсезрәк тә хис итә шикелле... Аңардагы бу үзгәреш галәмәтен миңа һич көтмәгәндә генә ачык сизәргә туры килде. Соңгы дәресләрнең берсендә мин, «Салих әфәнде» дип, нидер әйтә башлаган идем, шул чакта ул кисәк кенә мине бүлдерде:

— Туташ, Алла хакы өчен сез миңа «әфәнде» дип дәшмәгез әле.

Шактый катгый рәвештә әйтелгәнлектән, ахрысы, мин моңа гаҗәпләнә калдым:

— Нигә, әллә ярамыймы, әллә тыелган сүзме?

— Юк,— диде ул, көлемсерәп кенә,— тыю турында декрет чыкканы юк әле... Тик мин үзем аны теләмим.

— Ни өчен?

— Сез күрмисезмени? — диде ул, һаман шулай көлем-

серәп.— Мин бит «әфәнде» булырга өлгерә алмыйча калган кеше. Соңрак туганмын лабаса!

Чынлап та, ул дөрес әйтә түгелме соң? Әфәнделәр гадәттә дәү, могтәбәр кешеләр була торганнар иде, ә моңа бит юньләп мыек та чыкмаган әле... Һәм мин үзем дә аңа — яшь кенә егеткә «әфәнде» дип дәшүнең әллә ничек сәер, ят булуын тоя идем кебек. Әмма шул ук вакытта башкача дәшү мөмкин дә түгел иде.

Аз гына аптырап торганнан соң, мин кыюсыз гына сорадым:

— Ә ничек дип дәшәргә соң?

— Хәзер, үзегез дә беләсез, бөтен кешегә дә «иптәш» дип дәшәләр,— диде Салих... Салих әфәнде.— Ләкин мин сезгә, миңа да шулай дәшегез, дип әйтергә җөрьәт итә алмыйм. Әллә ничек килешеп бетмәс кебек, бигрәк тә туташ кешегә. Сез миңа, һич булмаса, «абый» дип дәшә аласыз. Ә «Салих» кына дисәгез, бигрәк тә яхшы.

Дөрестән дә, нигә «абый» дип кенә дәшмәскә? Миннән берничә яшькә олырак ич ул!.. Казан кызлары үзләреннән яшьрәк берәр егетне ошатсалар, аңа да «абыем җаным» диләр әле. Тик менә әтием яратмас дип куркам. Әллә ни уйлавы бар. «Әфәнде» сүзе кешеләрне берберсеннән ераграк тота, ә «абый», киресенчә, якынайта төшә... Юк, мин болай итәрмен: әтием алдында бик эре генә «Салих әфәнде» дип дәшәрмен, икәү генә булганда чын ихластан «Салих абый» диярмен, ә үзем өчен генә ул бары тик «Салих» кына булыр. Бу исем миңа бик ошый, аның үзенә дә бик килешә, шулай булгач, әйдә, «Салих» кына булып калсын ул миңа!

Мактанудан булмасын, безнең укулар хәзергә, шөкер, шактый әйбәт бара. «Туган тел»дән соң мин инде нотага карап, «Хәмдия»не, «Асылъяр»ны, «Ямьле Агыйдел буйлары»н һәм «Галиябану»ны чибәр генә уйнарга өйрәндем. «Галиябану»ны Салих (әфәнде түгел, ә Салих!) аеруча ярата икән. Унсигезенче елның язында «Галиябану» драмасы беренче тапкыр Казанда уйналгач, аның көе халык арасына бик тиз таралды. «Галиябану сылуым-иркәм» дип җырлап йөрмәгән кеше юктыр хәзер... Салих әйтә, әсәрнең уңышын тәэмин иткән, аны яшәткән нәрсә шушы көй, ди. Халык кына тудыра алган шушы көйдә татар кызы белән татар егетенең иң саф, иң пакь, оялчан-инсафлы, әмма бәхетсез мәхәббәтләре искиткеч тирән, күркәм, моңлы булып ачыла, ди. Бер уңайдан ул Галиябану ролендә уйнаган Әшрәф ханым Синаеваны да мактап бетерә алмый. Буе-сыны, тавышы-моңы, нәфислегенечкәлеге белән тере Галиябануның нәкъ үзе ул, ди.

Аннары, Салих җыр-музыканың, ниһаять, сәхнә әсәрләренә керүен бик өметле, бик зур яңалык дип карый икән. Хәзергә әле халык көйләрен файдаланган, ә тора-бара музыкантлар тарафыннан махсус көйләр язылган сәхнә әсәрләре һичшиксез туачак, ди. Бик ышанып, бик рухланып әйтә ул моны!

Безнең дәресләр теге беренче көндәге тәртип белән бара диярлек. Башта Салих миннән элек өйрәнгән көйне уйнатып карый, аннары үзе берәр яңа көйне уйнап күрсәтә һәм шуны миңа нота буенча кат-кат уйнарга куша. Һәр дәрескә көйнең үз кулы белән язган нотасын китерә. Әлеге вәгъдә иткән Черни «Этюдларын» да алып килде ул миңа. Бармакларыгыз тик тормасын өчен мин аны сезгә бүләк итәм, диде. Бик файдалы булып чыкты алар минем өчен...

Ике дәрес арасында инде мин ул күрсәтеп киткән көйне бик әйбәтләп өйрәнергә тырышам, шуның өстенә даими күнегүләр рәвешендә әлеге этюдларны һәм бүтән җиңелрәк пьесаларны әледән-әле кабатлый торам. Кыскасы, безнең Сабира әйтмешли, пианиноны иртән дә дыңгырдатам, кич тә дыңгырдатам. Тик шуңа түзеп, тыңлап утыручы гына юк.

Салих (Салих абыем!) мине дәрес саен диярлек мактый. Юри түгел, юатыр өчен генә түгел, ә чынлап мактый бит, әхри! (Бу да Сабира сүзе.) «Сезнең слух бик әйбәт икән, ди, сез бик тиз отасыз һәм дөрес уйныйсыз, ди, сез, туташ, музыка өчен генә яратылгансыз»,— ди бит хәтта! Мин үзем башта моңа бик үк ышанып та бетмәдем. «Туташ» булганга күрә генә мактый торгандыр әле дип уйладым. Ләкин тора-бара үзем дә сизә башладым: минем уйнавым чынлап та көннән-көн яхшыра, шомара бара иде. Бәлки, бу минем «кабилиятемнән» киләдер, ә бәлки, Салих кебек оста музыкант, чибәр егет өйрәткәнгә күрәдер... Мин бит инде аңа булдыксыз яки ялкау бер кызый-шәкерт кенә булып күренергә һич тә теләмим. (Тәүбә! — әйттем исә кайттым.)

...Әмма Салихның үзе кебек уйнау... юк, бу кадәресе юк әле, юк... Үткән дәрестә ул, дәртләнеп китепме, тоташтан берничә халык көйләрен уйнап күрсәтте: «Хәмдия», «Казан сөлгесе», «Тәфтиләү» — йа Хода, ничек итеп уйнады ул аларны!.. Мин хәтта сихерләнүдән курыккандай аңа туры карарга да кыймыйча, тик эчемнән генә: «Уйнасын... уйнасын, туктый гына күрмәсен»,— дип, бала шикелле теләп кенә утырдым. Бәя бирү минем эшем түгел, кулымнан да килми ул, әмма шуны гына әйтә алам ки, Салих халык көйләрен шундый табигый, шун-

дый йомшак-нәфис итеп уйный менә, әйтерсең ул аларны отып кына алмаган, ә үзе, үз йөрәгендә тудырган... Чын әгәр!.. Һәрхәлдә, бу осталык кына түгел, бу аның халык моңына әверелүе дисәм, бер дә хата булмас. Ләкин, һичшиксез, осталык та бар. Мин инде аның кулларын акчарлак канатына охшаткан идем. Ә менә «Эрбет»не уйнаганда шул ук куллар карлыгач очуын хәтерләтеп җибәрде. Нәкъ карлыгач очкандай, аның куллары тигез-җиңел генә йөзеп китә, кыйгачлап кына бер югары күтәрелә, бер түбән төшә. Әйе, кодрәтле куллар!

Иң ахырдан ул «Тәфтиләү»не уйнады... Әллә көй үзе, әллә аның уйнавы шулкадәр бәгырьгә төшә, шулкадәр җанны ләззәтле газапка дучар итә ки,— моны телдән аңлату һич мөмкин түгел, ишетергә, бары тик ишетергә генә кирәк! Бу көйгә хәзер Тукай сүзләрен җырлыйлар. Тукайның зарын, ачы язмышын...

> Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
> Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

Салих уйнап бетергәч, читтә генә тыңлап утырган этием дә, ир кеше, нык кеше булуына карамастан, тиз генә телгә килә алмыйча торды. Тик бераздан гына карлыга төшкән тавыш белән:

— Рәхмәт, Салих әфәнде! — дип куйды.— Тәмам ереттегез карт күңелне, рәхмәт сезгә!

Салих артына борылмыйча гына башын игәндәй итте, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Мактаганны яратып та бетерми, ахрысы... Һәрхәлдә, аның бу игътибарсызлыгына минем әз генә эчем дә пошып куйды.

Шушы көннән соң Салих минем күңелемне һәм уемны үзенә тагы да ныграк бәйләде. Мин аның турында күп уйланам, ничектер менә бик кирәген, бик чынын гына беләсем килә: кем ул, нинди кеше асылда? Болай бит ул гади бер музыкант кына, мине укытып йөрүче чибәр бер егет кенә, әмма сизәм — акылдан бигрәк йөрәгем белән сизәм: зур бер талант, зур бер кодрәт булырга тиеш аңарда. Уйнавыннан гына түгел, ә бөтен кыяфәтеннән — йөзеннән, күзләреннән, хәтта сүзләреннән сизәм кебек. Мондый камил килеш-килбәтле кеше буш булмаска тиеш, минемчә... Әллә ялгышам микән, Ходаем?..

Әнә шулай уйландыра, борчый, тарта мине Салих «әфәнде»!.. Шул ук вакытта мин аңа шактый гына иялә-шеп тә өлгердем инде. Килгәнен гел көтеп кенә торам. Оятрак булса да яшерә алмыйм — аның янымда утыруын тою, тавышын ишетү, ак-матур кулларын күрү ми-

нем өчен тансык, тансык кына түгел, күңелле-рәхәт!.. Әлбәттә, мин моны үзем генә беләм, Салихның үзенә берәр төрле сиздерү юк, Аллам сакласын!.. Киресенчә, еш кына аның алдында оялам-кызарам да әле мин...

Ә менә Салих үзе миңа ничек карый икән, ни уйлый икән минем турыда?.. Гомумән, нәрсә хис итә икән ул мине күргәндә, минем... янымда утырганда?.. Менә шуны беләсе иде ничек тә!.. Болай бик игътибарлы ул миңа, әдәпле, нәзакәтле, гел «туташ, туташ» дип кенә тора. Ә нииндирәк туташ? — хикмәт менә шунда ич! Бары әдәп йөзеннән (бигрәк тә әтием алдында), телдән генә әйтелә торган «туташ»мы, әллә, булмаса, аның өчен... интересный туташмы? Гаеп итмәгез, бик тә шуны беләсем килә минем!..

Бүген дәрес көне — ул киләсе көн. Иртән күземне ачып җибәргәч тә шул исемә төште. Мин куанычымнан елмайдым һәм... уйландым. Гаҗәп, ул искә төшү белән күңелдә ниндидер бер җыр-моң туган кебек була. Нидән бу, аның музыкант булуыннан киләме, әллә ул үзе музыканы хәтерләтәме?.. Буламы икән соң күңелдә музыка тудырырлык кешеләр?! Аннары бүлмә эче дә бүген, бәйрәм иртәседәй, гадәттәгедән яктырак кебек. Бусы да миңа нигәдер сәер тоелды. Күтәрелебрәк тәрәзәдән карасам, тышта кар яуган икән ләбаса! Беренче кар, тансык кар!.. Менә ни өчен дөнья бердән яктырып та, чистарып та киткән икән! Быел, әйтергә кирәк, караңгы көз нишләптер бик озакка сузылган иде. Ноябрь узды, ә кар һаман төшми дә төшми. Урамнар пычрак, чокыр-чакырларда су, өйләр, коймалар гел юеш... Бик туйдыра, бик күңелсез була икән ул кыш үз вакытында килми торса.

Юк, учлап карамыйча ярамый иде бу беренче карны! Тиз генә түбән төштем дә, иңемә шәл генә салып, аягыма сай галошлар гына эләктереп, ишегалдына чыктым. Сабира болдырдан капкага бара торган юлны көрәп тә куйган икән инде, әмма калган җир ак киез җәйгәндәй чипчиста тора. Бер эз төшмәгән кар өстеннән атлап, мин бакча буена таба киттем. Азрак баргач та иелеп, мамыктай карны ике куллап учыма алдым, кая, нәрсәгә атыйм икән дип, кысып-кысып йомарлый башладым, ә ул, карны әйтәм, укмашмый гына бит! Коры, таралып бара. Димәк, эреми торган кар, китмәскә килгән кар!.. Көне дә шактый салкын икән — мин моны бигрәк тә галошларым аша сизеп алдым. Ә һавасы нинди тагын, һавасы!.. Сулаганда күкрәк үзеннән-үзе киңәеп бара... Әйбәт! Йә, ак кыш, пакь кыш, төкле аякларың белән кил инде, булмаса!

Шул чакта өй ишегеннән әнием кычкырды:

— Гөләндәм, кер тизрәк!

Мин, тәпиләрен өшеткән песи шикелле, сак-сак кына басып өйгә ашыктым. Әнием мине тиргәп каршы алды:

— Шыр тиле, бер кат күлмәктән генә чыгалармыни, салкын тидерсәң соң?!

Ул кадәресен уйлап тормаганмын шул. Хәер, әллә ни өшемәдем дә, берни булмас әле, Алла бирсә!.. Аннары кәефем бик әйбәт ич минем, ә кәефе әйбәт кешегә салкын тимәскә тиеш, әнием бәгырем!

Чәйдән соң озак кына пианинода музицировать итеп утырдым. (Маргарита Яковлевна шулай дип әйтергә ярата торган иде.) Башта, билгеле, Салих өйрәткән көйләрне уйнап чыктым. Ахырдан бармаклар өчен генә, бер дә иренмичә, төрле күнегүләр ясадым. Шактый ялыктыргыч эш, ләкин шунсыз оста уйнаучы булам димә.

Төшке аштан соң мин үз бүлмәмдә китап укыган булып, асылда исә Салих килер вакыт җиткәнне көтеп утырдым. Декабрь көне бик кыска, сәгать өчтән үк инде тәрәзәләргә эңгер-меңгер иңә башлый, ә ул биштә генә килергә тиеш әле. Ничек кенә үткәреп җибәрергә бу вакытны?.. Минутларны санап дигәндәй көтәм, ә үзем килер сәгате якынлаша барган саен тынычсызлана, хәтта дулкынлана да башлыйм. Гаҗәп, һаман әле мин аның белән очрашуга күнегеп җитә алмыйм. Нидән бу?.. Әйткәнемчә, мин бит инде аңа шактый гына ияләштем дә, ул үзе дә минем белән бик гади, бик тыйнак тота үзен, шулай булгач, аның килеп-китүләренә гадәти бер нәрсә итеп кенә карарга кирәк иде. Ләкин юк, карый алмыйм, киресенчә, аны күбрәк күргән саен минем әлеге хәлем (дулкынланып көтүем) көчәя генә бара. Бу мине гаҗәпләндерә дә һәм борчый да. Моның серен аңламыйм һәм аңларга куркам да шикелле.

Сәгать биш тулгач та мин залга төштем, ләкин Салих килмәгән иде әле. Беренче мәртәбә кичегүе... Әтием, унлы лампаның яктысы гына җитмәгәч, тәрәзә төбенә шәм яндырып куеп, үзенең креслосында гәзитә укып утыра иде. Сары кәгазьгә начар гына басылган әллә «Эш», әллә «Эшче» гәзитәсе инде шунда. Хәзерге гәзитәләрне белеп тә бетерә алмассың — үзләре дә, исемнәре дә гел үзгәреп кенә тора. Соңгы ел-ел ярым эчендә аларның ниндиләре генә чыкмады. Күбесе онытылды да инде... Ләкин әтием өчен гәзитә — тылсымлы бер көзге диярсең, кулына төшкән берсен карап-укып бара. Хәер, аның хәзер бүтән эше дә юк. Сәүдәләр бетте, магазиннар ябылды. Доверенный чагында көн-төн чапкан кеше хәзер өендә тик кенә утырырга мәҗбүр... Нишләсен ул?.. Иртәнге якта базар тирәсеннән бер әйләнеп керә инде (базар бар,

базарның беткәне юк), көн саен диярлек өйлә яки ястү намазына кереп чыга (мәчет күршедә генә), ә калган вакытын менә шулай гәзитәләр карап, Салих килгән көнне безне тыңлап үткәрә. Шуны әйтергә кирәк, әтием минем сабыр табигатьле, аз сүзле кеше. Бөтен уе-фикере үз эчендә генә — зарланырга яки уфтанырга бер дә яратмый. Гүя ул сабыр гына нидер көтә, нәрсәгәдер ышанып тора. Шулай ук үзе кебек эшсез калып, базар таптаучылар белән дә артык аралашмый булса кирәк. (Һәм бик дөрес итә, минемчә.) Бердәнбер сөйләшкән кешесе — әнием, әнием белән икәүдән-икәү генә үз бүлмәләрендә кичләрен шыпырт кына сөйләшәләр. Шуңа күрә мин дә бернәрсә дә белмим. Начармы безнең хәлебез, әллә түзәрлекме — һич тә хәбәрем юк. Тормышыбыз искечәрәк бара, элекке кебек мул тормасак та, әллә ни аптырамыйбыз да шикелле... Һәрхәлдә, тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Шулай да вакыт-вакыт минем эчем бик поша, бик беләсем килә: ни көтә безне, ни булыр безгә?! Әниемнән бу хакта сорап та караганым бар, ләкин ул да мине балага санагандай кырт кисеп кенә әйтә:

— Син әнә укуыңны бел, башкасын тикшермә! Берни дә булмас, Алла бирсә!

Әнием шулай дигәч, мин тынычланган кебек тә булам, ләкин күпмегә?.. Заман искиткеч тиз үзгәрә, иртәгә ни буласын мин түгел, чегән хатыны да әйтеп бирә алмас!

...Менә парадный ишектә кыңгырау тавышы ишетелде. Мин хәтта урынымнан кузгала яздым, ләкин нәкъ вакытында тыелып калдым — әтием алдында аны каршы алырга чыгу ярыймы соң?! Сабира, ишетеп, тиз генә ишеккә китте. Ә бераздан, кулларын угалап, залга ул... Салих килеп керде. Суыктан яңаклары да кызара төшкән, күзләре дә гадәттәгедән ныграк елтырый... Өстендә бик ыспай утырган кара тужурка, тужурка астыннан кигән ак күлмәгенең яка чите күренеп тора. Ул әүвәл әтием янына барып, аның белән исәнләште. Әтием, урыныннан торып, аны ачык йөз белән каршы алды. Гадәттәге соравын бирде:

— Йә, Салих әфәнде, кәефләрегез ничек, саулык-сәламәтлек?

— Рәхмәт, Әхмәтҗан абзый, хәзергә зарланырлык түгел.

— Бик хуп. Бирсен Алла!.. Соң, дөньяда ниләр бар?

— Дөньядамы?.. Дөньяда хөррият бар,— диде Салих, елмаеп кына.

— Шөкер, анысын күрдек. Тагын ниләр бар?

— Ә сезгә ни кирәк соң?..

— Миңамы?.. Миңа, мәсәлән, тоз кирәк,— диде этием дә, көлеп.

— Тоз?! Менә анысын миннән сорамагыз инде, Әхмәтҗан абзый. Тоз эзләп йөрергә туры килгәне юк. Хәер, ападан бер ишетеп калган идем: базарда, имеш, чи тиреләрдән селкеп җыйган нафталинлы тоз саталар дип... Дөрестерме-юкмы, ул кадәресен әйтә алмыйм.

— Дөрес, Салих әфәнде... тире складында эшләүчеләр андый тозны да саттылар. Тоз хәзер иң кадерле нигъмәт!

— Ашка ярамыйдыр ич ул?

— Нык кына юып киптерсәң, ярый, диләр. Ләкин аны сатучыларны да тотып япканнар булса кирәк.

— Менә, Әхмәтҗан абзый, дөньяда ниләр барын сез миңа караганда күбрәк беләсез икән.

— Чүп-чарын, Салих әфәнде, вак-төяген генә...

— Зуррагы нәрсә соң?

— Зуррагын сездән ишетәсе килгән иде. Мәсәлән, кайчан бу дөнья үзенең эзенә төшәр икән?

— Ә ул бит нәкъ үз эзеннән бара, Әхмәтҗан абзый,— диде Салих, гүя ваемсыз гына итеп.— Нигә, әллә дөрес түгелме?

Әтием кычкырып көлгән булды:

— Шук кеше сез, Салих әфәнде, яшәве җиңелдер сезгә!

Салихның йөзе шунда ук җитдиләнде, күзләре дә кинәт уйчанланды, ләкин ул артык бер сүз дә әйтмәде. Менә ничә сынаганым бар: этием белән Салихның сөйләшүе гел шулай, ни Аллага, ни муллага дигәндәй, бер нәтиҗәсез бетә дә куя. Башта бу миңа бик сәер тоела иде, борчып та куйгалый иде, ләкин тора-бара аңлагандай булдым: Салих асылда җитди мәсьәләләр турында акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган кеше булса кирәк. Инде сүз чыга калса да, әнә шулай ярым шаяртып, көлкегә әйләндереп бетерергә тырыша. Нидән бу, табигате шундыйга күрәме, әллә яшьлегеннән киләме? Ә бәлки, этием белән зур нәрсәләр турында җәелеп сөйләшүне кирәксез саныйдыр. Ләкин бит этием дә тел бистәсе түгел, бик чамалап кына сөйләшә торган кеше.

Салих минем яныма килде. Баш иеп кенә:

— Кичерегез, туташ, бүген соңгарак калдым,— диде.

— Зарар юк,— дидем мин.

Ул кулы белән генә утырырга ишарә ясады. Пианино каршына икебез дә утыргач, башта:

— Кәефегез ничек? — дип сорады.

— Рәхмәт, начар түгел,— дидем мин.

— Яхшы, алайса... Беләсезме, музыка бит ул бик бәй-

ләнчек нәрсә, кайчак йоклаганда да колактан китмичә йөдәтә.

— Шулай укмыни?

— Ихлас. Минем үзем белән еш кына шулай булгалый. Дөрес, миңа күп уйнарга да туры килә... Хуш, инде башласак та ярый торгандыр.

— Мөмкин... Нәрсәдән? — дидем мин, уйнарга әзерләнеп.

— Элек өйрәнгәннәрне кабатлагыз.

— Кайсын?

— Кайсы да ярый... Кайсысын күңелегез тели.

Әйе, күңел дигәнең төрле чагында музыканың төрлесен тели. Мин «Хәмдия»не уйный башладым. Ләкин Салих мине шунда ук туктатты:

— Сез, туташ, минем өчен уйнамагыз. Үзегез, үз ләззәтегез өчен уйнагыз. Җаныгыз кушканча — иркен, хөр, табигый итеп... Ә мин — юк, мин читтән генә тыңлаучы!

Ул хәтта бер читкәрәк тартылып та утырды. Мин яңадан башладым. Үзем теләгәнчә һәм үзем тойганча итеп. Бер дә тартынмыйча, иркен, табигый итеп... Әмма ләкин барыбер аның тыңлавын сизеп торам — сизмичә мөмкин дә түгел. Тыңлавын гына түгел, миңа төбәлеп карап утыруын да сизеп торам. Хәтта уйнавымны тыңлый-тыңлый минем хакта нидер уйлавын да тоям шикелле... Ул һәрвакытта миңа нидер уйлап карый, нидер уйлап... Баштарак мин аның күксел-зәңгәр күзләренең бу карашыннан бик уңайсызлана идем, ә хәзер юк, хәзер уңайсызланмыйм, киресенчә, шулай каравын телим, шулай караса, миңа рәхәтрәк кебек, йөрәгемә нindидер якты моң тула кебек...

Мин уйнап бетердем. Яхшы уйнадым мин бу юлы. Салих та аз гына дәшми торганнан соң шулай диде, «әйбәт уйнадыгыз, туташ!» диде.

Уйнау да илһам эше. Бер дәртләнгәч, бер, ничек дим, иң кирәк кылын тотып алгач, музыка үзеннән-үзе бик табигый, бик җиңел уйнала. Минем белән дә шулайрак булды — моңарчы өйрәнгән көйләрнең барысын да җиңел-дәртле уйнап чыктым.

Шуннан соң Салих:

— Болай булгач, туташ, без сезнең белән берәр катлаулырак көйне дә өйрәнә алабыз,— диде. Аз гына уйланып торды да: — Рөхсәт итегез әле,— дип, минем урынга күчеп утырды.

— Мин сезгә хәзер «Агыйдел каты ага» көен уйнап күрсәтәм. Ишеткәнегез бардыр, менә ул!..

Уйный башлады һәм әкрен генә сүзләрен дә әйтеп барды:

Агыйделдә йөрсәң иде,
Камыштан көймә үреп,
Былбыл булып, гөлгә кунып
Сөйләшсәң иде күреп.

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә.
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем илә.

Икенче тапкыр сүзләрен әйтмичә генә уйнап чыкты.

— Рәхим итегез! — диде ул, яңадан миңа урынымны биреп.

Мин утыргач, һәрвакыттагыча алдан язып китергән нотасын алдыма ачып куйды. Шуңа карап, кыюсыз гына, әкрен генә уйный башладым. Билгеле, беренче тапкырда рәтле-башлы чыкмый инде ул. Нотага күз ияләшеп җитмәгән, еш кына төртелеп тә каласың, шунлыктан кирәксез пауза да ясала, урынсыз кабатлану да була. Ләкин Салих мондый вакытта бик сабыр тыңлый, ризасызлык-фәлән һич күрсәтми, тик тагын һәм тагын кабатларга гына куша. Уйнаганда миңа бу җирендә андан-те (салмаграк), бу төшендә аллегро (кызурак) дип әйтеп тә тора. Инде эзенә төшә башлагач, менә шулай дөрес, яхшы, дип рухландырып та куя.

Иң ахырдан ул миңа, көлемсерәп кенә:

— Сез бу каты аккан Агыйделне дә җиңел кичәрсез,—диде.— Ләкин...

Һәм менә шуннан соң һич тә көтелмәгән искиткеч бер хәл булды: сүзен әйтеп бетермичә, ул нотаны үзенә тарта төште дә кулындагы карандашы белән ике юл арасына тиз-тиз генә нидер сызгалады. Аннары миңа шуны этәреп:

— Ләкин нотаның менә бу җирләренә аеруча игътибар итегез,— диде.— Күрәсезме?

Башта ук мин ул күрсәткән сызыкларның нота билгеләре булмыйча, язу икәнен ачык күрсәм дә, берничә секунд күзләремә ышанмыйчарак тордым: язу... нинди язу бу?.. Тик шуннан соң гына укый алдым. Юллар арасына: «Миңа сезнең белән сөйләшергә кирәк, кайчан, кайда мин сезне күрә алам?» — дип язылган иде... Моны укыгач, мин шулкадәр аптырап, каушап, югалып калдым ки, кинәт зиһенем таралып, күз алларым томанланып киткәндәй булды. Бер мәлгә хәтта сулыш алудан да туктадым. Ходаем, бу ни бу?! Ничек җөрьәт иткән ул?.. Әтием карап утыра ич!.. Әгәр сизә калса?! Ләкин болай өнсез калу ярамый иде, болай берни әйтә алмыйча утыру

үзе бик хәтәр иде. Әтиемнең мотлака нидер сизүе мөмкин. Шуңа күрә мин нота дәфтәренә иелдем, күз йөрткән булдым, Салихтан хәтта: «Шушы җиреме?» —дип сораган да булдым. «Әйе, әйе, нәкъ шул җире»,—диде ул, кулындагы карандашын миңа биреп... Бу — җавап көтәм дигән сүз иде. Йа Хода!.. Мин тагы да иелә төшеп, «ярый, яхшы, онытмам» дигән булып, тиз генә сызгаладым: «Миңа болай язмагыз, әтием сизәр!»

Ул минем сүзләрне шунда ук укып та барды, ләкин бик тыныч калды. Тик бер иңбашын сәер генә сикертеп куйды. Һәм шунда ук:

— Алайса, туташ, бүгенге дәрес шушының белән тәмам,— диде дә урыныннан торды. Әтием янына барып, берни булмагандай, аның белән сөйләшә башлады.

— Әхмәтҗан абзый, безне тыңлап утыру сезнең өчен күңелсездер инде. Һаман бер үк нәрсәләрне кабатлыйбыз да кабатлыйбыз.

Әтием дә урыныннан торды:

— Алай димәгез, Салих әфәнде! Сезнең дәресләрегез минем өчен дә кызыклы, бик мәмнүн булып тыңлап утырам. Ләкин әйтегезче, шәкертегездән сез канәгатьме?

— Әлбәттә!

Ә мин шул арада бөтен ноталарымны җыеп алдым да мыштым гына залдан чыгып та киттем. Үз бүлмәмә менеп, бераз тын алгач, Салихның язган сүзләрен яңадан укып чыктым. Берничә кат... Аның кулын мин беренче мәртәбә күрәм әле... Саклаганда да ярар иде, ләкин юк, бетерергә, тизрәк бетерергә кирәк! Һәм резинка белән аларның барысын да (үзем язганнарны да) тиз генә чистартып бетердем.

## V

Әйтәсе дә юк, Салихның язганнары минем бөтен җан тынычлыгымны алды. Үземә урын тапмыйм, ни уйларга да белмим һәм торып-торып хәйран калам: моңарчы үзен шулкадәр тыйнак тоткан, һични сиздермәгән укытучым дәрес вакытында миңа әнә ни язды бит! Курыкмыйча, әтиемнең карап утыруына да игътибар итмичә! Нәрсә бу — кыюлыкмы, әллә... юләрлекме?.. Моның минем өчен дә, үзе өчен дә никадәр хәтәр икәнен ул белергә тиеш иде ләбаса!.. Ләкин, күпме генә гаҗәпләнсәм дә, мин аңа үпкәли алмыйм, юк, һич тә үпкәли алмыйм... Мин сизәм, мондый тәвәккәллек өчен җитди сәбәп булырга тиеш, әлбәттә, шулай, уен эш түгел ич бу!.. Дөрес, ул алдан записка язып, шуны безнең Сабира аша тапшыра алган булыр иде. (Сабира бит аңа гел генә ишек ача.)

Ләкин Сабирага да ышанып бетмәгән, күрәсең... Димәк, нотага язудан башка чарасы да калмаган инде.

Әмма иң аптыратканы бу түгел әле. Иң аптыратканы — ул минем белән кайдадыр читтә, аулакта гына сөйләшергә тели! Нигә, ни өчен? Ни әйтмәкче була ул миңа? Бик кирәкле сүзе бар микәнни, Ходаем?! Нәрсә икән соң ул? Шуны уйлап, шуны беләсем килеп күпме баш ватмадым, күпме борчылмадым мин... Хәтта йокыдан калдым, ашау-эчүдән, әнием сизә күрмәсен дип курка да башладым. (Шөкер, эш аңа хәтле барып җитмәде.) Аннары вакыт узып, бераз тынычлана төшкәч, үз-үземә: туктале, җаный, ник син бу хәтле өзгәләнәсең, дидем. Исең киткән икән! Салих укытучым гына түгел, егет кеше дә бит әле. Ә егет кешенең кыз кешегә нәрсә әйтәсе булмас! Мәсәлән, менә минем кебек туташка? Чынлабрак уйлаганда, моны көтәргә дә була иде ич! Ихлас! Аның һәрвакытта миңа үтә игътибарлы булуы, йомшак мөгамәләсе, дәшүләре, ә вакыт-вакыт уйчан-серле генә карап та куюлары — болар барысы да нидер аңлата иде түгелме соң?! Ә бәлки әле, аның күңелендә миңа карата үзенә бер төрле хис тә яшидер яки уяна башлагандыр. Мин моны, һәрбер кыз шикелле, үз теләгемнән, үз өметләремнән чыгып кына әйтмим — мин егет кешенең йөрәк тибешен күңелем белән сизенеп әйтәм. Бик ихтимал, Салих та минем йөрәк тибешен сизгәндер... Ике якта да туган шушы сизенүләр... мәхәббәтнең беренче яралгысы, беренче чаткысы түгелме соң? Шулай башлана шикелле, Ходаем, шулай башлана шикелле...

Ләкин... җитәр бу турыда, җитәр! Мин, тиле, һәрвакыт шулай бик тирән керә башлыйм. Ярамый болай. Әниләр әйтмешли, киләчәккә тапшырыйк. Безнең очрашачак көннәребез күп ич әле!

Тик күңелемдә бер генә төер калды: мин үземнең җавабым белән аның кәефен бозмадым микән? Ни уйлады икән ул?.. Хәер, монысын да киләчәккә калдырыйк, иң якын киләчәккә!

## VI

Бу килүендә дә ул һәрвакыттагыча җыйнак һәм пөхтә иде. Әмма бөтен ягы да килгән кешенең дә аеруча күзгә ташлана торган берәр нәрсәсе була икән. Салихта исә бу —аның күзләре һәм бик чиста ак маңгае... Ишектән килеп керүенә иң элек менә шул ак маңгае белән урман күледәй зәңгәр күзләре минем игътибарымны биләп ала иде. Шуннан соң гына мин аның башка якларын да күрә башлыйм.

Бу юлы мин аны шактый хәвефләнеп, эчке бер борчылу белән каршы алдым, билгеле. Ни дияр ул миңа, ничегрәк итеп карар, үпкәсен сиздерерме-юкмы? Ләкин аның кәефен чамалау бик читен иде. Гадәттәгечә ул үзен бик тигез, бик тыныч тота. Эчендәгесен һич сиздерми. Күрәсең, табигате шундыйдыр инде, көләр, көлдерер, әмма бервакытта да караңгы чырай күрсәтмәс.

Дәресне башлар алдыннан ул миңа беренче мәртәбә, туташ димичә, исемем белән дәште:

— Гөләндәм, утырыгыз! — диде.

Бик гади генә, шәкертенә дәшкән төсле генә итеп әйтте ул моны, ә шулай да минем өчен бу бәлзәм йоттырган шикелле булды. Димәк, миңа үпкәсе юк! Үпкәсе булса, бик әдәп белән, әмма коры гына итеп «туташ» дияр иде. Һәрхәлдә, нәкъ менә бүген беренче мәртәбә исемем белән дәшмәс иде.

Әйтергә кирәк, безнең бүгенге дәрес тә гадәттәгедән башкачарак үтте. Салих миңа яңа көй өйрәтеп тормады, (ахрысы, язып китергән нотасы булмагандыр), ә искеләрне кабатлау белән генә чикләнде. Мин аларның барысын да уйнап чыктым. Ул бер сүз дәшмичә тыңлап утырды, соңыннан төзәтү-мазар да ясамады, тик иң ахырдан сәер генә бер сорау бирде:

— Әйтегез әле, уйнаган чакта сез ни күрәсез?

Мин аптырап калдым: ни ишетәсез түгел, ә ни күрәсез?! Ул аңлатырга тырышты:

— Менә сез «Агыйдел»не уйнадыгыз. Шул чакта сезнең күз алдыгызга берәр төрле күренеш килмәдеме?

— Юк шикелле... Ә нәрсә килергә мөмкин?

— Мәсәлән, ярларына сыя алмагандай бөтерелеп, кызу гына аккан Идел үзе... Аргы якта, киң тугайда, киез эшләпә кигән агайлар тезелешеп печән чабалар... Ә бирге якта, су читендә ап-ак казлар канат кагына.

Бу шулкадәр сәер-кызык булып тоелды — мин хәтта көлеп җибәрдем.

— Ни өчен казлар, ни өчен кер чайкаучы кызлар түгел?

— Бу да бик табигый,— диде ул, җанланып.— Һәрхәлдә, шул көй тәэсирендә күз алдыгызга ни дә булса килергә тиеш иде.

— Алай икән!.. Ә сезгә киләме соң?

— Һәрвакытта! Нинди генә көйне уйнамыйм яки тыңламыйм, шунда ук минем хыялымда берәр күренеш тумыйча калмый. Мисал өчен, «Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем» дигән гади генә авыл көен алыйк. Менә шул көйне ишеттем исә, минем күз алдыма гел генә гаҗәеп бер күренеш

килә: авыл, кояш баеп барган вакыт, көтү кайткан, сөт исе аңкый, кызлар, яшь киленнәр ак чиләкләренә тыныч кына күшәп торган сыерларын савалар. Ә шул чакта ындыр артыннан бер егет, йөгәнен иңенә салып, авыз эченнән генә әлеге «Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем» не көйләп, батып барган кояшка карап, кайдадыр утлап йөргән атын эзләп китеп бара... Менә нинди күренеш!

— Кызык! — дидем мин дә, гаҗәпләнеп.— Бик җанлы күренеш, әллә үзегез уйлап чыгарасызмы?

— Юк, туташ, бу — музыканың бер кодрәте! — диде Салих, җитди генә.— Уй-хисләрне генә түгел, хыялларны да уята ул! — Аннары аз гына уйланып өстәде: — Миңа калса, композиторлар да музыка язган чакта аны ишетеп кенә калмыйча, әнә шулай күрә дә торганнардыр.

Шунда ук минем күңелгә «ә сез кайдан беләсез?» дигән сорау килде, ләкин мин аны әйтеп тормадым, билгеле. Йә хәтерен калдырырмын... Ул бит үзе дә чын музыкант, аның шулай уйлавы гаҗәпмени?!

Әтиемә дә кызык тоелды, ахрысы — ул да сүзгә кушылды:

— Салих әфәнде, сез тасвир иткән гүзәл манзара кайчандыр күргәнне искә төшерү генә түгелме соң?

— Дөрес, музыка беренче нәүбәттә нәрсәнедер искә төшерә, күз алдына китерә, сагындыра, әмма аның, ягъни музыканың, тәэсире моның белән генә чикләнми: ул һич күрмәгән-белмәгән җирләрне, илләрне, кешеләрне дә хыялда тудыра. Мәсәлән, сезнең казакъ даласында йөргәнегез бармы?

— Юк, Салих әфәнде, туры килгәне юк.

— Минем дә әле күргәнем юк. Ләкин Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укучы казакъ шәкерте моңаеп, үзенең җырын суза башласа, минем күз алдыма шунда ук казакъның чиксез даласы, ак тирмәләре, сибелеп, көтү-көтү йөргән җылкылары килә да баса! Мин хәтта шул җылкыларның җил каерган озын ялларын да күргәндәй булам. Ышанасызмы?

— Ышанам, Салих әфәнде! Була андый хәл, була!

— Мин моның бик күп мисалларын китерә алыр идем, ләкин җитеп торыр хәзергә,— диде Салих һәм, тынып, нидер уйланып калды.

Аның үз кәефе дә бүген сәер генә иде. Нәрсәдер җитмиме аңа, нидер борчыймы аны, һәрхәлдә, күңеле-хыялы белән каядыр читтә, еракта йөри иде кебек.

Шулай тынып, уйланып торганнан соң, ул миңа Шопенны уйнарга кушты.

— Нәрсәсен? — дип сорадым мин.

— Берәр җиңелрәген. Мәсәлән, прелюдияләреннән берәрсен! — диде ул.

Ноталар арасыннан Шопенны табып, шуннан бер прелюдияне ашыкмыйча гына уйный башладым. Ул башын игән килеш кенә тыңлап утырды. Үземә калса, әйбәт кенә уйнап чыктым. Ә ул, музыка тәмам тынгач кына исенә килгәндәй, тирән сулап әйтеп куйды:

— Әнә нинди бит ул!.. Гүзәл, нәфис, әйтерсең йөрәкне ефәккә урый!.. Юк, сезгә болардан һич тә аерылырга ярамый. Уйнагыз сез аларны, күбрәк уйнагыз! Шунсыз чын музыкант булу мөмкин дә түгел, туташ!

Әтием тагын үз сүзен кыстырды:

— Ә шулай да үзебезнеке җанга якынрак бит, Салих әфәнде!

— Әлбәттә, яхшымы-начармы, үзебезнеке безгә ана сөте белән кергән, Әхмәтҗан абзый! Безнең бөтен моңыбыз, дәртебез, юанычыбыз халык көйләрендә. Әмма ләкин дөньяда музыка дигән бер бик борынгы, бик бай сәнгать тә бар бит әле. Менә шул сәнгатьтән без дә азыкланырга тиешбездер инде. Югыйсә «Әчтүч-Бибкәй кыз»дан ерак китә алмабыз. Шулай бит, Гөләндәм?

Ул, әз генә көлемсерәп, миңа сынаган да, якын да иткән төсле итеп карады. Мин ирексездән кызардым, шулай да дәшми калмадым:

— Әйе, Салих әфәнде, мин сезнең белән килешәм,— дидем.

Болай чынлап уйлаганда, аның шулай соравы, минем шулай дип җавап бирүем бик табигый иде һәм бик урынлы да. Ләкин шуңа карамастан мин үземнән бер дә канәгать түгел идем. Әдәп кагыйдәсен саклыйм дигән булып, һаман үземне ясалма рәвештә тотарга мәҗбүрмен. («Әфәнде» имеш, «килешәм» имеш,— харап инде!)

Ләкин әтием алдында бүтәнчә булдыра да алмыйм. Ә Салих, билгеле, моны сизә, сизү генә түгел, эченнән, бәлки, көлә дә торгандыр әле. Үзе ул, әдәп кагыйдәсеннән һич чыкмаса да, безнең араны ничек тә гадиләштерергә тырыша кебек. Бүген исә шул нәрсә аның кыланышында аеруча нык сизелә иде. Менә хәзер дә ул миңа, тик торганнан нидер исенә төшкәндәй:

— Сез, Гөләндәм, җырлый да белә торгансыздыр әле? —диде.

Йә, мин ни дип җавап бирергә тиеш инде? Әгәр аның бу сүзендә аз гына көлү яки үртәү кебек нәрсә сизсәм, минем җавабым да бик кыска булыр иде. Ләкин ул моны бер дә шик кузгатмаслык итеп әйтте. Шуңа күрә мин дә сорау белән генә чикләндем:

— Ни өчен алай дип уйлыйсыз?

— Музыкант кеше үзе өчен генә булса да җырларга тиеш,— диде ул.

Ләкин минем, җырлый беләм, дияргә һич тә исәбем юк иде. Нигә кирәк әле бу? Безнең дәрескә аның ни мөнәсәбәте бар?.. Ләкин әтиемнең минем белән мактанасы килде, ахрысы.

— Дөрес әйтәсез, Салих әфәнде,— диде ул, вәкарьлеген саклап кына.— Безнең Гөләндәмне Ходай тавыштан да мәхрүм итмәгән. Чибәр генә җырлый ул!

Моны ишеткәч, Салих бөтенләй дәртләнеп китте.

— Ышанам, ышанам! Ягез әле, туташ, без әфәндегезгә дә бер җырлап күрсәтегез, булмаса!

Билгеле, минем әтиемә ачуым килде, шулай ук Салихның соңгы сүзләре дә күңелемә бер дә ошамады.

— Мин җырчы түгел,— дидем, шактый киреләнеп.— Минем чит кеше алдында бервакытта да җырлаганым юк!

— Ә мин чит кеше түгел ич! Хәлфәгез! — диде Салих, ничектер ваемсыз-хәйләкәр генә итеп.

— Ләкин бит сез мине җырчылыкка өйрәтмисез!

— Ә бәлки, өйрәтермен дә... Мин бит сизәм — сез җырлый алырга тиешсез! Ягез әле, ягез!

— Зинһар, кыстамагыз! — дидем мин, ялварып.— Булмый, җырлый алмыйм.

— Менә мин сезгә аккомпанировать итим әле,— диде ул, минем ялваруыма һич тә игътибар итмичә, һәм пианино каршысына күчебрәк утырды.— Сез ашыкмагыз, уйлагыз... Иң элек теләгән көегезне искә төшерик.

Ләкин минем һаман әле карышасым килә. Җырлый алуыма ышансам да, карышасым килә. Шул ук вакытта артык тискәреләнүдән дә куркам — аның кәефен бозмыйм да гайрәтен чигермим дип куркам. Шулай да икеләнә төшебрәк мин:

— Башка вакытка калдырыйк,— дидем.— Бүген әллә ничек, кәефем юграк.

Салих башын борып, бик туры итеп минем күзләремә карады. «Мин сораганга күрә генә җырлыйсыгыз килми, шулаймы?» дия иде аның кинәт җитдиләнеп киткән күзләре. Тәмам какшатты мине аның бу карашы... Җитмәсә, әтием дә әйтеп куйды:

— Кызым, йә, йә, кыстатма!

Ахырда мин әкрен генә урынымнан торып бастым. Салих исә яңадан уйнарга җыенды һәм берни дә булмагандай йомшак кына сорады:

— Нәрсәне телисез?.. Бәлки, «Сибелә чәчәк»не җырларсыз?

— Авыр булмас микән?

— Карагыз!.. Әмма хатын-кыз тавышына бик туры

килә ул. Исеме үк җыр бит! Сибелә чәчәк!.. Чәчәкләрнең җилдән сибелгәнен күргәнегез бармы?

— Бар, әлбәттә... Безнең бакчадагы чияләрнең чәчәкләре җиргә ап-ак кар шикелле ява торган иде.

— Минем дә күргәнем бар, тәңкә-тәңкә булып яталар, иеме? Ләкин бу җырда гөлчәчәкләрнең җилдән сибелүе турында әйтелә. Бичара чәчәкләр!.. Ярый, башлап карыйк, булмаса!

...Бармакларын җиңел генә клавишларга тидерде һәм беренче аккордтан соң ук инде «Сибелә чәчәк» минем колагымда гына түгел, күңелемдә дә яңгырый башлады. Җырлыйм, әлбәттә, җырлыйм! Сүзләре дә тел очымда гына тора, тик аның бер тапкыр уйнап чыкканын гына көтәм.

Уйнап бетергәч, ул миннән: «Шулай ярыймы?» — дип сорады. Мин баш кына кактым. Ул яңадан башлады, мин, тирән генә бер тын алып, аңа иярдем... Минем җырым бу, җанымны сызландырган моңлы, ләззәтле җырым!

Гөлбакчага керәмсең,
Гөлбакчага керәмсең лә,
Гөл чәчәген өзәмсең?
Өзелгән гөл чәчәге күк
Аерылуны сизәмсең?
Сибелә чәчәк җилләр лә искәндә,
Өзелә үзәк исләремә төшкәндә.

Бу хәтле дә оста аккомпанировать итәр икән Салих абый! Әйтерсең канатлар өстендә генә күтәреп илтә. Шул ук вакытта ник бер генә тапкыр минем тавышымны басып китсен! Җырның бик сузылган җирендә тынып торган кебек тә була, ләкин нәкъ кирәк чакта гына тагын күтәреп ала.

Мин, үземә калса, тигез-җиңел генә җырлап чыктым. Әмма матур-моңлымы? — бу кадәресен инде миннән сорамагыз. Хөкемне ул чыгарырга тиеш. Кыстап-кыстап җырлатты ич, тик ни әйтсә дә, турысын гына әйтсен иде! Ләкин ул ни өчендер ашыкмый иде әле. Җыр тынгач, күпмедер вакыт алдына гына карап, нидер уйланып торды, аннары ашыкмыйча гына миңа таба борылды, яңа күргәндәй, сәер генә бер карап куйды, бары шуннан соң гына елмаеп, бик гади генә итеп:

— Курыккан идегез, менә җырладыгыз бит! — диде.

«Шул гынамы?» дип уйладым мин, пошынып, ләкин ашыга төшкәнмен икән. Аз гына көттереп, ул, ниһаять, әйтте:

— Тавышыгыз, безнеңчә әйтсәк, сопрано, дөресрәге, лирик сопрано икән. Матур тавыш. Тембры да йомшак, чиста... Ләкин иң әһәмиятлесе, туташ, сез көйне нечкә хис итеп, тәмен белеп дигәндәй җырлыйсыз. Мактау йөзеннән түгел, ә чын дөресен әйтәм.

— Рәхмәт! — дидем мин, дулкынлануымны сиздермәскә тырышып.

— Тагын берәрне җырламыйсызмы?

— Юк,— дидем мин, ашыгып.

Күрәсең, аңардан шундый мактауны ишеткәч, яңадан җырлап күрсәтергә курыкканмындыр инде. Була икән мондый хәл дә! Ләкин ничектер акланырга кирәк иде. Әзрәк хәйләгә керешеп:

— Сез кичерегез инде,— дидем,— бүген минем барасы җирем бар, ашыгам, башка вакытка калдырыйк. (Хәер, дөрестән дә, туган апаларга барып кайтырга кирәк иде миңа.)

— Яхшы алайса! — диде Салих.— Ләкин беләсезме, туташ, сезне иркенрәк урында, мәсәлән, сәхнәдән җырлатып караганда да зарар итмәс иде. Ничек уйлыйсыз?

Мин куркуымнан бары:

— Ни сөйлисез?! — дип кенә алдым.

Әтием дә, бик гаҗәпләнгән булып:

— Сез безнең кызыбызны әллә җырчы да итмәкче буласыз инде, Салих әфәнде? — диде.

— Нигә, Әхмәтҗан абзый,— диде Салих, бик тыныч кына,— җырчы булу гаеп эшмени?.. Ходай биргән талант ич ул! Сез үзегез дә туташның чибәр генә җырлавын әйтеп тордыгыз бит әле.

— Анысы болай гына, сезнең өчен генә... Иллә мәгәр Гөләндәмнең кайдадыр, кемнәрдер алдына чыгып җырлавы асла килешә торган эш түгел. Безнең мөселман ни... әдәбенә һич сыймый ул!

— Ник сыймасын! — диде Салих, ваемсыз гына.— Мөслимәләр дәртләнеп җырлый, мөселманнар рәхәтләнеп тыңлый — бик табигый нәрсәгә әйләнде бит инде бу хәзер!

— Нинди мөслимәләр? Кайда?.. Ә, сез әртисткәләрне әйтәсез! Шулай диегез, мөслимәләр, димәгез. Бу — икенче мәсьәлә. Аларның кәсепләре шул... Кәсеп ул тамак туйдырыр өчен, ә Гөләндәмгә андый кәсепнең кирәге булмаячак, Алла боерган булса! Гаиләдә уйнарлык кына музыка белсә, аңа шул җиткән. Сез инде, Салих әфәнде, аны шуңа гына өйрәтегез! — дип бетерде ул сүзен, ничектер ялварган шикеллерәк итеп.

Салих ни өчендер җавап биреп тормады, ә яңадан пианинога борылды да, канатларын җәйгәндәй, кинәт кенә дәртләнеп уйнап та җибәрде. Попурри тезгәндәй бер көйдән икенчесенә, өченчесенә күчеп, төрле вариацияләр ясап, бик кызу уйнады ул... Бездә аның болай уйнавы беренче тапкыр иде әле. Бу мине шактый гаҗәпләндерде дә һәм әзрәк кенә борчылырга да мәҗбүр итте. Гүя

этиемнең сүзләренә каршы ниндидер бер яшерен ният белән уйнаган төслерәк тоелды миңа... Чыннан да, ул кисәк кенә уйнап бетерде дә әтиемнән кычкыра биреп сорады:

— Әйтегез әле, Әхмәтҗан абзый, Гөләндәм туташ менә шулайрак уйнаса, сез канәгать булырсызмы?

— Бу хәтле үк булмаса да, без канәгать,— диде әтием, көлеп.

— Ә уздырып җибәрсә?

— Һем, һем, анысына да каршы түгелбез.

— Менә мин дә Гөләндәм туташка шуны телим! — диде Салих, бу сүзләренә ниндидер бүтән бер мәгънә дә салгандай итеп.

Аннары ул урыныннан торды, пианино капкачын сак кына ябып куйды. Һәм миңа аеруча түбәнчелек белән башын иеп:

— Туташ, сезнең барасы җирегез дә булгач, мин вакытыгызны артык алырга җөрьәт итә алмыйм,— диде.

Әтием дә аны озатыр өчен креслосыннан торды. Хәер, мин аның бездән кайчан чыгып киткәнен күрмәдем. Гадәттәгечә, залдан иң элек үзем чыгып киттем. Башта бу шулай кирәк кебек иде (бигрәк тә әтием өчен), ә хәзер моның килешмәгәнен, ясалма бер әдәп кагыйдәсе икәнлеген сизә башладым. Ни өчен мин аны озатып калмаска тиеш? Кыргыйлык ич бу, билләһи.

Бер ярты сәгатьтән соң киенеп, урамга чыксам, Салих безнең тыкрык башында әрле-бирле йөренеп тора! Өстендә озын чабулы кара пальто, башында каракүл бүрек. Күрү белән таныдым, ләкин ни өчендер «Улмы соң?» дип уйлап та алдым, гаҗәпләндем, хәтта каушадым, әмма ихтыярсыздан куандым да.

Мине күрүгә ашыгып каршыма килде, елмая төшеп:

— Көтмәгән идегезме? — диде.

Мин зиһенемне җыеп җавап биргәнче, ул, янәшәмнән атлый-атлый, сүзен кызу гына дәвам иттерде:

— Сез минем белән очрашырга теләмәсәгез дә, мин менә әрсезләнеп сезне көтеп алдым. Кәефегез кырылмасын, туташ!..

— Салих абый, зинһар, мине дөрес аңлагыз! — дидем мин, ашыгып.— Һич тә теләмәүдән түгел, тик әтием сизә күрмәсен дип курыктым мин...

— Әтиегез өчен мин бары сөекле кызына музыкадан дәрес бирүче генә шул,— диде ул, көрсенеп.— Югыйсә өенә аяк та бастырмас иде.

— Алай әйтә күрмәгез! — дидем мин, ялварып.— Әтием дә сезне хөрмәт итә, ышаныгыз!

— Хуш, ышаныйк та ди... Ул чагында мин сезнең

аңардан бу хәтле... куркуыгызны аңлап җитә алмыйм, Гөләндәм!..

— Ләкин сез беләсез ич, әтием минем иске фикердәге кеше, ә мин кыз бала, үзегез дә аңларга тиешсез.

Салих кинәт кенә көлеп куйды:

— Шулай шул... Мин — бүре, ә сез — бәрән, минә ашый күрмәсен дип саклап утыра да инде ул!

— Юкка көләсез, Салих абый, юкка! — дидем мин, елардай булып.

Салих, шунда ук җитдиләнеп:

— Кичерегез! — диде.— Сездән көләргә һич тә уйлаганым юк, мөмкинме соң? Тик сез үзегез бит, әтиемнән куркам, дисез — шуңа гаҗәпләнәм мин.

— Әйе, куркам, әмма үзем өчен түгел, сезнең өчен! — дидем мин, яшь тулы күзләрем белән аңа карап.— Сезне югалтырмын дип куркам, аңлыйсызмы?!

Салих бер мәлгә тып-тын булып калды, хәтта адымнарын әкренәйтә төште. Ә мин эчемнән генә: «Ходаем, ничек әйттем мин моны? Ничек әйттем?!» — дия-дия, һаман кызу гына атлый бирдем... Бераздан аның йомшак кына дәшкәнен ишеттем:

— Гөләндәм, ашыкмагыз!

Мин әкренрәк атладым. Ул килеп җитте дә беләгемнән кысып тотты, ләкин шунда ук кире җибәрде.

— Рәхмәт! — диде ул, дулкынлануыннан, ахрысы, пышылдап кына.— Рәхмәт, Гөләндәм!.. Әллә ничек минә күзләрем кинәт ачылып киткәндәй булды. Беләсезме, миндә дә бары шул теләк бит: сезне бер дә югалтасым килми. Сез бик сәләтле кыз, Гөләндәм, сез музыка өчен яратылгансыз. Сезне очратуыма мин бик шатмын...

Ул аз гына тынып торды, тирән итеп бер сулыш алды, аннары яңадан башлады:

— Шулай да минем сезгә әйтәсе сүзем бар, Гөләндәм! Музыка дәресе белән бәйләнмәгән сүзем бар, шуның өчен генә мин нота кәгазенә «очрашыйк» дип язарга да мәҗбүр булдым. Ләкин сез борчылмагыз, хәтәр сүз түгел ул.

— Мин тыңлыйм!

— Ә сүзем шул,— диде Салих, ашыккандай кызу гына,— сезгә дөньяга чыгарга кирәк, Гөләндәм, аңлыйсызмы, дөньяга чыгарга! Бу бик мөһим... Югыйсә сезгә килгән саен мин бер нәрсәгә гаҗәпләнәм: сез беркая да чыкмыйсыз, читлектәге кенәри шикелле, гел бүлмәгездә бикләнеп утырасыз... Нәрсә бу, ни өчен?.. Тыяламы, рөхсәт итмиләрме?

— Әтием әйтә, хәзер куркыныч вакыт, ди...

— Һич тә дөрес түгел!.. Киресенчә, бик кызыклы вакыт! Дөнья шау-гөр килеп тора — ишетмисезмени? Ә төрле

коточыргыч сүзләргә килгәндә, ышанмагыз, бик күбесен арттырып сөйлиләр. Совет власте шәһәрдә тәртип урнаштырды инде, менә йөрибез — берни дә булганы юк. Кичләрен мин үзем сезне каршы алырмын, үзем озатып куярмын, тыныч булыгыз! Ә чыгарга кирәк, театрларга, концертларга йөрергә кирәк. Сез — булачак музыкант, барысын да күрергә, ишетергә тиешсез. Мин сезне әдипләр, артистлар, музыкантлар белән таныштырырмын... Менә күрерсез, үзегезне канатлар үскәндәй хис итә башларсыз. Сәнгать ул хөрлек ярата, хөр кеше генә аның бусагасыннан атлап керә ала. Югыйсә нәрсә бу, хорафатлар җимерелгән бер заманда бикләнеп яту? Юк, ярамый, акыллым, бигрәк тә сезгә ярамый!

Салихның бу әйткәннәре миңа, билгеле, нык тәэсир итте. Әмма шушы зур, мөһим сүзләр арасыннан берсе минем колагыма аеруча ныграк кереп калды: «акыллым» диде бит ул миңа!.. Һәм шушы бер сүзе белән ул мине үзенә ничектер тагы да якынайта төшкәндәй итте.

— Сез хаклы,— дидем мин, тиз генә килешеп,— сез бик хаклы, Салих абый!.. Үзем дә сизәм — дөньяга, кешеләр арасына чыгарга кирәк, барысын да күрергә, белергә кирәк. Сез, хөррият заманы, дисез — моны кем генә тоймый икән? Җиде кат стена аша да үтеп керә бит ул!.. Ләкин мин бикләнеп ятучы түгел, мине бикләп куйган кеше дә юк. Без элек чыга идек, әнием белән «Сәйяр» спектакльләренә бара торган идек. Тик хәзер генә тыелдык. Дөнья бик буталып китте бит. Шәһәрдә атышлар, үтерешләр дә булды. Әле аклар, әле чехлар, әле кызыллар — кем баш икәнен дә белмәссең. Менә безнекеләр мондый чакта чыгып, күренеп йөрүдән бик саклыналар. Бигрәк тә әтием минем өчен курка, урамда эт-кош күбәйде, ди... Минем тыңламыйча хәлем юк, шуңа күрә менә «бикләнеп» утырам да инде.

Без Кабан буе урамының башына җитеп туктаган идек. Аңа «Шәрык» клубына, ә миңа Мещанскийга таба китәргә кирәк иде.

— Әлбәттә, әти-әнине тыңламыйча ярамый,— диде Салих, уйчан гына.— Ләкин аларның котын алган бик буталчык, куркыныч вакытлар үтте бит инде. Казан тирәсендә хәзер аклар да юк, чехлар да юк, кызыллар гына баш. Ә алар тәртипне саклый беләләр, җыен эт-кошка селкенергә дә ирек бирмиләр. Аннары, әти-әниләрнең үз исәпләре, үз кайгылары, ә безнең үз теләгебез, үз максатларыбыз — электән үк ул шулай килгән инде. Кыскасы, Гөләндәм, мин сезне башлап бер спектакльгә чакырмакчы идем.

— Нинди спектакльгә?

— «Соңгы сәлам»гә. Кәрим абыйның бу әсәре былтыр

бер куелган иде инде, быел менә яңадан уйнала. Килерсез бит?

— Рәхмәт, Салих абый!.. Ләкин белмим шул.

— «Белмим» түгел, киләсез! Әгәр теләсәгез, мин үзем Әхмәтҗан абзыйдан рөхсәтне сорармын.

— Юк, юк,— дидем мин, ашыгып.— Ярамый. Мин әнием белән генә сөйләшермен.

— Бигрәк тә яхшы!.. Көнен мин сезгә алдан хәбәр итәрмен. Исән-имин әниегезгә кайтарып тапшыруны да үз өстемә алам, ләкин килмичә калмыйсыз, ишетәсезме?

— Мөмкин булса,— дидем мин, икеләнеберәк.

— Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, туташ! —диде ул, көлеп.— Шулай да безнең бүгенге сөйләшү әйбәт булды әле, һәрхәлдә, минем өчен.

— Минем өчен дә,— дидем мин, кыюланып.

— Шулаймы? — диде ул, ничектер яктырып.— Мин бик шат!.. Тик ешрак, ешрак булсын иде безнең хөр сөйләшүләр...

Мин дәшмәдем. Ул миңа кулын сузды.

— Ә хәзергә сау булып торыгыз!

Мин перчаткамны салмыйча гына кулымны бирдем. Бу безнең беренче тапкыр кул бирешүебез иде. Җыйнак, нәфис кулының шактый нык-көчле булуын сиздем.

— Ә беләсезме,— диде ул, минем кулымны җибәрмичәрәк торып,— сезнең исемегезне үзгәртеп була икән ләбаса!

— Ничек итеп?

— Гөлгенәм! Гөләндәм урынына — Гөлгенәм!

— Зинһар, алай әйтә күрмәгез! — дидем мин, ут капкандай кызарып.

— Сезнең үзегездән башка моны берәү дә ишетмәс,— диде ул, серле генә итеп.

Мин, оялуымнан ни әйтергә белмичә, башымны идем дә тиз-тиз генә китеп тә бардым.

## VII

Юк, килешмәде әле бу, качкан шикеллерәк килеп чыкты. Әмма башкача мөмкин идемени соң? Берәү күзләремә карап миңа «Гөлгенәм!» дисен дә, мин шуңа авыз ерып, тагын нидер көтеп торыйм, имеш! Әлбәттә, мин китәргә, шунда ук китәргә тиеш идем. Үпкәләп, ачуланып түгел, һич юк, ә артык көтелмәгән, артык серле-сихри сүз ишетүдән... Мондый сүзне тыныч кына кабул итеп буламы соң?! Салих үзе дә аңлагандыр, аңларга тиеш!

Аңардан шулай аерылып киткәч, мин әле туган апаларыма да туры гына барып кермәдем. Урамнан урамга

күчеп, озак кына йөрдем әле мин... Тынычланырга, йөрәкне урынына куярга, уйларны әзрәк кенә булса да тәртипкә китерергә кирәк иде миңа... Салих белән беренче мәртәбә сөйләшүебез ич бу — ике ай пианино янында янәшә утырганнан соң, беренче мәртәбә икәүдән-икәү генә туры килеп сөйләшүебез!.. Ә сөйләшү үзе, миңа калса, шактый кызыклы, мәгънәле булды шикелле. Бигрәк тә Салихның әйткәннәре... Инде менә уйлыйм: ул әйткәннәрнең кайсы дөрес, кайсысы чын күңелдән, кайсысы минем өчен әһәмиятлерәк? Боларны әле хәзер генә аерып, белеп бетерүе дә бик читен. Һәрхәлдә, иң мөһиме — аның миңа әйткән назлы сүзләрендә түгелдер инде, назлау сүзен туташ кешегә комплимент итеп тә әйтергә була. (Гәрчә комплимент та юктан гына әйтелми, ул да нидер аңлатырга тиеш...) Иң мөһиме — Салихның минем өчен борчылуында, кайгыртуында, мине зуррак, иркенрәк дөньяга чакыруында булса кирәк. Ә бу инде кечкенә мәсьәлә түгел.

Әмма минем өчен тагы да мөһимрәге — ул да булса шушы көтелмәгән сөйләшү безне бер-беребезгә ничектер бәйли төште, безнең арада ниндидер бер уртак нәрсә тудырган кебек булды. Моннан соң инде без бары укытучы һәм укучы гына булып калмабыз шикелле... Һәм бу хәл миңа тынычлык бирми, юк, бирми, нәрсәдер менә сагаеп көтәргә мәҗбүр итә... Теләп һәм куркып көтәргә!

## VIII

Мин, ничек кенә булса да «Соңгы сәлам»гә барырга дип, үземә сүз биреп куйдым. Бер килүендә Салих миңа спектакльнең көнен дә әйтте. Хәзер инде әнием белән сөйләшергә кирәк иде. Сөйләшү, әлбәттә, җиңел булмаячак. Әниемнең башта ук каршы төшүе мөмкин иде. Үзе дә куркыр, мине дә куркытып маташыр: «Театрга йөри торган вакытмыни»,— дияр. Яки исә ул миннән, һичшиксез: «Кем белән бармакчы буласың?» — дип сораячак. Менә шуңа минем, күпме генә уйлансам да, җавабым юк. Бары: «Үзем генә»,— дип әйтергә туры килер, ахрысы. Ләкин әнием минем үземне генә җибәрәме соң?! ...Кыскасы, тәгаен генә бер хәйләсен таба алмасам да, мин әнием белән сөйләшергә булдым. Тик каушамыйча, гади бер нәрсә хакында сүз баргандай итеп кенә сорарга, кирәксә, нык кына тартышырга да. Ахыр чиктә мин бала түгел бит инде, теләгән җиремә барырга да, йөрергә дә хакым бардыр, шәт! Бер башлагач, сүзен табармын әле. Халык бара ич, халык белән бергә кайтырмын, диярмен.

Спектакльгә бер көн калгач (ул 18 декабрьдә булырга тиеш иде), мин кичке чәйдән соң әниемә җайлап кына әйттем:

— Әни,— дидем,— театрда яңа спектакль куела икән, минем шуны бик күрәсем килә, син инде миңа рөхсәт итәрсеңме?..

— Нинди спектакль ул? — диде әнием.

— «Соңгы сәлам». Былтыр бер уйналган икән инде ул, халык бик мактый үзен...

Әнием аз гына дәшми торды да аннары туп-туры сорады:

— Нәрсә, Салих әфәнде чакырамы?

Мин моны һич тә көтмәгән идем. Бу хәтле дә белеп, туры китереп сорар икән! Бик гаҗәпләндем мин моңа һәм, билгеле, шактый аптырап, каушап та калдым. Әмма мин ялганлый алмый идем, ялган сөйләргә өйрәнмәгәнмен дә... Ирексездән ялганлый башласам да, әнием барыбер сизәчәк һәм гафу да итмәячәк. Ләкин дөресен әйтү дә бик хәтәр: әниемнең рөхсәт итмәве генә түгел, минем өчен, бигрәк тә Салих өчен, бик күңелсез нәтиҗә ясап куюы да ихтимал. Шулай да мин дөресен әйтергә булдым:

— Әйе, әни,— дидем, оялыбрак кына.— Салих әфәнде миңа ул спектакльне карарга кушкан иде.

Әнием һичнәрсә сиздермәде, хәтта йөзеннән бер күләгә дә узмады, бары тыныч кына сорады:

— Ул үзе дә бара торгандыр бит?

— Ул шунда, оркестрда уйный ич! — дидем мин.

— Ә, әйе шул, оныта язганмын,— диде әнием, аннары аз гына уйланып торды да карар чыгаргандай әйтте: — Ярый, барырсың, ләкин үзең генә түгел.

— Кем белән соң? — дидем мин, сак кына.

— Берәр дус кызың белән... Әнә Сания апаның Суфиясын чакырырсың!

— Барыр микән?

— Ник бармасын — куанып барыр. Әнисенә үзем әйтермен.

Мин дәшмәдем. Минем «ахирәтләр» ияртеп йөрисем килми иде, билгеле... Әнием, шуны сизгәндәй:

— Сиңа ялгыз йөрергә иртә әле, үзең дә белергә тиешсең,— диде.

Шуның белән сүз бетте. Гомумән, безнең гаиләдә сүз күп булмый иде. Минем колакка да гел генә: «Теге ярамый да бу ярамый!» — дип тукып кына тормыйлар. Күбрәк әнә шулай «үзең белергә» яки «үзең аңларга тиешсең» дип кенә әйтәләр. Һәм мин аңларга, ягъни әтиәнинең нәрсә теләүләрен, нәрсәне рөхсәт итә алуларын

үзем белергә, үзем чамаларга тиеш идем. Әмма шулай да мин бик канәгать, мин спектакльгә барачакмын! Әнием Салихның чакыруын кире какмады — бу, һичшиксез, «Салих әфәнде» белән хисаплашу иде. Хисаплашмыйча мөмкин дә түгел, чөнки Салих минем укытучым, чөнки заманасы шуны куша. Ләкин шуның белән бергә бу әле мине «Салих әфәнде» кулына тапшыру дигән сүз дә түгел. Ять-яшь кенә туташны яшь егет белән икесен генә халык арасына чыгару? — Аллам сакласын! Әнием үзенчә акыллы да, сизгер дә иде. Ул, әлбәттә, этиемне дә күндерәчәк.

Тик менә тагылып барачак «ахирәт» кенә гел эчемне пошырып тора. Дөресен генә әйткәндә, безнең арада чын дуслык та юк. Әниләр үзләре ахирәт булгач, безне дә «ахирәт кушарга» тырышалар. Ләкин Суфия ул миннән ике-өч яшькә олырак, миңа чебешкә караган төслерәк итеп карый. Үзе генә күп белә, гел өйрәтеп торырга ярата, бигрәк тә егетләрдән бик сак булырга куша (әйтерсең үзенең авызы пешкәне бар!). Шуның өстенә ул әнисе кебек зур гәүдәле, таза кыз — мин аның янында чынлап та чебеш төсле генә булып калам. Әйтәсе дә юк, ул миңа бик шәп «күз-колак» булыр.

Әмма бәхет бар икән әле. «Ахирәтем» авыру булып чыкты, ангина икән үзендә, врач салкынга чыгып йөрергә кушмаган. Шул ук вакытта мин, эш сүтелмәсә генә ярар иде, дип курка да калдым. Әнием барыбер ялгыз җибәрмәс, димәк, икенче «ахирәт» табарга кирәк булыр. Кемгә әйтеп карарга: Кәримәгәме, Зәкиягәме, Зәйнәпкәме?.. Ләкин баш ватып эзләп торырга туры килмәде —асравыбыз Сабира (рәхмәт төшсен үзенә!) мине бу кыенлыктан коткарды: «Борчылма, туташ, бергә барырбыз»,—диде. Мин моңа бик тә риза идем, тик менә әнием риза булырмы? Асрау белән җибәрүне килештерерме? Ә Сабира безнең бик сылу кыз, килмәгән җире юк, шуның өстенә үткен-чая да. Ул үзе үк, бер дә каушап тормыйча, әниемә:

— Апа, миңа да туташ белән бергә театрга барырга рөхсәт итегезче! — диде.

Белмим, әнием эченнән ни уйлагандыр, ләкин шулай да, әзрәк икеләнгәннән соң, ризалыгын бирде. Ни әйтсәң дә хөррият заманы, тыю-кысуларның ярамаганлыгын беләләр... Аннары иң мөһиме — без бергә барып, бергә кайтачакбыз, әнием иң элек менә шуны уйлаган булырга тиеш.

...Безнең куанычыбыз эчебезгә сыймый иде. Икәү генә калгач, кочаклашып, сикерешеп тә алдык. Бигрәк тә Сабираның шатлыгы ташып бара, чөнки аның өчен театрга барудан да зуррак бәйрәмнең булуы мөмкин дә

түгел иде. Шуның өстенә ул минем өчен дә бик сөенде, чөнки Салих чакыруы буенча баруымны белеп тора. Ә Салихны ул да ярата, минем өчен, гүя мин булып ярата. «Менә шундый шәп егеткә гашыйк булсаң да ярый, ичмасам!» — ди ул җай чыккан саен. Сизәм инде, үзенчә миңа теләктәшлек белдерәсе килә. Баштарак мин бик уңайсызлансам да, соңыннан аның бу эчкерсез сүзләрен ничектер ихтыярсыздан көтә торган булып киттем.

Ярый, моны куеп торыйк. Безнең кайгыбыз хәзер бүтәндә — театрга әзерләнергә кирәк. Ә кызлар өчен бу ансат эштән түгел: нәрсә кияргә, ничек киенергә, чәчләрне ничек төзәтергә, бизәнергәме-юкмы? — Менә күпме аның кайгысы... Мине һаман бер нәрсә борчый: Сабира белән безнең өс-башыбыз бертөсле үк булмаса да, бик үк аерылып та тормаска тиештер инде. Ничек тә бертигезрәк киенергә кирәк. Шуның өчен мин башта Сабираның «туалетын» тикшереп карадым. Былтыр гына тектергән, әле юньләп кимәгән дә шактый модный — тар билле, тар җиңле, иңбашлары күпертмәле зәңгәр йон күлмәге бар икән. Минем дә зәңгәр күлмәгем бар (тик фасоны гына башкачарак), димәк, без бертөследән кия алабыз. Тик менә аякларда гына төрлечә — Сабирада шнурлы гади ботинка, ә миндә зур перламутр каптырмалы модный туфлиләр. Ләкин моны берничек тә тигезләп булмый инде. Күлмәкләребез озын, аякларыбыз бик күренеп тормас әле, дип тынычланган булдык... Инде башны нишләтергә — калфак кияргәме-юкмы?.. Әнием яланбаш баруыбызга һич тә риза түгел. Сабира да шуны әйтә, яланбаш йөрергә оялам, ди. Ә минем нигәдер киясем килми, калфакны хәзер ташладылар инде, дим. (Хәер, моның дөрес түгеллеген үзем дә беләм: чәчләрен кыркып, яланбаш йөрүчеләр күренгәләсә дә, калфакны бик кияләр әле.) Ахырда риза булырга туры килде. Икебез дә вак энҗеле сай калфаклар кидек. Сабирага әнием үзенекен биреп торды.

Бу әле безнең алдан киенеп каравыбыз гына иде. Сабира белән икәү генә калгач, без трюмо көзге алдына янәшә бастык. Каршыбызда бертигез диярлек ике бик матур туташ басып тора! Тик берсе бик яшь әле, ә икенчесе — олырак. Бик яшенең йөзе сөттәй ак, чәчләре чемкара, ә күзләре зәп-зәңгәр. Кара чәч, зәңгәр күз! — бу бит әллә ничек, бер дә табигый түгел сыман. Нигә Ходай мине яратканда төсләрне шулай саташтырды икән?! Ә олыракның чәче дә, күзләре дә кара, хәтта йөзе дә каратутлы, әмма бик чиста. Ходай бу юлы саташмаган, игътибарлырак булган. (Тәүбә, тәүбә!) Сабира миңа әйтә: «Гөләндәм, син нинди матурсың!» — ди. Ә мин әйтәм:

«Юк, Сабира, син тагы да матурраксың»,— дим. Ә ул: «Кит, тиле, көлмә!» — ди миңа, үпкәләп. Ә мин көләргә уйламыйм да. Ул бит миңа караганда, ничек дим, гәүдәгә җитүрәк, биегрәк, күкрәкләре дә тулырак, тик мин моны аның үзенә әйтергә генә оялам.

Ә театрга без, насыйп булса, иртәгә барачакбыз. Салихка хәбәр итә алмадык инде, ләкин ул мине барыбер көтәчәк. Әйе, көтәчәк!.. Йа Ходай! Бу бит минем егет чакыруы буенча беренче мәртәбә театрга баруым... Салих абыем, Салих бәгырем, мин шулай ук сезнең игътибарны җәлеп итәрлек, театрга дәшәрлек чын туташ булдыммыни инде?! Ни бәхет бу, ни бәхет!

Икенче көнне без Сабира белән җыенып, киенеп-ясанып, гәзиткә төргән туфлиләрне култык астына кыстырып, сәгать ике тулар-тулмас өйдән чыгып киттек. Болай көпә-көндез кузгалуыбыз гаҗәп тоелмасын. Чөнки татар спектакльләре Проломныйдагы рус театрында («Большой театр»да) көндезге сәгать өчтә башлана иде. (Кичләрен руслар үзләре уйный.) Салих әйтә, бу озакка бармый, тиздән татар театрының үз бинасы булачак, ди. Милли сәнгатькә хәзер киң юл ачылачак, ди. Әлбәттә, шулай булырга тиеш, азатлык, тигезлек, диләр ич!

Без килеп җиткәндә, театр алдында халык күп түгел иде әле. Иртәрәк, ахрысы, дип уйладык, шулай да эчкәре уздык. Ә Салих ишек төбендәге билет тикшерүчедән аз гына арттарак басып тора иде инде. Менә кайчан ук көтә башлаган! Безне күреп, ул елмайды, без аңа елмайдык. Шунда ук ашыгып яныбызга да килде. Мин, Сабира белән икәү булгач, кәефе бозылмасмы икән дип борчылган идем. Ләкин, киресенчә, ул аңа чын ихластан сөенде генә.

— Менә рәхмәт, Сабира туташны да калдырмагансыз! — диде, аның да кулын кысып, һәм билет тикшерүчегә: — Болар минем кунакларым,— дип, безне эчкә алып кереп тә китте. Гардероб янына баргач, өстебездән салырга да булышты. Шул арада хәл-әхвәлебезне дә сорашып алды. Аннары көлеп кенә: — Инде, туташлар, сезгә көзге дә кирәктер,— диде һәм безне идәннән түшәмгә кадәр сузылган зур көзге янына да китерде. Мин, бераз әйләнгәләп, өс-башымны карадым, чәчемне төзәткәләдем, ә Сабира үзенең көзгедәге кыяфәтенә чит бер кешегә карагандай күз төшереп кенә алды.

...Фойега уздык. Бер читтәрәк туктап, уртада әйләнгән халыкны күзәтәбез. Салих әйтә, минем өчен тамаша шушыннан башлана, ди. Театрга килгән халыкка читтән генә карап торырга ярата икән: кешене читтән күзәтеп белү кызыклы, ди... Бәлки, шулайдыр да... Ми-

нем исә театрга килмәгәнемә бер ел бардыр инде, ә бу вакыт эчендә безнең шәһәрдәниләр генә булып узмады. Театр эчендә дә зур үзгәрешләр булгандыр, бигрәк тә тамашачы нык үзгәргәндер дип уйлаган идем. Алай ук түгел икән. Хатын-кызлар шул ук дияргә ярый — күбесе европача киенгән, әмма барысы да калфаклы ханымнар һәм туташлар. Иске моданы саклыйлар икән әле. Тик, бая әйткәнемчә, чәчләрен кистергән яланбашлы хатыннар да сирәк кенә күренгәли. Өсләрендә аларның билен каеш белән буган гади солдат гимнастеркасы һәм кыскарак кара юбка. Ә аякларында солдат итекләре! Кемнәр алар — хәрби идарәләрдә эшләүчеләрме, әллә хәрбиләр тирәсендә йөрүчеләр генәме? Бәлки, бу хәзер үзенә күрә бер модадыр яки хөрлек билгеседер?!

Ирләр исә шактый чуар. Элеккечә тройкадан бик фырт киенгәннәр дә күренеп кала, зур бант тагып, озын блузадан йөрүчеләр дә күренгәли, җиз төймәле яшькелт тужурка кигән студентлар да күзгә чагыла. Шулай да хәрби киемлеләр күбрәк. Болары инде кызыл гаскәриләр, өсләрендә гади гимнастерка яки дүрт кесәле френч, зәңгәр яки кызыл галифе, озын кунычлы итекләр, әмма бернинди погон-мазар яки башка дәрәҗә билгеләре юк. Дөрес, кайберләренең күкрәгендә кызыл бантиклары бар, ләкин бит аны хәзер теләсә кем кадый ала шикелле. Кыскасы, солдатмы, офицермы (хәер, офицер дию һич тә ярамый хәзер) — аерып булырлык түгел, бары тик кыяфәтенә, тотышына, өс-башының шәплегенә карап кына чамаларга була... Арада бик көязләре дә күренгәли. Эре, һавалы йөриләр. Хатын-кызга артык игътибар да итмиләр кебек, әмма бер карасалар, көйдереп алырлык итеп карыйлар.

Алар арасыннан Салих белән исәнләшеп узучылар да булды. Шул чакта миңа да күзләре белән сөзеп карарга өлгерделәр. Мин инде уңайсызлана да башладым. Салих шуны сизгәндәй:

— Әйдәгез, без дә агымга иярик,— диде.

Без кузгалдык. Мин Сабираны култыклап алдым, Салих минем якка чыкты, ләкин аз гына ара калдырып янәшәмнән атлады. Култыклау түгел, миңа орынып китүдән дә саклана кебек... Бүген ул кара костюм, ак күлмәк, кара бантиктан иде — бик килешә икән үзенә.

Салих Сабирага җитди генә әйткән була:

— Сабира туташ, мин сезне берәр комиссар белән таныштырыйммы?

— Юк, юк, кирәкми! — ди Сабира, чынлап курыккандай.

— Нигә? Комиссарлар арасында бик шәп кешеләр бар.

Әнә сул ягыгызга карагыз әле. Күрәсезме, матрос тужуркасы кигән егетне? Фамилиясе — Җиһаншин. Питердан җибәрелгән бик гайрәтле матрос-комиссар диләр аны!

— Булса ни,— ди Сабира, исе китмәгәндәй, ә шулай да үзе каршы яктан узып баручы киң җилкәле, куе кара кашлы пәһлевандай таза егеткә күз төшермичә үтә алмый.

— Сез юкка куркасыз,— ди Салих, отыры шаяртып.— Карап торырга бик гайрәтле күренсә дә, хатын-кыз янында ул бик юаш икән... Кулга ияләшкән арыслан кебек диләр, чын булса!..

— Ә сез аның шундый икәнен кайдан беләсез?

— Минме?.. Егет театрны бик ярата, бер генә спектакльне дә калдырмый... Безнең артисткалар аның белән танышырга да өлгерделәр инде — мин шулардан ишеттем. Ә артисткалар ирләрне таный беләләр, Сабира туташ!

Сабира кискен генә башын селки:

— Юк, миңа әртисткәләрдән калган кәмисәр кирәкми, үзләренә булсын!..

Салих рәхәтләнеп көлә. Шаркылдамыйча, ничектер әкрен тавыш белән, әмма бик тәмле итеп көлә. Аңа ияреп мин дә көләм — көлмичә мөмкин дә түгел: менә бит ул безнең беркатлы Сабирабыз үзенең көнчелеген дә күрсәтеп өлгерде.

Салих, көлеп туйгач, шулай да аңа йомшак кына әйтте:

— Сез мине, зинһар, кичерегез! Мин бит болай гына, кызык өчен генә... Үпкәләмәгәнсездер ич?

— Үпкәлим тагын! — диде Сабира, эре генә.

Шул арада беренче звонок та булды. Без, яңадан берике тапкыр әйләнгәч, зал ишегенә таба борылдык. Салих безгә урыннарның бик әйбәтен алып куйган икән — партерның өченче рәтендә, уртадан уза торган юл кырында гына... Мин аның үзенә урын булмас дип пошынган идем, ләкин урын өчебезгә дә булып чыкты.

— Ничек белдегез безнең икәү киләсебезне? — дип сорадым мин аңардан, ә ул серле генә итеп:

— Күңелем сизде,— диде һәм, кавалерларча иелә биреп, Сабирага кереп утырырга тәкъдим итте: — Сабира туташ, рәхим итегез!

Аның янына мин утырдым, ә иң кырыйга Салих үзе утырды.

Тамашачылар — калфаклы хатын-кызлар да, элеккеге әфәнделәр дә һәм хәзерге кызыл комиссарлар да кереп, урындыклары белән азрак дөбердәшкәннән соң, ниһаять, утырышып беттеләр. Сәхнә артыннан җиз кыңгы-

рау соңгы мәртәбә шалтырады, кемнәрнеңдер ашыгып йөрүләре, кабаланып чыш-пыш сөйләшүләре ишетелеп калды. Ниһаять, барысы да тынды һәм пәрдә әкрен генә икегә аерылды.

...Без «Соңгы сәлам»не карыйбыз. Якты сәхнәдә яхшы ук бай җиһазлы татар сәүдәгәренең өе. Күпмедер вакыт сәхнә буш тора, тик бераздан гына европача бик зәвык белән киенгән, утызлар тирәсендәге, урта буйлы чибәр генә ир кеше килеп керә. Ул әле бер сүз дә әйтми, сәхнә буйлап әрле-бирле йөренә, аннары туктап, күкрәк кесәсеннән бер фотокарточка чыгара да шуңа уйланып карап тора.

Салих иелә төшеп миннән сорый:

— Таныдыгызмы?

Мин «Сәйяр» артистларының барысын да диярлек таный идем, ләкин сәхнәдәге ирнең тавышын ишетмәгәч, икеләнебрәк калдым.

— Тинчурин бу,— ди Салих, шыпырт кына.— Үз әсәрендә баш рольне уйный!

Шул арада сәхнәгә юка гына зифа буйлы, мөлаем-матур гына яшь бер хатын газеталар күтәреп килеп керә. Ир кешегә йомшак кына, Вахит, дип дәшә. Хатыны икән.

— Ә бусын? — ди Салих миңа.

— Бусын таныдым. Өммегөлсем ханым Болгарская, шулаймы?

— Дөрес!

Без, артык сүз алышмыйча, бик игътибар белән сәхнәдә барган вакыйганы карыйбыз. Беренче күренештән үк инде ир кешенең үз хатынын яратмавы, каядыр читтәге икенче берәүне яратуы ачыклана башлый. Җитмәсә, ул «берәү» рус кызы булса кирәк — шулай аңлашыла. Татар сәүдәгәренең рус кызына мәхәббәте — бу, әлбәттә, бик кызыклы иде. Хәзер үк инде гадәттән тыш нидер көтәргә мәҗбүр итә. Вахитның исә сөйкемле хатыны гына түгел, шактый диндар карт әнисе дә, кечкенә баласы да бар икән әле... Кая илтеп чыгарыр, ни белән бетәр бу... мәхәббәт?!

Артистлар, минемчә, бик табигый уйныйлар. Тинчурин кайгылы-уйчан, хыялый кешедәй үзенең эчке дөньясына бикләнгән, шуңа күрә якыннарына үтә игътибарсыз, ә сәүдә эшләренә әйтерсең бөтенләй кулын селтәгән... Хатыны исә (Болгарская) иренең шушы хәлен күрә, сизә, газаплана, еш кына җылап та ала, әмма ләкин аңа каты бәрелүдән курка, ничек тә кәефен бозмаска тырыша. Ярата ул, бичара, чынлап ярата ирен!

Бу урында мин үз хәлем турында да әйтмичә уза алмыйм. Сәхнәдә барган вакыйга минем дикъкатемне бет-

кәнче биләп алса да, мин янымда утырган Салихны бер генә секундка да онытып тормадым. Әз генә кыенсыну катыш эчке бер сөенү белән аны тоеп утырам. Ходаем, нәрсәдер инде бу,— үзем дә аңламыйм!

...Беренче пәрдә бетте. Урыннарыбыздан торгач та, Салих безгә әйтте:

— Сез, туташлар, мине кичерегез инде, үзегезне генә калдырырга туры килә. Миңа оркестрым янына барырга кирәк.

— Барыгыз, бар, безнең өчен борчылмагыз,— дидек без аңа.

Ул алданрак чыгып китте. Халыкка ияреп, ашыкмыйча гына без дә фойега чыктык. Мин бер читтә генә басып тормакчы идем дә, Сабира беләгемнән тотып кыстый башлады...

— Әйдә, әйдә, йөрибез! Абыстайлар шикелле стена буенда авыз каплап тормыйк әле.

Аның кешедән бер дә калышасы килми иде — башкалар уртада йөриләрме, димәк, ул да иркенләп йөрергә тиеш. Кай җире ким аның бүтәннәрдән?! Тыңларга туры килде үзен... Ә бераздан фойеның алгы башындагы сәндерәгә урнашкан кечкенә оркестр дәртле генә уйнап та җибәрде. Ике скрипка, ике мандолина һәм пианинода «Баламишкин»ны сыздыралар. Халыкның бердән йөзләре ачылып, хәрәкәтләре җиңеләебрәк киткәндәй булды — кәефле елмаешып, башларын күтәрә төшеп атлый башладылар. Хәрби киемдәгеләр исә аеруча тураеп, дөньяның хуҗаларыдай горур карап, һавалы атлыйлар, тик ара-тирә бөгелә төшеп, яннарындагы кызларның колакларына нидер әйтәләр, ә кызларга әйтерсең шул гына кирәк тә — күңелләре кытыклангандай тәкатьсездән кычкырып көлеп җибәрәләр. «Баламишкин»нан соң оркестр «Ком бураны»н уйнады, аннары, озын көйгә күчеп, «Уел»ны салмак кына суза башладылар. Һәм, музыканың сихри кодрәтенә буйсынып, кешеләрнең дә кәефләре шунда ук үзгәрде. Гүя, «Уел» дулкыннарына уралып, каядыр еракка-еракка агып киттеләр. Кычкырып көлүләре бетте, үзара сөйләшүләр дә тынды, тик идәнне чыш-чош ышкыган аяк тавышлары гына ишетелеп торды. Ә уйнаучылар өздерәләр генә, бигрәк тә беренче скрипка өздерә — уйнаучысы кечкенә кара кеше — Мөхәммәт абый Яушев. Ләкин мин күбрәк пианинога колак салам, Салихның ничегрәк уйнавын ишетәсем килә. Дүрт-биш кешелек оркестрда да, билгеле, беренче нәүбәттә скрипка-мандолина тавышлары яңгырый, шулай да мин Салих уйнавын аермачык ишетәм. Шул скрипка-мандолиналарга тәмам көйләнеп, алар белән бергә үрелеп дигәндәй,

гадәтенчә, җиңел-йомшак кына итеп уйный ул... Хәер, аның уйнавын мин иң зур оркестрны тыңлаганда да менә шулай ап-ачык ишетер идем кебек.

Күрәсең, антракт беткәндер, музыка тынды, халык залга керә башлады. Без дә борылдык. Шул чакта мин ложа ишеге төбендәрәк бер төркем яшьләрнең кемнедер уратып алуларына игътибар иттем. Туктала биреп (ә Сабира моны сизмичә алдан кереп китте), әйе, туктала биреп карасам, түгәрәк эчендә, тәгәрмәчле креслода бер кеше утырып тора. Моңарчы күргәнем булмаса да, мин аны шунда ук таныдым. Рәсемнәре буенча, ишеткәннәрем буенча, хәтта әсәрләре буенча да мин аны таныдым: бу — Фатих Әмирхан иде. Йа Рабби, әдип Фатих Әмирхан! Минем иң яраткан әдибем!.. Билгеле инде, мин үтеп китә алмадым, әдәп кагыйдәсен бозып булса да, бер читтәрәк тукталдым — мондый форсаттан файдаланмыйча калу мөмкинмени?! Дөрес, әйләнәсендәге кешеләр иркенләп карарга комачаулыйлар, ләкин шул ук вакытта алар аша-сыннан күзәтү минем өчен уңай да иде. Ничек кенә булмасын, мин әдипнең йөзен-кыяфәтен дә, өс-башын да шактый тулы-ачык күрдем. Ул яланбаш иде, чәче кыска итеп китәрелгән, борын өстендә калын пыялалы пенсне, шуңадыр, ахры, коңгырт күзләре аеруча зур булып күренә. Иреннәре дә калын, һәм бу аның чыраена нинди дер бер ныклык, тәвәккәллек биреп тора кебек... Кигәне кара тройка, катыргы ак яка, шуңа ак төрткеле зур гына кара галстук бәйләгән. Ә әйләнәсендәге яшьләр — нәкъ аның үз геройларына охшаган берничә калфаклы туташ та яшел тужуркалы бер-ике студент — ул шулар белән, яңагына таянган килеш, ашыкмыйча гына нидер сөйләшә. Дөресрәге, яшьләр бер-берсен бүлә-бүлә аңа нидер сөйлиләр, ә ул башын каккалап, күбрәк тыңлап кына утыра... Миңа калса, әдип бу «чорналыш» уртасында калудан бик үк канәгать тә түгел шикелле, һәрхәлдә, ул нигәдер уйчан, җитди-уйчан, күзләре дә салкын (әллә пыяладанмы?), гүя менә ирексездән генә яшьләрнең комплиментын тыңларга да шуларга саран гына елмаеп җавап бирергә мәҗбүр — шулай күренде ул миңа. Әмма бу мин күрергә теләгән әдип иде, хыялымда мин аны нәкъ менә шушындый ирләрчә җитди-горур, чын интеллигент кыяфәтле бер кеше итеп саклый идем. Тагын шул — мин аның гарип булуын күптән ишетеп белә идем, ләкин менә хәзер үз күзем белән күргәч,— ни гаҗәптер — ул миндә кызгану хисе уятмады. Мескенлектән бик өстен иде ул!

Кузгалырга да вакыт иде инде. Әдип тирәсенә җыелган яшьләр дә таралдылар, ә мин һаман китә алмыйча

торам. Ярый әле, шул арада Салих килеп җитте. Ул шунда ук Фатих Әмирханны күрде һәм аңа таба атлады. Әдипнең салкын-уйчан йөзе ничектер бердән йомшарып-җылынып киткәндәй булды. Үзе үк башлап:

— Ә, Салих туган! — дип дәште.— Уеныгыздан бик мәмнүн булдык, рәхмәт сезгә!..

Алар кул бирешеп күрештеләр.

— Сездән мактау сүзе ишетү безнең өчен зур шәрәф ул! — диде Салих, дулкынлана төшеп.— Мин моны, әлбәттә, иптәшләремә дә җиткерермен.

Әдип башка сүз әйтмәде. Салих исә, тиз генә миңа таба борылып:

— Гөләндәм туташ, килегез әле! — диде.

Мин тәмам аптырап, каушап калдым: бу ни эш, ни өчен чакыра ул мине? Ә Салих һаман дәшә:

— Килегез инде, килегез!

Кыстатып торуның һич килешмәсен аңлап, мин урынымнан кузгалырга мәҗбүр булдым.

— Фатих абый,— диде Салих, түбәнчелек белән генә.— Рөхсәт итсәгез, мин Гөләндәм туташны сезнең белән таныштырырга теләгән идем.

— Рәхим итә күрегез,— диде әдип, елмаеп кына.— Туташлар белән танышудан ваз кичә алмыйм!

Бу минутта мин нишләргә, ни әйтергә кирәклеген һич белә алмыйча тора идем. Әдип шуны сизде, ахрысы, үзе башлап миңа кулын сузды. Бик таркау хәлдә булсам да, мин аның озынча-ябык, кайнаррак кулын тойдым.

Ә Салих ашыгып мине мактарга кереште:

— Гөләндәм туташ пианинода шактый чибәр уйный. Кабилияте бар. Киләчәктә, һичшиксез, музыкант булырга тиеш.

— Бирсен Алла! — дип куйды әдип.

— Мин инде аның сезне никадәр яратып укуын әйтеп тә тормыйм.

— Дөрес эшлисез! — диде әдип, ваемсыз гына, аннары миңа туры гына карап әйтте: — Салих әфәнде сезнең хакта мотлака белеп әйтәдер дип уйлыйм. Сезгә, туташ, аның өметләрен акларга гына кала.

— Рәхмәт! — дидем мин, чак ишетелерлек итеп.

Фойеда беркем дә калмаган иде инде. Залда ут та сүнде. Сүз беткәнгә ишарә ясап: «Хәзергә, туганнар!» —диде әдип. Артында басып торган түгәрәк кенә ак сакаллы, сөйкемле генә бер бабай әдипнең креслосын тәгәрәтеп, якындагы ложага алып кереп китте. Без әдипкә баш иеп калдык. Ашыгып залга кердек. Пәрдә ачылмаган иде әле. Мин шунда ук Салихка үпкәмне белдерергә ашыктым:

— Ник сез мине Фатих абыйга күрсәттегез? Шундый уңайсыз булды миңа, оятымнан нишләргә дә белмәдем. Ходаем, ярыймы соң шулай кинәт кенә...

— Ник ярамасын?! — диде Салих, әкрен генә көлеп.— Бик уңай килеп чыкты ич!.. Фатих абый үзе дә бит, туташлар белән танышудан ваз кичә алмыйм, диде.

— Ваз кичә алмый шул, бичара!.. Әмма туеп беткәндер инде ул алардан.

— Сез — башка! — дип куйды Салих, җитди генә.

— Ничек «башка»?

— Шулай. Мин бит сезне аның белән чибәр туташ итеп кенә түгел, ә бигрәк тә булачак музыкант итеп таныштырдым. Сәнгатьнең әһлесенә күрсәттем мин сезне, Гөләндәм!

— Йа Ходa! Булачак музыкант!.. Сез дә көләсез...

— Аллам сакласын! — диде Салих, ашыгып, һәм кулыма җиңелчә генә орынып алды.— Тынычланыгыз! Бу таныштыру өчен соңыннан үзегез дә миңа рәхмәт әйтерсез әле. Фатих Әмирхан ич ул!.. Ә хәзер спектакльне карыйк.

Пәрдә ачылган иде инде. Кайда бу, нәрсә бу? Сәхнәдә чит шәһәрдәге номерларның бер бүлмәсе икән. Әлеге яшь, чибәр татар сәүдәгәре сәгатенә карый-карый кемнедер көтә. Номер хадимәсе кереп-чыгып йөри. Бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлгә төрле ашамлык-эчемлекләр кертеп куя. Ә бераздан, хадимә чыгып киткәч, ишек кагалар. Вахит ашыгып ишеккә бара. Ишек ачыла һәм бусагада битенә кара вуаль каплаган бик зифа буйлы яшь кенә бер туташ пәйда була. Күпмедер вакыт алар бер-берсенә өнсез карашып торалар. Аннары Вахит: «Ольга, бу синме?» — дип, кызга ташлана. Кыз вуален күтәреп җибәрә дә егет кочагына сыена. Менә кемне Вахит зарыгып, сабырсызланып, үзенә урын таба алмыйча көткән икән!

Әйе, әйтәсе дә юк, кыз искиткеч сылу-чибәр. Вахит шашынып аның кулларын, йөзен, күзләрен үбә башлый. Менә кайда икән ул... мәхәббәт! — тилерүгә якын ниндидер иңрәүле, ялварулы, газаплы хәтәр мәхәббәт!..

Ольга исемле рус кызын моңарчы мин күрмәгән яңа артистка уйный иде. Салих колагыма иелеп кенә әйтте, Әшрәф Синяева, диде. Петербургтан махсус театр курслары бетереп кайткан яшь артистка икән. Кара син аны —татар кызлары нишли хәзер?!

Яшь артистканың буе-сыны бик нәфис-килешле, йөзе дә бик гүзәл-сөйкемле, тавышы да чиста-ягымлы иде. Кыскасы, үзенең роленә бөтен ягы белән дә туры килгән чын, табигый рус кызы!

Әмма яратамы соң бу чәчәктәй матур, яшь марҗа кызы

татар сәүдәгәрен? Ярата, бик ярата сыман... Һәрбер әйткән сүзе, һәр кыланышы шуны раслап тора кебек... Нәрсә ди ул?.. «Мин бит сине сагынып гакылдан яза яздым... Юк, чынлап та, Володя, бу синме?.. Бу синме, Володя?.. Бу төш түгелме?» — ди ул, Вахитның күзләренә керердәй булып... Менә ул иреннәрен Володяның авызына суза, калтыранган тавыш белән: «Сөеклем, князем минем... өзелеп сөям бит мин сине!.. Аңлыйсыңмы, бөтен барлыгым белән бит мин сине сөям!» — ди, һәм алар һушларыннан язганчы үбешәләр. Ходаем, шул дәрәҗәгә җитәргә кирәк бит! Оятымнан мин хәтта башымны ияргә мәҗбүр булдым. Әмма ләкин, шулай шашынып яратышуларына карамастан, кызның мәхәббәтенә ышануы читен иде. Чын мәхәббәт түгелдер бу, берәр төрле хәйлә генәдер дигән шик күңелне менә берөзлексез тырный да тора. Һәм бу шик, бу сизенү әсәрдәге вакыйга куера барган саен отыры арта гына бара.

Чынлап та, Ольга бу татар сәүдәгәрен ни өчен яратырга тиеш әле? Байлыгы өчен дияр идең, ул үзе дә миллионер кызы. (Әсәрдә миллионнарны кушу турында сүз дә булып ала, ләкин мин моны аңламадым: мәхәббәт бар җирдә нинди миллионнар турында сүз булырга мөмкин икән?) Матур, таза ир булганы өчен дияр идем, Ольга шикелле шундый чибәр кызга үз шәһәреннән, үз милләтеннән сайлап алырлык шәп егет табылмас идемени?.. Җитмәсә әле, Вахитның яшерүенә карамастан, кыз аның хатынлы-балалы кеше булуын да белә шикелле... Юк, ничек кенә юрама, Ольганың мәхәббәтен аңлавы да, аңа ышануы да читен иде. Бәлки, кызга Вахитны гаиләсеннән, диненнән, милләтеннән аеру кирәктер? Ольга бит аңа, әтиләр белә, әтиләр сине көтә, дип әйтә. Ул аны үзләренә кат-кат чакыра, аңа зур бәхетләр вәгъдә итә. Ниһаять, соңыннан Вахитны алып китәр өчен ул торган шәһәргә дә килә. Димәк, Ольга боларның барысын да әтиләре белән уйлашып, киңәшеп эшли! Нинди мәхәббәт була соң бу?!

Ә менә Вахитның Ольганы өзелеп яратуы бер төрле дә шик уятмый. Киресенчә, ул инде мәхәббәтеннән тәмам исергән, акылын җуйган кеше, Ольганың колына әверелеп, ак-караны күрмичә, үзенең һәлакәтенә бара торган кеше... Аның газапларына карап булмый иде, әледән-әле яшь төере бугазга килеп тыгыла иде. Залда әкрен генә елап утыручылар да булды шикелле. Бигрәк тә соңгы пәрдәдә... Соңгы пәрдәдә алар Идел яры буенда очрашалар. Вахит, Ольга белән качар өчен, өен, гаиләсен, карт әнисен ташлап шунда килә. Әмма Вахитны соңгы минутта нидер тота, гүя ул үзенең алдында төпсез упкын күрә. Китәргә дә, чигенергә дә мөмкин

түгел. Һәм ул, гел ашыктырып торган Ольганы, хәзер артыңнан барып җитәрмен, дип, көймә белән пристаньга озата да үзе яр буенда... атылып үлә... Әйе, менә револьверын чыгарып, чикәсенә тери дә... Ходаем, үзең күрсәтмә моның кебек бәхетсез үлемне!.. Атылыр алдыннан ул: «Мин алдандым, алар мине алдадылар!» — ди. Димәк, белгән нинди җәтмәгә эләккәнен... Иң ахырдан, Идел өстендәге акчарлакларга мөрәҗәгать итеп, алар аша әнисенә, хатынына соңгы сәламен тапшыра.

Әнә шулай җан тетрәтеп һәм нигәдер шомландырып бетә бу «Соңгы сәлам» дигән спектакль. Алкышлар көчле булды. Пәрдә берничә мәртәбә ачылды. Тамашачылар әсәрне язган һәм баш рольне уйнаган Кәрим абый Тинчуринны аеруча озак алкышладылар. Ул арыган кыяфәт белән, әмма бәхетле елмаеп, башта үзе генә, аннары Болгарская белән Синяеваның кулларыннан тотып, аларны да алгарак чыгарып, халыкка кат-кат башын иде.

Спектакль сәгать җиделәр тирәсендә генә бетсә дә, тышта күптән караңгы төшкән иде инде. Һава шактый салкын, зәһәр генә җиле дә бар, бик сирәк урыннарда гына, җилдән селкенгәләп, зәгыйфь кенә фонарьлар яна. Тротуар чокырлы-чакырлы, тайгак — Сабира белән икәү нык кына култыклашып атлыйбыз. Ә Салих минем яннан гына гүя мине саклап бара, ләкин беләгемнән алырга кыймый. Мин эчемнән генә борчылып, әллә үзем алыйм микән, дип тә уйлап куям, әмма моңа минем батырлыгым җитми, билгеле... Урам уртасыннан ара-тирә извозчиклар чаптырып узып китәләр — аларда хәзер байлар түгел, ә кызыл комиссарлар кырын ятып кайта.

Билгеле инде, кайтып җиткәнче безнең арада сүз яңа гына күргән спектакль турында барды. Һәркемнең үз хөкеме. Мәсәлән, безнең Сабирага марҗа кызына гашыйк булган яшь сәүдәгәр бер дә ошамаган икән.

— Бай маена чыдый алмый, шуңа сикерә ул! — ди, ачуланып.— Әнә, сикерә торгач, үзенең башына да җитте. Шул кирәк аңа!

— Ни сөйлисез, Сабира туташ! — ди Салих, бик гаҗәпләнеп.— Сез мәхәббәткә ышанмыйсызмыни?

— Ник ышанмыйм — ышанам! Мәхәббәт бит ул бербереннән яхшы белгән, тиң килгән кешеләр арасында гына була. Ә болар нәрсә? Икесе ике шәһәрдән, берсе марҗа, икенчесе татар да иншу хатынлы, балалы... Ә хатыны нинди сөйкемле, сабыр, ярата да бит әле шул азгынны!.. Юк инде, юк, сөйләмәгез, чын гашыйк түгел бу... Татар байларының марҗалар артыннан себерелгәнен ишеткәнебез бар инде.

Салих башта, гадәтенчә, рәхәтләнеп бер көлә, аннары, тынычлангач, миннән әкрен генә сорый:

— Ә сезнеңчә ничек, Гөләндәм?

Ә мин ни әйтергә дә белмим. Күңелемнән әллә ниләр уйласам да, нигәдер менә тотып кына әйтер сүзем юк. Салихка да шулайрак аңлаттым, ә ул тагын сорый:

— Ә сез алар арасындагы мәхәббәткә ышандыгызмы?

— Ничек дим?.. Вахитның яратуына ышанмыйча мөмкин түгел, ә менә Ольганың... юк, мин ышана алмадым аның чынлап яратуына.

— Ни өчен?

— Кызны бит гүя туганнары котыртып тора, шулар кушуы буенча ул Вахитны гаиләсеннән аермакчы да була — шулай аңладым мин пьесадан... Ә нигә, ни өчен кирәк соң аларга татар сәүдәгәре?

— Чукындырыр өчен! — ди Сабира, кискен генә.

Салих тагын бер рәхәтләнеп көлә:

— Ну, Сабира! Ярып кына сала!..

— Ату ни өчен?.. Нинди урыс үз кызын чукынмаган татарга бирсен ди?!

— Ә бәлки, кызның туганнарына татар сәүдәгәрен чукындырып тормыйча гына йоту кирәк булгандыр? Икенче яктан, Вахит та рус капиталын эләктерү турында хыяллангандыр?.. Сәүдә эшләре хәйләи-шәргыйгә корылган нәрсә бит ул!

— Әллә тагын, анысын мин ишетмәдем.

— Ләкин пьесада шул нәрсә дә сизелә бит!.. Кыскасы, туташлар, минем фикеремчә, монда күп нәрсә зур бер төенгә бәйләнгән: дин, гаилә, байлык мәсьәләләре... Вахит менә шул төенне чишә алмыйча һәлак була да инде. Бигрәк тә дин һәм милләт аермасы күп кенә очракта гашыйкларны әнә шундый фаҗигагә китерә дә... Әйе, авыр фаҗига, тамыры аның бик тирән әле. Әмма киләчәктә андый фаҗигаләр булмас, булмаска тиеш.

— Чынлап әйтәсезме?

— Әйе, Гөләндәм! Иске хорафатлар әкренләп җимерелә бит, үзегез дә күрәсездер... Мәсәлән, байлык белән ярлылык та гашыйклар арасында шундый ук киртә иде, ә хәзер аның ни әһәмияте бар?..

Дөрес сүзгә җавап юк, диләр — мин дәшмәдем. Без инде кайтып та җиткән идек. Семинария каршысында тукталдык. (Ә безнең йорт шуның кырыендагы тар тыкрыкта гына.) Монда, күл буенда, һава тагы да салкынрак, җиле дә көчлерәк иде. Салих та:

— Туташлар, сезне бу суыкта өшетеп тотасым килми,

булмаса, барыгыз инде,— диде. Ә аның үз аягында шиблетлар гына иде. Сабира, шуларга күрсәтеп:

— Үзегезгә карагызчы, аяксыз каласыз ич, йөгерегез тизрәк! — диде.

— Ә мин өйрәнгән инде,— диде Салих, ваемсыз гына, һәм саубуллашыр өчен безгә кулын сузды.— Тәмле йокы, матур төшләр сезгә, туташлар!

— Сезгә дә шулай ук,— дидем мин, кулымны биреп.— Рәхмәт спектакль өчен.

Ул миңа елмаеп кына карады:

— Рәхмәтне мин әйтергә тиеш, Гөләндәм!.. Тыңладыгыз. Тик соңгысы булмасын!

Мин килешкәндәй башымны гына кактым. Ул җитез генә борылып китеп барды, без дә ашыгып өебезгә таба йөгердек.

...Әнием безне чәй әзерләп көткән. Өебез май кебек җылы, тик бераз караңгырак. Керосинга хәзер кытлык булгач, түшәмдәге зур фарфор лампаны яндырмыйча, күчереп йөртә торган җиделе лампаны гына кабызалар. Әтием ясту намазына киткән икән...

Без өчәү генә чәй эчәргә утырдык. Әнием спектакль турында сораша башлады. Әйткәнмендер дә инде, безнең әни «заман имин» чакта үзе дә театрга йөрергә ярата иде. Хәтта русныкына да баргалый иде. Тик хәзер генә, бигрәк тә әтиемне тыңлап, чыгып йөрмәс булды. Әтием минем, әйткәнемчә, үтә сак кеше. Кайчагында аның әйтеп ташлаган сүзләре дә кызык кына: «Тизрәк влас булсын,— ди,— акмы-кызылмы — минем өчен барыбер, югалтырлык капиталым юк, ә влас кирәк, төпле влассыз тәртип-низам булмаячак»,— ди. Ул шуны көтеп утыра.

Әнием: «Йә, ни күрдегез, ошадымы соң?» — дип сорауга Сабира: «И-и Бибимәликә апа...» — дип, гаҗәп-хәйранга калгандай, бик тәфсилләп спектакль турында сөйли дә башлады. Ишеткәнен яки күргәнен әнә шулай түкмичәчми, бизәп-матурлап, үзеннән дә өстәп энигә сөйләү аның иң яраткан эше иде... Мин сүзгә катнашмадым. Минем үзем өчен генә бик әһәмиятле, бик кадерле кичерешләрем бар — аларны бирәү белән дә бүлешәсем килми. Ике генә чынаяк чәй эчтем дә тизрәк үз бүлмәмә менеп киттем.

Әйе, бүгенге кичә минем хәтеремнән тиз генә чыкмас, юк, чыкмас! Шунда күргән-кичергәннәр белән бөтен күңелем-хыялым тулган минем... Күпме дулкынландырган, күпме уйлар кузгаткан гаҗәеп бер спектакль, Тинчурин, Болгарская, Синяеваларның сокландыргыч уеннары... Әле дә менә шулардан айнып җиткәнем юк... Ә

Фатих Әмирхан белән танышу! Моның һич көтелмәгән тәэсирен ничек кенә әйтеп бирим икән? Хәтта спектакль үзе бер мәлгә югалып, онытылып торган кебек булды. Ишеткәндә исеме генә дә мине сихерләгән мәшһүр әдип көннәрдән бер көнне миңа җылы карашын ташлар, минем кечкенә кулымны үзенең үлемсез кулына алыр дип уйлаганым бар идемени?! Юк, болар барысы да бер кич өчен күп иде, бик күп иде... һәм боларның барысына да Салих, рәхмәт төшкере, «гаепле» ич!

Салих!.. Бөтенесеннән дә тирәндәрәк ята ул минем йөрәгемдә. Нәкъ менә бүген, бүгенге кичәдән ул миңа тагы да якынрак булып китте түгелме соң?.. Залга кереп янәшәсенә утыргач та, мин бу якынаюны тоя башладым бит! Һәм менә хәзер дә, чишенеп җылы урыныма яткач та, мин шул егет кешегә карата туган гаҗәеп бер яңа, тансык якынлык хисен йөрәгем-тәнем белән тоюдан һич арына алмыйм... Нәрсә соң бу, Ходаем, нәрсә соң?! Шулай ук бу минем буй җиткән кыз булып өлгерүем микәнни инде?! Рәхәт тә миңа, куркыныч та... Әчке күлмәк кенә каплаган түшләремне ике кулым белән кочаклап, кемнәндер оялып качкандай, йөземне тизрәк мендәргә яшерәм.

## IX

Иртән уянып, күземне ачып җибәрүгә, караңгылы-яктылы бүлмә эчендә колагыма әллә нинди сәер тавышлар ишетелде. Нәрсәдер ачуланып мыгырдана, ухылдый, кинәт кенә үкереп тә куя; өй үзе дә нәрсәдәндер ыңгыраша, шыгырдый, әкрен генә селкенә дә кебек. Шик юк, бу сәер тавышлар тыштан килә иде. Тиз генә үрелеп, тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәреп карасам, тышта галәмәт буран икән ләбаса! Шул дөньяга сыя алмыйча котырына, имеш!

Кичә Салих безне озата килгәндә, Кабан өстеннән кар себертеп искән әче җил тора-бара әнә нинди дәһшәтле буранга әйләнгән. Дәһшәтле буран, мине уяткан шикелле, аны да сискәндереп уяткандыр әле. Ул да күксел-зәңгәр күзләрен зур ачып, буран тавышын тыңлый-тыңлый уйланып ята торгандыр... Безнең аралар бик ерак та түгел бит — аның торган йорты Мещанскийда гына — ул да шушы араның якынлыгын тоямы икән? Әллә аңа бу ара бик ерак булып тоеламы икән? Еракмы, якынмы безнең ара?.. Еракмы, якынмы?..

Йә, тиле түгел диген инде мине, ни уйлап ятам бит, әй генәм!.. Буран гаепле моңа, буран шулай саташтыра, буран бөтен нәрсәне йә бик якынайта, йә бик еракка

алып китә. Менә буран басылгач, барысы да яңадан үз урынына кайтыр, һәм мин дә бәлки бервакыт чын дөресен генә белермен. Чын дөресен?! Әмма кирәкме соң ул «чын дөресен генә» белү, кирәкме? Нәрсә китерер ул миңа — сөенечме, әллә көенечме? Ходаем, тагын әллә ниләр уйлый башладым. Юк, торырга кирәк, торырга! Бу җен-пәриләр оркестрына охшаган кыргый-шомлы буранны тыңлап ята торгач, бөтенләй хыялыйга әйләнерсең, билләһи!

Ә вакыт соңдыр инде, өйдәгеләр күптән торганнардыр. Безнең әти калган чәйгә торып чыгуны бер дә яратмый, тизрәк җыештырып алырга куша. Бигрәк тә уянганнан соң урын өстендә киерелеп-сузылып ятуны җене сөйми — начар бер гадәт итеп саный ул аны. Уяндыңмы — тор, шайтан коткысына бирелеп ятма, ди. Белеп әйтә әти кеше!..

Менә шул шайтан коткысына бирелмәс өчен юрганымны ачып ташладым да җәһәт кенә торып утырдым. Идәнгә аякларымны салындырып, җылы чүәкләремне эләктердем, өстемә бумази халатымны киеп алдым. Чәчләремне җыештырып, батист яулык белән бәйләгәч, песидәй тавышсыз гына басып, кухняга төштем. Әлбәттә, чәйне эчкәннәр, самавыр-чынаяклар да залдан кухняга күчкән иде... Әнием, әз генә шелтә белдереп:

— Озак йокладың, кызым! — диде.

Иркә кызлар кебек, башым-фәлән авырта, дип ялганларга да мөмкин иде, ләкин мин инде ялганлап торырга ирендем. Бары:

— Тышта буран ич! — дип кенә куйдым.

Җавабым балаларча булып чыкты, күрәсең, әнием, ирексездән көлемсерәп кенә:

— Алайса ник тордың, буран басылганны көтәр идең,—диде.

— Ачыктым әле,— дигән булдым да, өстәл башына гына утырып, өлешемә калган йомырка тәбәсен ашый башладым, аннары сөтләп, баллап чәй эчтем. Буш чынаякларны юып, сөртеп торган Сабира миннән хәйләкәр генә:

— Йә, туташ, төшеңдә ниләр күрдең? — дип сорады.

Аның ни уйлап сораганын сизәм инде, шуңа күрә юри ваемсыз гына:

— Әллә тагын, хәтерләмим,— дидем,— каты йоклаганмын.

— Ай-һай, чын микән? — диде Сабира, ышанмыйча. Аннары мич янында булашкан әниемә ялт кына карап алды да пышылдап кына әйтте:

— Мөгаен, теге... зәңгәр күзле егетне күргәнсеңдер әле, керми калмас ул синең төшеңә!

— Чү! — дидем мин аңа, шелтә белән. Ә ул, хәерсез, чынаякларын шалтыраткалап, миңа күз генә кысты: янәсе, курыкма, ишетмәс, ишетсә дә берни булмас!

Бу тел бистәсеннән тагын шундый берәр нәрсә ишетмим дип, мин юри тәрәзәгә карап тора башладым. Ә буран тәрәзә турында гына, әйтерсең котырынып йон тетә — һични күреп булырлык түгел. Тик аның бер ярсып китеп, бер тына төшеп улавы гына ишетелә. Нигәдер эчем поша, сулкып поша, ни эшлим икән, дип аптырап уйланам, ә үземнең кыл да кыймылдатасым килми. Сабира белән минем бүлмәдә карта ачарга яки дураклы уйнарга да булыр иде, ләкин аның тиктормас теленнән, җанны җәрәхәтләп урти башлавыннан куркам. Мин бит Салих турында уйларга гына яратам, әмма аның хакында сөйләргә, бигрәк тә кеше сөйләгәнне тыңларга бер дә яратмыйм... Нишләргә соң?.. Буранга да ачуым килеп куя, гүя миндәге эч пошуга, гаҗизлеккә, эшсезлеккә бары ул гына гаепле!

Ә менә Сабира өчен таш яуса да барыбер. Әнә ул ап-ак оекбашларын киеп алган да җил шикелле бөтерелеп кенә йөри. Бер эшен бетерүгә икенчесенә тотына, шул арада үзе такылдарга да, көләргә дә, хәтта җырлап алырга да җаен таба. Ул инде бишмәтен башыннан гына бөркәнеп, киез каталарын эләктереп, бер-ике тапкыр ишегалдына да чыгып керергә өлгерде. Кергәч, кагына-кагына шаркылдап көлә генә: «Чистый пәри туе! — ди.— Куеныңа кияү генә кертәсе көн икән бу, әхри!» — ди. Әшәке, ничек теле әйләнә!

Юк, миңа да нидер эшләргә кирәк. Дөрес, һәрвакытта мине үзенә дәшеп-чакырып торган эшем-юанычым бар: ул — музыка, ул — залдагы пианино. Тик бүген ни сәбәптер ул да тартмый иде. Ләкин беләм — барып янына утырдым исә, минем кәефем үзгәрәчәк. Чәй яныннан торып, бүлмәмә мендем дә, халат урынына күлмәк киеп, залга төштем. Әтием гадәтенчә анда, креслосын тәрәзә яктысына тартыбрак, сары кәгазьгә тонык кына басылган газеталарны карап утыра иде.

Пианино янына килгәч, мин аңардан сорадым:

— Әти, мин сиңа комачауламыйммы?

Ул, газетасыннан башын күтәрә төшеп:

— Зарар юк, уйна! — диде һәм миңа сынап кына бер карап алды.

Аның шушы кыска гына карашы мине эчтән генә булса да куырылып куярга мәҗбүр итте, гүя ул барысын да күрә, белә, аңлый иде. Ләкин бервакытта да ни уйлаганын, шиген яки шелтәсен минем үземә туп-туры

әйтмәс. Бары әнием белән генә сөйләшә. Әйтергә теләгәнен әнием аша гына миңа җиткерә. Билгеле инде, кичә минем театрга баруым турында да алар арасында сүз булган, булырга тиеш — әтиемнең сынаулы карашы моны бик ачык сиздерде. Хәер, үткән эшкә салават дигәндәй, мин үзем өчен хәзер һич тә борчылмыйм, тик менә Салихка гына берәр зәхмәте тия күрмәсен дип борчылам. Әтиемнең бит бик хәтәр ягы да бар: шулай дәшми генә йөреп, берәр төрле карарга килсә, аны инде үләм дисәң дә үзгәртеп булмаячак. Ә бәлки әле, әнием аңа барысын да әйтеп тә бетермәгәндер — ана кеше, гадәттә, җитеп килгән кызын канаты астына ала инде ул!

Мин кулларымны клавишлар өстенә сак кына салдым. Ни уйныйм икән? Бармаклар үзләреннән-үзләре клавишларның әле берсенә, әле икенчесенә баса — нечкә һәм калын авазлар чыга. Авазлар әкренләп терелә, җанлана, авазлар бер-берсен ишеткән кошлар шикелле кушыла башлый. Тукта, нәрсә бу?.. «Сакмар» ич! Бик тә яраткан көем, шуңадыр инде, менә үзеннән-үзе килде дә чыкты. Бик артык сузмыйча, әмма борылышларын ничек тә өзмичә генә табигый итеп, нәфис-моңлы итеп уйнарга тырышам. Сүзләрен дә эчемнән генә кабатлап барам: «Үсәдер лә таллар Сакмар су буенда, үсәдер лә кызлар әнкәләре куенында». Әтием дә бик ярата бу көйне... Ул инде укуын да оныткандыр, газетасына караган булып кына тыңлап утырадыр. Әтиемнең күңеле таш түгел, ул мине, һичшиксез, ярата, хәтта минем белән горурлана да торгандыр әле... Әмма, әмма, әти, бәгърем, ни өчен син миңа карата бу кадәр саклык күрсәтәсең?.. Нидән шикләнәсең, ни ошамый сиңа?.. Зифа талдай үсеп җиткән кызыңның үз бәхетен үзе сайларга хакы юкмыни, әти, җаным бәгърем?!

Уйнап бетергәч, башымны иеп, тынып калдым. Кинәт күңелем тулды, шунда ук торып, чыгып китәсем килде. Ләкин тагын әтиемнән яхшысынмадым. Әллә аңа, әллә үземә ачуым килеп, яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль... Менә шулай! Ә авазлардан гамма хасил була, ди Салих... минем Салих абыем... Бармакларым йөрүдән туктады. Син, Салих, кулымны бәйлисең, син, Салих, күз алдымнан китеп тор әле!.. Яки кил, яныма утыр, сиңа ияреп уйнавы миңа шундый җиңел, шундый рәхәт!.. Ә болай булмый, булмый лабаса!.. Җитәр!..

...Кинәт кенә урынымнан кубып, як-ягыма да карамыйча, ашыгып чыгып киттем. Бүлмәмә менгәч тә тизрәк урын өстенә капландым. Шушы кирәк булган икән миңа,

җыелып торган яшьләрнең бәреп чыгуы кирәк булган икән... Әйдә, чыксын, чыгып кына бетсен!..

Ә төштән соң буран басылды. Бераздан Сабира да җилләнеп менеп җитте.

— Әйдә, ятма мыжып... Кар көрәргә чыгабыз! — диде ул, аягымнан ук тарта башлап.

— Тукта, нишлисең? Авырттырасың ич, тиле!

— Бигрәк черки тимәс чер итәр!.. Тор, тор, әйдә!

Ул җенледән котылып буламы соң — тордым тизрәк... Кухняга төштек тә, иске бишмәт, киез итекләрне киеп, бияләйләрне алып, ишегалдына чыктык. Әтием дә чыккан, сарай-каретник алларын көрәп йөри иде. Мин үземә агач көрәкнең җиңелрәген сайлап алдым. Башта капкага илтә торган юлны көрәдек, аннары, урамга чыгып, капка төбен көрәргә тотындык. Монда буран карны шактый калын салган икән, көри торгач бөтенләй кызарып, пешеп чыктык. Ә шулай да кар көрәү бик күңелле эш. Саф һава, өзлексез хәрәкәт бөтен сүлпәнлекне юа да төшерә. Бердән җиңеләеп китәсең. Аннары бит әле буран артының үзенә генә хас яме, хозурлыгы да бар. Табигать котырып-дулап алганнан соң ничектер хәлсезләнеп, юашланып кала. Тын, тымызык, бер чыбык та селкенми, шылт иткән тавыш та юк. Күк йөзе сыекланып, агарып, биекләнеп китә. Кар шикәрдәй ап-ак, чип-чиста, ә һава... чишмә суы кебек, эчеп тә туярлык түгел!.. Еш кына туктап, көрәкләребезгә таянып ял итәбез.

— Менә кып-кызыл әнис кебек булдың,— ди Сабира миңа.

— Ә үзең соң... пешкән чия кебек, чиртсәң каның чыгарга тора!

— Минем каным чыкканчы, синең җаның чыгар! — ди дә Сабира мине төртеп җибәрә.

Мин чак-чак егылмыйча калам, ә ул чыркылдап көлә! Аннары үзем аны ике куллап кинәт кенә төртеп җибәрәм. Сабира лып итеп карга утыра, ә мин аның өстенә ташланам.

— Кемнеке чыгар бит әле, кемнеке чыгар! — дия-дия, аны карга ничек тә тирәнрәк батырырга тырышам. Ләкин Сабира көчлерәк шул. Аяк-куллары белән мине читкә этәреп ташлый да күз ачып йомганчы өстемә менеп тә атлана. Малайларча итеп... Мин, котым алынып, ялвара башлыйм:

— Сабира, бу нишләвең, оятсыз! Тор, җибәр! Җибәр, дим! Әтием күрсә, ни әйтер?!

— Әтиең күрмәс! — ди Сабира, отыры үчекләп.— Ә менә Салихың күрсә, ни әйтер иде икән, ә, Гөләндәм туташ?! Син шуңардан куркасыңмы?

Салихың! Бу ни дигән сүз?.. Миңа шундый уңайсыз, оят булып китте ки, гарьләнүемнән күзләремә хәтта яшьләрем килеп тыгылды.

— Җибәр! — дидем мин, чак еламыйча.— Әшәке!

Сабира үзе дә минем хәлне сизеп алды булса кирәк, шунда ук аягына басып, мине дә тартып торгызды. Өстемне кага-кага, үзенчә юатырга да тырышты:

— Йә, йә, ачуланма, мин бит болай гына, уйнап кына инде, әхри!..

Мин дәшмәдем, дәшәрлек хәлдә түгел идем. Уйнапмы, чынлапмы, әмма бик җан җиремә кагылды ул минем. Соңыннан тынычлансам да, әкренләп аңа үпкәм басылса да, «Салихың» дигән сүзе, мине үртәгәндәй, бик озак колагымнан китмичә торды. Бик кадерле, бик яшерен серемне бер сүз белән гүя фаш итте дә куйды. Әнә шулай үтеп китте минем... буранлы көнем!

## X

Ахыр чиктә әтиемне дә урыныннан кузгаттылар. Бүген иртән — без әле чәйдән дә тормаган идек — урам комитетының әгъзасы Хәйретдин абзый, бер хәрби кешене ияртеп, безгә килеп керде. Сабира ишек ачарга чыккан иде, алданрак ашыгып керде дә шомлы гына итеп: «Килделәр!» — диде. Без тынып калдык, тик ишектән Хәйретдин абзый күренгәч кенә азрак тынычландык.

Күп кенә еллар Сәгъдиевләрдә кучер булып торган Хәйретдин абзый, иске гадәте буенча, әүвәл кычкырып сәлам бирде:

— Әссаләмегаләйкем, Әхмәтҗан абзый!

— Вәгаләйкүмәссаләм! — диде әтием, урыныннан торып.— Әйдүк, Хәйретдин!

Шунда ук аның артыннан итекләрен кага-кага кергән хәрби кеше дә күренде.

— Без йомыш белән генә, Әхмәтҗан абзый! — диде кучер.

— Алай икән, рәхим итегез, ни йомыш?

— Менә бу кәминдәнттән килгән иптәш үзе әйтер.

Ләкин сырма бушлат киеп, билен буган, наган таккан хәрби кеше сүзен әйтергә ашыкмады. Ул иң әүвәл ни өчендер безнең зал эчен дикъкать белән күздән кичерде, бары шуннан соң гына:

— Исәнмесез, хуҗа! — диде.

— Ә, үзебезнең мөселман кешесе икән әле,— диде әтием, куангандай.— Аллага шөкер, туган! Әйдәгез, түрдән узыгыз! Әзрәк яманлап йөрисез! Әнисе, кая, самаварыңны яңарт әле.

— Юк! — диде хәрби кеше, кулын күтәрә төшеп.— Чәйләп утырырга килмәдек, гафу!

Аннары итекләренә карап алды да бер читтәрәк торган урындыкка үрелде. Әтием аңа шунда ук урындыкны алып бирде. Шуңа утыргач, хәрби кеше башындагы кызыл йолдызлы соры солдат бүркен арткарак этәрә төште дә куеныннан урталайга бөкләгән бер дәфтәр тартып чыгарды. Әтием башта аның алдында нишләргә белмичәрәк торды, аннары үзе дә чигенебрәк бер урындыкка утырды.

Хәрби кеше өшегән бармаклары белән дәфтәренең битләрен көчкә генә ачкалап карарга тотынды.

— Исем-фамилиягез?

— Безнеңме?.. Әхмәтҗан булабыз, Әхмәтҗан Солтанов.

— Дөрес, Әхмәтҗан Солтанов! Ничә яшьтә?

— Тиздән илле биш тулачак, Алла боерган булса!

— Кайчан ул «тиздән»! Берничә көннән, берничә атнадан што ли?

— Юк, алай ук тиз түгел, кем, иптәш, туган!.. Язга, апрель аенда, Алла бирсә!

— Ә-ә, ерак икән әле! — диде хәрби кеше, иягеп чөеп.— Менә шулай, Әхмәтҗан абзый, бүген сез тимер юл комендатурасына барырга тиешсез.

Әтием сизелерлек агара төште.

— Ни өчен? Рәхим итеп, шуны әйтмәссез микән?

— Рәхим итмичә дә әйтәбез аны!.. Эшкә мобилизовать итәбез без сезне!

— Алай. Нindiрәк эшкә инде, белергә мөмкин булса?

— Кар көрәргә!.. Тимер юлны кардан чистартырга. Составлар үтә алмый тора, абзый кеше, шәһәргә утын керми, утсыз-сусыз калуыбыз бар. Положение шундый, халыкны мобилизовать итәбез!..

— Аңлашыла! — диде әтием. Ул инде шактый тынычланган иде, ләкин шулай да тамагын кыргалап яңадан сорады бит:

— Эһем-эһем... Мәҗбүри индеме бу?

Хәрби кеше әтиемә сәер генә карап алды:

— Ә сез ничек уйлыйсыз?

— Гафу итегез, туган, белмәгәнгә күрә генә соравым.

— Әллә эштән куркасызмы? — диде хәрби кеше, аны тыңламыйча.

— Юк, эштән курыкмыйбыз. Без эшләп өйрәнгән кеше.

— Байларда доверенный булып, шулаймы?

— Анысы соңыннан. Ә башта ат карап та йөк ташып дигәндәй...

— Менә бик әйбәт!.. Яңадан рабочий булып карагыз... Шулай, абзый кеше, сәгать уннан да калмагыз! Күрәгегезне дә онытмагыз, аннары үзегезгә бер өч күлмәк азык та алыгыз!

— Нигә? — диде әтием, аптырабрак.— Өйгә кайтырга мөмкин булмасмыни?

— Ераграк җибәрсәләр — булмас!

Хәрби кеше урыныннан торды, тагын ни өчендер зал эченә күз йөртеп чыкты. Яңа гына күргәндәй, миңа бик төбәлеп карады. Әйтәсе килмәгән шикелле, авыз эченнән генә «борчыдык!» дип куйды, аннары кычкыра биреп:

— Хушыгыз! — диде.

— Хушыгыз, хуш! — диде әтием, аларны озата чыгып.

Ул борылып кергәч, без барыбыз да берничә минут сүзсез генә утырдык. Бу хәлгә ничек карарга да белми идек. Бер яктан, хәвефләнергә урын да юк кебек, эшкә генә куалар, икенче яктан, әллә ничек хәвефле дә кебек —өеңә кире кайтармасалар, нишләрсең?!

Ахырда әтием башлап телгә килде:

— Ярар, баш салындырып утыра торган чак түгел, Аллага тапшырдык! Әнисе, әзерләнергә кирәк.

Әнием авыр гына сулап урыныннан торды.

— Ярый ла өч кенә көнгә булса!

— Юл чистарту белән генә эш бетсә, өч көнгә дә бармас. Вакыт күпме әле?

— Тугызынчы ярты,— дидем мин.

— Ике генә рәкәгать намаз укып алырга өлгерәм икән әле... Ашыгыйк. Чакырганнан иртәрәк бару хәерле.

— Нәрсәләр әзерлим соң? — диде әнием.

— Җылкы ите куярга онытма, ә калганын үзең кара!

Әтиемне калдырып, без өчебез дә кухняга чыктык.

Ә бераздан мин яңадан әйләнеп кердем. Әтием келәм өстенә намазлык җәеп тора иде.

— Ни кирәк, кызым?

— Саквояж кирәк иде.

— Нинди саквояж? — диде әтием, гаҗәпләнеп.

— Теге үзең белән йөртә торган саквояж... азыкларыңны салырга!

— Әй башсызлар, башсызлар! — диде әтием, ачынып.—Мәскәү байларына товарга бармыйм ласа мин!.. Бөрмәле капчыкка салыгыз барысын да, ишетәсеңме, бөрмәле капчыкка!

Анысы да табылды тагын... Ит-май, чәй-шикәр, ике бөтен икмәк, сөлге-сабын, яңа оекбаш — шуларның барысын да киндер капчыкка тутырып, бавын да тартып бәйләп куйдык. Ә бер ярты сәгатьтән әтием иске бишмәтен, иске

бүреген, олтан салган киез итекләрен киеп, билен яшел билбау белән буып, ике кат бияләйләрен дә кулына алып, әзерләнеп бетте. Чыгып китәр алдыннан утырып дога кылдылар, аннары әнием ашыгып киенә башлады.

— Син кая? — диде әтием.

— Озата барам.

— Кирәкмәс, әнисе, Себер җибәрмиләр ич.

— Әзрәк кенә булса да барыйм инде,— диде әнием, ялваргандай.

— Әзрәк кенә дисеңме?.. Әзрәк кенә ярый алайса! — диде әтием, гүя аны кызганып.

Алар чыгып киткәч, без Сабира белән икәү генә калдык. Кызык хәл!.. Әтиемнең элек юлга чыгып китүләрен ихтыярсыздан исемә төшердем (заманында Мәскәү, Петербург, хәтта Варшавага еш кына барып йөрде ул). Әмма ничек чыгып китә иде?! Бер көн алдан мунча кереп, сакал-мыегын төзәтеп куяр иде. Өстенә Петербург мастерларыннан махсус тектергән иң яхшы тройкасын кияр иде; жилет кесәсендә алтын чылбырлы сәгать, бармакларында — алтын балдаклар... Җәен — бостоннан теккән җиңел генә пальто, кышын — мех эчле тун... Ә вокзалга шәп ат җигелгән резин ходлы пролеткада гына илтеп куялар иде үзен! Әнә шулай аның китүе дә, кайтуы да безнең өчен бәйрәм генә иде, чөнки әтием барган бер җиреннән безгә кыйммәтле бүләкләр алып кайтмыйча калмый иде... Кайчан гына иде бит әле бу?! Заманның шундый кинәт, тиз үзгәрүенә исең-акылың китәр! Нишлисең, язмыштан узмыш юк, диләр. Тик шулай да авыр, эч поша, хәтта өебез дә бушап, күңелсезләнеп калгандай булды. Мин түгел, әнә Сабира да көенә.

— Абзый кызганыч! Юкка, үзем генә барыйм, дип әйтмәдем.

— Кит, җүләр, шундый куркыныч җиргә! — дим мин аңа, гаҗәпләнеп.

— Кемнән, нәрсәдән?

— Анда торганы ирләр генә ич!

— Ирләр үзләре миннән курыксыннар! — ди Сабира, гайрәтләнгән булып.— У-у, мин ул ирләрне!

Мин ирексездән көләм:

— Куырып ашар идең бугай!.. Ләкин әтием җибәрер иде дисеңме?

— Менә анысы дөрес! Җибәрәме соң?!

Мондый көнне һәм мондый чакта нәрсәгә тотынырга да белмисең. Ә кирәк, нindидер эш-хәрәкәт кирәк — шунсыз эч пошуын басып булмаячак. Сабира да шуны чамалап, ахрысы, әрле-бирле йөренде дә, миңа килеп:

— Әйдә, әхри, кер юабыз! — диде.

Әлбәттә, бу эш инде, ләкин мин кулларыма карыйм: эссе, сабынлы суда бер дә бозасым килми шул үзләрен... Сабира, очлы күз, шуны сизеп алды бит:

— Ә-ә, Салих әфәнде киләсе көнмени әле бүген? — дигән булды.

— Булса соң!

— Музикәл бармакларыгыз кызарыр бит, туташ!

— Җен, пәри, албасты! — дидем мин, кинәт кызып. Телеңне тартып кына өзәр идем мин синең!.. Әйдә, чыгар керләреңне, юабыз!

— Йә, йә, нәнәм, чәпчемичә генә! — диде Сабира, шунда ук мине юмалап.— Мин аңлыйм ич, барысын да аңлыйм... Син миңа булышырсың гына, яме?

Шулай итеп, без эшкә дә тотындык. Сабира керләрне чыгара башлады, ә мин утын керттем, су керттем. Плитәне ягып җибәрдек. Ул арада әнием дә кайтып керде. Кәефе начар түгел иде кебек. Без аңардан, кая кадәр озаттың, ни күрдең, дип сорадык.

— Печән базары чатына хәтле генә,— диде әнием.— Халыкны шактый күп җыйганнар икән, араларында бик могтәбәр кешеләр дә бар. Гаеткә барган шикелле төркем-төркем булып стансага таба киттеләр.

— Тәкбир әйтмәделәрме соң? — диде Сабира.

Әнием Сабираның көлеп сораганына каршы, ачуланыбрак:

— Юкка тотынгансыз бу эшкә! — диде.— Кеше озатканнан соң идән себермиләр, кер юмыйлар,— белергә кирәк иде.

Бу юлы инде Сабира дәшмәде. Көч белән баса-баса керен юа гына бирде. Мин инде кечкенә ялгашта үземнең вак-төяк керләремне генә юыштырдым. Кулларымны сакладым.

Ә кичкырын, билгеләнгән вакытта, Салих та килде. Әмма һич булмаган бер хәл — ул ишектән үк көлә-көлә килеп керде. Моңа мин бик гаҗәпләндем. Шулай да ул, яныма килеп кулымны кыскач, көлүеннән туктап, әдәп белән генә миннән сорады:

— Кәефегез ничек, Гөләндәм?

— Рәхмәт! Ә сезнеке?

Ул яңадан әкрен генә көләргә тотынды. Мин тагын аптырап калдым:

— Ни булды, ник көләсез?

Ләкин ул гадәтенчә көлеп туктагач кына ни булганын сөйли башлады:

— Беләсезме, әле сезгә килешли генә шундый бер кы-

зыкка очрадым. Барабызчы агай... (ул тагын әзрәк кенә көлеп алды), әйе, менә чикмән якасын күтәреп, урәчәле чанасына аягурә баскан барабызчы агай, дилбегәсен болгый-болгый, Мәскәуски буйлап чаптырып килә. Артында моның бер мөселман абзый бөрешеп кенә утырып бара. Кызу чапкан ат чатка җиткәч кинәтрәк борылды, ахрысы — бу абзый чанадан очып төште дә калды. Ә барабызчы шуны сизмичә атын куа да куа. Урамдагы кешеләр аңа төрле яктан: «Әй, Гыйбад, юлчыңны төшереп калдырдың бит!» — дип кычкыралар, сызгыралар, ә агайның гамендә дә юк, борылып та карамыйча китте дә барды... Инде күз алдыгызга китерегез (ул тагын көлә башлады), агай... агай теге абзый әйткән җиргә барып җиткәч, атын туктатып, борылып караса, пассажиры юк, пассажирдан җилләр искән! Йә, кызык түгел диегез?!

Кызык икән шул, ләкин мин нигәдер көлә алмадым. Бары:

— Теге очып төшкән абзый үзе торып, артыннан йөгермәдемени? — дип кенә сорадым.

— Кая йөгерсен! — диде Салих, батист яулык белән күзен, маңгаен сөрткәләп.— Ул, бичара, түгәрәк, юан гына бер кеше — онга баткан таракан шикелле көрткә чумды. Кемдер тартып чыгарды үзен! — Салих шунда ук җитдиләнеп, тирә-ягына каранып алды.— Гафу итегез, ә әтиегез кайда соң?

Мин икеләнебрәк калдым: әйтергәме-юкмы? Юл чистартырга җибәрделәр, дип әйтүе ничектер кыен да, оят та кебек иде. Шуңа күрә:

— Әтием өйдә юк шул әле,— дию белән генә чикләндем.

— Алайса безнең дәрескә кайтып өлгерер,— диде Салих, елмаеп кына.

— Белмим тагын... бәлки, бүген кайтмас та. Аны бит эшкә җибәрделәр.

— Әх, шулаймыни?! Кая, нинди эшкә инде?

Ләкин минем кыенсынып торуымны күргәч, ул бераз гаҗәпләнеп өстәде:

— Хәер, әйтмәсәгез дә була!

— Юк, ни өчен? — дидем мин, уңайсызланудан ашыгып.— Әтиемне начар эшкә җибәрделәр.

Салих миңа туры гына карап, иңбашын җыерып куйды:

— Эшнең авыры була, хәтта пычрагы була, әмма начары була микән? Бер дә ишеткәнем юк, Гөләндәм!

— Соң... тимер юл чистарту, сезнеңчә, яхшы эшмени инде ул?

— Авыр эш. Бигрәк тә Әхмәтҗан абзый кебек өйрәнмәгән кешегә.

— Менә шул шул! Олы кеше дип тә тормадылар!

— Алай икән!.. Күрәсең, шулай кирәк булгандыр инде, башкача мөмкин булмагандыр... Ләкин сез артык борчылмагыз, Гөләндәм. Әхмәтҗан абзыйга күмәк халык арасында әллә ни авыр булмас, яшенә карамастан, таза кеше ич ул!

Мин дәшмәдем, минем бу хакта сүзне тизрәк бетерәсем килә иде. Ләкин Салихның әйтер сүзе бетмәгән икән әле.

— Беләсезме, Гөләндәм,— диде ул, аз гына тынып торганнан соң,— шәһәрнең хәле бик авыр бит! Азык юк, ягулык юк, юллар җимерек. Без менә йөргәч күрәбез: мәктәпләр ягылмый, лазаретлар ягылмый, ә анда бит мәҗрүх солдатлар ята. Билгеле инде, яңа власть ничек кенә булса да шушы авыр хәлне җиңеләйтергә тырыша. Ләкин аңа халыкның ярдәме кирәк, Гөләндәм, аңлыйсыңмы?

Әлбәттә, бик аңлашыла, бигрәк тә Салих шулай гади генә төшендереп тә биргәч, тик миңа бу хакта сүз алып баруы читен иде. Шуңар күрә мин бары: «Аңлыйм, Салих абый!» — дию белән генә чикләндем.

— Менә бик әйбәт! — диде ул, ләкин шулай да сорады: — Йә соң, чибәрем, бүген нишлибез, сабак укыйбызмы, әллә калдырып торабызмы?

— Юк, нигә калдырырга? — дидем мин, гаҗәпләнебрәк.— Мин бит сезне көнозын көтеп тордым!

— Шулай укмыни?! Утырыштык алайса!

Бу юлы пианино янына ул үзе башлап утырды. Ләкин уйнарга ашыкмады. Миңа таба борылып, сер әйткәндәй әкрен генә:

— Гөләндәм, мин сезгә бүген ике гаҗәеп нәрсә китердем бит әле,— диде.

— Нәрсә икән ул? — дидем мин, шунда ук кызыксынып.

— Ашыкмагыз, хәзер белерсез... Ләкин башта шуны әйтәсем килә: без моңарчы гел халык көйләрен, ягъни чыгаручысы билгесез булган көйләрне уйнадык. Ә бүген мин сезгә чыгаручысы мәгълүм булган ике көй уйнап күрсәтәчәкмен.

— Андыйлар да бармыни?

— Бар шул! Берсен аның сез дә белергә тиешсез. Бу — Заһидулла абзый Яруллин тарафыннан язылган «Тукай маршы». Ма-рш! — аңлыйсызмы?

— Беләм, ишеткәнем дә бар.

— Ул халык арасына бик тиз таралды. Без дә аны еш кына уйныйбыз.

— Заһидулла абзый үзе дә сезнең оркестрда уйнаган түгелме соң?

— Әйе, баштарак уйнады. Аны «Сәйяр»ның беренче музыканты дияргә була. Тукай, Галиәсгар абзый, Кариевлар белән якыннан аралашкан кеше. Аннары мине дә рояль телләренә басарга башлап ул өйрәтте. Минем беренче хәлфәм!

— Шулаймыни? Күптәнме?

— Шактый вакыт узды инде аңа.

— Сез үзегез аны эзләп таптыгызмы?

— Дөресрәге, ул мине «тапты»!

— Кызык бу, сөйләгез әле!

— Сөйләсәм, озакка китмәс микән?! — диде Салих, ак маңгаен ышкып.— Кыскасы, болай булды. Малай чактан ук минем бармакларым тик тормый иде инде. Апам миңа кечкенә гармун алып бирде — мин шуны ничектер ансат кына тарткаларга да өйрәндем. Ә безнең җизнигә —безнең җизнине беләсезме икән, Шиһап Әхмеров, китапханә тотучы — менә аңа гел генә әдипләр, шагыйрьләр килеп йөриләр иде. Шул җөмләдән Заһидулла абзый да бездә еш кына була торган иде. Мин, билгеле, алар алдында кечкенә тальянымны кычкыртмый идем. Әйтергә кирәк, ни өчендер кешеләрдән яшеренеп, ялгыз гына уйнарга ярата идем. Шулай да Заһидулла абзыйның сизгер колагы минем каралтылар артына посып гармун тартуымны ишетеп алган бит! Бер ишетә бу, ике ишетә, аннары мине чакыртып алып, үзе алдында уйнарга куша. Ә мин, тиле, аяк терәп киреләнәм, оятка калудан куркам, янәсе... Тик җизни кыстагач кына уйнап күрсәттем. Шуннан соң Заһидулла абзый җизнигә әйтә, синең бу каенишеңә Ходай бик сизгер бармаклар биргән икән, Шиһабетдин әфәнде, чынлабрак шөгыльләнергә кирәк үзе белән, югалып калмасын, ди. Малайда нидер барын без үзебез дә чамалый идек, ди җизни дә. Менә шул сөйләшүдән соң озак та үтми, безнең мәгърифәтле җизнәбез ничектер туры китереп, бер тотылганрак рояль дә сатып ала. Бу синең өчен, Салих, ди ул миңа. Беләсезме, Гөләндәм, моның кебек зур бүләкне минем күргәнем дә юк һәм яңадан күрүемә ышанмыйм да. Көннәр буе мин шул көзгедәй ялт иткән, эченә әйтерсең дөньяның бөтен сихри авазларын җыйган мәһабәт, кара, өч аяклы «өстәл» тирәсендә генә әйләнә торган булдым. Менә шул чакта инде Заһидулла абзый мине рояль алдына утыртып, бер изге эшкә керешкәндәй бисмилласын әйтеп, рояльнең ак-кара телләренә басарга да өйрәтә

башлады. Һәр көн диярлек үзе теләп, бары мине өйрәтү өчен генә (әлбәттә, бернинди мөкяфәтсез!) махсус килә торган иде бу җаны-тәне белән музыкага бирелгән гаҗәп кеше! Ихтимал, шул чакта мин музыканың аңа бөтен гомерен дә, йөрәген дә багышлаган кешеләр эше генә булуын аңлап та калганмындыр!

Салих тынды, минем аңа туп-туры карап утыруыма уңайсызлангандай, башын бераз гына читкә дә борды. Ә мин карамыйча булдыра алмыйм, чөнки аның сүзләрендә һичбер төрле фальшь юк, үзен-үзе күтәрергә, күрсәтергә тырышу юк — барысы да бик табигый һәм бик гади, чөнки аның өчен музыка бары чын мәхәббәт эше икән! Димәк, бернинди ясалу-кыланууларга мохтаҗ түгел ул!

— Инде рәхим итеп, хөрмәтле Заһидулла абзыйның «Тукай маршы»н уйнап карыйк! — диде ул, мине уйларымнан айнытып. Ләкин мин, аңа башларга ирек бирмичә, тиз генә сорадым:

— Ә сез Тукайның үзен күрдегезме?

— Күрдем, бәгырь, күрдем!

— Кайчан, кайда?

— Безгә, җизни янына килгән чагында.

— Әйтегез әле, ниндирәк кеше иде ул?

— Бик зур кеше иде, бәгырь!

— Мин аның шагыйрьлеген әйтмим, ә кыяфәткә ничегрәк иде, дим... Имеш, ул буйга кечкенә, арык кына бер кеше булган, диләр, дөресме шул?

— Дөрес, әмма буйга бик озын кешеләр дә аның алдында түбәнчелек белән башларын ияләр иде,— диде Салих, хәйләкәр генә елмаеп.

— Мин чынлап сорыйм, ә сез көләсез! — дидем мин, әзрәк үпкәлисем килеп.

— Юк, мин көлмим,— диде ул, шунда ук җитдиләнеп.— Хикмәт аның буендамыни, Гөләндәм?!

— Әлбәттә, түгел! Ул кадәресен генә мин дә аңлыйм инде. Ә сезгә аның белән сөйләшергә туры килдеме?

— Тукай минем белән сөйләштеме дип сорамакчысыз — шулаймы? Ул миннән дәүрәк иче!

— Гел шаяртасыз, Салих абый!

Ләкин Салих нидер үзенекен уйлый башлаган иде, ахрысы,— дәшми калды. Тик бераздан гына ул шундый ук уйчанлык белән:

— Мин бер нәрсәне бик ачык хәтерлим, Гөләндәм! — диде.— Көннәрдән бер көнне миңа, ниһаять, аның алдында да уйнарга туры килде. Билгеле, Заһидулла абзыйның бик нык кыставы аркасында гына, югыйсә мин үзем һич тә җөрьәт итә алмаган булыр идем. Чөнки бу

махсус Тукай өчен, ул ишетсен дип уйнату иде. Әле башка кунаклар да бар — алар да көтәләр. Үзенә күрә бер имтихан дисәм, һич тә артык булмас!.. Уйнаган чакта мин моны бөтен җаным-тәнем белән дигәндәй сизеп тордым, ә ул, Габдулла абый, йомшак диван башында бөрешеп кенә шылт та итмичә тыңлап утырды. Ул инде бик сырхау иде... Бер көйне уйнап бетергәч тә кунаклар шаулашып миңа: «Менә афәрин, менә рәхмәт, шәкерт!» — диештеләр. Ләкин мин Габдулла абыйның тавышын ишетмәдем — ул үзенең почмагында һаман шулай тын гына, хәрәкәтсез генә утыра бирде. Әмма ул минем яңадан уйнавымны көтә иде, мин моны ничектер йөрәгем белән сиздем... Һәм аның өчен генә тагын ике көй уйнап чыктым. Шуның соңгысы — «Әллүки» иде.

Салих ни өчендер кинәт кенә пианино өстенә иелә төште һәм көттеребрәк, әкрен генә: «Менә шул!» — дип әйтеп куйды. Мин дә бер мәлгә сүзсез калып, тынып тордым. Аннары сак кына сорадым:

— Әмма соңыннан ул сезгә ни дә булса әйткәндер бит?

— Ишетмәдем, бәгырь, ишетмәдем! Уйнап бетергәч тә мин торып чыгып киттем — әйтерсең бизгәгем кузгалды, качтым тизрәк! Балалык инде... Шулай да Габдулла абый нидер әйткән булырга тиеш, чөнки шактый вакыттан соң, ул үзе үлгәч инде, Заһидулла абзый миңа бер сүз чыкканда әйтә куйды: «Бел, Салих, син Тукайның фатихасын алган кеше!» — диде. Гаҗәп зур йөк бу минем өчен, әгәр чын булса?!

— Чыгып китмәгән булсагыз, аның фатихасын үз авызыннан ишеткән булыр идегез,— дидем мин.

— Ә бәлки, чыгып китүем кирәк тә булгандыр?!

— Ни өчен?

— Чын дөресен шәкертнең үзеннән бигрәк хәлфәсенә әйтәләр гадәттә!

— Шәкерт күңелен табу да кирәк бит!

— Зарар юк. Йә артык масаеп киткән булыр идем. Ә масаю ул вак, көнче кешеләр эше. Ярый, Гөләндәм туташ, сүз бозау имезер, ди, әшкә кучик, булмаса!

— Мин тыңлыйм, Салих абый!

Салих пианинога тартылыбрак утырды, кулларын җәя төште, ләкин башлап киткәнче әүвәл шуны әйтте:

— Тукайның үлеменә карата җыр туарга тиеш иде — тумыйча калуы мөмкин түгел иде. Һәм ул җыр туа — шагыйрьнең бик яраткан музыканты Заһидулла абзый Яруллин күңелендә туа ул җыр!.. Башта Заһидулла абзый җырын «Тукай хатирәсе» дип атый, ләкин озак та үтми, әзрәк үзгәреп, «Тукай маршы»на әйләнеп китә.

Сүзләренә игътибар итегез:

Ташладың син безне, Тукай,
мәңгелеккә ташладың.
Син хәзер дөньяда түгел,
үзгә хәят башладың*.

Үзгә хәят!.. Халык күңелендә мәңге яши башлау!.. Инде тыңлагыз!..

Гадәттә нәфис-йомшак кына уйнаган Салих бу юлы кулларын киң җәеп, батыр-көчле итеп башлады. Хәтта үзе дә бераз арткарак каерыла төште. Һәм музыка да, үзенең остасын тапкандай, ничектер бик куәтле булып яңгырады.

— Ишетәсезме, бәгырь? — диде Салих, дәртләнеп уйныйуйный.— Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, ул аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас! Ә менә бу җирендә — тыңлагыз әле, тыңлагыз! — ниндидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?! Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык — ишетәсезме сез шуны?!

Әйе, ишетәм мин, ишетәм! Ишетү генә түгел, әллә нинди бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсым да килеп китте. Музыка һәм халык икесе бергә кушылса, бик тирән яткан тойгыларны да кузгата икән ул! Аннары минем Салихтан: «Сез дә шушының кебек музыка яза алыр идегезме?» — дип сорыйсым килә, ләкин куркам, бик яшерен теләгенә (әгәр шундый теләге булса) саксыз орынудан куркам!

Ике тапкыр уйнап чыккач, Салих туктады һәм, хәлсезләнгәндәй иңбашларын салындыра төшеп, бераз тынып торды. Аннары миңа урын биреп:

— Инде сез уйнап карагыз! — диде.— Нотасыз гына — нотасын язып килергә өлгерә алмадым.

— Юк,— дидем мин,— сездән соң уйнарга кулым бармый, кыстамагыз!

— Ник?

— Шулай инде, җөрьәт итә алмыйм... Ә сез миңа икенчесен дә уйнап күрсәтегез әле, булмаса!

— Ярый алайса,— диде Салих һәм бер иңбашын сәер генә сикертеп куйды да яңадан пианино каршысына тартылыбрак утырды.— Икенчесе... икенчесе, Гөләндәм, романс булачак!

---

* Бу юлларны миңа шагыйрь Нури Арсланов исенә төшереп язып бирде.— *Ә.Е.*

— Романс?! Чынлап әйтәсезме?

— Әлбәттә! Башта марш иде, ә хәзер — романс! «Мәхәббәтем» дип атала.

— Кызык! Кем язган соң аны?

— Уфа җырчысы Фәттах Латыйпов! Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй шигырен ул нотага салган, диләр... Хуш, ничек әле үзе? — Ул сүзләрен исенә төшереп, әкрен генә җырлап карады: — Тормыш синсез — җилле диңгез, күз карам! — һәм шуңа ялгап уйнап та китте.

Әйтәсе дә түгел, бу моңарчы без белгән, без уйнаган көйләрнең берсенә дә охшамаган иде. Яңгырашы, агышы бөтенләй яңача, колак ишетмәгәнчә!.. Һәм сүзләре дә бик сәер — ничек кенә дип әйтергә? — әллә нинди шашыну, өзгәләнү бар сүзләрендә:

Миннән ник качтың?
Күккә ник аштың?
Ник сөйдең дә ник
Тәмугка аттың?..

Көе дә сүзләренә бик туры килә икән — шундый ук тирән сагыш, әрнү, йолкыну ишетелеп тора үзеннән. Кыскасы, ошады миңа бу романс!

Уйнап бетергәч, Салих миннән сорады:

— Йә, ничек соң, бәгырь?

— Ә сезнеңчә ничек? — дип сорадым мин үз нәүбәтемдә.

— Мин — гашыйк! — диде Салих, бер генә сүз белән.

— Шулкадәр үк әйбәтмени?

— Көнләштерерлек дәрәҗәдә!.. Әмма шунысы зур куаныч — бездә, ниһаять, чын музыка туа башлады бит!.. Менә сиңа марш, менә сиңа романс!.. Ләкин болар әле беренче карлыгачлар гына... Болар артыннан бер заман симфонияләр, хәтта опералар туа башлар!.. Фатих абзаңның «Фәтхулла хәзрәт»тә язганнары коры хыял гына булып калыр дисеңме әллә?! Татар операсын ул үзе күрәчәк әле, насыйп булса!

— Кайдан сездә бу кадәр ышаныч?

— Вакыты җитте, Гөләндәм, вакыты!

— Әмма ләкин кешесе дә кирәк ич әле... Композиторларың кайда?

— Алары да булыр!.. Милли азатлык нәрсә өчен соң ул?! Безнең ише изелгән халыкка юл ачу дигән сүз түгелмени? Ә талантлар табылачак, бар алар!

Минем тагын аңардан: «Бәлки, сез дә музыка яза башларсыз әле?» — дип сорыйсым килде, ләкин бу юлы да ни өчендер тыелып калдым. Дөресен генә әйткәндә, мин

инде эчке бер сизенү белән аның оста уйнаучы гына булып калмаячагын, иртәме-соңмы үзе дә музыка яза башлаячагын сизә идем. Тик менә үзенең бу хакта һичбер сүз әйткәне юк. Хәтта ялгыш кына да...

— Йә, «Мәхәббәтем» бик ошагач, үзегез дә уйнап карагыз инде,— диде ул миңа.

Бу юлы мин баш тартмадым. «Мәхәббәтем»не күңелемдә чакта уйнап карыйсым килде. Салих торып бер читкә китте, мин әкрен генә башладым. Юк, болай түгел шикелле... Ничегрәк соң әле? Тукта, менә болай... Әйе, әйе, нәкъ шулай!.. Көйне әйбәт кенә «тотып», ишетептоеп, шуңа тәмам бирелеп-дәртләнеп, уйнап чыктым ахырда үзен!.. Хәтта Салихның артыма килеп басканын да сизмәдем. Бары колагыма бик якын иелеп, назлыйомшак кына пышылдап:

— Гөлгенәм, мин хәйран! — диюен ишеткәч кенә сискәнеп киттем. Аның җылы сулышы ачык муеныма тиде — мин, үбә, ахрысы, дип, бер мизгелгә бөрешеп, өнсез булып калдым. Ләкин ул... үпмәде, яныма утырып, сул кулымны ике учына алды да, күзләремә карап, яңадан кабатлады:

— Мин хәйран!.. Сез, акыллым, мелодияне шулкадәр тиз тотып аласыз... мин ни әйтергә дә белмим. Талант, чын музыкаль талант — бары шул гына!

— Арттырасыз, Салих абый! — дидем мин, сөенечемнән балкып.

— Һич юк! — диде ул, җитди генә.— Арттырырга яратмыйм, аннары мондый нечкә эштә арттырырга ярамый да. Беләсезме, мин сезне бер бик әйбәт музыка әһеле белән таныштырам әле.

— Кем ул?

— Әхмәтсолтан Габәши...

— Ә ни өчен мине аның белән таныштырмакчы буласыз?

— Күрсен, уеныгызны ишетеп карасын. Ул бик укымышлы кеше, музыканы бик яхшы белә... Үзе... бик сөйкемле дә,— диде Салих, елмаебрак.

— Юк, кирәкми, таныштырмагыз... Йә гашыйк булып куярмын! — дидем мин дә, сүзне уенга борасым килеп.

— Эһем-эһем! — дип, тамак кыргалады Салих.— Мин каршы түгел, лаек кеше!

— Шулай да мин теләмәсәм?

— Барыбер таныштырам!

— Ни өчен соң? Нигә кирәк ул?

— Кирәк, бәгырь, кирәк! Сезнең үзегез өчен кирәк!

— Ә минем менә беркем белән, хәтта бик әйбәт, бик сөйкемле кеше белән дә танышасым килми.

— Бу нинди кирелек? — диде Салих, кинәт ачуланган булып.— Ахыр чиктә сез, туташ, мине тыңларга тиешсез. Онытмагыз — мин сезнең хәлфәгез!

Ә минем юри киреләнәсем килә, чынлап үпкәләр микән дип сынар өчен генә киреләнәсем килә:

— Әгәр тыңламасам?

— Ул чагында мин сезгә җәза бирәчәкмен!

— Нинди җәза?

Салих инде көлеп җибәрүдән чак тыела иде, шулай да кашларын җыера төшеп, әйткән булды:

— Мин сезне, туташ, сандык күтәртеп, әнә почмакка бастырып куярмын!

Инде мин ирексездән көлеп җибәрдем:

— Ү-ү, сандык бик авыр ич ул! Безнең сандыкларны дүртәр кеше генә күтәрә ала!

— Ә мин,— диде Салих, көлә-көлә,— күршегездәге мәдрәсәдән берәр шәкертнең таракан оялап беткән кечкенә сандыгын алып чыгармын да шуны эчендәге бөтен чүп-чарлары белән сезгә күтәртермен!

— Әбәү, кирәкми, юк-юк, тараканнардан бик куркам! —дидем мин, кулларымны бала шикелле селтәп.

Икебез дә күзгә яшьләр килгәнче рәхәтләнеп бер көлештек. Ниһаять, көлешеп беткәч, Салих миңа, үзеннән-үзе хәл ителгән мәсьәлә турында искә төшергәндәй:

— Ярый, Гөләндәм, Солтан абый белән кайчанрак очрашуыбызны мин сезгә хәбәр итәрмен,— диде.— Ә хәзер рөхсәт итегез, миңа китәргә вакыт!

— Нигә бик тиз?

— Егетләрем көтә! — Аннары иелә биреп әкрен генә әйтте: — «Мәхәббәтем»не онытмагыз!..

...Әтием өйдә булмагач, бу юлы мин аны үзем озата чыктым. Тышкы ишек төбендә безнең ара күкрәк күкрәккә тияр дәрәҗәдә бик якын калган иде, мин стенага елыша төшеп, нидер көткәндәй ирексездән, хәтта сулышымны бүлеп, тынып тордым. Ләкин Салих миңа орынмады, бары сул кулымны каты гына кысты да колагыма шыпырт кына: «Хуш, Гөлгенәм!» — диде һәм шунда ук ашыгып чыгып та китте. Мин дә, әллә үкенечтән, әллә сөенечтән, тирән генә бер көрсенеп, тизрәк өйгә ашыктым.

Салихны озаткач, бераздан өчәү генә кичке чәйгә утырдык. Әтием юк, әтием кайдадыр юл чистарта. Ни хәлдә йөридер инде ул, бичара?! Әнием күңелсез, ләкин тыштан сабыр — ул бер дә уфтанырга яратмый. Минем дә, кинәт вөҗданым уянгандай, җаным сыкранып куйды: әтием шундый хәлдә чакта мин монда берни булмагандай романс өйрәнеп ятам. Ярыймы, килешәме бу?..

Хәер, әллә ни хәсрәткә тарырлык хәвеф юк та кебек, ә шулай да күңел борчыла, эч поша.

Чәйдән соң үз урыннарыбызга таралыштык. Өй эче тып-тын, йоклап кына үткәрә алмаслык кышкы төн — нишләргә?.. Иренеп кенә чишендем дә, җылы-йомшак урыныма ятып, Купринның «Аң»да татарча басылган «Сүләмиф»ен укый башладым. Бик матур, бик шигъри язылган әсәр, ләкин ни сәбәптер йотылып кына укый алмыйм — уйларым мине һаман каядыр читкә алып китәләр. Уйларым да әллә нинди — ни башы, ни ахыры юк, бик биектән аккан кучмә болытлар шикелле килә торалар, китә торалар... Аптырагач, журналны ташлап, урынымнан торам, лампаның филтәсен басып, тәрәзәгә киләм. Җаным тыныч түгел, җаныма нидер кирәк минем... Ә тышта гаҗәеп тын, сыек-зәңгәр төн, кеше эзе төшмәгән ап-ак чиста кар... Ә биек салкын күктә яңа гына туган нечкә ай!.. Тын гына, серле генә сызылып тора ул!.. Бу минем яңа, унтугызынчы елга кергәч, беренче тапкыр күргән яшь аем! Нәрсә вәгъдә итә ул миңа, ни көтә мине киләчәктә? Ел озын, ел хәвефле, туасы һәм туласы айлар күп,— ни буласын алдан белүләре бик читен шул миңа, бик читен!.. Ә син дәшмисең, серле, салкын аем, дәшмисең?!

## XI

Салих мине Печән базары чатында көтәргә тиеш — без шуннан Большой театрга, аларның репетицияләренә китәчәкбез. Тиз тотты Салих бу эшне... Әле үткән атнада гына, Солтан Габәши белән таныштырам, дип әйткән иде, инде менә ай-ваема куймыйча мине алып та бара. Музыкантлар белән танышу, музыка дөньясына керү минем өчен бик кирәк, ди ич! Әлбәттә, шулайдыр, тик мин уңайсызланам, әзрәк кенә куркам да, чөнки... бик яңа дөнья бит әле ул минем өчен! Ахыры хәерле булсын, энием әйтмешли!..

«Печән базары» дигәнебез ул асылда Евангилистовский урамы дип атала. Бик киң урам булганга күрә, анда элек-электән үк сала халкы печән сата. Халык теленә кергән исеме дә шуннан киткән, билгеле. Бу чыкылдап торган татар оясы, әмма шул урамда, ягъни Евангилистовский белән Захарьевский чатында, зур гына ак чиркәү дә бар. Ә тирә-юнендә вак кына мәчетләр...

...Бүген русларның берәр бәйрәмедерме — чиркәүнең тимер ишеге киңенчә ачык, баскычының ике ягына да карт-коры, гарип-гораба саилчеләр җыелган. Мин килеп җиткәндә, Салих шул саилчеләрдән аз гына читтәрәк,

башын кырынрак салып тик кенә басып тора иде. Янына ук барырга кыймыйча, аптырабрак туктадым. Ләкин егетем үзе мине күреп алды да ашыгып яныма килде.

— Кичерегез! — диде ул, уңайсызланыбрак.

— Нишләп тора идегез анда, саилчеләр янында? — дидем мин, гаҗәпләнүемне яшермичә.

— Садака эләктерер өчен түгел инде,— диде ул, көлеп.—Чиркәү хорын тыңлый идем... шәп җырлыйлар, шайтан алгыры!

— Әллә яратасыз?

— Мин барысын да тыңларга яратам, Гөләндәм, хәтта чәүкәләр хорын да!.. Ә көлмичә генә әйткәндә, чиркәү хоры үзенә бер зур сәнгать бит ул!.. Гасырлар буенча эшләнеп килгән сәнгать, шуңа күрә аны тыңлау һич тә язык түгел!.. Киттекме?

Без Болак күперенә таба атладык. Салих, сүзен дәвам итеп, миңа төрле диннәрнең музыка сәнгатен гомумән бик оста файдаланулары, кайчандыр Себастьян Бах, Моцарт кебек бөек композиторларның гыйбадәтханәләр өчен махсус музыка язулары турында бераз сөйләп барды. Ахырдан:

— Тик безнең мәчетләр генә музыкадан мәхрүм,— диде, көрсенеп.— Шәригать дигән нәрсә мәчеткә курай белән сорнайны гына керткән булса да, дин әһелләре музыкага бу кадәр тискәре карамаслар иде. Ә шуның аркасында без күпме артка калдык!

Минем нишләптер кинәт сорыйсым килде:

— Сез азан әйткәнне тыңларга яратасызмы?

— Әйе, бигрәк тә кичке азанны... Авылда тыңлаганым бар, кояш баеган чакта... Гаҗәп сагышлы, моңлы ишетелә шул чакта кичке азан! Гүя фани дөньядан аера ул сине, уйлар, өметләр — барысы да бик кечерәеп кала. Тик соңыннан бик ямансу булып китә, тизрәк үзебезнең шушы гөнаһлы дөньяга әйләнеп кайтасы килә... Дөнья кызыклырак бит, Гөләндәм?!

Шулай иркен генә сөйләшкәләп атлый торгач, без Большой театр алдына да килеп җиттек. Тагын ниндидер икеләнү мине ишек төбендә тукталырга мәҗбүр итте. Салих та туктады.

— Әллә нигә... кыенсынам,— дидем мин, аның сораулы карашыннан уңайсызланып кына.

— Ни өчен тагын?

— Анда... кешеләр күптер.

— Минем музыкант иптәшләрем генә,— диде Салих. Аннары кулымдагы котик муфтамны йомшак кына сыйпап, көйсез баланы юаткандай көлә-көлә өстәде: — Песи, песи, пескәем, ягез, йә, курыкмагыз, усал этләр юк анда!

— Үзегез дә юмалый беләсез тагын! — дидем мин дә, ирексездән көлеп.

Без театрның караңгырак алгы коридорына кердек. Аны узгач, Салих мине икенче каттагы, тәрәзәләре урамга караган кечерәк бер фойега алып менде. Монда өч кеше бар иде. Икесе рояль янында үзара сөйләшеп утыра, ә берсе алардан шактый читтә, күкрәгенә терәгән скрипкасына башын кырын салып, смычогының очы белән генә бик әкрен нидер уйнап тора иде... Салих мине алар белән таныштыра башлады.

— Бу Мөхәммәт абый Яушев,— диде ул, иң элек скрипка уйнаучыны күрсәтеп.— Ә бу Фәйзи Биккинин — һәм скрипкачы, һәм гармунчы. Бусы инде минем малай чактан ук дустым Мансур Мозаффаров дигән егет була.

Алар өчесе дә, түбәнчелек белән башларын иеп, кулымны кыстылар.

— Гөләндәм туташ! — диде Салих минем өчен.— Сезгә аның хакында әйткәнем дә бар.

— Әйе, ишеткән идек,— диештеләр егетләр, ә Мөхәммәт абый дигәне шунда ук миңа урын да тәкъдим итте:

— Утырыгыз, туташ!

Бу кечкенә буйлы абый яшь ягыннан арада иң өлкәне булса кирәк, борын төбендә генә бер чеметем кара мыегы да бар, ләкин үзе бик җиңел сөякле кешегә охшаган. Бер генә минут та тик торуны белмидер кебек, хәтта чем-кара күзләре дә!.. Ак чырайлы Биккинин да шулай ук буйга кечкенә, гәүдәгә юка гына бер кеше, әмма табигате белән башка — сабыр, басынкы, бер дә тегенең кебек очынып тормый... Ә Мансур дигәннәре бөтенләй япьяшь, үсмер малайлыктан чыгып килгән егет кенә, үзе бик оялчан да булса кирәк, минем белән күрешкәндә нәкъ кызлар төсле ияк очына кадәр кызарды.

Мин дә, беренче минутларда үземне шактый бәйле хис итсәм дә, ничектер бик тиз тынычландым. Абыйлар гади, тәкәллефсез иделәр, миңа артык исләре китеп, күз елтыратып тормадылар. Шунда ук үзара сөйләшә башладылар, көлешеп тә алдылар — күренә, араларында дуслык, бердәмлек нык булса кирәк. Тагын бер нәрсәне сизмичә калмадым: Салихка үз, якын итеп кенә түгел, ә өстенрәк бер кеше итеп, хөрмәт белән дә карыйлар икән.

— Солтан абый килмәдемени әле? — дип сорады Салих егетләрдән.

— Килеп җитәргә тиеш,— диде Мөхәммәт абый.— Әллә башлый торабызмы?

— Азрак көтик,— диде Салих, аннары миңа борылып

әйтте: — Солтан абыйга яңа әзерләгән көйләребезне уйнап күрсәтмәкче булабыз. Сез дә менә бер уңайдан тыңларсыз.

Алар үзләренең шушы кечкенә оркестрларында кайбер татар көйләрен полифония нигезендә, ягъни төрле тавышта, уйнаячаклар икән. Бик матур килеп чыга, имеш. Көйнең мелодиясе ничектер яңарып, бизәкләргә баеп, хәтта яңгырашы да көчәеп китә, ди. Һәм бу яңалыкны оркестрга беренче башлап Салих үзе керткән икән.

Шул арада ишекне әкрен генә ачып, тагын бер кеше тавыш-тынсыз гына килеп керде. Керү белән өстендәге пальтосын салып, урындык башына иләп кенә бөкләп куйды. Шунда гына иптәшләре аны күреп алдылар.

— Менә ич үзе дә!

Димәк, шушы икән Әхмәтсолтан Габәши! Әйтергә кирәк, ул минем игътибарымны шунда ук үзенә бәйләп өлгерде. Ни хикмәттер, бу да кечкенә буйлы иде (әллә музыкантлар барысы да бер калыптан төшкәннәр инде), әмма башкалардан бөтен килеш-килбәте белән бик нык аерылып тора. Зур башлы, калку маңгайлы, карасу йөзле, гәүдәсе озынрак, ә аяклары кыскарак та кәкрерәк, атлаганда үрдәк шикелле чайкалыбрак атлый. Кыскасы, аны һич тә чибәр кеше дип әйтеп булмый. Ләкин аның бөтен кыяфәтеннән бик саф күңелле кешеләргә генә хас садәлек, самимилек, һәм шуларның чагылышыдай үзенә бер мөлаемлык бөркелеп тора. Бигрәк тә зур күзләре нәкъ сабыйларныкы төсле бик ачык, бик эчкерсез карыйлар, тик аларның төбендә генә ниндидер бер яшерен моң-сагыш чагыла кебек... Калын иренле авызы да аның тартынып, кыюсыз гына елмаядыр шикелле...

Менә ул ашыкмыйча гына иптәшләре янына килде, һәркайсы белән кул биреп күреште. Мин бер читтәрәк тора идем. Ул миңа таба да борылды һәм Салих шунда тиз генә:

— Бу Гөләндәм туташ була,— диде.

Солтан абый, каршыма килеп, сүз әйтмичә генә кечкенә кулын сузды. Бары шуннан соң гына:

— Сез Салихның шәкертеме? — дип сорады.

— Әйе,— дидем мин, нигәдер каушабрак.

— Ишеткән идем, Салихтан күп нәрсәгә өйрәнергә була,— диде ул, бик гади генә итеп.

Ләкин Салих көлеп кенә үз сүзен әйтергә ашыкты:

— Сез, Солтан абый, мине алай бик күтәреп җибәрмәгез әле, чебешләрне көз көне саныйлар ич!

— Мин ышанып әйтәм.

— Әмма мин бер нәрсәдән канәгать,— диде Салих,— Гөләндәм туташ белән шөгыльләнү минем үзем өчен дә бик файдалы.

— Шулай булырга тиеш тә. Өйрәтү — өйрәнү дигән сүз ул, бигрәк тә музыкада!

Миңа калса, Солтан абый бик мәгънәле сүз әйтте кебек, ләкин ул аны шундый гади итеп, гүя очраклы рәвештә генә әйтте ки, башкалар моңа әллә ни игътибар да итмәделәр шикелле. Һәм шунда ук алар үз эшләре турында сөйләшә башладылар. Мин, бер читтәрәк утырып, аларның сүзләреннән шуны аңладым: февраль азакларында артистлар һәм һәвәскәрләр катнашы белән зур бер кичә үткәрелергә тиеш икән. Бу кичәне комиссар иптәшләрнең соравы буенча мәҗрүх кызыл гаскәриләр файдасына үткәрәчәкләр икән. Элек, ягъни большевикларга кадәр, мондый кичәләр еш кына була торган иде. «Шәрык кичәсе» дип әйтәләр иде аларны... Хәзер исә ничек дип атарлар — бу кадәресе ачыкланып бетмәгән икән әле, һәрхәлдә, исем мәсьәләсен шул ук комиссар иптәшләр хәл итәргә тиешләр, имеш...

Кыскасы, бу да шул «Шәрык кичәсе» сыманрак милли уеннар, танцалар белән үтә торган зур бер әдәби-музыкаль кичә булачак. Бәлки әле, милли ашлар да булыр — әгәр буфет ачарга азыгын-төлеген тапсалар... Кичәдән җыелган бөтен акча, ишеткәнемчә, мәҗрүх кызыл гаскәриләр файдасына китәчәк. Шуның өстенә акчалата һәм әйбергә иганә җыю да булачак икән (мәсәлән, хатын-кызларның җылы оекбашлар, бияләй-перчаткалар бәйләп китерүләрен бик өмет итәләр икән)... Әнә шундый зур бер эш алда тора, имеш.

Кичәнең җыр-музыка өлешен әзерләү Солтан абый Габәшигә йөкләнгән икән. Музыкантлар бүген шуның өчен җыелганнар булып чыкты. Алар бу эшкә гаять зур дәрт белән тотынганнар — сүз бит кызыл гаскәриләргә ярдәм итү турында бара!.. Салих үзенең оркестры белән шул кичә өчен махсус программа да әзерләгән — бүген шуны Габәшигә уйнап күрсәтәчәкләр. Ләкин көтәсе кешеләре бар икән әле. Ихтимал, шуңа күрәдер, сүзләре беткәч тә, Солтан абый миңа таба борылды һәм, сөйкемле генә елмаеп:

— Әллә туташны тыңлап карыйбызмы? — диде.— Салих, сез рөхсәт итәрсез бит!

— Мин — рәхәтләнеп,— диде Салих, тиз генә.— Әмма туташ үзе ни әйтер?!

— Гөләндәм туташ... шулай бит әле? — диде Солтан абый, миңа мөрәҗәгать итеп.— Гөләндәм туташ, эш сездән тора... Уйнап күрсәтсәгез, без бик мәмнүн булыр идек.

— Һай, юк! — дидем мин, кинәт балаларча куркынып...

— Ни өчен? — диде Солтан абый, гаҗәпләнүдән каш-

ларын күтәреп.— Ни гаебе бар аның? Сез уйный беләсез, ә безнең тыңлыйсыбыз килә, шулай бит, әфәнделәр?

Иптәшләре беравыздан:

— Бик дөрес! — диештеләр.— Туташларның рояльдә уйнавын безгә бик сирәк ишетергә туры килә.

— Ишетәсезме?.. Йә, килегез, утырыгыз!

Дәү абыйлар шулай ихлас белән сорагач, киреләнеп тору, әлбәттә, килешмәячәк. Шулай да мин әле икеләнә идем — ни әйтсәң дә, үзенә күрә бер сынау ич бу!.. Уйный алмасам, нишләрмен?! Хәер, уйнавын уйнармын да бит, тик абыйлар ни әйтерләр?.. Яныма Салих килде һәм, гадәтенчә, йомшак, әмма нык кына итеп:

— Ягез, кыюрак булыгыз! — диде.

— Әллә ничек, кинәт кенә,— дидем мин, уңайсызлануымны яшермичә, ә үзем рояль янына атладым.

— Ә сез ашыкмагыз!

Иплә утыргач, кулларымны клавишлар өстенә салып, аз гына уйланып тордым.

— Ни уйныйм соң?

— Күңелегезгә ни килсә, шуны! — диде Солтан абый.

Башка аккорд алып, шуннан яхшы белгән көемне — «Яз да була»ны уйный башладым. Музыканың бер кодрәте шунда ки, кулларың инструментка тию белән ул сине инде үзенә тәмам буйсындыра һәм ничегрәк итеп уйнарга да үзе үк куша. Тик ишетә бел дә тоя гына бел! Кыскасы, мин әйбәт кенә уйнап чыктым шикелле. Абыйлар шылт та итмичә тыңладылар һәм уйнап бетергәч тә бер сүз дә әйтмәделәр. Алар гүя дәвамын көтәләр иде. Мин яңадан бер кыска көй һәм бер озынрак көй («Һаваларда йолдыз»ны) уйнадым.

Уйнап бетергәч, абыйларга таба борылырга курыккандай, күпмедер вакыт кузгалырга кыймыйча утырдым. Бары Солтан абыйның җиңел генә сулап «Рәхмәт, туташ!» диюен ишеткәч кенә урынымнан тордым. Салих исә сүзсез генә иелеп, минем кулымны үпте. Ә Мөхәммәт абый Яушев, тәмам җанланып:

— Юкка гына, туташ, ялындыргансыз икән! — диде.— Сезгә кушылып, үземнең скрипканы хәтта сыздырып җибәрәсем килде!

Мин, әлбәттә, шат идем, оча алуына сөенгән күбәләктәй шат идем, тик сүзем генә юк, сүз әйтерлек көчем дә юк...

Аз гына паузадан соң, Солтан абый:

— Сез, туташ, әйтергә кирәк, көйне шактый нечкә тоеп уйныйсыз, Салихның үзе кебегрәк,— диде, үпкәләтмәстәй генә көлемсерәп.— Уңыш телим сезгә, тик укуыгызны ташлый күрмәгез!

Аннары ул Салихка таба борылды:

— Салих, туташны безнең кичәгә чакырганда яхшы булыр иде бит. Ничек уйлыйсыз?

— Минемчә дә начар булмас иде,— диде Салих, миңа мәгънәле генә күз атып.

Инде Солтан абый минем үземнән сорады:

— Туташ, сез каршы түгелсездер бит?

Мин әле сүзнең ни турыда барганын аңлап та бетерми идем, шуңа күрә беркатлылык белән бары:

— Килә алсам,— дип кенә куйдым.

— Юк, сез тәгаен әйтегез, безгә алдан белеп торырга кирәк.

— Нигә ул?

— Без бит сезне үзебезнең кичәдә катнашырга чакырабыз.

Мин аптырап киттем: кичәдә катнашырга?! Була торган эшме соң бу? Әллә шаяртып кына әйтәләрме?.. Ә Салих... Салих ни диде соң?.. Мин аптыраудан ни әйтергә белмичә тордым, тик бераздан гына, башымны кат-кат чайкап:

— Юк, мөмкин түгел бу,— дидем.

— Ни өчен? Нәрсә тыя сезне? — диде Солтан абый, йомшак кына итеп.

Ләкин бит мин аларга, эти-әниемнән куркам, дип әйтә алмыйм. Моның хәзер бик көлке тоелуы мөмкин.

Әмма икенче бер җитди сәбәп тә бар бит әле: кем булып кына катнаша алам мин андый зур кичәдә? Һәм тизрәк шуны әйтергә дә ашыктым: кичерегез, дидем, мин үземнең кем булып катнашуымны һич тә күз алдыма китерә алмыйм, дидем.

— Нигә, менә бүгенге кебек рояльдә ялгыз уйнарсыз,— диде Солтан абый, бик гади генә итеп.— Татар кызы рояльдә соло уйный! Бу бик яңа нәрсә булачак.

Мин ни әйтергә дә белмәдем. Шуннан Солтан абый Салихка мөрәҗәгать итеп сорады:

— Салих, сез туташның укытучысы, ялгыз уйнавына ничек карыйсыз?

— Минемчә, иртәрәк әле, Солтан абый,— диде Салих.— Сәхнә шартларында уйнар өчен зур тәҗрибә кирәк, аннары, безнең тамашачылар да андый нәрсәне ишетеп өйрәнмәгән әле... Туташка авыр булыр!

«Рәхмәт, дустым»,— дидем мин, эчемнән генә сөенеп.

— Ә оркестрга кушылып берничә көй уйнаса? — диде Солтан абый.

Аның бу сүзен Мөхәммәт абый да куәтләп җибәрде:

— Менә бу ярый торган фикер!..

— Ләкин бит аның өчен шактый репетиция үткәрергә

кирәк булачак. Ә вакытыбыз бик чикле,— диде Салих, уйланып, аннары, кинәт нидер исенә төшкәндәй, һич көтмәгәндә өстәде: — Әмма туташның тагын бер мөмкинчелеге бар әле: ул матур гына җырлый да!

Ах, бу Салихны!.. Нигә кирәк булды моны әйтү, нигә? Хур итә ич инде мине, Ходаем!

Ләкин башкаларга аның әйткәне җитә калды.

— Шулаймыни? — диде Солтан абый, чынлап куангандай.— Менә бик әйбәт! Туташ бездән бу сәләтен дә яшермәс, иншалла!.. Шулаймы, Гөләндәм туташ, сез җырларсыз бит безгә?

— Мин җырчы түгел, Салих абыйга ышанмагыз! — дидем мин, ирексездән дорфа гына итеп.

— Җырчы түгел, ягъни сәхнәләрдә җырлап йөргән җырчы түгел... Анысына без дә ышанабыз. Салих та алай дип әйтмәде, минемчә... Җырлый аласыз, диде ул, һәм без моңа да ышанабыз. Сездә моң бар, слух бар, тик хикмәт тавышта гына... Тавышыгызны да ишетик инде, туташ!.. Аннары, сез һич тә борчылмагыз, без барыбыз да монда үз кешеләр, бер гаилә дип әйтерлек. Гаеп итү юк, димәк, хафаланырга урын да юк.

— Белмим, белмим,— дидем мин, ике кулым белән битемне учлап. Әмма сизәм — Солтан абыйның шундый үз итеп әйткән сүзләренә каршы торырга да көчем җитмәс кебек. Ә алар көтәләр, сабыр гына, әдәп белән генә көтәләр... Нишлим соң, Ходаем?

Ул да булмый, Салих рояль янына тәвәккәл генә килеп утырды да:

— Мин уйнасам, җырлый ул! — дип, кулларын җәеп, иркен-җиңел, әмма гадәтенчә йомшак кына итеп уйный да башлады: — Сезнең яраткан көегез, Гөләндәм!

Әйе, бу минем яраткан көем... «Мәдинәкәй» иде. Хәер, эш яратуда гынамыни?! Салихның куллары рояль телләренә тию белән әйтерсең йөрәк кылларына килеп кагылды һәм мин чарасыздан диярлек аңа иярдем:

Карлыганнан кара ай кашларың,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч.
Бөрлегәндәй кызыл йөзләрең.
Шикәрләрдән тәмле, балдан татлы,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең...
.............................................

Әле кыймылдаган кеше юк, сүз әйткән кеше дә юк — мин дә җырымны яңадан кабатладым.

Бу юлы инде җырлап бетерүем булды — кемдер арттан:

— Афәрин, туташ,— дип кычкырып та куйды.

Мин хәтта сискәнеп киттем. Артыма борылып карасам, ишек төбендә генә тулырак ак йөзле, зур гына соры күзле бер кеше басып тора. Кем ул? Күрәсең, мин җырлаган чакта сиздермичә әкрен генә кергәндер инде, чөнки башкалар да аның тавышын ишеткәч кенә борылып карадылар. Һәм берничәсе, куанышып:

— Ә, Кәрим! Кәрим абый! — диделәр.

Ул кеше исә аз гына чайкала биреп безнең янга килде дә туп-туры миңа кулын сузды:

— Туташ, мин болар кебек музыка әһеле түгел,— диде кабаланыбрак,— шуңа күрә сүземне алдан әйтеп калырга ашыгам: матур, моңлы җырладыгыз, миңа бик ошады, ихлас! Комплимент дип уйламагыз, әмма үзегез дә Мәдинәкәй кебек кара кашлы, зәңгәр күзле икәнсез! — Һәм ул каты гына итеп минем кулымны кысты.

Мин аяк очыма кадәр кызардым, ә ул, берни булмагандай, башкалар белән күрешә башлады. Аннары яңадан миңа таба борылды:

— Гафу итегез, туташ! Ашыгып, исемегезне сорарга да оныткунмын... Татарлык!.. Кем дип беләбез инде?

Ләкин мин телгә килгәнче, Солтан абый әйтеп өлгерде:

— Безнең гаеп, Кәрим, без таныштырырга тиеш идек. Бу — Гөләндәм туташ була.

— Гөләндәм?.. Чибәр исем!

— Салихның шәкерте. Фортепьянода уйный... Танышу йөзеннән без әле менә туташны уйнатып та, җырлатып та карадык.

— Бик хуп! Зинһар, дәвам итә күрегез!.. Мин дә бик вакытлы килгәнмен икән.

Шулай диде дә, тыңларга җыенгандай, бер читкәрәк китте. Мин инде аның, «Кәрим» дигән исемен ишеткәч тә, кем булуын чамалаган идем. Нык, базыграк гәүдәле бу җитез кеше чынлап та Кәрим Тинчурин булып чыкты. Даны таралган артист һәм әдип!..

Ләкин, кызганычка каршы, мин аның алдында җырлый алырлык хәлдә түгел идем инде. Әллә ничек берьюлы бушап, тугарылып калдым. Җырласам да, рәтле-юньле чыкмасын сизеп торам. Шуңа күрә, абыйларның көтеп торуына карамастан, уңайсызланып кына:

— Кичерегез, артык булдыра алмыйм,— дидем дә әкрен генә рояль яныннан киттем.

Минем хәлне башлап Солтан абый аңлады булса кирәк.

— Ярый, әфәнделәр, туташны ирексезләмик! — диде һәм, аз гына уйланып, минем үземә шуны әйтте: — Сез

җырлый аласыз... Дөрес, тавышыгыз бик көчледән түгел, әмма йомшак-ягымлы, сулышыгыз да шактый иркен... Ихтимал, көчлерәк тә җырларсыз... Кыскасы, Салих белеп әйткән: сезнең сәхнәгә чыгып җырларлык чамагыз бар...

Аннары ул шунда ук Кәрим Тинчуринга мөрәҗәгать итте:

— Кәрим, без Гөләндәм туташны үзебезнең кичәгә чакырып торабыз. Сез ни диясез?

— Бик мәслихәт! — диде Тинчурин, урыныннан торып.— Туташны сәхнәдән җырлатырга мөмкин, бик мөмкин.

— Ишетәсезме, моны сезгә Кәрим абыегыз әйтә!

— ...Әлбәттә, билгеле бер хәзерлек кирәк булачак,— дип өстәде Тинчурин.— Үз тарафымнан мин туташка кыюрак булырга киңәш итәр идем — сәхнә кыюлыкны ярата ул!

— Инде, туташ, сезнең сүзне ишетик. Ни әйтәсез? — диде Солтан абый, миңа ягымлы гына карап.

Ни әйтим?.. Рәхмәт әйтеп кенә баш тартыргамы? Юк, бу бик зур сансызлык булыр кебек. Шундый мөхтәрәм абыйлар ышанып дәшәләр ич!.. Аннары, гаҗәп мавыктыргыч та бит әле ул — сәхнәгә чыгып җырлау... Нинди генә татлы хыяллар уятмый ул синдә?! Һәм мин инде күңелемнән риза булырга да әзер идем, әмма ләкин менә хәзер үк шул «риза» дигән сүзне әйтергә ничектер җөрьәт тә итә алмыйм. Бик хәтәр, бик четерекле бер эш булып тоела ул миңа.

Ахырда, шактый көттереп, мин:

— Кичерегез, Солтан абый, хәзер генә бер сүз дә әйтә алмыйм, уйларга вакыт бирегез,— дидем.

— Яхшы! — диде ул, килешеп.— Уйлагыз, без сезне ашыктырмыйбыз... Инде риза булсагыз, репетиторыгыз янығызда, бергәләп тагын берничә көй әзерләрсез. Салих, ишетәсезме?

— Ишетәм, Солтан абый! — диде Салих, дәртле генә.— Тыныч булыгыз, туташның ризалыгын да алырмын, көйләрен дә әзерләрмен.

Шуның белән сүз бетте, мин китәргә җыена башладым. Бүлмәдә кешеләр дә күбәйде, шуларның берничәсе хатын-кызлар иде.

— Кая ашыгасыз? — диде Салих, гаҗәпләнебрәк.

— Вакыт, Салих абый, вакыт! — дидем мин, чынлап та каядыр ашыккандай. Ә дөресен генә әйткәндә, аларның репетициясендә ят бер кеше булып утыруны ничектер килештермәдем.

Салих минем хәлемне аңлады булса кирәк, артык кыстап тормады һәм урамга чаклы озата да чыкты.

Театр ишеге төбендә тукталгач та, мин аңа чын үпкә белән:

— Салих абый, сез мине нинди читен хәлгә куйдыгыз,— дидем.— Шулай ярыймыни инде?

— Ник,— диде Салих, бер дә исе китмичә генә,— мин бит сезне таныштырырга дип алып килдем. Башта ук әйтеп.

— Таныштыру шушы буламыни?.. Белмәгән, күрмәгән кешеләр алдында мине уйнарга да, җырларга да мәҗбүр иттегез.

— Әйе, таныштыру нәкъ шушы була инде. Шуның өчен китердем дә мин сезне музыкантлар янына.

— Ә нигә сез миңа аны алдан әйтмәдегез?

— Алдан әйткәч, сезне китереп буламыни?! — диде Салих, эчкерсез көлеп.— Сез бит ни... сары песнәк кебек, чак кына хәтәр сизү белән очарга гына торасыз.

— Бу чаклы да хәйләкәр булырсыз дип һич тә уйламаган идем. Ярый, мин дә моны бер исегезгә төшерермен әле, менә әйтте диярсез!

— Гөлгенәм! — диде Салих, күзләремә карап.— Әллә чынлап та үпкәлисез инде?

Мин дәшә алмадым. Минем инде үпкәм дә эреп беткән иде. Нигәдер бик якын, кадерле булып китте ул миңа шушы минутта.

— Сез керегез инде,— дидем мин, борчылып.— Салкын тидерерсез, яланбаш кына чыккансыз!

— Хушыгыз алайса! — диде ул, кулымны кысып, һәм җибәрмичә торып, әкрен генә өстәде: — Шушы йомшак кулыгызның җылысы шималь суыкларыннан да саклаячак мине, Гөләндәм!

— Әйтмәгез! — дип кенә пышылдый алдым мин һәм, башымны иеп, тиз генә китеп бардым... Бераздан түзмичә артыма борылсам, ул, кышкы салкынны һич сизмәгәндәй, минем тарафка һаман карап тора иде әле...

## XII

Ах, әгәр дә мин ул кичәгә катнашуның ахыры ни белән бетәсен алдан белгән булсам! Хәер, бу мөмкин дә түгел иде. Чөнки мин гел бер юнәлештә, бары бер нәрсә турында гына уйландым: катнашыргамы-юкмы?.. Яшь кенә тәҗрибәсез башыма бу да артыгы белән җиткән иде.

Әйе, нишләргә миңа — катнашыргамы-юкмы?

Бер караганда, сәхнәгә чыгып җырлауның әллә ни куркынычы юк та кебек. Җырлыйлар ич минем кебекләр!

Шундый ук ике куллы, ике аяклы һәвәскәрләр, тик Ходай биргән тавышлары булгач, чыгалар да җырлыйлар. Миңа да бит — кемнәр диегез, Габәши, Тинчурин кебек абыйлар! — сез, туташ, җырлый аласыз, дип әйттеләр. Шулай булгач, ник тәвәккәлләмәскә?!

Хуш, тәвәккәлләп чыктым да ди. Ялан кадәр якты сәхнә уртасында ялгыз берүзем басып торам, ә караңгы залдан без шикелле йөзләрчә күзләр миңа төбәлгән: «Йә, чибәркәй, тыңлап карыйк әле сине дә»,— дигән төсле, буй-сыныңны, кигән киемеңне, һәрбер хәрәкәтеңне тикшереп күзәтеп торалар. Юк, куркыта бу мине, куркыта!.. Алла сакласын, әгәр шуннан тавышың бетеп куйса яки җырыңны онытып җибәрсәң? Залда пышылдау, көлү башланса, өстәвенә берәрсе сызгырып та җибәрсә — күз алдыгызга китерәсезме?.. Бу бит бер мизгел эчендә җимерелеп төшү, тәмам хур булу, сәхнәдән чыгып качу дигән сүз булачак. Ә мине чакырган, миңа күпмедер өмет баглаган дәү абыйлар ни әйтерләр?.. Йөземә күтәрелеп карарга да кыймаслар, ник чакырдык бу җебегәнне дип эчләреннән генә үзләрен тиргәрләр (ихтимал, кайберәүләр, мәсәлән, Солтан абый, юаткан да булыр, әмма ләкин аңардан миңа ни файда — ояты, хурлыгы барыбер кала ич!). Ә Салих... Салих ни уйлар, ниләр кичерер?.. Шуны гына уйласам да, йөрәгемә бозлы салкын йөгерә... Юк, иртә әле миңа тәвәккәлләргә, иртә! Җитмәгән әле аның вакыты, җитмәгән!..

Мин инде әтием-әнием турында әйтеп тә тормыйм. Алдан рөхсәт сорауның һич мәгънәсе юк — билгеле, авыз да ачтырмаячаклар. Соңыннан белсәләр, өйдә зур җәнҗал кубачак. Аларның унҗиде яше дә тулмаган бердәнбер кызлары каядыр артистлар арасына барып, сәхнәләргә чыгып җырлап йөрсен, имеш! Бу аларның котын алачак. Бигрәк тә әтием моны кичермәячәк һәм хөкеме каты булачак аның!.. Иң әүвәл ул мине Салихтан аерачак. Берәр сылтау табып, әдәп белән генә аны безгә килеп мине укытып йөрүдән туктатачак. Йә, минем өчен моңардан да зур җәзаның булуы мөмкинме соң?!

Әнә шулай йокысыз төннәр, курку-шикләнүләр, башка капканчы уйланулар, хәтта, аптырагач, шыпырт кына елап та алулар... Ходаем, нигә болар? — тотарга да: «Юк, булмый!» — дип кенә әйтергә иде бит. Ә мин, шуларның берсенә дә карамастан, риза булдым да куйдым. (Күрәсең, теләк куркудан көчлерәк!) Әмма беләсез инде, моның төп сәбәпчесе минем... гаять үзсүзле дустым Салих булды. Ул үгетләде, ул кыстады, ул, ниһаять, күндерде. Гаҗәп, аның өчен бөтенесе бик ачык та бик гади иде: шикләнү —

ни дигән сүз ул?! Солтан Габәши кебек кеше белмичә чакырамыни? Үзеңә ышанырга кирәк, бәгырь, ышанырга! — шунсыз сәнгать бусагасыннан атлап керергә дә ярамый. Кайчагында таланты кечкенә, чамалы гына кеше дә үз-үзенә чамасыз ышану аркасында сәнгатьнең, түренә үк җитмәсә дә, ишеге төбеннән шактый ерак уза. Шик — көя ул, аңардан үзеңне ашатырга ярамый. Аннары ул, Салих, минем янымда булачак, миңа аккомпанировать итәчәк бит. Аңлыйсызмы сез шуны, Гөләндәм? ди ул миңа.

Инде әти-әнидән курку мәсьәләсенә килгәндә — ни әйтергә? Иске хорафатлар җимерелгән бер вакытта бу әллә ничек көлке дә, аяныч та. Дөрес, әти-әниеңне тыңлама, дип әйтергә теләми ул, әмма изге эш, күркәм эш өчен әзрәк тартышырга да кирәктер ләбаса!.. Юк, ул музыкант дусларына: «Гөләндәм туташ әтисеннән курка!» — дип әйтмәячәк. Беләсезме, нинди сылтау табачак ул? Бик җитди рәвештә: «Туташны Әлдермеш* егетләре урлап киткәннәр!» — дип кенә әйтәчәк.

Әнә шулай кызартты, көлдерде һәм ахыр чиктә җиңде мине бу, Әлдермеш егетләренә биргесез, Салих Сәйдәшев дигән егет!

Шулай да мин ризалыгымны тик бер шарт белән генә бирдем: исемемне афишада чыгармаска.

— Кечкенә мәсьәлә,— диде Салих, ничектер бик тиз килешеп.— Матур җырласагыз, исемегез икенче көнне үк бөтен шәһәргә таралыр.

Хәзер инде һәртөрле шик-шөбһәләрне бер читкә ташлап, «матур җырлар» өчен нык кына әзерләнергә кирәк иде. Салих миңа өч көй тәкъдим итте: берсе Солтан абыйга җырлап күрсәткән «Мәдинәкәй», икенчесе — «Сакмар» (моны мин үзем дә җырларга яратам), өченчегә тагын бер җиңелрәк көй, мәсәлән, «Исле гөл»не әзерләргә кушты. Һәм ул килгән саен, йә дәрес алдыннан, йә дәрестән соң, без аларны кабатлый торабыз. Әтием элекке кебек безне хәзер саклап утырмый. Теге вакытта юл чистартып кайтканнан соң гадәтен бераз үзгәртте — дөньяга чыгып йөри башлады. Әзрәк кешеләр белән аралашасы, кемнәр ни сөйләгәнне ишетәсе килгәндер инде. Ә сүз безнең көннәрдә күп, бик күп, тыңлап кына бетерерлек тә түгел... Дөрес, хәзер власть башына тагын кем менәр икән дип шомланып көтүләр бетте шикелле. Һәрхәлдә, чехлар киткәннән соң кире кайткан большевиклар властьны кулларында нык

*Казаннан ерак түгел бер авыл исеме. Халкы бик чая булган диләр.— *Ә.Е.*

тоталар булса кирәк. Шәһәрдә үзенә күрә иминлек, тәртип-тынычлык. (Хәер, Салихның әйтүенә караганда, тынычланырга иртәрәк икән әле. Бөтен җирдә фронт, бөтен яктан аклар һөҗүм итеп маташа, кызыл гаскәр шуларга каршы каты сугышлар алып бара, ди. Анысы шулай инде, сугыш барганда чын тынычлык буламыни ул?!)

Аннары әтиемне чыгарга, йөрергә мәҗбүр иткән икенче бер җитди сәбәп тә бар: соңгы вакытларда азык-төлек табулары бик читенләште. Беркайда бернәрсә сатылмый — кибетләр күптән ябылып бетте. Теләсәң кайдан тап!.. Ярый әле, Казанның Печән базары бар, бөтен алыш-биреш шунда икән хәзер, билгеле, ачыктан-ачык түгел, әмма итәк астыннан җаның теләгән нәрсәне табып була, диләр. Әтием дә менә шуннан онын-ярмасын, итен-маен дигәндәй табып китерә. Акчага аламы, әйбергә алыштырамы — ул кадәресен мин белмим дә. Монда әле үз кайгым да үземә бик җиткән.

Кыскасы, без репетировать итәбез — Салих уйный, мин җырлыйм. Тик артык иркенәеп кенә булмый, чөнки өйдә әни бар, аңа сиздерәсебез килми. Болай тыелып кына җырлау, тыелып кына сөйләшүләр Салихны да канәгатьләндерми иде. Шуңа күрә ул мине бер-ике мәртәбә театрга да чакырды. Анда инде чын репетиция ясадык. Солтан абзый, кат-кат җырлатканнан соң, миңа гадәтенчә ипләп, ашыкмыйча гына бик урынлы киңәшләрен бирде. Җырларга өйрәтү дә бик кирәк нәрсә икән ул. Үзем дә сизәм: ничектер иркенәеп, көчәеп киткәндәй булды минем җырлавым! Аннары Кәрим абый да мине кайбер «артистлык сәнгатенә» кызу гына өйрәтеп алды. Сәхнәгә ничек килеп чыгарга, ничек чыгып китәргә — шуларны үзе үк күрсәтеп бирде. Җырлаганда кулларыгыз камчы шикелле асылынып тормасын, менә болай тотыгыз, җан булсын аларда, диде. Каушап калмас өчен залның беренче рәтләренә карамаска, ә түренә карарга кушты. Хәтта, җырлап беткәч, алкышлауларга каршы матур гына итеп баш иярга дә күрсәтеп бирде. Үзе ул боларның барысын да гаҗәп оста эшли белә иде.

Иң ахырдан өстемә нәрсә кию турында да сүз булып алды. Кәрим абый бер дә тартынмыйча буй-сынымны махсус күздән кичерде дә:

— Сезнең, туташ, фигурагыз бик сылу, күз генә тимәсен, тик менә буегыз гына сәхнә өчен кечерәк икән,— диде.— Өстегезгә тар гына озын күлмәк, аякларыгызга биек үкчәле туфли, ә башыгызга кечкенә энҗеле калфак кисәгез яхшы булыр. Сез биегрәк һәм тагы да сылурак булып күренерсез.

Мин, кызарып кына:

— Ярый, Кәрим абый, мин сез кушканча киенергә тырышырмын,— дидем. Әнә бит ул сәхнәгә чыгуның нинди серләре дә бар!

Ә берничә көннән соң минем күптән күренмәгән дус кызларым — Әҗем Мөршидәсе белән Аит Мәрьяме көтмәгәндә безгә килеп керделәр. Кызарышканнар, тыннарын көчкә алалар — ни булган боларга, дип аптырый калдым.

— Ишеттеңме, ахирәткәй,— диде Мөршидә, ишектән керүгә,— «Шәрык кичәсе» булачак икән ләбаса!

Ә-ә, эш әнә нәрсәдә икән!

— Шулаймыни,— дидем мин, кызыксынган булып.— Кайдан белдегез?

— Менә әле генә Мәскәүский чатында афишасын укыдык.

— Күптән булганы юк иде ич мондый кичәнең,— диде Мәрьям.— Бәлшәвикләр вакытында бу беренче генә әле. Әллә иске заман кайта инде?!

— Кайтыр сиңа, көтеп тор! Мәҗрүх кызыл гаскәриләр файдасына дигән ич.

— Алай икән, соң нәрсәләр булачак ул кичәдә? — дип сорадым мин, ваемсыз гына.

Мөршидә белән Мәрьям, бер-берсен бүлә-бүлә, кабаланып тезә дә башладылар:

— Ике бүлектән зур концерт!

— Соңыннан милли уеннар, сәгать өчкә кадәр танцы!

— Конфетти белән серпантиннар!

— Иң оста биючеләргә бүләкләр биреләчәк!

— Һи, бик күп икән! — дидем мин, чынлап гаҗәпләнгәндәй.— Ә концертына кемнәр катнаша, язмаганнармы?

— Без белгәннәрдән Фатыйма Гумерова, Әшрәф Синяева, Ситдыйк Айдаров, Мохтар Мутин...— дип санап китте Мөршидә.— Без белмәгәннәр дә күп, алары һәвәскәрләр булса кирәк.

Шөкер, афишада мин юк икәнмен, булсам, иң элек дөнья шаулатып шуны әйтерләр иде.

— Тагын нәрсә?

— Тагын «Салих Сәйдәшев тәхте идарәсендә милли оркестр уйнап торачак» икән.

— Аны бик чибәр егет диләр, иеме Мөршидә?

— Күргәнем бар,— диде Мөршидә, эре генә.— Болай ничава үзе. Әтисе читек каючы булган диме шунда.

Сүзне Салих тирәсеннән тизрәк читкә борасым килде:

— Йә, тагын, кызлар?

— И, әйтергә дә онытып торам — буфетта милли аш-

лар да булачак икән,— диде Мөршидә, аеруча җанланып; камыр ашларын бик ярата торган иде ул.

— Менә монысына мин бик үк ышанып та бетмим,— диде Мәрьям.— Мондый хәерче вакытта азыгын каян тапсыннар?

— Комиссарлар таба, җаным, кирәксә, җир астыннан да таба!

— Алай, бик күңелле, кызык булачак икән шул,— дидем мин, көрсенеп кенә.— Сез нишләргә уйлыйсыз инде, кызлар?

— Ә без барабыз! — диделәр алар, икесе дә беравыздан.— Ә син, Гөләндәм?

— Белмим шул,— дидем мин, әз генә икеләнгән булып.— Барасы иде дә бит, әнием ни әйтер тагын.

— Бармыйча калырга ярыймы соң әллә нидә бер килгән шундый кичәгә. Бибимәликә апа белән үзебез сөйләшәбез, теләсәң!

— Ә кайчан була инде ул кичә?

— Егерме алтынчы февральдә, җомга көн, «Новый клуб»та дигән афишада.

— Вакыт бар икән әле... Ярый, кызлар, әнием белән башта үзем сөйләшим, сезнең дә барасыны әйткәч, бәлки, болай да рөхсәт итәр.

Кызларым шуңа риза булдылар. Ләкин чыгып киткәнче мине һаман «үтереп» кыстадылар: «Гөләндәм, ахирәткәй, җаным, берүк бармыйча калма, соңыннан бик тә үкенерсең!» — диделәр.

Бу хәтле кыстауның үзенә күрә шактый зур сере бар иде: безнең әниләр кызларын берәр җиргә җибәргәнче иң элек кемнәрнең баруы белән кызыксыналар. Шуңа карап рөхсәтләрен йә бирәләр, йә бирмиләр. Менә ни өчен Мөршидә белән Мәрьямгә минем «Шәрык кичәсе»нә баруым бик кирәк: әниләренә кайтып: «Бибимәликә апаның Гөләндәме дә бара», — дигәч, аларга рөхсәтне алуы җиңелрәк булачак. Минем өчен дә ул шулай: «Аит Мәрьяме дә бара», — дисәм, әниемә мине җибәрмәү кыенрак булачак. Кыскасы, берәр кичке тамашага барырга кирәк булса, безнең хәйләкәр кызлар әнә шулай бер-берсен сөйри торганнар иде.

Бу җәһәттән Мөршидә белән Мәрьямнең килеп, мине «котыртып» китүләре яхшы да булды әле. Әмма, икенче яктан, аларның кичәдә булулары минем хәлемне бик читенләштерәчәк тә иде. Сәхнәгә килеп чыгуымны күрү белән алар, билгеле, шаккатып калачаклар һәм икенче көнне үк инде бу «фәүкылгадә» вакыйганы бөтен таныш-белешләргә исләре китеп сөйләячәкләр. Көне-сәга-

те белән ул әниемә дә килеп җитәчәк... Әтием дә беләчәк. Шуннан соң ни буласын әйтеп тору кирәк микән? Хәер, минем өчен хәзер барыбер инде, теләсә ни сөйләсеннәр!.. Чигенү юк, чигенү мөмкин түгел. Бөтен уем-күңелем белән мин тик шул кичәдә, шул кичәнең кешеләре арасында — гүя Салих дәшкән дөньяга кердем дә инде мин... Башка нәрсә күземә дә күренми, уема да һич керми. Мин җырларга тиеш. Матур итеп, мине чакыручыларны да, мине тыңлаучыларны да канәгатьләндерерлек итеп. Йә, моңардан да зуррак башка кайгының булуы мөмкинмени хәзер?!

Һәм менә ул, минем өчен зур сынау көне — егерме алтынчы февраль көне килеп тә җитте. Әнием күп карышып тормыйча гына рөхсәт тә итте. Аңа, таныш кызларның баруыннан да бигрәк, кичәнең «мәҗрүх солдатлар файдасына» булуы ныграк йогынты ясады шикелле (ана кеше ич!), чөнки миңа, иганәгә дип, бер әйбәт кенә сөлге белән бер пар җылы оекбашлар да бирде.

Сәгать биштән үк мин ашыкмыйча гына әзерләнә башладым. Әйбәтләп юындым, чәчләремне тарап үрдем. Кәрим абый киңәшен истә тотып, өстемә киясе нәрсәләрне сайлап алдым: кара бәрхеттән тар гына озын күлмәк, биек үкчәле туфлиләр, кечкенә энҗеле калфак... Шуларны киеп көзге алдына баскач, үземне чынлап та үсеп киткән төсле итеп күрдем. Бу эштә миңа Сабира да булышты.

Мин әле сөрмә тарта, пудра яга белмим (дөресрәге, кирәген тапмыйм), әмма хушбуйның бик нәфис ислесен сөртергә яратам. Бу юлы да, бизәнеп тормыйча, бик кадерләп кенә тоткан француз хушбуен муеныма, кашларыма, колак яфракларыма сөрткәләдем. Сабира, хәерсез, борынын киереп исни-исни, Салих абыйны исертеп кенә һушыннан яздырмасаң ярар иде, дигән була. Мин аңа үпкәләмим дә, көлмим дә. Мин бүген бик тыныч.

...Кызлар мине алырга керделәр. Әнием белән бик ачык сөйләштеләр. Гөләндәмне икебез ике ягыннан саклап кына йөртербез, югыйсә комиссар иптәшләр чибәр кызларны конфисковать итәргә яраталар икән, дип көлешеп тә алдылар. Комиссар сүзе телгә бик кереп китте әле. Аеруча хатын-кызлар аны кызыксынып та, куркып та гел кабатлый торалар... Әзрәк шаулашканнан соң без, ниһаять, Аллага тапшырып, кухня яктан гына чыгып киттек. Хәерле сәгатьтә!

Кар һәм йолдызлар яктысы гына төшкән урамнан шагыр-шогыр атлап кызу гына барабыз. Суык, каты суык бүген! Тамагымны саклар өчен авыз-борынымны мех яка

эченнән бер дә чыгармыйм. Урам буш, капкалар бикле, тәрәзә капкачлары ябык, кеше заты юк диярлек яки бик сирәк очрый. Аны да каршыңа килеп чыккач кына шәйләп аласың. Ялгыз булсаң, йөрәгең ярылыр иде, ә өчәү булгач, сер сынатмыйбыз инде. Тик сөйләшми-нитми йөгерәбез генә...

Әйткәнемчә, мин тыныч. Күңелем төбеннән генә кая һәм ни өчен баруымны уйлап куйгаласам да, нишләптер үземдә бернинди курку-борчылу кебек нәрсә тоймыйм. Гүя алар барысы да артта калды инде.

Клубның ишегеннән барып керүгә безне Салих каршы алды. Чара юк, мин аны «ахирәтләрем» белән таныштырырга тиеш идем. Ул сүз әйткәнче (йә «бәгырем», йә «Гөлгенәм» дип куяр тагын), мин шуны эшләргә дә ашыктым:

— Таныш булыгыз, болар минем дус кызларым!

Салих көлемсерәп, баш иеп кенә алар белән исәнләште. Ул үзе дә нидер сиздe булса кирәк, сез, кызлар, чишенеп фойега менегез, диде дә шунда ук безнең яннан китеп тә барды... Ике-өч адым да китәргә өлгермәгәндер, күзләренә ут капкан «ахирәтләрем» кабаланып сорашырга да тотындылар:

— Кем бу?

— Салих абый. Музыкадан укытучым,— дим мин, ничек тә гади генә итеп.

— Әллә Салих Сәйдәшев? — ди Мөршидә, «күргәнем бар» диюен онытып.

— Әйе, шул үзе!

— Кара, бик яшь ләбаса!

— Нигә, укытучы сакаллы булырга тиешмени?

— Юк инде, Гөләндәм, укытучың үзеңнән олы, солидный кеше булмаса... әллә ничек, килешми... хәтәр!

Мин бик гаҗәпләндем:

— Ни өчен хәтәр?

— Укытам дигән булып, башыңны әйләндерә башласа, йә, нишләрсең?!

Кызларым чыркылдашып көлделәр, ә мин ни әйтергә дә белмәдем — ниндидер бер хакыйкать ишетелеп киткәндәй булды Мөршидәнең бу сүзләреннән... Ә бит ул аны һични уйламыйча, бары көнчелектән генә әйткән булырга тиеш.

Өске киемнәребезне салып, икенче катка — биек түшәмле озын гына фойега мендек. Халык шактый килгән икән инде. Фойеның уртасы әйләнеп йөрүчеләр белән тулган диярлек. Күп кенә яшьләрнең күкрәгендә ефәк тасмадан очын салындырып, матур итеп таккан кызыл бант — инкыйлабка хөрмәт билгесе. Хәрбиләр дә бүген

күп икән. Араларында шактый дәү абыйлар да күренә — комиссарларның зурларыдыр, ахрысы...

Түрдәге почмакларның берсендә кечкенә өстәл, аның янында шәфкать туташлары булып киенгән ике ханым басып тора. Өсләрендә ак кофта һәм кара юбка, башларында кызыл ай белән йолдыз тегелгән ап-ак бөркәнчек. Шуны маңгайларына төшерә биреп, колакларына гына кыстырып куйганнар — бик килешә үзләренә. Безнең кулдагы төргәкләрнең нәрсә икәнен белгәндәй, бер хәрби:

— Кызлар, бүләкләрегезне әнә шунда илтегез,— дип китте.

Без шәфкать туташлары янына барып, төргәкләребезне бирдек. Берсе алып, икенчесе язып тора. Исем-фамилияләребезне сорадылар. Мин исемемне генә әйттем, фамилиямне әйтеп тормадым.

Инде миңа кызларымнан ничек тә аерылып, Салихны тизрәк күрергә кирәк иде. Ләкин шул арада Салих үзе безнең янга килеп җитте. Ул ашыга иде, ахрысы, килүе белән миңа туп-туры:

— Гөләндәм, сезгә сүзем бар,— диде дә бер читкәрәк китте.

Аның мондый тәвәккәллек белән дәшүе мине әз генә уңайсыз хәлгә дә куйды. Ә бәлки, шулай кирәк тә булгандыр — качышлы уйный торган чакмыни хәзер?!

Мин китә башлагач, Мәрьям:

— Син югалма инде,— диде.

Ә Мөршидә, көлгән булып, артымнан:

— «Укытучысы» бик тә чибәр, югалса да гаҗәп түгел,— дип калды.

Әнә ни ди бит, явыз! Юк, тәвәккәл булмыйча ярамый хәзер, ярамый!

Салих янына баргач, ул миңа сынап кына бер карап алды да көлемсерәп сорады:

— Бу сакчыларны сезгә кем тагып җибәрде?

— Шулай килеп чыкты инде, сез аларга игътибар итмәгез!

— Ә сез үзегез?

— Минем өчен дә барыбер,— дидем мин.

— Яхшы алайса,— диде ул, җитдиләнеп.— Беләсезме, Гөләндәм, безгә сәхнә артына керергә вакыт.

— Иртәрәк түгелме соң әле?

— Миңа хәзер оркестрым янына барырга кирәк, шуңарчы үзем сезне кертеп калдырмакчы идем.

Мин уйланыбрак калдым: вакыт та җитә, димәк!

— Сез тыныч булыгыз! — диде Салих, мине юатып.— Анда барысы да җыелганнардыр инде.

— Ә үзегез кайчан килерсез?

— Өченче звонок булу белән! Киттекме? Әллә башта юлдашларыгызга әйтеп киләсезме?

— Юк инде, әйтеп тормыйм. Алар барыбер мине югалганга саныйлар.

— Ә мин табылганга саныйм! — диде Салих, хәйләкәр генә күз кысып һәм мине ияртеп тар коридордан каядыр алып китте.

Берничә ишекне узып, кыска гына баскычтан менеп, без, ниһаять, сәхнәгә барып кердек. Бу, түшәмсез-стенасыз дигәндәй, үзе иләмсез зур, үзе бик салкын бер урын икән... Тик каядыр биектә аркылы сузылган киртәләр күренә, аларга калын итеп ниндидер киндер нәрсәләр уралган, ә баш-башларыннан әллә нинди баулар асылынып тора. Сәхнәнең ике пәрдәсе бар: берсе — авыр, зурысы — тамаша залына караган, икенчесе — сәләмәрәк тә җиңелрәге — иң артка эленгән. (Соңыннан белдем: задник дип атала икән ул.) Салих мине менә шул пәрдә артына алып керде, ә анда рәттән өч бүлмәнең өч ишеге тезелеп тора. Артистларның киенеп-ясана торган бүлмәләре икән алар. Өчесеннән дә сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелә. Салих иң кырыйдагысының ишеген ачып, миңа алдан юл бирде. Керсәк, бүлмәдә дүрт кеше сөйләшеп утыралар. Солтан абый белән Кәрим абый, ә икесен мин танымадым. Аларның берсе какча гәүдәле, җирән кыяфәтле, кара кәләпүшен кырынрак салган зифа гына бер егет иде. Икенчесе хәрби киемнән, бик төз буйлы, куе кара чәчле, тулы гына ак чырайлы шактый чибәр бер кеше иде.

Без керүгә дүртесе дә урыннарыннан тордылар. Кәрим абый ачык йөз белән:

— Ә, Гөләндәм туташ, рәхим итегез! — диде.

Мондый чакта мин ирексездән уңайсызланып китәм, чөнки шундый дәү абыйларның түбәнчелек белән каршы алулары башлыча Салих хакынадыр дип беләм. Алай дисәң, ни өчен алар минем кебек бер яшь туташ алдында үзләрен чын кавалерларча тотмаска тиешләр?! Гади әдәп һәм мәдәнилек билгесе ич бу!..

Салих ашыга иде, юри шаярткан булып:

— Әфәнделәр, туташны сезгә тапшырам, саклагыз үзен! — диде дә чыгып китте.

— Җаныгыз тыныч булсын! — дип калды Солтан абый аның артыннан.

Салих чыгып киткәч, Кәрим абый мине әлеге ике кеше белән таныштыра башлады. Кәләпүшле зифа егетне күрсәтеп:

— Бу Габдрахман Камал абыегыз булыр. Бүгенге кон-

цертны алып баручы... Шул сәбәпле, без, үз нәүбәтебездә, сезне дә аның мәрхәмәтле кулына тапшырырга мәҗбүрбез. Сез шуңа ризамы?

Шаяртыбрак әйткән бу сүзләргә каршы мин дә елмаеп кына баш кагып ризалыгымны белдердем. Ә Габдрахман Камал исә кулындагы урталай бөкләнгән ак кәгазьне ачып карады да:

— Сез, туташ, программада бишенче икәнсез,— диде.—Алданрак әйтермен, әзер булып торырсыз!

Аның тавышы гаҗәп саф, ачык, ничектер үзеннәнүзе яңгырап китәргә генә тора иде.

Шуннан соң Кәрим абый моңарчы бер читтәрәк көлемсерәп кенә торган әлеге хәрби кеше белән дә мине таныштырды.

— Бу — Шамил иптәш Усманов. Дәһшәтле комиссар, ялкынлы әдип! Ишеткәнегез бармы?

— Бар! — дидем мин, икеләнебрәк, чөнки ачык кына һич тә хәтерләмим: ишеткәнем бар да кебек, юк та кебек. Шулай да мин аңа моңарчы күз күрмәгән дәү бер җанварга караган шикеллерәк итеп карадым.

Ә Шамил Усманов таза ак тешләрен күрсәтеп елмайды да:

— Мин бик шатмын! — диде һәм, кавалерларча тураеп, миңа башын иде.

«Әллә көлә инде, Ходаем!» — дип борчылып куйдым мин. Ләкин ул гади-ихлас кына итеп өстәде:

— Туташ, мин сезгә бүгенге концертта зур муаффәкыять телим, от души!..

«Дәһшәтле» комиссарның мондый нәзакәтлек күрсәтүе миңа, билгеле, бик сәер тоелды.

...Алар барысы да үз эшләренә ашыгалар иде шикелле.

Кәрим абый Габдрахман Камалга:

— Сәхнәне җыештырып бетерергә кирәк, икенче звонокны бирергә дә вакыттыр инде,— диде. Аннары миңа карап әйтте: — Күршедә генә ханымнар бүлмәсе, сез шунда кирәгез. Анда җылырак та, күңеллерәк тә булыр.

Ул шулай дигәч, мин дә аларга ияреп бүлмәдән чыктым. Ләкин күрше бүлмәгә минем кереп торасым килмәде. Анда зур артисткалар, дәү апалар җыелгандыр, дип уйладым мин, ахмакланып; кереп игътибарларын үземә җәлеп итмим әле, янәсе!.. Әнә шулай тискәреләнеп мин сәхнә артында гына әрле-бирле йөренә башладым. Ә аран шикелле шыксыз, ягылмаган зур сәхнә бик салкын иде — мин моны бик тиз сизеп алдым. Шунда ук борылып бүлмәгә генә керәсе иде дә бит, әмма үҗәтлекне тиз генә җиңеп буламыни?! Ул арада фойеның югары сәндерә-

сендә уйный башлаган оркестр тавышы да ишетелде... «Ай, былбылым»ны уйныйлар — һай, дәртле-матур уйныйлар да соң! Түзмәдем, сәхнәнең алдынарак узып, тыңлый башладым, хәтта бер мәлгә әшәке салкынны да онытып җибәрдем.

Ә бу вакытта Габдрахман Камал абый һәм тагын ике егет, югарыдан әлеге киртәгә ураган ниндидер киндерләрне сүтеп төшерә-төшерә, кызу гына эшләп йөриләр иде.

— Туташ! — дигән кискен тавышка сискәнеп киттем.—Ник бүлмәгә кермисез, туңарсыз ич монда!

Борылып карасам, Камал абый икән бу...

— Кичерегез! — дидем мин, гаебемне сизеп, бәлки, комачаулый да торганмындыр әле мин аларга... Кире сәхнәнең артынарак киттем һәм... гаҗәпләнә калдым: теге киндерләрне төшергәч, сәхнә бөтенләй икенче рәвешкә кергән иде. Артта кояшлы каен урманы, урман өстеннән бик биектә ак болытлар агыла, ә агачлар арасыннан бормаланып ат юлы килеп чыга. Як-якта да ботакларын җәйгән шундый ук ак каеннар... Гүя бу җәйнең эссе көннәрен хәтерләткән чәчәкле, хуш исле, гаҗәеп матур бер аланлык, имеш! Без шушы кояшлы аланлыкта җырлаячакбыз икән. Йә, әкият түгел диген инде!

Ә шулай да мине әкрен генә калтырата. Бүлмәгә керсәм дә, хәзер соңдыр инде. Залда яңгыраган звонокны да ишетмәгәнмен, ахрысы. Сәхнә артына керүчеләр күбәйде, бүлмәдән ханымнар да чыга башладылар. Зат киемнәре өстеннән кайсы иңенә мамык шәл, кайсы пальтосын салган — минем кебек җүләр түгелләр икән шул!

Бер читтә һаман ялгызым гына торам, карыйм, күзәтәм. Кызык дөнья, кызык кешеләр! Әмма үзләрен бик гади, бик иркен тоталар. Дөрес, мин аларның күбесен белеп тә бетермим әле, ләкин кайберләрен элек күргән спектакльләр буенча таныйм да шикелле; әнә теге юка-озын гына гәүдәле, ак чырайлы, гел елмаеп кына сөйләшә торганы Өммегөлсем ханым Болгарская булырга тиеш. Ә арада иң яше, иң чибәре Әшрәф Синяева булса кирәк. Тагын әнә теге аяк йөзеннән үк зәңгәр ефәк күлмәк кигән, тулы күкрәкле, сары чәчлесе Мәрьям Рахманкулова түгелме икән? Әгәр шул булса, бу инде соңгы вакытларда исеме бик таралып киткән яшь җырчылардан исәпләнә.

Ирләрдән аеруча бер кеше минем игътибарымны үзенә җәлеп итте. Пенсне кигән бу таза, нык гәүдәле кеше, сөзәргә җыенган үгез сыман, озын ял чәчле башын ия биреп, кулларын күкрәгенә куеп, һичкемгә дәшми-карамый бер читтә әрле-бирле йөри дә йөри... Кем булыр бу?.. Өстендә кара бәрхеттән иркен-озын толстовка, муе-

нында ак тасмадан бик зур бант — юк, андый-мондый гына кешегә охшамаган ул!

Ниһаять, зарыктырып көттергән минем Салихым да килеп җитте. Ашыккан, күрәсең, битләре кызарып чыккан. (Ә кызыллык аңа бик сирәк чыга.)

— Әллә гел шушында тордыгыз? — диде ул, килеп җитүе белән.

Мин гаепле бала сыман бары елмайдым гына. Ул сак кына кулымны тотып карады да:

— Боз кебек булган лабаса! Ах, сезне, сезне! — диде, пошынып.— Ник бүлмәгә кермәдегез?

— Кереп тормадым шул... Ә сез борчылмагыз, миңа хәзер суык түгел инде,— дидем мин, эчке калтыравымны ничек тә басарга тырышып. Дөрестән дә, өшүемне сизми башлаган идем, (ә калтырау болай гына ул), киресенчә, вакыт-вакыт миңа эссе дә булып киткәли иде.

Шул чакта безнең янга Өммегөлсем Болгарская килде.

— Исәнме, Салих! — диде ул, бер туганына дәшкәндәй итеп кенә.

— Исәнмесез, Гөлсем апа! — диде Салих, түбәнчелек белән.

— Шушында керсәм, һич чыга алмыйм,— дип зарланды Болгарская.— Залда халык күпме соң?

— Бик күп. Аншлаг дияргә мөмкин.

— Яхшы инде алайса... Мәҗрүх гаскәриләргә әҗере дә күбрәк булыр, ичмасам!

— Әлбәттә!

— Ә бу чибәр туташны кем дип беләбез?..— диде Гөлсем апа, мөлаем карашын миңа күчереп.— Таныштырмыйсың да!..

— Гафу, Гөлсем апа! — диде Салих, тиз генә.— Бу Гөләндәм туташ була, бүгенге концертта катнашачак!

— Шулаймыни?! Яңа җырчы, димәк! Беренче мәртәбәме?

— Әйе, беренче мәртәбә генә!

— Хәлегезне аңлыйм, матурым! — диде Гөлсем апа минем үземә, аркамнан сыйпагандай итеп кенә.— Беренче тапкыр халык алдына чыгу — билгесез тирән дәрьяны кичү белән бер инде ул!.. Әмма сез тыныч булыгыз, иркәм, без барыбыз да аны кичтек, сез дә, иншалла, кичәрсез!

Әнә шулай юатты мине күптән танылган, тәҗрибәле артистка. Билгеле инде, аның бу хикмәтле сүзләре минем дә ышанычымны арттыра төшкән кебек булды.

Ул да булмый, сәхнә артында Габдрахман Камалның көчле тавышы яңгырады.

— Иптәшләр, дикъкать! Хәзер башлыйбыз, тавыш, хәрәкәт бетсен! Һәркайсыгыз кайчан, кем артыннан чыгуыгызны белеп, әзер булып торыгыз!

Башлана! Чаң суккандай тәэсир итте бу... сәхнә арты шунда ук тынып калды, бөтенесен, хәтта күнегеп беткән артистларны да бер мәлгә җитди киеренкелек биләп алды. Минем исә йөрәгем урыныннан кубардай булып тибә башлады. Гүя бу минутның килеп җитәсен мин белми торганмын!

Өммегөлсем апа, шыпырт кына:

— Ярый, мин залга чыгыйм әле,— диде.— Хәзергә монда эшем юк. Сезгә уңыш, иркәм!

— Рәхмәт! — дидем мин, дерелдәгән иреннәрем белән генә.

Менә әкрен генә пәрдә дә ачылды. Караңгы залда гүләү тынды. Йөзләрчә кешеләрнең дикъкатен, көтүләрен сиздереп, аннан якты салкын сәхнәгә җылы адәм сулышы бөркелгәндәй булды. Аз гына көттереп, ике «агач» арасыннан Габдрахман Камал җиңел адымнар белән килеп чыкты да, кыйгачлый биребрәк, сәхнәнең нәкъ алдына барып басты.

...Ул нидер сөйли башлады. Бик дәртле, ялкынлы итеп, ләкин аның чыңлап торган тавышы караңгы зал өстендә үтә кискен яңгырый иде. Әллә шуңа, әллә безгә аркасы белән торганга күрә, беренче сүзләрен мин юньләп аера алмыйча да калдым. Тик соңгы сүзләре генә килеп җитте безгә:

— Шәрык уянды! Богаулар өзелде! Гасырлар буенча изелгән мәзлүм милләтләргә тулы азатлык килде. Бүген без шуның олуг тантанасын кичерәбез. Әмма каты, канлы көрәшнең беткәне юк, иптәшләр! Кискен көрәш, рәхимсез көрәш дәвам итә, иптәшләр! Шик юк ки, бу көрәш пролетариат революциясенең җиңүе белән бетәчәк! Бүгенге кичәбезне без революциянең шанлы көрәшчеләренә — каһарман кызыл гаскәриләргә багышлыйбыз! Яшәсен бөтен дөнья инкыйлабы, бетсен капитал, бетсен зольмәт, иптәшләр! Азатлык кояшы бөтен галәмне балкытсын!

Һәм ул башын иде. Халык аңа дәррәү кул чапты. Шуннан соң Камал абый концертның беренче номерын игълан итте.

— Музыкаль трио! Скрипкада — Мөхәммәт Яушев, гармунда — Фәйзи Биккинин, мандолинада — Мансур Мозаффаров!.. «Аккош маршы!»

Сәхнәгә өч егет чыктылар һәм баскан килеш кенә уйнап та җибәрделәр.

— Ник калтырыйсыз? — диде Салих миңа, әкрен генә.

— Үзем дә белмим! — дидем мин, бөтен тәнем белән куырылып.

— Ярамый, бәгырь!.. Тынычланыгыз!

Юк, бу тынычсызланудан-борчылудан түгел иде. Мин инде тиздән чыгасымны уйламыйм да диярлек. Миңа салкын үткән булырга тиеш — шул йөри тәнем буйлап... Хәер, нервалар да шаяра торгандыр инде, бәлки, менә бу музыканың дә тәэсире бардыр?! Музыканы мин бервакытта да тыныч кына тыңлый алмыйм, юк, тыңлый алмыйм!..

Ә өч егет үзара гаҗәп бер килешкәнлек, осталык белән өздереп кенә уйныйлар лабаса!.. «Аккош маршы»ннан соң «Әрбет», «Бибкәй кыз», «Прховой Фатих», «Шакир солдат», «Гөлмәрфуга»... Халык аларны тиз генә җибәрмичә, кат-кат биска чакырып, әнә шулай күп уйнарга мәҗбүр итте.

Алардан соң, җиз төймәле яшел тужурка кигән, чемкара чәчләрен сулдан уңга ерып тараган, базык-таза гына бер студент егет чыгып җырлады. Ахрысы, башкорттыр. Иркен, көр тавыш белән ул «Ашказар»ны, «Кәраван сарай»ны һәм «Коңгыр бозау»ны җырлады. Тамашачылар аңа да бик мәмнүн булып кул чаптылар.

Әмма иң хикмәтлесе теге иңнәренә озын чәчләрен тарап төшергән, берәүгә дә дәшми-карамый ялгыз бер читтә йөренеп торган сәер кешенең чыгып сөйләве булды. Камал абый халыкка аны тантаналы рәвештә «Мохтар Мутин!» дип игълан итте. Менә кем икән ул... Исем-фамилиясендә үк үзенә тарта торган нәрсәдер бар аның!

Ашыкмыйча гына чыкты ул, алга ук узмыйча караңгырак бер урында тукталды, шылт та итмичә көтеп торган залга беравык җитди-усал гына карап торды да, әкрен-шомлы итеп:

— Таң вакыты... татар йоклый,— диде.

Әнә шулай, шигырьнең исемен дә әйтеп тормыйча башлап китте ул! Һәм тыңлаучыны сискәндererлек итеп башлаганнан соң ниндидер бер гаҗизлек, аптырау, әрнү белән дәвам итте:

.................................

Мин, йокысыз, уянам.
Уянам да тиле кебек
Тик берүзем уйланам.
Уйланам, уема батамын,
Тормыймын, үзем ятам...
Ятмас идем дә, җибәрми
Атадан калган хатам.

Артистның көчле, матур тембрлы тавышы интонацияләргә искиткеч бай иде. Менә ул кинәт иң югары ноктага күчеп, бер үк вакытта ялварган да һәм янаган да төсле шашынып, Аллага мөрәҗәгать итә:

Алларын белгән татарларның
тик син, бер Алла!
Әйт!
Бетәрләрме икән татарлар
Җир йөзеннән,
әллә белерләрме икән
хаталарын бер алда?

Иң ахырдан исә, зур бер хакыйкатьне ачкандай тынычланып, газаптан бушанып, ләкин шуның белән бергә халыкка өндәү ташлагандай нык-батыр һәм тантаналы итеп тәмамлады ул:

Бетмә, надан, туг яңадан
Мәгърифәтле анадан!
Бул кеше, үзең тырыш, өмет итмә,
Хата ул өмит Алладан!*

Гүя тирән газаптан туган шигырь үзе һәм бигрәк тә аны шулкадәр белеп, тоеп сөйләү тамашачыларны тәмам сихерләде булса кирәк, алар өзлексез кул чабып, артистны кат-кат биска чакырдылар. Ләкин Мутин абзый бер генә тапкыр чыгып, һич тә исе китмәгән бер кыяфәт белән шашынган залның галеркасына кадәр күз йөртеп узды да, яллы башын ияр-имәс кенә бөгеп, күпмедер вакыт тик кенә торды. Аннары кисәк кенә күтәрде дә шундый ук тыныч горурлык белән ашыкмыйча гына чыгып та китте.

— Бу артист бер заман татар сәхнәсен шаулатачак әле! — дип калды Салих та аның артыннан.

Ул да булмый, безнең янга Камал абый килде.

— Туташ, тиздән сезнең нәүбәт, әзер булып торыгыз,— диде ул, ашыгып.— Салих, ишеттегезме?

— Ишеттек, без әзер! — диде Салих.

— Йа Рабби! — дип куйдым мин, ирексездән. Нигәдер кинәт кенә куркып-шомланып киттем. Дөрес, җырлый алуыма мин моңарчы ышанып тордым, тик менә хәзер бөтен тәнемдә йөргән шушы бизгәк мине бик борчый иде. Шул гына харап итмәсә ярар иде, Ходаем! Тавышым үзгәрмәде микән?.. Хәер, белеп буламыни инде аны хәзер генә?!

Ә Салих әзрәк кенә шаярткан да булып, мине һаман әкрен генә юата: «Әнә Мутин абзагыздан үрнәк алыгыз, аның кебек горур, салкын, тыныч булыгыз,— ди.— Тамашачыны онытыгыз, бары минем өчен генә җырлагыз, шул чакта тыңлаучылар да сездән бихуш булырлар»,— ди.

---

* Сәгыйть Рәмиев шигыре, 1914 елда Галимҗан Ибраһимов төзеп чыгарган «Яңа әдәбият» китабыннан алынды.— *Ә.Е.*

Аңа әйтүе ансат! Белсә иде ул минем хәлемне... ә бәлки, белеп, юатырга тырышуыдыр.

Чү, Камал абый мине әйтә түгелме соң? Бик ачык итеп, залны яңгыратып:

— Яшь һәвәскәр җырчы Гөләндәм туташ Солтанова! Рояльдә — Салих Сәйдәшев! Рәхим итегез.

«Әйдә, атлагыз!» — диде Салих миңа. Мин... атладым. Якты сәхнә, караңгы зал. Мин шуларның нәкъ чигеннән үтәм кебек... озак үтәм. Ниһаять, рояль янына җитеп туктадым. Шунда ук Салих та килеп утырды (ә мин аның артымнан килгәнен һич тә сизмәдем). Янымда — Камал абый, иелә биреп миннән сорый: «Беренче җырыгыз?» Мин иреннәремне кыймылдатам. Аннары ул залга кычкырып әйтә:

— «Мәдинәкәй».

Ә зал тып-тын... Хәер, бөтенләй үк тып-тын да түгелдер инде, тик минем бөтен-бөтен дикъкатем Салихта — ничегрәк итеп башлар ул?.. Мин бары шуны көтәм, залда хәзер һич эшем юк.

...Рәхмәт төшсен аның кулларына! Рояль телләренә түгел, гүя йөрәк кылларыма йомшак кына кагылды аның нәфис куллары! Гүя авазлар ярдәме белән дәште ул миңа: «Чын, саф «Мәдинәкәй» менә шушы була!» — диде. Һәм мин аңа буйсынып, аңа ияреп җырладым. Халык ихлас кына кул чапты. Кинәт миңа җиңел булып китте. (Сәхнә дигәнең ул хәтле үк куркыныч урын түгел икән...) Аннары мин «Сакмар»ны җырладым. Үземә калса, моны инде иркенрәк тә, рухланыбрак та җырладым шикелле. Бу юлы халык та ныграк кул чапты. Ләкин мин икене җырлаганнан соң, түбәнчелек белән баш иеп, сәхнәдән чыгарга тиеш идем. Һәм шулай эшләдем дә... Ә халык тынмый, халык биска чакыра. Тик мин белеп бетермим әле — кыстатыбрак торыргамы, әллә тәвәккәлләп чыгаргамы? Салих күзе белән генә миңа «ягез!» дигәндәй ишарә ясады һәм без яңадан чыктык. Алдан әзерләнгән тагын бер көебез бар иде — мин шуны («Исле гөл»не) җырладым.

Кул чабулар, биска чакырулар бу юлы да кабатланды. Әмма ләкин минем үземә бик җитте, ахрысы... Халыкка баш иеп, сәхнәдән ашыга-ашыга чыккач, тукталып та тормыйча, караңгырак бер почмакка барып постым. Миңа бик эссе иде, тынымны өзеп-өзеп алам, ә тез буыннарым туктаусыз калтырый...

Артымнан Салих та килеп җитте.

— Бәгырь, ник болай куян шикелле качтыгыз? — диде ул, сөенечле көлемсерәп.— Ишетәсезме, халык чакыра ич!..

Миңа хәзер тел әйләндереп бер сүз әйтүе дә авыр иде. Тик бераздан гына көчкә-хәлгә әйтә алдым:

— Мин янам!

Әйе, мин яна идем, утта яна идем... Салих пошынып минем күзләремә карады, аннары, аз гына икеләнгәннән соң, кулының сыртын маңгаема сак кына тидереп алды.

— Кайнар икән шул! — диде ул, җитдиләнеп.— Нәрсә бу, салкын зәхмәтеме?

— Ахрысы.

— Ярый торган эш түгел бу... Әйдәгез, чыгыйк әле моннан, булмаса!

Ул мине ияртеп буш фойега алып чыкты, аннары урам якка караган иркен генә бер бүлмәгә алып керде. Монда үзенә күрә буфет икән. Түрдә озын өстәл, өстәлдә галәмәт зур самавыр һәм шул самавыр янында йокымсырап ялгыз гына бер хатын утыра. Хәзергә монда һичкем юк иде.

Салих башта мине читтәге өстәлләрнең берсенә илтеп утыртты. Үзе исә, хатын янына барып:

— Апа, безгә ике стакан кайнар гына чәй ясагыз әле,— диде һәм борылып миңа дәште: — Гөләндәм, буфет бөтенләй үк буш түгел икән, нигъмәтләрнең төрлесе бар: чәкчәк, кош теле, пирожный — кайсын телисез?

— Миңа берни дә кирәкми,— дидем мин; ашау кайгысымы соң хәзер миндә!

Шулай да ул кечкенә поднос белән ике стакан куе чәй, ике пирожный һәм бер уч чамасы конфет китерде.

— Эчегез, суытмыйча гына! — диде ул, каршыма утыру белән.

— Миңа болай да кызу.

— Барыбер эчәргә кирәк... Шулай ук салкын тиде микәнни?

— Белмим. Башта өшетте, аннары яндыра башлады. Ә менә хәзер тагын калтырата...

— Эчегез әле, пешә-пешә булса да эчегез!.. Сезгә һич тә авырырга ярамый.

— Ни өчен? Авыру сорап килми ич!

— Әгәр сез авырсагыз, мине асачаклар,— диде ул, юри тавышын әкренәйткән булып.— Хәер, анысына түзәр дә идем, әмма сезне саклый алмавым өчен мин үземне иң авыр газапка дучар итәчәкмен.

— Кирәкми ул кадәр, Салих абый... Үтәр әле.

— Үтә күрсен!.. Ләкин авырырга ярамый диюемнең икенче сәбәбе дә бар.

— Анысы нәрсә?

— Сез бүген, Гөлсем апа әйткәнчә, дәрья кичтегез...

һәйбәт кичтегез! Бүген сезнең бәйрәм, Гөләндәм!.. Йә, шушындый көнне авырырга ярыймы соң?!

Салихның гадәтен беләм инде, ул шулай шаяртыбрак сөйләргә ярата. Әмма шуның белән бергә ул ике арада ничектер менә табигый үзләшү — якынаю да тудыра белә. Аңа һәрвакытта ышанасы килә. Әлбәттә, ул дөрес әйтә — бүгенге кичәне мин үзем өчен, һичшиксез, бәйрәм дип саный алам. Ләкин нигә ул минем өчен генә?

— Безнең уртак бәйрәм бу, Салих абый,— дидем мин аңа, сөенечемне яшермичә.— Барысына да сез сәбәпче!

— Килешәм, шулай да булсын... Беләсезме, музыкант белән җырчы бер-берсен тапсалар, аларның эшләре һәрвакыт уңышлы чыга.

— Сез гел киная белән сөйлисез!

— Ә мин әйтеп бетермәдем әле,— диде ул, минем күзләремә карап.— Тагын бер сәбәбен әйтәсем килә, бәгырь!

— Нәрсәнең?

— Авырырга ярамый диюемнең... Иң төп сәбәбен!..— Һәм ул башын иеп, бик азга гына тукталып калды. Аннары икеләнүе җиңгәндәй кисәк кенә күтәрелеп, яңадан миңа төбәлде.

...Бик тын иде. Без икәүдән-икәү генә. Бүлмә эче ярым караңгы, түшәмдәге ут сүндерелгән, тик почмаклардагы шәмдәлләр генә яна. Нигә ул миңа бу хәтле төбәлеп карый? Минем йөрәгемә үтеп керергә телиме яки миннән берәр нәрсә көтәме? Ә мин... мин аның тагы да караңгылана-тирәнәя төшкән күзләренең гипнозына эләккәндәй тәмам югалып, тын алырга кыймыйча утырам.

...Менә ул миңа үреләә төште, сузылып кулыма әкрен генә орынды һәм, ашыгып, кайнар пышылдап әйтте, ниһаять:

— Юк, сез белергә тиешсез, Гөләндәм!.. Вакыт, әйе, вакыт! Мин бит сезне яратам, иң саф, иң мөкатдәс бер ярату белән яратам! Ишетәсезме?

Мин ике куллап йөземне капладым. Йа Хода, менә кайчан ишеттем мин бу сүзне, хәтәр-көйдергеч сүзне! Ә бит көтә идем, көтә идем, күптән инде йөрәгем аның мәхәббәт сүзенә зарыгып, ачылып тора иде... Әмма ләкин менә хәзер ни әйтә алам мин, нишли алам?! Шундый хәлсез мин, бөтен тәнем утта яна, буыннарым таралып китәргә тора, тик елыйсым гына килә, үксеп елыйсым гына...

Салих ашыгып урыныннан торды, яныма килде, иелеп, ике кулымны да алмашлап үбә башлады.

— Кичер, бәгырь! Кичер...

— Юк, сез кичерегез мине... Әллә ни булды миңа... Кайтасы иде.

— Әйе, әйе, сезгә кайтырга кирәк. Үзем озатам. Тик авырый гына күрмәгез, авырый гына!

Без буфеттан чыктык. Фойе буш, бер җирдә беркем юк. Залда һаман әле концерт бара. Гардероб янында Салих миңа киенергә булышты, үзе дә киенде.

Урамга чыккач та ул мине шундагы извозчикларның берсенә утыртты. Аякларымны калын япма белән урнаштырып куйды. Артсыз чанага үзе дә менеп утыргач һәм шома гына кузгалып киткәч, ул мине җил-суыктан саклар өчен билемнән алып, ышыклап барды. Башка вакытта мин моны, бәлкем, рөхсәт тә итмәгән булыр идем, ләкин бүген инде хәлсезлектән үземнең аңа сыенасым килә иде.

...Бер-ике көннән хәлемне белергә вәгъдә биреп, Салих шул ук извозчикта кире театрга китеп тә барды.

## XIII

Мин чынлап торып авырдым. Икенче көнне инде урынымнан да тора алмадым. Дөрес, башта, өйдәгеләрне хәвефләндермәс өчен, әзрәк кенә салкын тигән, башым гына авырта, дигән булып, чын хәлемне яшерергә тырыштым. Ләкин шул ук кичне температурам кырыкка җитә язды. Моны күреп куркуга төшкән әнием электән үк безгә таныш карт врачны тизрәк чакыртып китерде. Сакал-мыегы белән бераз Чайковскийны хәтерләткән карт врач килеп карагач, миндә «испанка»* дигән авыруның башланганын әйтте. Бу бик йогышлы авыру икән. Шуңа күрә мине кем дә булса бер генә кеше карарга тиеш, диде. Аннары ул берничә төрле дару язып калдырды, бары урын өстендә генә ятарга, кайнар сөт эчәргә, тирләргә һәм аз гына өргән салкыннан да бик сакланырга кушты.

Әйтергә кирәк, авыру мине бик кисәк һәм бик каты бөтереп алды. (Күрәсең, авыруның башы миндә «Шәрык кичәсе»нә барганчы ук булгандыр инде, тик салкын арандай сәхнәдә өшеп торуым аны көчәйтеп кенә җибәргәндер...) Температура, әйткәнемчә, кырыкка җитте, башым ярылырдай булып авыртырга тотынды, көчле томау, ютәл башланды. Мин үземә урын таба алмыйча ут эчендә бәргәләнеп яттым, вакыт-вакыт хәтта аңымны да югалткаладым. Билгеле инде, әтием-әнием минем бу көтелмәгән авыруымнан тәмам куркуга төштеләр һәм баштарак аптырап-каушап та калдылар. Шулай да әнием, врач куш-

*«Испанка» дип ул елларда бик нык таралган гриппның бер төрен атаганнар.— *Ә.Е.*

каннар белән генә канәгатьләнмичә, мине үзе белгәнчәрәк тә дәваларга кереште. Мәтрүшкә кайнатып эчерде, төнгеleккә кайнар сөткә бал изеп эчерде, аякларыма кайнар су салган шешәләрне чүпрәккә урап куйды.

Боларның барысы да ярдәм итте булса кирәк, бер дүртбиш көннән соң мин үземне җиңелрәк сизә башладым. Температурам әкренләп утыз җидегә кадәр төште, баш авыртуы һәм томау да бетте диярлек, тик ютәл генә һаман җибәрми иде әле. Әмма мин бик нык хәлсезләнеп калдым, биш көн эчендә авыру минем бөтен көч-куәтемне әйтерсең суырды да алды. Түгәрәк өстәлдәге кечкенә көзгене үрелеп алып, шуңа карагач, үземнең дә исем китте: күзләрем баткан, күз төпләрем каралып уелган, борыным шешенеп, зураеп киткән, ә битемдә әллә нинди хәвефле кызыл таплар!.. Бик әшәке нәрсә икән бу матур исемле явыз чир!

Иң авыр хәлдә яткан минутларымда да мин... Салихны онытмадым. Алай гына түгел, үз-үземне оныткалаган чакларда да ул ничектер минем аңымда яшәде. Соңыннан уйлыйм: әнә шул онытылып киткән чакларымда мин аның исемен дә телгә алмадым микән? Моның булуы бик мөмкин ич! Тик белә генә алмыйм, әйтүче дә юк миңа... Әнием ләм-мим бер сүз әйтми, хәтта нидән, ничек авырып китүемне дә сорашмый. Ә бу хәерлегә булмаска тиеш. Белә, барысын да белә, күрәсең... Белмиме соң?! Теге «ахирәтләрем» «Шәрык кичәсе»ндә күргәннәрен түкмичәчми күптән сөенчеләп китереп җиткергәннәрдер инде. Ләкин әнием сабыр хатын — мине мондый хәлемдә, әлбәттә, борчымаячак. Шулай ук Салих турында да хәзергә берни дә әйтмәячәк. Әмма ахыры моның ни булып бетәр, ахыры?.. Бигрәк тә әтием белә калса... Менә нәрсә «испанка»дан да яманрак көйдерә дә яндыра мине хәзер!

Салих бит, бер-ике көннән хәлеңне белергә килермен, дигән иде. Килдеме икән, юкмы икән, кемнән генә шуны белергә соң?.. Әниемнән сорау мөмкин түгел, Салих килсә дә, ул аны миннән яшерәчәк. Моны бары Сабирадан гына белеп булыр иде, ләкин аны да әле минем янга кертмиләр. Ә Салихның килүе минем өчен шундый әһәмиятле, шундый кирәкле, әйтерсең тизрәк терелүем бары шуңа гына бәйләнгән. Килеп кергән сәгатендә үк мин, бернинди авыру булмагандай, җиңел генә аякка басар идем кебек. Менә бит ни өчен түбәндәге һәр тавышка колак салып, ишектән күземне алмыйча зарыгып ятам мин... Әгәр шул кичне ул «яратам» дигән сүзен әйтмәгән булса, миңа хәзер күп мәртәбә җиңелрәк булыр иде. Ә ул әйтте, «яратам, мөкатдәс бер ярату белән яратам!» диде. Йа Рабби! Мин бит бу сүзне аңым-

ны югалткан минутларда да исемнән чыгармадым, гүя чигәмдәге кан тамыры шикелле ул өзлексез тибеп торды. Әйе, бу сүз, чын була калса, мине терелтәчәк, иң каты авырудан да терелтәчәк! Инде ялган әйткән булса — Тәңрем, кичерә күр! — терелү миңа нигә кирәк, нигә?!

Сукырның бөтен теләгәне ике күз, диләр,— ниһаять, дүртенче көннең иртәсендә минем янга, бик аз гына вакытка, Сабира кереп чыкты. Баш очыма ук килде дә иелеп әкрен генә:

— Ах, туташ, туташ! — диде.— Ни булды, нигә болай кинәт авырып киттең?

— Әйтмә инде, Сабира!.. Салкын тидердем шул, үземдә гаеп.

— Бөтенләй суырылып калгансың, җаным! Урамда озаграк тордыңмы соң?

(Нигә ул алай дип сорый? Димәк, аның колагына да нидер кергән инде.)

— Юк,— дидем мин,— урамда бер минут та тормадым. Театр бик салкын иде, әллә кыш буе якмаганнар үзен... Иңемә шәлемне салырга да онытканмын.

— Терел инде тизрәк, терел! — диде ул, минем күзләремә туры карарга тырышып.

— Тереләсе иде дә бит,— дидем мин, йөземне читкә борып.

Ә ул һаман миңа төбәлеп карый, гүя нидер әйтәсе бар да тик мин сораганны көтә. «Әйт инде, җаным, әйт тизрәк! — дим, күңелемнән аңа ялварып.— Беләсең ич миңа ни кирәген, үзең дә беләсең! Зарыктырма, телдән әйттермә, зинһар!» Ахырда ул мине аңлагандай, тагы да иелә төшеп, шыпырт кына:

— Салих абый килгән иде,— диде.

Мин күзләремне йомдым, әз генә тынып яттым.

— Кайчан?

— Кичә, кич белән...

Ә шулай да нидер буа мине, җиңел генә тын алырга бирми.

— Чак кына көт, Сабира!.. Озак тордымы?

— Салих абыймы? Юк, озак тормады.

— Кем... кем белән сөйләште?

— Әтиегез белән...

Алай икән... Килгән... Озак тормаган... Әтием белән генә сөйләшкән... Ә әнием белән сөйләштеме икән?

Сабирадан сорыйм:

— Әнием белән сөйләштеме?

— Юктыр, ахрысы... Апаның залга кергәнен дә күрмәдем мин...

— Шулай да... күпме торды Салих абыең?

— Ну, күп булса, бер ярты сәгать чамасы... Нигәдер тиз китте.

«Әйе, тиз киткән, тиз... Ә ни өчен?.. Сабира моны белми, әлбәттә... Алар залда икәү генә сөйләшкәннәр. Салих, билгеле, минем хәлемне сорашкандыр, әмма ләкин әтием ни дип әйтте икән? Әтием... Ах, беләсе иде бит! Әнием дә аның килгәнен миңа әйтмәде ич! Мине борчымас өчен генәме?.. Юк, аның өчен генә булмас, ышанмыйм!..»

Минем инде Сабирадан бүтән бернәрсә дә сорыйсым килми иде. Шулай да ул, акланырга теләгәндәй:

— Абзый үзе Салих абыйны озата чыкты,— диде.

Карасана, әтием үзе чыккан!.. Кы-зык! Моңарчы бит Салих артыннан тышкы ишекне гел Сабира ябып кала иде. Ә бу юлы әтием үзе... Сабирага берәр сүз әйтеп калдырмасын дип курыккандыр инде... Әнә ничек саклыйлар икән минем газиз башкаемны, рәхмәт төшкерләре!

— Син бар инде, Сабира,— дидем мин, тагын хәлсезләнә башлап.— Рәхмәт сиңа!

— Ә син, туташ, тыныч кына ят! — диде Сабира, мине юатырга теләп.— Салих абый килер әле, килер!..

Әйе, әлбәттә, диясем килде минем. Әмма беләм: шушы минуттан минем бәгырьне билгесезлек иги башлаячак. Килерме, килгәнен миңа әйтерләрме, әллә инде аңа юл киселдеме? — менә нәрсә турында гына мин өзлексез уйланып ятарга мәҗбүр булачакмын. Хәзер барысы да әтием белән әнием кулында — алар хөкеме барысын да хәл итә. Ә бәлки, иткәннәрдер дә инде... Кай гөнаһ шомлыгына дучар булдым соң мин бу әшәке авыруга? Ник саклана белмәдем, ник шул җылырак бүлмәләренә кереп тормадым?.. Инде менә шуның җәзасын таты: бер кичне аның «яратам» дигән сүзен ишет тә икенче көнне үк аны күрүдән мәхрүм бул, имеш!

Юк-юк, миңа авырып ятарга ярамый, һич тә ярамый! Ничек тә тизрәк торырга, аякка басарга, хәтта авыруымны йомарга, яшерергә!.. Ул кирәк, Салих кирәк миңа!.. Мин бит әле үзем аңа берни дә әйтергә өлгермәдем, күптән йөрәгемдә туганны, телемдә тибрәнгәнне әйтергә өлгермәдем ләбаса!.. Йа Раббем, үзең сихәт бир, үзең куәт бир миңа!..

Әмма... җан теләсә дә, язык җибәрми дигәндәй, күпме генә ашкынсам да, миңа урыннан тору тиз генә насыйп булмады. Хәер, бер генә мәртәбә тордым һәм шуның белән бөтен эшне боздым шикелле. Бик матур кояшлы көн иде. Дөнья әйтерсең нурда коена, кар өсләре учлап энҗе бөртеге сипкәндәй җем-җем уйнаклап тора, кыектан өзе-

леп төшкән тамчылар, кинәт кабынып, тәрәзәмнән күренеп кала. Минем күңелемдә дә кинәт нидер кабынды, бөтен сырхауларым онытылып китте, үземне тәмам терелеп җиткәндәй хис иттем. Әллә каян гына килгән бер җиңеллек белән тиз генә урынымнан тордым, халатымны кидем, иңемә мамык шәлемне салдым да түбәнгә, кухняга төшеп киттем. Дөрес, минем буыннарым хәлсез иде әле, башым да әйләнә иде, ләкин болар гына мине тотамы соң?!

Шулай да әниемнең, мине күргәч, коты алынды:

— Бу ни хәл, ник төштең?

— Менә төштем инде,— дидем мин, тыштагы кояштай елмаеп.

— Иртә әле сиңа, кызым, иртә! Ютәлең дә бетмәгән, йә өзлегеп китәрсең, Алла сакласын!..

— Миңа әйбәт хәзер, ә ялгызыма күңелсез!

— Күңелсез... Ахырын уйларга кирәк,— диде әнием, ризасызлыгын яшермичә, ләкин мине кире куып тормады.

Кухнядагы зур өстәл тәрәзәгә терәп куелган иде — мин шуның бер башына барып утырдым. Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә дигәндәй, Сабира дөбер-шатыр табак-савыт юа, әнием исә куна тактасына он или. Ә мин, тәрәзәдән төшкән кояшка аркамны куеп, әниемнең ике учы арасында тигез генә чайкалган иләккә карап утырам. Вакыт-вакыт ютәлем кузгала, ләкин мин аны ничек тә басарга тырышам. Әгәр шул чакта миңа, тәрәзәгә аркаң белән утырма, дип әйтүче булган булса иде! Юк шул, үзем дә тәрәзә салкынын сизмәдем, әнием дә нишләптер моңа игътибар итмәде.

Кыскасы, шул ук кичне минем яңадан температурам кинәт кенә күтәрелде. Кырыкка җитте ул!.. Ютәлем көчәйде, тавышым үзгәрде, хәтта тынымны да гыжылдап ала башладым. Икенче көнне үк әлеге карт врачны чакырттылар. Ул килгәч, урын өстендә, эчке күлмәгем аша гына күкрәгемне тыңлап карады, иреннәрен кысып, бераз дәшмичә торды, аннары яңадан тыңлады, бары шуннан соң гына әниемә борылып әйтте, салкын тиюдән туташның үпкәсе шешә башлаган, диде... Бу бик җитди авыру иде. Бигрәк тә хәзер, беркаян бернинди дару табып булмаган заманда... Ахыры ни белән бетәр? — моны карт врач та өзеп кенә әйтмәде. Шулай да ул әниемә мине дәвалау ысулларын бик әйбәтләп төшендерде, таба алсагыз, дип, берничә рецепт та язып калдырды. Минем үземә исә: «Гүзәлкәй, бу авыруны сез үзегез генә җиңә аласыз, шуңа күрә нык булыгыз, тәшвишкә бирелмәгез, ты-

ныч ятыгыз, иншалла, сәламәтләнерсез!» — диде... Әмма ләкин миңа барысын да әйтеп бетермәгән икән. Озата чыккан әниемә генә, берничә көннән кризис башланыр, шул чакта мине тагын чакыртырсыз, дип әйтеп киткән.

Хәлнең никадәр җитди-куркыныч икәнен мин беренче көннән үк сиздем. Гүя үлем үзе минем бугазыма ябышырга чамалый иде. Нинди акылга сыймас нәрсә бу — үлем!.. Юк, моның булуы мөмкин түгел, һич тә мөмкин түгел! Алла рәхимле, мин тереләчәкмен, әлбәттә, тереләчәкмен!.. Тик врач бабай кушканны онытмаска, бернинди тәшвишкә бирелмичә тыныч кына, сабыр гына ятарга кирәк миңа.

Ә хәтәр авыру, мәкерле авыру, мине сынарга теләгәндәй, көннән-көн көчәя, көннән-көн аяусыз рәвештә куәтемне суыра бара. Тын алуларым бик-бик авырлаша, күз алларым караңгылана, зиһенем дә еш кына томалана. Мин инде врач әйткән кризисның кайчан башланганын да күпме дәвам иткәнен дә үзем белмәдем. Хәлем искиткеч авыр булган, тәмам кыл өстендә генә калганмын. Үлем чынлап та бугазымнан ала язган, күрәсең... Әмма, Аллага мең шөкер, мин шулай да бирешмәгәнмен, тешем-тырнагым белән каршы торып булса да, җиңеп чыкканмын.

Кризистан соң, мин, ниһаять, күземне ачтым. Иң беренче сизгән нәрсәм шул — мин үземнең, балы агып беткән кәрәз шикелле, бөтенләй бушап, җиңеләеп калуымны тойдым. Билгеле инде, минем кыл кыймылдатырлык та хәлем калмаган иде. Карт врач бер килүендә мине сөендерергә тырышты: «Менә әйттем ич, гүзәлкәй, авыруны сез үзегез генә җиңә аласыз, дип... Яшь организм шул!.. Хәзер куркыныч үтте дияргә дә ярый. Ләкин кузгалырга иртә әле, иртә, озак кына ятарга кирәк әле сезгә!..»

Көне-төне мине карап, минем хәсрәттән әнием дә бик өшәнгән иде. Атналар буе янымнан китмичә кан калтырап утырган чакларында ниләр уйлап, ниләр кичергәнен аның саргаеп-суырылып калган йөзеннән үк күреп була иде. Әниләрнең сабырлыгына исең китәр!.. Авыру карауның бөтен җәфасын күтәрү өстенә, ул әле сиңа бернинди наразыйлык-фәлән дә сиздерми. Ә бит әнием минем авыруымның төп сәбәбен бик яхшы белеп тора, әмма ул хакта авыз ачып ник бер сүз әйтсенче!..

Хәлем бик авыраеп киткән чакларда әтием дә яныма кереп утыргалаган. Тик мин моны үзем белмим, хәтерләмим. Ә менә соңгы тапкыр, инде кризис узгач, кереп чыгуын яхшы хәтерлим. Бик йончыган, картаеп киткән төсле күренде миңа әтием. Хәер... мин аңа туры гына карый да алмадым. Аяк очымда миннән күзен алмыйча күпмедер

басып торганнан соң, ул, башын селкеп, тирән әрнү сиздергән эчке бер тавыш белән, әкрен генә: «Әй, бала, бала!» — диде дә, ничектер авыр гына борылып, ашыкмыйча гына чыгып та китте. Мин аның бөкрәйгән аркасын гына күреп калдым. Әллә аны, әллә үземне кызганып елыйсым килде, ләкин минем еларлык та хәлем юк иде әле.

Әйе, мин чынлап торып үлем куркынычын кичердем. Ә бу бөтен куркынычлардан да дәһшәтлерәк куркыныч кешенең эчке халәтен дә үзгәртмичә калмый икән. Шул куркыныч аркасында мин күпмедер вакытка дөньяның бөтен нәрсәсен онытып тордым. Хәтта «аны» да — «ул» да онытылды, каядыр читкә китте. Чыкмаган җаным, сүнеп бетмәгән аңым бары бер генә нәрсә — үлем тырнагыннан котылу өчен генә көрәшкән булырга тиеш. Тик мин моны бераздан ис кергәч кенә аңладым.

...Инде менә күзләрем ачылуга әлеге гаҗәеп дөнья үзенең язгы кояшы, тәрәзә башында гөрләгән күгәрченнәре, әллә каян гына килгән серле өннәре, гел алышынып торган төс-бизәкләре, онытылмаган хатирәләре, сүнмәс өметләре белән әкрен генә миңа кайта да башлады. Бер үк вакытта, шушы искиткеч тансык дөньяның үзәгенә әйләнеп, «ул» да кайтты. Хәтта кинәт сискәндереп кайтты... Иртәнге сәгатьләрнең берсендә, йокылыуяулы яткан чагымда «ул» минем яныма кергән, миңа иелеп карап тора, имеш! Мин кул сузымында гына — иягендәге чокырын да күрәм кебек... Мин бик курыктым — Ходаем, без ялгыз икәү генә бит, минем өстемдә бер кат эчке күлмәк кенә ич, әнием килеп керсә, ни булыр?! Хәер, шул секундта ук моның саташулы төш кенә икәнен аңласам да, күзләремне ачарга кыймыйча күпмедер әсәрләнеп яттым әле... Төшемә аның әнә шулай бик ачык булып керүен яратам мин...

Минем авырый башлавыма, шәт, айдан артык узгандыр инде. «Шәрык кичәсе» 26 февральдә булган иде, ә хәзер апрель башы булырга тиеш. Менә күпме вакыт безнең очрашканыбыз юк. Кайда йөри икән ул, ни эшләр бетерә икән, мине онытмады микән, безгә тагын килгәне бармы-юкмы аның?.. Әмма ни газап — боларның берсен дә белә алмыйм мин. Минем янга әүвәлгечә бары әнием генә кереп йөри, ул гына карый мине... Гаҗәпләнәм дә мин моңа, чөнки авыруым хәзер йогышлы түгел бит инде, шулай булгач, ни өчен мине, әйтик, Сабирадан аералар?

Дөрес, Сабираның кереп чыккан чаклары да булгалады. Йә өстемне алыштырырга, йә урын-җиремне рәтләргә, ләкин гел әнием барында гына, ул карап торган чакта гына... Билгеле, сүз алышу мөмкин түгел иде, ә шулай

да ул үзенең аз гына хәйләкәр-мәгънәле күз карашы белән нидер әйтергә тели иде кебек. Аннары әшен бетереп, чыгып киткән чагында һаман бер үк сүзне кычкыра биреп кабатлый иде:

— Терел, туташ, тизрәк терел!..— Һәм шушы сүзе белән гүя «синең терелүеңне ул да көтә!» дип әйтмәкче була иде.

Кризистан соң бер ун көн узгач, мин, әкрен генә торып, бүлмә эчендә генә йөргәли башладым. Баскычтан төшәргә-менәргә рөхсәт итмиләр әле. Хәлем дә бик тиз бетә — аз гына йөрим дә тагын урыныма килеп ятам. Каты тоткан икән шул рәхимсез авыру, каты тоткан — тәмам күләгәгә әйләндерде үземне!.. Шулай да адәм баласы — әрсез җан, бер кузгалгач, тырыша-тырмаша булса да үрмәли инде. Мин дә тырышам, мин дә үрмәлим, һәм көннән-көн әкренләп хәлләнә баруымны үзем генә сизеп торам.

Тик менә һава җитми миңа, һава кирәк, саф һавага бик чыгасым килә. Ләкин ул хакта әлегә уйларга да кушмыйлар. Кар суы минем өчен бик хәтәр, тәмам ныгып җитмичә, язгы җепшек һавага чыгарга һич тә ярамый, диләр. Моны карт врач үзе бик нык кисәтеп әйтеп киткән икән.

Ә болай өй эчендә йөрим инде, түбәнгә — кухняга да төшәм. Сабираның мәзәкләрен дә тыңлап утырам, әтием югында залга да керәм (ни өчендер әтием күзенә еш күренәсем килми минем). Бер тапкыр пианино янына да килеп утырдым, капкачын ачтым, клавишларын баскалап карадым. Әллә ничек сәер генә яңгырады аның тавышы — гүя миннән читләшкән кебек тоелды. Бармакларым элекке көчен, җитезлеген югалткан икән шул, бәлки, шуңа күрә рәнҗидер әле минем сизгер җанлы пианинам!..

Ләкин миңа пианиноны озак «рәнҗетергә» туры килмәде. Әнием ишетеп, шунда ук килеп җитте.

— Кызым, сиңа ярамый әле, ярамый,— диде ул, минем ябык иңбашларымнан тотып.— Онытып тор әле син аны хәзергә!..

— Нәрсәне?

— Менә шул нәрсәңне, дим... Йә өзлегеп китәрсең.

— Мин болай да бик озак онытып тордым инде. Музыка яратмый ул онытып торганны.

— Сихәтләнгәч, кызым, сихәтләнгәч, Алла бирсә!

— Ә Салих абый килерме соң? — дидем мин, балаларча беркатлылык белән.

Әнием әз генә дәшми торды. Аннары туры гына җавап бирәсе килмәгәндәй әйтеп куйды:

— Син үзең дә хәзер яхшы уйныйсың, кызым!

— Ләкин бит безнең дәресләребез бетмәгән иде әле.
— Алары инде казага калып торыр...
— Ни дигән сүз ул, мин аңламыйм!.. Музыка дәресләрен өзәргә ярамый бит, әни...
— Ярамаса да туры килә инде.
— Ни өчен?
— Шулай кирәк таптык әтиең белән.
— Ләкин минем үземнән сорамадыгыз ич!
— Әй, бала! — диде әнием, ачынып.— Сорарлык хәлдә идеңмени син?!
— Ул чагында минем терелгәнне көтәргә иде.
— Бу бит инде, кызым, ата-ана эше! Салих әфәндене сиңа мөгаллим итеп әтиең үзе чакырды, үзе менә, вакыты җиткәч, аңа әйбәтләп кенә әйтте дә.
— Нәрсә дип?
— Кызыбыз Гөләндәм белән мондый хәл булып киткәч, без инде сезне артык тотарга җөрьәт итә алмыйбыз, диде. Әнә шулай әдәп белән генә... Шунда ук тиешле акчасын да чыгарып бирде.
Мин ике куллап йөземне капладым: әдәп белән генә, акча сузып, бусагадан борып җибәргәннәр!..
— Оят, оят! — дидем мин, әрнеп-сыкранып.
— Оят? Кемгә оят? — диде әнием, ачулана төшеп.— Син ай ярым урын өстендә яттың, кыл өстендә калган чакларың булды, без әтиең белән атналар буе баш очыңнан китмәдек... Ә кем аркасында?..
Ах, әнә нәрсә икән ул!.. Бик нечкә җирдән тотты әнием. Мин хәтта бер сүз әйтә дә алмадым. Йөземне каплаган килеш, бөгелеп өнсез утыра бирдем.
Әнием йомшара төште:
— Әлбәттә, Салих әфәнде — яхшы музыкант, сине дә күп нәрсәгә өйрәтте, ләкин ул, яшьлеге аркасында булса кирәк, үзенең төп вазифасыннан чыга башлады. Без бит аңа сине җырчы артист итәргә кушмадык.
Бу юлы инде дәшмичә каласым килмәде. Әнием күптән ишетеп белгәнне, ниһаять, үзем әйтергә булдым:
— Әйе, мин «Шәрык кичәсе»ндә чыгып җырладым, ләкин бу бит әле артистка булам дигән сүз түгел. Анда минем кебек һәвәскәрләр күп иде.
— Инде үзең дә танмыйсың икән! — диде әнием, авыр гына сулап.— Әй, кызым, кызым!.. Ә нәтиҗәсе ни булып чыкты?.. Юк инде, безнең бердәнбер кызыбызны югалтасыбыз килми — Салих әфәнде гафу итсен!
— Ләкин бит минем авыруыма ул гаепле түгел!..
— Ә котыртып илтүче кем соң?
— Ах, әни, ник алай дисең?! Үзең рөхсәт иттең ич!

— Минем сиңа якмаган сәхнәләргә чыгып җырларга рөхсәт иткәнем юк!

— Аның ни гаебе бар соң?! — дидем мин, ниһаять, яшьләремә буылып.

Әнием чынлап курка калды.

— Гөләндәм, балам, тукта, җитәр! — диде ул, башымны ике кулы белән дә күкрәгенә кысып.— Сиңа болай гасабиланырга ярамый, ярамый, ишетәсеңме? Бетерик, сөйләмик, буласы эш — булган, ахырын Алла хәерле итсен!

...Озак тыела алмадым мин. Йөрәгемә бик күп җыелган икән шул... Көчсезлек, гаҗизлек, билгесезлек, әйтелмәгән, әйтеп тә булмый торган сүзләр — барысы да әче, кайнар яшькә әйләнеп акты да китте. Сау чагым булса, бәлки, тыела да алыр идем, ә хәзер, әйдә, аксын, чыгып бетсен инде, булмаса! Мин тынычлана төшкәч, әнием мине сак кына урынымнан торгызды һәм үз бүлмәмә хәтле озата да менде. Урын-җиремне яхшылап рәтләгәч, ятарга кушты.

— Менә шулай тыныч кына ят, кызым! — диде, өстемә юрганымны каплап.— Берүк өзлегә күрмә инде...

Ләкин үзе чыгып китәргә ашыкмады. Аз гына нидер уйланып торды да аяк очыма карават читенә генә утырды. Беравык миңа сынагандай карап торганнан соң, сабыр гына:

— Кызым, Гөләндәм! — диде.— Бер сүз чыкканда сиңа шуны да әйтәсем килгән иде. Тик син борчылма, тыңлап кына ят!.. Ийе, менә шуны әйтмәкче идем: дөньяның хәзер бик хәвефле чагы, кызым. Сугышлар тагын көчәйде булса кирәк. Уралдан Колчак дигән берәү кызылларга каршы һөҗүм итеп килә, диләр. Уфаны алган икән инде... Ә җәнүптән* Деникин дигән бер генерал һөҗүм башлаган, имеш. Бу власның гомере әллә бар, әллә юк — Ходa белсен!.. Шәһәрдә төрле шомлы хәбәрләр йөри, тентүләр, кулга алулар да көчәйгән, шикле кешеләрне чүпләп кенә торалар икән. Әтиең менә елдан артык кәсепсез утыра, беркая чыкмый-йөрми, көн итүләре бик авырлашты, кызым! Үз хәлебезне үзебез генә беләбез... Авырып китмәсәң дә, музыка дәресләрен барыбер өзәргә туры килер иде. Бел, аның кайгысы түгел бездә — баш кайгысы!.. Бер Ходаның үзеннән иминлек сорап, заманның тынычланганын сабыр гына көтеп ята торган чак... Шуңа күрә, Гөләндәм, сиңа да әйтәсем килә: онытып тор әле син барысын да, онытып тор!.. Күңелеңне дә бозма, юкбар уйлар белән башыңны да ватма!.. Сәламәтләнәсең бар әле синең, аякка басасың, ныгыйсың бар... Хак Тәгаләдән

---

* Көньяктан.— *Ә.Е.*

шуны сорыйк, кызым!.. Бик куркыттың син безне, бик куркыттың... Уеннан уймак дигәндәй, бик хәтәр авырып киттең шул... Ә хәзер тыныч кына ят инде, балам, йокларга тырыш, йокы бик файдалы ул синең өчен!..

Әнием юрган аша гына аягымны, кулымны сыйпаштырды да урыныннан торды. Ә мин күзләремне йомган идем, йоклар өчен түгел — башка берни дә ишетмәс өчен йомган идем. Җитте инде, җитте! Хәлсезләндем дә бугай, температурам да азрак күтәрелде шикелле. Ләкин минем аны үлчәп карыйсым килмәде.

Әйе, әнә шулай, барысын да онытып торырга кушып чыгып китте әнием. Онытып торырга?! Мөмкинме соң бу?.. Йөрәк тибүдән туктап тора алмый бит!.. Бер типкән арада да күңелгә ниләр генә килеп китми! Ниләр генә!

...Ә Салих килмәс, юк, килмәс инде. Кирәгем бетте минем бу йортка, дигәндер... Әле безгә яңа килеп йөри башлаган чагында ук ул миңа ничектер бер әйткән иде, Әхмәтҗан абзый өчен мин бары музыкант кына, сезне укытырга кирәгем булмаса, өенә аяк та бастырмас иде, дигән иде. Мин ул чакта аңа каршы төшеп, юк, бу дөрес түгел, әтием сезне бик хөрмәт итә, дип әйткән идем. Ә хәзер кем хаклы булып чыкты инде?.. Ә бәлки әле, Салих абый болар барысы да миңа әйтеп, минем ризалык белән эшләнгәндер дип тә уйлый торгандыр... Әгәр шулай уйласа, бу бит коточкыч гаделсезлек булачак... Әйе, коточкыч. Йа Рабби, ничек кенә төзәтим мин бу гаделсезлекне, ничек кенә... Мин бит әле көчсез, мин бит әле берни дә, берни дә эшли алмыйм!..

Әмма юк, мин ышанмыйм, ышанасым килми, теләмим. Уйламас ул алай, уйламас — уйларга тиеш түгел. Ярата ич ул мине, ярата! Үзе әйтте ич, саф, мөкатдәс бер ярату белән яратам, диде... Ә яраткач, начар уйламыйлар бит инде, шулай түгелме?! Яраткач, матур уйлыйлар, гел сагынып кына, шулай ич?! Ә мин терeләчәкмен, кадерлем, тереләчәкмен, Алла бирсә!.. Без көрәшәчәкбез, кадерлем, әлбәттә, көрәшәчәкбез!

Тик менә... ниткән Колчак икән ул тагын?.. Уралдан килә, диме?.. Ни өчен килә, кызылларны бетерергәме? Салих өчен дә куркынычтыр бит бу?! Ачыктан-ачык кызыллар яклы ич ул!.. Ни булыр аңа? Ләкин мин бәхетсезлек көтмим, мин сине югалтуыма ышанмыйм, дустым, юк, ышанмыйм! Син югал, имеш! — ничектер акылыма сыймый бу минем...

...Караңгы да төшеп килә икән инде... Эңгер-меңгер вакыты. Шәһәр чиркәүләре зур чаңнарын салмак кына кагалар: доң... доң... доң!.. Бик ямансу була миңа бу ва-

кытта... Дөнья гүя миннән әкрен генә ераклаша, ераклаша... Син дә ераклашасың, каядыр китәсең, китәсең... әмма, күпме генә ераклашсаң да, мин сине күрәм — офыкта кабынган бердәнбер йолдызым төсле итеп күрәм мин сине, кадерлем!..

## XIV

Кар сулары китеп бетте. Җир сарыкты, утырды, кипте. Тик урам уртасында гына ишегалларыннан ыргыткан соңгы боз кисәкләре эреп яталар. Көннәр бик җылы тора, тиздән аларның да юеш эзләре дә калмас, болай булгач...

...Җылы-җилсез көннәрдә мин дә һавага чыгып йөри башладым. Үзебездән ерак китмим, күбрәк Кабан буенда гына әрле-бирле йөренәм. Сәламәтләндем дияргә ярый инде... Ләкин нишләптер бик озакка сузылды бу сәламәтләнү — менә һаман да әле тәмам хәлләнеп, ныгып җитә алганым юк... Берара әйбәт кенә алга киткән идем, аннары тагын кирегә чиккәндәй булдым. Нидер ярамады... Шуңа күрә миңа бик сакланырга кушалар. Үпкә чиреннән соң яңадан өзлегү бик хәтәр нәрсә ул, диләр (Чехоткага әйләнеп китүе бар, имеш!). Йөрергә чыга башласам да, әнием кат-кат киенергә кушып, теңкәмә тиеп бетә, артымнан гел, озак йөрмә, ерак китмә, суга якын барма, дип ялварып кала.

Кабан инде боздан арчылган, аңа хәзер Болак аша Идел суы керә, ул тулып-күтәрелеп, гүя киерелә биреп ята. Яр битләрендә беренче тере яшь үлән дә баш төртеп чыгып килә. Карт тирәкләрне сырган бөреләр дә көннән-көн бүртә, сагызлана бара — тиздән, бәлки, нәни яфракларның очлары да күренә башлар. Ә аннары барысы да, гөлт итеп кабынгандай, ямь-яшел җилфердәшеп китәр бер заман!.. Әнә шулай килә язлар — һичнигә карамыйча!..

Тик минем язым гына нигәдер килергә ашыкмый. «Ул» юк, очраганы да юк, хәбәре дә юк. Билгесезлек мине газаплый. Күңелем, җәйрәп яткан шушы тын күлдәй, сагыш, сызлану, нәүмизлек белән тулы... Аерылышканга ике ай тулды бит инде. Бигрәк кинәт өзелде барысы да — исең китәр!.. Билемнән йомшак кына тотып, извозчикта озата килде, ике көннән хәлеңне белергә керермен, бәгърем, дип, вәгъдә биреп калды һәм менә шуннан соң, ай күрде, кояш алды дигәндәй, минем өчен юкка чыкты да куйды!.. Әмма өметемне һич тә өзмим әле мин. Без бит бер шәһәрдә яшибез, бер үк урамнардан йөрибез. Без, әлбәттә, очрашырбыз, очрашмыйча калмабыз, насыйп булса! Тик кайчан, кайда! — эш бары шунда гына!

Йөрергә чыккан саен бу өмет миндә уяна. Гүя ул да күл буена килеп, мине көтеп йөридер кебек тоела башлый миңа. Кабаланып өйдән чыгам, карана-карана урам башына чаклы бер узам, ике узам, аннары чатта тукталып, иптәшләрен югалткан баладай, тик кенә басып торам. Ләкин әнә теге яктагы халык кайнашкан «Болгар», «Амур» тирәләренә барасым килми — оялам, дөресен генә әйткәндә, хурланам да: эзләп йөрү кыз кешенең эшемени ул?! Нәүмизлек баса мине, авыр миңа, әмма ләкин түзәргә кирәктер инде, сабыр итәргә, өметне учтан төшермәскә кирәктер...

Минем хәлне бердәнбер аңлаучы — ул да булса Сабира иде. Аңа әйтү кирәк тә түгел, үзе барысын күрә дә, белә дә ул... Бер-ике тапкыр миннән: «Туташ, Салих абыйны эзләп табыйммы әллә?» — дип тә сорады. Ләкин мин аңа: «Бар, тап!» — дип әйтә алмадым,— оялумы, хурланумы — нидер тотты мине... Шулай да Сабира, шәһәргә чыккалаган араларда каяндыр ишетеп, миңа кайбер хәбәрләр китерде. Мәсәлән, театр (ягъни кышкы сезон) ябылган икән инде, артистларның күбесе фронтларга киткәннәр, имеш, ә бер төркемне ни өчендер Самарага да җибәргәннәр... Бу «имеш» хәбәрләр мине бер яктан әзрәк тынычландырса, икенче яктан хәвефләнергә дә мәҗбүр итте. Болай булгач, дип уйладым мин, Салих та шәһәрдә ялгыз калмас, ул да башка артистлар белән бергә кая да булса киткәндер. Тик менә солдат итеп кенә алып куймасыннар үзен! — бу мине борчый, бик борчый. Сугыш бик куркыныч нәрсә бит ул, Алла сакласын!.. Хәер, аның кулына мылтык тоттырмаслар — мылтык тотар өчен яратылмаган ич аның куллары!

Кыскасы, мин өмет белән яшим. Вакыты шулай — кеше бүген монда, иртәгә әллә кайда. Атналар, айлар үтсә дә, мин аны көтәчәкмен! Көтү... ышанып, сагынып көтү минем эш — кызлар эше ул!

Июнь башларында Сембердән безгә әниемнең бертуган энесе Касыйм абый килде. Соңгы бер-ике елда аның килгәне юк иде — заманнар да буталып китте, юл йөрүләр дә мөшкелгә әйләнде. Шуңа күрә кадерле абыйның һич көтмәгәндә килеп чыгуы барыбыз өчен дә (бигрәк тә әнием өчен) зур шатлык булды. Өйгә бәйрәм төсе керде, өстәлдән аш-су өзелмәде, ә сорашу-сөйләшүләрнең очы-кырые булмады.

Касыйм абый аеруча миңа карап гаҗәпләнә иде.

— Гөләндәм, карале, син тәмам җиткән кыз булгансың лабаса! Һай-һай-һай!.. Бөтенләй чибәр туташка әверелгәнсең... Күз генә тия күрмәсен үзеңә! — ди ул, кат-

кат башын чайкап. Бер түгел, берничә мәртәбә әйтте ул моны... Аңа ияреп, мин үзем дә гаҗәпләнә калдым: ике ел җитеп килгән кыз өчен күп вакыт, күрәсең... Ә шулай да әллә ничек уңайсыз, оялам... Нидер уйлап әйтә шикелле абыем... Бер тапкыр әниемнән дә сорап куйды:

— Гөләндәмгә ничә яшь соң инде?

— Апрельдә унҗидесе тулды,— диде әнием.

— Алай икән, балигъ булган икән шул,— диде Касыйм абый, мәгънәле генә итеп.

Бу ишеткәннәрем миндә билгеле бер шик һәм сагаю уятты. Нидер бар абыйның уенда, нидер бар!.. Моны сизеп була бит. Бигрәк тә кичке чәйдән соң аның миннән гел генә пианино уйнатуы, шул чакта миңа бик сынап каравы һәм комплимент әйткәләве, ә мин чыгып киткәч, өчәү генә калып, ярты төнгә кадәр сөйләшеп утырулары — болар барысы да юкка гына булмаска тиеш иде... Чынлап та, нинди максат белән килеп чыкты икән Касыйм абый көтмәгәндә генә?.. Әллә хат белән чакырдылар микән үзен?.. Дөрес, әти-әниемнең бертуган якын кеше белән сөйләшер сүзләре күптер инде... Хәзерге хәвефле вакыт, тормыш авырлыгы, баш-мал кайгысы — беткәнмени шуның кебек киңәшер нәрсәләр... Әмма, сизеп торам, сүз, һичшиксез, минем хакта да бара... бара булса кирәк. Җиткән кыз диләр ич! (Ходаем, бу сүзнең ни икәнен бары мин үзем генә белергә тиешмен бит!) Җиткән кызның язмышы турында уйламыйлар-киңәшмиләрме соң?! Җиткән кызны күрүчеләр, белүчеләр, аңа исәп тотучылар булмыймы соң?! Һәм моңа каршы берни эшләр хәл дә юк икән ләбаса!..

Кыскасы, мин тынычлыгымны җуйдым, хәтәр сизгән кошчык кебек, үземә урын таба алмый башладым. Әнием миңа бүген булмаса иртәгә нидер әйтер кебек — мин менә гел шуны көтеп йөрим. Ләкин көн артыннан көн уза, әтием белән Касыйм абый көндезләрен шәһәргә чыгып, базар тирәләреннән, үзәк урамнардан, мәйданнардан йөреп кайталар. Касыйм абый, туры килгәндә, мәйданнардагы митингларны да туктап тыңларга ярата икән. Кайткач, исе киткәндәй: «Кара, безнең татар иптәшләр дә авызларыннан ут чәчәргә остарып беткәннәр ләбаса»,— дип сөйләнә. Ә кичләрен тагын сөйләшеп утыралар, самавыр яңартып, чәйләр эчәләр, әмма миңа беркемнең бер сүз әйткәне юк әле. Шул рәвешчә атна-ун көн вакыт узып та китә. Касыйм абый китү турында да сөйләнә башлый. Мин инде тынычланган кебек тә булам. Ләкин ашыга төшкәнмен икән — менә беркөнне иртәнге чәйдән соң әнием, ниһаять, миңа әйтте:

— Кызым, Касыйм абыең безне үзе белән алып китмәкче була,— диде.

Мин, билгеле, шунда ук сагая калдым:

— Кемне?

— Синең белән мине инде.

— Кая, Сембергәме?

— Юк, Сембергә түгел, үзләренең утарларына чакыра. Җәйнең матур чагында ял итеп китәрсез, ди.

Мин дәшмәдем, әнием исә, сүзен дәвам итеп:

— Без әтиең белән бу эшне бик мәгъкуль күрдек,— диде.— Синең үпкәләрең таза түгел, сиңа авыл җирендә ял итү бик файдалы булачак, кызым.

— Анысы шулай да бит,— дидем мин, аптырабрак,— тик вакытымы соң хәзер?

— Нигә, иртәрәк дисеңме?

— Юк, алай димим... Сугыш вакыты бит, андый ерак җиргә бару куркыныч булмас микән?..

— Аллага тапшырырга туры килә инде, кызым. Абыең әйтә, безнең якларда хәзер тынычлык, ди. Ходай язмаган эш булмас, тәвәккәлләргә кирәктер, ахрысы...

— Белмим шул, әни,— дидем мин, борчылуымны яшермичә.— Нигәдер күңелем тартмый.

— Йә, йә, кирегә юрама әле,— диде әнием, ачуланыбрак.— Синең өчен тырышабыз, сиңа саф һава, яхшы тәрбия кирәк. Дәү этиләреңнең утарын беләсең ич, аның кебек җиргә кеше акча түләп тә бара.

Әйе, беләм, бик яхшы беләм мин дәү әтиләрнең утарын. Гаҗәеп матур җирдә утыра ул ялгыз утар. Бер йөз адымда гына чокыр төбеннән бик саф, бик йөгерек инеш агып ята, каршыда гына, каплап куйган казан сыман, бөдрә әрәмәлек каплаган йомры тау тора, инеш үрендә, бер-ике чакрым китсәң, зур калын урман башлана, инешнең бу ягында исә, чокырны менгәч тә, чирәм яткан типтигез ялан башланып китә... Тау итәгендә куе чиялек, урманда какы, балтырган, чикләвек, ә чирәмлектә яфрак асты саен кызарып, пешеп яткан җир җиләге... Юньләп җыйган кеше дә юк, ичмасам!

Бу утарны минем дәү әти, әниемнең әтисе, Сембернең ахун хәзрәте, әллә бөлгән, әллә күчеп киткән бер байдан кайчандыр сатып алган булган. Шуңа күрә аны хәзер Ахун утары дип йөртәләр. Ләкин бабай үзе дә һәм уллары да шәһәрдә торгач, монда, бу утарда, хуҗалык эшләре белән чынлап шөгыльләнмәгәннәр. Игенне бик аз иккәннәр, бераз мал асраганнар, умарта тотканнар һәм күп итеп (сатар өчен) печән чаптырганнар. Асылда кечкенә утар аларның җәйләрен бала-чагалары белән кай-

тып, ял итә торган дача сыман урыннары булган. Дәү әтием үзе умарта карарга һәм үлән-чәчәкләр җыеп киптерергә яраткан... «Тәңренең шушы шифалы ганимәтләре өчен генә асрыйм мин бу утарны»,— ди икән ул.

Инде менә Касыйм абый безне шунда алып китмәкче була. Бармаган җиребез түгел. Рәхәтләнеп, җәелеп дигәндәй, безнең анда ял иткән чакларыбыз булгалады. Бик яраткан идем мин ул еракта гы утарның инешен, шау чәчәктәге яланнарын... Башка вакыт булса, мин куанакуана барырга риза булыр идем. Әнием дә хаклы, минем сәламәтлегем өчен һичшиксез файдалы булачак анда. Әмма хәзер минем Казаннан бер җиргә дә чыгып китәсем килми. Казан тота мине, Казан җибәрми. Китсәм, үкенечкә булыр кебек, гомерлек үкенечкә!.. Күңелемдә сүнеп бетмәгән өметем бар — шул кадерле миңа, шуны саклыйсым килә!.. Ләкин китмәс өчен нинди генә сылтау табарга? Юк бит ул, юк! Инде сәбәбен әйтмичә генә, балаларча киреләнеп, юк, бармыйм, дисәм, бу әти-әниемне, бигрәк тә Касыйм абыйны бик гаҗәпләндерәчәк, нигә, ни өчен дип сорашу китәчәк, хәтта әле миңа карата тәгаен бер шик тә тудырачак. (Әнием исә барырга теләмәвемнең асыл сәбәбен бик тиз сизеп алачак.)Нишләргә соң инде, нишләргә? Бик четерекле бит әле минем хәлем, ни уйларга, ни әйтергә дә белмим...

Ә кичке чәй янында Касыйм абый үзе инде ул хакта сүз башлады:

— Әниең әйткәндер, Гөләндәм, мин бит сезне алып китәргә дип килдем. Үзебезнең утарга... аның хәзер бик хозур чагы, рәхәтләнеп бер ял итеп китәрсез, ийе!..

— Рәхмәт инде, Касыйм абый! — дидем мин, җавапсыз калмас өчен генә.

— Менә бик әйбәт... Берсекөнгә юлга чыгарбыз, Ходай кушса!

— Шулай ук бик тизмени?..

— Ә нигә сузарга? Кунак булдым инде, Казаныгызны күрдем... Печән өсте дә җитә. Миңа утарга кайтырга кирәк, чибәрем!..

— Ә соң анда... утарда куркыныч түгелме? Ялгыз урын... Шомлы хәбәрләр йөри...

— Син, Гөләндәм, бер дә борчылма! — диде Касыйм абый, тиз генә.— Безнең ул якларда, шөкер, хәзергә тыныч әле. Шәһәрдән ерак, олы юллардан читтә, безгә сугылган кеше дә юк. Аннары безнең утар кечкенә бит, бояр имениесе түгел. Ә боярларны талап бетерделәр инде... безгә, Аллага шөкер, кагылучы да булмады.

Мин дәшмәдем — бу хакта мин ни беләм дә ни әйтә

алам?! Касыйм абый, минем икеләнүемне тәмам сындырырга ашыгып:

— Әле мин сиңа, Гөләндәм, иң кирәген әйтмәгәнмен икән,— диде.— Дәү этиең, синең авырганыңны ишеткәч, бик хафа булды. Сезне алып кайтырга да ул кушып җибәрде. Туташыбызга хәзер саф һава, таза аш, кымыз кирәк булыр, диде. Утардагы кешебезгә бер бия дә бәйләргә кушты... Әнә ничек борчыла синең өчен дәү этиең, сылуым!..

— Әйе,— диде этием дә,— дәү этисе Гөләндәмне үз баласыннан да якынрак күрә шул... Аның сүзен тыңламау зур сансызлык булыр иде... Менә мин дә шуны уйлап, хәвефле чак булса да, каршы килмәдем. Барырга кирәк, кызым, дәү этиеңнең фатихасын алырга кирәк.

Йә, моннан соң мин, юк, бармыйм, дип, ничек әйтә алам? Дәү этием үзе кушкан бит!.. Ә мин аның минем өчен хафалануына да, алып кайтырга кушуына да ышанам. Дөрес, дәү этием — карт хәзрәтнең онытлары аз түгел иде, ләкин алар барысы да аның янында диярлек, ә мин берүзем читтә, еракта, шуңадыр инде ул мине аеруча бер җылылык, күңел нечкәлеге белән ярата торган иде. Бик кечкенә чагымда ук инде әнием мине Сембергә, дәү этиләремә еш кына алып кайта торган булган. Әле дә хәтеремдә: дәү этием мине тезенә утыртып, ак сакалы белән муенымны кытыклый-кытыклый, колагыма әкрен генә нидер көйли иде, ә ял итәргә ятса, гел генә кочагына алып ята торган иде. «Бәбкәчемнең исен яратам шул»,—дип әйтә икән... Инде буй үсеп, кыз булып җиткәч тә, ул миңа һәрвакытта бик йомшак, бик игътибарлы булды. Минем киләчәк язмышым өчен эчке бер уйлану, борчылу сизә идем мин аңарда... Ул үзе дә миңа: «Ике догамның берсендә, кызым, синең исемеңне Алла каршында яд итмичә калмыйм»,— дип, еш кына әйткәли иде.

Менә ни өчен Касыйм абыйдан «дәү этиең кушты» дигәнне ишеткәч, мин инде каршы бер сүз дә әйтә алмадым. Дөресрәге, намусым мине карышмаска мәҗбүр итте. Ә өметемне мин, өметемне, кая гына барсам да саклаячакмын. Аннары, без бик озакка китмибез ич, ике-өч атнадан, исән булсак, борылып та кайтырбыз. Барыбер шәһәр халкының да таралып торган чагы — әнә шулай юатырга тырыштым мин үземне... Тик соңрак әнием алдында бер шарт куйдым: «Сабира да барсын, Сабира барса гына барам»,— дидем.

Әнием, гаҗәпләнгән булып:

— Бусы тагын ни? — диде.— Чәчләрегез бәйләнмәгәндер ич!

— Ә мин анда ялгыз башым нишләрмен?

— Без бар ич, тагын кем кирәк сиңа?

— Миңа иптәш кирәк. Иптәшсез мин беркая чыга да, йөри дә алмаячакмын...

— Ярый, юк өчен хәсрәткә тарма! — диде әнием, мине тынычландырып.— Сабираны үзебездән калдырмыйбыз.

Шул ук кичне мин, Сабираны куандырырга теләп, аның үзенә дә әйттем.

— Беләм,— диде Сабира, исе китмичә генә.

— Каян беләсең?

— Апа миңа өченче көн үк әйтеп куйды.

— Өченче көн үк!.. Ә ник син аны миңа әйтмәдең?

— Әниеңнән узып әйтергә тагын! — диде Сабира, кырыс кына.— Апа болай да миннән бик шикләнә!

— Шикләнә?! Ни диеп?

— Сүз йөртмәсен диептер инде. Сизә бит ул безнең араны.

— Әллә сораганы да бармы?

— Юк, сораганы юк. Апа хәйләкәр ул, сынап кына йөри.

Аңлыйм инде, аңлыйм... Әнием миңа да ышанып бетми, Сабирадан да шикләнә. Утарга алып китүнең дә берәр сере бардыр әле, кымыз эчеп, ял итәр өчен генә булмас!.. Мин авыр гына сулап куйдым.

— Менә китәргә туры килә инде... Дәү әтием чакырткан. Ярый әле, син дә барасың.

— Әйе, беләм.

— Син барысын да беләсең... Тик...— мин сүземне әйтеп бетермәдем.

— Нәрсә «тик»?

— Йә, ярар инде!

— Юк, юк, әйтеп бетер,— диде Сабира, бәйләнә калып.— Нәрсә ул «тик»?

Бик уңайсыз иде миңа, шулай да әйтмәс җиремнән әйттем:

— Тик «аның» гына кайда икәнен белмәдең.

— Үзең гаепле,— диде Сабира, кычкыра биреп.— Миңа ихтыяр куйган булсаң, мин аны сиңа җир астыннан табып китергән булыр идем, беләсеңме?

— Чү, шаулама! — дидем мин, сискәнеп.— Җитәр, сөйләмик ул хакта.

Сабира тиз генә мине иңбашымнан кочаклап алды:

— Җаным, бәгырем! Иркә туташым! Син бер дә кайгырма!.. Ул үзе сине эзләп килер, бер айдан, ике айдан, әмма барыбер эзләп килер!.. Менә әйтте диярсең! Син кошчыкны онытa аламы соң ул?!

Шунда ук бугазыма төер килеп тыгылды — мин йөземне тизрәк читкә бордым. Тынычлана төшкәч кенә:

— Ярый, куйыйк аны... Безгә әзерләнергә дә кирәк бит әле,— дидем, аннары җанланырга тырышып дәвам иттем: — Беләсеңме, дәү этиләрнең утары шундый матур җирдә, каршыда гына тау, чиялек, кечкенә генә инеш...

— Беләм, җаным, беләм! — диде Сабира, чын-чынлап куангандай.— Китәбез, Ходай кушса!.. Казанны җир йотмас әле... Җәйнең шушындый хозур чагында, син әйткән инеш буйларында ял итеп, күңел ачып, шәкертләр әйтмешли, бер сәрхуш булып кайтырбыз, ичмасам! Тик син борчылма, җаным, борчылма!

— Мин... борчылмыйм...

— Менә бик әйбәт!.. Шулай кирәк... Йә, нәрсәләреңне алмакчы буласың?

Чынлап та, нәрсәләр генә алыйм икән соң?.. Күп аласым килми: берничә ситсы күлмәк, жакет, җәйге җилән, җиңел туфлиләр — утарда йөрер өчен шулар, минемчә, бик җиткән. Һәрхәлдә, затлы күлмәкләремнең берсен дә алмыйм — минем анда кыз багар өчен килүчеләргә күренәсем юк әле. Ләкин Сабира бер яхшысын да алырга куша: «Белмәссең, шәһәрдән кунаклар килүе бар, шул чакта ни киярсең?» — ди. Ярый алайса, дидем дә, тагын бер модныйрак тегелгән ефәк күлмәгемне дә алырга булдым. (Соңыннан әнием, минем әйберләрне тикшереп, бер дә канәгать булмыйча, тагын берничә затлы күлмәк, шуның өстенә энҗеле калфагым белән зиннәтле тагар нәрсәләрне дә алырга кушты. Утарда аларның нигә кирәге бар? дигәч, анысын мин үзем беләм, син әйткәнне тыңла, дип кенә җавап бирде. Бик гаҗәп иде бу да! Мин ни уйларга да белмәдем.)

...Икенче көнне инде без бары җыену, әзерләнү мәшәкате белән генә уздырдык. Әнием иртән иртүк, зур мичне ягып, пешеренергә тотынды. Татарның гадәте, юлга чыга башласа, хаҗга җыенгандай, әллә никадәр азык-төлек әзерли. Өч тавык кына суеп кыздырдылар. Сарык ите белән бозау ите дә куырылды. Берничә таба вак бәлеш. Шуның өстенә тагын күпме камыр ашлары!.. Әкәмәт инде... Тик шуны әйтергә кирәк, без утарга атларда барачакбыз икән. Чөнки утар Иделдән шактый еракта — пароход белән китсәң дә, Сембергә җитеп, аннан барыбер атларда барырга туры киләчәк. (Әлек без гел шулай Сембер аша йөри идек.) Ләкин Касыйм абый әйтә, пароходларга хәзер ышаныч юк, ди, хәрбиләр басып алып бетерделәр, ди. Шуңа күрә атлар яллап, туп-туры Казанның үзеннән бару тынычрак булачак, ди... Ә бу ике көнлек юл икән. Пешергән-төшергән азыкларны, бәлки, ашап та бетерербез әле.

Әтием белән Касыйм абый бөтен әзерләгән нәрсәләрне — кием-салымны, юлда ашыйсы, анда баргач тотасы

азык-төлекне, кәрзин-әрҗәләргә тутырып, баулар белән кат-кат урап, бәйләп, зал уртасына куйдылар. Кичкырын гына Сабира белән без икәү мунча ягып уздырдык. Башта әтием белән әнием, аннары Касыйм абый кереп чыкты. Иң ахырдан гына җылы мунчада без — ике кыз — әйбәтләп юындык. Шул эшләр белән җәйге озын көн үтеп тә китте.

Ә иртәгесен сәгать алтыда ук безнең капка төбенә пар атлар җиккән ике тарантас килеп туктады. Аларның берсен әтием, икенчесен Касыйм абый яллаган. Хуҗалары татарлар, олы гына яшьтәге агайлар, әтиемнең танышлары икән.

Алар килгәндә без инде иртәнге чәйне эчеп өлгергән идек. Озак кымшанмыйча гына киенештек-ниттек тә утырышып бер дога кылдык. Аннары ирләр кәрзин-төеннәрне чыгарып, тарантасларга әйбәтләп урнаштырдылар. Беренче атка әнием белән Касыйм абый, икенчесенә Сабира белән мин иплэп кенә утырдык. (Ярый әле, тарантаслары рессорлы, югыйсә рессорсыз тарантас таш юлда бик яман сикертә ул...) Ниһаять, агайлар да, җилән чабуларын җыештырып, кучерга менеп утырдылар. Әтием безгә: «Хәерле сәгатьтә!» — диеп, ялгызы капка төбендә басып калды.

Атлар кузгалып тыкрыктан таш урамга борылгач, тигез генә бәргән тояк тавышлары белән тып-тын күл буен яңгыратып, җиңел генә юырттырып та киттеләр. Мәскәүский чатына да килеп җиттек, ләкин бу тирәдә дә тынлык һәм бушлык иде. Иртән иртүк ачыла торган чәйханәләр, хәрчәүниләр барысы да ябык. Ә зур магазиннар һәм складлар янында мылтыклы хәрби сакчылар тора. Җәйге иртәдә шәһәрнең бу кадәр буш булуы бик сәер иде — гүя ул тынын чыгармыйча нидер көтә кебек.

...Дамбаны да уздык, Бишбалтаны да үттек, инде менә Үсиягә дә килеп җиттек. Безне моннан аргы якка, Югары Осланга атлар, арбалар ташучы «Волгарь» дигән пароход чыгарырга тиеш. Шуннан соң тау яклап безнең озын юлыбыз башлана.

Яр башында туктап торабыз. «Волгарь»ның теге яктан чыкканын көтәбез... Иделне минем быел беренче мәртәбә күрүем әле. Һәркемгә дә шулай микән, әмма минем үземә Иделнең гаҗәеп бер тәэсире бар. Аның ярына килеп баскач та, дөнья, ничектер бердән киңәеп, яктырып киткәндәй була. Хыял шунда ук аның куәтле, сабыр агымына ияреп, әллә кайларга — еракларга китеп бара... Тарта, бик тарта Идел үзенә!.. Дәшә, чакыра!.. Шуңадыр инде ел саен Идел буйлап кая да булса барып кайтмыйча җан һич тә түзә алмый.

...Салмак кына ишелеп аккан мәһабәт елгага карап, шулай онытылып утырган чагымда, Сабира кисәк кенә минем янтыгыма китереп төртте. Мин хәтта сискәнеп киттем.

— Туташ, карале! Артыңа кара! — диде ул, кабаланып.

Мин аның бу кыланышына гаҗәпләнебрәк борылып карадым. Артыбызда гына авыл агайлары утырган берничә арба тора. Искитәрлек берни дә күрмим.

— Йә, нәрсә бар соң? — дим.

— Ә син иң артка кара, яңа гына бер пар ат килеп туктады, шуңа кара!

— Йә, шуннан?

— Күрмисеңмени? — диде Сабира, өтәләнеп.— Анда утырган егетләрнең берсе Салих абый ич!

Йа Рабби!.. Берьюлы хәлсезләнеп киткәндәй булдым, кинәт тавышым югалды. Көчкә генә әйтә алдым:

— Булмас ла!..

— Күзеңә ак төштеме әллә, гарип! — дип тирги Сабира мине.— Шул инде, Салих абый, нәкъ үзе, эшләпәдән!

Юк, күзләремә ак төшмәде төшүен, әмма яшь пәрдәсе җәелеп өлгерде. Шулай да мин аны күрдем, күрдем... Әйе, тарантас кырыенда утырганы, эшләпә кигәне Салих шул, Салих! Йа Раббем, ничек туры китердең, ничек итеп юлларыма китереп чыгардың син аны?!

Ә Сабира, тиле, кулларын чәбәкләп, сикергәләнергә тотынды.

— Ул да безне күрде! Күрде, күрде... Әнә, тарантасыннан төшеп, безгә таба килә!

Мин, тиз генә борылып, иелеп, күзләремне сөртергә ашыктым. Селкенергә дә куркам үзем... Ул килеп җитте. Ул дәште, әкрен генә дәште:

— Гөләндәм!.. Гөләндәм... син?!

Мин аңа таба борылдым һәм... башымны гына кактым — авыз ачарга көчем җитмәде. Ә ул миңа карый, керфек тә какмыйча йотылып, сөенеп, гаҗәпләнеп карый, мин дә бу күксел-зәңгәр күзләрнең сихеренә эләккәндәй карыйм, карыйм, ә сүз юк, сүз чыкмый, икебез дә телгә килә алмыйбыз. Белмим, күпмегә сузылгандыр бу сүзсез онытылып югалып тору, әмма кыбырсынып утырган Сабира ахырда түзмәде, зур бер нәрсәне хәбәр иткәндәй кычкырып:

— Ә без сезне таныдык, Салих абый! — диде.

Салих уянып киткәндәй булды, таркау гына елмаеп:

— Мин дә сезне таныдым,— диде.— Менә Гөләндәм борылып карау белән танып алдым.

— Ә мин бит сезне алданрак күрдем, сез мине күрмәдегезмени?

— Мин икегезне дә берьюлы күрдем,— диде Салих, уңайсызланыбрак, аннары миңа карап сорады: — Нинди сәфәр бу, кая барасыз?
— Без утарга китеп барабыз,— дидем мин, телгә килеп.
— Нинди утарга?
— Дәү әтиләрем утарына.
— Еракмы ул?
— Ерак диләр.
— Үзегез генәме?
— Юк, әнием дә... Безне Касыйм абыебыз алып бара.
— Шулаймыни? Кайда соң алар?
Мин бер арба аша алда торган тарантасны күрсәттем. Әнием белән Касыйм абый безне, билгеле, күрмиләр иде. Шулай да Салих, үзе барып, алар белән күреште. Әнием, аны күргәч, бик аптырап киткәндер инде, ләкин ничек тә сиздермәскә тырышкандыр. Моннан караганда, иске танышларча дустанә-ачык кына сөйләштеләр кебек.
Шул арада бу якка килеп туктаган «Волгарь»дан ярга кешеләр, атлар чыга башлады. Салих та, яңадан безнең янга тиз генә әйләнеп килде дә, әйтеп калырга ашыккандай:
— Гөләндәм, мин сезне күрүемә искиткеч шатмын, сезнең сау-сәламәт булуыгызга шатмын, гомумән бүгенге уңышлы юлга чыгуыма әйтеп бетергесез шатмын! — диде.
Сөенечемнән тәмам балкып:
— Ә сез кая китеп барасыз соң? — дип сорадым мин.
— Без — Буага, Гөләндәм!
— Иптәшләрең кемнәр?
— Фәйзи белән Мансур. Сез аларны беләсез...
— Әйе, беләм. Буага ни өчен?
— Кайбер йомышлар белән. Былтыр бит мин анда татар һәм чуаш хорлары оештырган идем... Шулар таркалмаган булса, бер-ике концерт бирергә дә исәбебез бар... Ярый, Гөләндәм, без әле сөйләшербез, юлларыбыз Буага чаклы бергә икән.
— Әлбәттә! — дидем мин, җиңел генә ышанып.
Ул иптәшләре янына китте. Алдагы арбалар кузгалып, паром басмасына төшә башладылар. Без дә кузгалдык, безнең арттан — башкалар да... Агайлар атларын, башларыннан тотып, тыя-тыя гына төшерделәр. Ниһаять, дөбердәшеп кереп, урнашып беттек. Тыгызлык, күчәрләр күчәргә тиеп тора, печән, сбруй, тир исе аңкый, ә шулай да бик күңелле бу атлар, арбалар арасында. Атлар үзләре дә, берберсенә бик якын торганга күрәме, әзрәк тынычсызланалар, колакларын уйнаткалыйлар, такта идәнне тырнап пошкырынып та куялар. Әллә еракта ярлардагы яшел тауларны күреп,

йөрәкләре шулай җилкенәме аларның?! Менә пароход, каршыдагы Ослан тауларына: «Көтегез... көт... көт!..» — дип дәшкәндәй, берничә тапкыр өзеп-өзеп кычкыртты да, каты су агымын ерып, авыр-салмак кына кузгалып та китте.

Һәм... кирәк бит, Ходаем! Ярдан аерылып китәргә дә өлгермәдек, Салих тарантасындагы өч егет «Сәфәр» көен уйнап кына җибәрмәсеннәрме?! Берсендә скрипка, берсендә мандолина, ә Салих кулында кечкенә генә тальян гармун... Мин әле аның гармун уйнавын беренче мәртәбә ишетәм... Әмма шундый өздереп уйныйлар, шундый өздереп уйныйлар, йа Рабби, тыңлап түзәрлек кенә дә түгел! Әллә нәрсә бу — сихер, тылсым — әллә нәрсә бу! Җитмәсә, үзебезнең Идел өстендә! Паромдагы бөтен кеше — татары, чуашы, русы — тып-тын калдылар (музыка ул кайчагында кешене шулай телсез дә итә), тик йөзләре яктырып, күзләрендә шатлыклы дәрт кенә кабынды. Ә Касыйм абый инде түзмәде — арбалар өстеннән күчә-күчә, егетләрнең янына ук барып утырды. Аңа, Сембер кешесенә, скрипка-гармунда сиптереп уйнаган татар көйләре аеруча тансык булырга тиеш, билгеле. Сабира да мине тәмам азаплап бетерде. Билемнән каты итеп кысып ала да, колагыма кайнар пышылдап: «Син нинди бәхетле, Гөләндәм!» — ди миңа. Аңлыйм инде, аңлыйм аның ни әйтергә теләгәнен, тик менә бу хәтле каты итеп кысмасын иде. Мин бит болай да өзелергә генә торам... Ә егетләр «Сәфәр»дән соң «Алтын-көмеш»не уйнап җибәрделәр, аның артыннан «Алмагачлары»н... Шулай итеп, Ослан-га чыгып җиткәнебезне сизми дә калдык.

Паромнан исән-сау ярга чыктык, бераз урам буйлап бардык, аннары борылып, шактый озын, текә юлдан Ослан тавына менә башладык. Ат тотучылар җәяү атлыйлар. Егетләр дә тарантасларыннан төште. Сабира миңа да: «Әйдә, төшик!» — дигән иде дә, мин инде кыймадым, чөнки шул арада Касыйм абый да, төшеп, егетләр янына килде. Алар юлдан аз гына читтәрәк, ләкин безгә якын гына атлап баралар. Сөйләшкәннәре ишетелеп тора. Касыйм абый, килеп җитүе белән, тегеләрне кыстый башлады:

— Егетләр, Салих әфәнде, әйдәгез безнең утарга!.. Берике көн кунак булып китәрсез. Чынлап әйтәм, бик хозур җир, үкенмәссез!

Касыйм абыйның бу чакыруы минем игътибарымны шунда ук бик нык биләп алды. Ашыгып, дулкынланып диярлек уйлыйм: үз теләге белән генә чакырамы ул, әллә әнием белән сөйләшеп тәме?.. Мөмкин эшме бу?.. Ә Салих... Салих ни дияр?.. Ләкин ул ашыкмый, башын иеп, бераз уйланып баргач кына әйтеп куйды:

— Рәхмәт, кем... Касыйм абый, рәхмәт!

— Салих әфәнде, мин бит ихлас күңелдән, ышанасызмы?

— Ышанабыз, Касыйм абый!..

Ләкин шуңардан башка бер сүз дә әйтмәде Салих... Ә мин борчылуымнан ни эшләргә дә белмим: нигә ул риза түгел, нигә форсаттан файдаланмый, моның кебек уңай җайның чыгуына меӊ тапкыр шөкер генә итәсе бит!.. Минем хакка эшләргә тиеш ич ул моны, минем хакка!.. Шушы юл өстендә генә очрашып, бер генә мәртәбә сөйләшә дә алмыйча, тиздән аерылышып та китсәк, бу бит... бу бит гомерлек үкенечкә булачак! Ул шуны аңлыйдыр лабаса!.. Хәер, мин, тиле, бик ашыгып борчылам түгелме соң?! Бәлки әле, аның иптәшләре белән сөйләшәсе бардыр, бәлки, Касыйм абыйдан ишетүгә риза булуны килештермәгәндер — кешедә әдәп һәм горурлык дигән нәрсә дә бар бит. Аннары, саклык йөзеннән дә ул бераз сабыр итәргә тиеш түгелмени?!

Тауны да менеп җиттек. Касыйм абый үз тарантасына китәр алдыннан егетләргә тагын әйтте:

— Уйлагыз әле, егетләр!.. Дөньясын дер селкетик әле бер, валлаһи!.. Безнең анда бик тыныч, бик аулак, шәп булачак, искиткеч!.. Ә Буага өлгерерсез, Буа беркая да качмас!

Егетләр елмаешып башларын гына селектеләр, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәделәр. Касыйм абый киткәч, Салих, безнең тарантас янына килеп, янәшә бара башлады. Сабира аңардан шунда ук:

— Йә, Салих абый, утарга барасызмы? — дип сорады.

— Белмим шул,— диде Салих, елмаеп кына.

— Ник белмисез?..

— Сездән чакыру ишеткән юк бит әле.

— Пәрәмәч,— диде Сабира, исе китеп.— Утар хуҗасы үзе дәшеп торганда сезгә тагын нинди чакыру кирәк?

— Хуҗаныкы гына җитми безгә. Сезнең, менә Гөләндәм туташның да сүзен ишетәсе килә,— диде Салих, күзләрен миңа хәйләкәр генә сирпеп.

Мин комачтай кызарып киттем бугай, ә Сабира тәкатьсез шаркылдап көлеп җибәрде.

— Әй-яй бу Салих абыйны!.. Юкәдә икән ләбаса чикләвек!.. Йә, әйт үзенә, җаным, әйт инде! — диде ул, минем кабыргама төртеп.

Болай төртеп, кыстап торганда әйтүләре бер дә җиңел түгел, әмма әйтмичә кала аламмы соң инде мин?! Һичшиксез белергә тиеш ул минем күңелемдәге бердәнбер теләкне! Оялыбрак булса да:

— Абыйның чакыруына мин дә кушылам,— дидем, ниһаять.

Сабира шунда ук элеп алды:

— Ишеттегезме, әфәнде, туташ ни диде? Абыйның чакыруына мин дә кушылам, янәсе!.. Ә дөресен генә әйткәндә, туташ сезнең баруыгызны абыйсына караганда да ныграк тели, чәчрәп китим менә!

Салих та, бөгелә биреп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ә минем Сабираны тарантастан бөтенләй төртеп төшерәсем килде.

— Йә, барасызмы инде? — диде телгә беткән кызый.

Салих көлүеннән туктады.

— Рәхмәт, кызлар! — диде.— Сезнең арттан мин утарга гына түгел, Сембернең үзенә дә, кирәксә, Себергә дә барыр идем. Ләкин...— ул нигәдер әйтеп бетермәде.

— Нәрсә тагын ул «ләкин»!..

Салих авыр гына сулап куйды.

— Дөньяның «ләкин»нәре күп, Сабира туташ! — Аннары миңа карап, әкрен генә дәште: — Гөләндәм, сез кечерегез, мин бу хакта сезгә әйтермен әле... Ә хәзер иптәшләрем янына барырга вакыт, әнә Мәликә апа да артына борылып карады. Бу бит әле озын юлның башы гына...

Алдагы пар ат юырттырып китеп бара иде инде. Безнең агай да, дилбегәсен кагып, атларын юырттыра башлады. Салих, туктап, үзенең тарантасын көтеп алды да иптәшләре янына сикереп менеп утырды. Сабира аның артыннан кычкырып калды:

— Салих абый, җаным, тагын уйнарсыз бит?!

Салих, елмаеп, аңа кулын изәде.

— Алай бәйләнчек булырга ярамый инде,— дидем мин, әзрәк шелтә белдереп.

— Син дә! — дип куйды Сабира, кырыс кына.— Тарантасыңда утырып калырсың әле, бик чытлыкланып маташсаң... Буаларына аерылып китәрләр дә барырлар, менә-терә!

Чынлап та!.. Безгә сөйләшергә, аңлашырга кирәк ләбаса!.. Ни уйлый ул, нишләмәкче була?.. Шулай тарантас кырыеннан аны-моны сөйләнгәләп барыр-барыр да үз юлы белән аерылып китәр микәнни?! Юк, ышанмыйм әле мин моңа, ышанмыйм! Сабира юкка гына мине куркытмасын!

Арттагы тарантаста егетләр яңадан дәртле генә уйнап җибәрделәр. Музыка тавышын ишетүгә, Касыйм абыйлар да атларын әкренәйтә төште. Без дә салмак кына юырттырып, тибрәлеп кенә барабыз.

Башта егетләр бер-ике кыска көй уйнадылар, аннары «Бөдрә тал», «Салкын чишмә» кебек озынрак көйләргә күчтеләр... Скрипка, гармун, мандолина... Минем әллә көләсем, әллә елыйсым килә — үзем дә белмим. Әйләнә-юнь-

дәге ялан-кырлар да күзләремә әллә ничек, бер ямь-яшел яктырып, бер кара-кучкылланып киткәндәй күренә — әйтерсең аларның да «кәефләре» музыкага ияреп, ирексездән шулай үзгәреп тора! Юк, чынлап та, адәм йөрәгеннән табигатьнең тиңсез аваз-өннәренә әз генә булса да охшап чыккан бу музыканы үләннәр, чәчәкләр, бөҗәкләр дә, бәлки, ишетә торгандыр?! Без барыбыз да бер туфрактан яралганбыз ич!.. Җир барыбызга да бер газиз ана!.. Минем тын гына сулап яткан җиргә нәни аякларым белән йомшак кына басасым килә, җылы күкрәгенә капланып, битемне үлән-чәчәкләренә ышкыйсым килә. «Әй, миһербанлы җир, бәхет бир миңа, бәхет!» — диясем килә... «Яки җылы-йомшак куеныңа ал да гөлчәчәкләреңнең берсе итеп яшәт мине!» — диясем килә. Юк, әллә ни бу, әллә ни. Юк, музыка белән бу хәтле үк сихерләнергә ярамый, һич тә ярамый!..

...Күпмедер уйнагач, алар тындылар. Менә бик әйбәт булды. Шунда ук күктә тибрәнгән тургай тавышы да ишетелде. Сузып-сузып, өзеп-өзеп кенә җырын җиргә чәчә ул... Җанга тынычлык инде. Рәхәт, талгын, моңсу тынычлык!

Инде кояш та төшлеккә җитеп бара. Көн дә бик эсселәнде. Атларның эшлияләре астыннан ак күбекләр дә чыкты. Атлаганда эчләре белән сулыйлар, мәхлуклар!.. Безгә дә җиңел түгел, эсседән, гел утырып барудан арыййончый башладык, Касыйм абый, көн кызуында берәр авылга кереп, ялга туктарбыз, дигән иде. Кайчан гына шул авылга җитәрбез икән? Ә юл озын, үрләр менә, үрләр төшә, ләкин очы һаман күренми әле...

Бер сай чокырны чыкканда, Салихлар тарантасы безне узып китте. Шул чакта Салих миңа чәчәк ташлап узды. Мин чәчәкне тотып алдым. Озын гына сабаклы зәңгәр чәчәк. Нәфис кенә хуш исе дә бар. Ни өчен ташлады икән, ни әйтмәкче булды икән ул миңа? Хәер, әллә нәрсәсе юктыр әле, шаярып кына ташлагандыр!..

Тагын күпмедер баргач, алдыбызда ак чиркәүле зур гына бер урыс авылы күренде. Сөзәк кенә тау итәгендә, бормаланып аккан ниндидер елгачык буенда алма бакчаларына күмелеп утыра. Таза, матур авылга охшаган.

Алдагы атлар туктады. Касыйм абый, тарантастан төшеп, Салихлар янына килде.

— Егетләр,— диде ул аларга,— без шушы авылда ялга туктамакчы булабыз. Сез ни уйлыйсыз?

Егетләр, аптырап калгандай, бераз дәшми тордылар. Әле бит Иделне чыкканда гына абыем бик дәртләнеп үзләрен кунакка да чакырган иде. Ә хәзер... ни уйлыйсыз, имеш!.. Минем дә моңа бик кәефем кырылды. Мөгаен,

бу әнием әшедер, әнием аның колагын нык кына борган, күрәсең.

Ләкин Касыйм абый, хатасын үзе дә сизеп алды булса кирәк, егетләрнең җавабын да көтмичә:

— Ә нәрсә уйлап торырга! — диде.— Керәбез, вәссәлам! Атларга да ял кирәк, шулай бит, агай?

— Хак сүз,— диде Салихлар кучеры.— Атларга — бигрәк тә!

— Кузгалдык алайса!

— Урын табылырмы соң? — дип сорады Салих, гүя сүзсез калмас өчен генә.

— Ник табылмасын... Бер ишегалдына сыймасак, ике йортка керербез. Минем знакумнар күп монда.

...Кузгалып киттек. Ә бераздан, елга аша чыгып, авыл урамына да барып кердек. Урыс авылларының күбесе шикелле үк монда да йортлар бер яклап кына утырган, шуңа күрә яшел чирәмле урамы ким дигәндә ике-өч чакрымга сузыла торгандыр. Шактый гына баргач, авыл уртасына җитәрәк, Касыйм абыйларның атлары калай белән япкан таза йортның киң капкасына борылып туктады. Алар артыннан без, безнең арттан Салихлар да килеп туктадылар.

Урысның ишегалды гадәттә зур булмый. Моның да ишегалды өч пар ат өчен бик тыгыз икән. Шул сәбәпле Касыйм абый, күрше йорт белән сөйләшеп, Салихларны шунда җибәрде. Ә егетләрнең үзләренә ачык йөз белән:

— Түлке, егетләр, чәйне бер табында, бергәләп эчәбез,—диде.— Салих әфәнде, ишеттегезме?..

— Ишеттек! — диде Салих, артына борылмыйча гына. Боларның барысына да минем бик игътибар итүем аңлашылса кирәк. Мине иң куркытканы — Салихның берәр нәрсәгә кәефе кырылып, әйтик, безгә тагылып йөрүдән хурланып, бөтенләй ташлап китә күрмәсеннәр дигән уй иде. Горурлыгына көч килсә, аның моны эшләве бик мөмкин ич. Тотарлар да китеп барырлар... Хәер, юк, ул моны эшләмәс. Мин бар бит әле, минем хакка ул бөтенесенә дә күз йомарга тиеш, әлбәттә.

Ишегалдына кереп тарантаслардан төшүгә, безне киң итәкле озын сарафан кигән, тулы гәүдәле, ак чырайлы чибәр генә хозяйка-марҗа ачык йөз белән каршы алды:

— Рәхим итегез, кунаклар! — диде ул саф татарча.

Без бик гаҗәпләндек, ә хозяйка, шуны күреп, шаркылдап бер көлде.

— Нигә исегез китте?.. Мин бит татар авылында үстем, безнең атай гомере буе шунда тегермән тотты. Тик менә татарга гына чыгып булмады,— диде ул, көрсенгән булып.— Әйдәгез, әйдә, рәхим итегез!

Ул безне өйнең бакчага караган ачык верандасына алып керде.

— Монда кояш төшми, җиләс, рәхәтләнеп ял итәрсез!

— Рәхмәт, рәхмәт! — дидек без.

— Ә ятып алырга теләсәгез, өйгә керерсез. Көне буе тәрәзә капкачларын ябып тотабыз, чебеннең эзе дә юк.

Верандада зур өстәл, палас салган озын гына кәнәфи, берничә таза урындык — кыскасы, ашап-эчеп утырыр өчен иркен, күңелле урын. Сабира белән икәү азык-төлекне дә алып килдек. Хозяйка үзе өстәлдә торган зур ак самавырны алып, бакчага — җиргә төшереп куйды. Чиләк белән суын да китереп салды. Сабира төшеп аңа булыша башлады — чырасын телде, кабызып җибәрде, морҗасын бастырып куйды. Мин дә алар янына төштем. Бакча шактый зур иде, елгага таба сузылып киткән, түре күренми дә. Бу тоташы белән алма бакчасы икән. Алма агачлары юан-таза, һәркайсы җәелеп үскән. Ә койма буйларында чияләр — алары да таза, биекләр. Мондый бакчаның алма-чиясе дә бик күп була торгандыр инде. Хозяйканың үзеннән дә сорадым.

— Бакчагыз бик зур икән, җимешен кая куеп бетерәсез?

— Сата торган идек,— диде хозяйка.— Безнең авылның кәсебе шул — алма-чия үстереп сату... Күргәнсездер, монда йорт саен шундый бакча.

— Ә кемгә сатасыз, шәһәргә илтепме?

— Шәһәр бездән ерак, илтүе бик мәшәкатьле... Фрукты сатучылар үзләре килеп, бакчаның бөтен урожаен сатып ала торганнар иде. Агачта килеш. Аннары, җыйдырып, сортын сортка аерып, әрҗәләргә төяп, пристаньга озаталар...

— Анысы яхшы булган икән.

— Яхшы иде дә бит, андый эшләр хәзергә туктап тора шул әле,— диде хозяйка, сузып кына.— Былтыр да килүчеләр булмады, быел да булмас, диләр. Белмим, нишләрбез инде.

Хозяйканың зары аңлашыла — шәһәрдә сәүдә эшләре бетте шул. Ә алмагачлар ел саен үзенекен биреп тора, кешеләрнең ызгышында аларның эше юк.

Самавыр кайнап чыкканчы, без ике кулдан чәй урыны әзерләргә керештек. Әнием кәнәфигә ятып кына торды — аның, тарантаста килә-килә, биле авырта башлаган икән. Ә Касыйм абзый, кулларын угалап, һаман әрле-бирле йөренә — күрәсең, ашыйсы бик килгәндер инде. Ләкин әнием, башта агайлар эчеп алсыннар, соңыннан үзебез иркенләп эчәрбез, диде. Касыйм абый шунда ук аларны чакыра китте.

Тиздән агайлар, капчыкларын тотып, килеп тә җиттеләр. Икмәкләрен, пешкән йомыркаларын, бәрәңгеләрен чы-

гардылар. Әнием Сабирага куырган ит тә турап куярга кушты. Агайлар, ачык верандадан бакчаның хозурлыгына сокланып, күпме файда китерүен үзләренчә исәпләп: «Безнең татар авылларында шушы байлык юк лабаса!» —дип уфтанып, ипләп-җайлап кына ашарга-эчәргә тотындылар. Без инде боларның эшләре бик озакка сузылыр дип курыккан идек, ләкин алай ук инсафсыз кыланмадылар.- Бишәр чәшкә эчкәннән соң, күлмәк итәкләре белән битләрен сөртеп, амин тотып, яңадан атлары янына киттеләр.

Тик менә самавырны өстәп яңартырга туры килде. Табынны да яңабаштан әзерләдек. Чакырган егетләребез бар ич, кунакчарак булсын дидек. Әнием ике ягына куйган кәрзиннәрдән бөтен сыйларын чыгарып, өстәлгә тезде. Касыйм абый, һаман йөренеп:

— Нигә көттерәләр инде? — диде.— Сабира, әллә барып киләсеңме?

— Әйткәнсеңдер ич? — диде әнием, тыныч кына.

— Әйттем, әле менә кучерларын дәшкәндә дә әйтеп килдем.

— Шулай булгач?..

— Тартыналармы шунда...

Сабира аларның сүзе беткәнен дә көтеп тормыйча:

— Тукта, абыстай исеменнән үзем дәшим әле,— диде дә китеп тә барды.

Әнием аны туктатмады. Риза булуы идеме бу, әллә тыелып калуымы — анықын тиз генә белмәссең. Тыштан ул берни дә сиздерми. Әмма Салихның безгә туры килүе, минем белән очрашуы аңа ошап бетмәскә тиеш. Күпме генә үзен тыныч тотмасын, хәтәр сизгән җәнлек шикелле, ниндидер бер сагаю бар аңарда — мин моны ничек дим, күрмәсәм дә тоеп торам. Билгеле инде, бу хәл мине бик тынычсызлый иде.

Ишегалды ягыннан егетләрнең шаулашып килүләре ишетелде. Касыйм абый аларны веранда баскычында каршы алды.

— Ай-һай, егетләр, хәзрәтләр шикелле көттерергә яратасыз икән!..

— Мең кәррә гафу! — диде Салих, иелә биреп.— Юлдан соң тузаннарны кагып, кое суы белән чиратлашып юынган идек, шуңа бераз вакытыбыз китте.

— Беләм инде, музыкантлар өчен пөхтәлекне саклау фарыз гамәл!..

— Ягез, әфәнделәр, утырышыгыз,— диде әнием.

Егетләрнең кулларында үз төенчекләре дә бар иде, ләкин әнием аларны чиштереп тә тормады. «Ризык болай да җитәрлек, сезгә яңадан пешереп бирүче булмас, сакла-

гыз!» — диде. Ә абыем: «Куегыз, егетләр, кунакка кеше үз азыгы белән киләмени?!» — дип тә өстәде. Егетләр бер-берсенә караштылар, кызарыштылар, ахырда төенчекләрен веранда идәненә куярга мәҗбүр булдылар.

Алар өстәлнең бер ягына тезелешеп утырдылар, без — абый, әнием, мин — кәнәфигә урнаштык. Сабира чәй ясарга утырды. Касыйм абый, кулларын угалап:

— Эх, бу тавыклар янына теге иблис ширбәте дә булсачы! — диде.— Әллә хозяйкадан сорап карыйсы микән, аңарда «үзе куган» бардыр инде, мөгаен!

Әнием аңламыйча сорады:

— Анысы нәрсә тагын?

— Үзе куганмы?.. Мунчадан чыккан хәмер!

— Куй, шундый җирәнгечне эчәр идеңме әллә?

— Монда бик оста куалар аны, апам!.. Николай аракысыннан да шәбрәк була, валлаһи!..

— Юкны сөйләмә, андый үзе харам, үзе нәҗес нәрсәне табыныма якын да китермим,— диде әнием катгый рәвештә.

Егетләр, ләм-мим бер сүз әйтмичә, тик кенә утырдылар. Аларга хәтта уңайсызрак та булды түгелме икән, чөнки кыяфәтләре нигәдер җитди-киеренке иде. Касыйм абый да тамагын кыргалап кына куйды.

— Мин сезне менә кәраван чәе белән сыйлыйм әле,— диде әнием. Егетләрнең Биккинин дигәннәре моңа гаҗәпләнә калды, ахрысы, юка гына иреннәрен ерып сорады:

— Кәраван чәе?! Табыламыни әле ул?

— Кайдан табылсын, искедән калганы гына... Без, олылар, бөртек чәйсез тора алмыйбыз инде, сез, яшьләргә, аның, бәлки, әллә ни хаҗәте дә юктыр...

— Безгә дә иң шәбе — кәраван чәе! — диде Салих, елмаеп кына.

Шул рәвешчә сүзгә-сүз ялганып, анысын-монысын сөйләшкәләп, күңелле генә ашап-эчеп утырдык. Юл ачыктырган икән. Кунакларыбыз да баштарак кыенсынып, аннары инде бер дә тартынмыйча ашадылар. Тик аларның Мансур дигәннәре генә бик оялчан, кыюсыз икән. Аның әле авызыннан бер сүз дә чыкканы юк, гел алдына карап, елмаеп кына утыра. Ахырда әнием үзе аңардан: «Кем улы буласыз, әти-әниегез кем?» — дип сорады. Егет нигәдер кинәт кенә кызарды, ашыкмыйча гына әйтеп бирде.

— Алай, сез Маһруй ханым Мозаффария улы буласыз икән,— диде әнием, ачылып китеп.— Беләм, бик яхшы беләм әниегезне, шәһәребездә бит ул танылган мөгаллимә, укымышлы хатын! Сезгә карап, үзем дә уйлаган

идем, бу, мөгаен, тәрбия күргән баладыр, дип... Алма агачыннан ерак төшми шул!..

Бу сүзләрне ишеткәч, Салих миңа мәгънәле генә итеп бер карап куйды. Мин беләм, Салих әтисез үскән, җизнәсе кулында тәрбияләнгән бала. Ихтимал, шуңа күрә ул әниемнең соңгы сүзләренә игътибар да иткәндер. Әмма ләкин кимсенү, хәтер калу кебек нәрсә сизмәдем мин аның карашында — бары: «Сез дә ишетегез!» — дигән киналяле көлү генә чагылып узды, миңа калса...

Әйе, безгә әле хәзергә шулай эчтән генә уйланырга яки күз карашларыбыз белән генә аңлашырга туры килә. Нидер көткәч, нәрсәгәдер ышанып торгач, без үзара хәтта гади сөйләшүдән дә тыелып утырабыз. Йа Хода, кайчан гына соң безнең үз сәгатебез җитәр?! Һәм җитәр микән ул?..

Салихның мине борчыган бер ягы булса — ул да аның үзен гаять тыныч тотуы... Тыштан һичнәрсә сиздерми ул. Менә ашап-эчеп беттек, егетләр урыннарыннан тордылар, әниемә рәхмәтләрен әйтәләр, ә мин бер читтә, багана шикелле, кузгалмыйча көтеп торам. Ичмасам, берәр сүзе яки карашы белән ни дә булса сиздермәсме дип көтәм. Ләкин ул, баскычтан төшкәч кенә, борылып, миңа җитди генә бер карап алды да тып-тыныч китеп тә барды. Шуннан теләсәң ни аңла, теләсәң ни көт!..

Алар киткәч, без Сабира белән өстәлне җыештырырга кереште. Әнием кичтән дә соң ятып, бүген дә юл килеп арганга күрә, чәйдән торгач та өйгә кереп йокларга ятты. Миңа да ял итеп алырга кушты. Касыйм абый да, каядыр китеп, үзенә урын тапты булса кирәк... Безнең дә эшебез бетте. Инде нишләргә? Сабира миңа шушында, кәнәфидә генә ятып торырга кушты. Әкрен генә өйгә кереп, мендәр дә алып чыкты.

— Апа йоклый,— диде ул миңа, шыпырт кына.

— Ә син кая ятасың? — дип сорадым мин аңардан.

— Мин ятмыйм әле.

— Ник?..

— Чү!.. Эшем бар,— диде ул, серле генә итеп.— Ә син шушында гына ят, яме!..

Шулай диде дә верандадан сак кына төшеп, ишегалдына чыгып китте. Ә бераздан урам капкасының келәсе чыкылдап куйды. Кая китте, ни өчен китте? — Хода белсен!.. Мин борчылып, сагаеп, колак салып ятам... Күпмедер вакыт узды. Тынлык. Ишегалдындагы атларның мышнап, авыр сулап печән күшәүләреннән башка берни дә ишетелми. Күрәсең, аруым бик җиткәндер инде, бер мәлне үзем дә сизмәстән оеп киткәнмен.

Ах, бу татлы йокы!.. Бакча, һава, тынлык!.. Тик менә

кемдер мине иңбашымнан сак кына кат-кат селкетә. Кинәт бөтен гәүдәм белән сискәнеп күземне ачып җибәрсәм, Сабира өстемә иелеп тора. Колагыма бик әкрен генә:

— Сине Салих абый көтә! — ди.

Мин шул мизгелдә үк торып утырдым.

— Көтә?.. Кайда?

— Бакча түрендә... Бар тизрәк!

— Әйе, әйе... Тик әнием сизмәс микән?

— Сизә калса, үзем берәр хәйләсен табармын.

Торып бастым. Ләкин нидер җитми, башым ялангач, башыма эзләп маташам.

— Мә минем яулыкны! — диде Сабира.

Яулыгын эләктереп алдым да аяк очларым белән генә верандадан төшеп киттем. Нәкъ каршыдагы сукмактан, иелә-бөгелә, кызу-кызу гына бакча түренә таба атладым. Ә йөрәгем тибә, тибә, сикереп төшәрдәй булып тибә.

Бакчаның түре елга ярына чаклы ук барып җитә икән. Кеше күзе һич төшмәслек аулак бер урын! Мин килеп җиткәндә, Салих читән буендагы миләш төбендә тик кенә басып тора иде.

Мине күрүгә, каршыма атлап, ике кулын сузды. Мин дә ирексездән диярлек аңа кулларымны суздым.

— Ник калтырыйсыз? — диде ул, кулларымнан тоткач та.

— Юк, ул ни, ашыкканга күрә генә,— дидем мин, калтыравымны һич тә баса алмыйча.

— Тынычлан, бәгырем! — диде ул, шунда ук «син»гә күчеп. Шушы якын итеп әйтелгән гади генә «син» мине чынлап та тынычландыра төшкән кебек булды.— Безнең вакытыбыз бик аз, ә сөйләшер сүзләр күп, белмим нидән башларга да,— диде ул, аз гына тынып торганнан соң.— Иң элек, синнән гафу үтенәсем килә, кадерлем! Саклый белмәдем мин сине, ә соңыннан күпме газап кичерергә туры килде шуның өчен...

— Үтте бит инде,— дидем мин, әкрен генә.

— Әйе, үтте, мең шөкер! Син сау-сәламәт!.. Әмма авырып китүеңнең нәтиҗәсе минем өчен ни булып чыкты?.. Мин сине югалттым, мин сине бер күрүдән мәхрүм ителдем — син моны үзең дә, шаять, белә торгансыңдыр.

— Әйе, беләм.

— Бик зарыктым мин... Өч ай үтеп китте бит, өч ай!

Мин тыела алмадым, мин аңа күтәрелеп карамыйча гына кыюланып әйттем:

— Теләсәң, элегрәк тә күрә алган булыр идең!..

— Үпкәңне аңлыйм, бәгырем, акланып тормыйм, гәрчә акланыр өчен җитди сәбәпләр булса да... Тик шуны гына

әйтәсем килә: әтиегез Әхмәтҗан абзый белән сөйләшкәннән соң минем өчен юллар тәмам киселсә дә, мин әле сезнең тирәләргә барып йөрдем. Ничек кенә булса да Сабираны очратып, аңардан синең чын хәлеңне сорашмакчы идем... Ләкин бер килүемдә Сабира урынына Әхмәтҗан абзыйның үзенә очрап куйдым бит, бәхетсезлеккә каршы! Искиткеч уңайсыз, ахмак бер хәлдә калдым. Шуннан соң инде сезнең тирәгә барып йөрүдән тыелырга мәҗбүр булдым. Аннары үзеңнән берәр хәбәр булмасмы дип тә һаман көттем. Ник Сабираны гына, һич югы, җибәрми дип, өзгәләнгән чакларым да аз булмады. Күпме вакыт авырдың соң син, бәгырь?

— Урын өстендә — ай ярым.

— Ай ярым! — дип кабатлады ул.— Ә мин белмим... мин бөтенләй хәбәрсез!.. Ни булды соң сиңа, кадерлем?

— Үпкәм шеште...

Салих иреннәрен кысып, аз гына дәшми торды, аннары башын игән килеш, әкрен генә:

— Кичер мине, бәгырь, кичер! — диде. Мин бит бик ялгышканмын, мин әтиең сүзләрен синең дә сүзләрең дип кабул иттем. Син үзең безнең араны өзәргә теләгәнсең дип уйладым ахыр чиктә. Аңлыйсыңмы? Менә нәрсә мине шушы көнгә кадәр тыеп, борчып, газаплап килде... Димәк, бу дөрес түгел,— минем уйлавым, шулаймы, дөрес түгелме?..

Мин башымны кагып кына «әйе!» дидем, ә ул сулышы иркенәеп киткәндәй ашыгып дәвам итте:

— Әмма бел, бел, җаным, күрмәсәм дә, күрүдән мәхрүм булсам да, мин сине бер генә көн, бер генә сәгать тә онытып тормадым. Уемда, йөрәгемдә гел син идең, син!.. Ишетәсеңме?!

— Ишетәм! — дидем мин, пышылдап кына.

— «Шәрык кичәсе»ндә минем әйткән сүзләремне онытмадыңмы?

— Юк...

— Алайса миңа күтәрелеп карале! — диде ул, иягемнән йомшак кына тотып.— Менә шулай... Инде тыңла, зәңгәр күзем!.. Ялгыз миләш шаһитыбыз булсын, шушы урында кабатлап әйтәм: мин сине яратам!.. Яратам, бәгырем!.. Мәҗнүн шикелле гашыйк мин сиңа! Бу чын, бу хакыйкать, ышанасыңмы син?

Ни әйтим, ни дип җавап бирим?.. Минем бит аңардан тилмереп көткән сүзем ич бу!..

— Ышанам! — дидем мин, күзләремне түбән төшереп.

Ул минем башымны күкрәгенә кысты. Ә йөрәге аның тибә, дөп-дөп тибә... Күпмедер вакыт шулай тик кенә торгач, ул, ниһаять, тынычланып, миңа сабыр гына әйтте:

— Инде тыңла, Гөләндәм! Безгә тиздән аерылышырга туры киләчәк...

— Нигә, утарга бармыйсызмыни?

— Бара алмыйбыз, Гөләндәм!.. Буада безне көтәләр. Аннары абыегызның чакыруы да болай гына, музыкантлар итеп кенә, ә безнең алай йөрисебез килми. Син моны аңларга тиеш!.. Әмма бу очрашу минем өчен һич көтелмәгән бер бәхет булды. Сүнеп барган өметләрем яңадан терелде, яңадан!.. (Ул, сүзен бүлеп, тирән генә бер сулап куйды.) Ә өметем минем бик зур, бик изге, әйтимме, беләсең киләме?.. Тагын кайчан очраша алырбыз, белеп кал син!.. Киләчәктә без бергә булырбыз дигән өмет белән яшим мин... Ишетәсеңме, бәгырем? Ник дәшмисең?..

Дәшәргә?! Ничек итеп, нинди сүзләр белән?! Мин башымны тагы да түбәнрәк ия төштем.

— Хәер,— диде ул, бераз көткәч,— бу, бәлки, буш хыял гынадыр... Синең бит әле миңа «яратам» дигән сүзне әйткәнең юк... Нинди өмет ди ул?.. Әмма, әмма син яратасың бит мине, Гөләндәм, яратасың!! Ялгышу мөмкин түгел! Шулай ич?.. Яратасың ич?!

— Белгәч, ник сорыйсың инде? — дидем мин, үпкәли башлап.

— Йа Хода! — дип куйды ул.— Шул бер сүзне әйтергә дә көчең җитми ләбаса!.. Бик яшь шул әле син, кошчыгым, бик яшь!..

— Ә син картмыни?

Ул бер мәлгә тынып калды, аннары, гүя тәкатьсездән, бөгелә-сыгыла көлә башлады. Гадәтенчә, бик кәефләнеп, рәхәтләнеп көлде ул. Бары көлеп туйгач кына сүзен әйтә алды:

— Ах, Гөлгенәм, Гөлгенәм! Йә, ничек инде сине сабый димәссең?! Ләкин сабый авызыннан да кайчак бик дөрес сүз чыгып куя. Әйе, мин дә карт түгел шул, япьяшь егет, тик шунысы бар инде — мин үз-үземә хуҗа кеше, бәйсез кеше, эшем өчен дә, сүзем өчен дә җавап бирә алам. Мәсәлән, мин сине, әгәр теләсәң, бүгеннән үк яучы җибәреп, әти-әниеңнән үземә сорар идем. Ләкин сизеп торам: алар сине миңа бирмәячәкләр. Вакыты җитмәгән әле. Аннары, мин бит бары музыкант кына, музыкадан башка минем бүтән бернинди дә байлыгым юк. Ә алар аны байлыкка санамыйлар.

— Бәхет — байлыкта түгел, диләр ич!

— Дөрес әйтәләр, акыллым! Тик байлыкны аера белергә кирәк. Менә синең йомшак, ягымлы тавышың, шушы сизгер бармакларың минем өчен зур байлык, һәм минем аларны бер дә ычкындырасым килми,— диде ул,

көлемсерәп кенә, ләкин шунда ук җитдиләнеп өстәде: — Әмма сабыр итәргә туры килә, бәгырь, сабыр итәргә. Вакыты шундый, авыр, хәвефле вакыт... Сугышлар көчәеп китте. Бер яктан Колчак, икенче яктан Деникин... Минем дә гаскәргә алынуым бик мөмкин. Алмасалар да, Казанда тик ятып булмас. Беләсезме, безнең артистларның күбесе фронтларга китеп бетте инде, шунда уйнап йөриләр. Хөррият һәркемгә дә бик кадерле, дустым, сакларга кирәк аны ничек тә! Югыйсә Алла сакласын...

Нәкъ шушы минутта йорт ягыннан ниндидер хәрәкәт, тавыш ишетелгән кебек булды. Әнием торып чыкмадымы икән дип, мин курка калдым. Салих та, сүзен әйтеп бетермичә, колак салып тора башлады.

— Кемдер йөри, әнием булмагае,— дидем мин, тынычсызланып.

— Аз гына сабыр! — диде ул, кулымнан тотып.

— Вакыт, җаным!

— Бик тиз, кызганыч! — дип куйды ул, гүя үз-үзенә, аннары ашыгып әйтте: — Моннан соң без бер-беребезне югалтырга тиеш түгел, ишетәсеңме?.. Югалтмаска һәм аерылмаска! Ишетәсеңме?

— Ишетәм!

— Утарда күпме торырсыз икән?

— Белмим әле. Берәр ай торырбыз, ахрысы...

— Озак!.. Мин көтәрмен... Кайткач та Сабира аша хәбәр ит. Минем торган җирем Мещанский урамда, зәңгәр мәчеттән ерак түгел, Шиһап Әхмеров йортын сораса, һәркем әйтеп бирер... Ул минем җизнәм, онытмассыңмы?

— Юк, онытмам!

— Инде миңа вакытлыча Казаннан китеп барырга туры килсә, мин апамда хат калдырырмын, шул хаттан минем кайда икәнемне белерсең.

— Китмәссең әле...

— Бәлки, китмәм дә, китсәм дә, кайтырмын. Без күрешербез, Гөлгенәм! Тик... сине берәрсенә биреп кенә куймасыннар.

— Сөйлә тагын!

— Юк, мин болай шаяртып кына.

— Син үзеңне сакла!

— Тыныч бул!.. Син дә тазарып кайт!

— Рәхмәт! Миңа вакыт!

— Хуш алайса, бәгырем, хуш!.. Яле, миңа бер кара!

Мин аңа күтәрелеп карадым. Ул бер генә мизгел икеләнгән шикелле булды да аннары кинәт кенә мине үзенә тартып алды. Һәм сул кулы белән күкрәгенә кысып, иеләбиреп, иреннәремнән суырып та үпте. Мин карышмадым.

Ул янә икенче тапкыр, мөһер салгандай, озак итеп үпте.

— Җитәр! — дидем мин, хәлсезләнеп.

— Кичер! — диде ул буыла төшкән тавыш белән һәм мине кочагыннан җибәрде.

Бер мәлгә башым әйләнгәндәй мин чайкалып куйдым, ләкин шул секундка ук борылып китеп тә бардым. Салих, миләш агачына таянып, баскан урынында торып калды.

Ашыгып өй янына килсәм, торган кеше дә, йөргән кеше дә күренми, хәтта «саклап торучы» Сабирам да кәнәфигә кырын төшеп йоклап киткән. Тик ишегалдындагы агайлар гына атлары тирәсендә чуалалар — шуларны ишетеп курыкканбыз, күрәсең.

Ә бер сәгатьтән соң без, җыенып, яңадан юлга чыктык. Әүвәлгечә алдан Касыйм абый белән әнием, алар артыннан без, безнең арттан Салихларның пар аты —әйбәт кенә хәл алганнан соң җиңел генә юырттырып барабыз. Кырлар өстендә җәйге озын көннәрдә генә була торган сүлпән, хәрәкәтсез тынлык — барысы да талчыккан, оеган, хәтта кошлар да очмый. Арттагы егетләр дә бик тын — уйнамыйлар да, көлгән-сөйләшкән тавышлары да ишетелми. Шулай кирәк. Минем дә күңелем шушы талгын тынлык белән тулы. Миңа рәхәт, миңа тавыш та, уен да — берни дә кирәкми. Барысы да үз эчемдә минем — кояшы да, чәчәкләре дә, музыкасы да! Мин Салихның әйткән сүзләре турында да уйламыйм, мин әле тик аның үбүе турында гына уйлыйм. Чөнки аның үбүе минем иреннәремдә саклана, чөнки бу минем егет кеше белән беренче мәртәбә үбешүем. Беренче мәртәбә!.. Гомерең буена да онытылмыйдыр инде ул...

Менә бервакытны Салихлар пар аты безне чаптырып узып китте. Күпмедер җир узгач, сулга каерылган юл башында алар туктадылар. Безнекеләр дә туктады. Шушында аерылышабыз икән. Аерылышабыз... Алар — сулга, без — турыга. Йөрәккәем, тыныч бул, гомерлеккә түгел ич!.. Егетләр, тарантасларыннан төшеп, безнең белән саубуллаша башладылар. Салих иң элек әнием һәм Касыйм абый белән саубуллашты. Аннары безнең янга килде. Башта Сабирага кулын бирде, тик иң ахырдан гына миңа сузды. Минем аңа бик туры итеп, өзелеп, бирелеп карыйсым килде, әмма күз яшьләремне тыеп кала алмам дип курыктым. Ә ул, нидер көткәндәй, минем кулымны һаман җибәрмичә торды. Бары иң соңгы минутта гына мин аның пышылдап әйткән сүзен ишеттем:

— Онытма!..

Без кузгалдык. Шунда ук өч егет безнең арттан скрипка, гармун, мандолинада «Аккош маршы»н уйнап та җи-

бәрделәр. Мин бөтен гәүдәм белән артыма борылдым. Аларның атлары кузгалмаган иде әле. Салих җиргә баскан да, кечкенә гармунын күтәрә биреп, тибрәндереп, илаһи бер дәрт белән уйный инде, әйтерсең менә күкрәгеннән безгә аккошның үзен очырмакчы була! Мин ак кулъяулыгымны чыгарып аңа кат-кат болгадым, аннары... кинәт кенә Сабираның алдына бөгелеп төштем.

## XV

Менә бер атна инде без утарда яшибез. Килгәч тә, утарның бөтен тирә-ягын Сабира белән икәү йөреп чыктык. Монда дөнья гаҗәп иркен һәм буш — кешеләрдән буш. Иң якын мукшы авылы да моннан биш чакрымда. Халык йөри торган олырак юл да бу тирәдән үтми — әнә шундый бер аулак, тыныч почмакта икән безнең утарыбыз.

Һәм шушында без бары алты кеше торабыз: утарны караучы Әхмәтша абзый хатыны Бәдернисa апа белән, аннары Касыйм абый белән без. Өч хатын-кыз. Җитмәсә әле, ике җирдә: Әхмәтша абзыйлар — ихата эчендәге кечкенә өйдә, ә без калай белән япкан зур өйдә торабыз. Бер уйласаң, куркыныч та инде. Явыз адәмнәргә, килеп, безне харап итеп китү ни тора?.. Ләкин аны уйламыйсың, ваемсыз гына тора бирәсең... Аннары утарны бозау чаклы ике зур эт саклый. Көндез алар бәйдә, келәт астында яталар, тик караңгы төшкәч кенә Әхмәтша абзый үзләрен бәйдән ычкындыра. Өч чакрымнан кеше якынлашканны сизәләр, ди Әхмәтша абзый. Тавышлары да аларның котыңны алырлык. Шуның өстенә Касыйм абыйның ау мылтыгы бар, кичтән шуңа патрон тыгып яткан була. Хәер, моның әллә ни ышанычы юктыр инде, чөнки мылтыкның чыны да халык арасында күп таралган, диләр.

Ләкин безнең өчен шунысы бик әйбәт — төннең хәзер иң кыска чагы. Бер яктан караңгы төшәргә өлгерми, икенче яктан әкрен генә сызылып таң да ата башлый. Ә көн яктысыннан пәриләр генә түгел, төрле куркыныч уйлар да кача.

Сабира белән без икәү күп йөрибез — югыйсә бу озын көнне кая куеп бетерәсең? Вак-төяк эшләрдән, ятып ял итүләрдән соң да әллә никадәр вакыт кала әле. (Монда гомумән вакыт дигән нәрсә бик мул һәм бик бәрәкәтле икән.) Әхмәтша абзый икебезгә дә каен тузыннан яңа тубаллар тегеп бирде — шуны беләгебезгә эләбез дә йә кырга, йә инеш буена чыгып китәбез. Кеше аягы басмаган җирнең байлыгына исең китәр!.. Кырга чыксаң, чирәм арасында оясы-оясы белән җир җиләге пешеп ята, инеш буендагы куаклыкларда учлап алырлык карлыган да

бөрлегән (тик катырак әле алар), ә тау итәгендәге чиялек бөтен иңе белән тоташ кызарып тора. Җыеп алучы да юк, ичмасам!.. Без башта, бер дә күрмәгәндәй, бик комсызланып җыйган идек. Көн дә тубалларыбызны тутырып йә җиләк, йә карлыган алып кайтабыз. Әнием, чүпләп, чистартып, әзрәк варенье да кайнатты (шикәр аз шул) күп итеп киптерде, күп итеп кагын койды. Аннары ул да бу эштән туйды.

— Җитәр, ташымагыз, кая куеп бетерергә белмим,— диде.

Ә безгә эш кирәк, безнең җыймыйча хәлебез юк. Сабираның карлыган ашый-ашый авызы каралып бетте инде.

Әнә шулай үтә минем көннәрем. Ашау-эчү Аллага шөкер! Чирәмдә генә йөргән сыерларның сөте, каймагы, яшь тәкә ите, шуның өстенә көн дә өч-дүрт шешә кымыз да эчәм. Бер заман, бөртеккә эләккән тавык шикелле, күзгә күренеп тула да башладым. Хәтта курка калдым: әгәр шуннан юанаеп китсәм, нишләрмен?! Ә Сабира, явыз, көлә генә: «Кияүгә чыккач нечкәрерсең»,— ди.

Әмма тәнгә тазарудан да бигрәк минем күңелем көр, кәефем яхшы иде. Миңа рәхәт, миңа хозур — әйләнәмдә шау чәчәктән сугылган кыр-ялан, чуер ташлар өстеннән уйнаклап йөгергән инеш, каршыда тын гына басып торган мәһабәт тау — кәҗә бәтиедәй сикерә-сикерә чап, тавына менеп кит, инешендә кояштан янган битеңне, түшләреңне ю — тагын ни кирәк миңа?! Ләкин, чын дөресен генә әйткәндә, бу ваемсыз рәхәтлек, бу шаян кәеф мондагы шифалы табигатьтән генә түгел иде, әлбәттә. Мин әле Салих белән очрашудан айныганым юк, мин әле аның сүзләрен күңелемдә йөртәм, минем әле үзем генә белгән бик кадерле серем бар. Без бергә булырбыз, бәгырем, мин шул өмит белән яшим, диде ич ул миңа. Ә өмит — канат бит ул, ак канат!.. Менә шул җилкендерә, шул очындыра инде мине дә! Аяз, бик аяз әле баш өстемдәге күгем дә!

Утарда бер атна чамасы торганнан соң, Касыйм абый, хатыны белән балаларын алып килер өчен, Сембергә кайтып китте. Без инде аңа озак тормагыз, дип, бик нык әйтеп калдык. Гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, ул киткән көннең кичендә үк, бөтен дөньяны иңләп, таулар ишелгәндәй күкрәп, өстебезгә давыллы яңгыр килде. Төне буе яшен өйнең бөтен тәрәзәләрен өзлексез яктыртып, дөм караңгы тышны чатыр да чотыр телгәләп, үкерепдулап, яңгырны уратып-уратып койды гына. Гарасат купты дип торабыз. Шулхәтле котыбыз алынды — кая керергә, нишләргә белмәдек. Яшен китереп сугар да өебез гөлт итеп китәр төсле, билләһи менә!.. Сабира белән икәү

өйнең түр почмагына, идәнгә кочаклашып утырдык та эчебездән генә бөтен белгән догаларыбызны бутый-бутый укыган булдык. Шул чакта да Сабира, тиле, шырык-шырык көлә тагын. «Ник көләсең?» — дигәч, «Ишетмәдеңмени, Хозер Ильяс бабайның күчәре шартлап сынды бит»,— ди, юньсез! Тәүбә дә итми, ичмасам! Әнием генә куркуын алай бик сиздермәде. Авыз эченнән генә укынып, ишек-морҗаларны тикшереп, тәрәзә пәрдәләрен төшереп, һаман йөренеп торды. Ул төнне инде безгә күз йомарга туры килмәде. Ә таң алдыннан давыл басылды, бераздан яңгыры да туктады, күк ачылды һәм менә ялт итеп кояш та чыкты. Гаҗәеп якты, йомшак, юеш исле, җем-җем уйнаклап торган көн туды. Без йөгерешеп ишегалдына чыктык. Кара шарлавыклар котырынып, күбекләнеп түбәнгә таба һаман ага иде әле. Ихата уртасында ыштан балакларын тездән югары сызганган, кулына тимер көрәк тоткан Әхмәтша абзый исе китеп карап тора: «Ну, бирде дә соң Ходаның хикмәте! — ди, башын чайкап.— Ярый әле, мал-туарга зыяны тимәгән, тик әнә мунчаның кыегын туздырган да ишегалдында торган арбаны агызып киткән»,— ди. Ә безгә кызык, безгә анысы гына җитми, мунчаны агызып киткән булса, безгә тагы да кызыграк булыр иде.

Дүрт көннән соң Касыйм абый да хатын, бала-чагаларын төяп кайтып җитте. Аларга ияреп, икенче атта бер ханым белән бер егет тә килгәннәр иде. Әнием бу ике кунакны аеруча куанып каршы алды.

— Һай, кадерле кунаклар, менә рәхмәт, менә килеп яхшы иттегез! — дип, аларның бер алдына, бер артына төште.

Дөрестән дә, болар ни җитте генә кешеләр түгел иде. Сара апа бөтен килеш-килбәте, өс-башы белән бай чиновник хатыннарына охшаган: гәүдәгә мәһабәт, таза, түгәрәктулы битле, ап-ак юан муенлы, чәч толымарын да ул нәкъ марҗаларча баш өстенә урап өеп куйган. Өстендә ак сүченчәдән бик иркен тегелгән җәйге җилән, кулында кояштан сакланыр өчен бамбук саплы, бик нәкышләп эшләнгән япон зонтигы... Кыяфәтендә аның татарныкы дип әйтерлек бернәрсә дә юк иде. Хәтта сөйләшүе дә татарча өйрәнгән рус хатыннарыныкы кебегрәк. Әнием белән алар кыз чакларыннан ук якын танышлар, минем дә шулай ук беренче мәртәбә генә күрүем түгел.

Егет исә Сара апаның бердәнбер улы. Исеме — Газиз, аларча әйтсәк — Азиз... Әнисенә бер дә охшамаган — озынябык, йөзе каратутлы, күзләре дә чем-кара. Ул да европча киенгән, өстендә җиз каптырмалы кара накидка, ба-

шында ак панама, ә накидка астында ачык сорыдан бик шәп тройка... Ул инде коммерческий училищены бетергән, Салихка караганда яшькә дә олырак булырга тиеш.

Менә шулай. Бала-чагалар да кайткач, кадерле кунаклар да килгәч, безнең тып-тын утарыбыз бердән җанланып китте. Ыгы-зыгы, шау-шу көчәйде. Ашау-эчү мәшәкатьләре дә артты. Ләкин болардан зарланган кеше юк, киресенчә, бар да шат, бар да бик канәгать, көлү-сөйләшүләр дә бер генә минут та диярлек тынып тормый. Әлегә әйтәсе дә түгел, күңелле минутлар.

Сара апа ни сәбәптер миңа бик игътибарлы. Елмаеп кына карый, сөеп кенә дәшә, ике сүзнең берендә «Сүеклем!» дип кенә тора. Кайчагында, исе киткәндәй, русчалап: «Однако же, какая ты прелесть, Гулечка моя!» — дип тә куя, мине тәмам кызартып.

Ә улы менә бер дә алай түгел. Бик аз сүзле, миңа әллә ни игътибар да итмәгән төсле, дөрес, каравын карый инде, ләкин махсус «ухаживать» иткән булып эчемне пошырмый. Әллә бик әдәпле, әллә артык кыюсыз — мин әле белеп тә җиткерә алмыйм. Һәрхәлдә, зарарсыз егет.

Шулай да без аны, кунак егете булгач, үзебез белән ияртеп йөрибез. Ике ахирәт апаның сүзләре һич бетәрлек түгел, аулакка китәләр дә берөзлексез нидер сөйләшәләр дә сөйләшәләр. Вакыт-вакыт Касыйм абыйны да чакырып алалар. Ә безне, барыгыз әнә Газизгә матур җирләрне күрсәтегез, дип, өй тирәсеннән куып кына торалар. Һәм без өчәүләшеп йә кырга, йә инеш буена чыгып китәбез. Ләкин Сабира да, мин дә, өйрәнелгән гадәт буенча, ирексездән диярлек гел җиргә карап, җиләген-фәләнен эзләп йөрибез, ә Газиз, кымыз шешәләрен күтәреп, безнең арттан тавышсыз гына ияреп йөри. Без дәшмәсәк, ул авызын да ачмый. Болай килешми бит инде. Кунак егетен сөйләндерергә кирәк ич, ләкин мин үзем нишләптер һич кенә дә менә сүз таба алмыйм. Шуны сизепме, Сабира аның игътибарын күбрәк билә... билергә тырыша. Сабирага уйлап тору кирәкми, теленә килгәнне әйтә дә сала.

Бер ул тотты да сорап куйды:

— Газиз әфәнде, сез кем буласыз?

Егет, бичара, аптырап калды:

— Аңламадым, туташ!

— Нинди кеше, дим?

Егет иңбашын гына җыерды.

— Белмим.

— Ничек белмисез?.. Кәмисәр түгел инде сез, анысы күренеп тора. Әртискә дә охшамагансыз. Купич малаемы әллә?

— Мин банкта служить итәм.
Алайса сездә акча күптер инде.
— Акча — казенный, туташ!
— Шулаймыни? Кызганыч!
Мин Сабираның бу тиле-миле сөйләнүеннән егетнең хәтере калмагае дип курка калдым, шуңа күрә үзем дә сораган булдым:
— Банклар эшлимени әле?
— Акча барында банк эшләмичә тормый, туташ!
— Яптылар түгелме соң?
— Алар — частный банклар.
— Алай икән. Сез безне наданлыкта гаепләмәгез инде, Газиз әфәнде!
— Что сез! Боже упаси!
— Кая, кулыгызны бирегез әле,— диде Сабира аңа.— Бирегез, бир, курыкмагыз, тешләмәм! Упаси!
Егет кыюсыз гына кулын сузды, ә Сабира аның учына тутырып җиләк салды.
— Ашагыз, сезнең өчен кызарып пешкәннәрен генә җыйдым. Ату безнең ялан җимешен авыз да итмичә китәр идегез бугай.
— Рәхмәт, туташ, рәхмәт! — диде егет, баш иеп.
Ә икенче бер йөрергә чыкканда Сабира, явыз, аңардан: «Безнең Гөләндәм туташ сезгә ошыймы?» — дип сорамасынмы тагын.
Миңа шултикле уңайсыз булып китте — түзмәдем, Сабираның аркасын төяргә тотындым:
— Менә сиңа! Менә сиңа!.. Телеңә тилчә дә чыкмый, ичмасам!..
Егет тә бик кызарды, күпмедер вакыт ни әйтергә дә белмичә торды. Аннары, түбән карап кына:
— Мин бит Гөләндәм туташны күптән беләм,— диде.
Сабирага бу җитә калды:
— Әнә ишетәсеңме, Газиз әфәнде, сине беләм, ди. Күргәнегез дә бармы?
— Әйе, бар.
— Әнә, әнә ишетәсеңме, күргәнем дә бар, ди!
— Ә мин белмим, белмим, күргәнем дә юк! — дидем мин, кырт кына кисеп.
— Оныткансыздыр,— диде егет, уйчан гына.
— Бәлки.
— Сез ул чакта яшь кенә кыз идегез.
— Кайчан соң ул?
— Ну... моннан бер өч ел элек. Казанга баргач, мин Мәликә тәтәй белән күрешер өчен сезгә кергән идем. Без сөйләшеп утырганда, сез мәктәптән кайтып керде-

гез. Мәликә тәтәй: «Менә бу минем кызым Гөләндәм»,— диде. Мин торып баш игәч, сез миңа реверанс ясадыгыз, ләкин шунда ук чыгып та киттегез.

Кылт итеп исемә төште: әйе, кайчандыр мин үзебездә студент формасы кигән бер чандыр гына егетне күреп калган идем шул. Әнием соңыннан аны «бик әдәпле егет икән» дип мактап та торды. Ничек итеп онытканмын, күргәч ничек танымаганмын — шуңа исем китә. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге, диләрме әле?.. Шулайрак килеп чыкты шул. Хәзер инде исемә төшсә дә, таныдым дип әйтүе ничектер уңайсыз. Бөтенләй игътибарсызлыгымны икърар итү була. Шуңа күрә кыенсынып кына:

— Бәлки, шулай булгандыр,— дидем.— Ләкин сез гафу итегез, минем бөтенләй хәтеремнән чыккан.

— Зарар юк,— диде егет, тыныч кына.

Ә өч көннән соң алар китеп тә бардылар. Өч көн буена әнием белән Сара апа һаман нидер сөйләштеләр, ләкин барыбер сүзләре бетмәгәндер, ахрысы, чөнки аларны озатканда әнием кат-кат:

— Тору кирәк иде бит әле, тору кирәк иде, бигрәк тә тиз китәсез инде,— дип үрсәләнде.

Сара апа да, ачынып:

— Ах, Мәликә җаным, бик кенә торыр идек тә бит, мөмкин түгел шул,— диде.— Азиземә комиссары өч кенә көн вакыт бирде. Нишлисең, заманасы бит, заманасы!

— Тиздән тагын күрешергә Ходай насыйп итсен инде,— диде әнием.— Газиз улым, Казанга юлың төшсә, туры үзебезгә кил!

— Рәхмәт, тәтәй! — диде егет, башын ия биреп.

Тарантаска утырыр алдыннан Сара апа мине: «Килче, гүзәлем!» — дип чакырып алды һәм, аналарча тулы күкрәгенә кысып, аркамнан сөйде. Ә нидер көткәндәй миннән күзләрен алмыйча карап торган улына мин инде үзем кул суздым (әдәп кагыйдәсе кушканча); ул шуңа бик куанып, түбәнчелек белән минем бармак очларымны кысты.

Кунаклар киткәч, гадәттә күңелсез булып кала. Әйләнәдә бушлык туа, эч поша... Ләкин минем өчен бу гадәти күңелсезлек кенә түгел иде. Ниндидер билгесез бер борчылу, тынычсызлану орлыгы салып киттеләр алар минем йөрәгемә. Ни өчен, нинди максат белән килделәр дә киттеләр? — шушы нәрсә ихтыярсыздан мине әледәнәле уйландыра иде.

Ә бер биш-алты көннән соң кинәт минем моннан тизрәк кайтып китәсем килә башлады. Һичнәрсә — бу тып-тыныч утар үзе дә, әйләнәсендәге бик тә ямьле кырлары-яланнары да, җыеп бетермәслек җиләкләре-чәчәк-

ләре дә — берсе дә күземә күренмәс булды. Әйтерсең үкереп торган диңгез уртасындагы ташландык бер утрауда яшисең, билләһи!.. Салихның сүзләре исемә төште: «Дөнья искиткеч тиз үзгәрә!» — дип әйткән иде ул миңа. Үзгәрмиме соң!.. Шәһәрләрдә, авылларда әллә ниләр бардыр әле. Кешеләрне әллә ниләр көтәдер. Бу үзгәрешләр кемнәргә генә кагылмый торгандыр. Бәлки, Салихка да тигәндер, бәлки, миңа да тиմәкчедер... Күңел тыныч түгел, күңел йолкына, күңел нидер сизенә!.. Юк, артык монда калырга ярамый, китәргә, китәргә, тизрәк китәргә!

Билгеле инде, әниемне дә бик нык кыстый башладым. Көн дә китү турында сүз чыгармыйча калмыйм. Әнием, гаҗәпләнеп: «Ни булды сиңа?» — ди. «Берни дә булганы юк,— дим,— кайтасым килә — менә шул!..» Җитмәсә, Касыйм абый да авыз ачтырмый, балалар да «китмисез!» дә «китмисез!» — дип итәккә ябышалар. Ләкин әнием тиздән үзе дә китәргә кирәк дигән карарга килде. Өч атна тулып узды бит инде. Ә Казанда өй ялгыз, әтием ялгыз, минем дә торасым килмәгәч, монда артык ятуның мәгънәсе юк иде.

Соңгы мәртәбә Сабира белән икәү каршыдагы текә тауга мендек. Яшел үзәннәр, сөзәк калкулыклар аша күгелҗем томан эченә китеп югалган ялан-кырларга, офыкларны каплап караеп торган урманнарга, еракттагы авылларның ялтырап күренгән чиркәү гөмбәзләренә сүзсез генә карап тордык.

Ә түбәндә, инеш аша гына, безнең утарыбыз — моннан кечкенә, боек кына булып күренә... Менә без китәбез, шуннан соң Касыйм абый да бала-чагаларын төяп кайтып китәр. Утар бөтенләй кешесез калыр. Ә күпме матурлык аның әйләнәсендә!.. Тапталмаган матурлык!.. Яңадан сиңа килү насыйп булыр микән, утарчык, бәгырем?.. Әллә син үзең дә тиздән бетәрсеңме икән?

...Әле балалар да йокыларыннан уянмас борын, җәйге кояш белән бергә торып, без утардан чыгып киттек. Бу юлы безне Әхмәтша абзый пар атта илтә барды. Үз кешебез булгач, ничектер җан да тынычрак, баруы да күңеллерәк иде... Көн кызуында атларга ял бирер өчен бер урман ышыгында туктап, яшел чирәмдә генә үзебез дә ашапэчеп, әзрәк кенә баш та куеп алдык. Ә караңгы төшәр алдыннан бер татар авылына җитеп, Әхмәтша абзыйның баҗа тиешле кешесенә куна кердек. Ашлар өлгертеп, безне бик әйбәт кенә сыйладылар. Икенче көнне инде төш вакытларында үзебезнең Казаныбызга да кайтып җиттек.

Бу инде июль ахырлары иде. Шәһәрдә эссе, бөркү, тузан — утардан соң тончыгып үләрлек! Шулай да үз шәһәрең, үз өең җанга якынрак шул... Әтием дә исән-имин

генә торган. Болай тынычлык икән, ләкин азык-төлек хәлләре бик читенләшкән, шәһәрдә гаскәриләр дә бик күбәйгән.

Ә минем үз кайгым — Салих кайда икән, мин кайтканны белми инде ул, ничектер хәбәр итәсе иде бит үзенә! Кирәк булсам, Сабираны җизниләр өенә җибәрерсең, дигән иде, ләкин бер сылтаусыз җибәрүе әллә ничек уңайсызрак бит әле. Бераз сабыр итәргә туры килер инде.

Әмма... сылтау үзен озак көттермәде. (Сылтауның да нинди генә әле...) Кайтуыбызга өч-дүрт көн узды микән, әнием минә бервакытны мине үзләренең йокы бүлмәсенә чакырып алды. Әтием өйдә юк иде. Утырырга кушты. Мин эчемнән генә: «Бу нинди утырып сөйләшерлек сүз икән?» — дип, зур сандык өстенә утырдым. Әнием дә минем яныма утырды. Миңа карап әз генә дәшми торганнан соң, ашыкмыйча гына сүзен болай дип башлады:

— Кызым, әйтәсе сүзем бик мөһим, яхшылап тыңла. Хәер, мин моны сиңа утарда чакта ук әйтергә тиеш идем, ләкин өйгә кайтып, әтиең белән дә мәслихәтләшүне кирәк таптым. Ийе, Алланың язганы шулдыр инде, кызым, сине бер бик яхшы җиргә сорап торалар бит әле.

Мин инде сүзнең башыннан ук нәрсә ишетәсемне сизенгән идем һәм, бөтен тәнем белән ирексездән куырылып, таш сын шикелле өнсез дә калган идем. Шулай да, үземне көчләп диярлек, аңлап бетермәгәндәй сорадым:

— Ничек... сорап торалар? Ни дигән сүз ул?

— Син инде бала түгелсең,— диде әнием, сабыр гына,— кыз кешене сорауның нәрсә икәнен, шәт, үзең дә аңлыйсыңдыр. Сине Сара апаңның улы Газизгә сорыйлар.

— Туктале, әнием... Мин һаман да аңлап җиткермим... Ни өчен сорыйлар, нигә, нинди максат белән?

— Һай Аллам, бала булмале, Гөләндәм!.. Сине Газиз әфәндегә кияүгә сорыйлар, менә шул!

Мин урынымнан сикереп тордым.

— Бу була торган эш түгел ич, әнием!

— Тукта, сабыр! — диде әнием, мине кулымнан тотып.— Ни өчен була торган эш түгел?.. Һәрбер кыз бала үсеп җиткәч кияүгә чыга. Барыбызның да башыннан кичкән... Сиңа да вакыт.

— Юк, юк, вакыт түгел!..

— Анысын инде менә мин — әниең — яхшырак беләм. Аллага шөкер, унҗидең тулды.

— Барыбер мин теләмим, теләмим...

— Тукта, котырынма әле син! — диде әнием, кинәт ачуланып.— Яхшылап тыңла!.. Мондый эштә корт чаккан шикелле чәбәләнергә ярамый. Акыл белән уйлап эшләргә

кирәк... Безнең ризалыктан, безнең фатихадан башка синең аяк атларга да хакың юк — шуны беләсеңме син?.. Синең киләчәгеңне кайгырту безнең вазифа, Аллаһе Тәгалә тарафыннан безнең өскә йөкләтелгән ул... Ә без синең өчен Газиз Акбирдинны иң мәгъкуль кеше дип табабыз. Үзең дә күрдең, Газиз әфәнде укымышлы, чын мәгънәсендә интеллигент кеше, гаять тәрбияле, әдәпле, тыйнак егет. Дөнья күргән яхшы кешеләрнең уллары... Үзе әйбәт урында хезмәт итә. Аяк-кулы да таза... Тагын ни кирәк?

Ләкин минем инде тыңлап торырлык сабырлыгым калмады. Мин курка башладым. Әйтерсең башыма ефәк җәтмә ташлап, мине каядыр әкрен генә сөйриләр — уралып бетмәс борын миңа котылырга кирәк, котылырга!.. Кулымны әнием кулыннан тартып алдым да:

— Юк, юк, ишетәсем дә килми, ишетәсем дә! — дип, бүлмәдән атылып чыгып та киттем. Әнием артымнан:

— Гөләндәм! — дип кычкырып калды.

Менә кайчан башланды ул! Бу уен түгел, бу хәтәр, бик хәтәр!.. Хәзер инде һәр көнне сүз шул хакта гына барыр... Үгет-нәсихәт, ялвару, куркыту, күз яше... Бигрәк тә этием белән сөйләшү мине куркыта — күп тә сөйләмәс ул, әмма хөкем карарыдай рәхимсез булыр аныкы... Йа Ходам, көч бир, ярдәмеңнән ташлама! Әллә ничек бик кинәт төште әле бу минем башыма, бөтенләй менә зиһеннәрем таралып китте. Хәлбуки мин... мин мондый хәлнең буласын күптән сизәргә, сизү генә түгел, көтәргә тиеш идем ләбаса!.. (Хәтта Салих та, көлеп кенә булса да, үзеңне берәрсенә биреп куймасыннар, дип әйтте ич!) Билгеле, Касыйм абый килүдән үк башланган булырга тиеш бу эш, беренче хәбәрне дә, һичшиксез, ул китергәндер — әти-әнием белән озаклап сөйләшүләре шул чакта ук миндә ниндидер шик-борчылу тудырган иде бит инде. Ә безне утарга алып китүе? Миңа ял кирәк, имеш! Ярый, шулай да булсын ди. Әмма ләкин төп максат мине Сембер егетенә күрсәтү булган түгелме соң? Сара апаның, улын ияртеп, махсус шуның өчен генә килеп китүе — бу бит инде сукыр кешенең дә күзен ачарга тиеш иде. Ә мин?.. Бу хәтле дә беркатлы сабый булырга кирәк бит, җитмәсә, сизеп торган өстенә!..

Салих, бәгырем, менә безнең дә сыналу сәгатьләребез килеп җитте. Бөтен өметем, ышанычым бары синдә генә!.. Син ни әйтерсең — минем язмышым хәзер шуңа бәйләнгән... Үзең кушканча, мин сиңа бүген үк Сабираны җибәрәм — безгә ничек тә тизрәк очрашып сөйләшергә кирәк. Мин бик мохтаҗ синең сүзеңә, синең кулыңа, кадерлем!..

Ләкин... эчемнән аңа әнә шулай мөрәҗәгать итсәм дә, мин Сабираны бүген үк җибәрүдән тыелырга булдым.

Чөнки әнием, һичшиксез, моны сизәчәк һәм Сабираны беркая да җибәрмәячәк. Безгә дә әзрәк хәйләкәр, акыллырак булырга кирәктер инде. Бер көн эчендә генә әллә ни булмас әле. Ә иртәгә Сабира кая да булса чыкмыйча калмас һәм шул чагында тиз генә барып та әйтер... Шулай уйлап куйдым мин. Үземчә саграк эшләргә тырыштым.

Ә кичен Сабира мине чәйгә чакыра менгәч, аңа әйттем:

— Чәйгә төшмим. Әниемә әйт, туташның башы авырта, диген. Мине борчымасыннар... Инде, Сабира җаным, сиңа сүзем бар, яхшылап тыңла. Иртәгә, берәр йомыш белән шәһәргә чыккач та, син иң элек Салих абыеңны барып тап. Аның торган җире зәңгәр мәчеттән ерак түгел, Шиһап Әхмеров йортында. Сорашсаң — күрсәтерләр. Салихны чакырып чыгар да әйт: «Туташның бүген үк сезне күрәсе килә, кичектерергә ярамый, очрашу урынын һәм вакытын үзегез әйтеп җибәрегез»,— диген. Аңладыңмы?

— Моны да аңламаска!

— Берүк әнием сизә күрмәсен!.. Син минем хәлемне беләсеңме, Сабира?

Кинәт күземә яшьләрем килеп тыгылды — мин тизрәк йөземне каплады. Сабира, башымнан сыйпап, мине юатырга тырышты:

— Беләм, җаным, барысын да беләм... Тыныч бул, кушканыңны шоп-шома эшләрмен, чуртым да сизмәс!..

Минем аңа бик тирән рәхмәтемне әйтәсем килде, тик яшьләрем генә ирек бирмәде... Сабирадан соң минем яныма бүтән керүче булмады. Әнием дә, кыз баланың тузгыган күңеле бераз басылсын, тынычлансын, дигәндер инде. Иртәгә тагын кирәк кадәр әйтерләр, тагын тынычланырга вакыт бирерләр — менә шулай көн саен әйтә-әйтә, әкренләп мине күндермәкче дә булалардыр. Ах, авырдыр, бик авырдыр моның кебек басымга каршы торулары!..

Ниләр генә уйлап бетермәдем мин бу төнне!.. Бер генә минутка да күз алдымнан Салих китмәде, бер генә минутка да аның белән иртәгә очрашуым уемнан чыкмады... Саташып бетә яздым. Ләкин, күпме генә уйласам да, киләчәк минем өчен билгесез иде. Ни көтә мине, ни булып бетәр моның ахыры?.. Әле көн туасы бар, әле аның сүзен ишетәсем бар. Йа Ходай, сабырлык бир миңа!..

Билгеле, мин Сембер егете турында да уйландым. Ачуым аңа юк кебек, әмма гаҗәпләнүем зур иде. Үзе бит ул миңа берни дә сиздермәде. Эшне шулай әниләр аша гына йөртергә теләде микәнни бу «бик тәрбияле», «бик акыллы», бик мактаулы егет?.. Гаҗәп, гаҗәп!.. Сез нәрсә, мине

кулдан гына ала торган бер курчак дип белдегезме әллә?.. Ялгышасыз ич, Газиз әфәнде, ялгышасыз!..

Кайчан йоклап киткәнмендер — белмим, бер заман күземне ачып җибәрсәм, каршымда Сабира басып тора. Күзләре елтырый, авызы ерылган кызыйның!

— Әллә бардың дамы? — дип сорадым мин, тиз генә урынымнан кузгалып.

Сабира «лып» итеп караватым читенә утырды да, иңбашымнан кочып, битемә иелде.

— Бардым шул, күбәләгем! — диде, кызу гына пышылдап.— Бардым, күрдем, сиңа тау чаклы сәлам китердем.

— Кай арада өлгердең?

— Өлгердем инде... Торгач та апа мине базарга күмер алырга җибәрде. Шул форсаттан файдаланып, тиз генә барып таптым бит үзен, Салих абыеңны, җаным!

— Йә соң, йә?.. Нәрсә диде ул сиңа?

— Бик куанды... Бик төпченеп сораша башлаган иде дә, мин әйттем, вакытым юк, бик ашыгам, туташка нәрсә дип әйтим, дидем.

— Ә син ни өчен килүеңне әйттеңме соң?

— Әйтмичә!..

— Йә, шуннан?..

— Салих абый әз генә уйланып торды да, туташка әйтегез, бүген сәгать дүрткә Бакыр бабай бакчасына* килсен, мин аны шунда көтәрмен, диде. Берүк килмичә калмасын, дип кабатлады да әле.

— Рәхмәт, Сабира җаным, мең мәртәбә рәхмәт сиңа! — дидем мин, сөенечемнән еларга җитешеп.— Мәңге онытмам синең бу яхшылыгыңны!

— Йә, тагын... яхшылык!.. Минем үземә дә кызык ич гашыйкларга ярдәм итү.

— Кызык дисең?

— Уйнап кына әйтәм, туташ! — диде Сабира, мине юатырга ашыгып.— Сезгә Ходай үзе ярдәм итсен инде. Тик апа гына сизә күрмәсен. Мин чыгыйм әле, аның бүген болай да сөремнәре коелып тора...

Ялгыз гына калгач та әле мин юка одеял астыннан чыкмыйча бераз уйланып яттым. Уйларым минем хәзер бик гади генә нәрсәләр тирәсендә иде: әйтик, нигә ул миңа Бакыр бабай бакчасына килергә кушты икән? Бездән шактый еракта ич ул бакча. Күрәсең, аулаграк, тынычрак урын булсын дигәндер инде. Дөрес, шәһәрнең бай

---

* Державин һәйкәле торган бакчаны татарлар шулай атап йөрткәннәр. Хәзер бу урында опера театры.— *Ә.Е.*

руслар торган матур бер җирендәге ул кечкенә бакчага җомга көннәрендә безнең бу түбән яктан татар хатын-кызлары да менеп йөрергә яраталар. Ләкин бүген җомга түгел, бүген атнакич шикелле. Димәк, төркем-төркем йөрүче безнең тирә кызлары анда булмаячак... Ә менә вакытны Салих белеп диярлек билгеләгән. Төшке аштан соң әтием гадәтенчә бераз ял итеп алырга ярата, әнием дә кухня эшләреннән туеп, берәр сәгатькә үз бүлмәләренә кереп ята. Минем дә бу — чыгып йөргәли торган вакытым. Тик шул вакытны бүген көтеп алырга гына кирәк!

Хәзер мине иң борчыганы һәм куркытканы — әниемнең яңадан сүз башлау ихтималы иде. Әгәр башлый калса, бу минем хәлне шактый читенләштерәчәк. Мин, билгеле, каршы торачакмын, сүз үзеннән-үзе зурга китәчәк, һәм икебезнең дә кәеф һичшиксез бозылачак. Әниемнең әле минем чыгып китүемә дә каршы төшүе бик мөмкин иде.

Менә шул сүз чыкмасын өчен ниндидер бер хәйләсен табарга кирәк. Иң яхшысы — берәр эш табу, эш белән мәшгуль булу, ул чагында әнием дә чарасыздан тыелып торырга мәҗбүр булачак.

Шуларны уйлап, мин тиз генә урынымнан тордым да, сатин халатымны гына киеп, түбән төштем. Әнием мине күргәч тә йомшак кына сорады:

— Йә, кызым, кәефең ничек, башың авыртмыймы инде?

Моңа да җавапны уйлабрак бирергә кирәк иде. Һәрхәлдә, авыруга сабышырга ярамый.

— Кәефем зарарсыз кебек, әни,— дидем, әз генә боеклык саклап.— Башым авыртыбрак тора иде торуын, ләкин үтсә кирәк.

— Үтсен инде, авырый торган чак түгел,— диде әнием.

Мин, сабын, сөлге алып, бакчага юынырга чыктым. Бакча эчендә беседкабыз да бар. Матур-җылы көннәрдә шунда ашап-эчәбез дә. Бүген дә чәйне шунда гына эчкәннәр икән — өстәлендә самавыр белән җыелмаган чынаяклар тора.

Ишегалдына чыккан Сабираны яныма дәшеп, шыпырт кына әйттем үзенә:

— Син эш тап әле, эш!..

— Нинди эш?

— Ниндие дә ярый, миңа эш кирәк бүген.

Сабира, зирәк кыз, шунда ук «эшне» аңлап алды.

— Кергә тотынабыз!

Тагын кер!.. Хәер, ярый инде, хатын-кыз өчен иң әйбәт сылтау бу — кергә тотыну.

— Тик кереңне бик күп чыгарма,— дидем мин аңа.

Сабира шунда ук чарасына да кереште: ишегалдында торган бакка су салып, астына ягып җибәрде, аннары өйгә кереп, әнием алдында: «Кичәдән бирле шушы нәрсәләргә кулым кычый, юып ташлыйм әле үзләрен, булмаса!» — дип сөйләнә-сөйләнә, керләнгән сөлгеләрне, салфеткаларны, савыт-саба сөрткеч тастымалларны бер өемгә җыя да башлады. Әнием: «Каян исеңә төште әле?» — дип әйтергә өлгергәнче, мин дә тизрәк үз сүземне кыстырдым:

— Бик әйбәт, минем дә юасы нәрсәләрем бар иде.

Шулай итеп, без, әниемнең ризалыгын да көтмичә, керләребезне тышка чыгарып, рәшәткә буена тагаракларны куеп, эшкә дә тотындык. Керебез күп түгел иде, ләкин соң гына башлагач, ашыкмыйча гына югач, эшебез бер-ике сәгатькә сузылды. Аннары әле юган нәрсәләребезне, иске кәрзингә салып, Кабанга төшеп чайкап та мендек. Бакчада сузган бауга киптерергә элеп тә куйдык. Шул рәвешчә төшне дә җиткердек, ул арада әниемнең ашы да өлгерде. Без, «эшләп арган» ике кыз, ашны кухняда гына ашадык.

Табак-савытларны җыештыргач, мин үз бүлмәмә менеп киттем. Ә бераздан өй эче дә тынды — безнекеләр ял итәргә ятканнардыр. Сәгать өченче ярты... Вакыт та күп калмаган икән... Ниндидер бер киеренкелек мине били башлады. Йөрәгем дә сулгып-сулгып куйгалый... Тынычлыгым шулай кача, күрәсең... Башта, үтмәсме бу дип, күпмедер вакыт тик кенә утырдым, аннары торып ашыкмыйча гына җыена башладым. Иң элек кулларымны одеколон белән әйбәтләп сөрттем. Аннары өстемә көмеш төслерәк ефәк күлмәгемне, кыска кара жакетымны, аягыма биек үкчәле ак туфлиләремне кидем... Башыма нәрсә кияргә?.. Шушы киң читле эшләпәмне кисәм? — юк, килешмәс ул бүген... Йөземне дә, кирәксә, капларлык булсын дип, юка гына кара челтәр шарфымны ябындым. Булды, бетте шикелле. Чыгар алдыннан көзге каршына бастым. Мин җитеп килгән (әллә җиткән?) сылу гына кыз икәнмен ләбаса! Миңа үз язмышымны хәл итәргә вакыттыр инде. Аллага тапшырдым!

Түбән төшүемә әнием очрады. (Кай арада торып та чыккан!)

— Кая болай киенеп-ясанып? — дип сорады.

— Йөреп кайтам әле,— дидем мин, туктальп тормыйча гына. Шулай да аның миңа шактый сынап каравын күреп өлгердем... «Озак йөрмә!» — дип калды ул артымнан. (Әниләр сүзе һәрвакытта безне бәйли — гүя гомер буена бәйләүдә без...)

Печән базары чатына барып җиткәч, мин трамвай көтәргә булдым. Ара да шактый ерак, вакыт та аз калган иде... Ә ул андадыр инде, көтә торгандыр.

Бу юлы артык зарыктырмыйча гына иске трамвай да шалтырап килеп җитте. Мин кереп ачык тәрәзә янына утырдым. Урамны, кешеләрне гамьсез генә күзәтеп барам. Әллә нинди сәер бер бушлыкмы, тынычлыкмы үземдә. Хәтта кая баруым, ни өчен баруым турында да уйлап азапланмыйм. Гүя барсын да язмышка тапшырганмын.

Грузинский чатына җиткәч, трамвайдан төшеп, урам аша чыктым да, борынгы юнан* шагыйрьләренә охшатып эшләнгән Державин һәйкәле яныннан узып, бакчага кердем. Бакча юлларында һичкем күренми иде. Тик карт имән төбендәге эскәмиядә бер хәрби кешенең тезләренә таянып утырып торуы күземә чалынды, ләкин мин, аңа карамаска тырышып, үтеп китмәкче булдым. Аз гына китә төшкәч тә артымнан берәүнең:

— Ах, туташ, туташ, танымый да башлагансыз! —дигән тавышы ишетелде. Сискәнеп артыма борылсам, каршымда Салих басып тора!.. Озын кунычлы итекләрдән, гимнастеркадан, фуражкадан! Салих хәрби киемдә!.. Кинәт эчемдә нидер өзелгәндәй булды... Ә ул көлә.

— Танырсыңмы икән дип юри урынымнан тормадым.

— Каян таныйм инде!.. Хәрби киемнән күрермен дип башыма да китермәдем мин.

— Әллә хәрби кием миңа килешмиме? — диде, көлүеннән туктап.

Мин аның өс-башына игътибар беләнрәк карадым. Килешми дип әйтерлек түгел, киресенчә, бөтенесе дә өстендә бик ыспай утыра. Асыл сөяккә килешмиме соң?.. Ләкин минем аңа «килешә» дип әйтәсем килмәде. «Белмим» дип кенә куйдым. Башымда бөтенләй икенче уйлар иде.

— Кайчан алдылар соң әле сине? — дидем мин, аптыравымны яшерә алмыйча.

— Мин инде, бәгырь, алганнарын көтмәдем, үзем барып язылдым,— диде ул, гаепле сыманрак итеп.

— Үзең? Гаҗәп!.. Син музыкант ич, сугышка синең ни кирәгең бар?

— Ах, Гөләндәм, сугыш музыкасыз буламыни? — диде ул, гүя чын күңелдән.

Мин ни әйтергә дә белмәдем. Әллә тагын көлә инде, Ходаем! Ләкин Салих, минем боегып, нәүмизләнеп калуымны күреп, ике кулымнан тотты да йомшак кына: «Әйдә, утырыйк!» — диде. Без шул ук карт имән төбенә утырдык. Аннары, мине юатырга теләп, ахрысы, җитди-сабыр гына:

— Син борчылма, кадерлем! — диде.— Шулай кирәк

---

* Грек. — *Ә.Е.*

булды. Бер мин генә түгел. Әнә артистларның күбесе фронтларда уйнап йөриләр. Күп кенә әдипләр, шагыйрьләр дә кызыл гаскәр сафында хезмәт итә. Азатлык бик кадерле нәрсә, аны һәркем якларга тиеш. Бу намус эше, аңлыйсыңмы, бәгырем!

— Аңлыйм,— дидем мин, әкрен генә.

— Син — акыллы! — дип куйды ул, сөенгәндәй.— Тик син хафаланма. Бу озакка бармаячак. Күп булса бер ел, ике ел үтәр, контрреволюция һичшиксез җиңелер, сугышлар бетәр, без яңадан бергә булырбыз — сабыр гына итик!

Хафаланма! Сабыр гына итик!.. Ә менә хәзер, шушы минутта, минем бөтен өметләрем җимерелеп бара — ул шуны белми әле. Мин тәмам гаҗизлеккә төшеп, ни уйларга, ни әйтергә дә белмичә, башымны салындырып утырам... Китмә, ташлама, димме? — әмма бу бит аның... намус эше!.. Чигенәме соң ул?! Шулай ук барысы да бетәмени, өзеләмени инде, өзеләмени?! Йа Раббым!..

Аз гына көткәннән соң, ул минем кулымны яңадан ике учына алды, йөземә карап:

— Син бүген бик күңелсез, әйтмәсәң дә аңлыйм инде, бәгырь, аңлыйм, минем үземә дә һич тә җиңел түгел,— диде.— Мин сине өзелеп көттем, Гөлгенәм! Күрми калам дип бик курыккан идем. Сүзләрем бар сиңа, бик мөһим сүзләрем... Ләкин башта үзең сөйләле, синең тирәдә ниләр бар? Сабира әйтеп бетермәде, әмма аның мине эзләп килүе юкка гына түгелдер бит. Сөйлә, ни булды?..

Сөйләргә... Ләкин кирәкме соң инде ул хәзер? Нәрсәне генә үзгәртәчәк минем сөйләп маташуларым? Әмма ни өчен килдем соң мин аның янына?.. Зарыгып көтеп, ашкынып, өметләнеп, хыялланып... Һич югы, белеп калсын!

Шактый дәшә алмый торып, үземне көчләп диярлек әйттем ахырда:

— Мине... бирмәкче булалар...

Салих чак кына тайпылып куйды:

— Бирмәкче?! Аңлап бетермәдем, бәгырь!..

— Соң инде... кияүгә, дим.

— Ах, шулаймыни! Сине кияүгә бирмәкче булалар? Ниһаять, аңладым! — диде ул, көләргә итеп.— Кара син аны!.. Хәер, мин сиңа әйттем түгелме?.. Менә күрдеңме! Синдәй кызны озак тоталармы соң! Аннары ул җитдиләнеп сорады: — Хуш, кайчанрак бирмәкче булалар инде?

— Анысын белмим әле.

— Кемгә, нинди кешегә?

— Бер... Сембер егетенә.

— Син аны күрдеңме?

Мин икеләнебрәк тордым да әйттем:

— Ийе, күрдем.

— Кайчан, кайда?

— Әнисе белән утарга килгәннәр иде.

— Алай икән,— диде ул, шактый караңгыланып.— Шунда булдымыни инде танышу-сөйләшүләр?..

— Сөйләшү булмады, мин бернәрсә дә белмәдем.

— Кичер, бәгырь!.. Шулай да кайчан белдең соң син?

— Әнием моны миңа кичә генә әйтте.

— Кичә генә?! Нәрсә диде инде әниең?

— Сине... әнә шул егеткә сорыйлар, диде.

— Әлбәттә, чыгарга кирәк, дигәндер инде.

— Ийе, әтием дә, әнием дә бик телиләр.

— Һәм егет тә шәптер инде,— диде ул, ашыгып.— Баймы, укыганмы?

Мин аның теләмичә ирексездән генә соравын сиздем, шулай да турысын гына әйтергә булдым:

— Байлыгын белмим... Үзе ул коммерческий училище бетергән, хәзер ниндидер банкта хезмәт итә икән.

— Зур хәбәр китердең син миңа, бәгырь, көтелмәгән зур хәбәр!..

Шуннан соң ул нык кына уйга калды, күксел-зәңгәр күзләре дә караңгылана төшкәндәй булды. Мин дә, аңа комачауларга теләмичә, тик кенә көтеп утырдым. Күпмедер вакыт шулай уйга калып торганнан соң ул, ниһаять, миннән әкрен-йомшак кына итеп сорады:

— Йә, Гөләндәм, үзең... үзең соң нәрсә уйлыйсың?

Нәрсә уйлыйм мин? — бу да бит аңа ачык булырга тиеш. Әллә үз авызымнан ишетәсе киләме? Ләкин мин аңа бик гади генә итеп әйттем:

— Мин менә сиңа килдем.

Ул иелеп минем кулымны үпте, бу аның бик риза булу, бик якын итү билгесе иде.

— Бик дөрес иткәнсең, кадерлем, бик вакытлы килгәнсең,— диде ул, дулкынланып.— Теге бакча түрендә сөйләшкәнне онытмагансың икән, рәхмәт сиңа, рәхмәт!.. Без, әлбәттә, бергә булырга тиешбез. Вәгъдә — иман!

«Ничек итеп соң, Ходаем?» — дип уйлап куйдым мин. Ә ул сөйли бирде:

— Тик син мине гафу итә күр! Мин үз исәбемдә шактый ялгышканмын икән. Теге чакта көлеп кенә, сине биреп куймасыннар, дип әйтсәм дә, мин моңа күңелемнән һич тә ышанмаган идем. Каты көрәш бара, сугыш бетмәгән, кешеләрдә хәзер өйләнешү кайгысымыни, дип уйлаган булдым. Шуңа күрә безгә дә азрак сабыр итәргә мөмкиндер дип, үземчә исәпләгән идем. Ләкин кешеләр

безнең язмышларны башкачарак хәл итмәкче булганнар икән. Әмма без аны үзебезчә хәл итәргә тиешбез!

Ул бер генә секундка тукталып, миңа беравык бик төбәлеп карап торды. Һәм яңадан кызу гына башлап китте:

— Гөләндәм, кадерлем, әгәр мин бүген үк сезгә барып, әти-әниең белән үзем сөйләшсәм яки апа белән җизнине икесен яучы итеп җибәрсәм?.. Җизни минем бик мөхтәрәм кеше... Бәлки, аңларлар, риза булырлар?.. Ниһаять, син үз сүзеңне ачыктан-ачык әйтерсең. Синең сүзең бөтенесен дә хәл итәргә тиеш бит. Шулай түгелме? Йә, ни уйлыйсың?

Салихның болай әйтүе ничаклы гына урынлы булмасын, ләкин ул бернинди дә нәтиҗә бирмәячәк иде. Мин шулай дидем дә:

— Юк, Салих, безнекеләр риза булмаячаклар. Мин дә, ни генә әйтсәм дә, күндерә алуыма ышанмыйм. Аннары... син әнә солдат бит әле...

— Ә син бераз гына солдатка булып торырсың,— диде ул, көлеп, ләкин шунда ук урынсыз шаяртуын сизеп, кичерү сорагандай өстәде: — Син ачуланма, мин болай сүз туры килгәнгә генә... Инде... чынлап уйлаганда аның ни әһәмияте бар соң, бәгырь, мин синең өчен шул ук Салих ич!..

— Син өйләнерсең дә китәрсең, ә мин... мин нишләрмен, кем булып калырмын?!

Әйтүем дә булды, кинәт кенә йөземне каплап елап та җибәрдем. Күңелемнең ташып китәргә торганын күптән сизә идем инде — ахырда менә тыела алмадым. Салих та бер мәлгә аптырабрак калды. Шулай да ул тиз генә мине иңбашымнан кочып алды да юата башлады:

— Тынычлан, сөеклем, тынычлан!.. Кирәкми, түкмә күз яшьләреңне!.. Җайланыр, барысы да җайланыр, кошчыгым!.. Тик бетермә син болай үзеңне, бетермә!..

Мин әкренләп булса да тынычландым, читкә борылып кына яшьләремне дә сөрттем. Әзрәк кенә бушанып, җиңеләеп тә калган шикелле булдым. Тик менә Салихның кочагына кергәндәй утыру кыен иде миңа — кеше йөреп торган бакча ич бу... Ләкин Салих, үзе шуны сизеп, кулын минем җилкәмнән алды.

Шуннан соң ул, терсәкләренә таянып, озак кына уйланып утырды. Аннары катгый бер карарга килгәндәй әйтеп куйды:

— Иң яхшысы китү — китәргә кирәк!.. Ишетәсеңме, бәгырь?

Бер дә көтелмәгән сүз иде бу минем өчен.

— Кая... китәргә? — дидем мин, шактый аптырап.

— Оренбурга, менә минем белән бергә. Башка чарабыз юк безнең.

— Нигә... Оренбурга!

— Безне шунда җибәрәләр.— Ул, тураеп, миңа таба борылды. Йөзе, күзләре аның бик җитдиләнеп киткән иде.— Минем, көт, кайтырмын, дип, вәгъдә биреп кенә һәм синнән вәгъдә алып кына китәсем килми... Әкренләп бөгәрләр сине, сындырырлар... Юк, калдырырга теләмим мин сине үземнән, бергә китәбез!..

— Мөмкинме соң ул?

— Әлбәттә!.. Татар бригадасының комиссарлары мине бик яхшы беләләр, сөйләп аңлатсам, алар һич каршы килмәячәкләр. Бер татар кызын хорафат коллыгыннан коткару дип караячаклар бу эшкә... Йә, ни дисең, кадерлем?..

Болар барысы да шулкадәр сәер, яңа, һич көтелмәгәнчә иде ки, мин, билгеле, бер мәлгә тәмам югалып, аптырап калдым. Ни диеп әйтергә? Кинәт кенә, уйламыйча гына? Язмышым турында сүз бара ич! Каядыр китәргә, ияреп китәргә... җыен гаскәриләр арасында... Ә ахыры ни булып бетәр?.. Юк, уйлыйм әле мин, уйлыйм!.. Мин кыз кеше — Салих моны бик нык исендә тотарга тиеш.

Мин тагын сорадым:

— Кем булып барам инде мин... синең белән?

— Бөтенесе синең теләктән тора, Гөләндәм! — диде ул, минем сорауны көткәндәй, тиз генә.— Теләсәң, Казанда ук никах укытып өйләнешеп китәбез. Сабыр итик, дисәң, мин анысына да риза. Син барыбер минем юлдашым, дустым, вәгъдәләшкән кызым булып барасың. Син минем янымда, минем канатым астында, җаның тыныч булсын!

— Ә баргач?

— Баргач инде, бәгырь, Оренбург каласында хәрби дусишләр белән кечкенә генә туй ясап, бергә матур гына тора башларбыз. Без бәхетле булырбыз, Гөлгенәм!..

— Хыял гына түгелме бу, җаным? Син кем икәнеңне онытма!

— Сине һаман минем «солдат» булуым куркыта, шулаймы? — диде ул, көлемсерәп.— Мин гади солдат кына түгел бит, музыкант!.. Оркестрда уйнаучы, трубач!

— Син көләсең!..

— Көлмим, бәгырь, дөресен әйтәм. Минем өчен шартлар беркадәр җиңелрәк булыр дип әйтәсем килә. Билгеле, хәрби тормышның җайсыз, кыен, авыр яклары да булыр, ләкин аларына гына түзәрбез инде, акыллым!..

— Син ир кеше, сиңа әйтүе ансат!

Салих авыр гына сулап куйды. Күрәсең, минем һаман «кирегә тырнавым» аңа ошамый башлады. Бераз вакыт дәшми утырганнан соң, ул миңа сабыр гына болай диде:

— Беләсеңме, Гөләндәм, мин бит сине үземә хатын

итеп, ияртеп йөрер өчен генә чакырмыйм. Менә бу солдат гимнастеркасын, күн итекләрне салып ташлаганчы мин сиңа өйләнмичә дә тора алам. Мәхәббәт ул көтә дә белә... Әмма хәзер сүз бит синең язмышың, синең киләчәгең турында бара — шулай түгелме? Алайса без максатларны да зуррактан куйыйк. Синең музыкага талантың бар — менә шул талантың сүнеп, югалып калмаска тиеш... Бу бик мөһим, кадерлем, аңлыйсыңмы, бик мөһим!.. Безнең комиссарларның әйтүенә караганда, Оренбургта татар-башкорт яшьләре өчен шәрык музыка мәктәбе ачылырга тиеш икән. Әгәр ачылса, мине ул мәктәпкә һичшиксез тартачаклар. Мин инде күңелемнән сине кайтып яки чакырып алу турында да уйлап куйган идем. Кыскасы, бәгырем, безне бер мәхәббәт кенә түгел, уртак теләкләр дә бәйләргә тиеш... Син килешәсеңме моның белән.

— Килешәм,— дидем мин, нәрсәдер уйланып.

— Шулай булгач, эш нидә?.. Әллә минем яратуыма ышанмыйсыңмы? Әллә үзеңнең мәхәббәтең сүрелдеме?..

— Юк, Салих, юк,— дидем мин, айнып киткәндәй ашыгып.— Ышанып килдем мин сиңа, мәхәббәтем тартып китерде мине!..

— Алайса менә сиңа минем саф йөрәгем, сузган кулым, Гөләндәм, әйт син дә соңгы сүзеңне!

Ах, авыр иде минем хәлем, авыр иде, белсәгез!.. Күңелем белән гүя барысына да риза, барысына да әзер мин. Әмма ләкин... нидер мине куркыта, тота, ычкындырмый... Ярдәм кирәк миңа, аның үзеннән ярдәм кирәк — шунсыз булмый.

— Әйт, җаным,— дидем мин, хәтта ялварып,— мин ни эшләргә тиеш соң?..

Салих бераз гына көттереп җавап бирде:

— Безнең бер генә юлыбыз бар: өйдән чыгып китү...

Ул нигәдер тукталды, мин тын да алмыйча торам, аннары тагын кабатлады:

— Аңлыйсыңмы, әти-әниеңә белдермичә генә сиңа өегездән чыгып китәргә кирәк.

— Качып?.. Йа Хода!

— Безнең башка чарабыз юк,— диде Салих, кызу гына.— Мәхәббәтебез хакына син моны эшләргә тиешсең!.. Берәү дә — Алла да, бәндә дә — моның өчен сине гаепләмәс. Тормышта андый хәлләр булып тора!..

Әйе, булып тора!.. Качып киткән, диләр,ябышып чыккан, диләр... Миңа да шул гына язган микәнни?! Бер мәлгә күз алдыма әнием килде, әтием килде... Минем качып киткәнне белгәч, акылларыннан шашмаслар

микән?.. Бәддога укымаслар микән?.. Әмма Алла шаһит, минем бүтән чарам юк. Мин Салихны ярattым, Салихны гына ярата алам. Мин әтием белән әниемне дә бик яратам, әмма... нишлим соң башка чарасы булмагач!!

Салих, минем хәлемне ачык сизеп, дәшми-нитми тын гына янымда утыра. Мин беләм: ул көтә, минем соңгы сүземне көтә. Ләкин ашыктырырга, ирексезләргә теләми. Соңгы сүз — соңгы сызык, мин аңа язмышымны тапшырам — ул моны аңламыйммыни?.. Аның үзенә дә җиңел түгелдер — бик зур мәсьүлият ала ич ул өстенә!..

Ахырда мин сорадым аңардан:

— Кайчан соң?..

— Безнең вакытыбыз бик аз, Гөләндәм,— диде Салих.— Якшәмбе көнне безне озаталар, ә бүген атнакич... Димәк, калган ике көн эчендә... Иң яхшысы — иртәгә.

— Иртәгә?! — дидем мин, ирексездән хәтта сискәнеп.

— Кичектерергә ярамый, бәгырь!.. Кичектерү — хәтәр, тимерне кызуында сугарга кирәк... Аннары Казанда, һич югы, бер генә көн без бергә булырга тиешбез. Минем сине апам белән җизнигә күрсәтеп каласым килә.

Иртәгә, иртәгә... Соңгы сызыкның өстендә үк басып торам икән ләбаса мин! Тәңрем, көч бир миңа!..

— Син курыкма, кадерлем, кыю бул! — диде Салих, ничектер йомшак-тыныч кына.— Без саф, без гөнаһсыз кешеләр. Без никахсыз кушылмабыз. Әти-әниең дә ахыр чиктә безне кичерерләр. Ул хәтле иске, кара кешеләр түгел ич алар... Аңларга тиешләр... Йә, шулай сөйләштекме?

— Яхшы! — дидем мин, әллә ничек үзем дә аңламас бер җиңеллек белән.

— Көндезме, кичме? — дип сорады ул да, гади генә итеп.

— Көндез мөмкин булмас, җаным... Иң яхшысы — кич. Әти-әниләр яткач... Минем бит әле төенчегем дә булыр... (Гаҗәп, гаҗәп — без әнә шулай бик гади-җиңел генә сөйләшә башладык.)

— Күп әйбер алма.

— Бер төенчек инде.

— Алайса болай сөйләштек, мин сине кичке тугыздан көтә башлармын, беләсеңме кайда?

— Тугыздан ук иртә булмасмы?

— Зарар юк. Мин килеп, унга, уникегә, кирәксә, таңга чаклы да көтәрмен. Сезнең тыкрыктан ерак түгел, Кабан буенда йөреп торырмын.

— Караңгыда танырсыңмы соң?

— Һе, танымаска!.. Җилеңнән таныйм мин сине, бәгырем!

— Ә очрашкач кая барырбыз?

— Минем апаларга... Әлбәттә, алар синең киләсеңне алдан белеп торачаклар...

— Миңа бик оят булыр инде.

— Борчылма, бәгырем! Минем апа да, җизни дә бик белә, аңлый торган кешеләр. Кызлары шикелле каршы алырлар сине... Үзеңә генә аерым урын әзерләрләр... Менә шулай... Сөйләшеп бетердекме инде?

— Бетердек шикелле...

— Менә... алдым-бирдем дә ясадык! — диде ул, кинәт балаларча сөенеп.— Изге сәгатьтә, бәгырем!

— Изге сәгатьтә, җаным!..

Әйе, барысы да хәл ителде. Нинди газаплардан соң һәм нинди... ансат кына!.. Ә бакча эченә кичке караңгылык иңә башлаган икән инде. Мин ашыгып урынымнан тордым.

— Ходаем, бик озак утырганбыз!.. Мин кайтыйм инде.

Салих та урыныннан торды. Бәхете ташыган кешенекедәй яктырып киткән йөзе, дымлана төшкән күксел-зәңгәр күзләре белән ул миңа сөеп, сөенеп, сүзсез генә төбәлде, сүзсез генә кулымнан тотып, агач ышыгына табарак тартып китерде һәм аз гына калтырануын сиздергән тавыш белән:

— Гөләндәм!.. Гөлгенәм! — диде.— Син — минеке! Ярабби!.. Төш кенә түгелдер ич бу?

— Түгел,— дидем мин, инде үзем аңа сыена төшеп.

Шуннан ул мине ике иңбашымнан кысып алды да кызу-кайнар гына сөйләп китте:

— Гөләндәм, кадерлем, бу безнең озын сәфәрнең башы гына. Башы аның, бәлки, җиңел булмас, әмма ул безне зур бәхеткә илтергә тиеш... Сиңа сер итеп кенә әйтәсем килә: мин гади бер музыкант кына булып калмаячакмын, мин музыканы, боерган булса, үзем язачакмын!.. Ышанасыңмы? Хәзер үк инде мин күкәй салырга урын эзләгән тавык шикелле кыткылдап кына йөрим.— Һәм ул тыелырга теләсә дә, ничектер тыела алмыйча, бик бәхетле итеп көлеп тә җибәрде. Мин дә көлмичә кала алмадым. Шушындый чакта да каян шук сүзен таба, ничек итеп балаларча шатлана белә ул... минем Салихым!..*

Көлеп туктагач, ул маңгаемнан йомшак кына итеп үпте.

— Хуш, бәгырем! Хуш, акыллым!.. Рәхмәт фәрештәләре сакласын үзеңне!..

Ул мине бакча капкасыннан чыкканчы озата килде һәм әлеге мәһабәт һәйкәл янында басып калды. Мин яңадан трамвайга утырып, түбән төшеп киттем.

---

* Мәгълүм булганча, Салих Сәйдәшев үзенең «Озын сәфәр» дигән иң беренче көен 1920 елны Оренбургта яза.— *Ә.Е.*

## XVI

Әнием мине сынаулы караш һәм җитди чырай белән каршы алды. Борчылуы йөзенә үк чыккан иде. Шулай да ул миңа каты бәрелмәде.

— Озак йөрдең, кызым, әтиеңнән яхшы түгел,— дип кенә куйды.

— Озаграк йөргәнмен икән шул,— дидем мин, акланып тормыйча гына. Миңа үземне ничек тә табигый тотарга кирәк. Бер төрле дә шик-мазар уятмаска тиеш бит мин... Әлбәттә, бу җиңел булмаячак. Бигрәк тә җитди сүз чыга калса (ә ул чыкмыйча калмас), минем хәлем бик мөшкел булачак. Каракның бүреге яна дигәндәй, һич юктан да үземне фаш итеп куюым бар. Менә ни өчен калган бер тәүлек — озын бер сират күпере булып тоела миңа!..

Бераздан мине чәйгә чакырдылар. Кичә дә төшмәгәч, бүген инде төшмичә калу ярамаячак, билгеле. Ә шулай да әтием каршына төшеп утыру ихтыярсыздан каушата мине... Сүз башламас микән ул?.. Хәер, бездә моңарчы, гадәтме, шәригатьме кушуы буенча, ашаган-эчкән чакта озын сүзләр булмый торган иде.

Тәвәккәлләп төштем, утырдым. Әнием чәй ясап бирде. Әтием кулында гәзитә — миңа ул шуның өстеннән бер карап кына алды. Гүя болай да бөтенесен күреп-белеп торган төсле итеп кенә... Ләкин сүз башларга исәбе юк шикелле — карашыннан шулайрак сиздем.

Тик соңрак, гәзитәсен бер читкә куйгач, ул кызык кына шундый сүз әйтте:

— Боларның бөтен язганнары азатлык та хөррият, Ходаның хикмәте!.. Әмма ләкин бу гүзәл нәрсәләр влас кулында лабаса! Ә влас бик усал нәрсә ул... Бүген ул сиңа хөррият вәгъдә итә, ә иртәгә тартып ала да белә. Мисалларын күреп уздырдык. Әнә Николай да теге елны, азатлык бирәм, дип, манафис чыгарган иде дә, тәхетенә куркыныч туа башлагач, халыктан сайланган Думаны тотты да пыр туздырып куды. Тәхеттән берәүнең дә тәгәрәп төшәсе килми... Хикмәт ялтыравыклы вәгъдәләрдә түгел, ә гамәлдә — гамәл ни күрсәтер бит әле.

Кем өчен, ни өчен сөйләде ул моны — һич аңлый алмадым. Һәрхәлдә, әнием өчен яки Сабира өчен түгелдер инде. Бәлки, минем өчендер?.. Вәгъдәләргә ышанып бетәргә ярамый, диде ич!

Әмма сүзнең зурысы һәм мине нык борчыганы икенче көнне булды. Бу минем соңгы көнем... Иртәдән бирле әллә нинди авыр бер киеренкелек, гүя тимер кыршау шикелле, җанымны гел әкрен генә кысып, буып тора. Бик авыр

булыр төсле миңа бу көнне үткәреп җибәрү... Шуңа күрә бүлмәмнән дә күп чыгып йөрмәскә, әтием-әнием күзенә дә артык күренмәскә тырышам. Ләкин әтием җомгага киткәч, әнием үзе минем бүлмәмә көтмәгәндә генә килеп керде. Мин комодтагы әйберләремне караштыра идем — тиз генә аны ябып куйдым. Ул моңа игътибар итмәде шикелле... Башта үзе утырды, аннары миңа утырырга кушты. «Төшмисең дә, авырмыйсыңдыр бит»,— дип, хәлемне сорашты, шуннан соң гына әйтәсе сүзен башлады:

— Кызым, әтиең җомгага китәр алдыннан миңа синең белән тагын бер мәртәбә сөйләшергә кушты. Син үз сүзеңне әйтергә ашыкма, башта яхшылап тыңла. Бүген әйтмәсәң, соңыннан әйтерсең — без бит сине ашыктырмыйбыз... Син бала түгел инде, Аллага шөкер, балигъ булган кыз, иргә чыгуның нәрсә икәнен үзең дә яхшы аңлыйсың... Оялып яки киреләнеп торырга кирәкми, кызым, барыбер безне бер тыңламыйча хәлең юк... Әмма син шуны белергә тиешсең, Гөләндәм: иргә чыгу кыз бала өчен гаять җитди эш ул. Гомергә бер генә килә. Шуңа күрә һәр ягын уйларга кирәк бу эшнең. Бер хата адым кыз баланы гомере буена бәхетсез итәргә мөмкин.

Әнә шулай сөйләп китте әнием. Мин йөземне читкә борыбрак булса да аны, үзе кушканча, сүзсез генә тыңлап утырдым. Хәер, каршы сүз әйтергә урын да юк әле: иргә чыгу, әлбәттә, җитди эш, әлбәттә, ялгышмаска кирәк.

— Иң мөһиме — кемгә чыгасың,— дип, сүзен дәвам итте әнием,— бөтен хикмәт шунда. Иргә чыгу — гаилә кору, ә гаилә нык, гомерлек булырга тиеш. Моның өчен чыгасы кешең иң элек гаиләсен асрый, тәэмин итә алырлык булырга тиештер инде. Аның укыган булуы яки берәр кәсеп иясе булуы шарт — шунсыз ул хатынын да карый, балаларын да үстерә алмаячак, бигрәк тә хәзерге заманда.

Бу урында минем әниемне бүләсем килде. Тартынып кына булса да:

— Асрар, карар әле, дип кенә иргә чыгып булмый бит инде,— дидем.— Ә ярату, ә мәхәббәт кайда?

— Мәхәббәтне без дә инкарь итмибез,— диде әнием, миңа туры гына карап.— Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам дә инкарь итмәгән аны... Ләкин мәхәббәтне аера белергә кирәк, кызым. Кешенең тышкы кыяфәтенә яки матур сүзләренә генә гашыйк булу — бу әле чын мәхәббәт түгел. Андый мәхәббәт иртәме-соңмы төтен шикелле тарала да бетә... Хатын-кыздагы мәхәббәт ул күп вакытта ир кешенең мәхәббәтенә җавап рәвешендә туа. Ирең сине яратса, син дә аны ярата башлыйсың, ирең сиңа тугрылыклы булса, син дә аңа тугрылыклы була-

сың — шуңа күрә дә борынгылар, мәхәббәт никахтан соң килә, дип белмичә әйтмәгәннәр. Һәм бер дә борчылма, кызым, бу чын, таза мәхәббәт булачак.

Әнием беразга гына туктап торды. Мин, башымны түбән иеп, аның хәзер генә әйткән сүзләре турында уйланам. Ул, әлбәттә, ике кешене исендә тотып сөйләде боларның барсын да. Сембер егете укыган кеше, «кәсебе» бар, гаиләсен карый алачак, мине яратачак һәм мин дә никахтан соң аны яратачакмын. Ә Салих, юк, ярый торган кеше түгел. Музыкант кына. Бу һөнәре белән ул гаилә асрый аламы соң — бигрәк тә безнең татарда... Аннары, бездә гомумән музыкантларга, артистларга караш бик түбән. Артистка яки музыкантка кыз бирү ул дус-дошман алдында дәрәҗәңне генә төшерү дигән сүз... Кыскасы, Салих әфәнде, гәрчә төскә бик чибәр булса да, безгә лаек кеше түгел. Аның ни даны да ни малы! Ә минем мәхәббәт ул бары саташудан, балалыктан, тилелектән генә (дөрестән дә шулай шул —Салихны яратыр өчен мин никахны да көтеп тормадым), күп тә узмас, минем мәхәббәтем төтен шикелле таралыр да бетәр. Тик безне бер-беребездән аерырга гына кирәк.

Менә аларның (әтием белән әниемнең) карашлары. Ләкин Салих турындагы фикерләрен миңа бервакытта да ачыктан-ачык әйткәннәре юк. Хәтта менә хәзер дә әнием аның исемен телгә алмаска тырыша. Ә бит минем алар теләгенә ни өчен каршы булуымны ул белә, һәрхәлдә, сизеп тора. Гаҗәп бу, гаҗәп!..

Әнием тагын сүз башлады:

— Сине сораган егетнең әнисен дә, әтисен дә мин бик яхшы беләм, кызым. Әтисе дәүләт эшендәге кеше иде, моннан ике ел элек кенә сукыр эчәгесен кистергәндә вафат булып китте, мәрхүм... Әнисе дә кыз чагында гимназиядә укыды. Затлы, мөхтәрәм кешеләр, Сембердә үз йортлары. Таза, бөтен тормыш белән яшәделәр. Бердәнбер улларына бик яхшы тәрбия бирделәр, укыттылар, кеше иттеләр. Газиз әфәнде хәзер үз-үзенә хуҗа, мөстәкыйль бер кеше, әнисе белән генә тора... Соң үзең дә күрдең бит инде — коеп куйган чын зыялы!.. Андый егетне табулары бик читен бу заманда. Үз бәхетеңә үзең каршы килмә, кызым, каршы килмә!

— Мин бит шуңа ышана алмыйм, әнием! — дидем, бөтенләй җавапсыз калмас өчен генә.

— Нәрсәгә?

— Газиз әфәнде белән бәхетле булуыма.

— Ашыкма, кызым!.. Иң элек уйла. Бәхетнең нәрсә икәнен уйла. Аннары безне дә онытма. Синең бәхетең ул безнең өчен дә бәхет. Әтиең дә шуны әйтергә кушты,

Гөләндәм үзе турында гына уйламасын иде, диде. Син белергә тиешсең, без хәзер бик авыр вакыт кичерәбез, менә елдан артык инде әтиең кәсепсез йөри. Моңарчы иске запас белән яшәп килдек, әмма тора-бара нишләрбез? — бер Ходаның үзенә генә мәгълүм!.. Шуңа күрә яшермичә әйтәм, кызым, Газиз әфәндегә чыксаң, безгә дә ул бер терәк булыр иде. Олыгаеп барган көнебездә без сиңа сыенмыйча кемгә сыеныйк. Ир балабыз юк...

Кинәт әниемнең тавышы өзелде. Ул сыгылып төште, әкрен генә калтыранып елый да башлады. Мин тиз генә аны иңбашыннан кочып алдым.

— Әнием, бәгырем, куй, кирәкми!..

Минем үземнең дә елыйсым килеп китте, елый-елый аңардан кичерү сорыйсым, нәрсәләрдер вәгъдә итәсем килде. Ләкин... яшем дә чыкмады, сүзем дә — гүя корыган, югалган инде алар миндә.

Әтием җомга намазыннан кайтып керде булса кирәк, түбәндә аның тамак кырган тавышы ишетелде. Әнием дә күзләрен сөртә-сөртә урыныннан торды.

— Әтиең кайтты, аш куярга кирәк, син дә озакламый төш, кызым! — диде ул миңа, чыгып китешли.

Минем әнием нык хатын, сабыр хатын, күз яшен бик сирәк чыгара... Әмма бу юлы түзмәде, мескинәм!.. Ана йөрәгенең тирән ярасы ачылган кебек булды миңа. Бигрәк тә соңгы сүзләре мине тәмам аптыратты, авыр хафага салды. Күңелемә шунда ук төрле шик-шөбһә, нәрсәдәндер курку-шомлану керде, тәҗрибәсез башыма берьюлы төрле уйлар, урман кырмыскалары шикелле, үрмәли башлады. Әмма ләкин мин уйламаска тиеш идем, уйламаска, уйламаска! Бөтенесе хәл ителгән, чигенү юк, икеләнү-уйлану берсе дә кирәкми!.. Минем үз язмышым бар, мин үз язмышымнан баш тарта алмыйм, ишетәсезме?! Шаять, сез аңларсыз, сез кичерерсез мине, кадерле әтием, әнием!..

...Төшке аштан соң мин үз бүлмәмдә ашыкмыйча гына җыена башладым. Салих күп әйбер алмаска кушты. Әлбәттә, чегән шикелле зур төен күтәреп чыгып китеп булмас. Ләкин кечкенәсен дә хәзердән үк төйнәп кую ярамас. Шуңа күрә мин аласы эчке һәм тышкы күлмәкләремне, сөлге, кулъяулык, башка шуның кебек вак-төяк әйберләремне комодтан чыгармыйча гына әзерләп куйдым. Башыма менә бу кара челтәр шәлемне ябынырмын инде, ә менә бу зур кашемир яулыкка әйберләремне төйнәрмен. Тагын нәрсә?.. Өстемә кара жакетымны, аякларыма шнурлы ботинкаларымны киярмен. Бик җиңелчә генә инде, ләкин нихәл итәсең? Кала, барысы да өелеп кала. Хәтта зат әйберләрем дә. Ходай җан биргәнгә юнь бирер әле... Юк,

шулай да менә бу зур энҗе муенсам белән чылбырлы алтын беләзегемне алырмын... дөнья хәлен белмәссең...

Ә... йөрәгемне нидер сава, өзлексез авырттырып сава. Әйтерсең аңа яман бер сызлавык сөлек булып ябышкан. Хәерлегә генә булса ярар иде!.. Уйламыйм дисәм дә, ирексездән уйланам: әгәр әтием-әнием мине ныгытып кыссалар, мәҗбүр итәргә тырышсалар, миңа җиңелрәк булыр иде. Ә алар ышанып торалар, җавабымны көтәләр, тыныч кына йокларга ятарлар. Ә мин... Йа Хода!..

Әйе, әйтергә дә онытканмын, мин бит бүген өйдән чыгып китәсемне Сабирага белдермәдем. Аны бу эшнең шаһиты итәсем килмәде. Минем юкка чыгуымны белгәч тә, иң элек аңа бәйләнәчәкләр, аңардан таптырачаклар. Шуңа күрә ул бернәрсә дә белмәскә тиеш. Аңа әле болай да бик авыр булачак, бичаракаема!

...Син кичер мине, Сабира җаным, барысы өчен дә кичер! Күрсәткән яхшылыкларыңны онытмам, дустым, ишетәсеңме?

Тагын нәрсә калды?.. Тагын шул бар икән әле: караңгы төшкәч, әтием урам капканы үзе зур йозак белән бикләп куя. Ачкычы исә кухняга кергәч тә уң як стенада, гел бер чөйдә генә эленеп тора — капканы ачарга кирәк булса, һәрвакыт шуннан гына алабыз. Кухняга бер төшкәндә мин шул чөйгә күз салдым — ачкыч үз урынында иде. Ә бу минем өчен бик мөһим, чөнки ишегалдыннан урамга чыгып китәр өчен капканы минем үземә ачарга туры киләчәк. Безнең өебез ихата эчендәрәк тора, шуңа күрә капкадан башка бүтән чыгу юлы да юк.

Ә вакыт үтә, никадәр генә әкрен үтмәсен, әмма барыбер үтә. Менә кич тә булды, менә караңгы да төште. Элек-электән килгән тәртип буенча кичке чәй дә эчелде. Һәр көндәгечә, әтием, газитәләрен алып, үзенең йомшак креслосына утырды, әнием үзенең һич бетмәс сүтүтегү эшләренә тотынды. Сабира исә кухняда соңгы эшләрне бетереп маташа. Ә мин үз бүлмәмдә, кайчан болар ятарлар икән, кайчан өй эче тынар икән, дип, төнге җәнлек шикелле көтеп утырам. Үзем тыныч, гаҗәп тыныч, һични уйламыйм, әгәр йөрәкнең әкрен генә савып торуын сизмәсәм, бөтенләй юнь кеше мин.

Сәгатькә карыйм, тугыз тулган икән инде. Салих күл буена килеп җиткәндер яки җитә торгандыр. Кирәксә, таңга чаклы көтәрмен, диде ул. Көттермәскә иде шул... Әтием белән әнием бер ярты сәгатьтән үз бүлмәләренә күчәргә тиешләр. Димәк, озак көтәсе дә калмады.

Мин, торып, комодтан әзерләп куйган нәрсәләремне алып, кашемир яулыкка төйнәдем. Бераздан аягыма бо-

тинкаларымны кидем, тагын бераздан, жакетымны киеп, башыма кара челтәр шәлемне ябындым. Аннары, бүлмәдән баскычка чыга торган ишек янына килеп, өй эченә колак салып тора башладым. Шул чакта әнием бирәр йомыш белән менә башласа дигән уй мине тәмам тетрәтеп җибәрде. Ләкин мин тиз тынычландым. Бу вакытта безнең өйдә йөрү юк, бу вакытта алар яткан булалар... Тагын күпмедер вакыт сабыр гына көтәм — өй эче тып-тын!.. Сәгать унберенчегә киткән... Аллага тапшырдым.

...Төенемне алып, утны сүндереп, мин әкрен генә ишекне ачам, баскычтан бик әкрен генә төшәм. Ә шулай да тез буыннарым калтырый, тыным кысылып бара — гүя менә хәзер кемдер мине артымнан кинәт кенә тотып алыр шикелле... Бик сак кына, бик әкрен генә кухняга да барып җитәм. Кухня эче ул хәтле караңгы түгел, ике тәрәзәдән төшкән яктылык җитәрлек, әйберләрне шәйләп була. Бер дә ялгышмыйча ачкыч эленеп торган чөйгә барам. Менә ул чөй!.. Ләкин... Бу ни эш, чөйдә ачкыч юк! Ни өчен юк?! Әллә ялгыштыммы?.. Калтыранган кулларым белән стенаны капшыйм: шушы чөй инде, шушы чөй!.. Әмма юк бит, юк кына бит капка ачкычы!.. Мин өнсез калдым, багана шикелле катып калдым, егылып китмим дип, тизрәк стенага сөялдем. Үтә бер кызулык белән үрсәләнеп, өзгәләнеп уйлыйм: нишләргә, нишләргә соң миңа, йа Раббем?.. Безнең урам коймасы биек, менәрлек тә, төшәрлек тә түгел... Бер ягыбызда мәчет ихатасының калын таш коймасы, икенче ягыбызда Касыйм хәзрәт мәдрәсәсенең стенасы... Капкадан башка урамга бернинди юл юк бит, юк!..

Маңгаема, чәч төпләремә салкын тир бәреп чыкты. Әйтерсең минем шушында, төнге тынлыкта стенага сөялеп, гаҗизлеккә төшеп, өзгәләнеп торуымны әти-әнием дә ишетеп-күреп яталар кебек тоелды миңа...

Тизрәк-тизрәк Сабираны уятасым, аңа ташланасым, аңардан ярдәм сорыйсым килде. Берни күрмичә стенадан кубып, алга омтылуым булды — аяк астындагы каһәр суккан урындык дөбердәп авып та китте. Шул секундта ук зал ягыннан әниемнең тавышы да ишетелде:

— Кайсыгыз анда?.. Гөләндәм, син йөрисеңме?..

...Шуннан соң инде мин үз бүлмәмә ничек менеп, урын өстенә ничек егылуымны ачык кына хәтерләмим дә.

Әйтегезче, ни эшләдем мин, ни эшләдем?.. Ни булды миңа, Ходаем, ни булды?.. Нинди явыз шом мине шулхәтле өркетте, акылымны тартып алды, ихтыяр көчемне сындырып ташлады?.. Кем әйтә, кем аңлата ала моны миңа?.. Юк бит, юк — күрүче дә, белүче дә, аңлаучы да юк!

Әмма минем үземә моны аңлар өчен вакыт кирәк иде, шактый вакыт. Атналар узды, айлар узды, бары шуннан соң гына мин үземне һәм үз хәлемне бөтен рәхимсез дөреслеге белән аңлаган кебек булдым. Әйе, ул төнне әлеге каһәр суккан капка ачкычының урынында булмавы минем юлымны кисте. (Әтием аны ятар алдыннан гына алып куйган икән.) Әмма ләкин бердәнбер сәбәп бары шул тимер кисәгендә генәмени соң?.. Әлбәттә, түгел!.. Төп сәбәп, чын сәбәп шунда ки, башта ук миндә ныклы, катгый тәвәккәллек булмаган. Менә ни өчен мин соңгы минутка кадәр һаман да кемнәндер, нәрсәдәндер куркып шомлануым аша, каядыр тирәндә яткан һәм йөрәгемне өзлексез савып торган икеләнүем аша атлап чыга алмадым. Монда миңа, бәлки, Салихның гаскәри хезмәткә язылуы, яки әниемнең соңгы тапкыр елап әйткән сүзләре дә нык тәэсир иткәндер, ләкин ничек кенә булмасын, өзелеп, тилмереп яратуыма карамастан, мин Салих дөньясына атлап керер өчен рухым белән дә, аңым белән дә өлгереп җитмәгән булып чыктым. Аяусыз хакыйкать әнә шул!.. Югыйсә бит мин икенче көнне көпә-көндез дә чыгып китә алган булыр идем. Соң түгел иде бит әле, һич тә соң түгел иде!.. Ләкин минем инде моңа да кодрәтем җитмәде. Мин инде рухи сынган, тәкъдиргә буйсынган, язмышым белән килешкән идем.

...Бетерергә вакыттыр, ахрысы. Хатирәләремне, дим — гомерем буена онытылмаячак хатирәләремне!.. Барысы да күз алдымда, барысы да төштә генә кебек... Ах, нинди үкенеч бу, нинди үкенеч!.. Әмма соң үкенүдән хәзер ни файда?.. Юк, үкенү кирәкми, үкенү саргайтмасын мине!.. Минем әле горурланып яшәрлек, мәңге сүнмәс юанычым бар; Салих... мине лә сөйгән Салих югалмады минем өчен, юк, югалмады!.. Үзе кебек нәфис, гүзәл, якты музыкасы белән яңадан әйләнеп кайтты ул миңа!..

### Берничә генә соңгы сүз

Бу әсәр Казаннан читтә яшәгән бер ханымның кечкенә генә истәлеге нигезендә язылды. Кызганычка каршы, минем үземә аны күрергә туры килмәде — мин эзләп барганда, ул инде дөньяда юк иде (1963 елны вафат булган). Кызы Ләлә ханым белән очрашкач, ул миңа әнисенең Салих Сәйдәшне еш кына искә төшерүен, аның көйләрен пианинода яратып уйнавын, ә үләр алдыннан исә Сәйдәш музыкасын ишетергә теләвен сөйләп бирде.

Билгеле, бу әсәрне язганда мин истәлек иясенең исемен үзгәртеп алуны кирәк таптым.

*Февра*

# ЭЧТӘЛЕК

Әйтелмәгән васыять
7
Вөҗдан
45
Без дә солдатлар идек
153
Гөләндәм туташ хатирәсе
237

Литературно-художественное издание

*Амирхан Еники*
*(Еникеев Амирхан Нигметзянович)*

**СОЧИНЕНИЯ**

в пяти томах
том 3

*Повести*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *С.Н.Мифтахова, Л.Х.Касыймова, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001
елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.06.2002.
Форматы 84 108$^1/_{32}$. ВХИ кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 21,0+форз. 0,2. Шартлы буяу-оттиск 21,53. Нәшер-хисап
табагы 22,48+форз. 0,36. Тиражы 5000. Заказ Б-311.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.